ТАТАРСТАН ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕНЕҢ
ТАТАР ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ ҺӘМ ТӨБӘКНЕ ӨЙРӘНҮ ИНСТИТУТЫ

Г.Х.Галимуллина
А.Б.Насибуллина

# ХӘЕРБИ АВЫЛЫ ТАРИХЫННАН СӘХИФӘЛӘР

# СТРАНИЦЫ ИСТОРИИ СЕЛА КИРБИ

Казан – 2019

УДК 94(470.41)=512.145
ББК 2Рос.Тат=632.3

ТР ФА Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институтының
Гыйльми советы карары белән дәүләт йөкләмәсен үтәү
кысаларында нәшер ителде

**Редакция коллегиясе:**
И.А.Гыйләҗев, Р.Х.Кушмина, Р.Р.Салахиев,
М.З.Хәбибуллин, Б.Л.Хәмидуллин, Ф.Г.Ялалов

**Фәнни редакторлар:**
Р.В.Шәйдуллин, Л.М.Айнетдинова

**Әдәби редактор:** Ф.Р.Бәдретдинова

**Г 15** **Галимуллина Г.Х., Насибуллина А.Б. Хәерби авылы тарихыннан сәхифәләр**. – Казан: ТР ФАнең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты, 2019. – 500 б., илл.

Архив документларына һәм тарихи чыганакларга нигезләнгән әлеге хезмәт Татарстан Республикасы Лаеш районының Хәерби авылына багышлана. Басма туган як тарихы, милли мәдәният һәм традицияләр белән кызыксынучы киң катлам укучыга атап чыгарыла.

Данное исследование, проведенное с привлечением архивных и краеведческих источников, посвящено истории села Кирби Лаишевского района Республики Татарстан. Издание адресовано всем интересующимся историей, культурой и традициями родного края.

ISBN 978-5-902375-43-2

© Галимуллина Г.Х., Насибуллина А.Б., 2019
© Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты, 2019

# СҮЗ БАШЫ

Авыл… Син күпләребезнең гомер бишеге. Халыкның бар сагышын, шатлык-куанычларын, ярсуын, дәртен-куәтен, өмет-омтылышларын сыйдырган Моң чишмәсе синнән агып чыга, халыкның акылын-зирәклеген, булдыклылыгын, сабырлыгын, җитезлеген, җорлыгын һәм башка бик күп асыл сыйфатларын эченә җыйган, татарның үзенеке генә булган, шуңа да бик кадерле гореф-гадәтләр, йолалар синдә саклана, синнән тарала. Даннары дөньяга билгеле шәһәрләр дә синең нигез ташларыңнан үсеп күтәрелгән, и газиз авыл!

Нәсел тамырларын барлау, шәҗәрәләр төзү халкыбызның әүвәл-әүвәлдән килгән матур гадәте. Элек-электән күңелләргә сеңдерелеп киленгән «җиде буын бабаңны белү» гыйбарәсенең онытыла язган заманнары булды. Бүген исә нәсел җепләрен барларга, ялгарга керешүчеләр көннән-көн арта. Бу җепләр, башка җепләр белән үрелеп, авыллар, шәһәрләр тарихын хасил итә. Авыллар тарихы – халкыбыз тарихының аерылгысыз бер өлеше, әүвәл татар халкы башлыча авылларда гомер иткәнлектән, әйтергә кирәк, бик мөһим өлеше ул. Шуны аңлап, үз нәсел җебен барлый башлаганнар еш кына тулаем авыл тарихын өйрәнүгә кереп китә, тупланган мәгълүматны киләчәк буыннарга калдырырга омтыла. Сезнең кулыгыздагы әлеге китап та Лаеш районында урнашкан Хәерби авылына, аның аерым шәхесләренә багышлана. Анда бәян ителгәннәрнең шактый өлеше документлар белән раслана, ә кайберләре өлкәннәрнең истәлекләренә, авыл кешеләре сөйләгәннәргә нигезләнә. Китап төрле чорларга караган күп кенә фотосурәтләрне эченә ала, кушымтада архив язмалары, иске карталар бирелә. Шулай ук Татарстан Фәннәр академиясе Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты архивыннан алынган фотосурәтләр һәм язмалар да кулланылды. «Хәерби авылы тарихыннан сәхифәләр» китабы татар халкының үткәне һәм бүгенгесе белән кызыксынучы киң катлам укучыга атап чыгарыла. Ә шулай да ул Миләүшә тавында язларын чәчәк, җәен җиләк, мәтрүшкә җыеп, кышларын чана шуып, Мишә елгасында су коенып, Кайнывакта, Бай күлендә балык тотып, кер юып-чайкап, аны чикләвек куакларына җәеп киптереп, Ачканбайда, Талтамакта печән әзерләшеп үскәннәр өчен аеруча кызыклы булыр. Авторлар шундый теләкләр белән сезне Хәерби авылы сәхифәләренә дәшә.

*Г.Х.Галимуллина, ТР ФАнең Татар энциклопедиясе һәм*
*төбәкне өйрәнү институты өлкән фәнни хезмәткәре;*
*А.Б.Насибуллина, ТР ФАнең Татар энциклопедиясе һәм*
*төбәкне өйрәнү институты фәнни хезмәткәре.*

Ата-бабалары рухына дога кылыр өчен, адәм баласы үзенең нәсел-нәсәбен белергә тиеш.

*Шиһабетдин Мәрҗани*

Чабата, чыпта,
кара мунча,
салам түбә,
кабык арба –
хәзер кайда?
Булса булыр китапларда.
Чулпы чыңы,
бишек җыры,
азан моңы…
хәзер кайда?
Алар – җанда.

*Равил Фәйзуллин*

Якын миңа синең һәр урамың,
Таныш монда миңа һәрбер өй.

*Роза Кушмина*

# I БҮЛЕК

# ТУГАН ЯГЫМ — ЛАЕШ ЯГЫ

Лаеш ягы — туган ягым,
Сиңа бәйле язмышым.
Минем өчен син — серле күл,
Ә мин — синең камышың.
*Галимҗан Гайнетдинов*

Лаеш районы Татарстан Республикасының үзәк өлешендә урнашкан. Районның мәйданы якынча 2094,43 кв.км тәшкил итә, шул исәптән авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең мәйданы — 921,64 кв.км. Ул Лаеш шәһәрен һәм 23 җирле авыл үзидарәсен, 68 торак пунктны берләштерә. 2019 елда 41440 кеше яши. «Татар энциклопедиясе»[1] мәгълүматлары буенча район 1927 елның 14 февралендә оештырыла. 1920 елга кадәр хәзерге район җирләренең шактый өлеше Казан губернасының Лаеш өязендә, 1920–1927 елларда ТАССРның Лаеш кантонында була.




Лаеш районының чикләре һәм административ бүленеше берничә тапкыр үзгәртелә. 1938 елның 4 августыннан территориясенең бер өлеше — Столбище, 1944 елның 19 февраленнән Солтан (1946 елның 5 апреленнән — Корноухово) районына күчә. 1948 елда Лаеш районының мәйданы 1331 кв. км була, аңа 28 авыл советы, 87 торак пункт керә. Район территориясе 1954, 1959 елларда Корноухово һәм Столбище районнары исәбенә арта. 1960 елларда районның мәйданы — 2168 кв.км, посёлок һәм 21 авыл советы, 107 торак пункт була. 1963 елның 1 февралендә Лаеш районы бетерелә, территориясе Питрәч районына кушыла.

1 Татар энциклопедиясе: 6 томда / Баш мөхәррир М.Х.Хәсәнов, җаваплы мөхәррир Г.С.Сабирҗанов. – Казан: ТР ФАнең Татар энциклопедиясе институты, 2006. – 3 т.: К–Л.

1965 елның 12 гыйнварында район яңадан торгызыла, мәйданы — 2212 кв. км, халкы — 44 мең кеше, административ берәмлекләр — 22 (1 посёлок һәм 21 авыл советы), 97 торак пункт исәпләнә. 1970–1990 елларда районның кайбер авыллары Казанга кушылу сәбәпле, район территориясе кими.

## ЛАЕШ РАЙОНЫНЫҢ МУНИЦИПАЛЬ-ТЕРРИТОРИАЛЬ БҮЛЕНЕШЕ

«Лаеш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» №28-ЗРТ Татарстан Республикасы Законы буенча Лаеш районы 1 шәһәр һәм 23 җирле авыл үзидарәсен, 68 торак пунктны берләштерә.

| № | Муниципаль берәмлек | Административ үзәк | Торак пунктлар саны һәм исемнәре | Халык саны (2019 елның 1 гыйнварына) |
|---|---|---|---|---|
| | **Шәһәр җирлеге** | | | |
| 1 | Лаеш | Лаеш шәһәре | 1. Лаеш<br>2.Иске Пристань авылы | 10 218 |
| | **Авыл җирлекләре** | | | |
| 2 | Александровка авыл җирлеге | 25 Октябрь исем. совхоз посёлогы | 1. 25 Октябрь исем. совхоз посёлогы<br>2. Александровка посёлогы<br>3. Бутыри авылы<br>4. Югары Кармачы авылы<br>5. Түбән Кармачы авылы | 1759 |
| 3 | Атабай авыл җирлеге | Атабай авылы | Атабай авылы | 504 |

| № | Муници-паль берәмлек | Адми-нистратив үзәк | Торак пунктлар саны һәм исемнәре | Халык саны (2019 елның 1 гыйнва-рына) |
|---|---|---|---|---|
| 4 | Олы Кабан авыл жир-леге | Кече Кабан авылы | 1. Кече Кабан авылы<br>2. Олы Кабан авылы | 1634 |
| 5 | Габишев авыл җирлеге | Габишев авылы | Габишев авылы | 2859 |
| 6 | Державин авыл җирлеге | Державин авылы | Державин авылы | 466 |
| 7 | Егорьево авыл җирлеге | Каип авылы | 1. Берёзовка авылы<br>2. Бимә авылы<br>3. Егорьево авылы<br>4. Зимняя Горка (Кышкы Тау) авылы<br>5. Каип авылы<br>6. Кызыл Ил авылы<br>7. Пальцовка авылы | 1056 |
| 8 | Хәерби авыл җирлеге | Хәерби авылы | 1. Хәерби авылы<br>2. Травкино авылы | 994 |
| 9 | Көек авыл җирлеге | Яушыйк авылы | 1. Алексеевский поселогы<br>2. Яушыйк авылы<br>3. Көек авылы<br>4. Мысы поселогы | 109 |
| 10 | Макаровка авыл җирлеге | Ташкирмән авылы | 1. Макаровка авылы<br>2. Ташкирмән авылы | 609 |
| 11 | Кече Елга авыл җирлеге | Кече Елга авылы | 1. Кече Елга авылы<br>2. Полянка авылы<br>3. Шуран авылы | 977 |

| № | Муници-паль берәмлек | Адми-нистратив үзәк | Торак пунктлар саны һәм исемнәре | Халык саны (2019 елның 1 гыйнва-рына) |
|---|---|---|---|---|
| 12 | Матюшино авыл җир-леге | Матюшино авылы | Матюшино авылы | 161 |
| 13 | Нармонка авыл җирлеге | Нармонка авылы | 1. Астраханка авылы<br>2. Карадули (Карадулат) авылы<br>3. Караишево (Каришә) авылы<br>4. Нармонка авылы<br>5. Татар Кабаны авылы<br>6.Тетеево (Тәти) авылы | 2400 |
| 14 | Никольский авыл җирлеге | Никольский авылы | 1. Никольский авылы<br>2. Беляково авылы<br>3. Күнтәч авылы<br>4. Яңа Алан (Яңа Поляна) авылы<br>5. Пиголи авылы<br>6. Сапуголи (Сабакүл) авылы<br>7. Тарлаш авылы | 1154 |
| 15 | Орёл авыл җирлеге | Орёл авылы | 1. Орёл авылы<br>2. Соколовка авылы<br>3. Троицкий посёлогы<br>4. Чистое Озеро (Чистакүл) авылы | 1068 |
| 16 | Пәрәү авыл җирлеге | Пәрәү авылы | Пәрәү авылы | 687 |
| 17 | Комлы Кавал авыл җирлеге | Комлы Кавал авылы | 1. Комлы Кавал авылы<br>2. Вороновка авылы | 2209 |

| № | Муниципаль берәмлек | Административ үзәк | Торак пунктлар саны һәм исемнәре | Халык саны (2019 елның 1 гыйнварына) |
|---|---|---|---|---|
| 18 | Рождествено авыл җирлеге | Рождествено авылы | 1. Рождествено (Би) авылы<br>2. Дятлово авылы<br>3. Сиңгел авылы<br>4. Тамгачы авылы | 1213 |
| 19 | Сокуры авыл җирлеге | Сокуры авылы | 1. Сокуры (Сукыр Кадыш) авылы<br>2. Обухово авылы | 1623 |
| 20 | Урта Девятово авыл җирлеге | Урта Девятово авылы | 1. Урта Девятово авылы<br>2. Емельяново авылы<br>3. Мәмәт авылы<br>4. Смолдеярово авылы | 653 |
| 21 | Столбище авыл җирлеге | Столбище авылы | 1. Столбище авылы<br>2. Усад авылы | 7533 |
| 22 | Татар Сараланы авыл җирлеге | Татар Сараланы | 1. Татар Сараланы авылы<br>2. Рус Сараланы посёлогы | 368 |
| 23 | Татар Янтыгы авыл җирлеге | Татар Янтыгы авылы | Татар Янтыгы авылы | 304 |
| 24 | Чирпы авыл җирлеге | Чирпы (Чырпы) авылы | 1. Чирпы авылы<br>2. Имәнкискә авылы<br>3. Меретяки авылы | 882 |

Район территориясенең көнбатыш һәм көньяк чикләре Куйбышев сусаклагычы ярлары буйлап үтә. Районда Мишә һәм Бырыс елгалары ага. Мишә елгасы, Архиерей, Кавал (Кәвәл), Куян, Мүкле, Урман, Саламык, Саф, Сабакүл, Столбище күлләре, Чиста күлләр һәм ике Кара күл, Күл акчарлаклары колониясе, Идел-Кама саклаулыгының Саралан урманы, Столбище аучылык тыюлыгы районның саклаулы табигать объектларын тәшкил итә.

Лаеш районы территориясендә бронза гасырдан алып, Идел буе Болгар дәүләте һәм Алтын Урда чорларына кадәрге 170 тән артык археологик ядкәр табыла (мәс.: Атабай торулыгы, Имәнкискә культурасы, Хәерби шәһәрлеге, Хәерби туктаулыгы, Хәерби табылдыклары һ.б.).

Авыл хуҗалыгы җирләрендә сабан һәм уҗым бодае, арыш, солы, тары игелә, бәрәңге, яшелчә үстерелә. Бакчачылык нык үскән. Терлекчелекнең алга киткән өлкәләре — мөгезле эре терлек асрау, кошчылык. Районның сәнәгать предприятиеләре, нигездә, Лаеш шәһәрендә тупланган. Нармонка авылында — консерва заводы, Габишев посёлогында «Yaratelle» («Яратель») кошчылык фабрикасы, 25 Октябрь исемендәге совхоз посёлогында «Лаеш» кошчылык комплексы, Усад авылында «Казан май комбинаты» ачык акционерлык җәмгыяте, Хәербидә Казан медицина инструментлары заводының «Луч» филиалы һ.б. эшли. Район территориясендә «Казан халыкара аэропорты», «Татарстан авиакомпаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте, «Казан Экспо» Халыкара күргәзмә үзәге, «Санта» санаторие һ.б. урнашкан. Биредән Казан–Оренбург автомобиль юлы уза.

Лаеш районында 30 дан артык гомуми белем бирү мәктәбе, авыл хуҗалыгы техникумы, һөнәр училищесы, китапханәләр, клублар, музыка мәктәбе (Лаеш шәһәрендә) һәм аның авыллардагы филиаллары, балалар бакчалары, 157 урынлы 2 хастаханә, 2 амбулатория бар. Татар һәм рус телләрендә «Камская новь», «Кама ягы» район газеталары нәшер ителә. Лаеш районының тарихы шагыйрь Г.Р.Державин, декабрист Д.И.Завалишин, механик һәм математик Н.Г.Четаев, шагыйрь, прозаик һәм журналист А.К.Белозерцев, революционер һәм 26 Баку комиссарының берсе И.Я.Габышев (Габишев), Советлар Союзы Геройлары И.С.Матвеев, А.Т.Сергеев, С.И.Козлов, А.П.Малышев, Дан орденының тулы кавалерлары П.И.Наумов, К.З.Җаббаров, ТРның халык артистлары Ф.Х.Хәйруллина, Ф.К.Әхтәмова, Н.Н.Ибраһимова, ТАССРның халык артисты Г.И.Нуруллин, Россия Герое М.Р.Әхмәтшин исемнәре белән бәйле.

**ЛАЕШ РАЙОНЫ ГЕРБЫ ҺӘМ ФЛАГЫ**

(2005 елның 8 декабрендә раслана)[1]

**Герб тасвирламасы**: «Очлык хасил итүче көмеш дулкыннар өстендә сыек зәңгәр (зәңгәр, күк) җирлектә — ишкәксез һәм җилкәнсез, мачтасы вымпеллы, төялгән ябулы алтын каек, аның астында бер-берсенә караган ике җете кызыл (кызыл) балык».

1 Государственные и муниципальные символы Республики Татарстан = Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль символлары = State and municipal symbols of the Republic of Tatarstan. – Казань, 2017. – 247 с.





Лаеш районының Гербы һәм Флагы

Флаг тасвирламасы: «Киңлеге озынлыгына 2:3 нисбәттәге, горизонталь буенча тигез булмаган ике — зәңгәр (тукыма киңлегенең 7/10 өлеше) һәм ак буйларга бүленгән туры почмаклы тукыма; уртада — йөзеп баручы сары каек, аның астында — берсе икенчесенә караган кызыл төстәге ике балык».

Символика нигезләмәсе: Лаеш районы гербы Казан губернасы Лаеш өяз шәһәренең иң югарыда 1781 елның 18 октябрендә (иске стиль белән) расланган, тасвирламасында: «Калканның югары өлешендә Казан гербы. Түбәнге өлешендә, зәңгәр җирлектә, струг дип аталучы кузгалырга әзерләнгән зур каек сурәте, чөнки бу шәһәрдә иң мөһим пристань урнашкан», — диелгән тарихи гербы нигезендә эшләнгән. Район чикләренең күпчелек өлеше хәзерге вакытта Куйбышев сусаклагычы ярлары буенча уза, биредә Мишә һәм Бырыс елгалары да ага. Балык — традицион рәвештә зирәклек һәм муллык билгесе, ике балык сурәте район гербын шәһәр гербыннан аерырга мөмкинлек бирә. Очлыктагы ике балык — районда элек-электән үсеш алган балыкчылыкны белдерә. Алтын төс — уңыш, муллык, тотрыклылык, абруй һәм акыл; көмеш — сафлык, камиллек, татулык һәм үзара аңлашу; җете кызыл — хезмәт, кыюлык, көч, мәхәббәт һәм матурлык; сыек зәңгәр — намус, зыялылык, рухи омтылышлар символы. Гербтагы зәңгәр төс шулай ук Куйбышев сусаклагычының су киңлекләрен аңлата.

# II БҮЛЕК

## ХӘЕРБИ АВЫЛЫ: КЫСКАЧА КҮЗӘТҮ

Сандугачлы, таллы яшел бишек,
Хәербием – туган авылым.
Юксынуга түзмим, очып кайтам,
Шулкадәрле сине сагындым.

Язын Мишә буе шомыртлары
Кәләш кебек актан киенә.
Ак бөркәнчек япкан көнне уйлап
Үтәм әрәмәнең түренә.

Дулкынланам, янам; хәтер, дөрләп,
Истәлекләр миндә яңарта,
Хәербием, җаным-тәнем белән
Яратам мин сине, яратам.

Талтамакта җиләкләрең пешә,
Әрәмәдә үсә баланың.
Читкә китсәм чыгып, искә төшә,
Хәербием, синең тауларың.

*Роза Кушмина*

Хәерби авылы Лаеш районында, Казан тимер юл станциясеннән 32 км төньяк-көнбатыштарак, Мишә елгасыннан 3 км ераклыкта урнашкан. 2010 елда 789 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау, яшелчәчелек. Авылда урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә эшли. Мәчет бар (архитектура истәлеге, 1908 елда Казанның 1 нче гильдия сәүдәгәре С.С.Гобәйдуллин акчасына салына).

Хәербидә Татарстан, Ленин, Горький, Чапаев, Гвардия, Спартак, Авыл Советы, Урман, Елга, Дала, Яшьлек, Мәктәп, Ерганак, Ерак, Гәрәй, Яшьләр, Пионер, Куанычлы, Саз, Илфар Билалов, Бәхетле урамнары бар.

Хәерби авылы җирлегенә керүче Травкино авылы урамнары: Толстой, Пушкин, Тукай, Күл, Чирәмле, Бакча, Юл буе, Дача, Чияле, Миләшле, Якты, Чәчәкле, Яшел, Болын, Салават күпере, Кояшлы.

**2017–2018 елларга Хәерби авыл җирлегенең халык саны динамикасы**

| Торак пунктлар | Халык саны | | Динамика + һәм – |
|---|---|---|---|
| | 2017 ел | 2018 ел | |
| Барлыгы: | 948 | 994 | +46 |
| ш.и. Хәерби авылында | 920 | 954 | +34 |
| ш.и. Травкино авылында | 28 | 40 | +12 |

Хәерби авылы Казан ханлыгы чорыннан билгеле. XVI йөзнең 2 нче яртысында авыл хәзерге Столбище авылыннан көнбатышка таба урнашкан була. Бу урында Хәерби күле дип аталган күл әле дә бар һәм ул чал тарихыбызның телсез шаһиты булып бүген дә суларын чайпалдырып утыра.

XVIII йөздә – XIX йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крестьяннары катлавына керә, игенчелек, терлекчелек белән шөгыльләнә. XX йөз башында Хәербидә мәчет, мәдрәсә, җил тегермәне, 6 вак-төяк-ләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1857 дисәтинә тәшкил итә. 1920 елга кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Әстерхан волостенда, 1920 елдан ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 елның 14 февраленнән — Лаеш, 1938 нең 4 августыннан — Столбище, 1959 елның 26 мартыннан — Лаеш, 1963 елның 1 февраленнән — Питрәч, 1965 елның 12 гыйнварыннан Лаеш районында.

Хәерби авыл җирлегенә Травкино авылы да керә. Ул Хәербидән 4 км көнбатышта, Лаеш шәһәреннән 33 км төньяк-көнбатыштарак, Казан–Атабай автомобиль юлы буенда урнашкан. 2010 елда 11 кеше (руслар, татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. XVII йөз ахырында нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крестьяннары катлавына керә, игенчелек, терлек асрау белән шөгыльләнә. XX йөз башында Травкинода вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 390,5 дисәтинә тәшкил итә. 1920 елга кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Әстерхан волостенда, 1920 елдан ТАССРның Лаеш районында. 1927 елның 14 февраленнән — Воскресенский, 1927 елның 1 августыннан — Казан авыл районында, 1938 елның 4 августыннан — Столбище, 1959 елның 26 мартыннан — Лаеш, 1963 елның 1 февраленнән — Питрәч, 1965 елның 12 гыйнварыннан Лаеш районында.

**Хәерби һәм Травкино авылларындагы халык саны:**

| Халык санын исәпкә алу еллары | Хәерби | Травкино |
|---|---|---|
| 1782 ел | 123 ир-ат | 44 ир-ат |
| 1859 ел | 254 ир-ат | 76 ир-ат |
| 1897 ел | 1002 | 185 |
| 1908 ел | 1227 | 187 |
| 1920 ел | 1430 | 237 |
| 1926 ел | 1549 | 255 |
| 1930 ел | 1549 | |
| 1939 ел | 1666 | |
| 1949 ел | 1389 | 194 |
| 1958 ел | 1342 | 203 |
| 1970 ел | 1155 | 150 |
| 1979 ел | 934 | 69 |
| 1989 ел | 784 | 35 |
| 2002 ел | 812 | 20 |
| 2010 ел | 789 | 11 |
| 2018 ел | 954 | 40 |

## ХӘЕРБИ КҮЛЕ — АВЫЛНЫҢ ТАРИХИ ИСТӘЛЕГЕ

Хәерби күле – Көнбатыш Кама алдында, Идел елгасының югары террасасында, Лаеш районы Столбище авылында, элек Хәерби авылы булган урында урнашкан. Су өслегенең мәйданы 6,2 га, күләме 119,3 мең куб. м. Озынлыгы 525 м, уртача киңлеге 125 м, уртача тирәнлеге 2 м тирәсе, иң зур тирәнлеге 5 м. Күл карст-суффозия процесслары нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Озынча түгәрәк формада. Ярлары сөзәк һәм тәбәнәк. XX йөз урталарына кадәр Хәерби күле ермак аша Куян күле белән тоташкан була, соңыннан Олы Кабан авылы янындагы ерымнан комсу-балчыксыл китерелмәләр белән акрынлап бүленә һәм йомык сулык булып кала. Хәерби авылы хәзерге урынга күченеп утырса да, күл үзенең исемен саклап калган. Туенуы тотрыклы, явым-төшемнәр һәм грунт сулары исәбенә туена. Суы җиңелчә минеральләшкән (115,2 мг/л), йом-



Хәерби күле. Авылның тарихи истәлеге.

шак (5,6 мг-экв/л), азрак болганчык, саргылт төстә. Сугару һәм су кошлары өчен файдаланыла. 1978 елдан алып ТРның табигать истәлеге булып санала.

## ХӘЕРБИ АВЫЛЫНЫҢ КАРТАСЫ, ҖИР БИЛӘМӘЛӘРЕ ТАБИГЫЙ ШАРТЛАРЫ ҺӘМ РЕСУРСЛАРЫ

**Рельеф һәм геоморфология.** Хәерби авылы җирлеге Лаеш муниципаль районының төньяк-көнчыгыш өлешендә урнашкан. Геологик һәм геоморфологик үзенчәлекләре буенча Кама алды районына керә. Авыл җирлеге Идел елгасының – сул, ә Кама елгасының уң як ярлары буенча урнашкан. Өслекнең авышлыгы төньяктан көньяк-көнчыгышка юнәлгән. Биеклеге 56,0–124,6 м. Иң калкулыклы җир – территориянең төньяк-көнбатышында, ә түбәнлекле урыны – Мишә елгасы тугайлыгында.

**Геологик төзелеше һәм файдалы казылмалары.** Платформаның нигезендә түбән һәм урта протерозой токымнарыннан булган кристаллик фундамент ята. Аның өстендә палеозой (девон, ташкүмер һәм пермь), неоген һәм дүртенчел (түбән казан һәм югары казан) утырмалары булган тышлык.

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы мәгълүматлары буенча, Хәерби авыл җирлегендә 2 табигый торф чыганагы бар. Шуларның берсе – «Ачканбай» (Хәерби чигеннән төньяк-көнчыгышка таба 1,7 км да), икенчесе – «Бай күле» (Хәерби чигеннән көньякка таба 500 м да). Авыл җирлегенең көнбатышында, Никольский авылы җирлеге белән чиктәш, пыяла чималы чыганагы бар, ул әлегә үзләштерелә башланмаган.




Хәерби авылы җирлегенең генераль планы.

Хәерби тулысынча Столбище җир асты төче су чыганагы чикләрендә урнашкан. «Кирбинка» ҖЧҖ шушы суның Хәерби җирендәге өлешеннән тәүлегенә 0,173 мең м$^3$ минераль су җитештерә. Хәерби җире өлешендәге су составының күрсәткечләре түбәндәгечә: катылыгы – 1,5–7 мгэкв/л, магний – 7–50 мкг/л, кальций – 25–80 мкг/л, бикарбонатлар 140–400 мкг/л, калий – 2–20 мкг/л, йод – 40–60 мкг/л.

**Гидрологик шартлар.** Хәерби авылы җирлегенең җир асты сулары Кама-Вятка артезиан сулары бассейнына керә, бу Көнбатыш Кама алды гидрологик өлеше. Халык кулланышы өчен булган һәм авылның үзәкләштерелгән сулары казан сульфатлы-карбонатлы (P2kz) комплексыннан алына.

**Җир өсте сулары**. Хәербинең көнчыгыш чикләре буйлап Мишә елгасы ага. Мишә – Кама елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 186,4 км, ә Хәерби чикләренә 6,3 км туры килә. Бассейнының мәйданы 4180 кв. км. Елга башы Кукмара районы Ятмас-Дусай авылыннан 1,4 км төньяк-көнчыгыштарак ур-

ман массивында, Саба, Теләче һәм Питрәч районнары территориясеннән ага; түбән агымы һәм тамагы Лаеш районы территориясендә.

Элек елга тамагы Ташкирмән һәм Макаровка авыллары янында була, хәзер Карадулат авылыннан түбәндәрәк. Елганың түбән агымы Куйбышев сусаклагычы сулары астында калган һәм суднолар йөрешле Мишә култыгы хасил



Мишә елгасы Хәерби авылы янында.





Мишә елгасында балык та тотарга, коенырга да була.

иткән. Елга башының абсолют биеклеге 160 м, тамагыныкы — 53 м. Су җыелу мәйданы елга кушылдыклары, сыза һәм ерым үзәннәре белән бүлгәләнгән калкулыклы тигезлектән тора. Елга бассейны асимметрияле: уңъяк яр өлеше шактый зур. Үсемлекләр дөньясы, нигездә, караңгы ылыслы-киң яфраклы һәм киң яфраклы урманнардан, тугайлы болыннардан тора. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 17%. Сөрүле җирләр якынча 80%.

Мишә бассейны күп кенә урыннарда дүртенчел система яшендәге токымнар белән капланган пермь системасы казан һәм татар ярусы токымнарыннан тора. Су җыелу мәйданында рельефның карст формалары очрый. Мишә бассейны өчен көлсу типтагы урман туфраклары (аксыл соры, кара соры), шулай ук кәсле-көлсу туфраклар хас. Елга үзәне трапециясыман, түбән агымында җиңелчә генә белена; уңъяк сөзәклекләре, нигездә, текәрәк. Үзәннең киңлеге югары агымында 30 м дан түбән агымында 4–5 км га кадәр. Тугае киң, ике яклы, түбән агымда уйсулыклар, ерганаклар һәм элекке күлләр күп; тамак өлешендә елга өлешчә Куйбышев сусаклагычы сулары астында калган.

Мишә елгасының юлы бормалы, урыны-урыны белән болын һәм куакчыл үсемлекләр үскән утраулар (озынлыгы 15–65 м, киңлеге 20 м га, биеклеге 3 м га кадәр) хасил итеп тармаклана. Урта һәм түбән агымында киң плёслар (озынлыгы 0,2 дән 3 км га кадәр, киңлеге 15–40 м, тирәнлеге 2–5 м) күп, аларда исә агым тизлеге 0,1–0,2 м/с тан артык түгел. Елганың күп кенә урыннары сайлыклар белән катлауланган, аларда исә елга юлының киңлеге 10 м га ка-




Ямьле Мишә буйлары.



Бай күле ягыннан авыл күренеше.

дәр, тирәнлеге 0,2–0,6 м, агым тизлеге 1–2 м/с. Мишә ярлары комсыл балчыклы һәм балчыксыл комлы туфрактан тора, урыны белән текә, биеклеге 2–4 м, Казкаш елгасы тамагы янында 10 м га кадәр. Башлыча, елга төбе тигез, борылмаларда чокырлар очрый. Мишәнең 45 кушылдыгы бар, аеруча зурлары: Нысы (22,2 км), Нырсы (33,4 км) — сул; Казкаш (28,4 км), Кече Мишә (49,9 км), Тәмте (24,6 км), Кибәче (14 км), Норма (40 км), Сола (23 км), Шемелка (16,6 км) — уң кушылдыклар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,35 км/км$^2$. Мишәнең туенуы катнаш, агым кар сулары, җир асты кушылдыклары, явымтөшемнәр исәбенә барлыкка килә. Елга режимын күзәтүләр Питрәч районы Чыты (1932–53 елларда) һәм Лаеш районы Рождествено (1932–55), Обухово (1931–59) авыллары янындагы гидрологик постта алып барыла. Хәзерге вакытта Питрәч авылы янында пост эшли (1959 елдан).

Гидрологик режим өчен ташу вакытында су муллыгы (аларга еллык агымның 70% ы туры килә) һәм җәен нык саегу чорлары хас. Тигезлекнең уртача еллык тирбәнеше 7 м (макс. 9,8 м). Бассейнда еллык су агымының уртача күпеллык катламы 162 мм, ташу вакытында су катламы 113 мм. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры–апрель башында башлана. Мишә ноябрь уртасында туңа. Кыш ахырына бозның калынлыгы 35–50 см га җитә. Елга суының иң аз вакытында җир асты сулары белән туена. Бассейнының төрле урыннарында җир асты сулары белән туену модуле 0,5 тән 10 л/с·км$^2$ ка кадәр. Җәйге корылык-

лар вакытында Мишәнең югары агымы һәм аның кушылдыклары тар инешләргә әйләнеп кибә. Суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы югары агымында 0,008 м$^3$/с тан, урта агымында (Теләче авылыннан түбәндәрәк) 2,4 м$^3$/с ка кадәр һәм түбән агымында (Питрәч районы Колай авылы янында) 6,2 м$^3$/с. Елга тамагында суының уртача күпьеллык чыгымы 17,4 м$^3$/с (1979). Суы гидрокарбонат-сульфат-кальцийлы типта, язын йомшак (1,5–3 мг-экв/л), кышын һәм җәен каты (6–9 мг-экв/л). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 мг/л, кышын һәм җәен 700–1000 мг/л. Мишә бассейнында суның гомуми күләме 25,7 млн. м$^3$ һәм мәйданы 855 га булган 45 буа бар. Су ресурслары якынча 10 мең га га якын авыл хуҗалыгы җирләрен сугару өчен кулланыла. Яр буйлары ял итү урыннары булып тора. Мишә — ТРның табигать истәлеге (1978). Аның уңъяк ярында «Иске тегермән» табигать истәлеге урнашкан.



Саф күл. Табигать истәлеге.

Хәерби авыл җирлегендә күлләр күп. Алар барысы да Мишә елгасы тугайлыгына кертеп карала.

**Туфрак капламы, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы.** Хәерби авыл җирлегендә туфрак капламы күбесенчә куе соры-урман туфрагы. Нарат һәм киң яфраклы агачлар үсә. Болыннар төрле үсемлекләргә бай: кыр яраны, тукранбаш, люцерна һ.б.). Болыннарда печән әзерлиләр. Суер, божыр, тиен очрый. Кимерүчеләрдән урман, кыр тычканнары һ.б., кошлардан шәүләгән, карабүрек, миләш чыпчыклары, төрле тукраннар бар. Мишә елгасы янында су кошлары: кыр үрдәге, соры үрдәк, шөлди, акчарлак, камыш чыпчыгы, кыр казлары һ.б. бар.

# III БҮЛЕК

# АРХЕОЛОГИК ИСТӘЛЕКЛӘР

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең А.Х.Халиков исемендәге Археология институты мәгълүматлары буенча, ТРның Лаеш районы Хәерби авылы территориясендә һәм тирә-ягында өч археологик истәлек табыла: Хәерби шәһәрлеге, Хәерби туктаулыгы һәм Хәерби акча табылдыклары.

**Хәерби шәһәрлеге** (I меңьеллыкка карый) 1983 елда Мишә елгасы тирәсендәге территорияне тикшергәндә В.А.Семёнов җитәкчелегендәге Удмурт археологик экспедициясе тарафыннан ачыклана. 1987 елда Т.Останина Хәерби авылыннан 0,2 км көньяк-көнбатыш тарафта, Мишә елгасының уң ярында, Караеш (Караишево) авылы ягына таба икенче тау (халык телендә «Икеле тау») башында урнашкан шәһәрлекне тикшерә. «Тау итәге янында авыл халкы ел саен татарларның милли бәйрәме – Сабан туен уздыра. Шәһәрлектән төньяк-көнчыгыш тарафта, 0,1 км ераклыкта елганың элеккеге юлы уза, 2 км көнчыгышта Мишә елгасы ага»[1]. Шәһәрлек 1052 кв. м мәйдан били.

Сөзәклекнең көньягында һәм көньяк-көнбатышында алып барылган казу эшләре вакытында баганалардан һәм казыклардан калган 28 чокыр, 14 учак һәм бер хуҗалык чокыры эзләре теркәлә. Шулай ук хезмәт кораллары, тимер, сөяк һәм таш әзерләмәләр, сөңге очлыгы чөе кисәге, пычаклар, хәнҗәр кисәге, сандал (квадрат нигезле кисек пирамида рәвешендә), орчык башлары (орчыкны авырайту һәм эрләгән җепне беркетү өчен кулланылган авырлык очлыгы), сөяк эшләнмәләр (тишкечләр), тигельләр (төрле материалларны яндыру яки эретү өчен эшләнгән савытлар), сфера рәвешендәге бакыр аел (тәңкә) кисәге, 2862 керамик (керәч) чүлмәк ватыклары табыла. Савытларның формалары һәм аларны эшләүдә кулланылган балчыкның составы, бизәкләре буенча археологлар савыт-сабаларны 3 төркем-комплекска бүләләр:

***Беренче төркем.*** *Ананьино культурасы керамикасы.*

Хәерби шәһәрлеге керамикасы коллекциясендәге табылдыкларның 21% ы – Ананьино керамикасы. Савытлар тасмалап ябыштыру техникасы кулланып ясалганнар, өслекләре яхшылап шомартылган; формалары буенча алар гап-гади чүлмәк. Кама тамагы тирәсендәге Ананьино чоры истәлекләренең В.Н.Марков тарафыннан эшләнгән периодлаштырылу һәм хронология систе-

1 Останина Т. Кирбинское городище на реке Меше. Finno-Ugrica. №1 (5–6). 2001–2002. 15 б.

масы буенча, Хәерби шәһәрлеге керамикасы комплексын икенче хронологик чорга (б.э.к. VII гасыр) карый[1] дияргә мөкин.

***Икенче төркем.*** *Азелино культурасы керамикасы.*

Чүлмәк рәвешендәге соры, куе соры һәм кызгылт соры төстәге, эчке һәм тышкы өслекләре шомартылган савытлар табыла. Хәерби шәһәрлегенең савыт-саба ватыклары Азелино керамикасыннан беркадәр аерылалар, шуңа күрә аларны Азелино культурасына шартлы рәвештә генә нисбәт итәргә мөмкин.

***Өченче төркем.*** *Имәнкискә культурасы керамикасы.*

131 савыт-саба ватыгы табыла. Археологлар мәгълүматлары буенча, савыт-саба кулдан әвәләп эшләнгән, тышкы һәм эчке өслекләре йомшак әйбер белән шомартылган, керамика пөхтә итеп эшкәртелгән – шома өслек шуны күрсәтеп тора. «Имәнкискә культурасы истәлекләрен тикшерүче П.Н.Старостин шундый эчле савытларны Б төркеменә нисбәт итә; алар, аның фикеренчә, тигезсез һәм шома булмаган савытларга караганда, торулыкларда һәрвакыт сирәгрәк очрыйлар»[2].




Хәерби шәһәрлеге. Таш инвентарь.
1-4 – киле каплары; 5, 6, 8 – чакма ташы ватыклары; 7 – нуклеус (таш кыйпылчыгы); 9, 11 – ярма ваклагыч ватыклары, 10 – тегермән ташы ватыгы.

Хәерби шәһәрлегендәге казу эшләре вакытында төрле катламнарда һәм биеклектә 2711 сөяк табыла. Өске катламда табылган сөякләрнең зур өлеше башлыча Азелино һәм Имәнкискә культураларына карый. 352 сөякне тикшерү түбәндәге нәтиҗәне бирә: 40,6% ы – дуңгыз, 33,5% ы – ат, 24,4% ы – мөгезле эре терлек, 1,5% ы – мөгезле вак терлек сөякләре. Биредә ачыклык кертү сорала, Т.И.Останина фикеренчә, әлеге күренеш шәһәрлекнең өске катлавында (1–3 горизонтлар) терлекләрнең баш санына карата гына күзәтелә, ягъни сөякләр исәбе буенча беренче урынга ат «чыга»[3].

1 Останина Т. Кирбинское городище на реке Меше. Finno-Ugrica. №1 (5–6). 2001–2002. 24 б.
2 Шунда ук.
3 Шунда ук. 26 б.

Шәһәрлекнең планиграфиясен өйрәнеп, Т.И.Останина: «Шәһәрлек үлчәмнәренең кечкенәлеге, мәйданчык биеклекләре тигез урнашмау аркасында торак корылмалары төзү мөмкин булмаган. Безнең карашка, шәһәрлекнең көнбатыш яртысында табыну комплексы урнашкан, аның уртасында иң юан багана (диаметры 45 см, №13), ихтимал, пот (идол) торган. Көньяк, көнбатыш һәм төньяк тарафлардан аны баганалар (№17, 24, 28, 15, 6) һәм зур булмаган учаклар (VIII, VI, II, XIV, XIII) әйләндереп алган», – дип нәтиҗә ясый[1].

Үзәк баганаты фаразланган әйләнә сызыгы буйлап урнашкан учаклар һәм баганалар белән тоташтыручы уйланма сызыклар юнәлешеннән чыгып фикер йөрткәндә, шәһәрлек мәйданчыгының Ай һәм Кояш хәрәкәте фазаларын билгеләү өчен «хронометр» буларак хезмәт итүе ихтимал. Үзәк багана аша югары Ай чыгышы ноктасын, Кояш чыгышы нокталарын (22 июнь, 1 сентябрь, 8–9 октябрь), Түбән Ай чыгышы ноктасын, Көньяк ноктасын, Түбән Ай баешы ноктасын, Кояш баешы ноктасын билгеләү мөмкин булган. Алар буенча игенчелек эшләренең, мәҗүсилек бәйрәмнәренең календарь даталарын, җәйге Кояш торгынлыгы көнен билгеләгәннәр.

Терлек сөякләренең күпләп табылуы «шәһәрлекнең башка мәйданында, «хронометр»дан көньяк һәм көнчыгыш тарафларда корбан чалуларны күрсәтә»[2]. Мәйданчыкның территориясе дә, ныгытмалар да зур түгел. Мәйданчыкта үзәк баганалы «хронометр» урнашкан, фаразланганча, каһин (жрец) җитәкчелегендә шунда яңгыр, яктылык, уңыш бирүен сорап, мәҗүси аллаларга ялварганнар, йолалар үтәгәннәр.

**Хәерби туктаулыгы.** «Татарстан Республикасының археология истәлекләре җыелмасы»нда[3] 1819 нчы номер белән авылдан көньяктарак, Мишә елгасының уңъяк ярында тугай өстендәге терраса чыгынтысында сөрүле җирдә урнашкан Хәерби туктаулыгы тасвирлана (70×70 м). Анда Маклашеевка культурасына (Соңгы Казан алды культурасының Маклашеевка чорына) караган әвәләп ясаган керамика, тараксыман зигзаглы бизәкле соңгы чор рус керамикасы китекләре, известьташтан эшләнгән тегермән ташы ватыклары табыла. Хәерби туктаулыгы 1977 елда Е.П.Казаков тарафыннан тикшерелә. Коллекция Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең А.Х.Халиков исемендәге Археология институтының Археология музеенда саклана (Кир-77) (Казан археология экспедициясенең 1977 елгы хисабы; АК, 1981, №391).

1 Останина Т. Кирбинское городище на реке Меше. Finno-Ugrica. №1 (5–6). 2001–2002. 28 б.

2 Шунда ук.

3 Свод памятников археологии Республики Татарстан: В 3 т. / Җаваплы мөхәр. А.Г.Ситдыйков, Ф.Ш.Хуҗин. Казан, 2007. Т.3. 229 б.




Хәерби туктаулыгының Е.П.Казаков төзегән планы.

**Хәерби акча табылдыклары.** А.В.Васильевның 1930 елда басылган «Татарстан республикасында Алтын Урда акчаларының яңа табылдыклары» мәкаләсендә рабфак студенты Хариз Гарифовның Татарстанны өйрәнү җәмгыятенә (ТАССР Халык Комиссарлары Советының 1928 ел 10 июль карары белән оештырыла һәм 1930 елга кадәр эшли) «Татарстан Республикасының Лаеш районы Хәйриби авылы[1] тирәсендә» табылган татарча язулы 5 көмеш акча тапшыруы хакында белдерелә. Студент сүзләренә караганда, авыл халкы шундый ук «5 тиенлек көмеш акча зурлыгындагы, татарча язулы, араларында Хәбибулла хан исеме сугылганнары ешрак очраган көмеш акчаларны»[2] еш таба торган булган. Алтын Урда идарәчеләре арасында Хәбибулла хан исеме очрамавы сәбәпле, А.В.Васильев, ихтимал, әлеге хөкемдар Алтын Урдада һиҗри буенча 764–770 (милади 1362–1368) елларда идарә иткән Габдулла хан булса кирәк, дип фаразлый.

Барлык табылган акчалар Алтын Урда дәверенә карый:

- 2 акчадагы язуларда Шадибәк хан (һиҗри 802–809, милади 1400–1407 елларда идарә иткән) исеме укыла. Шадибәк исеменнән акчалар Азак,

1 Хәзер ТРның Лаеш районы Хәерби авылы.

Болгар, Кырым, Каффа, Урда, Сарай, Хаҗитархан, Харәзем, Шемаха шәһәрләрендә сугылган.

- 2 акчадагы язуларда Булат хан исеме укыла (Пулад хан – Шадибәк хан улы, һиҗри 810–813, милади 1408–1411 елларда идарә иткән);
- 1 акчадагы язуда Тимер хан (һиҗри 813–814, милади 1411–1412 елларда идарә иткән) исеме булу ихтимал.

Үзара низаглар, эчке ызгышлар, тәхеткә дәгъва кылган бертуганнар арасында барган һәлакәтле сугышлар, ханнарның еш алмашынуы Алтын Урданың таркалуына китерә. Шадибәк хан, Булат хан (Пулад хан) идарәсе тирән икътисади һәм сәяси кризис чорына туры килә, болар барысы да тискәре күренешләрнең, иҗтимагый ризасызлыкның көчәюенә, сәүдәнең һәм һөнәрләрнең сүнүгә йөз тотуына сәбәп була. Үзбәк һәм Җанибәк ханнар заманында сугылып, бизәкләренең һәм язуларының төгәллеге, пөхтәлеге ягыннан аерылып торган акчалар белән чагыштырганда, әлеге дәвердә сугылган акчаларның сыйфаты да түбән була.

Хәерби авылында табылган акчаларны А.В.Васильев нәфислек һәм төгәллек җәһәтеннән кайтыш акчалар исәбенә кертә. Мәсәлән, ул: «Шадибәк хан акчаларының берсе (№1) Болгарда сугылган, әмма елы тулысынча күрсәтелмәгән. Язуларда сүзләр өлешчә сугылган, хан исемендәге хәрефләр читкә сибелгән», – дип билгеләп уза[1]. Әлеге акчада гарәп хәрефләре белән түбәндәге язулар урнаштырылган:

| | |
|---|---|
| әс-солтан | Султан |
| Шади (бәк) | Шади (бек) |
| газим | Верховный |
| хан | Хан |
| Халид мә | Да длится царствование его |
| Зарб (акча сугу) | Чекан |
| Болгар | Болгар |
| 806 | 806 г. (или 809) |

Акчаның йөз ягында тыгызланмаган төен рәвешендәге бизәк бар.

Икенче акча (№2) беренчесенә охшаш, «әмма язу штемпель белән сугылган, йөз ягында акча бизәге урнаштырылган»[2].

1 Васильев А.В. Новые находки золотоордынских монет в Татреспублике // Труды Общества изучения Татарстана. Т.1. 1930. 173 б.

2 Шунда ук. 174 б.

Өченче акчадагы (№3) язулар:

| | |
|---|---|
| әс-солтан | Султан |
| ...хак | (право)судный |
| ... лад (Пулад) | (Пу)лад |
| Зарб (акча сугу) | Чекан |
| | Сарая |
| | нового |
| Болгар | Болгар |
| 8 | 8 |

А.В.Васильев өченче акча (№3) ике ханга нисбәтле – реверсы Шадибәк хан акчаларына карый, аверсы аның варисы Пулад хан тарафыннан һиҗричә 808 елда сугылган, дип фаразлый.

Дүртенче акча (№4) аверсындагы язу:

| | |
|---|---|
| әс-солтан | Султан |
| әл-гадел | правосудный |
| Булат хан | Пулад-хан |

Алдагы юл сакланмаган (ике хәрефнең өске яртылары гына күренә)[1].

Реверстагы язу:

| | |
|---|---|
| (...) арб (зарб – акча сугу) | Чекан |
| (Бол)гар | Булгара |
| җәдид | Нового |

Бишенче акчаның (№5) аверсында бер генә сүз – «әл-солтан» (әс-солтан), реверсында сүзләрнең ахыргы өлешләре: ...лид («халид» сүзеннән), ...кә («мәликә» сүзеннән), ...ур (Тимур сүзеннән) сакланган; җыелма мәгънә «...Тимер хан, патшалыгы гомерле булсын» дип фаразлана. Димәк, әлеге акчаны Пулад хан варисы Тимер ханга, якынча 818 елга (милади 1412 елга) нисбәт итә алабыз[2].

Лаеш районының Хәерби авылы янында табылган акчаларны тикшергәннән соң, А.В.Васильев аларның сирәк очраучы акчалар исәбенә керүе, ә язуларының исә акчаларның ашыгып сугылуы, материал җитмәве, укымышлылык дәрәҗәсенең һәм җитештерү рәвешенең төшенкелеккә китүе турында шаһитлек итә, дигән нәтиҗә ясый. Ул Хәерби авылы тирәсендә археологик тикшеренүләрне дәвам итү яңа ачышларга китерәчәк, Алтын Урданың башка ханнары акчалары да табылачагы ихтимал, дип исәпли.

1 Васильев А.В. Күрсәт. хезм. 175 б.
2 Шунда ук. 175 б.

# IV БҮЛЕК

# ТАРИХ БИТЛӘРЕННӘН

## ХӘЕРБИ АВЫЛЫ ТАРИХЫ ТУРЫНДА КЫСКАЧА МӘГЪЛҮМАТ

Хәерби авылының исеме борынгы заманнардан ук билгеле. Аның турында Казан ханлыгы чорындагы авыллар исемлегендә, Казан волостеның теркәү кенәгәсендә телгә алына. Авылның исеме Казан университеты профессоры, тарих фәннәре докторы И.П.Ермолаев (1932 елда туган) хезмәтләрендә дә күрсәтелә. Казан университеты профессоры, рус тарихы докторы Д.А.Корсаков (1843–1919) 1908 елгы җыентыкта Хәербидә 51 хәлле крестьян, 54 ясак түләүче, 18 йомышлы татар бар дип яза. Археолог, этнограф, географ, статист А.И.Артемьев (1820–1874) үз китабында Хәерби авылындагы 89 хуҗалыкта 280 ир-ат, 355 хатын-кыз яшәвен һәм авылның мәчете булуын күрсәтә. Е.И.Чернышев Хәерби янында кайчандыр «Харибей» авылы булганлыгын әйтеп уза. Бу Кирби–Хәерби транскрипциясенең башка варианты гына булырга да мөмкин, әлбәттә. И.А.Износков хезмәтләрендә авыл «Татарские Кирби» дип, XVIII гасыр карталарында «Каерби» дип күрсәтелә.

Элегрәк авыл Столбище авылы янындагы Хәерби күле буена урнашкан була. Казан ханлыгын руслар яулап алганчы ук, ә кайбер мәгълүматлар буенча Иван IV 1552 елда Казанны алгач, Хәерби, олы юллардан эчкәрерәк кереп, хәзерге урынына күчеп утыра. Бу вакытта авылда 87 хуҗалык исәпләнә, 354 ир-ат, 362 хатын-кыз теркәлә. Алар арасында берничә керәшен татарлар гаиләсе дә була. 1866 елга алар барысы да мөселман диненә күчеп бетәләр. Хәерби тирәсендә урманнар, болыннар күп була. Печәнне алар күрше авылларга да саталар. Тарихи документларда авылның исеме тагын түбәндәгечә искә алына: 1870 елның 16 февралендә Татарские Кирби авылы кешеләре Дәүләт милке министрлыгына урман биләмәләренең законсыз тартып алынуыннан ризасызлык белдереп, аларны кире кайтаруларын сорап гариза язалар. Хәерби авылы кешеләренең, Шәле, Пәрәү авыллары кешеләре белән берләшеп, Бимә җыены (Бимский сход) үткәрүләре дә тарихта теркәлеп кала.

1859 елда Казан губернасының торак пунктлары исемлегеннән Татар Хәербие һәм Рус Хәербие исемле ике авыл барлыгы күренә (**Кушымта 1, 2**).

Гомумән, архивларда Хәерби авылы турында шактый материал табылды (**Кушымта 2**). Алардан Татар Хәербие һәм Рус Хәербие дигән ике авыл булуы да күренә. Отставкадагы поручик улы, җирбиләүче А.М.Протопоповның

Рус Хәербие авылында крестьян җирләренең планын һәм күчермәсен сорап язган прошениесе очрады (**Кушымта 3**). Бу ике авыл кайчандыр янәшә булып, тора-бара Татар Хәербие, ә аннары Хәерби булып кына калган. Архивта эзләнүләр үткәргәндә авыл исеменең төрлечә язылышына тап булдык. Мәсәлән, Каирби, Каирбей, Русские Каирби, Татарские Каирби, Хайрби.




Казан губернасы Лаеш өязенең Генераль межалау планы фрагменты. 1793 ел.

Шулай ук Хәерби авылы турында Россия Дәүләт борынгы актлар архивы (РГАДА) һәм Татарстан Республикасы Дәүләт архивында (ГА РТ) саклана торган документлар исемлеге дә бирелә (**Кушымта 4, 5**).

Метрика кенәгәләре гарәп хәрефләренә нигезләнгән иске татар графикасында, татарча язылган. «Ревизия язмалары» («Ревизские сказки»)[1] дип атала торган җанисәп документлары рус телендә тутырылган. Аңлаешлырак булсын өчен китапта 1834 елда язылган «Ревизские сказки»ның күчерелмәсе тәкъдим ителә (**Кушымта 6, 7**). Бу документлар Татарстан Республикасы Дәүләт архивында саклана. Беренче өлеше 1834 елның 18 февралендә (Татарстан Республикасы Дәүләт архивы. 3 нче фонд, 2 нче тасвирлама, 49 нчы эш, 99–113 битләр), ә икенче өлеше шул ук елның 12 мартында (Татарстан Республикасы Дәүләт архивы. 3 нче фонд, 2 нче тасвирлама, 48 нче эш, 58об.–63 битләр) язылган. Таблицадан күренгәнчә, 1816 һәм 1834 елларда яшәгән кешеләрнең яше, гаилә хәле: хатыны, балалары, дөнья куйганнарының вафат булган еллары, яңа туган балаларның туган елы күрсәтелеп бара. Ике таблица нәтиҗәләрен кушсак, 1834 елда Хәербидә 197 ир-ат, 208 хатын-кыз яшәгәнлеге күренә.

1 Ревизияләр – Россиядә салым түләүче халыкның исәбен алу. Салым түләүнең нигезе шәхси хуҗалыкларга корылу сәбәпле, ревизияләрнең дә нигезе хуҗалыкларны барлау булган. Россиядә үткәрелгән ревизияләр: I. 1718–1719–1727 еллар; II. 1743–1746–1747 еллар; III. 1761–1762–1767 еллар; IV. 1781–1782 еллар; V. 1794–1795 еллар; VI. 1811 ел; VII. 1815–1816 еллар; VIII. 1833–1834 еллар; IX. 1850 ел; X. 1857–1858 еллар.

## ХӘЕРБИ АВЫЛЫ ТОПОНИМНАРЫ

Топонимика географик атамаларның җыелмасын, аларның килеп чыгышын, ясалышын, кулланылыш һәм үсеш эволюциясен, мәгънәсен, таралышын өйрәнә һәм тикшерә. Топонимнар билгеле бер җирдә яшәгән халыкның тормыш-көнкүреше, тарихы белән бәйләнгән. Хәерби белән бәйләнешле атамалар да авылның тарихын тирәнрәк белү өчен кирәк. Бу топонимнар авылның үткәнен, урнашу урыннарын, халыкның тел үзенчәлекләрен, кәсеп-хезмәтләрен, көнкүрешен ачыклау һәм хәтердә саклау мөмкинлеге бирә. Хәерби кешеләре телендә дә үзләренә бик якын һәм аңлаешлы Миләүшә таулары, Кайнывак, Ачканбай, Благай, Чарлаксаз, Шәриф канавы, Карга урманы, Фран елгасы, Җимерек елга, Труба юлы, Чибәш канавы, Бүре сазы, Куян атавы, Талтамак болыны, Карга урманы, Урака юлы, Тегермән Алан, Бай урамы, Атау урамы һ.б. атамалар бар. Алга таба алар сәхифәләребезгә үрелеп барыр.

## РИВАЯТЬЛӘР ТУАР ХИКМӘТ БЕЛӘН...

Халык арасында сөйләнеп килгән риваятьләр буенча, авыл башлыгы – би – Хәйретдин дигән кеше булган, шуңа нисбәтле авыл Хәйретдин би авылы дип йөртелә башлаган, соңыннан, әйтелеше җиңелрәк булганга, **Хәерби** авылы дип аталган, имеш. Авыл халкы үзенең күнегелгән яшәү урыныннан хәзерге урынга килеп утырганда авыл тирәләрен күлләр, сазлыклар һәм куе кара урманнар каплаган була. Күчеп утыру өчен сайланган урын хәзерге авылның көньягындагы **Түбән урам** һәм хәзерге **Бай урамының** бер өлешенә туры килә. Килеп урнашкач, халык авыл тирәсендәге ерым-чокырларга, калкулык һәм сазлыкларга исем бирә. Хәербинең көньяк-көнбатыш өлешендәге калкулыклар **Миләүшә таулары** дигән атаманы үзләре үк сорап тора, чөнки иртә язда бу тау битләрендә хуш исле зәңгәр чәчәкләр – миләүшәләр бик күп үсә. Менә шул Миләүшә тауларыннан башлап Мишә елгасына кадәр куе кара урман җәелгән була. Шул урман Хәерби кешеләрен православие миссионерларының чукындыруыннан да саклап калган, диләр. Соңыннан, бу урман биләмәләрен, якын-тирәдәге басу-кырларны Салих бай (Казан сәүдәгәре Салих Сабит улы Гобәйдуллин) сатып ала. Шуңа урманны **Бай урманы** дип йөртә башлыйлар. Еллар үтү белән урман сөрүле җир киңәйтелү хисабына кысыла бара, 1917 елгы Октябрь революциясеннән соң киселеп бетә. Урманның истәлеге булып Миләүшә



Миләүшә таулары янында Сабан туе.

тауларындагы әрәмәлек кенә кала. 1973 елга кадәр әрәмәлек авылга терәлеп үк торган әле. 1972 елда җәй буе яңгыр яумый, корылык була, шуның нәтиҗәсе буларак, 1973 елда байтак куаклар язын яфрак яра алмыйча корыйлар. Әрәмәлек шулай кечерәя.

Хәерби авылы үргә урнашкан. Көньяктан караганда ул тау башында, ә көнбатыштан караганда тигезлектә урнашкандай күренә.

Хәербидән Мишә елгасына илтүче юл өстендә халык телендә **Әчкә** дип йөртелә торган күл бар. Бу әлләни зур булмаган табигый күл. Авылга терәлеп үк торган икенче бер күлне **Бай күле** дип йөртәләр, монысы табигый күл түгел. Кайчандыр Миләүшә тауларының **Чишмә елгасы** дип йөртелгән ерымыннан чишмә бәреп чыккан һәм шушы күл урыныннан аккан. Кешеләр чишмәне буып, үзләре өчен ясалма күл булдырганнар. Буаны эшләтүче кеше Салих бай булган, шуңа күрә күлне дә **Бай күле** дип атаганнар. Ләкин тора-бара мул сулы чишмә буадан ташып, байның иген кырларын баса башлаган. Шуннан бай чишмә бәреп чыккан урынны тегермән ташы белән бастырган. Чишмәдән туенып тормаса да, күлгә язын кар сулары җыелган, җәен аңа яңгыр сулары да өстәлеп,



Бай күле.

күл халыкка күп файда китергән, анда җәй буе бала-чага су коенган, хатын-кызлар кер юган-чайкаган, малайлар ат коендырган.

1950–1960 елларда кышын күлдән торф чыгарганнар. Колхозда кәбестә утырту өчен торфтан кечкенә чүлмәкләр ясаганнар, яшь үсентеләрне башта шул чүлмәкләрдә үстергәннәр. 1990 елларга Бай күле, аңа Миләүшә тавының **Җимерек елга** дип йөртелгән ерымыннан ком ташылу сәбәпле, саеккан, каз-үрдәкләр йөзәрлек кенә калган. Алай да, 2000 елларда авыл кешеләре маймыч җибәреп, күлдә балык бик үрчегән, шунлыктан аны акчарлаклар, кыр үрдәкләре һәм ләкләкләр үз иткән. 2010 еллардан соң күл тагын да саега. Хәзер инде анда каз-үрдәкләр дә күренми. Әмма күл үзенең матурлыгын саклап калган, май аеның һәм июнь башларының җылы кичләрендә анда бакалар хоры искитәрлек! Ышанмаган кеше җәй башында Хәербигә килеп үзе тыңлый ала.



Җимерек елга.

Авылның көнбатыш өлешендә Ачканбай болыны җәелеп ята. Элек монда да сазлык булган. Салих бай сазлыкның суын киптертеп, аны куаклыклардан чистарттыра. Бу урынны бай ачкан болын дип йөртә башлыйлар. Тора-бара ул телгә Ачканбай болыны дип кереп киткән, имеш. Язларын Мишә суы, ярларыннан чыгып, Ачканбайга җәелә. Монда печән бик уңа.

Авылның көнчыгыш өлешендә **Благай** дип йөртелә торган икенче бер болын бар. Анда да элек сазлык булган. Җәйләрен, мондагы камышлы җылы суда тукланыр ризык җитәрлек булганга, Благайга кыр үрдәкләре, торналар һ.б. су кошлары күпләп кайткан. Ә кышларын, сазлык өсте боз белән каплангач, авыл халкы бирегә камыш урырга килгән. Камышны өй, абзар түбәләрен ябу, ишегалларын томалау өчен кулланганнар, ул мичкә ягарга да яраган. Благайның суларын 1954 елда Мишә елгасына агызганнар. Хәзерге вакытта ул кайчандыр казылган канаулар белән турыпочмаклык рәвешендәге зур-зур өлешләргә бүленгән хәлдә. Канау эзләре әле дә беленеп тора. Монда торф күп. Торфлы җиргә учак ягу тыелу турында кагыйдәне бозу сәбәпле, Благайның җәй буе янган чаклары булган.

Авылдан Мишә елгасына таба барганда **Чарлаксаз** янынnан үтәбез. Бу сазның элеккеге исеме Акчарлак сазы булган диләр. Урманнар киселгәч, сазлыклар киптерелгәч, бу урын да печән җиренә әверелгән. Благайны киптергәндә, экскаваторлар белән **Шәриф канавын** тирәнәйтеп, Чарлаксазның суын да Мишәгә агызганнар. Ни өчен Шәриф канавы дисәк, бу аны казыган Шәриф исемле кеше исеменә нисбәтле. Ул шул рәвешчә үзенең имана җирен арттырырга уйлаган. Шәриф абыйның нәсел дәвамчылары Хәербидә бүгенге көндә дә яшиләр. Мәсәлән, «Хәерби» ачык акционерлык җәмгыяте директоры Радик Кадыйр улы Вафин Шәриф бабайның оныгының оныгы була.



Кайнывак күле. 2002 елгы фоторәсем.



Хисам күле. Назимә Хисам кызы йорты. 20 гасырның 80 елларындагы күренеш.

Атамаларны тормыш үзе өсти тора. Хәербидән Сокуры авылына бара торган якта басуны аркылыга бүлеп җир астыннан газ һәм нефть үткәргечләр сузыла. Шуннан үткән юлны хәербилеләр **Труба юлы** дип атыйлар. Труба юлы буйлап Мишәгә барганда, кырда түбәтәй кебек түгәрәк, зур булмаган калкулык бар. Аны **Мал тавы** дип йөртәләр. Риваятьләр буенча, монда кайчандыр бай хәзинә табылган, бу хәзинәдәге күп акчаларны Казан ханы суктырган, имештер, бу хәзинә җиргә XV гасырда күмелгән булган. Бу әйтелгәннәрнең тарихи яктан исбатланганы юк, ләкин Мал тавы дигән калкулык бар һәм бу риваять тә яши.

Югарыда телгә алынган Труба юлы буйлап **Чибәш канавы** сузылган. Анда кайчандыр Сибгать исемле кеше үлгән, аны Сибәш дип

йөрткәннәр. Бу урынга исем шул кешегә нисбәтле. Авыл уртасындагы күл дә кеше исеме белән аталып йөртелә. Бу — Хисам күле.

Авыл халкы болын, чокыр, саз, юл, тауга үзе өчен җайлы атамалар тапкан (**Бүре сазы**, **Куян атавы**, **Талтамак болыны**, **Карга урманы**, **Урака юлы**, **Тегермән Алан** һ.б.). Авылның көндәлек тормышында хәзер дә шул килеш кулланылышта алар. Халык аларның яңгырашына күнегеп, исемнәре чыгуга, картадагыдай күз алдына китереп, калкулыкларында чәчәк, җиләк җыеп, болынында печән чабып, сәхраларында көтү көтеп, юлларыннан кинәнеп атлап, елга-күл суларында коенып, балык тотып, үзләрен шуларның хуҗасы итеп тоеп, төнлә уятып сорасалар да онытылмас-буталмаслык итеп җаннарына бикләгән. Бу атамалар авылның үткәне, халкының тел үзенчәлекләре, кәсеп-хезмәтләре, йола-тәртипләре, көнкүреше турында күпме сабак биргән икән!

## ГРАЖДАННАР СУГЫШЫ ҺӘМ АННАН СОҢГЫ ЧОР

1917 елгы Октябрь революциясеннән соң байларның маллары тартып алынса да, җирләре тиз генә бүленми. Хәербидә дә бай җире берничә ел буш ята. Алпавыт җирләре ирләргә дә, хатын-кызга да тигез итеп бүленә. Хәерби крестьяннарының җире бик аз булганлыктан, халык моңа бик сөенә.

1918 елда авылга ак чехлар керә. Бу Чех-словак корпусы калдыкларының Казанны калдырып китеп барган чагы була. Аклар Хәербидә берничә көн генә торып алалар, киткән чакта авылдан атлар, азык-төлек алып китәләр. Билгеле, халык булган әйберен яшерә, ак чехларга өлеш күп чыкмый. Ләкин иң шөбһәләндергәне аларның авылның кайбер ир-егетләрен дә мәҗбүри рәвештә үз гаскәрләренә кушып алып китүе була. Сөенечкә, бу кешеләр озак тормый, чехлардан качып, кире әйләнеп кайталар. Бу чорда авыл кешеләре арасыннан Кызыл Армиядә хезмәт итүчеләр була. Вәлиуллин Гарифулла, Насыйбуллин Гәрәй, Галиев Хәсән, Ситдыйков Кадыйрлар – беренче кызылармиячеләр.

Гражданнар сугышы чоры авыл хәтеренә бик михнәтле еллар булып кереп кала. Халыкның көнкүреше авырая. 1921 елгы ачлык вакытында бик күп кеше ачтан үлә. Җитмәсә, төрле авырулар: чәчәк, ваба, тиф һ.б. тарала. Хәербидә терлек заты, эт, мәче калмый. Болын һәм кырлардан аунап яткан мал сөякләрен җыеп, аннан он тарттыралар. Сөяк оны, черек бәрәңге, кузгалак, кычытканнан «аш» әзерләп ашыйлар. Авылда күз төшәрлек бер кыйммәтле, затлы-зиннәтле әйбер калмый – барысы да азыкка алыштырыла. Гаиләләре белән үлеп бетүчеләр дә була.

## АВЫЛ XX ЙӨЗ БАШЫНДА

XX йөз башында халыкның көнкүреш дәрәҗәсе түбән була. Кешеләр өйдә тукылган киндер күлмәк, чабата киеп йөри. Өйләр кечкенә һәм тәбәнәк була. Өй түбәләре камыш яки салам белән ябыла. Капка-коймалар кабыктан, читәннән үреп ясала. Авыл тирәсендә урманнар булса да, халык аннан файдалана алмый. 1917 ел революциясеннән соң Бай урманының рәхимсез рәвештә кисеп ташылуына гаҗәпләнмәскә дә була.

Элегрәк заманнарда өйне чыра яндырып яктырталар, ул сөрем чыгарып яна. Хәербигә беренче лампаны һәм беренче самоварны Насыйбулла бабайның әтисе алып кайта. Бүгенге көндә авылда Насыйбулла бабайның оныгының баласы һәм оныгының оныклары яши. Бу – Гәрәев Фәрит һәм аның балалары. Сүз уңаеннан шуны да әйтергә кирәк: самовардан чәйне бәйрәмнәрдә генә эчәләр һәм бары олылар гына самовар янына утыра.

Авылда мәдрәсә эшләп тора. XX гасыр башында мәдрәсәдә 40 малай һәм 30 кыз кадимчә белем ала. Хатларга адрес язасы булса, авыл халкы Вәлиев Гаяз агага бара. Ул авылда русча адрес яза белүче бердәнбер кеше була.

Хәербинең Бай урамында (Гаязов Ибраһим, Садыйкова Фаизәләр урынында) Казанның беренче гильдияле сәүдәгәре С.С.Гобәйдуллинның зур алма бакчалы дачасы урнаша. Аның ике катлы, 42 бүлмәле йорты да шунда корыла. Шуңа да «Бай урамы» бит инде ул.

Сокуры белән ике арада исә икенче бер байның зур утары була. Анда бай үзе тормый, бәлки аның ышанычлысы гына яши һәм эшне алып бара. Мондагы утарны алпавытның пар тегермәне, сыер-сарык абзарлары, зур бакчасы, ялланып эшләүчеләр өчен салынган йортлары тәшкил итә. Бу урынны Хәерби халкы Яңа авыл дип йөрткән, арадан байтагы шунда ялчы яки көнлекче булып гомер сөргән.

1918 елның җәендә Хәербидә зур янгын чыга. Хәзерге Атау урамы тулысынча диярлек янып бетә. Халык янгын сүндереп мәш килгәндә Әхмәтша исемле бер кеше Яңа авыл ягыннан кайтып керә дә: «Ни эшләп ятасыз, «сукырлар» (Сокуры авыл кешеләре, ягъни) Яңа авыл алпавытын талыйлар! Без өлешсез калабыз!» – дип кычкыра. Бу хәбәрне ишетеп, халык, янгынны сүндереп тә бетермичә, алпавыт утарын таларга торып йөгерә. Хәербиләр барып җиткәнче, Сокуры кешеләре байның сыер-сарыкларын, атларын үзара бүлешеп бетергән була. Малдан коры калган Хәерби кешеләре, моның белән ризалашасылары килмичә, Сокуры кешеләреннән өлеш чыгаруны таләп итә. Тегеләре риза булмагач, ике арада сугыш чыга. Алпавытның бер

баш терлеге, бер бөртек игене калмый: бар да талана, туздырыла. Өйләрен сүтеп бүрәнәләрен алып китәләр, аннан соң тегермәнен һәм хәтта йорт нигезендәге ташларга кадәр сүтеп ташыйлар. Хәзерге вакытка кадәр телсез шаһит булып бу утарның эзе саклана: кирпеч һәм таш ватыклары аунап ята, бакча урынында инде ничәнче кат кабат яңарган канәфер куаклары үсеп утыра. Салих бай дачасын да туздырып-бөлдереп бетерәләр.

XIX гасыр ахыры – XX гасыр башларында күршедәге Травкино авылы белән Миләүшә тавы арасында бай немец Франкның да утары була. Миләүшә тавындагы бер ерымны әле дә «Фран елгасы» дип атыйлар. Шул елга башында бу кешенең бакчасы, умарталыгы булган дип сөйлиләр.

## ХАЛЫКНЫҢ ТУКЛАНУЫ

Хәерби халкы гомер-гомергә иген иккән, шуңа күрә ашар ризыгын күбрәк оннан, ярмадан әзерләгән. Арыш, бодай, борчак, арпа һәм солы онын, тары, карабодай һәм борай, соңрак дөге ярмасын киң кулланганнар. Тарттырылмаган борчак белән ясмыктан төрле ашамлыклар әзерләгәннәр.

Авыл халкы ит яраткан, сарык, сыер, ат итеннән төрле ризыклар әзерли белгәннәр. Яңа суйган терлек итен өстен күргәннәр, итне җәй көне тозлап кулланганнар. Ат итеннән шулпа пешергәннәр, тутырма ясаганнар. Сөттән май, сөзмә, эремчек, катык, каймак, тура (корт) кебек ризыклар әзерләнгән.





Шулпа, тутырма, тура (корт).

Ә менә яшелчәләр белән эш башкачарак торган. Хәербидә яшелчә утыртмаганнар. Җәйләрен күрше Караишево авылыннан рус хатыннары чиләкләп тозлы кәбестә күтәреп килгәннәр һәм ярты литрлы бер банка кәбестәне бер йомыркага алыштырып биргәннәр. Шулар ук бер бәйләм суган бәбәген дә бер йомыркага алыштыра яки сатып бирә торган булганнар.

Вакытлар үтү белән хәербиләләр кыяр, помидор, суган, шалкан, әче торма, кишер, кабак, чөгендер, кәбестәне үзләре дә утырта башлый. Ләкин яшелчә








Авыл халкы әрәмәдән, тугайдан җиләк, балан, бөрлегән, чикләвек, мәтрүшкә һәм сары мәтрүшкә җыйган.

ризыкларының күбесе сезонлы гына кулланыла. Яшелчә үстерү һәм куллану, нигездә, Бөек Ватан сугышыннан соң башлана һәм акрынлап колач ала. Ә шулай да алардан төрле ризыклар эшләргә, кыш өчен күп итеп тозлап яки маринадлап куярга узган гасырның соңгы дистәләрендә генә өйрәнеп җитәләр дисәк тә ялгыш булмас. Илленче-алтмышынчы елларда авылда берничә генә гаилә, мәсәлән, Юнысов Габдулла, Нигъмәтов Хабуллар кышка кәбестә тозлап куя торган була. Алар кәбестәне 8–10 чиләк су сыешлы агач чапчакларда тозлыйлар. Кыш көне кем авырый, кемнең күңеле тели – болардан кәбестә алып китәләр, һәм, билгеле инде, бушлай.

Җиләк-җимешне авыл халкы гомер буе әрәмәдән, тугайдан җыйган. Хәерби халкы бигрәк тә балан яраткан. Аны пешереп бәлеш эчлеге ясаган, как койган, киптереп, төеп «балан оны» әзерләп куйган. Кыш көне балан онына бераз алма яки слива повидлосы өстәп, бәлеш пешергәннәр. Җиләкләрдән дә как койганнар, шулай ук кыш өчен киптереп тә куйганнар. Хәзер инде авыл халкы яшелчәсен дә, җиләк-җимешен дә йорт яны бакчасында үзе үстерә. Авыл апалары-әбиләре, киленнәре-кызлары төрле кайнатма, джем, повидло һәм компотны һәркайсы үзе белгәнчә осталык белән ясый һәм аларны кыш өчен күпләп әзерләп куя.

## ЙОРТ-ҖИР, ТОРМЫШ-КӨНКҮРЕШ

XX гасыр уртасында авылда түбәсе калай белән ябылган йортлар саны арта. Чыбыктан үрелгән читәннәрне такта яки рәшәткә коймалар алыштыра. Капкалар да нык, биек итеп ясала башлый. 1960 елларның ахырларында авылда түбәсе салам белән ябылган өй һәм каралты-кура калмый инде.

Сугыштан соңгы елларда халык мунчасыз интегә. Күп кешенең үз мунчасы булмау сәбәпле, булганнарына чират торып ягалар. Авылның бер башыннан икенче башына кадәр мунчага бару гадәти хәл санала. Ак мунчалар элек-электән мулла гаиләсендә яки берничә хәлле кешедә генә булып, күбесенчә кара мунчада юынганнар. Кара мунчаның миче морҗасыз итеп өелә, төтене-сөреме стенадагы махсус тишектән – төнлектән чыга, сөреме, әлбәттә, стеналарга да ягылып кала. Мунчалар йорт-җирдән читкә, бакча башларына салына. Бу ут-күздән саклану өчен эшләнә. Тормыш көйләнгән саен мунчалар арта бара, хәзер инде мунчасыз хуҗалыклар юк дәрәҗәсендә.



Халык киндер тукымадан тегелгән кием киеп йөри. Хатын-кызлар да, ирләр дә озын балаклы ыштан кияләр. Ул чакта ирләр чалбарны белми әле. Ыштанның бөрмәсенә кереш (резинка) түгел, ә шул ук киндер тукымадан тегелгән бау кертелеп, бәйләп куела торган булган. «Ыштан бавы» хәтта халыкның җырларына да кереп кала:

Печәнчеләр эшкә бара,
Стройга тезелеп.
Шуның берсе артта калган
Ыштан бавы өзелеп...



Кышка кергәч, бик күп өйләрнең түренә туку ыстаны (станогы) менеп утыра. Авылның уңган хатын-кызлары күлмәк-ыштанлык киндер тукыйлар, сөлге-тастымал сугалар. Сөлгеләр озын (2 м) итеп, баш-башлары кызыл төстәге җепләр белән бизәкләп сугыла. Авылда бу эш әле XX гасыр уртасына кадәр дә дәвам иттерелә. Совет чорында моның остасы Юнысова Фәйрүзә апа була.

Резина галошлар гасыр башында бик затлы аяк киеме санала. Аны сабан туе көнне генә кияләр. Ялтыравыгын кояш ашамасын дип, анда да әрекмән яфрагы белән каплап утыралар. Бәйрәмнән соң галошлар юылып, сандыкка ук салып куела. Шәһәргә барасы булса, кайбер ир-атлар күнитек кияләр. Ләкин җәяү барырга туры килгән очракта алар күнитекне биштәргә салып аркага асалар, чабата киеп, яисә яланаяк тәпилиләр. Кирәкле урынга җиткәч, итекләрен алып кияләр. Күнитек авыл халкы өчен бик кадерле, затлы аяк киеме була һәм аны бик сирәк кенә, аеруча бәйрәмнәрдә генә кияләр.

Кышларын исә эш җайлырак: киез итеккә күчелә. Сарык асрагач, киез итекле булырга була. Хәербилеләр үзләре итек басу эшенә оста түгел, йонны Күнтәчкә – Кунтечи дигән рус авылына илтәләр, ә андагы осталар менә дигән итек басып бирә. Кайбер елларда күрше-тирә районнардан итек басу осталары килеп, авылда итек басып яталар. Алар башта бер гаиләгә килеп керәләр. Гаиләнең заказын үтәп, шул йортның мунчасында итек басалар. Шул йортта торалар да. Бу йортта эш беткәч, мунчасы булган икенчесенә күчәләр. Шулай, чират буенча, авылның заказы беткәнче йөриләр. Тегүчеләр белән дә шул ук хәл. Авылга тегүчеләр килгәч, алар башта бер, аннары икенче гаиләдә торып, хуҗага, аның хатынына, бала-чагаларына бишмәтләр тегәләр. Ул чакта мех якалы бишмәт киючеләр сирәк була. Кешеләрне суыктан сарык тиресен иләп тегелгән кайры тун саклый.



Өйнең эче бик гади: ипи салу өчен киң төпле итеп чыгарылган мичнең аш пешерү өчен казаны һәм учагы да була. Мич авызын кече якка каратып, өйне бүлмә тактасы белән икегә бүләләр. Кече як кухня хезмәтен үти, аны почмак дип йөртәләр. Өйнең түрен тулысы белән сәке алып тора. Сәкегә ашъяулык җәеп, аның тирәсенә аяк бөкләп утыралар. Сәке бу очракта аш өстәле булып тора. Ашап-эчкәч, табынны җыештыралар. Ә кичен шул ук сәке караватвазифасын үти. Өйләрдә мендәрләр, түшәкләр булса да, кайвакыт аска иске бишмәт салып, өскә дә бишмәт ябынып йоклау гадәти хәл булып санала. Һәрбер өйдә ипи көрәге, ухват, чуен, кисәү таягы, пумала, киле була.

Чәйне самовар куеп эчәләр. Ашны казанда пешерәләр, аны табакка сосып алалар һәм бөтен гаилә бер табактан ашый. Ашка иң беренче ата-ана үрелергә

тиеш. Әгәр берәр бала бу тәртипне бозса, агач кашык белән кулына берне сугып та алалар. Бу гасырлар буенча килгән гадәт балаларны олыларга хөрмәт белән карарга, ата-анадан узмаска өйрәтә.



Тәрәзәләрнең өлгеләре элекке заманнарда карындыктан тарттырыла. Алар бик кечкенә була һәм яктылыкны да начар үткәрә. Заманнар үтү белән пыяла тәрәзәләр куела, ләкин әле алар бер катлы гына була. Ике катлап куелмагач, аларга боз ката. Кышка әзерләнгәндә һәр тәрәзәнең өстәге өлгесен генә капламый калдырып, калган өлешен тыштан аркылы такта белән каплыйлар, ә тәрәзә белән такта арасына мүк яки салам тутырыла.

Көзләрен өй тирәли казык кагып чыгып, читән тоталар. Өй белән читән арасына салам тутыралар. Салкыннан шул рәвешле саклаактлар.

XX гасыр урталарына кадәр авылда чиратлап каравыл тору тәртибе була. Һәр көнне бер хуҗалык авыл буенча кизү санала. Йорттан бер ир кеше төнлә



Иске кое. 2019 елда яңартылган.

йокламый, урам буйлап такылдавык шакылдатып йөри. Монысы авылны уткүздән һәм явыз ниятлеләрнең яман эшләреннән саклау өчен алдан күрелгән чара була.

## АВЫЛ УРАМНАРЫ ҺӘМ ӨЙЛӘРЕ

Бер әйләник авыл урамнарын... Хәербидә өйләр төзек, матур, буялган. Хуҗасы булып та, кадерсезләнеп яткан бер генә йорт та күренми. Арада хуҗасыз буш калган өйләр дә бар. Авыл кешеләренең уңганлыгы, пөхтәлеге, җыйнаклыгы күзгә ташлана. Тәрәз төпләрендә матур гөлләр үстерәләр.

Хәерби авылы өйләреннән торган фотосурәтләр җыелмасы һәр кешедә сагыну хисләрен уятыр, балачакларыннан җылы һәм шатлыклы хатирәләрен кайтарыр дип тәкъдим итәбез.






























































































































КИРБИ

# V БҮЛЕК

# ЕГЕРМЕНЧЕ ГАСЫР: ЯШЬЛӘР ҺӘМ БАЛАЛАР

Бер гасыр тарих өчен күп вакыт түгел түгелен. Ләкин шушы бер гасырда авыл яшьләренең никадәр үзгәрүен күрсәгез иде!

XX гасыр башында кич утыру, башка авылдан кунак кызларының утырмага килүләре кебек авыл элек-электән белгән матур гадәтләр яши. Әти-әни рөхсәтеннән башка төн буе урамда йөрү – күз күрмәгән, колак ишетмәгән бер хәл була. Егетләр һәм кызлар су юлында очрашырга җай табалар табуын, аны өлкәннәр дә күрмәмешкә салыша. Кызлар су китерә, егетләр ат эчертәләр. Бер-берсен шулай да күзләмәгәч, алар ничек табышсын-кавышсын?!

Кеше тормышындагы өйләнү, кияүгә бару кебек вакыйгалар әти-әни рөхсәте белән генә эшләнә. Балигъ булган улны өйләндерү, җиткән кызны кияүгә бирү ата-ананың Ходай каршындагы бик зур бурычы булып тора. Өйләнү-кияүгә чыгу белән бәйле йолалар тормыштагы иң әһәмиятле йолаларның берсе итеп карала. Эшләр аңа барып җиткәнче, авылның яшьләргә кагылышлы бик күп күңелле хасиятләре була әле. Шуларның иң билгелесе – кичке уеннар. Кичке уеннар, гадәттә, су буенда оештырыла. Кичке уен дисәк тә, алар кояш батканчы бармаган, кызлар энеләре күзәтүендә булган.

Әти-әниләр юкта өйдә кич утыру, аулак өй үткәрү иң күркәм гадәт санала. Аулак өйгә теләсә кемне кертмиләр, сайлап кына чакыралар. Бер-берсенә тиң



«Ак калфак» фольклор ансамбле сәхнәдә аулак өйдә кич утыру күренешен сурәтли.

булган, иш булган егет-кызлар анда җыелып күңел ачалар, төрле уеннар уйныйлар. Исеме аулак өй булса да, өйдә бер олы кеше барыбер кала. Ул, гадәттә, берәр үткенрәк җиңги булып, почмак якта утыра, бүлмә ярыгыннан карап, яшьләрнең үз-үзләрен тотышларын күзәтеп тора.



1 рәттә Мәгъсүмә, Миңнебикә, Сөембикә, Хәтирә улы Рушан белән, Нәсимә кызы Фирая белән. 2 рәттә: Сафин Хәйдәр, укытучы; эшләпә кигән кеше билгесез; Габдерәүф; гармун белән Миңнегәрәй; Харис; Миңнулла; Әхмәт.



Җәмилә апа балалары, туганнары белән.



Дания һәм Галимҗан Насыйбуллиннар балалары, туганнары белән.



1 рәттә: Әсхәт, Мәгъсүм;
2 рәттә: Галина, Роза, Гөлшат.





Сабан туе. Равил, Галимҗан, Зариф һәм кунак егете. 1966 ел.



Мансур Галәвов, Әмин һәм Рауза Закировлар, Фәимә, Зәлифә (кунак кызлары).



Гөлфирә Нигъмәтова.
1971 ел.







1. Фәрит, Зәкәрия абый, Рамил; 2. Айрат, Алсу; 3. Гайшә Сәлахова кызлары белән.




Минвәли Гыймадиев (артта, сулдан икенче) Мәскәүдә Бөтенсоюз авыл хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсендә.



Рәисә белән Әлфия.



Мөхәммәт, Җамали абый Казан Сабан туенда.



Нуриев Әхмәт, Хәмидуллин Минвәли.



Маһруй апа белән Фердинанд.



Сара, Сания, Әхмәт, Гайшә.



Хәмәтхан белән Кыям хәрби хезмәттә.



Гөлйөзем, Роза, Шамил, Әлфия. Сабан туе.



Закирова Галия кызлары һәм оныгы белән.










1. Бер урамда үскән кызлар: Гөлнара, Әлфия, Асия, Гөлшат, Сәмия, Миңнеруй, Альмира; 2. Әлфия һәм балалар; 3. Рәмзия һәм Илдус Булатовлар.













1–2. XX гасыр уртасында авыл яшьләре; 3. Бер урамда үскән егетләр: Рөстәм Хәсәнов һәм Әюп Юнысов; 4. Равия Закирова, Рузалия Абдуллина, Сания Солтанова. Артта: Ләйлә Хәмидуллина, Нәкыя Харисова, Нәзирә Фатыйхова; 5. Укытучы Гөлшат Кәримуллина укучылары белән. 1970 еллар уртасы; 6. Куян фермасында: Миңнегали, Флёра, Әлфия. 1970 еллар башы.













XX гасырда яшьләр һәм балалар.















XX гасырда яшьләр һәм балалар.















XX гасырда яшьләр һәм балалар.









XX гасырда яшьләр һәм балалар.

# VI БҮЛЕК

# МӘЧЕТ, ИМАМНАР

Хәерби авылында мөселман мәхәлләсенең теркәлү вакыты төгәл билгеле түгел. Кайбер язма чыганаклар Хәерби авылында XVIII гасырда ук мәдрәсә булганлыгын раслый. Борынгы татар әдәбияты һәм кульязмалар буенча мәгълүматлы белгеч Зәйнәп Максудованың (1897–1980) кульязмалар тупланмасында[1] Казан вилаятенең Хәерби авылында Габдәш бине Габдесәлам дигән мөдәрриснең мәдрәсә тотуы, аның мәдрәсәсендә укыганда, 1790 елда, Максуд бине Корбангали дигән шәкертнең бик матур каләм белән «Мелла Җами» китабын күчереп язып чыгуы әйтелә. Димәк, авылда 1790 елда ук мәчет-мәдрәсә булган! Без алга таба, аерым бүлектә, Максудилар нәселенә исем биргән Максуд атлы ул булдыклы шәкерт турында тәфсилләбрәк сөйләрбез.

XIX гасыр башында Хәербидә мәчет эшләгән, анда Казан губерна идарәсе тарафыннан билгеләнгән дин әһелләре хезмәт иткән. Хәерби авыл советы ар-



Хәерби авылы мәчете – XX йөз башы татар архитектурасы истәлеге. 1960 еллар фотосы.

1 Бустанов А.К. Библиотека Зайнап Максудовой = Зәйнәп Максудова китапханәсе. М.: 2019.

хивы материаллары буенча, 1907 елда янгын чыгып, мәчет яна. Ул 1873 елда салынган мәчет була.

Бүгенге көнгәчә сакланып килгән мәчет бинасы 1908 елда Казанның 1 нче гильдия сәүдәгәре С.С.Гобәйдуллин акчасына салына. Бу мәчет 1909 елның февралендә эшли башлый. Бинасы ике залллы, манарасы түбәдән күтәрелә. Бер катлы агач бина ике кыеклы түбә белән ябылган һәм традицион стильдә эшләнгән. Аның анфилада рәвешендә – берсе аркылы икенчесенә үтешле итеп тоташкан өч бүлмәсе: вестибюль һәм ике гыйбадәт залы бар. Мәчеткә керү юлы – көнбатыш якта.

Зал ара дивар өстенә чатыр белән төгәлләнгән ике яруслы манара куелган. Азанчы менә торган бормалы баскычлы сигез кырлы тоташ ярус 1991 елда төзекләндерү эшләре вакытында калай белән тышлана. Бу гыйбадәтханәнең фасадлары бизәлешендә эклектик элементлар күзгә ташлана.

Мәчет тарихы имам Әбүбәкеровлар династиясе белән бәйле. Династия башында Әбүбәкер Гомәров тора. Төбәк тарихын өйрәнүче Р.Кушмина язмаларында аның 1838 елда имам булып сайлануы күрсәтелә. 1883 елда Әбүбәкерне 1859 елда туган улы Мөхәммәткәрим Әбүбәкеров алыштыра. Татарстан Республикасы Дәүләт архивында Татар Хәербие авылы җамигъ мәчетенә мулла итеп Лаеш өязе Татар Хәербие авылы крестьяны Мөхәммәткәрим Әбүбәкеровны билгеләү турында документ бар (**Кушымта 8**). Аңа олы туганы Мөхәммәтвәли Әбүбәкеров булыша. Ул 1883 елда мәчетнең икенче мулласы итеп билгеләнә. Тагын шуны да искәртеп үтәргә кирәктер, Әбүбәкер Гомәровның кызы Шәмсеруй – татар композиторы Солтан Габәшинең әнисе.



Мулла Мөхәммәтгариф Миңнегалиев. XX йөз башы.

1893 елдан Хәерби мәчетендә Гыйльман Сәлиев мулла булып тора. Ул бәйсез холыклы кеше булып, кайбер гамәлләре өчен хакимият тарафыннан берничә тапкыр эзәрлекләнә. 1896 елда Оренбург Мөселман Диния нәзарәте тарафыннан өч айга эшеннән читләштерелә, 1897 елда исә бөтенләй азат ителә. 1901 елда имам-хатиб итеп Татар Янтыгы авылы крестьяны – Хәерби мәчете мөәзине Миңлегали Бикбулатовның улы Мөхәммәтгариф (1874 елда туган) билгеләнә (**Кушымта 8**).


КАЗАНСКИЙ ОРДЕНА ТРУДОВОГО КРАСНОГО ЗНАМЕНИ ГОСУДАРСТВЕННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ имени В. И. УЛЬЯНОВА-ЛЕНИНА
НАУЧНАЯ БИБЛИОТЕКА имени Н. И. ЛОБАЧЕВСКОГО
ОПИСАНИЕ РУКОПИСЕЙ
Выпуск XII
РУКОПИСИ ТАТАРСКИХ ПИСАТЕЛЕЙ И УЧЕНЫХ
Третья часть
ИЗДАТЕЛЬСТВО КАЗАНСКОГО УНИВЕРСИТЕТА

КУЛЪЯЗМАЛАР ТАСВИРЛАМАСЫ
XII чыгарылыш
ТАТАР ӘДИПЛӘРЕ ҺӘМ ГАЛИМНӘРЕНЕҢ КУЛЪЯЗМАЛАРЫ
Өченче бүлек
КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫ НӘШРИЯТЫ



Казан университеты Фәнни китапханәсенең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә саклана торган кулъязмалар арасында Шәрәфетдин Болгариның[1] «Рисаләи Тәварихы Болгария» әсәренең берничә күчерелмәсе бар. Шуларның берсен («596 т.» шифры белән саклана, 85 битле) Хәерби авылында 1864 елда Миңлегали бине мулла Бикбулат бине Бикмәмәт бине Җаммат бине Түгәрәк бине Мәскәү әл-Хәербиуи әл-Алани әл-Янтыкый әл-Болгари әл-Казани дигән кеше күчереп язган дип күрсәтелгән. Димәк, Миңлегали Бикбулатов шул елларда Хәербидә мулла булып торган дияргә була.

Хәерби авылы мәчетенә караган кайбер архив материаллары Татарстан милли китапханәсе директоры урынбасары Ирек Һадиев тарафыннан тәкъдим ителә (**Кушымта 9, 10, 11, 18**).

XX гасыр башында Хәерби бер мәхәлләле авыл була. Анда 505 ир-ат, 510 хатын-кыз исәпләнә. Авыл 159 хуҗалыкны берләштерә. Мәчет каршында мәдрәсә эшли, анда 40 ир бала һәм 30 кыз бала белем ала.

1917 елгы Октябрь революциясеннән соң да мәчетнең эшчәнлеге дәвам итә. Совет власте урнашкач, мәчеткә йөрүчеләр кимүгә бара. Бу һич тә халыкның диннән читләшүен аңлатмый. Бары үтә сак авыл халкы яңа властьтан ни көтәргә белми борчуга кала. Яңа власть кайда да каты кылана. Ләкин, ни гаҗәп, Хәербидә мәчетнең манарасын кисмиләр.

Бөек Ватан сугышы елларында мәчет бинасын җылытып тору өчен утын әзерләүче калмый. Хакимият әгъзалары да диннең «әфьюн» булуын аңлатып,

---

1 Шәрәфетдин бине Хисаметдин әл-Мөслими әл-Болгари – XVIII гасыр ахырында – XIX гасыр башында яшәгән галим. «Тәварихы Болгария» («Болгар тарихы») исемле хезмәт авторы.



1995 елгы фоторәсем.



2003 елгы фоторәсем.

ара-тирә басым ясый. Дин тотучыларны мәчет бинасын мәктәп итеп файдалануга бирергә ризалаштыралар. Шулай итеп, анда балалар укыта башлыйлар.

Үзгәртеп кору чоры башланганнан соң, мәчет яңадан дин тотучыларга кайтарып бирелә. Бинасы төзекләндерелә: түбәсе алыштырыла, тәрәзә йөзлекләре буяла, мәчет үзе такта белән тышлана. Шуннан соң ул озак еллар дәвамында төзекләндерелми. Шактый таушалган бинаны төзекләндерү күп көч һәм чыгым таләп итә. Беркемнең дә мондый эшкә алынасы килми. Мәчетнең авылны күкләр белән тоташтырып, аңа ямь биреп, әллә кайлардан күренеп, күңелне



2018 елгы фоторәсем.

җылытып торучы манарасы бер якка авыша башлый. 1985 елда бу манараны кисеп, аның урынына кыскартып, яңасын ясап куялар. Тик ул да озак тормый, 1998 елда «Вафин һәм компания» ширкәте директоры Р.К.Вафин һәм Татарстан финанс министры урынбасары Ш.Х.Сөнгатов тырышлыгы белән мәчеткә элеккеге кебек матур, биек манара урнаштырыла. Манара башына куелган ай Рәфис Нәҗип улы Ногманов тарафыннан эшләнә.

Әлеге мәчет белән бәйле тагын бер фактка тукталып үтү урынлы булыр. Татарстан Милли китапханәсе директоры урынбасары Ирек Һадиев, Мәскәүгә командировкага баргач, профессор Сәлмән Газиз улы Гобәйдуллин белән таныша, сөйләшеп китәләр. Сәлмән ага тарихчы һәм язучы Газиз Гобәйдуллинның улы булып чыга. Г.Гобәйдуллин – татарлар арасыннан чыккан беренче профессор да. 1937 елда ул «пантюркизм идеологы» дигән яла ягылып, атып үтерелә. Ә Хәерби мәчетен салдыручы атаклы Салих Гобәйдуллин Газиз Гобәйдуллинның әтисе булып чыга. Сәлмән аганың үз бабасы салдырган мәчет турында ишеткәне дә булмаган, чөнки алар 1925 елда Бакуга күчеп китәләр. Ул шунда мәктәпне тәмамлый, югары белем ала, соңыннан Мәскәүгә күченә. И.Һадиев сөйләгәннәрне Сәлмән абый дулкынланып тыңлый... Шуннан соң ике арада хатлар алышу башлана. Сәлмән абзый, түзмичә, сиксәненче яше белән баруга карамастан, Хәербигә килеп, бабасы салдырган мәчетне кайтып күрергә була. 1995 елның 3 ноябрендә алар хатыны Әминә ханым белән Хәербигә киләләр, мәктәп укучылары белән очрашалар. «Кара әле, ничек матур итеп татарча сөйләшәләр!» – дип, укучыларга карап сокланалар. Аннары мәчеткә кереп, анда ата-бабалар рухына дога кылып, мәчет картлары белән әңгәмә коралар (бу турыда «Кама ягы» газетасының 1999 ел, 8 сентябрь санында язма басылып чыга). Киткән чакта Сәлмән абзый мәктәпкә әтисе Г.Гобәйдуллинның «История татар» китабын һәм Гобәйдуллиннарның үз кулы белән төзегән нәсел шәҗәрәсен бүләк итә.

2015 елның декабрендә Хәербидә яңа мәчет ачыла. Ул 100 еллык тарихы булган мәчет белән янәшә төзелә. Иске мәчет 1991 елдан СССРның тарихи һәм мәдәният истәлекләренә кертелгән (Кушымта 13). Бу ике мәчет бер-берсен тулыландырып, нур чәчеп тора.

## КЕМНӘР АЛАР – ГОБӘЙДУЛЛИННАР? АЛАР ТУРЫНДА ХАЛЫК БЕЛӘМЕ?

Кемнәр соң алар – Гобәйдуллиннар? Алар турында Хәерби авылы халкы беләме? Әйдәгез, аларның нәсел шәҗәрәсенә күз салыйк. Иген игеп яшәгән нәселнең сәүдәгәрлеккә кереп китеп уңыш казану тарихы белән танышыйк.



1908 елда Хәерби авылында мәчет төзеткән Салих Сабит улы Гобәйдуллин.

Сабит Гобәйдуллин 1821 елда Казан губернасының Югары Пошалым авылында (хәзер Арча районында) хәлле крестьян гаиләсендә туа. Яшь чагында ук Казанга килә. Карета ясау эше остасы булып танила, аннары, мая туплап, сәүдә эше белән шөгыльләнә башлый. Аның уңганлыгын һәм тырышлыгын Казан сәүдәгәре Галикәев күреп ала һәм кызы Шәмсенисаны аңа кияүгә бирә. Хатынының әтисе булышлыгы белән ул үз мануфактурасын оештыра. 2 нче гильдия сәүдәгәр булып җитешә. Сабит Гобәйдуллин 1870 елларда дөнья куя.

Хәербидә җир биләмәләре булган Салих Гобәйдуллин – шул Сабитның улы. 1908 елда Хәерби авылында агач мәчет салдыру өчен акча бирә. Салих Сабит улы 1862 елның 20 июлендә Казанда туа. 1 нче җамигъ мәчет каршындагы мәдрәсәне тәмамлый, Ш.Мәрҗани шәкерте була. Ул әтисенең предприятиесен зурайта, мануфактура товарлары эшләп чыгара һәм сәүдә белән шөгыльләнә. 1910 елда мануфактураны шинель поставы җитештерүгә көйли; армия ихтыяҗлары өчен сукно җитештергәне өчен медаль белән бүләкләнә.

Гобәйдуллинның Казанда туку фабрикасы һәм керем китерүче күчемсез милке дә була (Островский урамы, 53 адресы буенча урнашкан 3 катлы кирпеч йорт; мосафирханә (постоялый двор) һәм трактир урнашкан 2 катлы кирпеч бина; Печән базары мәйданы янында урнашкан 3 катлы кирпеч бина, табыш йорты вазифасын үти). Салих бай 1908 елда Хәербидә ике катлы кирпеч йорт салдыра. Казанда демократик яшьләр үткәргән чараларга (әдәби-музыкаль кичәләр уздыруга, «Әлислах» газетасын чыгаруга), шулай ук Ш.Мәрҗанинең 100 еллык юбилеена багышланган җыентыкны нәшер итүгә акчалата ярдәм күрсәтә. Октябрь революциясеннән соң Гобәйдуллинның мөлкәте дәүләт тарафыннан тартып алына. 1927 елдан ул балалары белән Бакуда һәм Махачкалада яши. Салих Сабит улы Казанның бай сәүдәгәре Айтугановның Өммегөлсем исемле кызына өйләнгән була. Аларның кайбер балалары кечкенә чакта ук үлә бара, өчесе исән-сау үсеп җитәләр. Болар – Габделгазиз, Габделкадыйр һәм Мәрьям. Салих байның хатыны Өммегөлсем 1910 елда ук, нибары 46 яшендә үлеп китә, Яңа татар бистәсе зиратында җирләнгән. Салих бай башкача өйләнми, хатынынннан калып, ул әле тагын

25 ел яши, 1935 елда Дагстан АССРның Махачкала шәһәрендә вафат була. 100 еллык Хәерби мәчетен салдырган, авылга байтак игелек күрсәткән кешенең гомер тарихы менә шундый.



Газиз Салих улы Гобәйдуллин.

Салих Гобәйдуллин балаларының да аның юлыннан китүен, үз эшенең дәвамчылары булуын тели. Әмма балалар башка юл сайлыйлар, әтиләре аларның теләкләренә каршы килми. Кемнәр соң аның балалары? Бүген без язмышы Хәербигә бәйле бу кешенең өч баласы белән дә горурлана алабыз. Олы улы – Габделгазиз 1887 елның 15 июнендә Казанда туа. Газиз Гобәйдуллин – тарихчы, тарих фәннәре докторы (1927 ел), беренче татар профессоры (1927 ел), җәмәгать эшлеклесе, публицист. Казанда Шәрекъ академиясен нигезләүчеләрнең берсе.

Гаҗәеп киң кырлы галим Газиз Салих улы Гобәйдуллин «Идел-Уралчылар оешмасы» эшендә гаепләнеп репрессияләнә, 1937 елның 13 октябрендә Бакуда атып үтерелә. Үлгәннән соң аклана. 1995 елның 3 ноябрендә Хәербигә килгән Сәлмән абый менә шушы Газизнең улы инде.

Салих Гобәйдуллинның икенче улы – Габделкадыйр Гобәйдуллин. Ул 1888 елда Казанда туа, этнограф. Хезмәтләре Казан татарларының аш-су-






Казанда Гобәйдуллиннар йорты.




Сәлмән Газиз улы Гобәйдуллин төзегән шәҗәрә.

ларын, X йөз болгар акчаларын тикшерүгә карый. 1938 елда репрессияләнә һәм Красноярск краеның хезмәт белән төзәтү лагерена җибәрелә. 1944 елның 4 маенда үлә, үлгәннән соң аклана.

Салих Гобәйдуллинның кече баласы – Мәрьям Гобәйдуллина. Ул 1892 елда Казанда туган, этнограф. Хезмәтләре Татарстан, Әзәрбайҗан халыклары этнографиясенә карый, шул исәптән Казан татарлары, Әзәрбайҗан төркиләре ашлары турында очерклар авторы. 1933 елда Бакуда вафат була.

Менә Гобәйдуллиннар кемнәр алар! Бүгенге көндә дә Бай урманы, Бай урамы, Бай күле дип сөйләшүче Хәерби халкы бу атамаларның Салих бай исеме белән бәйле булуын белергә тиештер.

# VII БҮЛЕК

## АВЫЛ ЗИРАТЫНДАГЫ ГАРӘП ЯЗУЛЫ КАБЕР ТАШЛАРЫ

Кабер ташларында аерым кешеләрнең генә түгел, ә тулы бер халыкның күп гасырлык тарихы чагылыш таба. Алардагы язулар теге яки бу төбәкнең тарихи үсешен ачыклаучы мәгълүмат чыганагы булып хезмәт итәләр.

Совет һәм Россия тарихчысы, Урта Идел буе халыклары тарихын өйрәнүче белгеч, тарих фәннәре докторы С.Х.Алишев (аның турында «Хәерби авылы кияүләре» бүлегеннән укыгыз) кабер ташларындагы язулар турында түбәндәгеләрне әйтә: «Татар халкының бик мөһим байлыгы бар. Ул да булса, кабер ташларындагы язулар – эпиграфик истәлекләр. Татар халкының байлыгы дип мин шуның өчен әйтәм, чөнки алар күрше славян-урыс, фин-угор халыкларында булмаган һәм юк. Чуашлар аларга бөтенләй битараф карый. Башкортларда да алар булмаган. Алтын Урда кабиләләре каберләр өстенә таш куеп, аңа язу язып калдырмаганнар».

Хәерби авылындагы кайбер кабер ташларының язулары Татарстан Республикасы Милли китапханәсе директорының фәнни эшләр буенча урынбасары Ирек Һадиев тарафыннан укылды. Ташъязма текстларындагы язу юллары шартлы рәвештә номерланды. (Нияз Һадиев фоторәсемнәре).

***Әхмәдҗан Вәлид улына һәм Фәрхизадә Рәхмәтулла кызына куелган таш. 1905 ел.*** Алгы ягында *(уйма язулы)*: 1) би-хөкми Лилләһи; 2) бу кабер сахибе Әхмәдҗан Вәлид; 3) ...туксан өч; 4) ... ийүн 3-ендә; 5) 1905 елда зәнебе мәгъфүр улсын. Арткы ягында *(уйма язулы)*: 1) би-хөкми Лилләһи; 2) бу кабергә дахилә Фәрхиза[дә]; 3) әхмәтулла кызы Әх[мәт]жа[н]; 4) 31 яшендә ...; 5) кабере җәннәт бакчасы улсын.




1


2


3


4


5


6


7


8


9


10


11а


11б

№ 1. ***Хәсән Мөхәммәдшаһ улына куелган таш. 1939 ел.*** Алгы ягында *(уйма язулы)*: 1) Хәсән; 2) Мөхәммәдшаһ; 3) угылы; 4) туды 1888; 5) 1939 – 10/V; 6) вафат; 7) Аллаһ рәхмәт кыйлсын.

№ 2. ***Вәлиулла Сәйфелмөлек улына куелган таш. 1934 ел.*** Алгы ягында *(уйма язулы)*: 1) Һуа әл-Бакый; 2) Вәлиулла; 3) Сәйфелмөлек; 4) угылы; 5) 75 яшендә; 6) 1934...

№ 3. ***Галәветдин Фәхретдин улына куелган таш. 1929 ел.*** Алгы ягында *(уйма язулы)*: 1) Лилләһил-фатиха; 2) Галәветдин; 3) Фәхретдин; 4) улы 33 яшендә; 5) 1929 сәнә үктәбер; 6) 23-ендә 1348 сәнәи; 7) һиҗриядә вафат; 8) Аллаһу рәхмәт; 9) кыйлсын.

№ 4. ***Сәлахеддин Мөхеддин улына куелган таш. 1930 ел.*** Алгы ягында *(уйма язулы)*: 1) Лилләһил-фатиха; 2) Сәлахеддин; 3) Мөхеддин угылы; 4) 1930 сәнә гыйнвар; 5) 23-ендә вафат; 6) Аллаһу рәхмәт; 7) кыйлсын.

№ 5. ***Ибраһим Мифтахеддин улы Мөхеддиневкә куелган таш. 1920–1930 еллар.*** Алгы ягында *(уйма язулы)*: 1) [Лилләһил-фатиха]; 2) Ибраһим; 3) Мифтахеддин; 4) угылы Мөхеддинев; 5) ... яшендә; 6) ... сәнә нуябер 14; 7) вафат Аллаһу рәхмәт; 8) [кыйлсын].

№ 6. ***Сиддыйк Гали улы Юсуповка куелган таш. 1933 ел.*** Алгы ягында *(уйма язулы; 1–3 юллар кириллицада, 4–5 юллар гарәп графикасында)*: 1) Ситдик; 2) Гали [угылы]; 3) Юсупов; 4) Сиддыйк Гали; 5) угылы Юсупов; 6) 1872–1933.

№ 7. ***Мәрфуга Габид кызына куелган таш. 1937 ел.*** Алгы ягында *(уйма язулы)*: 1) бу ягында; 2) Мәрфуга; 3) Габид кызы; 4) 90 яшендә; 5) 1937 елда; 6) вафат; 7) Аллаһу рәхмәт кыйлсын.

№ 8. ***Хөсниҗәмал Баязид кызына куелган таш. 1927 ел.*** Алгы ягында *(уйма язулы)*: 1) Лилләһил-фатиха; 2) Хөсниҗәмал; 3) Баязид кызы; 4) Рәхмәтулла зәүҗәсе; 5) 77 яшендә; 6) 1927 сәнә февраль; 7) 7-ндә вафат; 8) Аллаһу рәхмәт; 9) кыйлсын. Уң ягында *(уйма язулы)*: 1) нәүвәрә Аллаһу мәркадиһа. Сул ягында *(уйма язулы)*: 1) гафәрә Аллаһу зөнубиһа.

№ 9. ***Рәхмәтулла Әхмәдҗан улына куелган таш. 1916 ел.*** Алгы ягында *(уйма язулы)*: 1) би-хөкми Лилләһи; 2) Рәхмәтулла; 3) Әхмәдҗан; 4) угылы нче; 5) яшендә вафат; 6) 1916 сәнәи румия; 7) 5-ендә апрель. Сул ягында *(уйма язулы)*: 1) җәгалә Аллаһу кабериһи раудат мин рийадил-җәннәт.

№ 10. ***Төхфәтулла Хәбибулла улына куелган таш. 1904 ел.*** Алгы ягында *(уйма язулы)*: 1) би-хөкми Лилләһи; 2) бу кабердә Хак Тәгалә рәхмәтенә; 3) ирешде Төхфәтулла бине Хәбибулла; 4) 71 яшендә 1322 сәнәи һиҗриядә; 5) шәүвәл 14-ендә дикәбер йедесендә; 6) 1904 сәнәи румиядә рәхмәтуллаһи рәхмәтән уасигатән.

№ 11. ***Габидә Хәсән кызына куелган таш. 1892 ел.*** Алгы ягында *(уйма язулы)*: 1) би-хөкми Лилләһи; 2) бу кабергә дахилә Габидә; 3) [Хәсән кызы] 80 яшендә; 4) Әхмәд зәүҗәсе 1892 сәнәдә; 5) нуябернең 14-ендә; 6) кабере мөнәүвәрә улсын.

## Сүзлекчә:

**бине** – улы (мәсәлән, «Гали бине Әхмәт» – Әхмәт улы Гали дигәнне белдерә)

**би-хөкми Лилләһи** – Аллаһының хөкеме белән

**гафәрә Аллаһу зөнубиһа** – Аллаһы гөнаһларын кичерсен

**дахилә** – керде

**җәгалә Аллаһу кабериһи раудат мин рийадил-җәннәт** – Аллаһ каберен җәннәт бакчасы кылсын

**зәнебе мәгъфүр улсын** – гөнаһы гафу ителсен

**зәүҗәсе** – хатыны

**Лилләһил-фатиха** – Аллаһ ризалыгы өчен мәрхүм рухына «Фатиха» сүрәсен укы!

**мөнәүвәрә** – нурлы

**нәүвәрә Аллаһу мәркадиһа** – Аллаһы каберен нурласын

**рәхмәтуллаһи рәхмәтән уасигатән** – Аллаһның киң рәхмәтләре ирешсен

**сахибе** – иясе

**сәнә** – ел

**сәнәи румия** – христианча (милади) ел

**сәнәи һиҗрия** – һиҗри ел

**улсын** – булсын

**Һуа әл-Бакый** – Ул (Аллаһы) мәңгелек

## VIII БҮЛЕК

## ХӘЕРБИДӘ КҮМӘК ХУҖАЛЫК

1929 елда авыл тормышында зур вакыйга була: күмәк хуҗалык төзелә. Башта бу хуҗалык ТОЗ (товарищество по совместной обработке земли), ягъни күмәкләшеп җир эшкәртү ширкәте дип атала. Соңыннан ширкәт колхоз итеп үзгәртелә. Ширкәтнең рәисе итеп Нигъмәтов Хабулны сайлыйлар. Тик ул бу эштә озак эшләми, хуҗалык колхоз итеп үзгәртелгәч, аның рәисе итеп Сафин Гәрәй билгеләнә.

Түбәндә күмәк хуҗалыкка беренче булып кергән хәербиләләрнең исемлеге китерелә. Шунда ук күмәк хуҗалыкка керүчеләрнең ничә аты булуы да күрсәтелә.

1. Сафин Гәрәй – 1 ат
2. Нигъмәтов Хабул – 1 ат
3. Гарипов Хабул
4. Әхмәтшин Газиз – 1 ат
5. Әхмәтшин Госман – 1 ат
6. Вафин Гариф – 2 ат
7. Гыймадиев Закир
8. Фәхриева Сара
9. Хәмидуллин Гарифулла
10. Хөснетдинов Габдулла
11. Вафин Харис
12. Ризванов Габдрахман

**Искәрмә:** Исемлек күмәк хуҗалыкка кемнең кем артыннан керүе тәртибендә бирелде.

Соңрак колхозга керүчеләр саны арта. Колхозчыларга җирне авылның төньяк-көнчыгыш өлешеннән бүлеп бирәләр. Күмәкләшүнең беренче елларында игеннәр бик уңа.

Колхозлашу Хәербидә дә каршылыклар белән бара. 4–5 хәлле гаиләне «кулак» дип читкә сөрәләр. Аларның сыерларын тартып алып колхозга бирәләр. Авыл кешесе яңалыкка шикләнеп карый. Күпләр күмәкләшүгә каршы чыга. Берара инде оешкан колхоз таралып бетә яза. Халык теленә бу чор «пыртузан» дип кереп кала («пыр тузган» дигән сүздән). Ләкин күмәк хуҗалык яңадан ныгый башлый. Беренче машиналар, тракторлар кайта. Бу 1931–1932 елларда була. Колхозның беренче тракторчысы Касыйм Закиров, ә шофер рус кешесе Вилков булган (исемен хәтерләмиләр).


Состав правления к-за "Аята" 21 ноября 34 г.
Т.Р. Лаишевского р-на












Силос ташучылар.

Күмәк хуҗалыкка «Алга» колхозы дип исем бирәләр. Ул шушы исем белән 1963 елга кадәр яши. 1963 елда күрше рус авылы Караишеводагы колхоз белән «Алга» колхозын кушалар һәм аңа «Мир» дигән исем бирәләр. Ләкин берничә елдан соң хуҗалык янадан икегә аерыла һәм Хәербидәге колхоз тагын «Алга» исемен йөртә башлый.

1975 елда «Алга»ны аерым колхоз буларак гамәлдән чыгарып, «Столбище» совхозының бүлекчәсе итеп калдыралар. Столбищедан килеп яңа трактор, машиналарны алып китәләр. Өч айдан соң «Хәерби» бүлекчәсен «Столбище»дан аерып «ҮЭБ» (Үзәк эксперименталь база) хуҗалыгына кушалар. «ҮЭБ»нең үзәге Сокуры авылында булып, Хәерби авылы шуның бер бүлекчәсе генә булып кала. 1978 елның 17 февралендә Хәербидә «Хәерби» совхозы оештырыла. 1995 елның 1 февраленнән бу совхоз «Хәерби» күмәк хуҗалыгы дип йөртелә башлый. Күмәк хуҗалык 1998 елның 28 апрелендә ТНВ «Вафин һәм компания» итеп үзгәртелә. (ТНВ – товарищество на вере, ягъни ышанычлылык ширкәте).

Колхоз тормышы төзелгән генә елларда җиңелдән булмый. Сугыштан соң гына әкренләп тернәкләнә башлыйлар. Ватан сугышыннан йөреп кайткан Гайнетдинов Салихҗанны колхоз рәисе итеп сайлыйлар. Ул колхоз белән 18 ел җитәкчелек итә. Гайнетдинов рәислек иткән чорда колхозда ат абзары, 4 рәтле сыер абзары, 1000 башка исәпләнгән дуңгыз абзары, суган саклау склады, двигатель белән эшли торган тегермән, пилорама, йон теттерү өчен бина, иген амбары, водокачка, үлчәү, клуб, мәктәп, радиоузел кебек корылмалар төзелә.

Колхоз бер җиңел машина, 7–8 йөк машинасы, кыру (токарный) станогы сатып ала. Трактор паркы оештырыла. 30 гектар җиргә алма бакчасы, 9 гектар җиргә кыр ышыклау полосалары утыртыла. Шушы чорда авыл радиолаштырыла. Боларның барысына да, әлбәттә, халыкның тырыш хезмәте нәтиҗәсендә ирешелә.

1950 елда барлыгы 316 колхозчы хуҗалыгы була. Хезмәткә яраклы ирләр 249, хатын-кызлар 378 кеше исәпләнә. Һәр колхозчы бер елга кимендә 168 хезмәт көне эшләргә тиеш дип билгеләнә. Хезмәт көне минимумын үти алмаган











Печән әзерләүчеләр. 1950 еллар ахыры.

19 кеше теркәлгән. Болар – күп балалы хатыннар, авыру кешеләр.

1952 елда күрше Караишево авылы турысында Мишә елгасын буып, ГЭС төзиләр. Ике авыл кешеләре бу эшне бик тырышып, зур энтузиазм белән башкаралар. ГЭС төзү өчен «Алга» колхозына дәүләт 45769 сум ссуда бирә. ГЭС төзелә, ике авыл халкы бәйрәм ясый. «Алга» кохозы кешеләре Караишевога атлар җигеп, гармуннар белән баралар. Ашау-эчү мәҗлесе оештырыла. Ләкин бу ГЭС биргән яктылыкка куану озакка бармый. Икенче елгы язгы ташкын аны агызып алып китә. Дәүләт «Алга»га ГЭС төзү өчен бирелгән ссуданы түләтми, аны гамәлдән чыгара.



Караишево авылы янындагы ГЭС. Интернет челтәреннән алынды.

1953 елгы чәчү планына күз ташлыйк: арыш – 445 га, бодай – 446 га, солы – 197 га, борчак – 60 га, тары – 55 га, карабодай – 18 га.

1953 елда «Алга» колхозының идарә әгъзалары:

1. Гайнетдинов Салих – рәис
2. Насыйров Хабул – бухгалтер
3. Гаязов Гарифулла – ферма мөдире
4. Минвәлиева Гайшә – терлекче
5. Гыймадиев Минвәли – агротехник
6. Сибиев Зиннәт – колхозчы
7. Вафин Һади – авыл советы рәисе
8. Кашапов Шафик – колхозчы.

Идарә әгъзалыгына кандидатлар: 1. Сәхбиева Гаян, 2. Галиева Мәрзия.

1954 елда колхозчыларга бер хезмәт көненә 44 тиен исәбеннән акчалата түләнә, 3 кг ашлык, 1,7 кг яшелчә, 1 кг салам, 2 г бал исәбеннән натуралата өләшенә. Кырчылыктан 346466 сумлык, терлекчелектән 170243 сумлык, башка тармаклардан 27669 сумлык саф табыш алына. Колхоз шул табыштан дәүләткә 37540 сум салым түли. Барлык милек 118666 сумга иминиятләштерелә.

1954 елда «Алга» колхозындагы терлекләр саны: атлар – 133, сыерлар – 237, сарыклар – 514, дуңгызлар – 225, кошлар – 1107 баш булган.



Гаян апа, балалар, Дания Юнысова, Һәдия Гәрәева, Бикә Сибиева, Габделхак Закиров, Нурмый Сәлахов, Зәкәрия Хөснетдинов, Зөфәр Каюмов.

**1953–1954 елларда колхоз дәүләткә житештереп саткан уңыш:**

| Еллар | 1953 | 1954 |
|---|---|---|
| Ашлык | 4588 ц | 4016 ц |
| Бәрәңге | 430 ц | 922 ц |
| Яшелчә | 1726 ц | 1614 ц |
| Ит | 193 ц | 273 ц |
| Сөт | 37414 ц | 69620 ц |

1955 елда бер хезмәт көненә 92 тиен акча, 1 кг 200 г ашлык, 860 г салам, 1,5 кг яшелчә түләнелә. Шул ук елда 1 гектардан 180 ц кәбестә, 141 ц кыяр, 135 ц помидор, 105 ц суган, 145 ц кишер, 100 ц башка яшелчәләр уңышы жыеп алына.

1956 елда Бай күленнән 2000 т торф чыгарыла. Ул кырларны ашлауга һәм кукуруза утырту өчен «чүлмәкләр» ясауга тотыла. Кырларга 5660 тонна тирес, 300 ц көл, 150 ц тавык тизәге чыгарыла. 1000 ц известь, 300 ц аммоний сульфаты, 300 ц калий тозы, 350 ц суперфосфат, 250 ц аммиак селитрасы ашламалары кайтарыла. Дәүләткә барлыгы 536 ц ит сатыла, шул исәптән: сыер ите – 152 ц, сарык ите – 92 ц, дуңгыз ите – 292 ц. Бу ел күрсәткечләре буенча:



Флюра Сәлахова, Дания Насыйбуллина, Халидә Шәрәфиева, Гөлфия Вафина, Дания Юнысова, Минниса Билалова (Хәсәнова), Нурмый Сәлахов (улы Мөхәммәт, кызы Гөлира), Саимә Сафина. 1961 ел.

1 сыердан – 2 мең л сөт, 1 сарыктан – 3,4 кг йон, 1 тавыктан – 75 күкәй, 1 умартадан – 40 кг бал алына (барлыгы 62 ц бал суыртыла).

1968 елда беренче суүткәргеч төзелә башлый. Шул ук елны колхоз идарәсенең яңа бинасы салына. Авылда беренче телевизорны Галәвов Галләм алып куя. Телевизордан татарча спектакльләр күрсәткәндә, аның йорты күрше-тирә өчен кинотеатрга әверелә.



Колхоз умарталыгы. 1966 ел.

## ХӘЕРБИНЕҢ ТӨРЛЕ ЕЛЛАРДА АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫНДА ЭШЛӘГӘН КЕШЕЛӘРЕ:

**Механизаторлар:** Булатов Илгизәр, Вафин (Зиннәтуллин) Мингали, Вафин Шафик, Вәлиев Галимҗан, Галиев Мансур, Зиннәтуллин Камил, Минвәлиев Хәйдәр, Насыйбуллин Галимҗан, Насыйбуллин Наил, Насыйбуллин Равил, Насыйбуллин Шамил, Сәхбиев Минвәли, Сәхбиев Мингали, Сибиев Мөхәммәт, Харисов Рәис, Хәмидуллин Минвәли, Хәмидуллин Мөхәммәт, Шәйхиев Камил, Юнысов Нәҗип һ.б.

**Иген чәчүдә эшләүчеләр:** Кашапов Зариф, Насыйбуллин Габдулла, Насыйбуллин Закир һ.б.

**Шофёрлар:** Вафин Дилүс, Вафин Ринат, Вафин Хатип, Гарипов Гази (Вазыйх), Гарипов Әнәс, Гаязов Миңнулла, Закиров Габделхак, Зарипов Мәгъсүм, Исмәгыйлев Суфиян, Фатихов Шамил, Хәбибуллин Гарифулла, Хәмитов Гариф һ.б.

**Шофёрлар династиясе:** Вафин Фатих (әтиләре), Фатихов Шамил (улы), Вафин Хатип (улы), Вафин Ринат (улы), Вафин Дилүс (онык), Вафин Рафис Ринат улы (онык, комбайнчы) һ.б.

**Электромонтёрлар:** Нигъмәтов Булат, Низамов Мингазиз, Ризванов Мәгъсүм һ.б.

**Балта осталары:** Вәлиуллин Шаһвәли, Закиров Әнвәр, Закиров Искәндәр, Ногманов Нәҗип, Садыйков Әнәс, Сәлахов Габдулла, Солтанов Нурхәмәт, Шакиров Кадыйр һ.б.

**Фермада эшләүчеләр:** Галәвовлар – бөтен нәселләре белән (Вәли абый, Хәләмгөл апалар һ.б.), Минвәлиева Гайшә, Минвәлиев Рәхим, Минвәлиева Фәния һ.б. бик күпләр.

**Ферма мөдирләре:** Вафин Кадыйр, Нуруллина Сания, Сәлахов Нурмөхәммәт һ.б.

**Сыер савучылар:** Баһавова Әнзия, Булатова Мөнирә, Вафина Нәкыя, Вафина Хәмдия, Галәвова Нурания, Галиева Галимә, Галиева Гөлүсә, Галиева Минзифа, Гарипова Минҗиһан, Гатауллина Зәлфирә, Әхмәдуллина Нәкыя, Җамалиева Гөлсинә, Закирова Ләйлә, Закирова Равия, Зарипова Флюра, Зиннәтуллина Нурхидә, Ибраһимова Ләлә, Кәлимуллина Гөлфирә, Маликова Нажия, Минбаева Дания, Мусина Минвафа, Насыйбуллина Сафия, Низамова Илсөяр, Низамова Сәлимә, Нуруллина Зәлфирә, Рәхмәтуллина Наилә, Сафина Сәйдә, Сәйфетдинова Лилия, Сәйфетдинова Мөршидә, Сәхбиева Наилә, Солтанова Сания, Фатихуллина Нәзирә, Харисова Гөлсем, Хәмидуллина Минзәлия, Хөснетдинова Сәгыйдә, Шәйхиева Люция, Шәйхиева Рәйсә, Шәмиева Рәмзия һ.б.







1. Авыл алдынгылары; 2. Бухгалтерия хезмәткәрләре. 1980 еллар.







1. Җәйләүдә; 2. Совхоз эшчәннәре.







1. Бухгалтерия хезмәткәрләре. 1990 еллар; 2. Агитбригада. Урып-җыю вакыты.


Министерство сельского хозяйства СССР
Центральный комитет
профсоюза рабочих и служащих
сельского хозяйства и заготовок

НАГРАЖДАЮТ КОЛЛЕКТИВ
[illegible]
ТАТАРСКОЙ АССР
ПОБЕДИТЕЛЯ ВО ВСЕСОЮЗНОМ
СОЦИАЛИСТИЧЕСКОМ СОРЕВНОВАНИИ

ПОЧЕТНЫМ
ДИПЛОМОМ

ЗА ПОВЫШЕНИЕ ЭФФЕКТИВНОСТИ
ПРОИЗВОДСТВА, КАЧЕСТВА РАБОТЫ
И УСПЕШНОЕ ВЫПОЛНЕНИЕ
СОЦИАЛИСТИЧЕСКИХ ОБЯЗАТЕЛЬСТВ,
ПРИНЯТЫХ НА 1976 ГОД

1


„ЕСТЬ ХЛЕБ—БУДЕТ И ПЕСНЯ...“

Л. И. Брежнев.

КОЛХОЗ, СОВХОЗ „Кирбинский“

МЕХАНИЗАТОРУ ТОВ. Хамидуллину Шафику Минваллиевичу

УВАЖАЕМЫЙ ТОВАРИЩ!

Райком КПСС, исполком районного Совета народных депутатов и райком профсоюза работников сельского хозяйства горячо и сердечно поздравляют Вас с трудовой победой, которую одержали Вы в социалистическом соревновании хлеборобов района в борьбе за урожай.

Честь и слава Вам!

Желаем Вам крепкого здоровья, личного счастья и еще больших успехов в труде на благо нашей великой Родины!

Рады сообщить Вам, что в райцентре в честь Вашего трудового подвига поднят флаг трудовой славы.

Секретарь РК КПСС: В. ВАСИЛЬЕВ.
Председатель исполкома райсовета: З. ВАЛИУЛЛИН.
Председатель РК профсоюза: В. КАМАЕВ

2


3

1. Иген җитештерү буенча Бөтенсоюз Социалистик ярыш җиңүчесенә бирелгән диплом. 1977; 2. Механизатор Ш.Хәмидуллинга хезмәт җиңүе өчен тапшырылган котлау; 3. Шагыйрә Э.Шәрифуллина белән ындыр табагында очрашу.

**Бозау караучылар:** Вафина Гөлфия, Вафина Минсылу, Вафина Рәмзия, Нигъмәтова Гөлфирә, Фәизова Минниса, Хәлиуллина Гүзәл, Хәлиуллина Саимә, Хәмәтгалиева Рания һ.б.

**Кырчылыкта эшләүчеләр:** Галиева Кәшифә, Галиева Мәгъсүмә, Гарипова Даһия, Гарипова Тәскирә, Мингалиева Минбәян, Мөхәммәтҗанова Гөлсем, Нигъмәтова Гөлфирә, Хәлилова Сания, Шакирова Җәмилә, Шәрәпова Халидә һ.б.


1


2

1. Идарә бинасы; 2. Илдар Мингалиев, Татарстанның атказанган механизаторы.









Терлек фермасы, машина һәм трактор паркы, ындыр табагы һәм кырлардан күренешләр.









Җитәкчеләр һәм механизаторлар.

# IX БҮЛЕК

## ХӘЕРБИ АВЫЛЫНДАГЫ ХУҖАЛЫК ҖИТӘКЧЕЛӘРЕ

1. Нигъмәтов Хабул Нигъмәт улы – ТОЗ (Товарищество по обработке земли) җитәкчесе (1930–1931 еллар).
2. Сафин Гәрәй – колхоз рәисе (1931–1941 еллар).
3. Закир абый (башка мәгълүмат юк).
4. Сабитов Фәйзрахман – «Алга» колхозы рәисе.
5. Гайнетдинов Салихҗан – «Алга» колхозы рәисе.
6. Хәлиуллин Һидият – «Мир» колхозы рәисе.
7. Гарифуллин Нурхәмәт – «Алга» колхозы рәисе (1968–1973 еллар).
8. Хаҗипов Мөҗип Нәҗип улы – «Алга» колхозы рәисе (1973–1975 елның октябре).
9. Гарифуллин Нурхәмәт – «Столбище» совхозының Хәерби бүлекчәсе управляющие.
10. Садриев Әсхәт Хәйретдин улы – Сокуры Үзәк эксперименталь базасының (ҮЭБ) Хәерби бүлекчәсе управляющие; ҮЭБ директоры – Бәширов Әнәс Әлмөхәммәт улы.
11. Гыйндуллин Рәис Хәбиб улы – «Хәерби» совхозы директоры (1978 елның мартыннан июленә кадәр).
12. Әхмәтҗанов Наил Насыйбулла улы – «Хәерби» совхозы директоры (1978–1982 еллар).
13. Әхмәтшин Альберт Дәүләт улы – «Хәерби» совхозы директоры (1982–1988 еллар).
14. Минбаев Фәрит Нури улы – «Хәерби» совхозы директоры (1988–1990 еллар).
15. Вәлиуллин Җәүдәт Зәет улы – «Хәерби» совхозы директоры (1990–1992 еллар).
16. Галиев Илдус Гарифулла улы – «Хәерби» совхозы директоры (1992–1995 еллар).
17. Сафин Нәҗип Харис улы – «Хәерби» совхозы директоры (1995 ел, апрель–сентябрь).
18. Вафин Радик Кадыйр улы – «Хәерби» совхозы, «Вафин һәм компания» Ышанычлылык ширкәте, «Хәерби» ЖЧЖ директоры (1995 елның 30 сентябреннән).

## БҮГЕНГЕ КӨН ҖИТӘКЧЕСЕ

**Вафин Радик Кадыйр улы** 1964 елның 31 гыйнварында Хәерби авылында туа. Сигезьеллык белемне Хәерби мәктәбендә, урта белемне Казандагы 10 нчы интернат-мәктәптә ала. 1981–1983 елларда Совет Армиясендә хезмәт итә. Армиядән соң Казан авыл хуҗалыгы институтында укып галим-агроном белгечлеге ала. 1995 елның 30 сентябреннән авылда хуҗалык җитәкчесе. 2004 елда Татарстан Республикасының, 2017 елда Россия Федерациясенең атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре исеме бирелә. Р.К.Вафин – авыл хуҗалыгы фәннәре кандидаты (2004).



Радик Кадыйр улының тормыш иптәше Фаилә ханым, шәһәр кызы булса да, авылны үз итә. Авыл тормышына җайлашып, терлек асрап, бакча карап яшиләр, өч кыз тәрбияләп үстерәләр. Бүген аларның инде өч оныклары бар.

Радик Кадыйр улы хезмәт юлын шофер булып башлый. Армиядән кайтып институт тәмамлаганнан соң, Лаеш районының Рождествено совхозына агроном булып урнаша. 1995 елдан Хәербидәге совхозны җитәкли. Ике ел саен җитәкче алышынып торган авыр еллар, булмас бу егеттән диючеләр дә аз булмагандыр ул вакытта. Бик яшь бит, тәҗрибәсе дә юк. Тик Радик Кадыйр улы бирешми. Күп укый, өлкән җитәкчеләр белән киңәшә, кирәк вакытта абыйсы Әнвәрдән дә ярдәм сорый. Хуҗалыкның исеме «ТНВ «Вафин и компания», ягъни «Вафин һәм компания» Ышанычлык ширкәте дип атала башлый. Бу исем алыштыру гына түгел, эш һәм җитәкчелекнең эчтәлеген һәм формасын үзгәртү дә була. Халык Вафинга иярә, ышана, моның сәбәбе, бәлки, ул үскән Вафиннар гаиләсе белән дә бәйледер. Кадыйр абый үзе дә, Миңсылу апа да, олы уллары Әнвәр дә шушы авыл кешеләре, шунда хезмәт иткәннәр. Әлбәттә, яшь хуҗа үзенә ышанычлы ярдәмче-



Радик Кадыйр улы тормыш иптәше Фаилә ханым белән.

ләр туплый. Беренче чиратта техника мәсьәләсе хәл ителә, нәселле мөгезле эре терлекләрнең баш саны 500 дән артып китә. Ә бу кышкы чорда бердәнбер табыш чыганагы дигән сүз. Радик Кадыйр улы җитәкләгән елларда иген саклау складлары төзелә, иген киптерү җайланмасы булдырыла. Әкренләп ширкәт алдынгы хуҗалыклар рәтенә баса, исеме район һәм республика күләмендә искә алына башлый. Җитәкчегә дә лаеклы исемнәр бирелә.

2019 елда хуҗалыкта 150 ләп кеше эшли. Хуҗалык «Хәерби» ҖЧҖ исеме белән аталып йөртелә. Авыл шәһәргә якын булу сәбәпле, эшчеләргә кытлык сизелә. Әмма Радик Кадыйр улы эшчеләрне чит төбәкләрдән чакыра. Аларга яшәү урыннары булдыра, туклану мәсьәләсен хәл итә.

Бүген фермада бар эш автоматлаштырылган. Сыерларны ашату, саву, чистарту, хәтта бозауларны тукландыру аппаратлар белән эшләнә. Җитәкче заман белән бергә атлый, яхшы нәтиҗәләргә ирешү өчен күп көч сарыф итә, чит төбәкләргә тәҗрибә уртаклашырга чыга, аларны үзләренә чакыра. Авылга хәтта Яңа Зеландия, Америка Кушма Штатларыннан да киләләр. Ул үзе дә ике тапкыр Германиягә барып, фермерлар белән очраша, аларның эшләре белән таныша.



Радик Кадыйр улы тормыш иптәше Фаилә ханым һәм кызлары белән.

Хуҗалык авылны төзекләндерүгә дә зур ярдәм күрсәтә. Балалар бакчасы төзелә, озак та үтми 162 урынлы мәктәп тә сафка баса. Мәктәпкә җиһазлар, укуукыту кирәк-яраклары, спорт инвентарьлары һ.б. алына. Мәктәп бакчасында яшелчә үстерү өчен орлыкларга кадәр Радик Кадыйр улы җитәкләгән хуҗалык бирә. Авыл зираты тулган булу сәбәпле яңа зиратка урын бирелгәч, билгеләнгән мәйданны койма белән әйләндереп алу чыгымнарын күтәрүче «Хәерби» җәмгыяте була. Изге ният белән йөргәнгәдер, җитәкченең эшләре гел алга бара. Радик Кадыйр улы әле кайчан гына мәчет төзетү уе белән яна иде, анысы да тормышка аша – авылдашлары, спонсорлар ярдәме белән 2018 елның гыйнварында Кадыйр мәчете ачыла. Менә шулай инде ике дистә елдан артык Хәерби авылындагы хуҗалыкны шушы авылдан чыккан кеше җитәкли. Таләпчән, кайчак кырыс, шул ук вакытта ярдәмчел җитәкчедән авыл бик канәгать.

## ЭЛЕККЕГЕ ҖИТӘКЧЕЛӘР

Авыл җирендәге хуҗалык җитәкчеләренең тормыш юллары шушы төбәк белән бәйләнгән зур бер тарих китабы ул. Нинди кешеләрне җитәкче итеп сайладылар икән соң? Беренче чиратта тәҗрибәле, эш рәтен белүче, җаваплылыкны беренче урынга куеп яшәүчеләрне. Мондый җитәкчеләрне туплау – СССР чорында да, хәзерге көннәрдә дә иң мөһиме. Колхоз төзелгән көннән башлап, алар өстенә зур җаваплылык йөкләнә. Колхоз җитәкчесе итеп авыл хуҗалыгы өлкәсендә урта яки югары белемле белгеч һәм һичшиксез практик, ягъни оештыру сәләте, җитәкчелек эшчәнлеге буенча җитәрлек тәҗрибәсе булган, кул астындагыларны кайгыртып яшәүчеләр сайлап куела.

Хәерби авылында хуҗалык җитәкчеләре булып эшләгән кайбер кешеләр белән таныштырып китәрбез.

**Нигъмәтов Хабул (Хәбибулла) Нигъмәт улы** 1907 елда Казан губернасының Хәерби авылында ярлы крестьян гаиләсендә туа. 1928–1930 елларда сатучы булып эшли. Армиягә алынмый, әмма Казанда 3 айлык җыенда (1 нче лагерь, артиллерия полкы, 8 нче батарея) була. 1926 елдан ВЛКСМ әгъзасы һәм ячейка секретаре.



1930 елда Хәербидә беренче колхоз оештырыла. Х.Нигъмәтов колхозның беренче председателе итеп сайлана. «Алга» дигән исемне дә ул тәкъдим итә.

1931–1932 елларда Казанда мех фабрикасында эшли һәм шул елларда ВКП(б) сафларына керә. 1933 елдан аңа партия эшләре йөкләнә, партия эшләрен оештыручы, пропагандист булып эшли. 1930–39 елларда Хәерби авылы кулланучылар җәмгыяте идарәсе рәисе, райпотребсоюзның (район кулланучылар җәмгыяте) Күчмә Кызыл байрагын 3 ел рәттән үзләрендә тота. 1933–34 елларда Сиңгел авылында Сталин исемендәге колхозда бригадир булып эшли. Шушы авылның беренче партия оешмасын төзи. 1934–1935 елларда Хәерби авылы клубы мөдире була.

Хәбибулла Нигъмәт улы 1935 ел ахырыннан 1937 елның 1 сентябренә кадәр Казанда Татар югары коммунистик авыл хуҗалыгы мәктәбендә укый. (Татар югары коммунистик авыл хуҗалыгы мәктәбе Татар коммунистик университеты базасында ВКП(б) Татарстан өлкә комитеты бюросының 1932 ел 19 декабрь карары нигезендә 1932 елның декабрендә оештырыла. ВКП(б) ҮКның

1932 ел 21 сентябрь карары нигезендә мәктәп алдына МТС, колхоз һәм совхозларның җитәкче хезмәткәрләрен, шулай ук районнарның партия һәм совет органнары җитәкчеләрен укытып әзерләү бурычы куела. Мәктәп белән ВКП(б) ҮКның авыл хуҗалыгы бүлеге җитәкчелек итә. Мәктәптә өч бүлек була: 1) хуҗалык бүлеге (ике еллык), МТС, колхоз һәм совхозлар өчен җитәкче хезмәткәрләр әзерли; 2) партия-совет бүлеге (өч еллык), район партия һәм совет органнары һәм совхозларның сәяси бүлекләре өчен җитәкче хезмәткәрләр әзерли; 3) комсомол бүлеге. Тиешле гомуми белеме булмаганнар өчен алты айлык әзерлек курслары оештырылган була. Мәктәпкә сайлап алу һәм комплектлау өчен ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты каршында мандат комиссиясе төзелә. Мәктәпнең ректоры һәм уку-укыту мәсьәләләре буенча проректоры ВКП(б) ҮКның авыл хуҗалыгы бүлеге тарафыннан билгеләнә). Нигъмәтов Хәбибулла Татар югары коммунистик авыл хуҗалыгы мәктәбен тәмамлап өлгерә алмый, мәктәп ВКП(б) Татарстан өлкә комитеты бюросының 1937 ел 22 август карары нигезендә ябыла.


АУЫL XUÇALЬĢЬ
МӘКТӘВЕ
ТАТАРСКАЯ ВЫСШАЯ
КОММУНИСТИЧЕСКАЯ
Сельско-Хозяйственная
ШКОЛА
1937
№ 12017

УДОСТОВЕРЕНИЕ

Слушатель 2 курса Татарской коммунистической сельско-хозяйственной школы т. Нигматов Х. командируется в Кукморскую МТС для прохождения производственной практики сроком с 1 июля по 1 сентября с/г.

...сентября по 25 октября тов. Нигматов предоставляется каникулярный отпуск.

/Вольфович/

Проректор уч.части /Жданов/

Татар югары коммунистик авыл хуҗалыгы мәктәбеннән бирелгән таныклык. 1937 ел.

1937 елның 1 сентябреннән Кызыл Юл районының «Кызыл юл» газетасы редакторы урынбасары булып эшли. 1938 елдан СССР телеграф агентлыгының Татарстан бүлекчәсе корреспонденты (ТатТАСС). (1933 елның декабрендә Россия телеграф агентлыгының (РОСТА) Татарстан бүлеге буларак оештырыла, 1935 елның гыйнварында Советлар Союзы телеграф агентлыгының Татарстан бүлекчәсе дип үзгәртелә, 1941 елның 10 июнендә ТАСС боерыгы белән гамәлдән чыгарыла).


A. T. S. S. R.
VKP (b) nьn Qьzьl Jul rajon Komitetь
həm rajon Baçqarma Komitetь Organь
„QЬZЬL-JUL" Gazetasь Redaksiəse
А. Т. С. С. Р.
РЕДАКЦИЯ ГАЗЕТЫ
„КЗЫЛ-ЮЛ"
ОРГАНА
Кзыл-Юлского Райкома ВКП
(б) и Райисполкома
23 января 1939 г.
№ 3/74

BELEŞMƏ

Bu beleşmə birelə Qьzьl Jul rajonь, "Qьzьl Jul" gazetasь redaksiəse tarafьnnan Niqmətof Xəbibulləqa şul xaqta, dəreslektə ul 1937 nce jьlnьn 3 nce sentəbrennən 1938 nce jьlnьn 26 ncь dekəbrenə qədər çavaplь redaktor urьnbasarь bulьp eşlədə.

Çavaplь redaktor: /MAXMUTOF/.
Sekretar: /SAFIN/.
23/1 39-J.

«Кызыл юл» газетасы редакторы урынбасары булып эшләве турында белешмә.

1938–1939 елларда Шекә җидееллык мәктәбе директоры булып эшли, ә 1939–1941 елларда Кызыл Юл районы (хәзер Арча районы) Апаз урта мәк-







1. Татар югары коммунистик авыл хуҗалыгы мәктәбендә. 1937 ел. Х.Нигъмәтов арттагы рәттә, уртада; 2. Х.Нигъмәтов үзенең гаиләсе белән. Утырганнар: әнисе – Миңнебикә, бала карарга булышучы кыз. Басып торучылар: хатыны – Мәрзия, Х.Нигъмәтов олы кызы Роза белән.

тәбендә укытучы. 1941 елда фронтка алына, авыр яраланып, контузия алып, госпитальгә эләгә. Дәваланганнан соң аны хәрби хезмәт өчен яраксыз дип табалар. 1942 елның мартында туган ягына әйләнеп кайта.

1943 елдан Хәерби мәктәбендә хәрби әзерлек укытучысы, 1945 елдан мәктәп директоры, 1951 елдан химия һәм биология укытучысы.

Хәбибулла Нигъмәтовның беренче хатыны Бәдризадә исемле була. Икенче хатыны Саралан авылы кызы, Хәерби мәктәбе укытучысы Вафина Мәрзия. Мәрзия белән Хәбибулланың 6 балалары була, шуларның икесе Хәербидә төпләнеп яши. Нигъмәтов Хәбибулла 1967 елның 13 июнендә вафат була. Хәерби зиратына җирләнә.


Sovetlar Sojuzь telegraf agentlьqьnьn Tatarstan bylege
„TATTASS"
—о—
Татарское отделение телеграфного агентства Советского Союза
„ТАТТАСС"
4 апреля 1938 г.
№ 39
Адрес: Казань, Таттасс, тел. № 1-27.

Действительно по 1 июля 1938 г.

УДОСТОВЕРЕНИЕ.

Корреспонденту ТатТАСС тов. Нигматову поручается освещение в печати хода избирательной кампании по выборам в Верховный Совет Татарской АССР по Кзыл-Юлскому, Ново-Явашскому избирательным округам и присутствовать на заседаниях окружных избирательных комиссий.

Просьба ко всем организациям оказывать тов. Нигматову полное содействие при выполнении возложенных на него обязанностей.

Зав. ТатТАСС (Курбанов)

1


Приказ № 608

от 17 ноября 1945 г.

§1.

§2.

Зав роно

2

1. СССР телеграф агентлыгының Татарстан бүлекчәсе корреспонденты таныклыгы. 1938 ел. 2. Хәерби мәктәбенә директор итеп билгеләү турында приказ. 1945 ел.

**Гайнетдинов Салихҗан Гайнетдин улы** 1915 елның 3 октябрендә Татарстанның Спас районының Көек авылында туа. Әти-әнисе үлеп, тулы ятим калган малайны Лаеш районының Нармонка авылындагы балалар йортына урнаштыралар. Бераздан аны Хәерби авылында яшәүче Әхмәтҗан абый белән Гайшә апа уллыкка ала. Яңа әти-әнисе янында малай хезмәткә өйрәнеп үсә. Үзенең яшьтәшләреннән зирәклеге белән аерылып тора, тормыш шартлары аны вакытыннан алда олыгайта.



Бик зур яңалык булып, районда машина йөртүчеләр курслары оештырыла. Курслар өчен иң сәләтле 7 егет сайлап алына. Шуларның берсе Салихҗан була. Ул курсларны уңышлы тәмамлап, Хәербидә шофер булып эшли башлый. Эшен җиренә җиткереп башкарганы өчен авылдашлары аны хөрмәт итәләр.

1937 елда Салих Гайнетдинов армия сафларына чакырыла. Хезмәте тәмамланыр алдыннан гына Бөек Ватан сугышы башлана. Ул фронтта артиллерия орудиесе төзәүчесе, шофер, взвод командиры була. Җиңү көнен Берлинда каршылый. Еллар үткән саен ул, 1945 елның маен искә төшереп, хәтерен яңарта торган була. Сугышчыларның ничек сөенүләрен, Җиңү шатлыгының кабатланмас мизгелләрен ул балаларына сөйләп калдыра. Сугышчан батырлыклары өчен Кызыл Йолдыз, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, күпсанлы медальләр белән бүләкләнә.

Демобилизацияләнгәннән соң Салихҗан Гайнетдинов инде күптән җанына газиз авылга әйләнгән Хәербигә әйләнеп кайта. Утны-суны кичкән солдатны «Алга» колхозы рәисе итеп сайлыйлар. Сугыш чорында тәмам таркала язган колхозны аякка бастыру өчен ул бөтен көчен, сәләтен, тәҗрибәсен эшкә җигә. Партия һәм хөкүмәт колхозларда атларның баш санын арттыруны бурыч итеп куя. Сугыш чорында атлар да фронтка алына. Ә сугыштан соңгы елларда авылда аттан башка булмый. Техника юк, барлык эшләр ат һәм кул көче белән башкарыла. Бу бурычны «Алга» колхозы уңышлы башкарып чыга. 1949 елда Салихҗан абый ТАССР Министрлар Советы Дипломы һәм 1000 сум акчалата премия белән бүләкләнә. (410 нчы номерлы диплом, 1950 ел, 5 май). Бүләк бирү алдыннан Салих абыйны КПСС өлкә комитетына чакырып алып: «Сезгә бүләк бар, сайлап алу мөмкинлеге бирәбез. Я сезгә Социалистик Хезмәт Герое исеме бирелә, яки Диплом һәм акчалата бүләк,» – диләр. Салих абый өенә кайтып, хатыны Камилә апа белән киңәшә. Өйләре бик иске, кышларын идәндә мунчала бозланып ката торган була. Шуңа күрә акчаны алып, өй салырга карар кылалар.

«Алга» колхозы авыл хуҗалыгы планнарын һәрвакыт арттырып үтәп бара. Шуның өчен ГАЗ-69 автомобиле белән бүләкләнә.

1950 елларда С.Г.Гайнетдинов Лаеш районында урман утырту эшендә катнаша. 500 гектар җирдә урман утыртыла. Хөкүмәт планнарын вакытыннан алда уңышлы үтәп чыгудагы эшчәнлеге өчен, ТАССР урман промышленносте министрлыгы карары белән Салихҗан Гайнетдинов велосипед белән бүләкләнә (ул вакыт өчен бу бик зур бүләк була). «Совет Татарстаны» газетасының 1959 ел 5 октябрь санында урман утырту юнәлешендәге уңышлар турында мәкалә басылып чыга.



Салихҗан ага үзен үстергән әти-әнисе һәм гаиләсе белән.

Куйбышев сусаклагычы төбендә каласы территорияләрне чистарту, мелиорация эшләре алып бару да Салих ага җитәкчелегендә эшләнә. 1957 елда 600 гектар сазлык киптерелеп, сөрүлек җиргә әйләндерелә. «Алга» колхозы яшелчәчелек белән дә шөгыльләнә башлый. Элек тозлы кәбестә эзләп рус авылларына йөргән хәербиләләр үзләре мул уңыш үстереп сата. 1958 елда «Алга» колхозы Столбище МТСының трактор паркын сатып ала. Салихҗан Гайнетдинов инициативасы белән авылда радионокта ачыла, клубка кино күрсәтү җайланмасы алына. Барадан



1



2

1. Гаилә архивыннан; 2. Гайнетдиновлар һәм Миңсылу апа (Идрис тәтә).

булса да, зур клуб та ул рәислек иткәндә салына. 1952 елда, Мишә елгасын буып, колхозара электр станциясе төзиләр, тик бу станция, язгы ташу вакытында җимерелеп, агып китә.

1957 елда, өстән кушу буенча, авылда дуңгыз фермасы төзелә. Хуҗалык зурайганнан зурая: нәселле атлар, сыерлар, сарыклар, кроликлар, каз-үрдәкләр, тавыклар һәм башка терлекләр үрчетелә.

1958 (кайбер чыганаклар буенча 1962) елда авылга электр кертелә һәм бу юлы инде гомерлеккә! Шул ук елда йон теттерү машинасы (шерстобойка) һәм такта ярдыру җайланмасы (пилорама) сатып алына. Колхозда терлекчелек комплексы, ашлык һәм терлек азыгы саклагычлар төзелә.

Гайнетдиновлар үз шәхси хуҗалыкларында да тик ятмыйлар: сыер, сарык асрыйлар, күпләп кош-корт тоталар. Бозауларын ел саен дәүләткә тапшырып баралар. Күпне күргән, күпне кичергән Салих ага җаваплылыктан курыкмый, эшләп тапкан һәр тиеннең ни икәнен белә. Авылда ул чакта өй түбәләрен салам белән ябалар әле. Янгын чыгу куркынычы зур була. Колхоз рәисе янгын сүндерү хезмәтен оештыра. Алга салам түбәләрне бетерү бурычы куела. Озакламый авылда салам түбәле йортлар калмый.

Бу гаҗәеп булдыклы, алдан күреп эш итүчән, авыл бәхетеннән Хәербигә килеп эләккән кеше турында язганда, тагын бер әһәмиятле вакыйганы искә төшереп китү кирәк. Салих абый колхозда 40 гектарлы алма бакчасы утырттыра. Кешеләрне гаҗәпләндереп, үзенең бәрәңге бакчасын да җиләк-җимеш бакчасына әйләндерә. Бәрәңгедән башка берни үстермәгән авылдашлар алма белән сыйланалар. Нинди генә сортлы алмалар үсми анда!

Салихҗан Гайнетдин улы — сугыш һәм хезмәт ветераны, өлкә, район партия конференцияләре делегаты, КПССның район комитеты әгъзасы, авыл советы депутаты була. 1954 елда СССР Авыл хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсендә (ВДНХ) булган алдынгылар слётында (Мәскәү, 189243 нче номерлы путевка), 1956 елда М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрын ачу тантанасында делегат булып катнаша.

Югарыда әйтелгәннәр аның эшчәнлегенең тулы исемлеге түгел. Ул гомеренең соңгы көненә кадәр җәмгыятьнең актив әгъзасы булып кала. 1960 елда, авыру сәбәпле, колхоз рәисе вазифасын үтәүдән туктавына карамастан, актив җәмәгать эшчәнлеге алып бара. 1962–81 елларда халык контроле төркеменә җитәкчелек итә. Салихҗан Гайнетдинов 2001 елның 5 октябрендә вафат була. Хәерби авылы зиратына җирләнә.

Хатыны **Гайнетдинова Камилә Вафа кызы**, 1923 елның 23 октябрендә Хәерби авылында туа, 5 яше тулганда әнисез кала. Камилә кечкенәдән хезмәткә өйрәнеп үсә, мәктәптә яхшы билгеләренә генә укый, гаиләдә өлкәннәрнең



1




2



3



4



5



6

1. Салих Гайнетдинов хатыны Камилә белән. 1995 ел; 2. Ат үрчетү һәм тайлар үстерүдә планны арттырып үтәгәне өчен бирелгән диплом. 1949 ел; 3. Мәскәүдә СССР ВДНХсында. 1954 ел; 5. Солдат хезмәтендә. 1939 ел; 4, 6. Салихҗан ага хуҗалык рәисе чорында.



1



2

Галимҗан Гайнетдинов; 2. Гайнетдиновларның кызлары: Миннеруй, Розалия, Минниса, Минзәлия.

ярдәмчесе була. Үсә төшкәч, колхозда эшли, ә Бөек Ватан сугышы елларында тылда эшләгән өчен СССР Югары Советы Президиумының «1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләнә.

Салихҗан абый белән Камилә апа 5 бала тәрбияләп үстерәләр:

Гайнетдинов Галимҗан Салихҗан улы (1949 елда туган), Лаеш авыл хуҗалыгы техникумының агрономия бүлеген тәмамлый. Совет армиясе сафларына алынып, Кара диңгез флотында хезмәт итә. Армиядән кайткач, Казан автотранспорт техникумында укып механик белгечлеге ала. Халыкара хөкүмәт элемтәсенең куркынычсызлык хезмәтендә эшли. Шигырьләр яза, Г.Р.Державин исемендәге район иҗат конкурсы лауреаты.

Гайнетдинова (Салеева) Миннеруй Салихҗан кызы 1952 елда туган, Мәскәү җиңел сәнәгать институтын тәмамлый. Җиңел сәнәгать һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү системасында эшли. 2002 елда ул «Росбытсоюз» җәмгыяте һәм Профсоюзлар Үзәк Комитетының «Халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү отличнигы» күкрәк билгесенә лаек була. Татарстан Республикасы Президентының 2007 ел, 16 октябрь Указы белән аңа «Татарстан Республикасының атказанган халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү хезмәткәре» исеме бирелә. «Казанның 1000 еллыгы» медале белән бүләкләнә, хезмәт ветераны.

Гайнетдинова (Домрачева) Минзәлия Салихҗан кызы (1955 елда туган), Казан химия-технология институтының инженерлык факультетын тәмамлый. Оборона сәнәгатендә эшли. 1990 елларда Казан дәүләт университетының филология факультетында белем ала һәм мәгариф системасына күчә.



Сафина Миннисa.

Гайнетдинова (Сафина) Миннисa Салих кызы (1957 елда туган), Казан педагогика институтының чит телләр факультетын тәмамлый. Педагогика өлкәсендә фәнни эшчәнлек алып бара. Педагогика фәннәре кандидаты (2005 ел), Казан федераль университетының чит телләр кафедрасы доценты (2008 ел). Күп фәнни хезмәтләр авторы.

Гайнетдинова (Аввакумова) Розалия Салихҗан кызы (1960 елда туган), Казан педагогика институтының тарих-филология факультетын тәмамлый. Укуын тәмамлагач, шәхси бизнес оештыра. Эшмәкәр.

**Гарифуллин Нурхәмәт Гарифулла улы** 1929 елның 28 февралендә Хәерби авылында туа. Мәктәпне 1945 елда тәмамлый һәм «Алга» колхозында колхозчы булып эшли башлый. Балачагы Бөек Ватан сугышы елларына туры килә. 1948–1949 елларда Тәтеш кырчылык авыл хуҗалыгы мәктәбендә белем ала. 1949–1952 елларда «Алга» колхозында агротехник. 1952–1955 елларда Авыл хуҗалыгы министрлыгының Казан шәһәрендәге колхоз рәисләре әзерләүче Татарстан урта авыл хуҗалыгы мәктәбендә укый. 1955 елдан Столбище районының «Прожектор» колхозында агроном, 1956–1957 елларда КПССның Столбище райкомында инструктор. 1964 елда Казан авыл хуҗалыгы институтын читтән торып тәмамлый. 1957–1967 елларда «Алга» колхозында агроном. 1967–1973 елларда «Алга» колхозы рәисе, 1973 елдан шунда ук агроном. «Почёт билгесе» ордены һәм медальләр белән бү-





| Награжден орденом | № ордена | Указом Президиума Верховного Совета СССР |
|---|---|---|
| „Знак Почета“ | 677648 | от „8“ апреля 1971 г. |

ж № 355329

Секретарь Президиума Верховного Совета СССР

„4“ мая 1971 г.

«Почёт билгесе» ордены белән бүләкләнү таныклыгы. 1971 ел.



«Алга» колхозы рәисе Н.Гарифуллин.

ләкләнә. Нурхәмәт Гарифулла улы 2014 елда вафат.

Хатыны – Сара Фазыл кызы (1931–2002), Балык Бистәсе районы Таулар авылында туган. Гарифуллиннар 5 бала тәрбияләп үстерәләр: Наил (1952 елда туган), Альфируз (1955), Рафаэль (1957), Таһир (1959), Айрат (1963).

**Әхмәтшин Альберт Дәүләт улы** 1941 елның 10 маенда Кама Тамагы районының Чаллы авылында туа. 1982 елның сентябреннән 1988 елның апреленә кадәр «Хәерби» совхозы директоры вазифасында. Альберт Дәүләт улы шушы еллар эчендә үзенең шәхси сыйфатлары һәм хуҗалык итү рәвеше белән Хәерби халкының ихтирамын яулый. Ул үзе дә совхоз эшчеләрен һәм хезмәткәрләрен, авыл халкын бик яратып кала. Бирегдән киткәннән соң башка урыннарда эшләсә, зур җитәкче вазифалар биләсә дә, ул Хәербидә эшләгән чорларын, үзе кул астында хезмәт куйган кешеләрне онытмый, исемләп хәтерли, хуҗалык тормышыннан хәбәрдар булып яши. Бүләкләре: ТРның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре (1998 ел); Хезмәт ветераны (2001); «Казанның 1000 еллыгы» медале (2005). Хатыны – Зөһрә Шәйхетдин кызы Әхмәтшина, 1947 елның 19 мартында Кама Тамагы районының Олы Кариле авылында туа. Лаеш районы Нармонка урта мәктәбендә химия һәм биология укытучысы, Нармонка «Кояшкай» балалар бакчасы мөдире булып эшли. Әхмәтшиннар ике ир бала тәрбияләп үстерәләр, алты оныклары бар. Олы уллары Айдар Альберт улы Әхмәтшин Казан «Оргсинтез» акционерлык җәмгыяте генераль директоры урынбасары. Кече уллары Илнур Альберт улы Әхмәтшин – менеджер.







**Минбаев Фәрит Нури улы** 1960 елның 7 сентябрендә Хәерби авылында туа. Казан авыл хуҗалыгы институтын (1982) тәмамлый. 1983–1985 елларда армия сафларында хезмәт итә. «Хәерби» совхозында инженер, баш инженер булып эшли. 1988–1990 елларда «Хәерби» совхозы директоры. Алга таба Ф.Минбаев КПССның Биектау райкомы оештыру-партия һәм кадрлар эше бүлеге инструкторы, «Татагропромремонт» заводының гомуми мәсьәләләр буенча директор урынбасары, «Татсельхозтехника» компаниясенең Березовский бүлеге управляющие, «Татсельхозтехника» компаниясе генераль директоры урынбасары, «Татэкосервис»ның гомуми мәсьәләләр буенча директор урынбасары, Казан шәһәре башкарма комитетының «Дортранспорт» оешмасы директоры, Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, «Металлстрой» ҖЧҖ директоры урынбасары, «Татмелиоводхоз»ның Казан идарәсе сугару-киптерү системаларын эксплуатацияләү филиалы башлыгы булып эшли. 2014 елдан «Татмелиоводхоз» идарәсе директоры урынбасары. Дипломнар, Мактау грамоталары белән бүләкләнә. Ике улы, 3 оныгы бар.



Оныгы Данияр белән.



**Галиев Илдус Гарифулла улы** 1947 елның 8 гыйнварында Әлки районының Алпар авылында туа. Туган авылында урта мәктәп тәмамлаганнан соң, укуын Казан ветеринария институтында дәвам итә. Дипломлы белгеч 1969 елда Лаеш районы «Алга» колхозына баш зоотехник итеп билгеләнә. Өч ел эчендә ул Хәербинең үз кешесенә әйләнә. 1972–1973 елларда армия сафларында хезмәт итә. 1973 елдан Лаеш районы Урта Девятово авылында, 1975 елдан – кабат Хәербидә, үз вазифасында. 1987 елдан Хәерби авыл советы рәисе, 1992–1995 елларда «Хәерби» совхозы директоры. 1971 елда Хәерби авылында туган Сибгатуллина Сания (Сафия) Сибгать кызына өйләнә. Уллары: Ринат (1971 елда туган) һәм Илсур (1975). Бүгенге көндә Илдус Гарифулла улының өч оныгы бар.

## X БҮЛЕК

## ИР-ЕГЕТНЕҢ УҢГАНЛЫГЫ КЫРЛАРЫННАН КҮРЕНӘ

Хәербинең һәм Лаеш районының җир белгече, диләр аның хакында. Бу чыннан да шулайдыр. Хуҗалыкта аның аягы басмаган бер карыш җир дә калмагандыр. Һәр басуны, аның кайсы почмагында нинди культура яхшы үсәсен биш бармагы кебек яхшы белә ул. Шуңа да башка авыл хуҗалыкларының да баш белгечләре аның киңәш-тәкъдимнәрен истә тотып эш итә. Сүзебез **Шамил Әхмәтҗан улы Кушмин** хакында.



Шамил ага тумышы белән Лаеш районы Татар Янтыгы авылыннан. Ул 1948 елның 17 сентябрендә туган, галим-агроном, Татарстан Республикасының (2002 ел) һәм Россия Федерациясенең (2007) атказанган агрономы. 1971 елда Казан авыл хуҗалыгы институтын тәмамлый. 1971–78 елларда Үзәк авыл хуҗалыгы экспериментал фәнни-тикшеренү институтында агроном булып эшли. 1978 елдан «Хәерби» совхозында, 1995 елдан «Хәерби» күмәк предприятиесендә, 2003 елдан «Хәерби» ҖЧҖтә баш агроном. Ул Татарстанда беренче булып үрентесез кәбестә үстерү ысулының сәнәгый технологиясен куллана, бәрәңге игүнең универсаль технологиясен гамәлгә ашыра, бөртекле культураларның орлыкчылык тармагы үсешенә зур өлеш кертә. Бөртеклеләр, азык һәм яшелчә культураларыннан зур уңышлар алуга керткән өлеше өчен медаль, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының күпсанлы Мактау грамоталары һәм дипломнары белән бүләкләнә.



Роза һәм Шамил Кушминнар. 1972 ел.

Шамилгә 10 яшь булганда аның әнисе Фатыйма апа үлеп китә. Әтиләре Әхмәтҗан абый өч ятим баласы белән икенче хатынга өйләнә. Рабига апа балалар өчен бик яхшы әни була.

Ә Хәербидә практикага килгән җиреннән кала ул. Эшләргә кеше






1. Шамил Кушмин хатыны Роза белән. 2017 ел.
2. Кушминнар кызлары Гөлназ, кияүләре Илнур, оныклары Мәдинә белән. 2017 ел.

булмау сәбәпле, Авыл хуҗалыгы институты ректоры исеменә хат язып, студент Кушмин Шамилнең укуын тәмамлауны кичектерүләрен сорыйлар һәм, ректордан рөхсәт алынгач, егетне Хәерби колхозына баш агроном итеп куялар. Ул бер елдан соң институтка барып, имтиханнарын тапшырып, агроном-экономист дипломын алып кайта. Тагын бер ел эшләгәч, армиягә алына. Аннан соң да Хәербигә әйләнеп кайта. 2019 елга аның эш стажы 50 елга тула. Авырып, катлаулы операцияләр ясатса да, эшеннән аерыла алмый Шамил Әхмәтҗан улы. Еллар үткән саен тәҗрибәсе ныгый барган белгеч беркайчан да сынатмый. «Әгәр яшьлеккә кире кайтып, кабат һөнәр сайларга туры килсә, мөгаен, шушы юлдан китәр идем. Мин аның тынгысыз хезмәт икәнен белеп үстем. Иртә торырга, соң ятарга кирәген дә аңладым. Шулай булса да, хезмәтемне яратам», – ди ул.

## ХӘЕРБИДӘ ҮРЕНТЕСЕЗ ЫСУЛ БЕЛӘН КӘБЕСТӘ ҮСТЕРҮ ТӘҖРИБӘСЕ

2004 елдан Хәерби хуҗалыгында агроном Кушмин Шамил Әхмәтҗан улы җитәкчелегендә 30 гектар мәйданда кәбестәне үрентесез үстерү ысулы кертелә башлый. Үрентесез ысул куллану каян килеп чыккан соң? Алдагы сүзебез шул хакта.

Баштарак Хәербидә кәбестәне кырга гел үрентеләрдән генә утырталар. 2004 елны үренте үстерә торган теплица корылмасы, кинәт яуган кар авырлыгын күтәреп тора алмыйча җимерелә, үрентеләр өстенә төшә һәм алар







1. Ындырда; 2. Агрономның машинасы. 2005 ел.

утыртырга яраксызга әйләнеп, хуҗалык үрентесез кала. Анысы гына да түгел, кабат яңаларын чәчеп үстерергә вакыт та калмый. Шамил Әхмәтҗанович белән хуҗалык җитәкчесе Радик Кадыйрович Вафин киңәшләшеп, орлыкларны ачык грунтка чәчәргә тәвәккәллиләр. Нәтиҗәдә, көз көне бик яхшы уңыш җыеп алалар. Башка елларны да кәбестәне шул ысул белән үстерергә булалар. Тәҗрибә күрсәткәнчә, болай үстерү ысулы чыгымнарны байтак киметә.

Мондый агротехнологиянең мөһим өлешен барлык вегетатив үсеш стадияләрендә үсемлекләрне корткычлардан һәм чүп үләннәрдән саклау системасы булдыру: орлыкларны әзерләү, үсемлекләрне үсеш этапларында зарарлы организмнардан саклау һәм алдагы елда чәчеләчәк орлыкны зарарсызландыру тәшкил итә.

Шулай ук чәчү вакытын дөрес билгеләү дә мөһим. Орлыкларны иртә язда чәчәргә кирәк, бу туфрак дымын файдаланып калуның ышанычлы ысулы. Бу очракта шытымнар тиз үсеп чыгалар. Соңрак өлгерешле сортларны чәчүнең кулай вакыты — апрель ахыры – май башы, ул вакытта 5 см тирәнлектәге туфракның температурасы 8–10 С° ка җитә. Туфракның дымлылыгы 75–80% булуы шарт.

Туфрак көздән әзерләнә. Туңга сөрү – уңышны арттыруны тәэмин итә торган иң мөһим агротехник ысул. Ул язгы эшләрне оештыруны җиңеләйтә, чөнки эшкәртелгән туфракка көзге яңгырлар дымы һәм язгы ташу сулары җиңел сеңә торган була. Туңга сөрү шулай ук чүп үләннәрне һәм корткычларны бетерергә булыша.

Корткычларга каршы тора ала торган чыдам сортларны сайлап ала белү кирәк. «Хәерби» хуҗалыгында башлыча «Подарок» («Бүләк») һәм «Экстра» кәбестә сортлары үстерелә.

| Еллар | **Чәчү мәйданы,** *га* | **Уңыш,** *т гектардан* | **Табыш,** *млн сум* |
|---|---|---|---|
| 2004 | 20 | 30 | 3,5 |
| 2005 | 23 | 58 | 3,2 |
| 2006 | 23 | 48 | 4,0 |
| 2007 | 25 | 46 | 3,6 |
| 2008 | 25 | 43 | 4,0 |
| 2009 | 25 | 45 | 4,1 |
| 2010 | 28 | 31 | 4,0 |
| 2011 | 30 | 50 | 4,3 |
| 2012 | 28 | 52 | 4,0 |
| 2013 | 26 | 48 | 3,8 |
| 2014 | 26 | 47 | 3,9 |
| 2015 | 22 | 40 | 3,5 |
| 2016 | 20 | 41 | 3,6 |
| 2017 | 16 | 60 | 3,7 |
| 2018 | 10 | 60 | 3,5 |
| Барлыгы уртача | 23,1 | 46,6 | 3,8 |

Үрентесез ысул белән үстергән кәбестәнең уңышы күп вакытта традицион ысул белән үстерелгәнгә караганда яхшырак чыга. Аларның тамырлары көчле була һәм тирәнгә китеп үсә, шунлыктан үсентеләр дым белән яхшырак тәэмин ителә һәм кыш көне дә сыйфатлы саклана, «шыгырдап тора».

«Хәерби» ҖЧҖендә житештерелгән кәбестә уңышы тотрыклы рәвештә гектардан 40–50 т тәшкил итә, кәбестә сатудан хуҗалык ел саен 3–4 млн сум табыш ала (табл. кара).

Шул рәвешле, Лаеш районының «Хәерби» ҖЧҖендә үрентесез кәбестә үстерү ысулы хуҗалык эшчәнлегенең прогрессив һәм рентабельле формасын тәшкил итә.

# XI БҮЛЕК

## СӘЯСИ РЕПРЕССИЯЛӘР КОРБАННАРЫ

1930 елларда Совет власте тарафыннан авыл җирләрендә колхозлаштыру һәм кулакларны сыйныф буларак юк итү сәясәте алып барылу массакүләм репрессияләргә китерә. Йорт-җирләреннән һәм мөлкәтләреннән мәхрүм ителгән крестьяннар Ерак Көнчыгышның һәм Төньякның яшәү өчен шартлары булмаган эчкәреге районнарына сөреләләр.

«Хәтер китабы» редакциясе әзерләп бастырган «Сәяси репрессияләр корбаннары» китабында Хәерби авылы кешеләре турында да мәгълүмат бар. Түбәндәге исемлек – шул китаптан, анда ничек бирелгән, шул рәвешчә китерелә.

**ВАФИН Хәбибулла Вафа улы**, 1905 елда Лаеш районы Хәерби авылында туган, шунда яшәгән. Татар, крестьян. 1931 елда Лаеш районы җирле башкарма органнары тарафыннан йорт-җиреннән, мөлкәтеннән мәхрүм ителгән. 8.2.1999 да акланган.

**МӨХЕТДИНОВ Җамали**, 1880 елда Лаеш районы Хәерби авылында туган, шунда яшәгән. Татар, крестьян. 1930 елда Лаеш районы җирле башкарма органнары тарафыннан йорт-җиреннән, мөлкәтеннән мәхрүм ителгән. 17.3.1998 дә акланган.

**ТӨХФӘТУЛЛИН Гайнулла**, 1881 елда Лаеш районы Хәерби авылында туган, шунда яшәгән. Татар, крестьян. Гаиләсе: хатыны Сәгыйрә (Заһирә) (1890), кызы Мәрзия (1915), кызы Җиһан (1919), улы Камил (1921), кызы Сафия (1923), кызы Сафура (1925), кызы Сәйдә (1927). Гаилә 22.8.1931 дә Лаеш РБК тарафыннан йорт-җиреннән, мөлкәтеннән мәхрүм ителгән һәм Чиләбе өлкәсенә сөргенгә җибәрелгән. 10.10.1995 тә акланганнар.

**ТӨХФӘТУЛЛИН Миңнебай Төхфәтулла улы**, 1876 елда Лаеш районы Хәерби авылында туган, шунда яшәгән. Татар, крестьян. Гаиләсе: кызы Бибизәһрә (1910). Гаилә 1930 елда Лаеш районы җирле башкарма органнары тарафыннан йорт-җиреннән, мөлкәтеннән мәхрүм ителгән. 26.8.1998 дә акланганнар.

**ФӘЕЗОВ Һади Кәрим улы**, 1901 елда Лаеш районы Хәерби авылында туган, шунда яшәгән. Татар, сәүдәгәр. Гаиләсе: әтисе Әбделкәрим Фәез улы (1873). Гаилә 1930 елда Лаеш РБК тарафыннан йорт-җиреннән, мөлкәтеннән мәхрүм ителгән. 22.8.1997 дә акланганнар.

**ХАЛИТОВ Зариф**, 1881 елда Лаеш районы Хәерби авылында туган, шунда яшәгән. Татар, крестьян. Гаиләсе: хатыны Газизә (1892), кызы Сабира (1914), улы Сәлим (1925), кызы Сания (1927), улы Нәҗип (1931). Гаилә 5.7.1931 дә Лаеш РБК тарафыннан йорт-җиреннән, мөлкәтеннән мәхрүм ителгән һәм Чиләбе өлкәсенә сөргенгә җибәрелгән. 29.4.1993 тә акланганнар.

**ШАКИРОВ Габдулла Мөхәммәтшакир улы**, 1907 елда Лаеш районы Хәерби авылында туган, шунда яшәгән. Татар, крестьян. Гаиләсе: әтисенең хатыны Шәфига (1899), хатыны Оркыя (1907), икенче хатыны Хәлимә (1910), кыз туганы Хәлимә (1924), ир туганы Закир (1926), кызы Хәлимә (1931), улы Һидиятулла (1940), кызы Әлфия (1947). Гаилә 1931 елда Лаеш РБК тарафыннан йорт-җиреннән, мөлкәтеннән мәхрүм ителгән һәм Чиләбе өлкәсенә сөргенгә җибәрелгән. 14.5.1996 да акланганнар.

**ЯРУЛЛИН Әхмәтсафа**, 1893 елда Лаеш р-ны Хәерби авылында туган, шунда яшәгән. Татар, крестьян. Хатыны Газизә (1897), кызы Нурия (1919), кызы Рауза (1928), улы Вафа (1929), улы Хафиз (1935). Гаилә 1930 елда Лаеш РБК тарафыннан йорт-җиреннән, мөлкәтеннән мәхрүм ителгән һәм Чиләбе өлкәсенә сөргенгә җибәрелгән. 27.6.1996 да акланганнар.

**ЯРУЛЛИН Хәйрулла**, 1874 елда Лаеш районы Хәерби авылында туган, шунда яшәгән. Татар, крестьян. Гаиләсе: хатыны Гайшә (1875), улы Абдулла (1905), килене Камәрия (1907), оныгы Мәрзия (1933), оныгы Һәдия (1937), оныгы Роза (1940). Татарстан ҮБК тарафыннан йорт-җиреннән, мөлкәтеннән мәхрүм ителгән һәм Хабаровск краена сөргенгә җибәрелгән. 1.8.1996 да акланганнар.

Татарстан Республикасы Дәүләт архивы материаллары арасында Хәерби авылында кулак гаиләсе дип табылган һәм республика чикләреннән куарга дип расланган документларның берсе табылды. Ул 1932 елның 31 мартында тутырылган, барлыгы 9 хуҗалыкның гаилә башлыгы һәм гаилә әгъзалары турындагы мәгълүмат теркәлгән. Бер үк сорауларга нигезләнеп тутырылган бу документта гаилә башлыгының исеме, фамилиясе, туган урыны, яше, милләте күрсәтелгән. Шулай ук социаль чыгышы, хәзерге социаль хәле, революциягә кадәр һәм аннан соңгы чордагы төп шөгыле, имана һәм аренда җирләре мәйданы, мал-туарлары күрсәтелеп, хуҗалык хәле, 1926 елдан авыл хуҗалыгы салымы, шәхси салым һәм башка төр дәүләт һәм җәмәгать салымнары турында мәгълүматлар бирелгән һәм иске, ягъни патша армиясендә, ак армиядә булу-булмавы да ачыкланылган. Алга таба гаиләсе турында мәгълүмат теркәлгән һәм бу гаиләнең ни өчен кулак хуҗалыгы итеп танылуы турында карар чыгарылган.

Кулак категориясенә кемнәр кертелгән соң? 1930 елда басылып чыккан нигезләмәдә күрсәтелгәнчә, кулак хуҗалыклары түбәндәге критерийлар буенча билгеләнә: он тарту, ярма яру тегермәне, май язу машинасы һәм башка төрле механик двигатель кулланыла торган җиһазлары булу; механик двигательле авыл хуҗалыгы машиналарын системалы рәвештә эшләтергә биреп тору; җиһазландырылган биналарны торак йорт итеп яки предприятие итеп файдаланырга кешегә биреп тору; сәүдә, рибачылык (ростовщиклык), арадашчылык белән шөгыльләнү. Әгәр дә хуҗалык санап кителгән билгеләрнең берсенә генә ия булса һәм гаилә әгъзаларына бүлгәндә елына бер кешегә 300 сум табыш алса, ул кулак хуҗалыгы дип исәпләнә. Алар авылның иң булдыклы, һәр яңалыкка сизгер, тату, яшим дип яшәүче гаиләләре, тырыш игенчеләр, җирдә эшләүдән тыш, тагын башка эш-кәсепләргә йөрәксенеп тотынган эшлекле кешеләре була. Колхозлар төзү чорында менә шул крестьяннар, кулаклар рәтенә кертелеп, «бөек төзелешләр»гә җибәрелгән дә инде. Аларның авылда чыгып китү фаҗигасен үз күзләре белән күргәннәр бүген исән түгел. Әмма бу хәсрәтне кичергәннәрнең, аларны һич чарасыз озатып калганнарның тетрәнүләрен без матур әдәбияттан укып, кинофильмнардан күреп бераз аңлый алабыз. Аның ачылыгын, әлбәттә, үз башыннан узганнар гына белә. Барып төшкән урыннарында да тормыш дәвам иткән − яңа буын кешеләр туган, әти-әниләренең күргән-кичергәннәре, яңа җирләрдәге газаплары аларның истәлекләрендә генә калган. Илебез тарихының «крестьян хуҗалыкларын күмәкләштерү» дип җайлы гына әйтеп һәм язып кителә торган ул чоры меңнәрчә-меңнәрчә кешеләрнең ачы язмышы, фаҗигасе белән бәйле. Шул михнәтле чорларны кичкән күпләрнең – туган җирдә калып колхоз корганнарның балалары һәм оныклары да, өлкәннәр сөйләгәннән, ул заманны бүгенге көндә дә чын йөрәктән әрнеп искә төшерәләр.

***Фонд Р-732, опись 4, дело 225 (31 марта 1932 г.)***
***Личная карточка на кулацкое семейство,***
***утвержденное к высылке из пределов Республики.***

***Ф.И.О.:*** *МИФТАХОВ Сунгат*

***Год и место рождения:*** *63 г., дер.Кирби Лаишевского района*

***Национальность:*** *татарин*

***Бывшая сословная принадлежность и социальное положение:*** *Мулла*

***Лишен ли избирательных прав, если не лишен то почему:*** *Лишен с 1924 г.*

***Род занятий (основной и подсобный) до Революции и после 1917 г.:*** *До 1917 г. арендовал землю до 2 га и после до 24 г. 3 га. До 17 г. имел 2 ло-*

*шади. 2 коровы, 15 овец, с 17 г. по 18 г. то же самое. До 17 г. и после до 28 г. эксплуатировал батрака, служитель религиозного культа с доходностью в год 1270 руб.*

***Привести данные с 1926 года о сельхозналоге, индивидуальном обложении и других видов гос. и общ. платежей, при этом если данное кулацкое хозяйство выполняло эти виды налогов по разряду «середняцкого хозяйства» — указать почему, приведя обоснованные мотивы к укрытию объектов обложения:*** *Индивидуальным налогом облагался в 29/30 г. в размере 100 р., в 30/31 г. 147 руб. 10 коп. с облагаемого дохода 357 руб. и в 1931 г. в размере 415 руб. с облаг. дохода 1270 руб.*

***Служба в старой и особо белой армиях, в белых кадровых формированиях, бандах и т.п., указав в каких частях, в каком чине и в какое время состоял, в том числе участие в «вилочном восстании» в ТР:***

***Члены семьи:*** *Жена: Бадигул, 60 л; сын: Хайрулла, 22 г.; дочь: Кашафа, 20 л., сын: Хамат, 15 л.*

***Когда окончена перепроверка данного хозяйства и кто из уполномоченных перепроверял, указать фамилию, имя, отчество каждого, служебное положение, партийность и адрес:*** *25 февраля 1932 г. Уполномоченный РИКа Ризванов, член ВКП(б).*

***Постановление:*** *Постановлением РИКа от 31 марта 1932 г. №17, как арендатор земли и лугов, служитель религиозного культа, эксплуататор батрака, признан кулацким хозяйством.*

***Ф.И.О.:*** *МУХАМЕТЗЯНОВ Мухаметша*

***Год и место рождения:*** *70 л., дер.Кирби Лаишевского района*

***Национальность:*** *татарин*

***Бывшая сословная принадлежность и социальное положение:*** *крестьянин кулак*

***Лишен ли избирательных прав, если не лишен то почему:*** *не лишен, по недосмотру с/совета*

***Род занятий (основной и подсобный) до Революции и после 1917 г.:*** *До 1917 г. имел: 3 лошади, 3 коровы, 25 овец и с 17 по 18 г.: 2 лошади, 2 коровы, 20 овец и после 31 г. 1 лошадь, 1 корову, 10 овец, имел ветряную мельницу с капиталовложением 1200 руб. и доходностью в год 1100 руб.*

***Привести данные с 1926 года о сельхозналоге, индивидуальном обложении и других видов гос. и общ. платежей, при этом если данное кулацкое хозяйство выполняло эти виды налогов по разряду «середняцкого хозяйства» — указать почему, приведя обоснованные мотивы к укрытию объек-***

***тов обложения:*** *Индивидуальным налогом облагался в размере 335 руб. с облагаемого дохода 1110 руб.*

***Служба в старой и особо белой армиях, в белых кадровых формированиях, бандах и т.п., указав в каких частях, в каком чине и в какое время состоял, в том числе участие в «вилочном восстании» в ТР:***

***Члены семьи:*** *Жена: Фатыма, 60 л., сын: Ганиакбер, 31 г.*

***Когда окончена перепроверка данного хозяйства и кто из уполномоченных перепроверял, указать фамилию, имя, отчество каждого, служебное положение, партийность и адрес:*** *25 февраля 1932 г. Уполномоченный РИКа Ризванов, член ВКП(б).*

***Постановление:*** *Постановлением РИКа от 31 марта 1932 г. №17, как имеющий ветряную мельницу, признан кулацким хозяйством.*

***Ф.И.О.:*** *МУХАМЕТШИН Зариф*

***Год и место рождения:*** *31 г., дер.Кирби Лаишевского района*

***Национальность:*** *татарин*

***Бывшая сословная принадлежность и социальное положение:*** *крестьянин кулак*

***Лишен ли избирательных прав, если не лишен то почему:***

***Род занятий (основной и подсобный) до Революции и после 1917 г.:*** *До 1917 г. имел скота: лошадей 3, коров 3, овец 30 и после до 28 г.: лошадей 2, коров 2, овец 20, с 28 г. лошадей 2, 1 корову, 15 овец, имел ветряную мельницу с капиталовложением 1200 р. с доходностью 1100 руб.*

***Привести данные с 1926 года о сельхозналоге, индивидуальном обложении и других видов гос. и общ. платежей, при этом если данное кулацкое хозяйство выполняло эти виды налогов по разряду «середняцкого хозяйства» — указать почему, приведя обоснованные мотивы к укрытию объектов обложения:*** *Индивидуальным налогом облагался в размере 246 руб. с облагаемого дохода 915 руб.*

***Служба в старой и особо белой армиях, в белых кадровых формированиях, бандах и т.п., указав в каких частях, в каком чине и в какое время состоял, в том числе участие в «вилочном восстании» в ТР:***

***Члены семьи:*** *Жена: Фатыма, 25 л; сын: Абдулла, дочь: Аминя*

***Когда окончена перепроверка данного хозяйства и кто из уполномоченных перепроверял, указать фамилию, имя, отчество каждого, служебное положение, партийность и адрес:*** *25 февраля 1932 г. Уполномоченный РИКа Ризванов, член ВКП(б).*

***Постановление:*** *Постановлением РИКа от 31 марта 1932 г. №17, как имеющий ветряную мельницу с капиталовложением 1200 руб. и доходностью 1100 руб. признан кулацким хозяйством.*

***Ф.И.О.:*** *ГУМАРОВ Карим*

***Год и место рождения:*** *72 г., дер.Кирби Лаишевского района*

***Национальность:*** *татарин*

***Бывшая сословная принадлежность и социальное положение:*** *торговец, служитель культа*

***Лишен ли избирательных прав, если не лишен то почему:*** *лишен*

***Род занятий (основной и подсобный) до Революции и после 1917 г.:*** *До 1917 г. и после до 1931 г. имел земельный надел, до 1917 г. имел 1 корову, 10 овец, с 1928 г. по 30 г. 1 корову, до 1917 г. имел ветряную мельницу с доходностью до 500 руб в год, бакалейную торговлю, служитель религиозного культа, 825 руб. в г. до 1917 и после до 30 г. имел 2-х батраков, Халитова Галима, Гайнутдинова Салима, имел сезонных работников до 300 трудодней.*

***Привести данные с 1926 года о сельхозналоге, индивидуальном обложении и других видов гос. и общ. платежей, при этом если данное кулацкое хозяйство выполняло эти виды налогов по разряду «середняцкого хозяйства» — указать почему, приведя обоснованные мотивы к укрытию объектов обложения:*** *Индивидуальным налогом облагался в 1930 г. и 31 г. в размере 133 руб., в кон. 1931 г. в размере 210 руб.*

***Служба в старой и особо белой армиях, в белых кадровых формированиях, бандах и т.п., указав в каких частях, в каком чине и в какое время состоял, в том числе участие в «вилочном восстании» в ТР:***

***Члены семьи:*** *Жена: Нуризания, 44 года.*

***Когда окончена перепроверка данного хозяйства и кто из уполномоченных перепроверял, указать фамилию, имя, отчество каждого, служебное положение, партийность и адрес:*** *25 февраля 1932 г. Уполномоченный РИКа Ризванов, член ВКП(б).*

***Постановление:*** *Постановлением РИКа от 31 марта 1932 г. №17, как экспуататор наемного труда и проживающий на не трудовые доходы признано кулацким хозяйством.*

***Ф.И.О.:*** *ХАЛИТОВ Зариф*

***Год и место рождения:*** *48 л., дер.Кирби Лаишевского района*

***Национальность:*** *татарин*

***Бывшая сословная принадлежность и социальное положение:*** *крестьянин-бедняк*

***Лишен ли избирательных прав, если не лишен то почему:*** *лишен с 1927 г.*

***Род занятий (основной и подсобный) до Революции и после 1917 г.:*** *с 1907 г. по 30 г. имел арендной земли и лугов до 2 га, до 17 г имел: 2 лошади, 2 коровы, 25 овец, с 17 по 28 г. имел: 2 лошади, 2 коровы, 15 овец, с 22 по 28 г. 1 лошадь, 1 корову, 5 овец; с 1921 г. по 27 г. имел постоянных батраков до 2-х человек и сезонных до 30 г. до 300 трудодней. С 21 по 27 г. имел бакалейную торговлю по 3-му разряду. В то же время торговал яйцами по 2-му разряду и в 21 г. торговал хлебом.*

***Привести данные с 1926 года о сельхозналоге, индивидуальном обложении и других видов гос. и общ. платежей, при этом если данное кулацкое хозяйство выполняло эти виды налогов по разряду «середняцкого хозяйства» — указать почему, приведя обоснованные мотивы к укрытию объектов обложения:*** *Индивидуальным налогом облагался в 28/29 г. в размере 49 руб. с облагаемого дохода 477 руб.*

***Служба в старой и особо белой армиях, в белых кадровых формированиях, бандах и т.п., указав в каких частях, в каком чине и в какое время состоял, в том числе участие в «вилочном восстании» в ТР:*** *в старой армии рядовым*

***Члены семьи:*** *Жена: Газиза, 40 л.; дочь: Сабира, 20 л., сын: Салих, 6 лет.*

***Когда окончена перепроверка данного хозяйства и кто из уполномоченных перепроверял, указать фамилию, имя, отчество каждого, служебное положение, партийность и адрес:*** *25 февраля 1932 г. Уполномоченный РИКа Ризванов, член ВКП(б).*

***Постановление:*** *Постановлением РИКа от 31 марта 1932 г. №17, как арендатор земли с применением постоянных батраков и сезонных рабочих, а также имевших бакалейную торговлю и яйцами.*

***Ф.И.О.:*** *ХАЙРИЕВ Зямал*

***Год и место рождения:*** *56 л., дер.Кирби Лаишевского района*

***Национальность:*** *татарин*

***Бывшая сословная принадлежность и социальное положение:*** *крестьянин кулак*

***Лишен ли избирательных прав, если не лишен то почему:*** *лишен с 27 г.*

***Род занятий (основной и подсобный) до Революции и после 1917 г.:*** *До революции и после до 30 г. кроме надельной земли арендовал у бедноты до 3 га, до революции и после 22 г. имел: 2 лошади, 2 коровы, 30 овец, с 22 по 28 г.*

*1 лошадь., 2 коровы, 10 овец. До 17 г. имел постоянного батрака и сезонных рабочих до 100 трудодней. С 17 по 19 г. сезонных до 350 трудодней. До 17 г. и после до 30 г. торговал мясом и яйцами.*

***Привести данные с 1926 года о сельхозналоге, индивидуальном обложении и других видов гос. и общ. платежей, при этом если данное кулацкое хозяйство выполняло эти виды налогов по разряду «середняцкого хозяйства» — указать почему, приведя обоснованные мотивы к укрытию объектов обложения:***

***Служба в старой и особо белой армиях, в белых кадровых формированиях, бандах и т.п., указав в каких частях, в каком чине и в какое время состоял, в том числе участие в «вилочном восстании» в ТР:***

***Подвергался ли суду и административным взысканиям:*** *Осужден в 1924 г. на 5 мес. условно*

***Члены семьи:*** *Жена: Галима, 55 л.; сын: Бадрутдин, 22 г., сын: Нурутдин, 13 л., дочь: Сулейбах, 10 л.*

***Когда окончена перепроверка данного хозяйства и кто из уполномоченных перепроверял, указать фамилию, имя, отчество каждого, служебное положение, партийность и адрес:*** *25 февраля 1932 г. Уполномоченный РИКа Ризванов, член ВКП(б).*

***Постановление:*** *Постановлением РИКа от 31 марта 1932 г. №17, как арендатор земли, с применением постоянных батраков и сезонных рабочих, а также имеющий торговлю яйцами, мясом признан кулацким хозяйством.*

***Ф.И.О.:*** *МУХАМЕТШИН Гариф*

***Год и место рождения:*** *45 л., дер.Кирби Лаишевского района*

***Национальность:*** *татарин*

***Бывшая сословная принадлежность и социальное положение:*** *крестьянин кулак*

***Лишен ли избирательных прав, если не лишен то почему:*** *не лишен*

***Род занятий (основной и подсобный) до Революции и после 1917 г.:*** *До 1917 г. имел: лошадей 3, коров 3, овец 30, с 1917 по 28 г. лошадей 2, коров 2, овец 25, с 28 г.: лошадей 2, коров 2, овец 20, имел ветряную мельницу с доходностью 1000 руб. в год; а также торговал мукой.*

***Привести данные с 1926 года о сельхозналоге, индивидуальном обложении и других видов гос. и общ. платежей, при этом если данное кулацкое хозяйство выполняло эти виды налогов по разряду «середняцкого хозяйства» — указать почему, приведя обоснованные мотивы к укрытию***

***объектов обложения:*** *Индивидуальным налогом облагался в 28/29 г. в размере 73 руб. 93 коп. с облагаемого дохода 593 руб. и в 31 г. в размере 280 р. с 1000 руб.*

***Служба в старой и особо белой армиях, в белых кадровых формированиях, бандах и т.п., указав в каких частях, в каком чине и в какое время состоял, в том числе участие в «вилочном восстании» в ТР:***

***Члены семьи:*** *Жена: Фатыма, 45 л; дочь: Шафика, 18 л., сын: Мингали, 16 л., сын: Садри, 14 л, дочь: Роза, 5 л., сын: Салим, 3 г.*

***Когда окончена перепроверка данного хозяйства и кто из уполномоченных перепроверял, указать фамилию, имя, отчество каждого, служебное положение, партийность и адрес:*** *25 февраля 1932 г. Уполномоченный РИКа Ризванов, член ВКП(б).*

***Постановление:*** *Постановлением РИКа от 31 марта 1932 г. №17, как имеющий с доходностью 1000 руб. и торговлю мукой, признан кулацким хозяйством.*

***Ф.И.О.:*** *ЯРУЛЛИН Хайрулла*

***Год и место рождения:*** *58 л., дер.Кирби Лаишевского района*

***Национальность:*** *татарин*

***Бывшая сословная принадлежность и социальное положение:*** *крестьянин кулак*

***Лишен ли избирательных прав, если не лишен то почему:*** *лишен с 1923 г.*

***Род занятий (основной и подсобный) до Революции и после 1917 г.:*** *До 1917 г. и после до 28 г. арендовал у бедноты землю и луга до 3 га, с 28 по 30 г. до 1 га, до 1917 г. имел: лошадей 4, коров 3, овец 30, с 1917 г. по 22 г. имел: 3 лошади, овец 30, с 22 по 28 г. лошадей 4, коров 2, овец 15, с 28 по 30 г. лошадей 1, коров 1, телка 1 и овец 13. До 17 г. и после до 30 г. имел торговлю мясом, имел патент 1-го разряда с применением батрака и сезонных работ до 490 трудодней.*

***Привести данные с 1926 года о сельхозналоге, индивидуальном обложении и других видов гос. и общ. платежей, при этом если данное кулацкое хозяйство выполняло эти виды налогов по разряду «середняцкого хозяйства» — указать почему, приведя обоснованные мотивы к укрытию объектов обложения:*** *Индивидуальным налогом облагался в размере 180 руб.*

***Служба в старой и особо белой армиях, в белых кадровых формированиях, бандах и т.п., указав в каких частях, в каком чине и в какое время состоял, в том числе участие в «вилочном восстании» в ТР:***

***Члены семьи:*** *Жена: Гайша, 58 л., сын: Абдулла, 26 л., сноха: Камаря, 25 л.*

***Когда окончена перепроверка данного хозяйства и кто из уполномоченных перепроверял, указать фамилию, имя, отчество каждого, служебное положение, партийность и адрес:*** *25 февраля 1932 г. Уполномоченный РИКа Ризванов, член ВКП(б).*

***Постановление:*** *Постановлением РИКа от 31 марта 1932 г. №17, как арендатор, с применением раб. силы и имевший торговлю мясом, признан кулацким хозяйством.*

***Ф.И.О.:*** *АБДРАФИКОВ Сафа*

***Год и место рождения:*** *52 г., дер.Кирби Лаишевского района*

***Национальность:*** *татарин*

***Бывшая сословная принадлежность и социальное положение:*** *крестьянин кулак*

***Лишен ли избирательных прав, если не лишен то почему:*** *не лишен*

***Род занятий (основной и подсобный) до Революции и после 1917 г.:*** *До 1917 г. имел лошадей 4, коров 2, овец 20, с 1907 г. по 22 г.: лошадей 3, коров 2, овец 20, с 22 по 30 г.: лошадей 3, коров 1, овец 10, имел ветряную мельницу с доходностью 788 руб., до 17 г. торгвал яйцами, после 17 г. мясом, мукой. До 17 г. и после имел батрака.*

***Привести данные с 1926 года о сельхозналоге, индивидуальном обложении и других видов гос. и общ. платежей, при этом если данное кулацкое хозяйство выполняло эти виды налогов по разряду «середняцкого хозяйства» — указать почему, приведя обоснованные мотивы к укрытию объектов обложения:*** *Индивидуальным налогом облагался в размере 195 руб. 20 коп. с облагаемого дохода 788 руб.*

***Служба в старой и особо белой армиях, в белых кадровых формированиях, бандах и т.п., указав в каких частях, в каком чине и в какое время состоял, в том числе участие в «вилочном восстании» в ТР:***

***Члены семьи:*** *Жена: Гайша, 48 л., сын: Ибрагим, 14 л.*

***Когда окончена перепроверка данного хозяйства и кто из уполномоченных перепроверял, указать фамилию, имя, отчество каждого, служебное положение, партийность и адрес:*** *25 февраля 1932 г. Уполномоченный РИКа Ризванов, член ВКП(б).*

***Постановление:*** *Постановлением РИКа от 31 марта 1932 г. №17, как имеющий ветряную мельницу с доход. 788 руб. и имеющий торговлю яйцами, мясом и мукой, а также имевший батрака, признан кулацким хозяйством.*

Алда санап үтелгән кайбер фамилияләр СССРдагы сәяси террор корбаннары исемлегендә дә бар. Мәсәлән, менә мондый мәгълүмат: «Халитов Зарип. Родился в 1881 г., Лаишевский р-н, с.Кирби; Проживал: Лаишевский р-н, с.Кирби. Приговорен: Лаишевский РИК 5 июля 1931 г., обв.: кулак. Приговор: высылка – Челябинская обл.. Реабилитирован 29 апреля 1993 г.»[1] Бу чыганакта Халитов Зариф 1881 елгы дип күрсәтелгән, ә 1932 елгы «Шәхси карточка»да, 48 яшьтә дип күрсәтелү (димәк, 1884 елгы) сәбәпле, аерма килеп чыкса да, бер үк кеше турында сүз баруына шикләнү урынсыз. Хәербидән кулак дип сөрелгән кеше шул бер – Халитов Зариф ул.

Ә менә Яруллин Хәйрулланың туган елы ике чыганакны чагыштырганда туры килә: «...Родился в 1874 г., Лаишевский р-н, д. Кирби; татарин; старатель на прииске. Проживал: Хабаровский кр., Ульчский р-н, прииск «Дяппе». Арестован 17 августа 1938 г. Приговорен: УНКВД Нижнеамурской обл. 7 февраля 1939 г., обв.: 58-10. Приговор: дело прекращено за недоказанностью обвинения».

СССРдагы сәяси террор корбаннары исемлегендә тагын бер шундый ук исем-фамилияле кеше бар: «Яруллин Хайрулла Яруллович. Родился в 1901 г., Лаишевский р-н, д. Кирби; татарин; колхозник.. Проживал: Лаишевский р-н, д.Кирби. Арестован 27 марта 1938 г. Приговорен: Судебной коллегией Верховного суда ТАССР 30 января 1939 г., обв.: 58-10 ч.1. («нецензурные высказывания в адрес руководства партии, правительства»). Приговор: 3 года лишения свободы, поражение прав на 2 года. Реабилитирован 4 июля 1990 г.».

Бу инде башка кеше. Беренче Яруллин Хәйрулла белән яшь аермалары да зур – 27 ел. Бу мисалдан зур татар авылы Хәербидә кайсы чорда да булдыклы һәм кыю кешеләр яшәгән, революциягә кадәр авылда Ярулла, Хәйрулла исемнәре популяр булган икән дип нәтиҗә ясарга мөмкин.

1 БД «Жертвы политического террора в СССР»; МВД Республики Татарстан.

## XII БҮЛЕК

## АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

Авыл җирендә яшәүчеләр өчен хакимият ул – иң элек авыл җирлеге советы. Авылда яшәүче һәр кеше ут-су, коммуникацияләр белән проблема килеп туса да, һәр төрле низаглар белән дә авыл советына мөрәҗәгать итә. Авыл советына, авыл җирлеге башлыгы янына юлларны төзекләндерү, яктырту, чүп-чарны чыгару, сукбай этләрдән арыну мәсьәләләре белән генә түгел, шикле кешеләр турында шикаятьләре белән дә киләләр. Әлбәттә инде халык монда хәлләренә керәчәкләренә, яхшы һәм кирәкле эшне бергәләп башкаруны оештырырга булышачакларына ышана. Хәерби авыл җирлегендә яшәүчеләр дә искәрмә түгел, алар да авыл советына мөрәҗәгать итә. Авыл җирлеге советының эше санап бетергесез күп. Мәсәлән, хәзерге вакытта үзара салым акчалары җыйнала, аларны юлларны карауга, урамнарны яктыртуга, яки башка уртак ихтыяҗларны канәгатьләндерүгә тотачаклар. Әлбәттә, бу бик мәшәкатьле эш. Аны тормышка ашыру барлык эшнең аз өлеше генә. Бигрәк тә бүгенге шартларда. Хәзер бит эшкә керешкәнче бик күп инстанцияләр аша үтәргә, документлар әзерләргә, тикшерүләр уздырырга, проект, планнар төзергә кирәк. Болар – «айсберг»ның күренми торган өлеше – вакытны күп ала, ләкин кеше күзенә чалынмый торган эшләр. Һәр кеше турында аерым кайгыртырга кирәк, авыл шул чакта гына сиңа йөзе белән борылачак. Кешеләр белән турыдан-туры эшләү четерекле, әмма бик кызыклы эш. Җирлектәгеләрнең байтагы пенсионерлар. Олылар яшь кеше тиз арада хәл итәрлек мәсьәлә алдында югалып кала. Хәерби авыл җирлеге башлыгы өчен мәсьәләнең зуры-кечкенәсе юк. Ул өйдә ут сүнде дип мөрәҗәгать итүгә дә, төнлә кайдадыр нәрсәнеңдер ватылуын яки янгын чыгуын хәбәр итеп шалтыратуларына да күнеккән инде. Шунда ук барысын да ачыклый, я телефоннан, я урынга барып хәл итә. Бер белмәгән кешенең күз алдына кем киләдер, ә Хәербидә авыл җирлеге башлыгы – гап-гади хатын-кыз! Ул – Минзәлия Дамир кызы Минбаева.



## БҮГЕНГЕ КӨН ҖИТӘКЧЕСЕ



**Минбаева Минзәлия Дамир кызы** 1965 елның 8 июнендә Лаеш районы Державино авылында туа. Мәктәпне тәмамлаганнан соң, Лаеш авыл хуҗалыгы техникумында укый, бухгалтер белгечлеге ала. 1983 елда Хәерби авылы совхозына терлекчелек буенча бухгалтер булып эшкә килә. Шунда эшләү дәверендә Илгизәр исемле егеткә кияүгә чыга. 1995–2001 елларда «Хәерби» совхозында бухгалтер, баш бухгалтер, район сәүдә палатасында сатучы була. 2001 елда Хәерби авыл советына депутат булып сайлана һәм авыл советы секретаре булып эшли. 2006 елда Хәерби авыл җирлеге башлыгы һәм авыл җирлеге башкарма комитеты рәисе итеп сайлана. 2002 һәм 2006 елларда Россия Дәүләт статистика комитетының «Бөтенроссия халык санын алуда актив катнашкан өчен» күкрәк билгесе, Мактау грамоталары, Рәхмәт хатлары белән бүләкләнә. Минзәлия ханым һәм Илгизәр Минбаевлар бер кыз һәм ике ул тәрбияләп үстерәләр. Алар да шушы авыл җирлегендә төпләнеп яшиләр. Кызлары Алсинә Гаязова (20.05.1986 туган) Хәерби авылының фельдшер-акушерлык пунктында шәфкать туташы булып эшли.


1


2


3


4

1–2. Гвардия һәм Бәхетле урамнары; 3. Балалар мәйданчыгы; 4. Зиратта өмә.

## ЭЛЕККЕГЕ ҖИТӘКЧЕЛӘР

**Сибиев Зиннәт Сибгатулла улы** 1892 елда Хәерби авылында туа. 1941–1943 елларда авыл советы рәисе. Шунда эшләгән җиреннән Зиннәт Сибиев 1943 елның октябрь аенда Бөек Ватан сугышына алына. Ул сугышта йөкче була. Великие Луки тирәсендә урман аркылы ат белән фронтка азык ташый. Немец гаскәрләре чигенгән вакытта аларның часте шул шәһәрдә калдырыла һәм 1946 елның октябрь аена кадәр шәһәрне торгызуда катнаша. Фронттан җибәргән хатларының берсендә ул, бәрелеш булыр алдыннан: «Без кара урманга җиләккә барабыз, теләктә торыгыз», – дип язган булган. З.Сибиев 1946 елның октябрь аенда, нәкъ 3 ел сугышып, исән-имин әйләнеп кайта.

**Минбаев Нури Миңнебай улы** 1924 елда Хәерби авылында туа. Бөек Ватан сугышы башлангач, 1941 елда аны окоп казырга җибәрәләр. Ул вакытта аңа бары 17 яшь кенә була. Шул кырыс сынауны узгач, 1942 елда Кызыл Армиягә алына. Берникадәр өйрәнүләрдән соң, 1942 елның көзендә, яшь солдатларны фронтка озаталар. Нури Минбаев каты бәрелешләрдә катнаша, дүрт тапкыр яралана. Соңгы ярасыннан соң, сугыш хәрәкәтләрендә катнашуга яраксыз саналып, Хәербигә әйләнеп кайта. Авылга кайткач, башта авыл советы секретаре, аннары 30 ел буе авыл советы рәисе булып эшли. Колхозның партия оешмасына җитәкчелек итә. Хатыны Зәкия апа белән алты бала тәрбияләп үстерәләр. Улы Фәрит «Хәерби» совхозында инженер (1982–1983), баш инженер (1985–1988), директор (1988–1990) булып эшли.



З.С.Сибиев.



Н.М.Минбаев.



Н.Х.Харисов.

**Харисов Нури (Нурмөхәммәт) Харис улы** 1933 елның 23 маенда туа. Хезмәт эшчәнлеген 1950 елда «Алга» колхозында башлап җибәрә. Татар авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институтының Үзәк эксперименталь базасында бригадир, «Хәерби» совхозында бригадир, техника куркынычсызлыгы инженеры була. 1978 елның ноябреннән 1984 елның февраленә кадәр авыл советы рәисе булып эшли. Соңрак, пенсиягә чыкканчы Дәүләт иминиятләштерү системасында хезмәт куя, Хәерби авыл советы каршында Госстрахның штаттан тыш агенты була. Хәзерге вакытта лаеклы ялда. Хатыны – Рауза Харисова совхоз бухгалтериясендә эшләп пенсиягә чыга. Алар 3 бала тәрбияләп үстергәннәр.

**Закиров Мингәрәй Мингали улы** 1951 елның 14 июнендә Хәерби авылында туа. 1978–1983 елларда зоотехник булып эшли. 1984–1988 елларда авыл советы рәисе. 1988–1991 елларда – «Алга» колхозы партоешмасы секретаре. 1991–2000 елларда Хәерби мәктәбендә хезмәт укытучысы.

**Галиев Илдус Гарифулла улы** 1947 елның 8 гыйнварында Әлки районының Алпар авылында туа. 1969 елда Хәербигә баш зоотехник итеп билгеләнә. 1987–1992 елларда Хәерби авыл советы рәисе.

**Вәлиуллин Якуп Вәлиулла улы** 1931 елның 2 сентябрендә Хәерби авылында туа. Хезмәт стажы 48 ел. Хәерби авылы кибетендә 30 ел сатучы булып эшли. Авыл советы рәисе вазифасын 1992–1995 елларда башкара. Мактау грамоталары, дипломнар белән бүләкләнә. Хезмәт ветераны.



М.М.Закиров.



Я.В.Вәлиуллин.



М.М.Гыймадиев.

**Гыймадиев Минзариф (Зариф) Минвәли улы** (1948–2017) Хәерби авылында туа. 1977–1981 елларда Үзәк эксперименталь базада, соңрак «Хәерби» совхозында баш инженер-механик, 1985 елдан химиялаштеру буенча агроном, 1990 елдан яшелчәчелек цехы башлыгы булып эшли. 1995–1999 елларда Хәерби авылы җирле үзидарә советы рәисе була. 1999–2008 елларда Хәерби мәктәбендә газ белән ягып җылыту эшендә.

**Ярмиева Илсөя Габдулла кызы** 1949 елның 15 сентябрендә Хәерби авылында туа. Яшелчә үстерү бригадасы бригадиры, 1990–1995 елларда Хәерби авыл советы рәисе урынбасары, 2001 елның апреленнән 2005 елның декабренә кадәр – рәисе. 1995–2001 дә Хәерби җирле үзидарә советы секретаре. 2000–2005 елларда Лаеш районының Хәерби җирле үзидарә советы депутаты итеп сайлана. Яшелчәчелектә һәм җирле үзидарә органнарында ирешкән уңышлары өчен Мактау грамоталары, Рәхмәт хатлары, медальләр белән бүләкләнә. Илсөя Габдулла кызы хезмәт ветераны. Лаеш районының Мактаулы гражданы.



И.Г.Ярмиева.



Благодарственное письмо

УВАЖАЕМАЯ ИЛЬСИЯ АБДУЛЛОВНА!

От имени Совета Лаишевского муниципального района выражаю Вам благодарность за большой личный вклад в развитие местного самоуправления.

Ваша принципиальная и результативная работа во имя интересов жителей снискали Вам заслуженное уважение и доверие.

Вы завоевали подлинный авторитет у населения, проявляя высокий профессионализм, надежность и трудолюбие.

Спасибо за Ваш труд, преданность и верность родному краю, за настойчивость в решении задач на благо Лаишевского района.

Желаю крепкого здоровья, благополучия Вам и Вашим близким.

Глава Лаишевского муниципального района А.П.Тимофеев

30.01.2006 г.



Илсөя Ярмиева бер ул — Ленарны тәрбияләп үстерә. Хәзерге вакытта килене Гөлназ, ике оныгы Эльвера һәм Радик белән Хәербидә яши. Лаеклы ялда булуга карамастан, авылның җәмәгать эшендә актив катнаша, «Ак калфак» фольклор ансамбле составында чыгышлар ясый.

# XIII БҮЛЕК

# МӘДӘНИЯТ ҺӘМ МӘГЪРИФӘТ

## МӘКТӘП

1934 елга кадәр Хәербидә башлангыч мәктәп кенә эшләп килә. 1934 елда 5 нче сыйныф ачыла һәм 1937 елда Хәерби җидееллык мәктәбенең беренче чыгарылышы була. Гарипова (Галиева) Фәүзия, Булатова (Галиева) Факиһә, Гаязов Мингали, Мингалиева Миңсылу, Мусин Исхак, Сафин Ибраһим һ.б. – беренче чыгарылыш укучыларыннан.

1961 елдан мәктәп – сигезьеллык, 1983 елдан урта мәктәп итеп үзгәртелә. 1985 елда Хәерби урта мәктәбе үзенең беренче чыгарылыш укучыларын тулы урта белем алу турындагы аттестат биреп, зур тормыш юлына озата. Бу вакытта мәктәп бинасы агачтан салынган һәм бер катлы була.

Авыл халкын, мәктәп укучыларын һәм укытучыларын сөендереп, 2003 елның 1 сентябренә мәктәпнең 162 укучыга исәпләнгән, типовой проект белән салынган ике катлы кирпеч бинасы сафка баса. Бинаның гомуми мәйданы 1495 м$^2$. Мәктәптәге 15 уку кабинеты, 60 укучы сыйдырышлы ашханә заманча җиһазландырылган. Мәктәп яны территориясендә спорт мәйданчыгы һәм укыту-тәҗрибә участогы бар.

2003 елдан Хәерби урта мәктәбенең директоры – Хурамшина Кадрия Кадыйровна, 2018 елдан директор булып Хәмәтгалиева Рузалия Зәки кызы эшли.



Мәктәп бинасы. 2019 ел.

## УКЫТУЧЫ – БӨЕК ИСЕМ!

Кешенең тормышта ирешкән уңышлары турында сөйләгәндә әти-әни белән янәшә куеп рәхмәт әйтелергә тиешле олуг зат бар. Ул – мөгаллим, укытучы, остаз. Һәрберебезнеке аерым алар, сурәтләре күңел түрендә йөри торган укытучыларыбыз. Алар, бала аңына белем сеңдергәндә, сиздермичә генә аның җанына тәрбия иңдерә, кешелеклелек, игелек орлыклары сала. Мөгаллимнәребез еш кына безнең барыр юлыбызны, димәк, язмышыбызны да билгели. Нинди генә мактау сүзләре әйтелмәсен, ул алар өчен аз. Хөрмәткә, мактауга үтә лаеклылар Хәербидә дә бар. Үз эшен җаны-тәне белән яратып башкаручылар, булган көчләрен, вакытларын кызганмый, алны-ялны белми эшләүчеләр белән данлыклы ул. Түбәндәге сәхифәдә Хәерби мәктәбендә эшләгән кайбер укытучылар турында мәгълүмат бирелер. Әүвәлрәк эшләгәннәрен, Хәерби мәктәбендә кабул ителгәнчә, «апа», «абый» дип тәкъдим итәрбез.

**Мәрзия Вафа кызы Вафина** 1921 елның 12 апрелендә Лаеш районы Татар Сараланы авылында туа. Саралан мәктәбендә, Казан һәм Чистай педагогия училищеларында укый. Саралан мәктәбендә яхшы укыганы өчен аны, үз



сыйныфын сикертеп, ике тапкыр алдагы сыйныфка күчерәләр. Шунлык белән ул мәктәпне яшьтәшләреннән ике елга алдан тәмамлап чыга. Әмма кызны, яше кечкенә дип, педагогия училищесына алмыйлар. Шуңа күрә аңа абыйсы, туган елын ике елга алга күчереп, 1919 елгы дип үзгәртеп документ ясап бирергә булыша. Чистай педагогия училищесын тәмамлап (1935–1938) Хәербигә укытучы булып килгәндә Мәрзияга документ буенча – 19, ә чынлыкта 17 яшь була. Шулай итеп, 1938 елның 15 августында Мәрзия Вафинаның хезмәт юлы башлана. Хәербигә килүгә аны башлангыч сыйныфлар укытучысы итеп куялар, шул ук вакытта өлкән пионервожатый эшен дә йөклиләр. Мәрзия Вафовна Хәерби мәктәбендә 1977 елга кадәр эшли. Аның укучылары арасында кемнәр генә юк: укытучылар, врачлар, инженерлар, төзүчеләр һ.б. Бик күпләр алар. Араларында фән кандидатлары да шактый.

Сугыш елларында (1942 елның 15 мартыннан 1945 елга кадәр) Мәрзия апа мәктәп директоры булып эшли. 1945 елның 21 декабреннән уку-укыту бүлеге мөдире вазифаларын башкара. 1945 елдан – Коммунистлар партиясе әгъзасы.



Мәрзия Вафина 1 сыйныф укучылары белән. 1965 ел.

Мәрзия апа Вафина Хабул абый Нигъмәтов белән 6 бала тәрбияләп үстерәләр. Ире үлгәндә төпчек баларына әле 7 генә яшь була. Балаларны үстереп тормыш юлына бастыру Мәрзия апа өстенә кала. Ул бу сынауны да ныклык белән уза. Мәрзия Вафа кызы 6 бала үстергән өчен II һәм I дәрәҗә Ана медале белән бүләкләнә. Зур гаиләнең – 6 бала, 3 килен, 3 кияү, 9 онык, 10 балаларының оныгы – кадерле кешесе булып олыгая. Мәрзия Вафа кызы Вафина 2006 елның 26 февралендә вафат була. Хәерби авылында җирләнгән.

Балалары: **Кушмина Роза** (1947 елда туган, Хәерби мәктәбендә татар теле укытучысы), **Нигъмәтов Булат** (1948–2014, «Хәерби» совхозы электригы), **Зиннәтуллина Гөлнара** (1952 елда туган, Татарстан телевидениесе режиссёры, редакторы, алып баручысы, ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре), **Галимуллина Гөлшат** (1953 елда туган, ЭВМ заводы инженер-конструкторы, хәзерге вакытта Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясенең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрә-



М. Вафина кызы Гөлшат һәм оныклары Алсу, Фәридә, Илдар, Наил, Гөлназ белән.

нү институтында өлкән фәнни хезмәткәр. Күп кенә фәнни хезмәтләр һәм «Физическая наука в Татарстане (1804–2000-е гг.)» монографиясе авторы), **Нигъмәтов Ринат** (1955–2005; Казанның «Мостострой» предприятиесендә механик, электрик булып эшли. Автомобильләр электрикасы һәм электроникасы буенча белгеч), **Нигъмәтов Айрат** (1960 елда туган, зур йөк автомобильләре йөртүче, механик, автомобильләр электрикасы һәм электроникасы буенча белгеч).



**Галия Гарифулла кызы Гарифуллина** 1915 елда Алексеевский районы Олы Тигәнәле авылында туа. Казан һәм Чистай педагогия училищеларында укый. Аның ире – Мәҗит Әхмәт улы Әхмәтшин да шул ук авылдан. Яшь гаилә Хәербигә килеп эшли башлый: Мәҗит абый – мәктәп директоры, ә Галия апа – башлангыч сыйныфлар укытучысы була. Гаиләдә кыз бала туа. Мәҗит Әхмәт улын сугышның беренче көннәреннән үк фронтка алалар. Сугыштан соң ул кабат Хәербигә әйләнеп кайта, тик тормыш хәлләре үзгәрү сәбәпле, Хәербидән китәргә мәҗбүр була. Алга таба Зеленодольск районында укытучы булып эшли.

Галия апа лаеклы ялга чыкканчы Хәерби мәктәбендә белем бирә. Ул авылда яңа гаилә кора. Бу гаиләдә улы Нил туа.

**Галләм Кашшаф улы Кашапов** 1917 елда Лаеш районы Саралан авылында туа. Саралан урта мәктәбен, яхшы билгеләргә генә укыганга күрә, вакытыннан алда экстерн рәвешендә тәмамлый. Укытучы булырга укый һәм РСФСР Халык мәгарифе комиссариатының башлангыч класслар укытучысы аттестатын ала (1939). Шуннан соң ул Хәерби җидееллык мәктәбенә укытырга килә. 1942–1945 елларда Бөек Ватан сугышында катнаша, туган якка 1946 елда әйләнеп кайта. II дәрәҗә Ватан сугышы ордены, «Батырлык өчен» (1944), «Сугышчан хезмәтләре өчен» (1945) медальләре белән бүләкләнә.



Г.Кашапов 1а сыйныф укучылары белән. 1947 ел.


Народный Комиссариат Просвещения
СВИДЕТЕЛЬСТВО
1


Российская Социалистическая Федеративная Советская Республика
Народный Комиссариат Просвещения РСФСР
АТТЕСТАТ
на звание учителя начальной школы
звания учителя начальной школы
2




1. Мәктәпне алдан тәмамлау турында документ; 2. Башлангыч классlar укытучысы булуын раслаучы документ; 3. Бөек Ватан сугышы ветераны Г.К.Кашапов.

Сугыштан кайткач, Хәерби мәктәбендә укытучы булып эшли. Хатыны – Мөнәвәрә апа. Бер уллары – Илдар Кашапов, армия хезмәтен үтәгәндә һәлак була. Галләм абый 1990 елның 14 июнендә вафат.

**Хәтирә Зиннәт кызы Сибиева** 1926 елның 22 февралендә Хәерби авылында туа. Мәктәпне тәмамлагач, педагогика училищесында укый, әмма гаилә хәле буенча соңгы елын укып бетерә алмый. 1943–1952 елларда башлангыч сыйныфлар укытучысы. Аннары китапханәче булып һәм колхозда төрле эшләрдә эшли. Хезмәт ветераны.



Хәтирә апаның ире – Минвәли Галәветдин улы Галәвов, 1928 елның 15 маенда Хәерби авылында туган. Бөгелмәдә укып, инспектор булып кайта. Столбищеда Район финанс бүлеге инспекторы, Сокуры авылы сельпосында экспедитор, Хәербидә бригадир, комбайнчы ярдәмчесе, совхозда экспедитор булып эшли. Хәтирә апа белән Минвәли абый 4 бала тәрбияләп үстерәләр: Фирдәвес, Флюра, Фирая, Мингали.

**Елизавета Николаевна Чернова** Мамадыш районы Усали авылында туа. Аның укучысы, Хәерби авылы кызы, хәзерге вакытта Баку шәһәрендә яшәүче Рәмзия Абдуллина-Мирзалиева беренче укытучысы турында үзенең истәлекләрен язып җибәрде:

«Мин 1979 елда беренче сыйныфка укырга кердем. Беренче укытучым, мәктәп бусагасын беренче тапкыр атлап кергәндә аның көләч йөз, ягымлы караш белән каршы алуы әле дә күз алдымда.

Укытучыбыз берьюлы ике сыйныф балаларына белем бирә иде. Саныбыз аз булмагандыр дип уйлыйм. Беренче һәм өченче сыйныфлар бер бүлмәдә бергә укыдык. Һәр партада өчәр бала утыра идек. Лиза апа башта өченче сыйныф укучыларына дәрес аңлата һәм язма эш бирә, аннары безгә, беренче сыйныф балаларына чират җитә иде. Тып-тын калып тыңлый идек укытучы апабызны. Шул хәтле балага белем бирергә ничек өлгергәндер ул, белмим.

Чернова Елизавета Николаевна – сугыш ветераны, сугышчан бүләкләргә ия булган укытучы. Әле дә хәтеремдә – өстендә озын җиңле ак кофта, кара сарафан. Күкрәгендә медальләр. Бик пөхтә, сабыр, таләпчән иде укытучыбыз, үз эшен, балаларны бик ярата иде.



Е.Н.Чернова үз сыйныфы укучылары белән.

Кызганычка каршы, миндә бер генә дә фотосы юк, фотограф килгәндә дә төшми иде Лиза апа: «Балалар, мин өлкән кеше, сурәткә төшәргә дә яратмыйм, әйдәгез, сез төшегез» – дип, безне тезеп бастыра иде.

Минем әтинең бертуган апасы вакытсыз вафат булды. Җизнәбез Ибрай абый безнең укытучыбыз Лиза апага өйләнде. Без өченче сыйныфны укып тәмамлаган 1981 елда алар Казанга, Дербышки поселогына күчеп киттеләр.

Ничәнчедә укыган чагым булгандыр, Ибрай абый вафат булып, аны авылга алып кайтып җирләделәр. Әтигә ияреп, мин дә зиратка бардым, чөнки укытучы апамны бик күрәсем килә иде. Лиза апабыз белән исәнләштем, үсеп, үзгәреп киткәнмендер, ул мине тиз генә танымады. Соңыннан бик озак сөйләшеп тордык, шул вакыттан бирле беренче укытучыбызны күргәнем булмады. Аның Ринат исемле улы бар иде. Мин әтигә ияреп Лиза апаларга бакча сукаларга бара идем. Классташларым белән җыелып бәрәңге алышырга, утын ташышырга менә идек. Укытучы апабыз безне чәй эчерми җибәрми иде. Без аның туган көне кайчан икәнен дә белмәдек: «Минем туган көн юк, балалар», – диеп елмая иде ул. Истә, дәрес вакытында йөрәк даруы эчә иде...»



1


2


3



4


5


6

1. 3б сыйныфы укучылары. 1947 ел; 2. Укытучылар Суфия Җамалетдинова, Мәрзия Вафина, Галина Мухина-Вафина укучылары белән; 3. Укытучылар. Утырганнар: Әминә Рәхмәтуллина, Зариф Галиев (директор), Суфия Җамалетдинова, Галләм Кашапов. Басканнар: Мәрзия Вафина, Галия Гарифуллина, Лера Сәйфуллина, Галина Мухина-Вафина, Хәйдәр Сафин; 4. Укытучы Әминә Рәхмәтуллина 1 сыйныф укучылары белән. 1955 ел; 5. 7 сыйныф укучылары. 1962 ел; 6. Укытучы Талип абый Даутов белән Бөреледәге җәнлек совхозына экскурсиягә баргач. 1958/59 уку елы.



1



2



3



4



5



6

1. Укытучы Мәрзия Вафина 1 а сыйныфы укучылары белән. 1956 ел; 2. Иске мәктәп бинасы. 1960 еллар башы; 3. Укытучылар. Беренче рәттә: (исеме билгесез) Секаева, Мәрзия Вафина. Икенче рәттә: Хабул Нигъмәтов, Риза Секаев (директор), Зариф Галиев, Габдрахман Ризванов, Габдулла Амиль. Өченче рәттә: Әминә Рәхмәтуллина, Хәфәзә Нуретдинова, Галия Гарифуллина, Хәтирә Сибиева, Чәчәк Сабирова; 4. Укытучы Әминә Рәхмәтуллина үзенең укучылары белән. 1950 еллар башы; 5. Укытучылар. 1960 еллар башы; 6. Укытучы Рәүф Закиров 5 сыйныф укучылары белән. 1966 ел.



1



2



3



4



5



6



7

1. 7 сыйныф укучылары. 1951 ел, 15 февраль; 2. Лера Сәйфуллина укучылары белән. 1950 еллар ахыры; 3. Укучылар. 1972 ел; 4. Мәктәп ишегалдында. Укытучылар: Гөлйөзем Нигъмәтҗанова, Илнура Галиева, Роза Нигъмәтова. 1966 ел, октябрь; 5. Укытучы Әминә Рәхмәтуллина. 6. Укытучы Гөлшат Кәлимуллина; 7. Роза Нигъмәтова, Рәүф Закиров.


1


2


3


4


5


6

1. Т.Мозаффарова һәм Р.Нигъмәтова; 2. Рушания Хуҗиева һәм укучылар: Равил Ногманов, Гүзәлия Сафина, Рамил Сафин, Нажия Ногманова, Илгизәр Сафин; 3. Укытучылар. Утырганнар: Р.Закирова, Г.Фәтхуллина, Л.Сәйфуллина, Фәрдия Гарипова, Д.Харисова, Фәридә Гарипова. Басканнар: Р.Вагизов, Р.Вагизова, Р.Хәсәнов, С. Сәмигуллина, Ф.Бәширова, М.Гатауллин, В.Егоров, В.Хәйбуллина, М.Хәйбуллин. 1987 ел; 4–5. Укытучылар. 1990 еллар башы; 6. С.М.Гайнетдинова үзенең укучылары белән

**Сания Мирзахәсән кызы Гайнетдинова** 1946 елның 19 ноябрендә Лаеш районы Сиңгел авылында туа. Әтисе Мирзахәсән абый Сталин исемендәге колхозда хисапчы, әнисе Таифә апа колхозчы була. Татар Сараланы авылында урта мәктәпне тәмамлагач, Сания апа Казан дәүләт педагогия институтының тарих-филология факультетына укырга керә. Институттан соң Хәерби сигезьеллык мәктәбенә тарих фәне укытырга җибәрелә. Бу мәктәптә 12 ел укыту дәверендә уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары булып та, соңрак директор булып та эшли. Ул укыту-тәрбия эшенең нәтиҗәлелеген үстерүгә зур игътибар бирә. Бу чорда уку йортларына керүчеләр саны арта. Укучыларның төрле юнәлештәге конкурсларда катнашуы да, укыту-тәҗрибә участогындагы эшчәнлек тә активлаша.



**Зәйтүнә Хабул кызы Насыйбуллина (Ибраһимова)** 1944 елның 10 июнендә туа. Татар Сараланы авылында урта мәктәпне тәмамлагач, Сиңгел һәм Татар Кабаны авылы мәктәпләрендә берәр ел башлангыч сыйныф укытучысы булып эшли. Җирле җитәкчеләр Зәйтүнәне "Комсомол" совхозына комсомол секретаре итеп куялар. Анда бер ел эшләгәч, яңадан Татар Кабаны мәктәбенә сорап кайтаралар. 1968 елда Хәерби сигезьеллык мәктәбенә эшкә җибәрәләр. Шул елларда читтән торып Казан педагогия институтында югары белем ала. Хәербидә башта башлангыч сыйныф, аннары өлкән сыйныфларда татар теле һәм әдәбияты укытучысы була. 1976 елда гаиләсе белән Казанга күченеп китә. 43 ел педагоглык стажы бар. Хәерби авылы егете Мөхәммәт Насыйбуллин белән гаилә корып, ике кыз – Алсу һәм Айсылуны тәрбияләп үстерәләр; 4 оныклары бар.



**Илсур Ислам улы Хуҗиев** 1946 елда туа. Аның хезмәт биографиясен ике өлешкә бүлергә була. Аның беренче өлеше мәктәп, мәгариф белән бәйле. Ул Арча педучилищесында, аннары читтән торып Казан дәүләт педагогия институтында укый. Арча районы (хәзер Әтнә районы) Комыргуҗа мәктәбендә математика укыта, Лаеш районының Хәерби мәктәбендә башта директор урынбасары, аннары директор булып эшли. 1972–1973 елларда армиядә хезмәт иткәннән соң, яңадан Хәербигә әйләнеп кайта. Әмма аны, яраткан хезмәтен

тыныч кына башкарудан аерып, башка эшкә кыстый башлыйлар. Укытучы эшен бик нык яраткан Илсур Хуҗиевның һөнәрен алыштырасы килми. Җирле



җитәкчеләр белән араны бозмыйча гына, ул Биектау районына юллама ала. Тормыш иптәше Рушания белән башта Суыксу мәктәбендә, аннан Дөбъяз мәктәбендә эшлиләр.

Язмыштан узмыш юк, дигәндәй, 1980 елда Хуҗиевка педагог хезмәтен барыбер алыштырырга туры килә – аны партиянең Биектау райкомы идеология бүлегенә мөдир итеп күчерәләр. Хезмәт баскычыннан югары күтәрелеп, ул төрле елларда оештыру бүлеге мөдире, партия райкомының II секретаре, Халык депутатларының район Советы башкарма комитеты рәисе урынбасары һәм үндүрт ел буе – 1991 елдан 2005 елга кадәр – район хакимияте башлыгы урынбасары булып эшли. Шулай итеп, ул чирек гасырга якын гомерен шәһәр яны районындагы җаваплы хезмәткә багышлый. Озак еллык нәтиҗәле эшчәнлеген бәяләп, Илсур Ислам улына Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре исеме бирелә. Ул шулай ук «Казанның 1000 еллыгы» медале, Татарстан Республикасының Мактау грамотасы белән бүләкләнә. Илсур Ислам улы Хуҗиев 2010 елның 16 декабрендә вафат.



Укытучылар мәктәп бакчасында. 1960 еллар ахыры.


1


2


3


4


5


6

1. 1989 елгы чыгарылыш укучылары укытучы Роза Кушмина белән; 2. Укытучы Фәридә Гарипова үзенең укучылары белән; 3. 1969 елгы чыгарылыш укучылары сыйныфташлар очрашуында: Илнура Вафина, Зәлфирә Мөбарәкшина, Даһия Ногманова, Мингали Галиев, Асия Миңнуллина, Тәнзилә Әхмәтшина, Гөлшат Нигъмәтова, Фирая Галәвова; 4. 1978 елгы чыгарылыш укучылары сыйныфташлар очрашуында; 5. Укытучы Р.Кушмина үзенең укучылары белән; 6. 1969 ел. 8 «а» классы кызлары: Фәнүзә, Зәлфирә, Гөлира, Асия, Ризәлә, Миннебикә, Даһия, Илнура, Тәнзилә, Фирая класс җитәкчеләре Фәридә Бикмуллина белән.


1


2


3


4


5


6

1. Укытучы В.Хәйбуллина өлкән сыйныф укучылары белән. 1985 ел; 2. Хезмәт дәресендә. Укытучы – В.Хәйбуллина. 1980 еллар ахыры; 3. 1985 елгы чыгарылыш укучылары. Утырганнар: Л.Садыйкова, Г.Минвәлиева, Р.Кушмина (укытучы), И.Закиров, Ф.Минбаева. Артта басканнар: Р.Харисов, И.Булатов, Р.Нуриев, А.Рәхмәтуллин, Н.Хәмәтгалиев; 4. Укытучылар – Фәридә Гарипова, Фәрдия Гарипова, Д.Харисова һәм укучылар. 1985 ел; 5. Укытучы Р.Кушмина һәм укучылар. 1990 ел; 6. Өлкән класс укучылары һәм укытучылар: В.Егоров, Ф.Шәрифуллин, Ф.Гаязов, Г.Закиров, М.Хәйбуллин. 1990 еллар башы.

**Әминә Галим кызы Шакирова** 1946 елның 30 июнендә Лаеш районының Татар Сараланы авылында Галим Шакир улы һәм Хәбибҗамал Сафиулла кызы гаиләсендә туа. Саралан урта мәктәбен тәмамлагач, Казан педагогия училищесында (1965–1968), Казан дәүләт педагогия институтының физика һәм математика факультетында (1971–76) укый. Хезмәт эшчәнлеген Биектау районының Элә Казаклары авылы мәктәбендә башлап җибәрә, башлангыч сыйныфларында укыта. 1971–1984 елларда Хәерби авылында математика фәненнән белем бирә, бик күп еллар уку-укыту бүлеге мөдире була. 1984–1993 елларда Казан шәһәренең 35 нче мәктәбендә (соңрак 1 нче гимназия), 1993–2010 елларда 85 нче мәктәптә математика һәм башлангыч сыйныф укытучысы булып эшли. Хәзерге вакытта лаеклы ялда.



**Роза Хабул кызы Кушмина** 1947 елның 11 апрелендә Хәерби авылында туа. Хәерби мәктәбен тәмамлагач, Татар Сараланы урта мәктәбендә укый. 1964 елда Хәерби сигезьеллык мәктәбендә өлкән пионервожатый булып эшли башлый. 1971 һәм 1973 елларда ВЛКСМ ҮКның «Иң яхшы пионервожатыена» күкрәк билгесе белән бүләкләнә.



1978 елда Казан педагогия институтын тәмамлый. Хәерби урта мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшли. «Өлкән укытучы», «Укытучы-методист», «Әйдәп баручы укытучы» исемнәре ала. Россия Федерациясенең «Халык мәгарифе отличнигы» (1994). Бик күп Рәхмәт хатлары, Мактау грамоталары бар аның. Хезмәт стажы – 41 ел.

«Укытучы булып туарга кирәк» – диләр. Роза Хабул кызы, чынлап та, бу дөньяга укытучы булып эшләр өчен тугандыр. Әти-әнисе дә шушы профессия кешеләре аның. Урта мәктәпне тәмамлагач ук, Хәерби мәктәбе директоры Зариф Галиев Роза Нигъмәтованы, район мәгариф бүлегенә хат язып, өлкән пионервожатый итеп соратып ала. Роза Хабуловнада бу хат әлегәчә саклана. Ул пионервожатый булып эшли башлагач, авылның пионер тормышында яңа, җанлы тормыш башлана. Роза оешмага яңа сулыш өргән кебек була: 1966 елда җәйге пионерлагерь оештырыла, район һәм республика күләмендәге форумнарда, пионер слётларында даими катнаша башлый-


Әкидә Гарифулловна!
Безнең үзебез дә пионер вожатыебыз
Казанга күчкәннән бирле вожатыебыз юк.
Вакытлыча рәвештә библиотекарь алып барды
Безгә Саралан урта мәктәбен бетергән
Нигматова [illegible] белдерә.
Эшкә сәләтле, [illegible], җитезлеге бар
шуның өчен, аны безнең мәктәпкә өлкән
пионер вожатые итеп билгеләвегезне со[illegible]
8/X 64 ел. Сәләм белән: [illegible] 1. Галее[illegible]

Район мәгариф бүлегенә язылган хат.

лар, «Аҗаган» хәрби-патриотик уены, «Дружина байрагын эзлә» һәм башка төрле уеннар уздырылып тора. Балалар аңа магнитка тартылган кебек тартылалар. Бу турыда күпсанлы фотосурәтләр сөйли.

Роза Хабуловна татар теле һәм әдәбияты укытучысы буларак, балаларда туган телгә, халкыбызның гореф-гадәтләренә мәхәббәт тәрбияли. Иң күп укучы ул алып бара торган «Яшь әдәбиятчы» түгәрәгенә йөри. Кайларга гына алып бармый аларны Роза апалары! Татар театрларында, атаклы кешеләр белән очрашуларда, Татарстан телевидениесендә, матбугат йортында да була укучылар. Авыл баласы өчен болар гомергә онытылмас вакыйга!

Хәерби авылы кешеләренең иң истә калганы – Роза Хабул кызы оештырган «Солдат хатлары» бәйрәме. Аны ел саен 23 февральгә атап уздыралар. Балалар белән әзерлек көздән үк башлана: армия хезмәтен үтәүче солдатларның адресларын барлау, аларга хатлар язу, җавапларын көтеп алу, солдатларның әти-әниләренә багышлап сораган җырларын өйрәнү. Ул көнне авыл клубы кеше белән шыгырым тула, һәр гаиләдә бу көнне көтеп алалар. Кичә үзе бер көнлек бәйрәм булса, аны кайтып-кайтып искә төшереп сөйләшүләр, солдат егетләргә бәйрәм рухын чагылдырган хатлар китү – менә шулар барысы да авылның җанын җилкендереп тора, тормышка ямь кертә.


1


2

1. Роза Кушмина кызы Гөлназ белән; 2. Туган як кырларында.







Роза Кушмина үзенең укучылары белән Казан телестудиясендә:
1. «Без авылда яшибез» тапшыруында. Редактор һәм алып баручы Гөлнара Зиннәтуллина һәм режиссер Камил Зәйнуллин белән; 2. «Ялкын» журналы хезмәткәрләре белән очрашу тапшыруында.

Хәзерге көндә Роза Кушмина лаеклы ялда, ләкин тик кенә яту турында уйламый да. Ул Хәерби авылы Ветераннар советы һәм «Ак калфак» җирле вокаль ансамбле белән җитәкчелек итә. Буш вакытында чигү чигә, оныклары Мәдинә белән Нәргизәне үстерешә.

Шушы урында Хәербидә аерым хөрмәткә ия булган бу ханымның тагын бер игелекле эшен әйтү зарур. Ул – гомере буе авыл, район, тирә-якның тарихын өйрәнеп, шуны җәмәгатьчелеккә җиткерә барган туган якны өйрәнүче, шушы өлкәдә тирән белем һәм тәҗрибә туплаган белгеч. Бу китапны язганда да Роза Хабуловна бөртекләп җыйган мәгълүматлар күп керде, аннан алынган фотолар да кулланылды. Без аның киңәшләренә таяндык. Барысы өчен дә рәхмәт аңа.

**Кадрия Кадыйр кызы Хурамшина (Вафина)** 1961 елның 30 мартында Лаеш районы Хәерби авылында колхозчы гаиләсендә туа. Башлангыч белемне авыл мәктәбендә ала. 6 сыйныфтан башлап Казан шәһәренең 10 нчы интернат-мәктәбендә укый. Мәктәпне тәмамлаганнан соң, Казан дәүләт педагогия институтында укып, татар теле һәм әдәбияты, рус теле һәм әдәбияты укытучысы белгечлеге ала. Диплом алганнан соң, ире белән Башкортстан Республикасының Ярмәкәй районында яши. Татар теле һәм әдәбияты, рус теле һәм әдәбияты предметларын укыта. 1997 елда Башкортстан Республикасының Мактау грамотасы белән бүләкләнә. 2001 елдан башлап Хәербидә рус теле һәм әдәбияты укыта, 2003–2018 елларда мәктәп директоры. Педагоглык ста-

жы – 36 ел. ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы (2007), РФ Мәгариф министрлыгы (2009) Мактау грамоталары, ««Казан шәһәрендәге 2013 елгы XXVII Бөтендөнья җәйге универсиада» медале белән бүләкләнә. 2013 елда Республика



күләмендә оештырылган «Иң яхшы мәктәп директоры» конкурсында җиңеп, Татарстан Республикасы грантын ота. Шул ук елда Россия күләмендәге шундый ук конкурста сертификатка лаек була. 2015 елда М.Җәлилнең 110 еллыгына багышланган медаль белән бүләкләнә.

Кадрия Кадыйр кызы җитәкче булып яңа мәктәпкә килсә дә, нәкъ шул яңа булуы белән анда эш хисапсыз күп була: мәктәп бакчасына нигез салына, агачлар утыртыла һ.б. ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы оештырган конкурста катнашып, грант оталар. Грант акчасына теплица, мотоблок алына. Мәктәп үзенә җитәрлек азык-төлек әзерли, артыгын сатуга чыгара башлый. Сатудан җыелган акча көндәлек төзәтү-ремонт эшләренә, балаларны бүләкләүгә, төрле чараларга тотыла. Кадрия Кадыйр кызы мәктәпне җитәкләгән дәвердә Актлар залы заманча итеп бизәлә, бик күп спорт инвентаре алына. Спонсорлар белән берлектә газ белән җылыту системасы куела. Мәктәптә Сугышчан дан һәм Хәрби-Диңгез Флоты музее булдырыла.

**Фәнзия Мөдир кызы Габдрахманова**, 1962 елда Буа районы Әхмәт авылында туа. Буа районы Чәчкаб урта мәктәбен (1979), Казан дәүләт педагогика



институтының физика һәм математика факультетын (1984) тәмамлый. Шул ук елны Хәерби мәктәбенә эшкә килә һәм 34 ел математика укыта, 22 ел уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары булып эшли. Югары категорияле укытучы. Үзенең фәнен һәм укучыларын бик ярата, алар конкурсларда һәм олимпиадаларда җиңүләр яулыйлар. Фәнзия Мөдир кызының бүләкләре: СССР Мәгариф министрлыгы Мактау грамотасы (1990); «Мәгариф өлкәсендәге казанышлары өчен» билгесе (2006); Бердәм дәүләт имтиханнарына әзерләүдәге уңышлары өчен РФ Мәгариф министрлыгы Мактау грамотасы (2009); «Иң яхшы укытучы» грантлары иясе (2011, 2012, 2013); Лаеш районы буенча табигыять-фән номинациясендә катнашып, «Иң яхшы дәресем» конкурсы җиңүчесе (2013); ТРның Лаеш районы Мәгариф бүлегенең Рәхмәт хаты (2013).



**Фәим Фәйзрахман улы Габдрахманов**, 1960 елда Лаеш районы Кече Елга авылында туа. Шул авылның Кече Елга урта мәктәбен (1978), Лаеш авыл хуҗалыгы техникумын (1979) тәмамлый. 1980–1981 елларда армия сафларында хезмәт итә. Казан дәүләт педагогика институтының география факультетын тәмамлый (1986). Әлки районының Яңа Салман авылында география һәм биология укыта (1986–1989).

1989 елда Хәерби урта мәктәбе директоры итеп билгеләнә. 2 ел директор, 11 ел уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары була, информатика һәм география фәннәрен укыта. Педагоглык стажы – 33 ел. Бүләкләре: ТР Лаеш районы Мәгариф бүлегенең Мактау грамотасы (2014).

## БҮГЕНГЕ КӨН ҖИТӘКЧЕСЕ

**Рузалия Зәки кызы Хәмәтгалиева** – беренче категорияле башлангыч сыйныфлар укытучысы, педагоглык стажы – 27 ел. 2017 елдан тәрбия эшләре буенча директор урынбасары, 2018 дән – Хәерби мәктәбе директоры. Бүләкләре: Лаеш районы буенча «Иң яхшы дәресем» конкурсында «Башлангыч мәктәп» номинациясендә икенче урын; «Иң яхшы укытучы» гранты иясе, «Ел укытучысы–2010» конкурсы номинанты; «Ел укытучысы–2017» конкурсында өченче урын, Лаеш муниципаль районы хакимияте башлыгының Рәхмәт хаты (2018), РФ Үзәк сайлау комиссиясе председателе Э.А.Памфилованың Рәхмәт хаты (2018) һ.б.





Рузалия Хәмәтгалиеваның ике улы бар. Бабасы Габдулла, әтисе Зәки һәм абыйсы Айрат Галиевлар – авылда зур ихтирамга ия булган мал табиплары.

Үзе эшләгән укытучылар коллективы да, укучылар һәм әти-әниләр дә аны ихтирам итәләр.

## БҮГЕНГЕ КӨН УКЫТУЧЫЛАРЫ

**Рөстәм Садри (Миңнебай) улы Хәсәнов** 1962 елда Хәерби авылында туа, Тормыш иминлеге нигезләре (ОБЖ) укытучысы, педагоглык стажы – 34 ел. Бүләкләре: ТРның Лаеш районы Мәгариф бүлеге Мактау грамотасы (2005); Лаеш районы Хәрби комиссариаты Мактау грамотасы (2006); Лаеш районы ЮХИДИ Мактау грамотасы (2007, 2008, 2009, 2010, 2011, 2012, 2013); Татарстан Республикасының Мактау грамотасы (2007); ТР Дәүләт Советының Рәхмәт хаты (2007); ТР Диңгезчеләр җыены Мактау грамотасы (2009); «Ел укытучысы–2013» конкурсы җиңүчесе; Лаеш районы Мәгариф идарәсенең Рәхмәт хаты (2014) һ.б.

**Фәрит Ибраһим улы Гаязов**, 1970 елда Хәерби авылында туа, югары категорияле физкультура укытучысы. Педагоглык стажы – 32 ел. Бүләкләре: «Аргамак» спорт уеннарында актив катнашканы өчен ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы Мактау грамотасы (2001); Лаеш районы Мәгариф бүлеге Мактау грамотасы (2005); Югары дәрәҗәдәге спортчылар әзерләгән өчен Лаеш районы хакимияте Мактау грамотасы (2010); ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы Мактау грамотасы (2011); Лаеш муниципаль районы хакимияте башлыгының Рәхмәт хаты (2012, 2014, 2015); ТР Милли көрәш федерациясенең Рәхмәт хаты (2014); «ТРның физик культура һәм спорт отличнигы» билгесе (2017) һ.б.

**Миләүшә Мансур кызы Галиева** 1963 елда Яшел Үзән районы Олы Шырдан авылында туа, беренче категорияле рус теле һәм әдәбияты укытучысы. Педагоглык стажы – 30 ел. Бүләкләре: ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы Мактау грамотасы (2005); Лаеш районы Мәгариф бүлеге Мактау грамотасы (2002, 2009); Укучыларны Бердәм дәүләт имтиханнарына әзерләүдәге нәтиҗәле хезмәте өчен Лаеш муниципаль районы хакимияте башлыгының Мактау грамотасы (2016); Рус теле буенча сәләтле балаларны сайлап алу һәм аларга булышудагы хезмәтләре өчен ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Рәхмәт хаты (2017) һ.б.

**Фәрит Мәхмүт улы Шәрифуллин** 1967 елда Саба районының Татар Икшермәсе авылында туа, беренче категорияле биология һәм химия укытучысы. Педагоглык стажы – 27 ел. Бүләкләре: «Иң яхшы укытучы» гранты (2011) һ.б.

**Гүзәл Ринат кызы Шәрифуллина** 1972 елда Актаныш районы Актаныш авылында туа, тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы. Педагоглык стажы – 27 ел. Бүләкләре: Татарстан Республикасының Мактау грамотасы (2011) һ.б.

**Рузилә Минвәли кызы Закирова** 1967 елда Хәерби авылында туа, беренче категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы. Педагоглык стажы – 24 ел. Бүләкләре: «Иң яхшы укытучы» гранты (2011) һ.б.

**Фирдәүсә Якуп кызы Хәмидуллина** 1971 елда Хәерби авылында туа, беренче категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы (2003–2014 елларда). Бүләкләре: ТР Лаеш районы Мәгариф идарәсе Мактау грамотасы (2014) һ.б.

**Резеда Марат кызы Вафина** 1969 елда Лаеш районы Сиңгел авылында туа, башлангыч сыйныф укытучысы. Педагоглык стажы – 26 ел.

**Ләйлә Зариф кызы Сафина** 1978 елда Хәерби авылында туа, беренче категорияле башлангыч сыйныфлар укытучысы. Педагоглык стажы – 22 ел. Бүләкләре: «Ел укытучысы–2009» конкурсы номинанты; ТР Лаеш районы Мәгариф идарәсе Мактау грамотасы (2014).

**Илмира Минвәли кызы Коркина** 1983 елда Хәерби авылында туа, инглиз теле укытучысы, педагоглык стажы – 16 ел.

**Луиза Илгизәр кызы Рәхмәтуллина** 1978 елда Лаеш районы 25 Октябрь исемендәге совхоз посёлогында туа, математика укытучысы, педагоглык стажы – 11 ел.

**Диана Геннадьевна Абдуллина** 1983 елда Кукмара шәһәр тибындагы посёлогында туа, башлангыч сыйныфлар укытучысы, педагоглык стажы – 13 ел.



1. Укытучылар: Р.З.Хәмәтгалиева, М.М.Галиева, Р.М.Закирова, Р.С.Хәсәнов, К.К.Хурамшина, Ф.М.Габдрахманова, Л.З.Сафина, Л.И.Рәхмәтуллина, Р.М.Вафина, Д.Г.Абдуллина, И.М.Коркина, Ф.И.Гаязов. 2018 ел.

# К.К.ХУРАМШИНА КОЛЛЕКТИВ ТУРЫНДА

«Мәктәп ул гаҗәеп, үз алдына максатлар куя-куя, шуларны чишә-чишә, өлкәннәр-балалар бер оешкан тату коллектив булып яшәүче үтә тынгысыз, ашкын, үзгә бер дөнья. Мин шул дөньяда укучы булып та, укытучы булып та, оештыручы-җитәкче булып та яшәдем. Мин җитәкче булып эшләгән дәвердә коллектив район күләмендә беренче бишлектә барды дисәм, тыйнаксызлык булмас. Югары категорияле татар теле укытучысы (бүген лаеклы ялда) Роза Хабул кызы Кушмина; югары категорияле математика укытучысы, өч ел рәттән «Республиканың иң яхшы математика укытучысы» (2012, 2013, 2014) исеменә лаек булган Фәнзия Мөдир кызы Габдрахманова; беренче категорияле химия-биология укытучысы, «Республиканың иң яхшы химия укытучысы» (2012) Фәрит Мәхмүт улы Шәрифуллин; беренче категорияле татар теле укытучысы, «Республиканың иң яхшы татар теле укытучысы» (2012) Рүзилә Минвәли кызы Закирова; беренче категорияле башлангыч сыйныфлар укытучысы, «Республиканың иң яхшы башлангыч сыйныфлар укытучысы» (2012) Рузалия Зәки кызы Хәмәтгалиева; беренче категорияле башлангыч сыйныфлар укытучысы Ләйлә Зариф кызы Сафина; беренче категорияле рус теле укытучысы Миләүшә Мансур кызы Галиева; Хәерби егетләре: югары категорияле физкультура укытучысы Фәрит Ибраһим улы Гаязов; технология укытучысы Рөстәм Садри улы Хәсәнов; 32 ел гомерен Хәерби балаларын укытуга багышлаган Фәим Фәйзрахман улы Габдрахманов һәм башкалар — мәктәпнең төп



составы иде. Санап китә калсаң, эшләнгән эшләр, катнашкан конкурслар да бик күп булды. Бу бит көндәлек төп эшебез — тиешле программалар нигезендә балаларга белем бирүдән башка, өстәмә тырышлык нәтиҗәсе.

Мәктәп укучылары ел саен район олимпиадаларында катнашып призлы урыннар яулады. Татар теле һәм әдәбияты, рус теле, технология, физкультура предметларыннан укучыларыбыз Республика олимпиадаларында катнашты. Уку-укыту эшләре буенча завуч Фәнзия Мөдир кызы җитәкләгән уку-укыту эшебез ел саен югары бәяләнде.

Бердәм дәүләт имтиханнарын укучыларыбызның 60–70 баллдан түбән биргәннәре булмады. Рус теле укытучысы Миләүшә Мансур кызы, математика укытучысы Фәнзия Мөдир кызы, география укытучысы Фәим Фәйзрахман улы, татар теле укытучысы Рузилә Минвәли кызы, биология укытучысы Фәрит Мәхмүт улы балаларның барысын да югары дәрәҗәдә әзерлиләр. Шундый укытучылар булганда эшләргә була.

Республика күләмендә оештырылган «Иң яхшы мәктәп бакчасы» конкурсында катнашып, йөз мең сумлык грант отып, мәктәп бакчасына парник, мотоблок алып куйдык. Бакчада үзебезгә җитәрлек яшелчә, җиләк җимеш үстердек. Боларның барысы белән күп еллар биология укыткан укытучылар Фәрит һәм Гүзәлия Шәрифуллиннар җитәкчелек итте, эш әле дә шул рәвешле бара.

Мәктәптә төрле түгәрәкләр эшләп килә. Спорт буенча Фәрит Гаязов җитәкчелегендә егетләребез татарча көрәш ярышларында республика күләмендә призлы урыннар яулый. Районда үткәрелгән чаңгы ярышында ел саен кубок алып кайта идек. Мәктәптә шашка, шахмат буенча конкурслар оештырдык.

Укучыларыбыз күп еллар мәктәпнең тәрбия эшләре буенча директор урынбасары булып эшләгән Рузилә Минвәли кызы җитәкчелегендә «Тамчы шоу», «Җырлыйк әле» телевидение тапшыруларында катнашып, җиңү яулап кайттылар. Авыл клубында укытучылар һәм укучылар көче белән концерт, спектакльләр куела. Бу инде күптәнге традиция. Районда үткәрелгән төрле әдәби чараларда да мәктәп теләп катнаша.

Тормыш иминлеге нигезләре укытучысы Рөстәм Садри улы Хәсәнов башлангыч сыйныф укучыларын «Имин көпчәк» Республика ярышларына әзерләп, командабыз күп тапкырлар җиңү яулады.

Мәктәбебездә бик матур, эчтәлекле музей оештырылды. Аның башлангычы өчен без Республиканың «Диңгез җыены» җитәкчесе Шәүкәт Хәнәфи улы Сөнгатовка рәхмәтле. Музейга районнан, республикадан, Россия шәһәрләреннән, хәтта чит илдән дә кунаклар килә. Балалар белән моряклар арасында тыгыз бәйләнеш урнашкан. Очрашулар еш була, «Батырлык дәресләре» оештырыла».


1


2


3


4


5


6


7

1. Чыгарылыш сыйныф укучылары; 2. Концертта катнашучылар; 3. Биюче кыз Ралина Сафина; 4. «Беренче театр» спектакленнән күренеш; 5. Укытучы Фирдәвес Хәмидуллина балалар белән; 6. Казанда Г.Тукай бәйрәмендә; 7. Биюче кызлар.


1


2


3


4


5

1. Мәктәп китапханәсендә; 2. «Соңгы кыңгырау» бәйрәме. 2019 ел; 3. Белем бәйрәме. 2018 ел; 4. Мәктәп музеенда кунаклар белән; 5. Биюче кызлар «Февральские выкрутасы» фестивалендә.

## КЫҢГЫРАУЛЫ МӘКТӘП ЕЛЛАРЫ

(А.Б.Насибуллина истәлекләреннән)

Әйтерсең лә пар атларда үтте
Кыңгыраулы мәктәп еллары;
Күңелләрдә гомерлеккә калыр
Шушы соңгы моңлы чыңлавы.

Беренче класска укырга килеп, тантаналы җыелышта беренче тапкыр кыңгырау чылтыраганда да, аннары ул һәр дәрес өчен ике тапкыр – аның башлануын һәм тәмамлануын белдереп көнгә әллә ничә мәртәбә чылтырый башлагач та, кеше әле бу чың кайтавазының күңелендә гомер буе яңгырап, моңландырып, үткәннәргә чакырып торасын белми. Халык шагыйре Шәүкәт Галиев нинди мәгънәле сүзләр язган. Композитор Рим Хәсәнов аны бәгырьләргә үтәрлек көйгә салган. Без хәзер, гамьсез балачагыбызга, мәктәп елларына кайтасы килеп китсә, шул җырны шыңшып булса да рәхәт истәлекләргә бирелә алабыз.

Мәктәп! Укытучы! Бу сүзләр күңелгә килүгә, берсен-берсе тыгызлап, күпме истәлекләр күз алдына килеп баса. Күпме уй-кичерешләр мәктәп белән бәйләнгән! Укытучы! Ә кем соң ул? Укытучы – сабыйны кулыннан тотып белем дөньясына алып керүче, барлык һөнәрләргә юл ачучы кеше ул. Киләчәктә нинди генә биеклекләргә ирешсәк тә, уңышларыбызның башында укытучыбыз тора. Минем беренче җөмләдән «класс» дип башлавыма гаҗәпләнмәсәгез иде. «Сыйныф» сүзен куллансам, истәлекләремнең чынлыгы югалыр кебек. Без бит «класс» заманы балалары.

Мин үзем Хәерби мәктәбендә 1978–1988 елларда укыдым. Башкаларга ничектер, мәктәп елларым – минем өчен иң матур һәм иң бәхетле еллар. Беренче укытучым – **Лера Рәхим кызы Сәйфуллина**. Лера апа үзе Хәербидә тумаган, ул Кайбыч районыннан. Аның тормыш иптәше **Хәйдәр абый Сафин** да мәктәп укытучысы булган. Мин укый башлаганда Хәйдәр абый исән түгел иде инде. Лера Рәхимовнаның балалары шәһәрдә яшиләр, ялга гына кайталар иде. Укытучыбыз безне үз балалары кебек яратты. Еш кына без аңа: «Апа, без сезгә килик әле бүген, өегезне җыештырырга», – дибез. Ә ул безгә ризалык бирә. Классташ кызлар белән дәресләрдән соң җыелып, аның өенә китәбез. Башта озаклап уйныйбыз. Лера апаның өе бик чиста, аны җыештырасы да юк, бар җирдә тәртип. Без уйнаганда ул ишегалдына чыгып керә, тыштагы эшләрен эшләштерә. Аннан без үзебез үк туздырып бетергән өйне җыештырырга тотынабыз. Соңыннан безгә Лера апа әле чәй эчертә, «Тагын килегез, бала-

лар, бик күңелле булды, өем дә ямьләнеп китте», – дип озатып кала. Ничек түзгәндер ул безгә, анысын ул вакытта уйлый да белмәгәнбез. Һәрберебезне яраткан, кайгырткан Лера апа. Без аны аңлап та бетермәгәнбез. Кирәк чакта кырыс та була белгән, безгә карата ярату хисләрен дә кызганмаган.

Бу чорда күрше бүлмәдә башлангыч класс укытучыларының тагын берсе – **Чернова Елизавета Николаевна** укыта иде. Без аны Лиза апа дип йөрдек, авыл бит, шулай күнегелгән. Лера апа белән Лиза апа үз классларын бер-берсе белән ярыша-ярыша укыталар кебек тоела иде: кем күбрәк нәрсәгә өлгерә, кемнең яхшы укучылары күбрәк. Тәнәфес вакытларында икесе аралашып, фикер алышып торалар иде. Без Лера Рәхимовна классында укыганлык белән горурлансак, күрше бүлмәдәгеләр Лиза апаны беркемгә алмаштырырга теләмиләр иде.

Елизавета Николаевна шулай ук Хәербинеке түгел. Ул безгә Мамадыш районы Усали авылыннан килгән. Бөек Ватан сугышы ветераны. Сугышта элемтәче булып хезмәт иткән. Япь-яшь элемтәче кызларның зур катушкаларга чорналган кабельләрне ничек фронт линияләренә сузуларын үзе сөйләгәне булды. Хәзер «их, күбрәк сөйләтәсе калган!» дип уфтанам. Тере тарих укыткан бит безне!

Мин югары классларга күчкәч, башлангыч класс укытучылары булып **Диләфрүз Нури кызы Харисова** һәм **Фәридә Шамил кызы Гарипова** да эшләде. Диләфрүз Нуриевна безне өлкән классларда информатика фәненнән дә укытты. Фәридә Шамилевна ноталарны яхшы белә, шуңа күрә сүзләре матур булган күп кенә яңа җырларны аның ярдәме белән өйрәнә идек.

Мәктәпкә килеп кергәч, ике якка озын коридорлар китә: бер якта башлангычлар, икенче якта өлкән класслар. И кызыга идек тә соң өлкәннәр ягына кереп чыгарга! Ә ул көн җитеп, без мәктәпкә 4 класс укучылары булып җыелгач, шул көнне үк күзләргә яшь килде. Тәнәфес саен Лера апа янына керәбез дә, аны кочаклап елыйбыз.

Өлкән классларда укыткан укытучыларыбыз да бик яхшы булдылар. Сүземне алгарак китеп әйтим, үземнең ике балам да Казан мәктәбендә укыдылар. Аларның ничек дәрес әзерләүләрен, алган белемнәрен күреп, минем укытучыларымнан да әйбәтрәк, белемлерәк укытучылар юк ахыры дип уйлый идем.

Җаны-тәне белән үз фәнен белдерергә тырышкан, һәрберебез өчен гадел булган укытучыларымның берсе – **Роза Хабул кызы Кушмина**. Роза апа Хәербидә туган. Ул безгә татар теле һәм әдәбияты укытты. «Татарча менә болай ул, ә русчада болайрак», – дип чагыштырып күрсәтә иде. Менә шулар барысы да истә калган. Нинди генә тантана-бәйрәмнәргә әзерләмәде ул безне. Бигрәк

тә истә калганы – «Солдат хатлары» кичәсе булды. Без аны уздырырыга ел саен бик алдан озак итеп әзерләнә идек. Башта Хәерби мәктәбен тәмамлаган һәм армия сафларына алынган егетләргә хат язабыз. Шуннан безгә алардан җавап хатлары килә башлый. Менә шушы хатларның эчтәлегенә, хаталары булмавына бик сөенә иде Роза апа. Солдатларның һәрберсе нинди дә булса җыр сорап яза. Шул җырларны өйрәнәбез. Бәйрәмгә солдатларның әти-әниләре, авылдашлар чакырыла. Бик күңелле, шул ук вакытта күзләрдән яшьләр чыгара торган зур бәйрәм була иде ул.

Тагын бер вакыйганы язып үтәсем килә. Бер елны авылда «Каз өмәсе» бәйрәме уздырдык, моны телевидение төшерергә килде. Роза апа безне бик тырышып әзерләде. Ә тапшыруны аның өендә төшерделәр. Моның өчен Роза Хабуловналар өендәге бар нәрсәне тышка чыгарып торырга туры килде. Ә бит урамда салкын, ноябрь ае! Аның ире Шамил абый да ничек берни әйтмәде икән дип гаҗәпләнәм. Аннан, тапшыру төшерү өчен, йолкынган каз түшкәләрен Роза апа бөтен авылдан җыеп алды. Халык аңа ышанган, аны яраткан инде. Югыйсә үзенә дип үстереп әзерләгән казларны ышанып бирерләр идеме икән. Әле дә хәтерлим, Роза апа аларга төрле баулар бәйләп, кайсы кемнеке икәнен кәгазьгә язып куйды. Ул көнне көне буе шушы тамаша булды. Балаларны һәм телевидение кешеләрен Зиннәтуллин Камил һәм Сафин Гайса абыйлар йортларында җыеп ашаттылар.

Роза апа белән бәйле истәлекләр бик күп. Ул безне кайларга гына алып бармады! Типографиядә газетаны ничек бастырганнарын карарга да бардык, «Яшь ленинчы» газетасы редакциясе хезмәктәрләре белән дә таныштык, язучы Фәнис Яруллинның өендә кунакта да булдык, театрларга барып, татарча спектакльләр дә карадык. Менә шундый кеше ул Роза апа. Хәзерге вакытта ул лаеклы ялда. Әмма хәзер дә тик утырмый. Роза апа Хәерби авыл җирлегенең Ветераннар советы рәисе, «Ак калфак» фольклор ансамбле җитәкчесе.

Көчле, гаҗәп дәрәҗәдә эрудицияле укытучыларымның тагын берсе – **Рушания апа Вәгыйзова**. Рушания апа шулай ук Хәербинеке түгел. Ул безгә химия һәм биология фәннәрен укытты. Дәрес вакытында бик кырыс, балаларның игътибарын үзенә җәлеп итеп тота, беркем дә кирәкмәс эш белән мавыкмый! Ә менә класстан соңгы эшләрдә, үзе җитәкли торган «Яшь натуралистлар» түгәрәгендә ул безнең дус кызыбыз кебек якынга әйләнә. Шуңа күрә без аны бик ярата һәм хөрмәт итә идек. Хәзер Рушания апа Балык Бистәсе районында яши.

Рушания апаның ире **Рөстәм Вакыйф улы Вәгыйзов** – минем иң яраткан һәм бик хөрмәт иткән укытучыларымның берсе. Ул безнең мәктәптә директор булып эшләде, физкультура, тарих укытты. Һәр җирдә чисталык-пөхтәлек

һәм тәртип булганны ярата иде. Балаларны ул мөстәкыйль булырга өйрәтте. Нинди генә эш булмасын, мәктәп яки район күләмендәме, безгә ышанып тапшыра иде. Укытучыга гына ияреп түгел, ә үзебез башлап йөргәнне хуплый иде. Рөстәм Вакыйфович җирле партоешма секретаре да иде. Хәзерге көндә ул Балык Бистәсе районы Рус Әшнәге авылында мәктәп директоры. Россия Федерациясенең Мактаулы мәгариф хезмәткәре (2006), «Мәгариф өлкәсендәге казанышлары өчен» билгесе (2000) белән бүләкләнгән.

Математика укытучыбыз **Фәнзия Мөдир кызы Габдрахманова (Бәширова)** иде. 1984 елны ул Казан дәүләт педагогия институтын тәмамлап Хәерби мәктәбенә укытучы булып килә. Үзе яшь, матур, зифа буйлы Фәнзия апа миңа беренче күрүдән үк бик якын булып тоелды. Күзләрендә әзрәк курку да, әзрәк моңсулык та бар иде аның. Бер дә белмәгән авыл, мәктәп, кешеләр – куркырсың да. Туганнарын, әти-әнисен сагыну хисләре дә булгандыр. Аның туган ягы – Буа районының Әхмәт авылы. Безнең авылдан шактый ерак ара. Әтинең апасы Роза апа шунда миңа әйтә: «Бар әнә, бу укытучы апаңны дәү әниләреңә алып кайт, алайса без аңа торыр урын таба алмыйбыз», – ди. Роза апа чынлап әйткәнме, шаярыпмы, анысын белмим, әмма мин Фәнзия апаны ияртеп алып кайтып киттем. Дәү әни белән дәү абый (мин Җәмилә дәү әнинең энесе Кадыйр Шакировны шулай дип йөртә идем) безне күргәч бик аптырашта калдылар. Дәү әни мине алып чыгып ачуланды да әле. Әмма Фәнзия апа аларда торып калды. И, шундый рәхәт чаклар иде ул! Дәү әни белән дәү абый укытучы апамны бик яраттылар, ул аларның үз кызларына, ә минем чын апама әйләнде. Ял көннәрен көтеп алып, аның янына кунарга барырга ашыга идем.

Ул килгән елны мин 7 класска бардым. Фәнзия апа башка классларда математика фәннәрен укыта башлады. Аны уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары итеп билгеләделәр. Әле ул вакыт Фәнзия Мөдировнага нибары 22 яшь булган! Яхшы укысам да, ул минем математикадан бар көчемне салып укымавымны сизеп алды. 8 класстан ул безнең класста алгебра һәм геометрия фәннәрен үзе укыта башлады. Алдагы классларда өйрәнелгән темаларны кабатлатып ныгыттырды. Без аның дәресендә тик кенә бер минут та утырып тормый идек: чиратлап такта янына чыгабыз, дәрес узганны сизмибез дә. Мәктәпне тәмамлаганнан соң, ул укыган институтның шул ук факультетына укырга кердем. Физматта укый башлагач шуны аңладым, минем классташларымның күбесе андагы студентлардан яхшырак укый алыр иде! Фәнзия апа укытучым да, апам да, дустым да булды! Хәерби мәктәбендә 34 ел белем бирде Фәнзия апа Габдрахманова. Тормыш иптәше Фәим абый Габдрахманов та укытучы, география фәненнән укыта. 30 ел бергә тормыш корып яшәп, ике бала үстерделәр.

Класс җитәкчебез **Минтаиб Габдрахман улы Хәйбуллин** иде, ул рус теле һәм әдәбияты укытты. Үз классы булгач, бигрәк тә кайгырта иде ул безне. Арабызда бер генә малай, калганнарыбыз – кызлар. Ир-ат укытучыга кыенрак булгандыр безнең белән. Аның үз кызы Эльвира да безнең белән укыды. Кайвакыт, кылган гамәлләребезгә шаккатып, күзлеге өстеннән карый иде Минтаиб абый. Шуннан барысын да аңлый идек. Минтаиб Абдрахмановичның тормыш иптәше **Венера Гыймран кызы Хәйбуллина** тарих фәнен һәм кызларга хезмәт дәресләре укытты. Күп кенә класстан тыш эшләрнең башлап йөрүчесе иде ул. Минтаиб абый да, Венера апа да Хәербигә күчеп килгән кешеләр.

Мин 1 класска укырга кергән елны әле безнең мәктәп директоры **Сания апа Гайнетдинова** иде. Завуч булып **Әминә апа Шакирова** эшләде. Әминә апа математика укытучысы, үз фәненең остасы иде. Ул 4 класста безне дә математикадан укытты. Аннары Казанның 35 нче мәктәбендә эшләде. Хәзерге вакытта лаеклы ялда.

Физика һәм математика укытучысы **Виталий Семёнович Егоров** гаиләсе белән Хәербигә эшкә килде. Виталий Семёновичны яратмаган укучы булмагандыр, минемчә. Ул «Яшь фотограф» түгәрәге ачкач, бик күп бала язылды, хәтта түгәрәкне ике төркемгә бүлергә туры килде. Аның тормыш иптәше Гөлзада апа авыл медпунктында медсестра иде. Шуңа күрә ул мәктәпкә еш керә. Тәрәзәдән аның килүен күреп калган Виталий Семёнович: «Балалар, Гөлзада апагыз кереп килә, качыгыз», – дип шаярта иде. Ә бу апайдан куркасы юк, аның тавышы шундый ягымлы, куллары шундый йомшак. Ясаган уколларын, прививкаларын сизми дә идек.

Малайларны хезмәт дәресләреннән – **Хәйдәр абый Сафин** укытты, физкультура укытучылары булып **Фәрит Якуп улы Вәлиуллин**, **Вәли абый Гатауллин**, **Рөстәм Садри улы Хәсәнов** эшләде. Рөстәм Садриевич башлангыч хәрби әзерлек (НВП) дәресләрен дә укытты. Класстан тыш эшләрдә ул һәрвакыт безнең белән иде. Вәли абый бик күп спорт ярышлары оештырды. Ул эшләгәндә, без чаңгы ярышларыннан кайтып керми идек. Кая гына барсак та – мәктәп күләмендәме, район күләмендәме – малайлар арасыннан беренче урынны безнең мәктәп укучысы Гаязов Фәрит ала иде. Фәрит Ибраһим улы Гаязов хәзер үзе дә Хәерби мәктәбендә укыта.

Бер елны мәктәбебезгә яшь физика укытучысы килде. Ул **Талия Галләм кызы Тимергалиева** иде. Яшь кеше булуын да исәпкә алыптыр, аңа пионервожатый эшен дә тапшырдылар. Балалар аны бик яраттылар. Әмма язмыштыр инде, ул берничә генә ел эшләп, үзен яраттырып өлгерде дә, фаҗигале рәвештә гомере өзелеп, бу якты дөньядан китеп барды. Май ае иде ул... Бар мәктәп елады...

Без укыган чорда үзебезнең Хәерби кызы **Тәскирә Шамил кызы Фатыйхова** диплом алып, физика укытучысы булып эшләргә кайтты. Бик яхшы укытучы иде ул, үз фәне белән кызыксындыра, аңлата белә иде. Шулай ук пионервожатый эшенә дә алынды. Шулай бервакыт укытучылар көненә әзерләнәбез. Укытучылардан яраткан җырларын алдан сорап, концерт куймакчы булабыз. Безне Тәскирә апа әзерли. Шул елны яшь рус теле укытучысы килгән иде, мин аны **Румия апа** дип кенә хәтерләп калганмын. Аның Бай урамында Фаизә апаларда квартирда торган вакыты. Без – Тәскирә апа, Румия апа һәм мин (ул вакытта 5–6 класс укучысы) Бай урамы аркылы авылны урап, аларга кайтабыз, чөнки Румия апа өйгә кереп сумкасын калдырасы һәм Тәскирә апаларга барасы. Миңа инде рәхәт, бу ике яшь укытучы мине ияртеп, дус итеп йөртәләр! Румия апа, Дагстаннан килү сәбәпле, татарча сөйләшә белми, ләкин бераз аңлый. Шулвакыт ул укытучылар көненә Тәскирә апаның нинди җыр соравы белән кызыксынды. Тәскирә Шамилевна «Сыерчыклар» җыры икәнен әйткәч, Румия апа «а-а-а» дип куйды, беразга тынлык урнашты. Аннары ул: «Таскира, а это коровушки, да?», – дип сорап куймасынмы. Шушы сүздән соң, урам тутырып бик озак көлгән идек! Нинди күңелле вакытлар булган. Тәскирә Шамилевнаны авыру бу якты дөньядан бик иртә алып китте. Шуннан бирле «Сыерчыклар» җырының сүзләре искә төшү белән күзгә яшь килә...

...Сыерчыклар, сыерчыклар,
Канатлы дусларым,
Бирегез киңәш сез,
Ярамны төзәтми
Ник ташлап китәсез?...

Кыска гына язмамда исемнәре әйтелми калган укытучыларым да бар әле. Кадерле мөгаллимнәрем, зинһар үпкәли күрмәгез. Һәркайсыгыз йөрәгем түрендә. Пионервожатыйлар да бик күп: Флюра Габделхак кызы Абдуллина, Дамирә Җамалый кызы Шәрәпова, Минзәлия апа Сафина, Рузалия Галимҗан кызы Закирова. Бу кешеләр белән бик күп күңелле хатирәләр бәйле.

Зур юлларга безне чыгардың син,
Күңелләргә бирдең омтылыш.
Соңгы кыңгырау булсын беренчесе,
Син каршыла безне, зур тормыш!

Шушы җырны җырлап чыгып таралыштык без синнән, мәктәп! Мәктәбем! Чыгып киткән көнебездән бирле, гомер буе Лаеш районы Хәерби мәктәбе укучылары булуыбыз белән горурланып яшибез. Син дә безнең белән горурлана алсаң иде.

## ПИОНЕР ОЕШМАСЫ

Хәербидә беренче пионер оешмасы 1932 елда төзелгән. Беренче пионерлар: Факиһә Галиева, Мөнәвәрә Ярмиева, Миңсылу Мингалиева, Миңнебай Вәлиуллин. Күп укучыларның әти-әниләре балаларының пионерга керүенә каршы булганнар. Яшьләре җиткән булса да, күп балалар пионерга кермәгән. Кайберләре галстукларын яшерен рәвештә тагып йөргәннәр. Беренче пионерлар урамнан үткәндә, өлкәннәр алар артыннан «алласызлар, имансызлар» дип карганып калганнар. «Пионерга кергән кеше, үлгәч, җәннәткә керми икән», – дип балаларны куркытырга тырышканнар.

Беренче пионервожатый Әхтәмов Каюм абый булган. Ул бу эшне мәктәптәге төп эше – укытучылык белән бергә алып барган. Әхтәмов Каюм – чыгышы белән Яушыйк авылыннан. Бүгенге көндә карарга фоторәсеме дә калмаган, илленче елларда янгын чыгып, фоторәсемнәре дә шунда янган. Ә менә аның кызының фотосурәтләре бихисап. Аның җанлы сурәте исә – «Бибинур» фильмында. Әйе, атаклы актриса Фирдәвес Әхтәмова Хәербинең беренче пионервожатые Каюм Әхтәмов кызы ул. Фирдәвес апа Әхтәмова Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисты (21.07.1939, Лаеш районы Курманаково авылы – 22.02.2012, Казан). Әтисен ул бик аз хәтерли, чөнки әтисе сугышка киткәндә сабый гына булып кала. Каюм Әхмәтов фронтта һәлак була.

1938 елдан пионер дружинасына Мәрзия Вафа кызы Вафина җитәкчелек итә. Ул мәктәпкә килгәндә мәктәп җирлегендә төзелгән пионер оешмасы бик зәгыйфь була әле, оешма бары 27 пионердан тора. 1938–39 уку елында инде оешма 130 баланы берләштерә, пионер тормышы җанланып китә. Сборлар, походлар, төрле уеннар оештырыла. Балалар яңа оешмага тартыла. Замана да үзгәрә.

Дәһшәтле Бөек Ватан сугышы еллары җитә. 40 нчы еллар пионерларына күп авырлыкларны күрергә туры килә: көлтә дә ташый алар, аны кул көче белән сугалар да, шул ук вакытта укуларын да дәвам итәләр. Мәктәп салкын. Утынны Мишә аръягындагы урманнан «уфалла» арбасына, кышын чаналарга төяп алып кайталар. Аны кисү мәктәп техничкалары өстенә төшә. Чи утынның януы да, җылысы да юньле булмый.

Бөек Ватан сугышы елларында пионерлар колхозга гына түгел, фронтка да ярдәм итеп тора. Алар өй саен йөреп йон җыялар. Олырак балалар ул йонны язып, эрләп, бияләйләр, оекбашлар бәйлиләр һәм фронтка посылка итеп салалар. «Кулъяулыклар, оекбаш-бияләйләр әзерләүдән тыш, түләүле концерт

куеп, җыелган акчаны фронтка сала идек. 1942 елда балалар белән бергә колхозга 60 га мәйданнан борчак йолкып бирдек, кырга башак җыерга йөрдек», – дип сөйли Мәрзия апа.

Сугыш еллары үтә. Ятим калган балалар, тол хатыннарның да күңел яралары бераз төзәлә башлый. Тормыш дәвам итә. 1948–1953 елларда дружинада пионервожатый булып Чәчәк апа эшли. Ул елларда мәктәптә пионер булмаган бала булмый инде. Һәр яше җиткән бала пионерга керә. Дружинага Бөек Ватан сугышы герое Олег Кошевой исеме дә шушы елларда бирелә.

1954–1958 елларда өлкән пионервожатый булып Рәхмәтуллина Әминә апа, 1961–62 уку елында – Мөхәммәтҗанова Зәлфирә апа эшли.

1964–1965 уку елында О.Кошевой исемендәге пионер дружинасының өлкән пионервожатые булып Нигъмәтова Роза эшли башлый. Ул – беренче пионер вожатыйларыннан булган Мәрзия апа Вафинаның олы кызы. Дружина советы председателе итеп Кашапова Сәкинә сайлана. Дружина советы каршында 4 штаб эшли: «Ашыгыч ярдәм», «Пионер фонаре», «Октябрятларның яшь дуслары», «Тимурчылар». Пионер дружинасы мәктәп җирлегендә оештырылып, мәктәптә пионер булмаган бер бала да калмаганлыктан, балалар өчен кайсы эшнең мәктәп укучысы, ә кайсыларының пионер отряды яки дружинасы әгъзасы сыйфатында башкарылуы аерым мәгънәгә ия булмый. Иң мөһиме – файдалы эшләр эшләнә, алар аерым кешеләргә, авылга, республикага, илгә файда китерә! Пионер звеносы, отряды, дружинасындагы эш биремнәрне үтәү мәктәп балаларында тормыш өчен зарур, киләчәктә бик тә кирәк булачак оешканлык, бердәмлек, максатчанлык, эшне ахырына җиткерә белү кебек асыл сыйфатларны ныгыта.

Укучылар уку белән хезмәтне бергә бәйләп алып баралар. 1958/59 уку елында Хәерби укучылары 8 тоннадан артык металл ватыгы, 1 ц чүпрәк, 1 ц сөяк, 50 кг макулатура җыеп тапшыралар. «Алга» колхозына 6,15 га мәйданнан бәрәңге алуда катнашалар. Мәктәпне җылыту өчен 15 кубометр утын кисеп өяләр. Шул ук елда мәктәптә куянчылык фермасы оештырыла, балалар шунда эшлиләр. 110 төп агач һәм куаклар утыртыла, пионерлар сыер фермасын шефлыкка алалар.

1959/60 уку елында колхозга 8 га мәйдандагы кукурузаның рәт араларын эшкәртеп бирәләр. 12 га мәйданда борчак йолкыйлар. 6,5 га мәйданнан бәрәңге алалар. 1460 үрдәк бәбкәсен 1 айлык итеп үстереп бирәләр. Колхоз умарталыгы өчен 250 данә кәрәз рамы ясала. Мәктәп өчен 50 кубометр утын кисеп өелә.

1966 елның 1 июнендә Хәерби сигезьеллык мәктәбе бинасында «Алга» колхозының «Акчарлак» пионерлагере ачыла. Лагерьны ачу тантанасында кол-


1


2


3


4


5

1. Пионерлар укытучылары белән. 1950 еллар; 2. Пионер отряды. Г. Гарифуллина классы. 1960 еллар; 3. Л.Р.Сәйфуллина классы һәм укытучылар. 1950 еллар; 4. Җәйге пионер лагеренда. Гармунда – укытучы Р.Закиров, пионервожатый – Р.Нигъмәтова. Уртада биючеләр – Әлфируз Гарифуллина һәм Зәлфирә Мөбарәкшина. 1966 ел; 5. В.И.Ленин туган көненә багышланган тантаналы линейка.


1


2


3


4


5

1. Пионервожатый Р.Нигъмәтова чемпион Рафаэль Насыйбуллин белән. 1966 ел; 2. Лаешта СССРның 50 еллыгына багышланган бәйрәмдә. Байракчы кыз – Кадрия Вафина. 1972 ел; 3. Барабанчы – Кәбир Насыйбуллин, пионервожатый – Р.Нигъмәтова, быргычы – Гыйльфан Галәвов, байракчы кыз – Розалия Хәйбуллина. 1967 ел; 4.Л.Голиков исемендәге отряд пионерлары. 1967 ел; 5. Ульяновск шәһәренә экскурсия. 1967 ел.

хозның партоешма секретаре Нури Минбай улы Минбаев, мәктәп директоры Зариф Гали улы Галиев, барлык укытучылар, ата-аналар катнаша. Лагерьда 10 ар көнлек өч смена эшли. Укучыларга төрле ярышлар, уеннар оештырыла. Һәр көнне колхоз кырында эшләп кайту да режимга кертелә. Пионерлар 2–3 сәгатькә суган чүбе утарга йөриләр.

1967 елның 12 июнендә мәктәпнең бары тик «5» ле билгеләренә генә укучылары Ульяновск шәһәренә юллама белән бүләкләнә. Укытучы Мөхәммәт Рәхимов һәм пионервожатый Роза Нигъмәтова җитәкчелегендә 25 укучы Ульяновск шәһәрендә экскурсиядә йөреп кайталар.

1970/71 уку елында Лаеш районы буенча укучыларның көл җыюлары оештырыла. Хәерби мәктәбе укучылары, 130 ц көл җыеп, район буенча икенче урынны алалар.

1971 елда Хәерби укучылары 15 тонна металл ватыгы җыеп, район буенча беренче урын яулыйлар. Лаеш районы пионерлары җыйган металл ватыклары бәрабәренә «Лаеш пионеры» комбайны алына һәм районның иң алдынгы комбайнчысына бирелә.

70 елларда Хәерби урта мәктәбе пионер дружинасы 4 тапкыр ВЛКСМ ҮКның истәлек тасмасына лаек була һәм Бөтенсоюз пионер оешмасы Үзәк Советының Мактау грамотасы белән бүләкләнә.

1971/72 уку елына кадәр Хәерби мәктәбе пионер дружинасы Олег Кошевой исемен йөртә. Район буенча бу исемне йөртүче дружиналар күп булу сәбәпле, район Пионерлар йорты башка исем алырга тәкъдим ясый. Ләкин исем болай гына бирелми, аны игелекле эшләр белән яулап алырга кирәк була. Дружина советы җыела, киңәшәләр, Муса Җәлил исемен алу өчен көрәшергә дип карар чыгарыла. Дружинадагы һәр пионер Җәлилнең бер шигырен яттан өйрәнә. Конкурс башта отрядларда, аннары дружинада үткәрелә. Конкурста түбәндәге укучылар җиңеп чыга:

1. Гарипова Фәридә.
2. Шаһитова Минзия.
3. Гаязова Гөлнар.
4. Вафина Сәмия.
5. Фатыйхова Тәскирә.
6. Гарипова Миңнеруй.
7. Гатауллин Илдар.
8. Гаязов Илфар.
9. Солтанова Ризәлә.
10. Хөсәенова Фирдәвес.
11. Зарипов Илһам.
12. Гарипова Фәрдия.
13. Хәмидуллина Минниса.
14. Вәлиуллина Рәмзия.

Шигырьләр конкурсы эшләрнең башы гына була. Һәр сыйныфта Җәлилгә багышланган һәм Җәлил сүзләренә язылган җырлар өйрәнәләр. Муса Җәлил-

гә багышланган китап укучылар конференциясе үткәрелә. Муса Җәлилнең дусты Фатих Исхаков белән элемтәгә кереп, Герой шагыйрь турында истәлекләр туплыйлар. Ул Муса Җәлил турында истәлекләр, Җәлил белән төшкән фоторәсемен җибәрә.

Ниһаять көткән көн килеп җитә. Авыл клубында пионер дружинасы сборы үткәрелә. Монда ВЛКСМның Лаеш райкомы бюросы беркетмәсеннән дружинага герой-шагыйрь Муса Җәлил исеме бирелү турында карар укыла. Пионерлар түбәндәге ант сүзләрен кабатлыйлар:

«Без, Лаеш районы Хәерби урта мәктәбе пионерлары, дружинабызга Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты, патриот шагыйрь М.Җәлил исемен алганда, Туган илебезне Җәлил кебек яратырга ант итәбез. М.Җәлил – безнең өчен мәңгелек үрнәк. Ул – безгә киләчәккә юл күрсәтүче якты маяк. Аның нинди газаплар күргәндә дә сынмаган бөек рухына, нинди бәяләргә дә сатылмаган намусына без сокланып һәм гаҗәпләнеп карыйбыз. Герой шагыйрьнең исемен дружинабызга алганда, Җәлил кебек туган илебезне сакларга, Җәлил исеменә беркайчан да тап төшермәскә ант итәбез! Яхшы укырга, җәлилче дигән мактаулы исемне лаеклы йөртергә ант итәбез!»


Ф. ТГ-12

МИНИСТЕРСТВО СВЯЗИ СССР

ТЕЛЕГРАММА

ПРИЕМ: __го __час. __мин.

Бл. № 71

Принял:

ПЕРЕДАЧА: __го __час. __мин.

№ связи

Передал:

Из Лаишево №*) 100/01

19 сл. 14/II го 11 час. 55 мин.

Служебные отметки:

Адрес: Лаишевский р-н ... Хаерби ... школа

поздравляем присвоением дружине имени М. Джалиля. Надеемся оправдаете это высокое звание героя

РК ВЛКСМ

Пионер дружинасына М.Җәлил исеме бирелү белән котлап ВЛКСМның район комитетыннан килгән телеграмма.

Дружинаның Җәлил исемен алуына пионерлар гына түгел, укытучылар да шатлана. Сбор махсус әзерләнгән программа белән үтәргә тиеш булса да, аның барышында үзгәрешләр була. Дулкынланган укытучылар да сәхнәгә күтәрелеп Җәлил шигырьләрен яттан сөйлиләр.

Хәерби урта мәктәбе укучылары бик актив һәм кызыксынучан. Нинди генә эш эшләргә тотынсалар да кайнарланып эшлиләр. Мәктәп укучылары «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») газетасы белән һәрвакыт дус яши. Мәктәптә укучы баласы булган һәр гаилә ел саен бу газетага язылa. 1984 елда газетаның 60 еллык юбилее үткәрелә. Шул уңайдан газета редакциясе иң яхшы стена газетасына конкурс игълан итә. Менә шул конкурста Хәерби мәктәбенең «Яшь әдәбиятчы» стена газетасы иң яхшыларның берсе дип табыла. Шул уңайдан «Яшь ленинчы» редакциясе иң актив укучылар-













1. Вожатый Гөлсинә Галәвова пионерлар белән; 2. Зәйтүнә Насыйбуллина классы укучылары. 1960 еллар; 3. Пионер отряды. Укытучы Гөлшат Кәлимуллина классы. 1970 еллар; 4. Гөлира һәм Гөлшат; 5. Пионерлар колхозга суган чүбе утауда булышалар. 1967 ел; 6. Җиңү көненә багышланган линейка.



1


2


3



4



5


6

1. Җыңү көненә багышланган линейкада пионервожатый Р.Нигъмәтова рапорт кабул итә; 2. В.И.Ленин туган көнгә багышланган тантаналы линейка; 3. СССРның 50 еллыгына багышланган район күләмендәге кичәдә. 1989 ел; 4. Казанга циркка бару; 5. В.И.Ленин туган көнгә багышланган тантаналы линейкада; 6. «Акчарлак» пионерлагеренда кичке учак янында. 1966 ел.

ны кунакка чакыра. 20 укучы укытучы Кушмина Роза җитәкчелегендә «Яшь ленинчы»ның 60 еллык юбилеена багышланган тантаналы җыелышка бара. Бәйрәм Матбугат йортында уза. Казан шәһәре пионерлары кунакларны каршы алып, 12 катка озатып куя. Анда укучылар газета хезмәткәрләре Илгизәр Сәмигуллина һәм шагыйрә Эльмира Шәрифуллина белән таныша. Алар кунакларның һәркайсына «Яшь ленинчы»ның матур итеп чыгарылган юбилей санын өләшә. Хәерби укучыларының бүләккә каршы бүләкләре була, алар газета хезмәткәрләренә мәктәп яны участогында үстерелгән кашкарыйлар бүләк итә.


ПОЧЕТНАЯ ГРАМОТА

Центральный Совет Всесоюзной пионерской организации имени В. И. Ленина

награждает

Пионерскую дружину имени М. Джалиля Кирбинской восьмилетней школы

в связи с 50-летием Всесоюзной пионерской организации имени В. И. Ленина.

«16» мая 1972 г.

ЦС ВПО им. В. И. Ленина


Всесоюзный Ленинский Коммунистический Союз Молодежи

Лаишевский районный комитет Татарской АССР

исх. №____ 11 февраля 1972 г.

ВЫПИСКА ИЗ ПРОТОКОЛА
БЮРО ЛАИШЕВСКОГО РК ВЛКСМ

от 11 февраля 1972 года.

О присвоении пионерской дружине Кирбинской 8-летней школы имени Героя Советского Союза, татарского поэта Мусы Джалиля.

Постановили: За большую и плодотворную работу по образу татарского поэта-героя пионерской дружине Кирбинской 8-летней школы присвоить имя Героя Советского Союза Мусы Джалиля.

Секретарь Лаишевского РК ВЛКСМ — А.ФАТТАХОВ —


[illegible]

Пионерская ПРАВДА

НАШ АДРЕС: [illegible]

Орган ЦК ВЛКСМ и Центрального Совета Всесоюзной пионерской организации имени В. И. Ленина

ПАМЯТКА ДЕТКОРА

[illegible]

19 февраля 73 г.

Здравствуйте, Роза!

Редакция районной газеты "[illegible]" переслала нам Вашу заметку "Первый успех".

Мы с удовольствием узнали о том, что пионеры Вашей дружины приняли активное участие в месячнике по сбору макулатуры. Ребята молодцы!

Было бы хорошо, если бы Вы писали нам и о других интересных, новых делах дружины. Ведь, как нам сообщили, в свою газету Вы пишете довольно часто. Почему бы Вам не стать и нашим корреспондентом?

Всего Вам доброго!

Литсотрудник

/Б.Королева/

[illegible]

«Яшь ленинчы»ның юбилей кичәсендә күренекле язучылар һәм шагыйрьләр Гомәр Бәширов, Сибгат Хәким, Илдар Юзеев, Гариф Ахунов, Мөхәммәт Мәһдиев, Казан дәүләт университеты профессоры Вахит Хаков һәм башка бик күпләр катнаша. Хәерби укучылары язучы Фәрваз Миңнуллин, «Башкортстан пионеры» газетасы редакторы Сафуан Алибаев, «Ялкын», «Азат хатын» журналлары хезмәткәрләре белән аерым да очрашу мөмкинлеге ала.

Очрашу күңелләрдә онытылмас тәэсирләр калдыра.

Бүгенге көндә илдә пионер оешмалары юк, алар ил таркалганда юкка чыкты. Кайберләүләр бу оешмага карата тискәре карашларын белдерсәләр дә, шуны әйтергә кирәк: заманында Хәерби мәктәбендә пионер оешмасы бик яхшы эшләде. Ул балаларның олыларны хөрмәт итәргә, кечеләрне кыерсытмаска, туган илне яратырга, физик яктан нык булырга һәм белемгә омтылырга өйрәтте.

## ИСТӘЛЕКЛЕ ГАЛСТУК
## (Роза ТУФИТУЛОВА, «Яшь ленинчы» газетасы редакторы. «Азат хатын», 1982 ел, май)

Безгә, пионер матбугатында эшләүче кешеләргә, бәйрәмнәр турында еш язарга туры килә. Пионерстан иле – бәйрәмнәр иле ул, андагы һәр вакыйга якты һәм тантаналы бәйрәмгә әверелә һәм быргы-барабан тавышлары, Ватаныбызның революцион яшьлеген хәтерләтеп, күңелләрне аеруча тетрәндереп яңгырый.

Бер елны миңа пионер бәйрәмнәренең берсен Казаннан ерак булмаган бер авылда каршыларга туры килде. Һич кенә дә хәтеремнән китми: май аеның гаҗәеп назлы бер иртәсе иде. Шул иртәдә Лаеш районының Хәерби авылы урамнары буйлап өч барабанчы малай йөрде. Өй турыларыннан шушы малайлар узган саен, авыл кешеләре, капкаларын ачып, озак итеп карап калдылар. Аннан берән-сәрән дә, төркем-төркем булып та авылның үзәк урамына юнәлделәр. Барабанчылар урамнарны соңгы кат ураганда, авылның олысы-кечесе мәктәп каршына җыелып өлгергән иде инде. Күз күнеккән гадәти тантана гына булмады ул – Хәерби пионерларының әлеге бәйрәм сборы! Муенында кызыл галстук йөрткән һәркемнең бәйрәме иттеләр алар аны. Кайчандыр үзләре дә пионерда үскән әби-бабайлар, әти-әниләр өчен дә чиксез сөенечле вакыйга булды ул.

Шушы очрашудан соң, республика пионерларының нинди генә бәйрәм тантанасында катнашсам да, Хәерби авылы барабанчыларын искә төшерә торган булып киттем.

– Шул гомер хәтерегездә сакларсыз икән?– дип гаҗәпләнеп каршы алды мине шушы бәйрәмне оештыручыларның берсе, укытучы Мәрзия апа Вафина. – Гомер дигәнең «ә» дигәнче уза да китә икән шул. Ул бәйрәмнән соң да ун ел вакыт узган. Менә мин дә укытудан туктадым... – диде ул, моңсу гына елмаеп. – Хәербигә укытучы булып килүемә дә кырык елдан артык инде. «Дүртенчеләрне укытырсың. Шуның өстенә без сине пионервожатый итеп билгелибез әле», – дип каршылаган иде мәктәпнең ул чактагы директоры Мәҗит ага Әхмәтов. Техникумда укыган чагымда ук, ак кофта киеп, галстук тагып, балалар җитәкләп йөрсәң иде, дигән хыялым бар иде. Хыялым чынга ашасын белгәч, сөенечемнән чак кына кычкырып җибәрмәдем!.. Ни әйтәсең инде унҗиде яшьлек кызның шушы кыланышы турында! Иртәрәк сөенгәнмен икән... Икенче көнне мәктәптә нибары биш-алты пионер барлыгын, оешманың барлы-юклы гына булуын аңлагач, коелдым да төштем. Шул кичне җәяүләп Саралангa – абыем Габдрахман янына кайтып киттем. Ул үзе-

безнең Саралан мәктәбендә укыта, вожатый да булып эшләгән кеше. Абый мине тыңлап бетерде дә ипләп кенә болай диде: «Әйдә, Мәрзия, Хәербиеңә озатып куйыйм әле... Шунда барын да сөйләшербез». Минем аптырашта калганны күреп: «Әйдә, әйдә, сиңа иртән дәрескә дә өлгерергә кирәк», – дип өстәде. Хәербигә без төнлә генә кайтып җиттек, фатир хуҗалары Хәмитгалим абзыйларның куркып ишек ачмый торулары исемдә. Мәңге онытылмаслык төн булды ул минем өчен. Балаларны уеннар белән мавыктыра белергә кирәк икән – абыем миңа әнә шуның серләрен аңлатты. Кызыл галстук таккач, аларда нинди үзгәрешләр буласын да бәйнә-бәйнә сөйләп бирде. «Шуны хәтереңә салып куй, – диде. – Син белемле кешеләр генә түгел, коммунарлар тәрбияләргә тиеш буласың. Коммунарлар – нәни коммунистлар дигән сүз ул. Димәк, син авылның беренче баскыч политик оешмасын төзергә тиеш буласың. Сиңа гадәттән тыш җаваплы эш тапшырылган, аңлыйсыңмы шуны?» Абыйның әлеге сүзләреннән соң мин тагын да югалыбрак калдым. Ул бик сизгер кеше иде, минем бу халәтемне аңласа да, сизмәгәнгә салышты. Иртән китәр алдыннан куен кесәсеннән бер төргәк чыгарып миңа сузды: «Сиңа булсын, Мәрзия. Бу – минем галстук», – диде...

...Мәрзия апаның күзләрен яшь пәрдәсе каплады һәм ул тыелып калды.

Әңгәмәне әнисе кырында утырган Гөлнара дәвам итте:

– Ул галстукны әни, вожатый булып эшли башлагач, Роза апага бүләк иткән иде. Аңарда саклана ул. Ә Габдрахман абый 1942 елда сугышта хәбәрсез югалган... Аны искә төшергәндә, ул шулай өзгәләнә шул инде, – диде дә, әнисен юата башлады.

Хатирәләр, хатирәләр... Абыйсының фатихасы белән башланган вожатыйлык эше Мәрзия апаның гомерлек хезмәтенә, иң яратып эшләгән эшенә әверелә. Сугыш елларында мәктәп директоры булып калгач та шушы вазифасын ташламый ул. 1945 елда Мәрзияне Коммунистлар партиясе сафына алалар. Шул көнне ул район мәгариф бүлегенә кереп, үзен гади укытучы эшендә калдыруларын сорый һәм вожатый эшен дә алып барачагын әйтә. Үтенечен канәгатьләндерәләр. Хәерби кешеләре, күкрәк баласын кечкенә арбага салып, бала-чага белән сугыш уены уйнап йөрүче Мәрзиягә гаҗәпләнмиләр инде. Кайчак үзләре да ярдәмгә киләләр, чөнки вожатый апалары биргән задание белән балалар өлкәннәр янына я колхоз оештыручы активистларны эзләп килеп чыгалар, я булмаса авылның беренче тракторчысын эзлиләр, яки сугышта батырлык күрсәтеп һәлак булган авылдашларының гаиләләренә, «десант төшереп», булышып китәләр.

– «Десант» димәктән, – ди Мәрзия апа, – без сугышта һәлак булган якташларыбыз хакында эзләнүләрне 1948 елда ук башлап җибәрдек. Хәзерге кебек

ил күләмендә уздырыла торган «Аҗаган» уены юк иде әле ул заманда. Әмма безнең Хәерби балалары ул уенны әнә шул чакта ук уйный башладылар.

Бу елларда Мәрзия апаның олы кызы Розадан соң улы Булат һәм кызы Гөлнара дөньяга килә. Әмма ул барыбер пионер тормышыннан аерылмый. Дүртенче баласы – Гөлшат тугач кына пионер эшләрен мәктәпкә яңа килгән яшь укытучыга тапшыра.

– Сүздә генә булды инде ул тапшыру. Бәйрәмнәр, төрле уеннар оештырганда, ничек түзеп торасың инде? Аннан мин шушы еллар эчендә бер нәрсәгә төшендем: гомерендә бер тапкыр да кулына флаг тотып карамаган яки барабан кагып сафларда узмаган бала безнең советча яшәвебезнең асылын, революция китергән казанышларны тулысынча аңлый алмый. Шундый тантаналар, бәйрәмнәр, уеннар оештырганда миңа һәрвакыт Гайдар ярдәмгә килә торган иде. Миннән күреп балаларым да шундый уеннар белән чын-чынлап мавыгып киттеләр.

Әйе, Мәрзия апаның ишле гаиләсендә 1956 елдан бирле бүгенге көнгәчә һәрвакыт кемдер пионер. Хәзер бу йортта аның иң беренче оныгы, IV класс укучысы Алсу галстук тагып йөри. Тиздән Наил белән Фәридә дә пионер булачаклар. Мәрзия апа эчке бер сөенү белән миңа Алсуның уз куллары белән бәйләгән оекбашларын күрсәтә.

– Сезнең «Яшь ленинчы»дан укыгач, балалар йортларында тәрбияләнүчеләр өчен икәүләп посылка әзерли башладык, – ди.

Мин Мәрзия ападан «истәлекле галстук»ның хуҗасы булып калган Роза хакында сораштырам. Ананың йөзе тагын да яктырып китә.

– Ышанмассыз да, бәлки. Роза да мәктәптә укыган чагында ук вожатый булу турында хыялланып йөрде. 1965 елны, ул урта мәктәпне бетергән елны, безнең мәктәбебезгә түләүле пионервожатый штаты бирелде. Әй, сөендек тә соң инде!

Роза да әнисе шикелле нәкъ ун ел вожатый булып эшли. Хәзер тел һәм әдәбият укыта.

– Менә ул вожатый булган заманда безнең өйдәге тамашаларны күрсәгез иде сез! — дип яңадан сүзгә кушыла Гөлнара. — Әтидән башлап кечкенә Айратка чаклы пионер бүлмәсе өчен ни дә булса эшли иде. Мәктәпнең пионер бүлмәсендә әлегә чаклы без ясаган стендлар саклана. Аннан ул елларда авыл җирләрендә җәен пионер лагерьлары оештырыла башлады. Шул чагында безнең гаилә тулысы белән шунда күчеп киткән иде. Әти генә өйдә калды. Роза апа — өлкән вожатый, әни — лагерь начальнигы...

Әниле-кызлы әңгәмәдәшләремне мин бүлдерми генә тыңлыйм. Алты баласы да хәзер Мәрзия апа янында утырса, хатирәләрнең иге-чиге булмас иде, мөгаен. Шунысы бәхәссез: әниләренең җанын биләгән пионер романтикасы

аларга да күчкән. Гөлнара үзенең хезмәт юлын Казан телевидение студиясенең балалар өчен тапшырулар редакциясендә режиссер ярдәмчесе булып башлап җибәргән. Гаиләдәге иң төпчек бала Айрат республика балалар больницасының «ашыгыч ярдәм» машинасында шофер булып эшли. Күп балаларның тормышын саклап калуда аның да өлеше бар. Мәрзия апаның улы Ринат та шофер. «Казаньхимстрой» трестында эшли. Узган ел аңа җәй буе комсомол кушуы буенча берләшмәнең пионер лагеренда вожатый булып эшләргә туры килә. Сынатмый егет.

Ниһаять, өстәлгә истәлекле бүләкләр һәм альбомнар алына.

– Менә иң зур бүләкләремнең берсе шул, – дип Мәрзия апа миңа В.И.Ленин исемендәге Бөтенсоюз пионер оешмасы Үзәк Советының Мактау грамотасын сузды. Ул аңа В.И.Ленин исемендәге Бөтенсоюз пионер оешмасына 50 ел тулу уңае белән бирелгән. 38 ел эшләү дәверендә, әлбәттә, истәлекле бүләкләр шактый җыелган. Аның күкрәген «Аеруча хезмәт күрсәткән өчен» медале бизи.

Альбомнардан аерым бер пөхтәлек белән урнаштырылган фоторәсемнәрне карарга керешәбез. Еллар узу белән саргайган ул рәсемнәрнең һәркайсыннан Мәрзия апаның күңел яктылыгын тоясың. Рәсемдәге бу малайлар һәм кызлар кемнәр генә булып үсмәгәннәр!

– Менә бу сөйкемле кызны гына карагыз әле. Венера Сафина дигән кызым. Отряд советы председателе иде. Ә хәзер РСФСР Югары Советы депутаты итеп сайланды.

Мәрзия апа Вафинаның истәлекле галстугы, һичшиксез, оныкларына күчми калмас. Һәм көннәрдән бер көнне Хәерби урамнарына яңадан барабанчы малайлар чыгарлар да бик күпләрнең хәтерләренә кагылып узарлар, шаулы пионер балачакларын исләренә төшерерләр, бәйрәм сборларына дәшәрләр...

Яңа буыннарда әнә шулай яңара пионерия романтикасы, шулай яши!

## СУГЫШЧАН ДАН ҺӘМ ХӘРБИ-ДИҢГЕЗ ФЛОТЫ МУЗЕЕ

Хәерби мәктәбендә Сугышчан дан һәм Хәрби-Диңгез Флоты музее 2009 елның 5 ноябрендә оешып бетеп, эшли башлый. Музей 36 м$^2$ мәйданны били. Аны төзүгә Татарстан Республикасы «Диңгез җыены» («Морское собрание») иҗтимагый оешмасының Беренче дәрәҗә старшинасы Шәүкәт Хәнәфи улы Сөнгатов һәм оешма ветераннары зур өлеш кертә. Мәктәп балалары да бик күп материал җыя. Хәзерге вакытта музейда 300 экспонат, Хәрби-Диңгез Флотына багышланган китапханә, Россия Хәрби-Диңгез Флоты корабльләренә караган бай картиналар галереясы бар.

Хәерби мәктәбе укучылары Татарстан һәм Лаеш районы буенча Россия Хәрби-Диңгез Флоты, шул исәптән су асты көймәләре ветераннарын эзләү эшләре алып баралар. Музейда батырлык дәресләре, ветераннар белән очрашулар уза. Үсеп килүче буынны патриотик рухта тәрбияләүдә бу музейның өлеше гаять зур.

Музейның җитәкчесе — Рөстәм Садри улы Хәсәнов. Ул 1962 елның 15 гыйнварында Лаеш районы Хәерби авылында туа. Шушы авылда сигезьеллык мәктәпне тәмамлый. 1980–1982 елларда Совет Армиясе сафларында хезмәт итә. Казан төзелеш техникумында укый. 1985 елда мәктәпкә эшкә килә, хезмәт һәм башлангыч хәрби әзерлек дәресләрен алып бара. Рөстәм Садри улының укучылары техник эшләнмәләр буенча район һәм республика олимпиадаларында призлы урыннарны яулыйлар. Укучылар кулы белән ясалган әйберләр район һәм республика күләмендә оештырылган күргәзмәләрдә күрсәтелә. Ә инде 2003 елда яңа мәктәп ачылу белән мөмкинчелекләр тагын да арта, яхшы техник база булдырыла.

Район күләмендә «Имин көпчәк» конкурсы оештырылуын белгәч, Рөстәм Садри улы, җиң сызганып, аңа әзерлек эше башлап җибәрә. Нәтиҗәләр дә озак көттерми: Хәерби укучыларыннан төзелгән команда 10 ел дәвамында район күләмендә беренчелекне бирми. Республика ярышларына юл ачыла. Рөстәм Хәсәновның укучылары анда да сынатмыйлар.

Мәктәптә Хәрби-Диңгез Флотына багышланган музей ачылу Рөстәм Садри улының эшчәнлеген яңа юнәлешкә борып җибәрә. Музейга җитәкчелек итү, аны экспонатлар белән тулыландыру, ветераннар белән очрашулар оештыру, балалар өчен «Батырлык дәресләре» үткәрү аның өчен укучыларга белем бирү кебек үк зур әһәмияткә ия. Мәктәп музее шулай ук төрле конкурсларда катнашып, җиңүләр яулый.

Рөстәм Хәсәнов «Судно һәм автомобиль модельләре» түгәрәген оештырып җибәрә. Балалар бу түгәрәккә бик теләп йөриләр. Алар үзләре ясаган макетлар белән район һәм республика күләмендә үткәрелгән ярышларда катнашалар, призлы урыннар яулыйлар. Рөстәм абыйлары балаларны шахмат серләренә дә өйрәтә. Укучылары шахмат буенча район күләмендә үткәрелгән ярышларда беренчелекне бирмиләр.

Рөстәм Садри улы — бик тынгысыз һәм тырыш укытучы. 2013 елда «Ел укытучысы» бәйгесендә, 2016 елда Халыкара күргәзмәдә, 2018 елда «Балаларга йөрәгемне бирәм» бәйгесендә катнашып, җиңүләргә ирешә. Озак еллар мәктәп балаларына төрле яклап тәрбия, белем бирүдәге уңышлары өчен ул төрле дәрәҗәдәге Мактау грамоталары, Рәхмәт хатлары, Муса Җәлилнең тууына 110 ел тулу уңаенан (2016 ел) истәлекле юбилей медале белән бүләкләнә.














Сугышчан дан һәм Хәрби-Диңгез Флоты музее эшчәнлегеннән күренешләр.












Сугышчан дан һәм Хәрби-Диңгез Флоты музее эшчәнлегеннән күренешләр.

## БАЛАЛАР БАКЧАСЫ

Авылда балалар бакчасы аерым бер дәрәҗәдә. Монда бит бәгырь җимешеңне курчак театрына да, «Макдоналдс»ка да, циркка, аквапаркка да алып барып булмый, балалар кафесында сыйлый да алмыйсың. Авыл баласы өчен балалар бакчасы зур дөньяга алып чыга, яшьтәшләре белән аралашырга мөмкинлек бирә торган бердәнбер урын. Кызганыч, авыл һәм шәһәр балалары арасындагы аерманы бетерергә мөмкин түгел әле бүген. Ләкин авыл балалары да сәләт өләшкәндә йоклап калмаган, белем алырга да, өйрәнергә дә атлыгып торалар. Балалар – безнең киләчәгебез. Ә тәрбиячеләр шул киләчәк матур булсын өчен тырышып эшләүче затлар.





Балалар бакчасы: 2001 һәм 2019 елгы фотолар.





1. Балалар бакчасы хезмәткәрләре Алсу Вафина, Минбикә Вафина, Әлфинур Вәлиева, Рәмзия Шәмиева балалар белән. 1984 ел; 2. Тәрбияче – Әлфинур Вәлиева балалар белән. 1985 ел.

Хәерби авылында балалар бакчасы 1978 елның июнендә ачыла. Аның беренче мөдире – Мәдинә Хәбибулхак кызы Закирова. Бала караучы тәрбиячеләр булып төрле елларда Минбикә Сафа кызы Вафина, Әлфинур Габдулла кызы Вәлиева, Алсу Габделхак кызы Вафина, Гөлфирә Нәҗип кызы Нигъмәтова, аш-су әзерләүчеләр булып – Минзәлия Габдулла кызы Минвәлиева, Илнура Хәмәтхан кызы Маликова, хуҗалык мөдирләре булып – Нил Ибраһим улы Маликов, Асия Габдулла кызы Зарипова, Рәмзия Шамил кызы Шәмиева эшли. Балалар бакчасы элеккеге тулай торак бинасының ике бүлмәсен биләп тора. Ясле-бакча яшендәге балалар саны кинәт кимү һәм бинаның бик иске булуы сәбәпле, 1995 елда балалар бакчасы ябыла. 2000 елның мартында 20 балага исәпләнгән, типовой проект белән төзелгән яңа бина төзелеп бетеп, балалар бакчасы ачыла. 2018 елда капиталь ремонт ясала. Яңа бакчага мөдир итеп кабат Мәдинә Хәбибулхак кызы Закирова билгеләнә, тәрбиячеләре – Лилия Ринат кызы Хөснетдинова, Фәрдия Шамил кызы Гыйләҗева,






Балалар бакчасының эчке күренешләре.

кече тәрбияче – Әлфинур Габдулла кызы Вәлиева, аш-су әзерләүче – Гөлназ Фирдинант кызы Каюмова.

Бүгенге көндә бакча мөдире булып Ләйсән Ришат кызы Закирова эшли, тәрбияче – Ләйсән Айрат кызы Вафина, кече тәрбияче – Әлфинур Габдулла кызы Вәлиева, аш-су әзерләүче – Фәридә Фәрит кызы Закирова.

**Мәдинә Хәбибулхак кызы Закирова**, 1951 елның 10 сентябрендә Зеленодольск шәһәрендә туа. Әнисе – Бибихәнифә Гыйбадулла кызы, гомере буе бухгалтер булып эшли. Әтисе – Фәхретдинов Хәбибулхак Фәхретдин улы, Серго заводында 50 ел слесарь була. Мәдинә ханымның энесе – Ихсан, Казан авиация институтын тәмамлап, инженер була, хәзер лаеклы ялда, Казан шәһәрендә яши.



Мәдинә Закирова – гаиләдәге олы бала. Урта мәктәпне (1968), Зеленодольск медицина училищесын (1971) тәмамлый, фельдшер белгечлеге ала. Яшь кызны юллама белән Хәерби авылына җибәрәләр. 1971–1972 елларда – Хәерби бала тудыру йортында эшли, 1972–1974 елларда – Хәерби фельдшер-акушерлык пункты мөдире. 1974–1977 елларда Казан шәһәренең 3 нче балалар хастаханәсенең неврология бүлегендә процедура кабинеты шәфкать туташы булып эшли. 1976 елда Хәерби егете Закиров Гәрәйгә кияүгә чыга. Шулай итеп, язмыш аны тагын Хәербигә алып килә. Авылга кайткач, Мәдинә ханымга яңа һөнәр үзләштерергә туры килә. 1978–1995, 2000–2011 елларда ул Хәерби балалар бакчасы мөдире була. Оештыру сәләте, тырышлыгы аңа бу урында берегеп эшләргә мөмкинлек бирә. Ире белән ике кыз үстерәләр. Олы кызлары – Фәридә, 1978 елда туган, Лаеш авыл хуҗалыгы техникумын һәм Казан авыл хуҗалыгы институтын тәмамлап, бухгалтер белгечлеге ала. Казан шәһәрендә яши һәм эшли. Гаиләләрендә ике кызлары – Зарина һәм Амира үсә. Закировларның икенче кызлары – Зөлфия, 1981 елда туган, Казан дәүләт педагогия институтын инглиз һәм татар телләре буенча тәмамлый. Казан шәһәрендә яши һәм эшли. Шулай ук ике бала – Аделя һәм Марсельне үстерәләр.

Мәдинә Закирова бик сабыр холыклы кеше. Хәербидә аны бик яраталар, хөрмәт итәләр. Хәзер лаеклы ялда булса да, аның яныннан кеше өзелми. Яхшы киңәшләре белән дә булыша Мәдинә ханым. Сәламәтлек – иң зур байлык, аны сатып алып булмый. Кешеләргә, аеруча балаларга, көнне-төнне белми ярдәм күрсәтеп, гомерләрен саклап калган изге кеше ул.

# АВЫЛ КЛУБЫ

Колхозлашу чорында кулак дип табылып, йортлары тартып алынганнарның каралты-кураларын сүтеп һәм берләштереп, клуб төзиләр Хәербидә. Шунда ук китапханә ачыла. Китапханәдән бик күпләр файдалана. Клубта кайвакыт концертлар, төрле мәдәни-агарту чаралары үткәрелә. Хәерби клубы кич чыгучыларны туры мәгънәсендә дә агартып кайтара, чөнки аның стеналары һәм түшәме акбур белән буялган була. Клуб тимер мич белән җылытыла. Ләкин андый мичнең җылысы тормаганга, клубка йөрүче күп булмый. Халык күп җыелган көннәрдә, кеше җылысына тимер мич кызуы да өстәлеп, бу бина парлана. Түшәмнән өсләренә акбурлы тамчы тамып, кешеләр өйләренә чын-чынлап онга төшкән таракан кебек таралышалар.

Сугышка кадәр һәм бигрәк тә сугыш артыннан клубка кинофильмнар килә башлый. Бу авыл халкы өчен бик зур вакыйга була. Ул чакта электр булмаганга күрә, киноаппаратны кул белән әйләндерәләр. Киномеханик рус кешесе, ул үзенә булышкан малайны кинога бушка кертә. «Әйләндер! – дип әйтә белми,


1


2


3


4

1. Клуб бинасы. 2006 ел; 2. Яңа ел бәйрәме рухы; 3. «Уракчы кызлар» биюе. 1989 ел; 4. Концертта. Китапханәче Фәридә Шәйхиева җырлый. Баянда – Илсур Абдуллин.

«Әләндер», – ди. Шуңа күрә бу беренче киноларны Хәерби кешеләре «Әләндер» дип йөриләр. Вакыт узу белән авылга бензин белән эшли торган двигатель кайта, киноаппаратны шуңа тоташтыралар. «Әләндер» сүзе дә төшеп кала.

Беренче клуб «Алга» колхозы көче белән 1952 елда салына. Заманы өчен ул шактый зур бина була. Клуб салынуга эшләр гөрләп китми әле. Күп яшьләр борынгыча аулак өйләргә җыелуны артык күрәләр. Авылның активистлары, укытучылар аулак өйгә җыелган яшьләрне таратып йөриләр. Өй хуҗасына авыл советы штраф сала. Шулай итеп, яшьләрне акырынлап клубка ияләштерәләр. Анда лекцияләр, кичәләр, концертлар оештырыла. Кичләрен егетләр бильярд, домино, шашка уйныйлар. Кызлар биеп-җырлап күңел ачалар, газета-журналлар укыйлар.

Хәерби үзенең оста гармунчылары белән дан тота. Мингалиев Рәшит, Насыйбуллин Шамил, Вафин Хафиз, Гаязов Миңнулла, Миңнебаев Шамил,









1. Клуб бинасы ремонттан соң. 2019 ел. 2. Клуб ачылышына килгән авыл халкы; 3. Ремонттан соң клуб бинасын ачу тантанасы. Район җитәкчесе Илдус Зарипов һәм ТР Дәүләт җыр һәм бию ансамбле солистлары. 2019 ел, 11 октябрь; 4. Клуб ачылу тантанасыннан. Балалар чыгышы.

Миңнебаев Нәҗип, Сафин Нәҗип, Вафин Габделхаклар клубта гармунны чират торып уйныйлар, гармун берсенең кулыннан төшеп өлгерми, икенчесе ала. Клубтан таралгач, төркем-төркем булып урам әйләнеп җырлашып йөрү гадәте була. Һәр төркемдә – бер гармунчы. Ләкин гасыр уртасында да, 60–70 елларда да яшьләр урамда төн буе йөрмиләр. Сәгать 10–11 ләрдә инде һәркем (бигрәк тә кызлар) өйдә булырга тиеш. Бу язылмаган закон һәм аны барлык кеше үти.

Клуб мөдире булып Гәрәев Минвәли (1964 елга кадәр), Исмәгыйлева Наилә (1993 елга кадәр) эшли.

1985 елда авыл клубының иске агач бинасын сүтәләр һәм «Хәерби» совхозы акчасына Мәдәният йортының яңа бинасы төзелә. Яңа бинада 200 урынга исәпләнгән зур тамаша залы, дискотекалар һәм бию кичәләре үткәрү өчен аерым зал бар. Авыл китапханәсе дә шул ук бинада урнаша.

2019 елда клубка заманча капиталь ремонт ясала. Ул хәзер авыл күрке булып балкып, үзенә тартып тора.



Клуб ягыннан авылның өстән күренеше.

## АВЫЛ КИТАПХАНӘСЕ

1936 елның 2 августында Хәерби авылында китапханә ачыла. Беренче китапханәче Файзелхак исемле читтән килгән кеше була. Берничә елдан соң ул туган якларына кайтып киткәч, эшне Мөхәмммәтшина Сөембикә дәвам итә. Ул шулай ук озак эшләми, кияүгә чыгып, ире белән шәһәргә китеп бара. Алга таба китапханәдә авылның үз кешесе Сибиева Хәтирә Зиннәт кызы эшли башлый. Авылдашлары аны бары тик яхшы яктан истә калдыра. Аларның сөйләве буенча, ул чакта китапханәгә йөрүчеләр саны бик күп була. Алар арасында иң күп китап укучы Гарифулла Ярмиев (1886 елда туган) һәм аның бертуган сеңлесе Мөнәвәрә аерылып тора. Аларның әтиләре бик укымышлы кеше иде, дип сөйлиләр авылдашлары алар турында. Балаларына мондый сыйфат, күрәсең нәселдән күчкән. Революциягә кадәр үк алар бик күп газета-журналларга язылалар, танылган шәхесләр Солтан Габәши, Якуб Чанышев, Фатих Әмирхан белән аралашалар.

1960–1969 елларда китапханә белән Фатыйхова Сания Хәмәтхан кызы җитәкчелек итә, шул еллар эчендә читтән торып Алабуга мәдәният училищесының китапханә бүлеген тәмамлый, авылдашларының зур хөрмәтен яулый. Ул үз эшен шулкадәр яратып, бирелеп башкара ки, авыл халкы аны яратып, ышаныч белдереп, Хәерби авыл советы депутаты итеп сайлый. 1969 елдан Сания ханым авыл советына хисапчы булып күчә.

Алдагы елларда Хәерби китапханәсендә түбәндәге хезмәткәрләр эшли: 1969–1970 елларда – Сафина Зәйтүнә Галимҗан кызы; 1970–1974 елларда – Зәйнуллина Әлфия (Мамадыш районының Кирмән авылы кызы); 1974–1977 елларда – Хөсәенова Гөлсинә; 1977–1978 елларда Гарипова



1



2

Китапханә урнашкан биналар: 1. 1936–1970 еллар; 2. 1970–1986 еллар.



С.Фатыйхова.



Г.Хөсәенова.



Ф.Шәйхиева.

Фәрдия Шамил кызы; 1979–1980 елларда – Гыймадиева Сәрия Авкат кызы; 1980–1981 елларда – Хәсәнова Зилә Юмадил кызы.

1982 елның ноябрь аеннан Хәерби авылы китапханәсендә Шәйхиева (Миңгалиева) Фәридә Исхак кызы эшли башлый, ул бүгенге көнгә кадәр шул хезмәттә. Фәридә ханым дүрт ел иске китапханә бинасында эшли, ә 1986 елда авылда зур Мәдәният йорты ачыла, китапханә өчен анда 100 кв. м мәйдан бүленә. Китапханә яңа Мәдәният йортына күчә.

Китапхәнә төзелешенә «Хәерби» совхозы директоры Әхмәтҗанов Наил Насыйбулла улы һәм Әхмәтҗанов Альберт Дәүләт улы зур өлеш кертә.

Китапханә – авылда төп мәдәни агарту учагы. Фәридә Исхак кызы шуны яхшы аңлап эш итә, китапханәдә төрледән-төрле кызыклы чаралар: тематик-музыкаль, әкият, шигырь кичәләре, «Могҗизалар кыры» уеннары, төрле темалар буенча көч сынашулар, ярышлар, язучылар белән очрашу һ.б.ны әзерләп уздыра.

Авылда булган башка оешмалар белән китапханә тыгыз элемтәдә эшли. Китап укучыларга ягымлы мөнәсәбәт, якты, чиста, уңай шартлар халыкны китапханәгә тартырга, китап укуга кызыксыну уятырга ярдәм итә.

Туган якны өйрәнү буенча зур эшчәнлек алып барыла. Авылда «Туган




1986 елдан башлап китапханә урнашкан клуб бинасы.

як» исемле даими күргәзмә эшләп килә. Татар халкының тарихын, гореф-гадәтләрен өйрәнүдә, яшь буынны үз халкының мәдәнияты белән кызыксынуга тартуда күргәзмәнең роле бик зур. Хәерби авылы китапханәсе авылда уздырылган башка барлык чараларда да актив катнаша. Китапханә фонды төрле юнәлешләрдәге: җәмгыять белеме, математика, физика, химия, әдәбият, тарих, информатика, философия, сәламәтлек саклау, транспорт, төзелеш, сәнгать, дин һ.б. темаларга караган китапларны берләштерә. Биредә шулай ук чит ил һәм рус классик әдәбияты, совет чоры матур әдәбияты, татар һәм рус телләрендә татар әдәбияты, балалар әдәбияты, туган як тарихына багышланган китаплар, белешмә әдәбият белән танышырга була.

Бүгенге көндә китапханәдә барлыгы 12692 данә китап бар, шул исәптән татар телендә – 6218 данә, рус телендә 6474 данә китап әйләнештә йөри. Китапханәдә язучылар иҗатына, истәлекле даталарга багышланган китап күргәзмәләре, язучылар белән очрашулар, шәхси һәм төркемләп консультация бирүләр оештырыла. Авыл халкының белемен күтәрү, дөньяга караш киңәйтү буенча китапханәдә зур эшчәнлек алып барыла.



Китапханәдә уздырылган әдәби кичәләрдән күренешләр.

## XIV БҮЛЕК

## БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫ ЕЛЛАРЫ

Бөек Ватан сугышына Хәербидән 300 ләп ир-егет алына. Немец-фашист илбасарлары белән 1418 көн һәм төн дәвам иткән сугыш әүвәл иң гайрәтле ирләрне йота, аннары унсигезе тулган егетләрне чүпли башлый. Кара печатьле кәгазьләр дә көттерми. Хәерби авылы да үз тарихындагы иң фаҗигале көннәрне кичерә. Татарстаннан һәлак булган яки хәбәрсез югалган 350 меңнән артык сугышчы арасында Хәерби авылыннан да «Я кайтырбыз, я кайтмабыз, сау булыгыз, туганнар!» дип җырлап чыгып киткәннәрдән ике йөзгә якын кеше бар.

Авыл тормышы, колхоз эше хатын-кызлар, өлкәннәр, үсмер кызлар-егетләр кулына кала, кул арасына керерлек балалар да эш белән мәшгуль була. Бу чор балалары – балачаксыз калган балалар алар. Ләкин халык барыбер өметсезлеккә бирелми. Хатын-кызлар ирләр хезмәтенә җигелә. **Сәхбиева Гаян**, **Зарипова Разия**, **Шәрәпова (Кашапова) Сәлимә** тракторчылар булып, **Юнысова Фәйрүзә апа** ат җигеп эшли. Авылда калган бөтен халык Җиңүгә үзеннән өлеш кертим дип тырыша, җир дә сукалый, иген дә чәчеп үстерә, уңышын урак белән урып ала. Ашлык киптерү өчен сушилкалар булмау сәбәпле, ашлыкны колхозчылар үз өйләренә алып кайтып, мич башларында киптерәләр. Авыл укытучылары, агитаторлар халыкны фронт хәбәрләре белән таныштырып тора, клубта концерт, спектакльләр куела. Авылның яшь кызлары, киленнәре авыл советына җыелып йон эрлиләр, сугышчылар өчен бияләйләр, оекбашлар бәйлиләр. Йорт саен йөреп җыйган тиреләрдән бияләйләр тегәләр. Кызлар фронтовикларга хатлар язалар. «Кызыл Татарстан», «Татарстан комсомолы», «Татарстан колхозчысы» танк колонналарын төзү өчен Хәерби халкы акчалата зур өлеш кертә. Иң зур суммадагы акчаны **Хәмитов Садыйк һәм Хәйруллин Хабулла** гаиләсе бирә.



Бөек Ватан сугышында һәлак булганнар истәлегенә куелган һәйкәл.

## БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫНДА ҺӘЛАК БУЛГАННАР ИСЕМЛЕГЕ

1. **Абдрахманов Исмәгыйль Габдрахман улы**, 1906 елда туган; кызылармияче, 26 нчы укчы дивизиянең 349 нчы укчы полкы, 12.5.1944 тә һәлак булган; Ленинград өлкәсенең Сошихино районы Мокоры (Мокары) авылында җирләнгән. Әнисе – Абдрахманова Латифа.
2. **Абдрахманов Исхак Габдрахман улы**, 1902 елда туган; кызылармияче, 42 нче укчы полк.
3. **Абдрахманов Минвәли Габдрахман улы**, кызылармияче, төгәл булмаган мәгълүматлар буенча, 1943 елда госпитальдә үлгән.
4. **Абдуллин Гариф Ибраһим улы**, 1923 елда туган; кызылармияче, 24.03.1942 дә сугышка алына, 357 нче укчы дивизиянең 1192 нче укчы полкы, 19.11.1944 тә һәлак булган; Латвиянең Ладынц авылы, Вайнёде хәрбиләр каберлегендә җирләнгән.
5. **Абдуллин Гарифулла**, 1914 елда туган; кызылармияче, 24.07.1941 дә сугышка алына, 1941 елның декабрендә хәбәрсез югала.
6. **Булатов Мансур Шәйхи улы**, 1924 елда туган; кызылармияче, 73 нче диңгезчеләр укчы бригадасы, 26.2.1943 тә Ленинград өлкәсенең Тихвин шәһәрендә 1394 нче госпитальдә үлгән.
7. **Булатов Мингали Гайнетдин улы**, 1903 елда туган; кызылармияче, 358 нче укчы дивизия, 20.7.1942 дә һәлак булган; Смоленск өлкәсенең Демидово районы Семёновка (Селиваново) авылында җирләнгән.
8. **Вафин Гариф**, 1910 елда туган; кызылармияче, 15.05.1942 дә сугышка алына, 15.08.1942 дә хаты килү туктала, хәбәрсез югала. Хатыны – Вафина Бикә.
9. **Вафин Гарифулла Зиннәт улы**, 1926 елда туган; кызылармияче, 8.11.1943 тә сугышка алына, 30.08.1944 тә соңгы хаты килә, хәбәрсез югала. Әнисе – Вафина Мәсрүрә.
10. **Вафин Зиннәт**, 1897 елда туган; кызылармияче, 15.08.1941 дә сугышка алына, 1941 елның декабрендә хәбәрсез югала. Хатыны – Вафина Мәсрүрә.
11. **Вафин Харис**, 1902 елда туган; кызылармияче, 26.07.1941 дә сугышка алына, 1941 елның ноябрендә хәбәрсез югала. Хатыны – Вафина Газзә.
12. **Вафин Хәбер (Хәбир) Вафа улы**, кызылармияче. *Исемлек ахырындагы искәрмәне дә карагыз (188 б.).*
13. **Вафин Хәбибулла Зиннәт улы**, кызылармияче.

14. **Вәлиев Мөхәммәт Вәли улы**, 1923 елда туган; кызылармияче, 33 нче гвардия укчы дивизиясе, 30.7.1943 тә һәлак булган; Донецк өлкәсендә җирләнгән.
15. **Вәлиуллин Газизулла Камали улы**, 1903 елда туган; кызылармияче.
16. **Вәлиуллин Гатаулла**, 1913 елда туган; кызылармияче, 24.04.1941 дә хәрби хезмәткә алына, 1941 елның ноябрендә хәбәрсез югала. Хатыны – Вәлиуллина Рабига.
17. **Вәлиуллин Миңнәхмәт Вәлиулла улы**, кызылармияче.
18. **Вәлиуллин Хәбибулла**, 1909 елда туган; кызылармияче, 2.08.1941 дә сугышка алына, 1942 елның гыйнварында хәбәрсез югала. Хатыны – Вәлиуллина Каидә.
19. **Габидуллин Минвәли Габидулла улы**, 1910 елда туган; кызылармияче, 15.08.1941 дә сугышка алына (Юдино РХКнан мобилизацияләнә), 1942 елның декабрендә хәбәрсез югала. Хатыны – Габидуллина Хәдичә.
20. **Гайнуллин Минвәли**, 1902 елда туган; кызылармияче, 23.10.1942 дә 129 нчы госпитальдә үлгән, Калуга өлкәсенең Мосальск районы Воронино авылы янында җирләнгән. Хатыны – Гайнуллина Асылбикә.
21. **Гайсин Рәүф**, 1919 елда туган; кызылармияче, пулемётчы, 1939 елның сентябрендә хәрби хезмәткә алына (Казан шәһәренең Сталин РХКнан мобилизацияләнә), 1941 елның декабрендә хәбәрсез югала. Әнисе – Ибраһимова Мәүлия.
22. **Галәвов Мингали (Мингалим)**, 1918 елда туган; кызылармияче, 1269 нчы укчы полк, 16.6.1944 тә хирургия күчмә кыр госпиталендә яралардан һәлак булган; Карелиянең Тассонен авылында җирләнгән.
23. **Галиев Бәдретдин**, 1910 елда туган; кызылармияче, 24.07.1941 дә сугышка алына, 1942 елның декабрендә хәбәрсез югала. Хатыны – Галиева Мәликә.
24. **Галиев Вәли**, 1909 елда туган; кызылармияче, 27.06.1941 дә сугышка алына (Лаеш РХКнан мобилизацияләнә), 1941 елның декабрендә хәбәрсез югала.
25. **Галиев Габдулла**, кызылармияче, 17.10.1943 тә һәлак булган; Могилёв өлкәсенең Ползучи авылында җирләнгән.
26. **Галиев Зариф Гали улы**, 1909 елда туган; кызылармияче, 146 нчы укчы дивизиянең 608 нче укчы полкы, 12.4.1942 дә һәлак булган; Калуга өлкәсенең Барятино районы Фомино авылында җирләнгән. *Исемлек ахырындагы искәрмәне дә карагыз (188 б.).*
27. **Галиев Камил**, 1914 елда туган; кызылармияче.

28. **Галиев Солтанәхмәт Хәлил улы**, 1925 елда туган; сержант, 219 нчы укчы дивизиянең 710 нчы укчы полкы, 9.2.1945 тә һәлак булган; Латвиянең Елгава өязе, Ауце волосте, Кундзини авылында җирләнгән.
29. **Галиев Харис Гали улы**, 1906 елда туган; кызылармияче, 23.06.1941 дә сугышка алына (Новгород өлкәсенең Боровичи РХКнан мобилизацияләнә), 1941 елның октябрендә хәбәрсез югала. Хатыны – Хөсниҗамал Сибгатулла кызы.
30. **Галиев Хәйбрахман**, 1912 елда туган; кызылармияче, 24.07.1941 дә сугышка алына, 1941 елның декабрендә хәбәрсез югала. Хатыны – Галиева Әминә.
31. **Галиев Шәмсевәли,** 1912 елда туган; кызылармияче, 1941 дә сугышка алына, 1941 елның сентябрендә хәбәрсез югала. Хатыны – Галиева Сәхипҗамал.
32. **Галчев Вавил**, 1911 елда туган; кызылармияче. *Исемлек ахырындагы искәрмәне дә карагыз (188 б.).*
33. **Гарипов Әкбәр**, 1922 елда туган; кызылармияче. *Исемлек ахырындагы искәрмәне дә карагыз (188–189 б.).*
34. **Гарипов Әнвәр**, 1914 елда туган; кызылармияче, 845 нче укчы полк. *Исемлек ахырындагы искәрмәне дә карагыз (188–189 б.).*
35. **Гарипов Ибраһим Гариф улы**, 1920 елда туган; кызылармияче, 1939 елда хәрби хезмәткә алына, 1941 елның октябрендә хәбәрсез югала. Әнисе – Гарипова Фатыйма.
36. **Гарипов Мингали**, 1920 елда туган; кызылармияче.
37. **Гарипов Нури Гариф улы**, 1926 елда туган; кызылармияче, 8.11.1943 тә сугышка алына, 1944 елның декабрендә хәбәрсез югала. Әнисе – Гарипова Фатыйма.
38. **Гарипов Хабул Гариф улы**, Хәерби авылында туган; кызылармияче. *Исемлек ахырындагы искәрмәне дә карагыз (189 б.).*
39. **Гарифуллин Габдулла**, 1918 елда туган; кызылармияче, 1939 елда хәрби хезмәткә алына, 1941 елның ноябрендә хәбәрсез югала. Әтисе – Хәмидуллин Гарифулла.
40. **Гарифуллин (Хәмидуллин) Ибраһим Гарифулла улы**, 1920 елда туган; кызылармияче, 1940 елда хәрби хезмәткә алына, 1942 елның апрелендә хәбәрсез югала. Әтисе – Хәмидуллин Гарифулла.
41. **Гарифуллин Нигъмәт Гарифулла улы**, 1924 елда туган; кызылармияче, 1943 елда сугышка алына, 1944 елның августында хәбәрсез югала.
42. **Гатауллин Әхмәдулла Мифтах улы**, 1924 елда туган; кызылармияче, 881 нче танкка каршы артиллерия һөҗүм полкы, 2.8.1943 тә һәлак

булган; Орёл өлкәсенең Кромы районы Ломовец авылында җирләнгән.

43. **Гатауллин Һади**, 1908 елда туган; кызылармияче, 23.06.1941 дә сугышка алына (Боровичи РХКнан мобилизацияләнә), 1941 елның декабрендә хәбәрсез югала. Хатыны – Гатауллина Галия.

44. **Гатауллин Харис**, 1907 елда туган; кызылармияче, 26.08.1941 дә сугышка алына, 1942 елның гыйнварында хәбәрсез югала. Хатыны – Ибраһимова Хәбибҗамал.

45. **Гаязов Мингали Гаяз улы**, 1919 елда туган; кызылармияче, 1940 елның февралендә Дөбъяз РХКнан мобилизацияләнә, 1942 елның февралендә хәбәрсез югала.

46. **Гыйлаҗев Закир**, 1905 елда туган, кызылармияче, 26.08.1941 дә сугышка алына, 1942 елның февралендә хәбәрсез югала. Хатыны – Гыйлаҗева Галимә.

47. **Гыйлаҗев Харис Гыйлаҗ улы**, 1908 елда туган; сержант, 66 нчы аерым диңгез укчы бригадасы, 23.1.1943 тә һәлак булган; Волгоград өлкәсенең Песчанки авылында җирләнгән.

48. **Гыйлаҗев Хәмәт Гыйлаҗ улы**, 1917 елда туган; кызылармияче, 3.08.1941 дә сугышка алына, 1942 елның мартында хәбәрсез югала. Әтисе – Вәлиев Гыйлаҗ.

49. **Гыйлаҗев Хәмәтгали Саматгали улы**, 1902 елда туган; кызылармияче, 26.08.1941 дә сугышка алына, 1941 елның декабрендә хәбәрсез югала. Хатыны – Гыйлаҗева Гайшә.

50. **Гыймадиев Габдулла**, 1901 елда туган; кызылармияче, 26.07.1941 дә сугышка алына, 1942 елның февралендә хәбәрсез югала. Хатыны – Гыймадиева Миңсылу. *Исемлек ахырындагы искәрмәне дә карагыз (189 б.).*

51. **Гыймадиев Габидулла Гыймади улы**, кызылармияче. *Исемлек ахырындагы искәрмәне дә карагыз (189 б.).*

52. **Гыймадиев Әхмәтвафа**, 1913 елда туган; кызылармияче, Казан шәһәренең Ленин РХКнан мобилизацияләнгән, 81 нче укчы полк, 6.5.1942 дә 1029 нчы эвакогоспитальдә яралардан үлгән; Иваново (Владимир) өлкәсенең Гороховец районы Золино авылында җирләнгән. *Исемлек ахырындагы искәрмәне дә карагыз (189 б.).*

53. **Гыймадиев Закир**, 1897 елда туган; кызылармияче, 31.10.1941 дә сугышка алына, 1942 елның февралендә хәбәрсез югала. Хатыны – Гыймадиева Миңлегөл.

54. **Гыймадиев Ибраһим**, 1911 елда туган; кызылармияче, 24.06.1941 сугышка алына, 1941 елның ноябрендә хәбәрсез югала.

**55. Гыймадиев Каюм Гыймади улы**, 1905 елда туган; кызылармияче, 1941 елның августында сугышка алына (Казан шәһәренең Молотов РХКнан мобилизацияләнә), 1941 елның декабрендә хәбәрсез югала. Хатыны – Гыймадиева Н.

**56. Гыймадиев Шәмсевәли**, 1907 елда туган; Казан шәһәренең Идел буе РХКнан мобилизацияләнгән.

**57. Җаббаров Гариф Садыйк улы**, 1914 елда туган; кызылармияче, 28.10.1941 дә хәбәрсез югалган.

**58. Җамалиев Габдулла Җамали улы**, 1915 елда туган; кызылармияче, 31.05.1941 дә Казан шәһәренең Молотов РХКнан мобилизацияләнә, 1941 елның октябрендә хәбәрсез югала.

**59. Җамалиев Низам**, 1912 елда туган; кызылармияче, 29.05.1941 дә хәрби җыенга алына, 1941 елның июлендә хәбәрсез югала. Хатыны – Җамалиева Хәдичә.

**60. Җамалиев Шиһап Җамали улы**, кызылармияче.

**61. Закиров Гарифулла Закир улы**, 1911 елда туган; кызылармияче, 24.06.1941 дә сугышка алына, 1941 елның декабрендә хәбәрсез югала. Әтисе – Галиев Закир.

**62. Закиров Минвәли**, 1909 елда туган; кызылармияче.

**63. Заһидуллин Гарифулла Заһидулла улы**, кызылармияче.

**64. Зиннәтов Хәйбулла (Хабул)**, 1923 елда туган; кызылармияче, 3 нче армия составындагы 5 нче укчы дивизиянең 190 нчы укчы полкы, 1943 елның февралендә һәлак булган; Тула өлкәсенең Арсеньево районы Поляны авылында җирләнгән.

**65. Ибраһимов Гайса**, 1898 елда туган, кызылармияче, 12.02.1942 дә Казан шәһәренең Сталин РХКнан мобилизацияләнә, 1942 елның апрелендә хәбәрсез югала. Хатыны – Ибраһимова Мәүлия.

**66. Ибраһимов Касыйм Ибраһим улы**, 1916 елда туган, кызылармияче.

**67. Ильясов Габдулла**, 1912 елда туган, кызылармияче, 15.07.1941 дә Новгород өлкәсенең Боровичи РХКнан мобилизацияләнә, 1944 елның августында хәбәрсез югала.

**68. Исмәгыйлев Нуриәхмәт**, 1915 елда туган, кызылармияче.

**69. Ишмөхәммәтов Хәмит (Халит)**, 1900 елда туган, кызылармияче, 17 нче гвардия укчы дивизиясенең 52 нче гвардия укчы полкы, 7.12.1942 дә һәлак булган; Тверь өлкәсенең Вельск районы Романово авылында җирләнгән.

**70. Кашапов Минвәли**, 1909 елда туган; кызылармияче, 24.07.1941 дә сугышка алына, 1941 елның ноябрендә хәбәрсез югала. Хатыны – Миңҗиһан.

**71. Каюмов Габделхәй Каюм улы**, кызылармияче.

**72. Кәримов Давыт Кәрим улы**, кызылармияче.

**73. Кәримов Мингали Кәрим улы**, 1919 елда туган; кызылармияче, 24.07.1941 дә сугышка алына, 1941 елның декабрендә хәбәрсез югала. Хатыны – Хәмитова Маһинур.

**74. Кәримов Хәмәтгариф Кәрим улы**, 1915 елда туган, кызылармияче, 29.05.1941 дә хәрби җыенга алына, 1941 елның ноябрендә хәбәрсез югала.

**75. Латыйпов Каюм**, 1902 елда туган; кызылармияче. *Исемлек ахырындагы искәрмәне дә карагыз (189 б.).*

**76. Латыйпов Миңнулла**, 1902 елда туган; кызылармияче, Казан шәһәренең Сталин районы РХКнан мобилизацияләнә, 1941 елның октябрендә хәбәрсез югала.

**77. Лотфуллин Әхмәт**, 1919 елда туган; кызылармияче, 20.08.1942 дә 5 нче гвардия укчы дивизиясенең 4 нче медсанбатында үлгән.

**78. Мәрдегалләмов Әхәт**, 1918 елда туган; кызылармияче, 1939 елда хәрби хезмәткә алына, 1941 елның октябрендә хәбәрсез югала. Әнисе – Мәфтуха.

**79. Минбаев Гарифулла Миннебай улы**, 1922 елда туган; кызылармияче, 28.04.1941 дә хәрби хезмәткә алына, 1942 елның февралендә хәбәрсез югала. Әтисе – Гайнетдинов Миннебай.

**80. Минбаев Сөләйман**, 1912 елда туган; кызылармияче, 1941 елда сугышка алына, 1942 елның июнендә хәбәрсез югала. Хатыны – Минбаева Миңҗамал.

**81. Минбаев Хәбибулла**, 1918 елда туган, кызылармияче, 1939 елда хәрби хезмәткә алына, 1941 елның ноябрендә хәбәрсез югала. Әтисе – Гайнетдинов Миңнебай.

**82. Минвәлиев Әһлиулла Минвәли улы**, кызылармияче.

**83. Мингалиев Габдулла Мингали улы**, кызылармияче.

**84. Мингалиев Миңнулла Гали улы**, 1923 елда туган; кызылармияче, Казан шәһәренең Сталин РХКнан мобилизацияләнә, 138 нче укчы дивизиянең 295 нче артиллерия полкы; 2.08.1942 дә хәбәрсез югала. Әнисе – Мәвкия.

**85. Миңнебаев Хәбибулла (Хабул) Миңнебай улы**, 1917 елда туган; кызылармияче, 3 нче Украина фронты составындагы 5 нче аерым мотоукчы бригада, 8.3.1944 тә һәлак булган; Николаев өлкәсенең Новый Буг районы Софиевка авылыннан 3 км көнчыгышта җирләнгән. Әтисе – Сәйфетдинов Миңнебай.

**86. Миңнуллин Хәйрулла**, 1907 елда туган; кызылармияче, 6 нчы бригаданың 386 тау-инженерлар сапер батальоны, 7.10.1944 тә һәлак булган; Польшада, Балигруд, Лишна авылында җирләнгән.

**87. Миңнуллин Габидулла**, 1909 елда туган; кызылармияче, 29.07.1941 дә сугышка алына, 1941 елның ноябрендә хәбәрсез югала. Хатыны – Миңнуллина Фатиха.

**88. Миркиев Закир Шакир улы**, 1926 елда туган; кызылармияче, 47910 нчы кыр почтасы, 1945 елның гыйнварында хәбәрсез югала. Әнисе – Миркиева Шафирә, Агайбаш авылыннан.

**89. Мифтахов Җамал (Җамали) Мифтах улы**, 1908 елда туган; кызылармияче, 65 нче армия составындагы 354 нче укчы дивизиянең 918 нче артиллерия полкы, 30.6.1944 тә 443 нче медсанбатта яралардан үлә, Могилёв өлкәсенең Бобруйск районы Доманово авылында җирләнгән. Хатыны – Мифтахова Бәдриҗиһан.

**90. Мифтахов Кыям**, 1905 елда туган; кызылармияче, 243 нче укчы дивизиянең 912 нче укчы полкы, 21.1.1942 дә һәлак булган; Тверь өлкәсенең Ржев районы Назарово авылында җирләнгән.

**91. Мифтахов Минвәли**, 1909 елда туган; кызылармияче, 4.01.1942 дә һәлак булган; Ленинград шәһәрендә Пискарево каберлегендә җирләнгән.

**92. Мифтахов Мингали Мифтах улы**, 1902 елда туган, кызылармияче, 26.08.1941 дә сугышка алына, 1942 елның гыйнварында хәбәрсез югала. Апасы – Мифтахова Шәмсия.

**93. Мостафин Харис**, 1900 елда туган; кызылармияче, 26.08.1941 дә сугышка алына, 15.09.1942 дә әсирлектә һәлак була. Хатыны – Мостафина Мәдинә.

**94. Мөхәммәтҗанов Гариф**, 1898 елда туган; кызылармияче, 1941 елда сугышка алына, 1943 елның декабрендә хәбәрсез югала. Хатыны – Мөхәммәтҗанова Сәгъдәт.

**95. Мөхәммәтҗанов Шәриф**, 1912 елда туган; кызылармияче, 29.05.1941 дә сугышка алына, 1941 елның декабрендә хәбәрсез югала. Хатыны – Мөхәммәтҗанова Рабига.

**96. Мөхәммәтшин Минвәли**, 1898 (1896) елда туган; кызылармияче, 49 нчы укчы дивизиянең 222 нче укчы полкы, 12.9.1942 дә һәлак булган; Волгоград өлкәсенең Дубовка районы Сухая Мечетка балкасында җирләнгән.

**97. Мусин Гайса**, 1924 елда туган; кызылармияче, 62 нче армия составындагы 24 нче укчы дивизия, 31.7.1943 тә Луганск (Волгоград) өлкәсенең Куйбышев районы Димитровка авылында һәлак булган.

98. **Мусин Йосыф Муса улы**, 1923 елда туган; кызылармияче, 145 нче аерым укчы бригада, 21.1.1943 тә һәлак булган; Псков өлкәсенең Великие Луки районы Борщанка авылында җирләнгән.
99. **Насыйбуллин Габдулла**, 1914 елда туган; кызылармияче, 1941 елның маенда сугышка алына, 1941 елның декабрендә хәбәрсез югала. Хатыны – Насыйбуллина Сабира.
100. **Насыйбуллин Габдулла Насыйбулла улы** (Оборона министрлыгы документларында Наскин Абдулла дип тә бирелә), 1906 елда туган; кызылармияче, 25.05.1941 дә сугышка алына, 1943 елның декабрендә хәбәрсез югала. Хатыны – Насыйбуллина Гайнищамал.
101. **Насыйбуллин Гарифулла**, 1908 елда туган; кызылармияче, 26.07.1941 дә сугышка алына, 1942 елның октябрендә хәбәрсез югала. Хатыны – Насыйбуллина Фатыйма.
102. **Насыйбуллин Зариф Насыйбулла улы**, 1906 елда туган; кызылармияче, 1941 елның августында сугышка алына, 1941 елның декабрендә хәбәрсез югала. Татарстан Республикасы «Хәтер» китабының 23 томында (1 нче кисәк) түбәндәге мәгълүмат та бар: 56 нчы укчы дивизиянең 184 нче укчы полкы, 19.5.1942 дә яралардан үлгән; Мәскәү шәһәренең 1 нче Донской крематорие.
103. **Насыйбуллин Сафиулла (Сафа)**, 1904 елда туган; кызылармияче, 2.02.1943 тә сугышка алына, 1944 елның гыйнварында хәбәрсез югала. Хатыны Насыйбуллина Шәрифә.
104. **Насыйбуллин Хәмидулла Насыйбулла улы**, кызылармияче.
105. **Нигъмәтов Габдулла Нигъмәтулла улы**, 1904 елда туган; кызылармияче, 1941 елның августында Лаеш РХКнан мобилизацияләнә, 1942 елның мартында хәбәрсез югала. Хатыны – Зөһрә.
106. **Ногманов (Ибраһимов) Ибраһим Ногман улы**, 1900 елда туган; кызылармияче, 26.08.1941 дә сугышка алына, 1942 елның февралендә хәбәрсез югала. Хатыны – Мәгърифә.
107. **Ногманов Нигъмәт Ногман улы**, кызылармияче.
108. **Ногманов Сибгать Ногман улы**, 1920 елда туган; кызылармияче, 1940 елда хәрби хезмәткә алына, 1941 елның ноябрендә хәбәрсез югала. Бертуганы – Ногманов Закир.
109. **Ногманов Хөсәен Ногман улы**, 1923 елда туган; кызылармияче, 7.03.1942 дә сугышка алына, 1943 елның гыйнварында хәбәрсез югала.
110. **Нуриев Ибраһим Нури улы**, 1919 елда туган; кызылармияче, 25.11.1939 да хәрби хезмәткә алына, 1941 елның сентябрендә хәбәрсез югала. Әтисе – Мифтахов Нури.

**111. Нуруллин Габдрахман Нурулла улы**, 1905 елда туган; кызылармияче, 24.08.1941 дә Казан шәһәре Сталин РХКнан мобилизацияләнә, 1941 елның ноябрендә хәбәрсез югала.

**112. Нуруллин Зиннәт Нурулла улы**, 1913 елда туган; кызылармияче, 1939 елда хәрби хезмәткә алына, 1941 елның ноябрендә хәбәрсез югала. Бертуганы – Нуруллин Фатыйх.

**113. Рәхмәтуллин Ибраһим**, 1922 елда туган, 07.07.1943 тә һәлак булган. Курск өлкәсенең Тросна районы Никольское авылында җирләнгән.

**114. Рәхмәтуллин Хәбибрахман (Хәйбер) Рәхмәтулла улы**, 1924 елда туган; кызылармияче, 06717 нче хәрби часть, 24.08.1942 дә сугышка алына, 1944 елның декабрендә хәбәрсез югала. Әнисе – Яруллина Маһруй.

**115. Рәхмәтуллин Хәмәт (Мөхәммәт) Рәхмәтулла улы**, 1921 елда Хәерби авылында туган; кызылармияче, Казан шәһәреннән мобилизацияләнгән.

**116. Рәхмәтуллин Шафик Рәхмәтулла улы,** 1923 елда туган; кызылармияче, 1942 елда Югары Ослан РХКнан мобилизацияләнгән, 92 нче укчы дивизия, 23.3.1943 һәлак булган; Ленинград өлкәсендә җирләнгән. *Исемлек ахырындагы искәрмәне дә карагыз (190 б.).*

**117. Рәшитов Габдрахман**, 1919 елда туган; кызылармияче, 1939 елда хәрби хезмәткә алына, 1941 елның ноябрендә хәбәрсез югала. Әнисе – Рәшитова Гандәлиф.

**118. Сабиров Габдулла**, 1924 елда туган; кызылармияче, 70 нче гвардия танкка каршы аерым һөҗүм дивизионының 64 нче укчы полкы, 27.3.1943 тә һәлак булган; Ленинград өлкәсенең Мга (хәзер Кировск) районы Карбусель авылыннан 1 км төньяктарак җирләнгән.

**119. Сабитов Салих**, 1913 елда туган; кызылармияче.

**120. Садыйков Габдулла**, 1914 елда туган; кызылармияче, 10.01.1942 дә сугышка алына, 1942 елның июнендә хәбәрсез югала. Бертуганы – Садыйкова Фаизә.

**121. Садыйков Кадыйр**, 1919 елда туган; кызылармияче. *Исемлек ахырындагы искәрмәне дә карагыз (189 б.).*

**122. Садыйков Минвәли Садыйк улы**, 1909 елда туган; кызылармияче, 17 нче гвардия укчы дивизиясенең 52 нче гвардия укчы полкы, 1942 елның декабрендә һәлак булган; Тверь өлкәсенең Вельск районы Романово авылында җирләнгән.

**123. Садыйков Мирсәлим**, 1901 елда туган; кызылармияче, 15.08.1941 сугышка алына, 1942 елның гыйнварында хәбәрсез югала. Хатыны – Җәмилә.

**124. Сафин Вафа Сафа улы**, 1908 елда туган; кызылармияче, 2.09.1941 Казан шәһәренең Молотов РХКнан мобилизацияләнә, 1941 елның декабрендә хәбәрсез югала. Хатыны – Мөхәммәтшина Шәмсия.

**125. Сафин Габдулла (Габидулла)**, 1913 елда туган; кызылармияче, 29.06.1941 дә сугышка алына, 1941 елның ноябрендә хәбәрсез югала. Әтисе – Садыйков Гариф.

**126. Сафин Галимулла**, 1907 елда туган; кызылармияче, 15.08.1941 дә сугышка алына, 1941 елның декабрендә хәбәрсез югала. Хатыны – Сафина Җәмилә.

**127. Сафин Гәрәй Әхмәтвафа улы**, 1900 елда Хәерби авылында туган; кызылармияче, 1941 елның сентябрендә хәбәрсез югала. Хатыны – Сафина Мәгъсүмә.

**128. Сафин Гыйззәт**, 1910 елда туган; кызылармияче, 15.08.1941 дә сугышка алына, 1941 елның декабрендә хәбәрсез югала. Хатыны – Сафина Җәмилә.

**129. Сафин Әхмәт Сафа улы**, 1921 елда туган; кызылармияче, 13.07.1941 сугышка алына, 1941 елның ноябрендә хәбәрсез югала. Әтисе – Хөсәенов Сафа.

**130. Сафин Закир**, 1909 елда туган; кызылармияче. *Исемлек ахырындагы искәрмәне дә карагыз (190 б.).*

**131. Сафин Зәвир Шәриф (Сафа) улы**, кызылармияче, 2.12.1942 дә һәлак булган, Смоленск өлкәсенең Белый районы Демяхи авылыннан 900 м төньяк-көнчыгышта җирләнгән. Хатыны – Сафина Бикә.

**132. Сафин Ибраһим Сафа улы**, 1919 елда туган; сержант, 22.06.1944 тә һәлак була, Одесса өлкәсенең Зельцы районы Зельцы авылында җирләнгән. Хатыны – Мәгъсүмә.

**133. Сафин Исхак**, 1916 елда туган; кызылармияче, 204 нче укчы дивизиясенең 700 нче укчы полкы, 21.2.1945 һәлак булган; Латвиянең Лиепая шәһәре янындагы Юлес-Муйжа хуторында җирләнгән.

**134. Сафин Кадыйр**, 1912 елда туган; кызылармияче, 1941 елда сугышка алына, 1941 елның ноябрендә хәбәрсез югала. Хатыны – Нәбиһа.

**135. Сафин Миңнулла**, 1903 елда туган; кызылармияче, 29.06.1941 дә сугышка алына, 1941 елның октябрендә хәбәрсез югала. Хатыны – Сафина Мәдинә.

**136. Сафин Нури**, 1915 елда туган; кызылармияче, 26.07.1941 дә сугышка алына, 1941 елның декабрендә хәбәрсез югала. Хатыны – Сафина Һаҗәр.

**137. Сафин Садыйк Сафа улы**, 1919 елда туган; кызылармияче, 1 нче гвардия мотоукчы дивизиясенең 3 гвардия мотоукчы полкы, 1941 елның

декабрендә һәлак булган; Мәскәү өлкәсенең Наро-Фоминск районы Бекасово станциясендә җирләнгән. Әтисе – Әхмәтов Сафа.

138. **Сафин Сөләйман Сафа улы**, 1912 елда туган; кызылармияче, Казан шәһәренең Сталин РХКнан мобилизацияләнгән. Хатыны – Нуриева Зәкия.

139. **Сафиуллин Гата**, 1897 елда туган; кызылармияче, 12.11.1941 дә сугышка алына, 1942 елның мартында хәбәрсез югала.

140. **Сафиуллин Зиннәт Сафиулла улы**, кызылармияче.

141. **Сәлахов Закир Сәлах улы**, 1913 елда туган; кызылармияче, 18.03.1941 дә сугышка алына, 22.09.1941 дә һәлак була. Хатыны – Сәлахова Мәгъфүрә.

142. **Сәхбиев Шиһап Сәхбетдин улы**, 1914 елда туган; кызылармияче, 7 нче гвардия моторлаштырылган дивизиянең 23 нче гвардия укчы полкы, 18.5.1942 дә һәлак булган; Карелиядә, Лоухи станциясеннән 46 км да җирләнгән.

143. **Сибгатуллин Гарифулла Сибгатулла улы**, 1906 елда туган; кызылармияче, Калуга шәһәре, 10 нчы хәрби часть, 25.07.1943 тә сугышка алына, 1944 елның мартында хәбәрсез югала. Туганнан туганы – Кашапов Габдулла.

144. **Сибиев (Гарифуллин) Зәкәрия Гарифулла улы**, кызылармияче, Калинин өлкәсенең Ржев районында 16.08.1942 дә һәлак булган. Әтисе – Сибиев Гарифулла.

145. **Сөнгатуллин Минвәли Сөнгать улы**, кызылармияче.

146. **Төхвәтуллин Гайса Миннебай улы**, 1920 елда туган; кызылармияче, 23 нче танк дивизиясе, 1940 елда хәрби хезмәткә алына, 21.08.1941 дә Новгород шәһәре янында әсирлеккә эләгә, 8.02.1944 тә әсирлектә һәлак була. Әтисе – Төхвәтуллин Миннебай.

147. **Фәизов Барый Фәиз улы**, кызылармияче.

148. **Халитов Габделхәй**, 1921 елда туган; кызылармияче, 24.06.1941 дә сугышка алына, 1942 елның маенда хәбәрсез югала. Әнисе – Халитова Гайшә.

149. **Халитов Исмәгыйль**, 1908 елда Хәерби авылында туган; кызылармияче.

150. **Халитов Каюм Халит улы**, кызылармияче.

151. **Харисов Галиәхмәт Харис улы**, кызылармияче.

152. **Хафизов Вәгыйзь**, 1918 елда туган; кызылармияче, 7.10.1941 дә сугышка алына, 1943 елның мартында хәбәрсез югала. Әнисе – Ихсанова Хәдичә.

153. **Хәбибуллин Мингали**, 1914 елда туган; кызылармияче, 24.06.1941 дә сугышка алына, 1941 елның ноябрендә хәбәрсез югала. Хатыны – Хәбибуллина Миңҗамал.
154. **Хәйруллин Нури Хәйрулла улы**, кызылармияче.
155. **Хәлилов Хәбибулла (Хабулла)**, 1911 елда туган; кызылармияче, 1941 елда сугышка алына, 1941 елның ноябрендә хәбәрсез югала. Әтисе – Гайнуллин Хәлил.
156. **Хәлиуллин Гарифулла**, 1904 елда туган; кызылармияче, 1941 елда сугышка алына, 1942 елның февралендә хәбәрсез югала. Хатыны – Хәлиуллина Миңсылу.
157. **Хәлиуллин Гарифулла**, 1920 елда туган; кызылармияче, 9.10.1943 тә һәлак булган; Ленинград өлкәсенең Кириши районы Ирса авылыннан 3,5 км да җирләнгән. Хатыны – Менсулова Михта.
158. **Хәлиуллин Ибраһим**, 1899 елда туган; кызылармияче, 26.08.1941 дә сугышка алына, 1942 елның февралендә хәбәрсез югала. Хатыны – Хәлиуллина Җәмилә.
159. **Хәмзин Бари**, 1915 елда туган; кызылармияче, 15.08.1941 дә сугышка алына, 1941 елның декабрендә хәбәрсез югала. Хатыны – Хәмзина Фәрхи.
160. **Хәмзин Мингали**, 1906 елда туган; кызылармияче, 1941 елны сугышка алына, 1941 елның декабрендә хәбәрсез югала. Хатыны – Фәхерниса.
161. **Хәмидуллин Габдулла**, кызылармияче.
162. **Хәмидуллин Гарифулла Хәмидулла улы**, 1916 елда туган; кызылармияче, 1939 елда хәрби хезмәткә алына, 1943 елның декабрендә хәбәрсез югала. Әнисе – Мөлекова Фагыйлә.
163. **Хәмидуллин Закир**, 1906 елда туган, өлкән лейтенант, 1941 елда Башкортстан АССРның Куергазы РХКнан мобилизацияләнгән, 24.06.1944 тә һәлак булган. Белоруссия ССР, Витебск өлкәсенең Дубровно районы Волкочиково авылында җирләнгән.
164. **Хәмидуллин Зариф**, 1900 елда туган; кызылармияче, 24.07.1941 дә сугышка алына, 1941 елның ноябрендә хәбәрсез югала. Хатыны – Гайшәбикә.
165. **Хәмидуллин (Хәмитуллин) Зәйнәб**, 1902 елда туган; кызылармияче, 11.10.1941 дә Югары Ослан РХКнан мобилизацияләнә, 1942 елның гыйнварында хәбәрсез югала. Хатыны – Марсумя (Мәгъсүмә?).
166. **Хәмидуллин Зиннәт**, 1903 елда туган; кызылармияче, Казан шәһәре РХКнан мобилизацияләнгән, 1942 елда һәлак булган.

**167. Хәмидуллин Насыйбулла Хәмидулла улы**, 1913 елда туган; кызылармияче, 26.08.1941 дә сугышка алына, 1941 елның октябрендә хәбәрсез югала. Хатыны – Хәмидуллина Гаян.

**168. Хәмидуллин Хәбибул Хәмидулла улы**, 1924 елда туган, кызылармияче, 24.08.1942 дә сугышка алына, 1943 елның апрелендә хәбәрсез югала. Әтисе – Хәйруллин Хәмидулла. *Исемлек ахырындагы искәрмәне дә карагыз (190 б.).*

**169. Хәмидуллин Хәбибулла Хәмидулла улы**, 1923 елда туган; кызылармияче, 193 нче укчы дивизия, 4.3.1943 тә һәлак булган; Курск өлкәсенең Промклево авылында җирләнгән. *Исемлек ахырындагы искәрмәне дә карагыз (190 б.).*

**170. Хәмидуллин Шафик**, 1920 елда туган; кызылармияче, 651 нче танкка каршы артиллерия һөҗүм бригадасының 62 нче артиллерия полкы, 3.9.1942 дә һәлак булган; Волгоград өлкәсенең Крутенский хуторында җирләнгән.

**171. Хәсәнов Ибраһим Хәсән улы**, 1924 елда туган; кызылармияче, 86 нчы гвардия укчы дивизиясенең 260 нчы гвардия укчы полкы, 21.9.1943 тә һәлак булган; Запорожье өлкәсенең Лиденау хуторында җирләнгән. Әнисе – Зөләйха.

**172. Хәсәнов Фатих**, 1910 елда туган; кызылармияче, 7.07.1941 дә сугышка алына, 1942 елның декабрендә хәбәрсез югала. Хатыны – Хәсәнова Минҗиһан.

**173. Хөснетдинов Баһаветдин**, 1901 елда туган; кызылармияче, 26.08.1941 дә сугышка алына, 1941 елның декабрендә хәбәрсез югала. Хатыны – Гайниҗамал.

**174. Хөснетдинов Габдрахман Хөснетдин улы**, Хәерби авылында туган; кызылармияче.

**175. Хөснетдинов Минвәли Хөснетдин улы**, кызылармияче.

**176. Хөснетдинов Мингали Хөснетдин улы**, кызылармияче.

**177. Хөснетдинов Нәбиулла**, 1913 елда туган; кызылармияче.

**178. Хөснетдинов Низам Хөснетдин улы**, 1905 елда туган; кызылармияче, 270 нче укчы дивизиянең 975 нче укчы полкы, 12.7.1943 тә һәлак булган; Белгород өлкәсенең Белгород районы Кошлаково авылында җирләнгән.

**179. Хөснуллин Бикмулла Хөснулла улы**, кызылармияче.

**180. Хөснуллин Гарифулла**, 1914 елда туган; кызылармияче, 26.08.1941 сугышка алына, 1942 елның октябрендә хәбәрсез югала. Хатыны – Хакифә.

**181. Шакиров Хәмәтша**, 1903 елда туган; кызылармияче, 26.08.1941 дә сугышка алына, 1941 елда хәбәрсез югала. Кызы – Шакирова Хәдичә.

**182. Шәйхиев Зиннәт**, 1903 елда туган; кызылармияче, 18.01.1942 дә сугышка алына, 1942 елның декабрендә хәбәрсез югала. Хатыны – Мәхүб.

**183. Шәмиев Ибраһим**, 1905 елда туган; кызылармияче, 23.09.1941 дә сугышка алына, 1942 елның гыйнварында хәбәрсез югала. Хатыны – Шәмиева Мәсрүрә.

**184. Шәрәфиев Минвәли**, 1908 елда туган; кызылармияче, 26.08.1941 дә сугышка алына, 1943 елның декабрендә хәбәрсез югала. Хатыны – Шәрәфиева Гаян.

**185. Шәрәфиев Мингали**, 1920 елда туган; кызылармияче, 25.05.1942 дә сугышка алына, 1944 елның сентябрендә хәбәрсез югала. Әнисе – Шәрәфиева Миңсылу.

**186. Шәрәфиев Сәлахи Шәрәфи улы**, кызылармияче.

**187. Юнысов Ибраһим Юныс улы**, 1900 елда туган; кызылармияче, 25.06.1941 дә сугышка алына, 1942 елның гыйнварында хәбәрсез югала. Хатыны – Юнысова Асия.

**188. Юнысов Исмәгыйль Юныс улы**, 1905 елда туган; кызылармияче, 29.06.1941 дә сугышка алына, 1941 елның ноябрендә хәбәрсез югала. Әтисе – Галиәкбәров Юныс.

**189. Яруллин Тимергали**, 1924 елда туган; кызылармияче, 27 нче гвардия укчы дивизиясенең 74 нче гвардия укчы полкы, 1.02.1943 тә һәлак булган; Волгоград өлкәсенең Александровка авылында (Вишневая Балка поселогы) җирләнгән. Әнисе – Яруллина Әсмабикә. *Исемлек ахырындагы искәрмәне дә карагыз (189 б.).*

**190. Яруллин Фәрит Заһидулла улы**, 1914 елда туган; кече лейтенант, Казан шәһәренең Бауман РХКнан мобилизацияләнгән, 82 нче укчы дивизиянең 250 нче укчы полкы, 7.10.1943 тә һәлак булган; Белоруссия ССР, Витебск өлкәсенең Дубровно районы Новая Тухиня авылында җирләнгән.

**191. Яруллин Хәйрулла Ярулла улы**, 1900 елда туган; кызылармияче, Казан шәһәренең РХКнан мобилизацияләнгән.

**192. Яруллин (Рәхмәтуллин) Шәриф (Шәфигулла)**, 1923 елда туган; кызылармияче, Югары Ослан РХКнан мобилизацияләнгән, 92 нче укчы дивизиянең 22 нче укчы полкы, 07338 нче кыр почтасы, 23.3.1943 тә һәлак булган; Ленинград өлкәсенең Сестрорецк шәһәрендә җирләнгән. *Исемлек ахырындагы искәрмәне дә карагыз (190 б.).*

**193. Яруллин Мингали Ярулла улы**, 1913 елда туган; кызылармияче, Казан шәһәренең Сталин РХКнан мобилизацияләнгән.

**Искәрмә.**

Бөек Ватан сугышы китергән кайгы-хәсрәт, ул ясаган яра һәм җәрәхәт күпләрнең йөрәгендә әле һаман төзәлми, әле дә әрни. Ул әрнү сагыну-юксыну, горурлык булып буыннан-буынга күчә һәм халык хәтеренә әверелә бара. Сугыш тәмамланган елны туган бала инде сигезенче дистәсен ваклый. Яу кырыннан исән-имин кайткан ветераннар сафы сирәгәйгәннән-сирәгәя. Шулай булса да, әле һаман әтисеннән хәбәр көтеп яшәүчеләр бар. Юк, алар аның исәнлегенә өметләнми, һичьюгы газизләренең кайда, кайчан һәлак булуын, кайда җирләнүен белергә тели.

Хәерби авылында туып, төрле хәрби комиссариатлар аша мобилизацияләнгән, сугыш кырыннан кайтмый калган кешеләр исемлеген барлап чыктык. Фронтка киткәннәрнең сугышчан юлы, кайда һәлак булуы яки җирләнүе турында төрле чыганаклардан белергә мөмкин. Без шуларның берсенә – РФ Оборона министрлыгының «Мемориал» (www.obd-memorial.ru) сайтына мөрәҗәгать иттек. Әлеге сайтта сугыш елларында һәлак булган яки хәбәрсез югалганнар турында мәгълүмат тупланган, фронтка алыну, хәбәрсез югалу яки һәлак булу вакыты, кайда җирләнүе, туганнарының исемнәре күрсәтелгән. Ләкин, төгәлсезлекләр дә байтак. Мәсәлән, югарыдагы исемлектә Вафин Хәбер (Хәбир) Вафа улы дигән кеше бар. «Мемориал» сайтыннан аңа төгәл туры килә торган ачык мәгълүмат табылмады. Әмма андагы «Вафин Хайбрыль, 1916 елда Хәерби (документта – Карби) авылында туган, Столбище РХКнан мобилизацияләнгән, 164 нче укчы дивизия, 17.11.1943 елда һәлак булган, Белоруссия ССР, Витебск өлкәсендә, Дубровно районы Козьяны авылындагы туганнар каберлегендә җирләнгән» дигән юллар исемлектәге сугышчыга туры килә һәм бу кешенең чын исеме Хәбибрахман (Хәйбри) булырга тиеш.

Галиев Зариф (1909 елда туган) һәлак булганнар исемлегендә дә, исән кайтканнар исемлегендә дә бар. Чынлыкта исә Зариф абзый исән кайта, Хәерби мәктәбе директоры булып эшли. Сугыштан соң хатыны белән өч бала тәрбияләп үстерәләр.

Тагын бер кеше турында мәгълүмат: «Галчев Вавил, 1911 елда Лаеш районы Хәерби авылында (документта – д.Киребек) туган, Казан шәһәре Сталин РХКнан мобилизацияләнгән, 29.03.1944 елда һәлак булган, Эстония ССР, Ида-Вирумаа өязенең Кяреконна авылында җирләнгән». Бу кешенең дөрес исеме һәм фамилиясе башкача, мәсәлән, Галиев булырга мөмкин.

«Мемориал» сайтында исемлектәге Гарипов Әкбәргә (1922 елда туган) яки Гарипов Әнвәргә (1914 елда туган) туры килүе ихтимал булган ике төрле мәгълүмат табылды: «Гарипов Анхар, 1922 елда Хәерби авылында туган, 283 нче укчы дивизиянең 843 нче укчы полкы, 1653 нче хәрби часть, кызылар-

мияче, 14.12.1941 дә Тула өлкәсенең Дугнин районында хәбәрсез югалган». Икенчесе – «Гарипов Анбар, 1922 елда Хәерби авылында туган, 29.09.1941 фронтка алына, 1942 елның ноябрендә хәбәрсез югала. Әтисе – Садыйков Гариф».

«Хәтер» китабы мәгълүматлары буенча Гарипов Хабул Гариф улы Хәерби авылында туган. Сайтта ул табылмады, әмма анда «Гарипов Хәмидулла, 1912 елда Хәерби авылында туган, әсирлеккә эләккән, коткарылган» дигән мәгълүмат бар.



1941 елның ноябрендә хәбәрсез югалган Ибраһим Гыймадиев.

Исемлектәге Гыймадиев Габдулла һәм Гыймадиев Габидулла Гыймади улы икесе бер үк кеше булырга мөмкин.

Шуңа охшаш төгәлсезлекләр бик күп очрый. Авылның исеме дә төрлечә: Кирбы, Кирви, Хайрбий, Кирпи һәм башкача бозып язылган. «Гимаднев Ахмед Вофа»ны Гыймадиев Әхмәтвафа дип фаразларга кирәк.

1902 елда туган Латыйпов Каюмны эзләгәндә шулай ук ике төрле мәгълүмат килеп чыга. Беренчесе – «Лапынов Каюм, 1902 елда туган, Кирабинский авыл советы, 7 нче гвардия укчы дивизиясе, 30.03.1943 тә Ленинград өлкәсендә һәлак булган. Хатыны – Лапынова Рәхимә». Икенчесе – «Латыпов Каюн, 1902 елда туган, Кибе авылы, 397 укчы дивизия, 4.01.1943 Ленинград өлкәсендә һәлак булган». Латыпов Каюнның исеме Новгород өлкәсенең Поддорье районы (элек Ленинград өлкәсе составында булган) Масловский авыл советы, Самбатово туганнар каберлегендә мәңгеләштерелгән (анда ук җирләнүе турында төгәл мәгълүмат юк).

Садыйков Кадыйр турында ике төрле мәгълүмат табылды. Беренчесе – 1945 елның мартында хәбәрсез югалган, икенчесе – 17.09.1944 һәлак булган, җирләнгән урыны: Эстония ССР, Валгай өязенең Палу авылыннан 800 м көньяк-көнчыгышкарак.

Хөснетдинов Минвәли һәм Хөснетдинов Мингали исемлектә булсалар да, алар турында сайтта мәгълүмат табылмады. Әмма анда «Хуснутдинов Айнсалай һәм Хуснутдинов Минсалий дигән кешеләр бар. Икесенең дә мәгълүматлары туры килә: 1913 елда Хәербидә туганнар, 12.08.1942 дә һәлак булганнар.

Яруллин Тимергали, 1924 елда Хәербидә туган, кайда һәлак булуы һәм җирләнгән урыны да күрсәтелгән. Әмма «Мемориал» сайтында бу кешенең исәнлеге, 1965 елда Краснодар краеның Ейск районында яшәве турында мәгълүмат урнаштырылган. Андый хәлләр дә булган.



«Хәтер» китабыннан тагын бер мәгълүмат: «Пычев Гурьян Иванович, 1899 елда Хәербидә туган, кызылармияче, 7534 нче укчы полк, 18.4.1945 тә яралардан үлгән; 58 нче хирургия күчмә кыр госпитале (ХППГ 58), Польшаның Нирзица шәһәрендә җирләнгән». «Мемориал» сайтында аның Олы Кабан авылы кешесе булуы күрсәтелгән. Гурьян Ивановичның Рус Хәербие авылында туган булуы, шунлыктан туган урыны Хәерби дип күрсәтелү ихтимал.

1923 елда туган Рәхмәтуллин Шафик Рәхмәтулла улы һәм 1923 елда туган Яруллин (Рәхмәтуллин) Шәриф (Шәфигулла) икесе бер үк кеше булырга мөмкин, чөнки туган еллары, мобилизацияләнгән хәрби комиссариатлары, дивизия номеры, һәлак булган даталары туры килә. Икесе дә Ленинград өлкәсендә җирләнгән дип күрсәтелгән.

Ә менә 1907 елда туган Сафин Галимулла һәм 1910 елда туган Сафин Гыйззәт һәлак булган көннәре һәм хатыннарының исемнәре белән туры киләләр.

Сафин Закир, 1909 елда туган; кызылармияче, 375 нче укчы дивизиянең 1243 нче укчы полкы, 15.7.1943 тә һәлак булган, Курск өлкәсендә җирләнгән дип күрсәтелгән мәгълүмат бар. Әмма шундый ук кеше исән кайткан ветераннар исемлегендә дә күренә. Уйлавыбызча, ул Сафина (Шакирова) Гайшәнең ире булырга тиеш.

1924 елгы Хәбибул һәм 1923 елгы Хәбибулланың фамилияләре һәм аталарының исемнәре дә, һәлак булган еллары да туры килә. Әмма бу мәгълүматлар белән генә алар икесе бер үк кеше дип нәтиҗә ясап булмый.




Бөек Ватан сугышында һәлак булганнар истәлегенә куелган һәйкәл. 2017 ел.



ВОЕННОМУ КОМИССАРУ
Ленинского РВК, гор.КАЗАНЬ

Призванный в ряды РККА ГИМАДИЕВ Ахмед Вофа 1913 года рождения, проживающий-Тат.Республика, Столбищенский район, д.Кирби 6-го МАЯ 1942 года У М Е Р.
Причина смерти: ДВУХСТОРОННЕЕ КРУППОЗНОЕ ВОСПАЛЕНИЕ ЛЕГКИХ.
Труп похоронен на кладбище д.Золино, Ивановской области, Гороховетского района.
Командование 81-го ЗСП просит оказать содействие об ускорении назначения пенсии РАЙСОБЕСОМ семьи умершего.

НАЧАЛЬНИК ШТАБА ПОЛКА
К А П И Т А Н /Сатиан/

ЗАВДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
Техник Интендант 2 р. /Молочков/

1



М В С С С С Р Ф. № 4а

Управление по учету погибшего и пропавшего без вести рядового и сержантского состава

Наш. исх. № 6/7617-39618 „ “ 194 г.

Известите гр. Гимадееву (30) (фамилия, имя, отчество) проживающ.

что военнослужащий Солдат (должность, воинское звание)
Гимадеев Каюм (фамилия, имя и отчество)
уроженец ТАССР Столбищенского р-н д Кирбях
1905 года рождения, находясь на фронте, пропал без вести в декабре 1941 г.

Начальник 6-го отдела
полковник
(Кошкин)

ЦТ МВС СССР 1785—46

2

1. Кызылармияче Әхмәтвафа Гыймадиевның һәлак булуы турында Казан шәһәренең Ленин районы хәрби комиссариатына килгән хәбәр; 2. Кызылармияче Каюм Гыймадиевның фронтта хәбәрсез югалуы турында хәбәр.


Ком-р медроты
Гв. В/врач II ранг.
Александров

1216

Ком-р б-на
40 МСБ гв В/врач III р.

121

Рапорт

Доводим до Вашего сведения, что военно-служащий РККА, Латфуллин Ахмед рядовой 98 г.сп, призванный Столбищенск. РВК, б/п, родился в 1919 г. поступил из операционной в госпитальную 18-8-42-8[10] с диагнозом; Проникающее осколочное ранение в брюшную полость?
Слепое осколочное ранение правой ягодицы.
Больной операбельный.
Введено: физиологического раствора 700г, камфора по пульсу 20% 2гр, морфин по 1гр 2 раза в день.
Домашний адрес: Татарская АССР, Столбищенский р-н, д. Чирби, Латфуллин В.
Умер при падении сердечной деятельности 20-8-42-20[00]

Ком-р медроты
Гв. В/врач II р.

Ком-р госп. взв.
Гв. В/врач III ранг.

1. Кызылармияче Әхмәт Лотфуллинның яралары, дәвалау барышы һәм вафат булуы турында медсанбатта тутырылган белешмә.



ИЗВЕЩЕНИЕ

Ваш сын Гв. Кр-у 20 Гв. Стр. П.
муж, отец, сын, брат, должность, наименование части, воинское звание
Латыпов Каюм
фамилия, имя, отчество
уроженец Татар. А.С.С.Р. Столбищинский р-н Карабишск. с/с.
село, деревня, район, город, область
находясь на фронте, ~~пропал без вести~~ был убит 1.04.43.
время и место
Похоронен в районе д. Козлово Поддорского р. Ленинградской Обл.
Настоящее извещение является документом для возбуждения ходатайства о пенсии (приказ НКО СССР № ............)

Командир части Гв. Полковник
М. П. / Осадько/

Военный комиссар

Начальник штаба

ЦТ НКО 4215–42

1



Куда: Татар. А.С.С.Р.
полное наименование села, деревни, района, области и
Столбищинский р.
почтового отделения. Если город, наименование улицы, номер
Карабишск. с/с.
дома и квартиры
адрес получателя
Кому: Латыпову Фахиму
фамилия, имя, отчество получателя
От кого: Полевая Почта 03646
наименование части и ее почтовый адрес

2

1–2. Кызылармияче Каюм Латыйповның һәлак булуы турында килгән хәбәр.



Полевая почта
57803
2 Апреля 1943 г
№ 96

ПОЛУЧЕНО
29 05 1943 г.
Вход. № 354

Форма № 4
220

ИЗВЕЩЕНИЕ

Ваш брат гвардии Красноармеец 13/части Полев. почты 57803
муж, отец, сын, брат, должность, наименование части, воинское звание
Сабиров Абдул
фамилия, имя, отчество
уроженец Тат. АССР Столбищенского р-на дер Кирби
село, деревня, район, город, область
в бою за социалистическую Родину, верный воинской присяге, проявив геройство и мужество, был убит 27 Марта 1943 года
время гибели
похоронен: в лесу на просеке 1 км. Севернее дер. Карбусель
точный адрес места
Мгинского р-на Ленинградской обл.
погребения

Настоящее извещение является документом для возбуждения ходатайства о пенсии (приказ НКО СССР № 220)

Командир части капитан Жук

Начальник штаба капитан Шигин

Военный комиссар

М.П.

12.4.57 г. выдан дубликат матери.

Получила сестра 1.6.43 г.

1



полное наименование села, деревни, района, области и почтового отделения. Если город, наименование улицы, номер дома и квартиры
дер. Кирби
адрес получателя
Кому: Сабирову Гарифан
фамилия, имя, отчество получателя
От кого: 13/часть Полевая почта 57803

2



Народный Комиссариат Обороны Союза ССР
Военный Подвижной Госпиталь № 5201
29 июня 1944 г.
№ 95

Место для штампа части

вэс-м III
26.7.44 г.

90
Форма № 4в

ИЗВЕЩЕНИЕ

Ваш Муж, командир взвода 437 истр. противотанк. полка, сержант
муж, отец, сын, брат, должность, наименование части, воинское звание
Сафин Ибрагим Сафинович
фамилия, имя, отчество
уроженец с. Ипрби Столбищенского р-на г. Казань Тат АССР
село, деревня, район, город, область
находясь на фронте, заболел Отравление неизвестным ядом
наименование болезни
умер 22 июня 1944 г.
дата смерти
похоронен с. Зельцы Зельцского р-на Одесской обл. на общем кладбище
адрес и наименование места погребения

Настоящее извещение является документом для возбуждения ходатайства о пенсии (приказ НКО СССР № __________)

Начальник госпиталя
Майор м/с /Злонтин/
М. П.
Зав. медицинским делопроизводством
ст. лейтенант /Жмурик/

ЦТ НКО. 2551—43

3

1–2. Кызылармияче Габдулла Сабировның фронтта һәлак булуы турында бертуганы Гариф Сабировка килгән хәбәр; 3. Сержант, 437 нче танкка каршы полкның взвод командиры Ибраһим Сафа улы Сафинның госпитальдә үлүе турындагы хәбәр.


Место для штампа 14 XI 1943 ПОЛУЧЕНО

Форма № 4 362

583

**ИЗВЕЩЕНИЕ** 047.

Ваш муж красноармеец
(муж, брат, военное звание)

Халиуллин Гарифуллин
(фамилия, имя и отчество)

Уроженец Тат. А.ССР. Столбищенский р-н с Кирбинск
(область, район, деревня и село)

в бою за Социалистическую Родину, верный воинской присяге, проявив геройство и мужество, был

Убит 9. Октября 1943 г.
(убит, ранен, умер от ран)

похоронен на кладбище 3½ км. запад. дер. Ирса
(место похорон) Киришского р-на Ленинградск. обл.

Настоящее извещение является документом для возбуждения ходатайства о пенсии (приказ НКО СССР №________).

**Командир части** майор. /Зинченко/

М. П.


14/XI-43 г.

Получила жена Халиуллина

Кызылармияче Гарифулла Хәлиуллинның фронтта һәлак булуы турында килгән хәбәр.



Прилагаемые к анкете свидетельские показания должны быть оформлены и заверены РВК.

*Начальник управления генерал-майор* (*Шавельский*)

АНКЕТА

| | |
|---|---|
| 1. Фамилия, имя и отчество разыскиваемого. | Сибгатуллин Гарифулла Сибгатул[лович] |
| 2. Год рождения. | 1906 года |
| 3. Место рождения: область, р-н, с/совет, деревня, город. | дер. Кирби Столбищинского р-на Татарская АССР |
| 4. Каким военкоматом призван, когда, в какую часть и когда направлен. | Столбищинским РВК 25 июля 1943 года часть 10 30 июля 1943 г. |
| 5. Военное звание. | рядовой |
| 6. Занимаемая должность в Красной Армии. | стрелок |
| 7. Когда прекратилась письменная связь. | 18 марта 1944 года |
| 8. Воинский адрес по последнему письму. | г. Калуга часть 10 |
| 9. Где проживал до призыва: область, р-н, с/совет, деревня, город. | д. Кирби Столбищинского р-на Тат Республике |
| 10. Дополнительные данные о разыскиваемом: письма товарищей, сообщения з/ч., свидетельские показания и др. (приложить к анкете). | Нет. |



| | |
|---|---|
| 11. При наличии сведений о гибели, указать: где и когда (месяц, число, год) погиб, место похорон. | Никакого сведений не было и нет |
| 12. Кто разыскивает: фамилия, имя, отчество заявителя. | Кашапов Абдул Кашапович |
| 13. Родственное отношение заявителя к разыскиваемому: отец, мать, жена и т. д. | двоюродной брат |
| 14. Подробный адрес места жительства заявителя: область, р-н, с/совет, деревня, город. | д. Кирби Столбищинского р-на Тат. республика |
| 15. Личное заключение военкома по материалам: (Военнослужащий: погиб, умер, пропал без вести и т. д.). | пропал без вести |

16. Приложение:

15 мая 1946 г. Столбищенский Районный военком ст. лейт. ... (подпись военкома и печать)

ПРИМЕЧАНИЕ. Без подписи Военкома и печати документ не действителен.

Решение Управления по учету потерь

Хәбәрсез югалган кызылармияче Гарифулла Сибгатуллинның язмышын ачыклау өчен туганнары тарафыннан тутырылган анкета.



1 2 3 4 5 6 7 8 9 10 11 12 13 14 15 16 17 18 19 20 21 22 23 24 25

**Personalkarte I: Personelle Angaben**

Kriegsgefangenen-Stammlager: 302

Beschriftung der Erkennungsmarke Nr. 16497

Lager: St. 302

Des Kriegsgefangenen

Name: Tuchwatulin Тухватулин

Vorname: Kaisa Гайса

Geburtstag und -ort: 7.9.1920 d. Kirbi

Religion: Musulman

Vorname des Vaters: Minlikai

Familienname der Mutter: Galimowa

Staatsangehörigkeit: Tatarin

Dienstgrad: Soldat солдат

Truppenteil: 26 Panz. Div. Komp. usw.:

Zivilberuf: Zimmermann Berufs-Gr.:

Matrikel Nr. (Stammrolle des Heimatstaates):

Gefangennahme (Ort und Datum): Nowgorod 21.8.41

Ob gesund, krank, verwundet eingeliefert: gesund

Lichtbild

16497

Nähere Personalbeschreibung

| Größe | Haarfarbe | Besondere Kennzeichen: |
|---|---|---|
| 168 | ll | keine |

Fingerabdruck des rechten! Zeigefingers

Name und Anschrift der zu benachrichtigenden Person in der Heimat des Kriegsgefangenen

Tat ASSR
Stolbischtscheuski r-n d. Kirbi
Tuchwatulin Minlikai

Wenden!

Умер 8.2.44 г.

Т. АССР
Столбищенск. р-н
д. Карби
Тухватуллин Минлибай

Төхвәтуллин Гайса турында әсирлектә тутырылган карточка.

## ХӘБӘРСЕЗ ЮГАЛГАН СОЛДАТ

1941 елның 22 июне. Якшәмбе көн. Кояш чыгарга иртәрәк әле. Кешеләр тыныч йокыда. Бөтен табигать сихри тынлыкка чумган. Кайдадыр еракта чут-чут итеп сандугач сайравы гына ишетелә. Шушы тынлыкны бозып, кинәт көнбатыштан самолетлар гөрелтесе ишетелә. Шомлы үкерү тавышы көчәйгәннән-көчәя бара, кешеләр ни булганын аңлап бетергәнче йөзләгән, меңләгән хәрби самолетлар тыныч шәһәрләр һәм авыллар өстенә бомбалар яудыра башлый. Күпкатлы йортлар гөрселдәп авалар, күккә тузан болыты күтәрелә, коточкыч янгын башлана. Дөньяның асты өскә килгәндәй була. Урамнарда, юлда очраган бөтен нәрсәне вата-сыта килүче свастикалы танклар, бала-чаганың, аналарның ачынып елаган тавышлары, кан, үлем...

Тиздән радио туган илебезгә фашистлар Германиясенең хыянәтчел һөҗүме турында дәһшәтле хәбәр җиткерә. Бөек Ватан сугышы менә шулай башлана. Һәркем өчен дә авыр сынау еллары башланып китә.

Хәербигә сугыш башлану хәбәре шул ук көнне килеп ирешә. Шул көнне үк ир-егетләрне җыйнап сугышка ала башлыйлар. Авыл халкы аларны озатып кала. Озатучылар аларга бер теләк – дошманны тизрәк җиңеп кайтуны телиләр.


МВС СССР Ф. № 221
Управление по учету погибшего и пропавшего без вести рядового и сержантского состава
Военному комиссару Столбищенскому
Татар асар
(адрес)
По уточненным данным солдат
(должность, звание)
Мустафин Харис
(фамилия, имя и отчество)
Уроженец д Кирба 1900 года
(область, район, деревня)
рождения, призванный ________ райвоенкоматом
умер в германском плену „15" сентября 1942 г.
По нашим данным семья жена Мустафина М
Столбищенский р-н д Кирба
Замените семье выданное ранее извещение, а если семья не имеет извещения, то выдайте таковое согласно приказу НКО № 023—1944 г.
№ 92
„16" VIII 1947 г.
Начальник „I" отдела

1900 елда туган Харис Хәйрулла улы Мостафин да сугышка иң беренчеләрдән булып китә. Хатыны – Мәдинә Габделкәрим кызы (1906–1998) белән алты балалары була: Зөлфа (1927 елгы), Разия (1929 елгы), Сәлим (1932 елгы), Миңневәли (1935 елгы), Габдулла (1937 елгы), Миңнегәрәй (1940 елгы).


Personalkarte I: Personelle Angaben

Stalag IV B Mühlberg

Kriegsgefangenen-Stammlager: 304 (IV H)

gestorben am 15.9.42 i. Lager IV B

Beschriftung der Erkennungsmarke Nr. 154705 Lager: IV B Mühlberg

Name: Mustafin Мустафин

Vorname: Charis Харис

Geburtstag und -ort: 1900 Kirbi Stolbischtschenski. Kasan.

Religion: mohom.

Vorname des Vaters: Chejruli

Familienname der Mutter:

Gestorben im Lager IV B

Staatsangehörigkeit: UdSSR Tatare

Dienstgrad: Soldat

Truppenteil: Schütz. Reg. Komp. usw.: ?

Zivilberuf: Landarb. Berufs-Gr.:

Matrikel Nr. (Stammrolle des Heimatstaates):

Gefangennahme (Ort und Datum): 8.7.41 Kargapoly

Ob gesund, krank, verwundet eingeliefert: ges.

Lichtbild

Größe: 174 Haarfarbe: schwarz

Nähere Personalbeschreibung

Besondere Kennzeichen:

Fingerabdruck des rechten! Zeigefingers

Name und Anschrift der zu benachrichtigenden Person in der Heimat des Kriegsgefangenen

Frau Mustafina Medinae Tatrespublik, Stolbyschtschenskii raion dorfe Kirbi

Мустафина Медина. Тат. респ. Столбищенский р-н д. Кирби

Wenden!

умер 15.9.42

Des Kriegsgefangenen

gem. im Sammelschreiben v. 27.11.42 Stalag IV B Mühlberg

OKW-Befehl v. 10.1.40 bestätigt 28. MAI 1942

Вх. № 12969 –47

Beschriftung der Erkennungsmarke Nr. Lager: Name:

Архивлар һәм «Мемориал»[1] сайты материалларын карасак, Хәербидән сугышның башында ук алынган кешеләрнең барысының да диярлек хәбәрсез югалган дип язылганын күрәбез.

1941 елның октябрь аенда Мәдинә апага Харис абый турында хәбәрсез югалган дигән хат килеп ирешә. Андый хәбәрне кеше югалганнан соң 3 ай узгач кына җибәрә торган булалар. Чынында исә Харис Мостафин 8 июль көнне әсирлеккә эләгә. Бу турыда немецлар ягында тутырылган карточка мәгълүмат бирә.

Сугыш беткәннән соң Зариф исемле бер солдат, шулай ук Хәерби авылы кешесе, Мәдинә апага килеп Харис белән әсирлектә булуларын сөйли (бу истәлекләр Харис аганың оныгы Таһира ападан язып алынды). Аларны сугышка бернинди корал да бирмичә, үлгән солдатның коралын алырга кушып кертәләр. Чолганышта калалар, күбесе әсирлеккә эләгә. Хәербинекеләр 3 кеше була: Харис, Зариф, тагын берәү (Таһира апа ул кешенең исемен хәтерләми). Тоткыннарның барысын бергә бер кысан бинага тутыралар, алар берничә көн басып кына тора, чөнки тыгызлыктан чүгәләү дә мөмкин булмый. Аннары, хәлсезлектән берәм-берәм үлүләр башлангач, урын иркенәя төшә. Ашарларына ипи бирә һәм эшкә чыгара башлыйлар. Үтәү өчен һәр кешегә аерым план куела. Эшли алмаган, планын үтәмәгән кешене атып үтерәләр. «Без бик хәлсез, шешенгән хәлдә, аягыбызга баса алмыйбыз, ә Харис – нык, эшкә чыгып китә, безнең өчен дә план үти. Шуңа күрә үзебезгә биргән ипинең бер өлешен аңа ашатабыз», – дип сөйли Зариф. Ләкин көннәрдән бер көнне Харис эшкә киткән җиреннән әйләнеп кайтмый, алар аны башкача күрмиләр. Хәрби әсирләр картасында Харис Мостафинның 1942 елның 15 сентябрендә үлгәнлеге теркәлгән. Хатынына хәбәрсез югалды дигән хәбәр килгәннән соң бер елга якын вакыт узгач... Нинди булган аның үлеме, анысын инде ачыклау мөмкин түгелдер. «Озакламый безне килеп пленнан коткардылар», – дип сөйләгән Зариф абый Мәдинә апага.

Менә шундый язмыш. Мәдинә Габделкәрим кызы алты баланы ялгызы аякка бастыра. Ул 1998 елда вафат була, шуңарчы ирен көтә. «Үлмәгәндер, нишләп үлсен, аны тиз генә үтерә алмаслар», – ди торган була оныкларына.

Әсирлектә булган кешеләрнең карточкалары сугыштан соң илгә кайтарыла, шунлык белән бик күп кешеләрнең язмышлары ачыклана төшә. Әмма документларның күбрәк өлешен Америка гаскәрләре алып китә, хәзер алар АКШның Милли архивында саклана. Кайчан да булса бу документлар да кайтарылыр, мәгълүматлар Интернетка куелыр, сугышта хәбәрсез югалган күп кенә совет солдатларының язмышлары билгеле булыр дигән өмет бар.

---

1 https://obd-memorial.ru

## МИФТАХОВ ҖАМАЛ

Җамал Мифтах улы 1908 елда Хәерби авылында туган. Аңа да ут эченнән исән кайтулар насыйп булмый. Хатыны Бәдриҗиһан апа өч баласын ялгызы тәрбияләп үстерә, ә икесен сабый чакларында ук җир куенына салырга туры килә. Журналист, «Ватаным Татарстан» газетасының хатлар һәм социаль мәсьәләләр бүлеге мөдире Фәния Арслānованың Җамал Мифтахов турында язган мәкаләсен тәкъдим итәбез.

## ҖАМАЛ СОЛДАТ КАБЕРЕ

*Ф.Арсланова*

Күршебез Бәдриҗиһан апа ялгызы яшәде. Ишегалды тутырып сарыклар асрады. Балалары аны үзләренә торырга да дәшә. Бәдриҗиһан апа гына озак тарткалаша. Күзе начар күрә башлагач кына өен сатып, кызы Сафия, кияве Габдулла янына күченде. Безнең урамга аннан соң да килеп йөрде әле ул. Күрше карчыклар – әни, Сәгыйдә апа, Бәдриҗиһан апа бик дус булдылар, бер генә көн дә күрешмичә, хәл белешмичә калмыйлар иде. Бәдриҗиһан апаның нигезен ташлап китәргә теләмәвенең тагын бер сәбәбе: ул ире Җамалның фронттан кайтуын көткән. Аның яу кырында үлеп калуына ышанмаган. «Каберен күрмичә, мәңге дә ышанмаячакмын», – дигән. Олыгайган көндә дә матурлыгын җуймады Бәдриҗиһан апа: талчыбыктай нечкә, төз гәүдәле, горур кыяфәтле иде һәм бик уңган. Аның җил-җил атлап печән өюләре... Күрше-күлән, ничек барына да өлгерә, әллә женнәре булыша инде, дип әйтә иде. Сугыш ачысы күргән, ялгыз көе балалар үстергән, тормышны үзе тарткан тол хатын башкача яши дә алмыйдыр.

Сугыш тәмамлангач та кайтмый Җамалы. Берсендә Бәдриҗиһан апаларга бер ир-ат килеп керә. Ирең батырларча сугышты, Белоруссия җирендә һәлак булды, аны үз кулларым белән җирләдем, дип сөйли. Ә үзенең яшь хатынга күзе төшә. «Фашистлар синең ireңне үтерде, минем гаиләмне юк итте, әйдә, кушылыйк», – ди. Өметен өзмичә, Хәербигә берничә тапкыр килә. Бәдриҗиһан апа гына сүзендә нык тора: «Ә Җамал кайтып керсә, ни диярмен, аның күзләренә ничек карармын?..».

Бәдриҗиһан апа соңгы сулышына кадәр ире исән кайтыр дип көтеп яши. Ул 2004 елда 88 яшендә вафат булды. Бәдриҗиһан апаның кичерешләре, сагышлары, юксынулары балаларына, оныкларына да күчкән. Быел оныгы Рөстәмгә Белоруссиягә, Домановодагы туганнар каберлегенә барып, бабасы кабере янында дога кылырга да насыйп була. Шуның өчен дә Аллаһы Тәгаләгә

рәхмәт укый. «Әнинең хыялын тормышка ашыра алдым», – дип сөенә. Рөстәм Насыйбуллин Лаеш районында мәктәп балаларын дзюдо, самбо көрәшләренә әзерләүче тренер буларак билгеле. Укучыларны җае чыкканда Халыкара ярышларда да катнаштыра. Узган ел Калининград шәһәренә дә шул максаттан барып чыгалар. Ярышлар вакытында башка төбәкләрдән килгән спортчылар, тренерлар белән дә дуслашалар. Рөстәм абый Белоруссиядән килгән тренерга күптәнге хыялын сөйли. «Могилёв өлкәсенең Бобруйск районындагы Доманово авылында туганнар каберлегендә бабам җирләнгән. Шуны күреп кайтасы иде», – ди. Белоруссиядән килгән вәкил Рөстәмне Әфганстанда үлеп калган милиция капитаны В.Юртовка багышлап февраль аенда Лида шәһәрендә узачак халыкара ярышка чакыра. Рөстәм абый мөмкинлекләр табып, шунда юлга кузгала. Аннан Домановога 320 чакрым тирәсе. Ерак булса да, барып җитмәслек ара түгел. Гомер буе көткәнне кулдан ычкындырырга ярыймы соң?

«Мине Россиядән бабасы каберен эзләп килгән кеше буларак, бик яхшы каршы алдылар, яшәү, ашау-эчү бушка булды», – ди Рөстәм абый. Үзе белән Татарстан гербын, флагын, бабасының фотосурәтен, аны «Сугышчан батырлык өчен» медале белән бүләкләү турындагы боерык күчермәсен (әлеге медальгә Җамал Мифтаховка үлгәннән соң тәкъдим ителә. Кызганыч, ул әле туган якларга кайтып җитмәгән), күчтәнәчкә чәк-чәк алып бара. Элек туганнар каберлеген Доманово авылы җирлеге карап торган. Хәзер авылда нибары өч-дүрт йорт кына сакланып калган. Күрше Брожский авылындагы урта мәктәптә сугыш истәлекләреннән торган музей бар икән. Рөстәм абый бүләк-күчтәнәчләрен шул музейга тапшыра. «Бөек Ватан сугышы тәмамлануга җиде дистә елдан артык вакыт узды. Туганнар каберлеген онытмыйлар, кадерләп саклыйлар. Чиста, пөхтә, тере чәчәкләр утыртып чыкканнар», – ди Рөстәм абый.




Р.Насыйбуллин бабасы кабере янында.

... Ә башта әле аны өметсезлек чорнап ала. Лида шәһәреннән Бобруйск районына шактый мәшәкатьле юл узып килеп җитәләр, берничә мәртәбә машиналары ватыла. Доманово авылы кешеләре аларны каберлекләрнең инде

югалуын әйтеп каршылый. Авылдан ерак түгел генә концлагерь булган икән. Фашистлар тоткыннарны атарга пуля кызганып, башта үзләреннән чокыр казытканнар, аннары хәлсез солдатларны шунда төртеп төшереп, терелəй күмгәннәр. Бу урыннарда җир селкенеп, кычкыру, ыңгырашу авазлары яңгырап торган. Авылдагы хатын-кызлар төнлә солдатларны казып алып, коткармакчы була. Тик фашистлар ирек бирми, ут ачалар. Рөстәм бабасының концлагерьда түгел, госпитальдә үлүен әйткәч кенә аны туганнар каберлеге янына алып китәләр. «Көн кичкә авышты. Эңгер-меңгер вакыт булгангамы, бик нык дулкынлану аркасындамы, язуларны укый алмый башладым. Каберлекләр дә, исемлекләр дә берничә иде», – ди ул. «Әнә украиннар, руслар янында татар фамилиясе дә күренә», – дип чакыралар аны озата баручылар. Анда кызылармеец Мифтахов Җамали (документларда исеме төрлечә күрсәтелгән) Мифтахович, 1909 елгы дип язылган икән. Рөстәм абый тыела алмыйча елап җибәрә.

Җамал абзый 1944 елның 30 июнендә һәлак була. Бу вакытта Бобруйск районында бик авыр сугышлар бара. Архив мәгълүматлары буенча, Доманово авылыннан шул көннәрдә кичү оештыралар. Өч тәүлек эчендә җиде дивизияне, бу 66 мең кеше дигән сүз, 1500 орудие һәм минометны, җиде мең атны, меңнәрчә йөкне, йөзләрчә машинаны күчерәләр. Шунда Җамал Мифтахов бик каты яралана. Штабка кайтып җиткән солдатны госпитальгә салалар. Ул шунда яралардан үлә.

Сугышка киткәндә дүрт баласы кала аның. Бишенчесе – күптән көтелгән улы әтисе фронтка киткәч туа. Баланы бер тапкыр да күрмәсә дә, аның авырып ятканын ерактан тоя ата. «Улыбызны сакла, аның белән нидер булыр кебек», – дип яза бер хатында. Чыннан да, бала зәгыйфь булып туа, ике яшендә үлә. Авылга фронттан хатлар сирәк килә. Ә берсендә: «Син мине танымассың да инде, – дип яза. – Уң колагым өзелде, яңак сөягем янчелде». Шул көнне үк өеннән җавап хаты китә: «Без сине көтәбез, исән кайт кына...» Хәер, Җамал да шул сүзләрне юллый: «Сугыш бетүгә таба бара, мин бик тырышып сугышам, исән кайтырмын, көтегез!» Әйтерсең лә ул сүзләр Бәдриҗиһанның күңеленә гомергә уеп языла. Сафия апаның исендә дә әтисенең әнә шул сүзләре калган: «Көтегез, мин, кайтырмын!»

## МУСИННАР[1]

Хәерби авылында яшәүче Мусин Муса Гайшә исемле яшь һәм чибәр кызга гашыйк була. Яшьләр өйләнешәләр. Бу бәхетле гаиләдә биш ир бала туа.

1 Мәкаләне Зәлфирә Мингали кызы Мусина-Хәмидуллина язып тапшырды; авторлар тарафыннан редакцияләнде.

Олы уллары **Мингали Мусин** 18 яшендә сугышка китә. Сугыштан ул яраланып кайта, гомере буе тәнендәге кыйпылчыклар белән яши. Бер кулы гарип булып кала. Мингали абый күп еллар колхозда эшли. Тормыш иптәше Зөләйха апа белән тормышта үрнәк булырлык дүрт бала тәрбияләп үстерәләр. Мингали абый 67 яшендә вафат була.

Икенче уллары **Исхак Мусин** 1939 елда Кызыл Армиягә алына. Ул Хәрби-Диңгез Флотында хезмәт итә, ләкин туган ягына әйләнеп кайтканчы сугыш башлана һәм аңа 7 ел хезмәт итәргә туры килә. Исхак абыйның тормыш иптәше Минвафа апа гомере буе колхозда сыер савучы булып эшли, авыл советы депутаты итеп сайлана. Исхак абый белән алты бала тәрбияләп үстерәләр. Хәзерге вакытта Минвафа апа авылда Дилүс исемле улы гаиләсендә яши.

Өченче уллары **Якуп Мусин** да сугышка алынып, Хәрби-Диңгез Флотында хезмәт итә. Бервакыт Исхак Мусин хезмәт итә торган корабль яна башлый. Якуп абыйлар янган корабльне коткарырга киләләр. Шунда ике туган очраша, бер-берсен күреп алып, кочаклашып елашалар. Алар икесе дә сугыштан исән-сау әйләнеп кайта.

Дүртенче уллары **Йосыф Мусин** сугышта хәбәрсез югалган санала. Соңрак билгеле булганча, Мусин Йосыф 1943 елның 31 гыйнварында һәлак була, Псков өлкәсе Великие Луки районы Борщанка авылында җирләнә.

Бишенче уллары **Сөләйман Мусин** Казанда 40 нчы заводта эшли, көннетөнгә ялгап сугышка корал ясый.

Әлеге мәгълүматларны язып тапшырган Мусина-Хәмидуллина Зәлфирә Мингали кызы Мусина Гайшә турында: «Безнең әби нихәлләр түзде икән, дүрт баласы сугышта катнашкан бит!» дип искә ала.


Место для штампа

ПОЛУЧЕНО 1943 г.
Вход. №

ИЗВЕЩЕНИЕ

Ваш к.-ц. Мусин Юсуф Мусаг…
(муж, сын, брат, военное звание)
(фамилия, имя и отчество)
уроженец Тат. АССР … р-н.
(область, район, деревня и село)
находясь на фронте, … убит 31 января 1943 г.

Настоящее извещение является документом для возбуждения ходатайства о пенсии (приказ НКО СССР № ______)

Командир части
Военный комиссар

М. П.

ЦТ НКО. 2214—42



Столбище РХКның СССР Кораллы көчләренең һәлак булган һәм хәбәрсез югалганнарны исәпкә алу идарәсенә җибәрелгән хәбәре. 24.06.1947. № 44586.



Новгород өлкәсендәге Самбатово туганнар каберлеге. Хәерби авылында туган Латыйпов Каюмның исеме шушы каберлектә мәңгеләштерелгән.



НКО СССР
ПОЛЕВОЙ
Подвижный госпиталь
№ 2416
4 авгус 1943 г.
Часов

ПОЛУЧ
15 VIII
Вход. №

Извещение

Ваш сын гвардии красноармеец Габдурах
Ваш уроженец города Казань, Сталинск
Кировского ч. в бою за Социалисти
ну, верный воинской присяге, проявив
и мужество был ранен и умер от
43 годе. Похоронен 28 июля в с. Рябинк
Обоянского района, Курской области на к
кладбище.

Настоящее извещение является документом
для возбуждения ходатайства о пенсии (прика
№ 138

Абдрахманов Минвәли Габдрахман улының һәлак булу хәбәре.

# ФРОНТТАН ХАТЛАР

## НАСЫЙБУЛЛИН ЗАРИФ (1906–1941)

Зариф Насыйбуллин Бөек Ватан сугышында һәлак булган. Аның берничә хаты сакланып калган.

### Беренче хат

«Сезгә сагынычлы сәламнәремне җибәреп, сау-сәламәт яшәвәгезне теләп калам. Шулай ук әти-әнигә күп сәлам. Һәм барча туганнарга, күршеләргә күп сәлам.

Үзебез хәзергә авыллар (авылдашлар. – *Ред.*) белән бергә юлда барабыз. Озакламый Мәскәүгә җитәбез. Без Ленинградка барырбыз, ахыры. Сугышның нәкъ күзенә барабыз, Ходай хәерле кылсын. Барган көнне үк төнлә чәчләребезне алып, киемнәр бирделәр, мунчага керттеләр. Барлык нәрсәне яңаны бирделәр. Ул көндә утырып торырга вакыт булмады; аягүрә, тегендә, монда чабып үткәрдек. Төнге сәгать 12 ләрдә машиналарга төялеп чыгып киттек. Сәгать 9 ларда поездга төялеп чыгып киттек. Вагоннар тыгыз, 1 вагонда 25 әр кеше. Ашарга сухари бирәләр.

Станцияләрдә халык күп, тыгыз; эвакуацияләнеп күчеп кайтучы хатын-кыз, бала-чагалар белән тулы эшелоннарның хисабы юк. Балалар өчен бик кайгырма инде, исән булсак, бер кайтырбыз. Урнашкач, аралар булса, хат язарбыз. Барып җитүгә сугыш эченә үк илтеп тыкмасалар.

Машиналарда барганда
Яшь алды күзебезне,
Асыл туган илебезне
Бер кайтып күрербезме.

Ярый хушыгыз, сау булыгыз. Сәлам белән Зариф».

### Икенче хат

«Сезки гыйззәтле булып торучы Җәмиләгә, Мөнирәгә, Госманга, Рәисә белән Әсхәткә, Әти белән Әнигә бик күп сагынычлы сәлам. Хәзергә үзебезнең хәл шундый: моннан киткәч, августның 12 сендә машиналардан төшеп Смоленски шәһәренә якынайдык. Мәскәүгә кадәр алай түгел иде, Мәскәүне үткәч тынычсызга китә башлады. Ерактан ук гөрселдәгән тавышлар котны алып тора, фашист самолётлары һаман бомба ташлап тора, безгә дә менә-менә килеп ташлый дип бардык. Барып җитәрәк, өч самолёт килеп чыгып бомбить итте, ләкин безнең эшелонга эләкмәде. Бомбалар ташлаганда вагоннардан чыгып

читкә таралдык. Безнекеләр дошман самолётына орудиедән аттылар. Шул вакыт безнең самолётлар да килеп чыгып дошман самолётын куып киттеләр. Монда сугыш ерак түгел инде, атышлар бик ачык ишетелә. Үзебез хәзер 21ебез дә бергә урман арасында ятабыз. Озакламый без дә алгы сызыкка ук китәрбез, ахыры, хәерле булсын.

Ашарга-эчәргә бар әле. Мәскәүдән булкилар алган идек. 1 сум 80 тиенлек булкилар, ашап бетергесез. Юлда барганда 1 хат салган идем, бусы 2 нчесе. Моннан соң хат салырга да вакыт булмас инде. Бик якынайдык, Аллага тапшырдык. Озакламабыз керербез ахыры. Ашыгыч кына арада язып алдым. Ярый хуш. Зинһар, балаларны сакла, аларны борчый күрмә. Госман бик азапланмасын. Утыныңның барын як, аннан сайгавыңны сүтеп ягарсың.

Безнең өчен кайгырмагыз, ил өстенә килгән афәтне без кумыйча кем кусын. Илне саклау безнең төп бурычыбыз инде.

Ярый хуш, сау булыгыз.

31 август, 1941 ел».

**Өченче хат**

«Сезки гыйззәтле булып торучы Җәмиләгә бик сагынычлы сәлам, шулай ук Мөнирәгә, Госманга, Рәисәгә, Әсхәткә күп сәлам. Шулай ук әти-әнигә, Таифә апага, барча туганнарга, күршеләргә күп сәлам. Сәлам соңында сәламәт яшәвәгезне теләп калам.

Үзебез Смоленск урманында сугышка керергә команда көтеп торабыз. Без әлегә монда торып торабыз. Сугыш бездән 35 чакрым ары, атыш тавышлары яхшы ук ишетелеп тора. Без торган урман эчендә тынычлык юк, бары да киеренке хәлдә тора. Дошман самолётлары безнең өстән әледән-әле әйләнеп китәләр. Самолётлар ялгыз гына түгел, 5 әрләп, 10 арлап очып китәләр. Һаман бомбить итеп торалар. Котычкыч хәлләрне күреп яшибез. Лагерьдан чыкканнан бирле аяк киемнәрен салган юк, ашау-эчү дә бертөрле генә, үзегез беләсез инде. Моннан соң тиз генә хатлар язулар да булмас. Бу хатны каравылдан алышынгач кына язып алдым, ара юк, хәрби өйрәнүләр күп вакытны ала. Бу минем өченче хатым. Авыллар, хәзергә 5 ебез бергә. Авыллар турында сөйләшеп алабыз. Безнең хәзергә адресыбыз юк әле. Сафин Гәрәй дә минем янда. Адреслы хат килсә, һәрберебезгә дә шул адрес ярый.

Сез бик кайгырмагыз, сезгә сугыш ерак әле, без илебезнең ул кадәр үк эченә үтәргә ирек бирмәбез.

Тәрәзәләр сылап куеп борчылмый торыгыз. Безнең турында бик кайгыртмагыз, ашагыз һәм эчегез, булган агачларны саклап ятмагыз, ягыгыз. Исән-сау дошманны җиңеп кайтсак, бар да булыр. Әгәр бу хат барып ирешсә, авыл

хәлләрен язып сал. Хәзер сентябрь, көннәр суыкка бара, бакча бәрәңгеләрең-не йолкып-йолкып булса да алып тор. Бәрәңге икенче икмәк ич ул.

Ярый сау булыгыз, башка язардай сүзләр юк. Өйдән алып килгән акчаларыбыз бар әле. Акчага алырга бер нәрсә дә юк монда.

9 сентябрь, 1941 ел».

**Дүртенче хат**

«Сезнең барыгызга сагынычлы сәлам белән сәламәт яшәвәгезне теләп калам. Зиннәт абыйлар, Гәрәй абыйларга күп сәлам. Казандагы әби-бабайга һәм башкаларга сәлам.

Үзем хәзергә сау-сәламәт, сезләрне дә сәламәт булсын дип теләп калам. Безгә хәзер алгы сызык 20 км ераклыкта. Без алга ук җиткән идек инде. Алгы сызыкка 3 км калгач чигендек. Без монда өйрәнүләр үтәбез. Бу хатны кырда окоп казыганда гына язып салдым; көн саен, сәгать саен һөҗүмгә күчүне көтеп кенә торабыз. Әллә бүген таңда ук чыгарырлар, Аллага тапшырдык, хәерле булсын. Монда гыйбрәтләр күп: шәһәрләр, авыллар җимерелә, яна. Сугыш хәлен үзегез беләсез. Үзебез хәзергә 5 ебез бергә. Хәмәтгали, Закир, Зиннәт, Гәрәй һәм мин. Башкаларыбыз артта калды. Монда көннәр начар, яңгырлы. Бер яктан дошман самолётлары бомбить итеп китә, икенчедән юеш. Бу минем 5 енче хатым. Сездән хат өмет итеп булмый инде. Чөнки бер урында гына тормаганга күрә, адрес юк. Бүген монда, иртәгә әллә кая китеп барабыз. Бу хатны 22 сентябрьдә яздым. Сез бәрәңгеләр аласыздыр инде. Син ничек тә ала күр инде, без кайта алмабыз. Бик бәхет булса гына әйләнеп кайтырбыз. Без хәзер бик куркыныч астында гына торабыз, керми булмабыз ахыры. Үзебез үзебез инде, сезне бик кайгыртабыз. Балаларга да авырлык инде. Сугыш авырлыгы аларга да төште. Хәзер салкын вакыт җитте, бияләйләребез дә юк. Безнең хәл төрле яктан да яхшы түгел. Бу хәлгә дә түзәр идек инде, сугышның эченә үк кермәсәк. Ярый хуш сау булыгыз.

Сәлам белән Зариф.

22 сентябрь, 1941 ел».

Туганнарына, авылдашларына, фронтовик дусларына карата күпме җылы сүзләр әйтелгән бу хатларда. Әмма Зариф Насыйбуллинга туган авылына исән-сау әйләнеп кайтырга насыйп булмый. Дүртенче хат соңгысы була...

Россия Федерациясе Оборона министрлыгының «Мемориал» гомумиләштерелгән мәгълүматлар банкы сайты мәгълүматлары буенча Татарстан АССР-ның Столбище (хәзерге Лаеш) районы Хәерби авылында 1906 елда туган Насыйбуллин Зариф 1941 елның декабрендә хәбәрсез югалган.

## САФИН ГӘРӘЙ
## (1900–1941)

Гәрәй абый Сафин сугышның беренче көннәрендә үк фронтка алына һәм шул ук елны хәбәрсез югала. Аның фронттан язган хатлары сакланып калган.

### Беренче хат

«Сагынычлы хат башы.

Гәрәйдән Мәгъсүмәгә, Саимәгә, Зәкиягә, Хәйдәргә, әти белән әнигә, Сабирага барча семьялары белән сагынычлы сәлам. Һәм дә Нәбиһәгә барча балалары белән сәлам, Сара апага, Мәфтухага, абыйларга, Хәмәтгали абыйларга, Вафа җизниләргә, Гыйләҗевка, Ярмиевкә, Ризвановка барчасына бик күп сәлам.

Безнең хәлне сорасагыз, хәзергә сау-сәламәт, наратлык урманы арасында торабыз. Лагерьда вакытта мунчага кергән идек, шуннан бирле өс-башларны алыштырган юк. Бүген бу урманда икенче көн, башка урманга күчеп йөрибез. Уеннар уйнаганыбыз юк, мылтыклар алганыбыз юк. Тагын монда 2 сентябрьдә рота, взвод, батальоннарга бүлделәр. Хәмитов Исмай, Гатауллин Х., Шәрәфиев В. аерым. Сабитов Ф. үзенә аерым. Шакиров Х., Сафин М., Хәмәтгалиев З. – калганнарыбыз бер ротада. Мин, Насыйбуллин З., Вафин З., Ногманов Ибрай бер отделениедә. Бергә ашыйбыз, бергә ятабыз. Әле кайчан сугышка барасыбыз билгеле түгел. Белеп булмый, бүген кирәк булса, бүген чыгарып җибәрәләр. Бу өч көндә яңгырлар тукталып тора, кояш кыздыра. Монда игеннәрне яхшы җыялар. Сездә ничектер. Яхшы итеп җыярга карагыз, киләчәктә ашарга кирәк булыр. Исән-сау кайтсак, безгә дә кирәк булыр. Авыл җирендә шундый сөйләүләр була. Герман килә, фәлән дә төгән дип. Бер дә куркырга ярамый. Тагын әллә ничә ел сугыш булса да, герман анда барып җитәчәк түгел. Колхозда армый-талмый эшләргә карагыз, без дә монда тырышачакбыз. Зарифтан Җәмиләгә һәм барча балаларына сәлам. Без өйдән чыкканнан бирле һаман агач төбендә кунабыз. Без Смоленская областьта, Мәскәүдән 300 чакрым чамасы арттарак ятабыз. Сугышны кайсы кеше 100, кайсы кеше 60–70 чакрым ераклыкта, ди. Дөрес итеп әйтүче юк. Кайсы кеше Смоленск бездә ди, кайсы немецларда ди. Без газеталар алганыбыз юк. Сау булыгыз! Хәзергә без сау-сәламәт, сезне дә сәламәт дип белеп калабыз. Исәнлектә кайтып күрешүне теләп калам. Без хәзер мондагыңа күндек инде, өйдәге шикелле йөрибез.

4 сентябрь, 1941 ел».

## Икенче хат

«Хат башы. Мәгъсүмәгә бик сагынычлы күп сәлам. Саимәгә бик сагынычлы күп сәлам. Зәкиягә бик сагынычлы сәлам. Әти белән әнигә, Сабира белән Галимҗанга сәлам. Һәм дә Нәбиһә белән балаларга сагынып сәлам. Мәфтуха апаларга балалары белән сәлам. Һәм дә барча тирә-күршеләргә, дус-ишләргә, безне сораганнарның барчасына аермыйча сәлам. Һәм дә Ризванов Габдрахманга барча семьясы белән аермаенча сәлам.

Безнең хәлне сорасагыз, без хәзергә сау-сәламәт, сезләрне дә сау-сәламәт дип беләбез. Мин хәзер пулемётный командада, пулемёттан атарга өйрәндем. Хәзер уеннарны бетердек. Авыллардан Хәмәтгали, Зариф, Закир, Зиннәт 4 се бергә. Алар да барыбер хәзер безнең белән бер тирәдә йөриләр. Озакламый Смоленск өлкәсенә китәбез әле без. Безнең гаскәр немецлардан кире алган шәһәрдән ерак түгел генә.

Бу хатны 22 сентябрьдә яздым. Ярый сау булыгыз. Исәнлектә кайтып күрешүне теләп калам. Фронтка чыгып китәбез.

22 сентябрь, 1941 ел».


МВС—СССР

Ф. № 4а

245

Управление по учету погибшего и пропавшего без вести рядового и сержантского состава

Наш. исх. № 6/08494-445 86с „___“ ______ 194__ г.

Известите гр. Садрину М пор № 63 (фамилия, имя, отчество), проживающ.

что военнослужащий солдат (должность, воинское звание) Садрин Фарай (фамилия, имя, отчество) уроженец ТАССР Апастовский р-и с Хирби 1900 года рождения, находясь на фронте, пропал без вести „___“ сентябре 1941 г.

Начальник 6-го отде[ла] полковник (Кошкин)

ЦТ МВС СССР 4346-46

Сугышчы дистә еллардан соң аның хатларын ятлардан кемнәрдер укыр дип, әлбәттә, уйламаган. Шуңа күрә ул туганнарына һәм якыннарына күп санлы сәламнәрен тапшырып, гади тел белән, ачыктан-ачык яза. Солдатка туган авылы тормышының иң вак көнкүреш нечкәлекләре дә кызыклы була. Язган хатларында Гәрәй абый гаиләсен фашистлар беркайчан да аның авылына барып җитмәячәк дип тынычландыра.

Югалтуларны ачыклаучы документлардан күренгән мәгълүматлар буенча, Татарстан АССРның Столбище (хәзерге Лаеш) районы Хәерби авылында 1900 елда туган Сафин Гәрәй 1941 елның сентябрендә хәбәрсез югалган.

## ХӨСНЕТДИНОВ НИЗАМ
## (1905–1943)

### Беренче хат

«Безки Кызыл Армия сафында хезмәт итүче улыгыз Низамнан газиз әнкәмә, әткәмә бик сагынып, бик саргаеп бик күптин күп сәлам. Улларым Зәкәрия белән Габдуллага бик саргаеп, бик сагынып, бер генә мәртәбә булса да күрәсем килеп күптин күп сәлам. Шулай ук улым Миңлегалигә бик күп сагынычлы сәлам. Туганнарга, тирә-күршеләргә дә һәркайсына аермаенча бик күп сәлам. Исән-сау кайтып күрешүне теләп калам. Үзем хәзергә исән-сау, сезне үлеп беткәнсездер дип беләм, чөнки бер хәбәрегезне дә белмим, хатыгызны алганым юк. Әллә хат язмыйсыз инде. Посылка сала алмассыз микән. Бик салкын, җылы оекбаш һәм бияләйләр сала алмассызмы. Оекбашлар яңа булмаса да ярар. Ярый хуш, сау булыгыз».

### Икенче хат

«Безки Кызыл Армия сафында хезмәт итүче туганың Низамнан Маһруй белән Миңлевәлигә бик сагынып, бик саргаеп, бик күптин күп сәлам. Һәм дә исемнәрен оныткан барча балаларыңа күп сәлам. Әни белән мәхрүм булып йөрүче улларыма сәлам. Сәлам соңында исән-сау кайтып күрешүне теләп калам. Хәзергә исән-сау әле, немецлар белән бик каты көрәшәбез. Безгә Мәскәүдән Сталиннан гвардейский исеме бирелде. Без, гвардеецлар, фашистларны көн саен кырып торабыз. Немец бездән кача, тиздән бетереп кайтырга уйлыйбыз. Башка язардай сүзем юк. Посылкагызны ала алмадым. Хәзергә тамак тук: ит, май, аракыларга кадәр бирәләр. Шулай да салкыннан бармаклар бераз өшеде. Маһруй, син безнекеләрне караш инде, ни эшләп торалар икән. Мин Столбищега семьяга ярдәм итү турында язу җибәргән идем, колхоз ярдәм итәр диләр. Миңлевәли карасын әле шунда. Шушы адрес белән хат язып

карагыз, күчмәсәк, бәлки алырбыз. Безнекеләрне зинһар ташламагыз, карый күрегез. Хатны 29 январьда яздым. Бәлки язларга кайтып булмас микән.

29 январь, 1943 ел».

Хатның һәр юлында туганнарына, якыннарына, туган авылына карата ярату сизелә. Низам абый аеруча үзенең уллары турында борчыла, чөнки аларның инде әниләре дә бу вакытта исән булмый. Шул ук вакытта туганнарын да ашау ягы әйбәт дип тынычландыра. Сугыш кырыннан Столбище военкоматына гаиләсенә булышлык сорап хат язганын күрәбез. Бу аның сугышта да кайгыртучан гаилә башлыгы булып калуын күрсәтә.

Татарстан АССРның Столбище (хәзерге Лаеш) районы Хәерби авылында 1905 елда туган, 270 нче укчы дивизиянең 975 укчы полкы кызылармиячесе Хөснетдинов Низам 1943 елның 12 июлендә һәлак булган. Белгород өлкәсенең Шебекино районы Кошлаково авылында җирләнгән.



## БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫ ВЕТЕРАННАРЫ

Исемлек «Хәтер китабы» редакциясе чыгарган «Алар илгә Җиңү алып кайтты» китабыннан алынды һәм үзгәртелми бирелде («Они вернулись с Победой». Лаишевский район Республики Татарстан. – Казань: «Книга Памяти», 2011. – 469 с.). Кызганыч, бүгенге көндә Хәерби авылы сугыш ветераннары арабызда калмады.

**Абдуллин Габделхак Габдулла улы**, 1924 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1942 елда мобилизацияләнгән, гвардия ефрейторы, 1946 елда демобилизацияләнгән. Кызыл Йолдыз, II дәрәҗә Ватан сугышы орденнары кавалеры. 19.5.2005 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Абдуллин Гәрәй Абдулла улы**, 1909 елда туган, яшәү урыны: Петровский авылы. 1941 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1945 елда демобилизацияләнгән. 16.4.1972 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Абдуллин Насыйбулла**, 1914 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1941 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1946 елда демобилизацияләнгән. 10.1.1988 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Әхмәтшин Дәүләтша Әхмәтша улы**, 1898 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1939 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1945 елда демобилизацияләнгән. 3.12.1961 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Әхмәтшин Мәҗит Заһидулла улы**, 1912 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. Рядовой, 1945 елда демобилизацияләнгән.

**Әхмәтшин Усман Әхмәтша улы**, 1910 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1939 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1945 елда демобилизацияләнгән. 26.1.1972 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Әхмәтшин Хабулла Әхмәтша улы**, 1916 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1941 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1945 елда демобилизацияләнгән. 22.3.1975 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Билалов Низам Билал улы**, 1926 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1944 елда мобилизацияләнгән, ефрейтор, 1950 елда демобилизацияләнгән. 16.12.1990 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Вәлиуллин Абдулла**, 1900 елда туган. 1941 елда мобилизацияләнгән, рядовой, укчы, 1946 елда демобилизацияләнгән.

**Вәлиуллин Абдулла Вәлиулла улы**, 1907 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1943 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1946 елда демобилизацияләнгән. 22.2.1973 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Вәлиуллин Гарифулла Вәлиулла улы**, 1896 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1942 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1943 елда демобилизацияләнгән. 6.2.1971 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Вәлиуллин Гатаулла Вәлиулла улы**, 1897 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1941 елда мобилизацияләнгән, 1945 елда демобилизацияләнгән. Ике Кызыл Йолдыз ордены кавалеры.

**Вәлиуллин Нури Вәлиулла улы**, 1924 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1942 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1945 елда демобилизацияләнгән. 1.3.1954 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Вәлиуллин Фатыйх Вәлиулла улы**, 1904 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1941 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1945 елда демобилизацияләнгән. 17.10.1988 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Вәлиуллин Шәвәли Зиннәт улы**, 1919 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1941 елда мобилизацияләнгән, сержант, 1946 елда демобилизацияләнгән. 6.3.1993 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Вәлиуллин Шафик Вәлиулла улы**, 1916 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1943 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1946 елда демобилизацияләнгән. 12.7.1997 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Вафин Гариф Вафа улы**, 1893 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1941 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1945 елда демобилизацияләнгән. 17.4.1962 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Вафин Гарифулла Вафа улы**, 1920 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1941 елда мобилизацияләнгән, ефрейтор, 1946 елда демобилизацияләнгән. 20.3.1997 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Вафин Фатыйх Вафа улы**, 1913 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. Рядовой, 1945 елда демобилизацияләнгән. 18.9.1958 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Вафин Хабулла Мөхәммәтҗан улы**, 1905 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. Рядовой, 1945 елда демобилизацияләнгән.

**Вафин Һади Закир улы**, 1913 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1941 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1945 елда демобилизацияләнгән. 19.7.1972 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Вафин Хәмәтхан Вафа улы**, 1915 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1941 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1946 елда демобилизацияләнгән. II дәрәҗә Ватан сугышы ордены кавалеры. 28.9.1999 вафат. Хәерби авылында җирләнгән.

**Габидуллин Габдрахман Габидулла улы**, 1924 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1942 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1945 елда демобилизацияләнгән. 17.7.1978 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Гайнетдинов Салихҗан Гайнетдин (Әхми) улы**, 1915 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1941 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1945 елда демобилизацияләнгән. Кызыл Йолдыз ордены кавалеры. 5.10.2001 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Гайнетдинов Сәлах Әхмәт улы**, 1916 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. Старшина, 1946 елда демобилизацияләнгән.

**Галиев Фәез**, 1914 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. Рядовой, 1945 елда демобилизацияләнгән.

**Галиев Абделхак Гали улы**, 1922 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1941 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1945 елда демобилизацияләнгән. 12.10.1971 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Галиев Габдрахман**, 1897 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. Рядовой, 1945 елда демобилизацияләнгән.

**Галиев Габдрахман (Гаптри) Хәмәтгали улы**, 1927 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1944 елда мобилизацияләнгән, гвардия рядовое, 1951 елда демобилизацияләнгән. 3.1.2007 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Галиев Габдулла Мөхәммәтгали улы**, 1905 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1941 елда мобилизацияләнгән, 1944 елда демобилизацияләнгән. 1958 елда вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Галәвов Галләм Галәү улы**, 1919 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1939 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1946 елда демобилизацияләнгән. II дәрәҗә Ватан сугышы ордены кавалеры. 7.7.1994 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Галәвов Минвәли Галәү улы**, 1926 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1943 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1945 елда демобилизацияләнгән. 22.6.1989 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Гарипов Газизулла Гарифулла улы**, 1910 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1942 елда мобилизацияләнгән, 1945 елда демобилизацияләнгән. 10.3.1994 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Гарипов Кыяметдин Гыймади улы**, 1925 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1943 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1948 елда демобилизацияләнгән.

**Гарифуллин Абдулла Гарифулла улы**, 1924 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1942 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1956 елда демобилизацияләнгән. I дәрәҗә Ватан сугышы ордены кавалеры. 27.10.1991 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Гатауллин Гариф Гатаулла улы**, 1924 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1942 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1945 елда демобилизацияләнгән. 17.12.1966 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Гатауллин Нургали**, 1925 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. Рядовой, 1946 елда демобилизацияләнгән.

**Гаязов Бәдретдин Гаяз улы**, 1910 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1941 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1945 елда демобилизацияләнгән. 26.10.1961 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Гаязов Гарифулла Гаяз улы**, 1921 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1939 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1946 елда демобилизацияләнгән. 29.5.1999 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Гыйлаҗев (Хисиев) Зариф,** 1900 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1941 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1945 елда демобилизацияләнгән. Эш урыны: «Алга» колхозы, колхозчы.

**Гыйлаҗев Мингали**, 1913 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. Рядовой, 1945 елда демобилизацияләнгән.

**Гыймадиев Минвәли Гыймади улы**, 1908 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1943 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1945 елда демобилизацияләнгән. 22.9.1964 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Гыймадиев Сафа Гыймади улы**, 1921 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1941 елда мобилизацияләнгән, ефрейтор, 1945 елда демобилизацияләнгән. III дәрәҗә Дан ордены кавалеры. 22.3.1980 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Ермиев (Ярмиев) Гарифулла Гатаулла улы**, 1890 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1941 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1945 елда демобилизацияләнгән. 10.7.1980 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Ермиев (Ярмиев) Фарук Гарифулла улы**, 1924 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1942 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1947 елда демобилизацияләнгән. 4.4.1989 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Ермиев (Ярмиев) Абдулла Гарифулла улы**, 1916 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1939 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1945 елда демобилизацияләнгән. 2.4.1954 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Закиров Әнвәр Закир улы**, 1926 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1943 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1945 елда демобилизацияләнгән. 19.10.1991 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Закиров Исхак Закир улы**, 1924 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. Сержант, 1947 елда демобилизацияләнгән.

**Закиров Мингали Закир улы**, 1918 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1936 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1945 елда демобилизацияләнгән. Кызыл Йолдыз ордены кавалеры. 13.6.1983 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Җаббаров Нури Харис улы**, 1925 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1942 елда мобилизацияләнгән, сержант, 1946 елда демобилизацияләнгән. 28.9.2000 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Зарипов Зариф Гатаулла улы**, 1897 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1941 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1945 елда демобилизацияләнгән. 22.9.1977 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Зарипов Касыйм Зариф улы**, 1924 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1942 елда мобилизацияләнгән, кече сержант, 1947 елда демобилизацияләнгән. 4.6.1964 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Зарипов Хәмәтсадыйк Хәмәтсадыйк улы**, 1920 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1942 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1946 елда демобилизацияләнгән. 20.4.1960 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Кәримов Закир Кәрим улы**, 1903 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1939 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1945 елда демобилизацияләнгән. 25.4.1981 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Кашапов Абдулла Кашаф улы**, 1924 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1941 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1945 елда демобилизацияләнгән. 17.12.1986 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Кашапов Вафа Кашаф улы**, 1910 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1941 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1946 елда демобилизацияләнгән. Кызыл Йолдыз ордены кавалеры. 23.9.1976 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Кашапов Галләм Кашаф улы**, 1917 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1942 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1946 елда демобилизацияләнгән. 14.6.1990 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Кашапов Зариф Кашаф улы**, 1921 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1941 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1946 елда демобилизацияләнгән. 1.7.1992 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Кашапов Ибраһим Кашаф улы,** 1906 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1942 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1945 елда демобилизацияләнгән. 23.7.1986 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Кашапов Шәфигулла Кашаф улы**, 1919 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1939 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1946 елда демобилизацияләнгән. Кызыл Йолдыз ордены кавалеры. 16.10.1980 вафат, Хәерби авылында җирләнгән.

**Маликов Ибраһим Малик улы**, 1913 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1941 елда мобилизацияләнгән, старшина, 1947 елда демобилизацияләнгән. 7.7.1974 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Мәннапов Әһлулла Мәннаф улы**, 1913 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1941 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1946 елда демобилизацияләнгән. 29.4.1986 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Минбаев Нури Миңнебай улы**, 1923 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1941 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1945 елда демобилизацияләнгән. Өч Кызыл Йолдыз ордены кавалеры. 20.8.2002 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Миңгалиев Исхак Миңгали улы**, 1926 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1943 елда мобилизацияләнгән, ефрейтор, 1946 елда демобилизацияләнгән. 24.6.1982 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Миңнуллин Гыйззәт**, 1911 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. Рядовой, 1945 елда демобилизацияләнгән.

**Мусин Исхак Муса улы**, 1919 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1941 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1945 елда демобилизацияләнгән. 28.7.1975 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Мостафин Нургали Хәмәтгали улы**, 1925 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1942 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1946 елда демобилизацияләнгән. 12.12.1988 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Мөхәммәтҗанов Зариф Мөхәммәтҗан улы**, 1906 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1941 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1945 елда демобилизацияләнгән. 14.6.1992 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Мөхәммәтҗанов Зиннәт Хәмәтҗан улы**, 1915 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1941 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1946 елда демобилизацияләнгән. 17.12.1993 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Мөхәммәткәримов Ибраһим**, 1903 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. Рядовой, 1945 елда демобилизацияләнгән.

**Насыйбуллин Закир Насыйбулла улы**, 1919 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1939 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1946 елда демобилизацияләнгән. 22.4.1999 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Насыйбуллин Әнвәр Насыйбулла улы**, 1923 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1941 елда мобилизацияләнгән, гвардия рядовое, 1945 елда демобилизацияләнгән. 31.1.1982 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Насыйров Хабулла Хәсән улы**, 1919 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1939 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1945 елда демобилизацияләнгән. 29.8.1970 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Нигъмәтов Хабулла Нигъмәт улы**, 1907 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1942 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1946 елда демобилизацияләнгән. 13.6.1967 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Ногманов Закир Ногман улы**, 1909 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1941 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1945 елда демобилизацияләнгән. 30.11.1991 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Ногманов Зиннәт Ногман улы**, 1903 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1939 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1946 елда демобилизацияләнгән. 22.8.1984 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Нуруллин Кадыйр Нурулла улы**, 1909 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. Столбище РХКнан мобилизацияләнгән, 28.10.1971 вафат булган, Казан шәһәрендә җирләнгән.

**Нуруллин Фатыйх Нурулла улы**, 1914 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1941 елда Столбище РХКнан мобилизацияләнгән, рядовой, минометчы. 4.2.1950 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Ризванов Габдрахман Ризван улы**, 1903 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1942 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1946 елда демобилизацияләнгән. 5.1.1983 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Ризванов Мәгъсүм Габдрахман улы**, 1927 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1944 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1951 елда демобилизацияләнгән. 29.6.2013 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Сабитов Фәйзрахман Сабит улы**, 1906 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1942 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1946 елда демобилизацияләнгән. 24.2.1983 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Садыйков Ашыйгали**, 1906 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. Рядовой, 1945 елда демобилизацияләнгән.

**Салихов Зиннәт Гыйлаҗ улы**, 1923 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. Рядовой, 1945 елда демобилизацияләнгән.

**Сәлахов Абдулла Сәлах улы**, 1917 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1942 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1946 елда демобилизацияләнгән. 3.8.1996 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Сәлахов Абдулла Таҗи улы**, 1917 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1939 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1946 елда демобилизацияләнгән. 2.8.1996 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Сәлахов Ибраһим Сәлах улы**, 1908 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1941 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1943 елда демобилизацияләнгән. 3.1.1978 вафат, Хәерби авылында җирләнгән.

**Сәлахов Нурми Мифтах улы**, 1924 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1942 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1947 елда демобилизацияләнгән. 18.10.1995 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Сафин Галимҗан Сафа улы**, 1920 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1942 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1946 елда демобилизацияләнгән. 18.1.1990 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Сафин Закир Сафа улы**, 1909 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1941 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1945 елда демобилизацияләнгән. 20.8.1996 вафат булган, Әзәрбайҗанның Баку шәһәрендә җирләнгән.

**Сафин Зиннәт Сафа улы**, 1919 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1941 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1946 елда демобилизацияләнгән. 27.1.1980 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Сафин Зиннәтулла Сафа улы**, 1919 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1939 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1945 елда демобилизацияләнгән. 10.9.1980 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Сафин Ибраһим Сафа улы**, 1905 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1942 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1946 елда демобилизацияләнгән. 12.5.1969 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Сафин Миңнегали Сафа улы**, 1919 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1939 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1948 елда демобилизацияләнгән. 27.7.1978 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Сафин Мөхәммәт Сафа улы**, 1921 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. Гвардия ефрейторы, 1946 елда демобилизацияләнгән.

**Сафин Хәйдәр Сафа улы**, 1916 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1939 елда мобилизацияләнгән, ефрейтор, 1945 елда демобилизацияләнгән. 1.1.1965 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Сафин Харис Сафа улы**, 1911 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1939 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1945 елда демобилизацияләнгән. 29.2.1996 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Сәхбиев Ибраһим Сәхби улы**, 1922 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. Өлкән сержант, 1946 елда демобилизацияләнгән.

**Сибгатуллин Абдулла,** 1924 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. Рядовой, 1946 елда демобилизацияләнгән.

**Сибиев Гарифулла Сибгатулла улы**, 1896 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1941 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1945 елда демобилизацияләнгән. 6.1.1982 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Сибиев Зиннәт Сибгатулла** улы, 1892 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1941 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1946 елда демобилизацияләнгән. 12.9.1965 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Хәбибуллин Зәйнулла Хәбибулла улы**, 1906 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1939 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1948 елда демобилизацияләнгән. 24.12.1976 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Хәйбуллин Зиннәт Хәйбулла улы**, 1898 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1941 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1946 елда демобилизацияләнгән. 8.4.1977 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Хәлилов Леонид Хәсән улы**, 1922 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. Рядовой, 1946 елда демобилизацияләнгән.

**Хәлилов Сибгать Хәлил улы**, 1918 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1941 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1945 елда демобилизацияләнгән. 1.6.1967 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Хәлиуллин Хабулла**, 1898 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. Рядовой, 1945 елда демобилизацияләнгән.

**Хәмәтҗанов Салих Әхмәтҗан улы**, 1924 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1942 елда мобилизацияләнгән, өлкән сержант, 1945 елда демобилизацияләнгән. 25.8.1997 вафат булган, Казан шәһәренең Мирный посёлогында җирләнгән.

**Хәмидуллин Вәли**, 1905 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. Рядовой, 1946 елда демобилизацияләнгән.

**Хәмидуллин Абдулла Хәмидулла улы**, 1924 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1942 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1945 елда демобилизацияләнгән. 6.4.1957 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Хәмидуллин Вәли Хәмидулла улы**, 1898 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1941 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1948 елда демобилизацияләнгән. 6.12.1983 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Хәмидуллин Гарифулла Хәмидулла улы**, 1892 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1941 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1945 елда демобилизацияләнгән. 19.9.1969 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Хәмитов Садыйк Хәмит улы**, 1903 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1937 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1946 елда демобилизацияләнгән. 9.1.1982 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Харисов Гәрәй Харис улы**, 1925 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1943 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1946 елда демобилизацияләнгән. 20.11.1990 вафат булган, Атабай авылында җирләнгән.

**Хәсәнов Гәрәй Хәсән улы**, 1924 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. Гвардия кече сержанты, 1947 елда демобилизацияләнгән.

**Хөснетдинов Барый Булат улы**, 1925 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. Рядовой, 1946 елда демобилизацияләнгән.

**Шәмиев Исмай Шәми улы**, 1908 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1937 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1946 елда демобилизацияләнгән. II дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары кавалеры. 24.1.1972 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.

**Шәрәфетдинов Һади Шәрәфетдин улы**, 1909 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. Рядовой, 1947 елда демобилизацияләнгән.

**Юнысов Абдулла Юныс улы**, 1909 елда туган, яшәү урыны: Хәерби авылы. 1941 елда мобилизацияләнгән, рядовой, 1945 елда демобилизацияләнгән. 10.9.1968 вафат булган, Хәерби авылында җирләнгән.






1. Бөек Ватан сугышы ветераннары. 1980 еллар башы;
2. Җиңү көненә багышланган митинг.

## ХӘЕРБИ АВЫЛЫНЫҢ БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫ ВЕТЕРАННАРЫ ТУРЫНДА

Сугыш дәһшәтен кичеп кайтканнарның истәлекләре бүгенге буыннар өчен чынлыгы белән кадерле документлар алар. Күргәннәре бик авыр, фаҗигале булгангадыр, фронтовиклар ул көннәрне искә алып сөйләргә яратмый иде. Сугыш мәхшәре, окоп газапларын бүлешкән дус-иптәшләренең үлемен күрү, салкыннан, туйганчы ашый, кешечә йоклый алмаудан һәм башка кыенлыклардан тилмерүләр, алар тулысынча үзләре генә тойган хисләр булып, үзләре белән китте. Шулай да кайбер Хәерби ветераннарының тыйнак истәлекләре калган. Бүген безнең аларны сезгә тәкъдим итү мөмкинлегебез бар.

**Вафин Гарифулла Вафа улы** 1920 елда Хәерби авылында туа. 1927 елда Хәерби мәктәбенә укырга керә. 4 сыйныфны тәмамлагач, укуын дәвам итә алмый. 12 яшеннән «Алга» колхозында колхозчы булып эшли.

Гарифулла Вафин 1941 елның маенда Кызыл Армия сафларына алына. Сугыш башланганда аның Көнбатыш Белоруссиядә хезмәт иткән чагы була. Беренче сугышчан чирканчыкны ул, артиллерист һәм разведчик буларак, Смоленск шәһәре янындагы сугышта ала. Беренче бәрелештән соң аларның частьлары таратыла һәм аның нигезендә Калинин шәһәрендә яңа часть оештырыла. Гарифулла абый 81 нче укчы дивизия составындагы 74 нче артиллерия полкының беренче дивизионында разведчик булып хезмәт итә. 1942 елның июлендә аларның дивизиясе Сталинград янына озатыла. Гарифулла Вафин Сталинград оборонасында катнаша, немецларны Сталинград янында камаганга кадәр шунда сугыша. «Сталинградны саклаган өчен» медале белән бүләкләнә. Ул сугышкан часть Венгриягә кадәр барып җитә. Венгриядә Секешфехервар һәм Бичке шәһәрләре янында немец оборонасын өзү сугышларында катнаша. «Будапештны алган өчен» медале белән дә бүләкләнә.

Бервакыт Гарифулла Вафин үзенең ике иптәше белән разведкага бара. Шунда аларга дошманның күпсанлы төркеме белән бәрелешергә туры килә. Алар 40 лап немец солдатын һәм офицерын, ике танкны, өч ут ноктасын юк итәләр һәм безнең командование өчен кыйммәтле мәгълүматлар бирә алган өч немецны «тел» итеп алып кайталар. Үзләренең частена исән-сау әйләнеп кайткач, Гарифулла Вафин III дәрәҗә Дан ордены белән бүләкләнә. Соңрак ике тапкыр «Батырлык өчен» медаленә лаек була. Сугышны Германиядә тәмамлый.

1946 елда авылга кайта, өйләнә, җиде бала (2 кыз һәм 5 ул) үстерә, бригадир булып эшли. 1997 елның 20 мартында вафат, Хәерби авылында җирләнгән.



Наградной лист.

1. Фамилия, имя и отчество: Вафин Гарифул Вафинович
2. Звание: Ефрейтор 3. Должность, часть: старший разведчик управления 1 дивизиона 74 арт. Кишиневск. полка 84 стрелков. Карпатской Краснознам. Дивизии

Представляется к награде орденом славы 3 степени

4. Год рождения: 1920 5. Национальность: Татарин
6. Партийность: ч/л ВКП/б/ 7. Участие в боях: с 6.41 г. по 8.42 г. – ... с 8.42 г. по 2.43 г. – Дон. фр., с 4.43 г. по 10.43 г. – степ. фр. – с 10.43 г. по 9.44 – 2 укр. фр., с 11.44 г. – 3 укр. фр.
8. Имеет ли ранения и контузии: ранен легко 3 раза
9. С какого времени в РККА: с 5.1941 г.
10. Каким РВК призван: Столбищенским РВК Татарской АССР
11. Чем ранее награжден: Медалью „За отвагу“ пр-з 74 АП №: 01/н от 23.8.44 г.
12. Постоянный домашний адрес: [redacted]

Краткое, конкретное изложение личного боевого подвига или заслуг.

20.12.44 г. при прорыве вражеской обороны в р-не г. Секешфехервар тов. ВАФИН выдвинувшись за боевые порядки пехоты указывал цели командиру батареи, в этом бою по его данным было уничтожено 2 станковых пулемета мешавших продвижению нашей пехоты.

22.12.44 г. западнее г. Секешфехервар обнаружил пушку противника стоящую на прямой наводке, которая была уничтожена огнем нашей батареи.

25.12.44 г. в р-не шосейной дороги северо-западнее г. Секешфехервар обнаружил 2 крупнокалиберных пулемета и 1-ну противотанковую пушку, которые были подавлены огнем нашей артиллерии, в этих боях лично сам взял в плен 3-х солдат противника.

Достоин Правительственной награды ордена "СЛАВЫ 3 СТЕПЕНИ".

Командир 74 артиллерийского Кишеневского полка
Подполковник (Вашнов)

"28" декабря 1944 г.

С представлением к Правительственной награде ордену "СЛАВЫ 3 СТЕПЕНИ"

Согласен.

Командующий артиллерией 84 СКД
Полковник /ПОМЕЛЬНИКОВ/

" " Декабря 1944 г.

Гарифулла Вафинны III дәрәҗә Дан ордены белән бүләкләү турында. 1944 ел.

**Минбаев Нури Миңнебай улы** 1923 елда Хәерби авылында туа. Сугыш башланганда аңа 17 яшь кенә була. Н.Минбаевның «Кама ягы» газетасында басылып чыккан истәлекләрен тәкъдим итәбез:

«Минем тормыш юлым күп кенә яшьтәшләремнеке кебек булды. Хәербидә крестьян гаиләсендә туганмын. Җидееллык мәктәпне тәмамлагач, «Алга» колхозында эшли башладым. 1940 елда, ул чакта миңа 17 яшь тулмаган иде әле, минем яшьтәге егетләрне җыеп, тимер юл төзелешендәге эшләргә өйрәтә башладылар. 1941 елның маенда безне Казан–Бөгелмә юлына эшкә билгеләделәр. Сугыш башлануга эш тукталды. Мин авылга кайтып төшкәндә йөзгә якын авылдашым сугышка киткән иде инде. 1941 елның 22 июне барыбызны да олыгайтты һәм Туган илне саклаучыларга әйләндерде. Шул ук елның көзендә республиканың көнбатыш районнарында саклану корылмалары төзелә башлады. Килеп җитә калса, дошманны Идел ярларында туктатырга тиеш идек. Безне Буа районына җибәрделәр. Килдураз авылы янында окоплар казыдык. Аннан соң армиягә алдылар. Бер ай Суслонгерда әзерлек үткәч, Мәскәүгә озаттылар. Мин анда авылдашларым Закир Сафин һәм Сибгат Рәхмәтуллинны очраттым. Өч ай буе әзерлек үттек. 1942 елның көзендә Воронеж фронтында идем. Күп тә үтмәде башым яраланды. Терелгәч, туган


А2 №031231

3 укр. ф.
3.1.44

Приказ № 24-н.
По 216 гвардейскому стрелковому полку 79 гвардейской краснознаменной Запорожской стрелковой дивизии 8 гвардейской армии.
„16" Октября 1943 года.

От имени Президиума Верховного Совета Союза ССР награждаю:

Медалью „За отвагу"
1 Гвардии красноармейца – наводчика батареи 45 мм пушек Мининдаева Нури за то, что он в боях за гор. Запорожье с 10.10 по 14.10.43 года смело вел огонь прямой наводкой и подавил огонь пушки противника, тем самым обеспечил пехоте продвижение вперед.
1923 года рожд. беспартийный, татарин, призван в РККА Столбищенским РВК Татар АССР.
Дом. адрес:



НАГРАДНОЙ ЛИСТ

1. Фамилия, имя и отчество ..Минбаев Нуры Тухватуллович..............

2. Звание.. гвардии сержант ........3. Должность, часть наводчик бат. 45мм. пушек 214 гвард. стр. полка, 73 гвард. стрелк. Краснознам. Запорожской ордена Суворова 2 степени дивизии.

4. Год рождения..1924...5. Национальность. татарин ...6. Партийность беспартийный

7. Участие в гражданской войне, последующих боевых действиях по защите СССР и Отечественной войне Белгородский фр. с 10.2.43 по 24.4.43. Юго-Западный фр. с 18.7.43 по 14.11.43. 3-й Украинский фр. с 14.11.43.

8. Имеет ли контузии и ранения в Отечественной войне.. ранен 24.11.43.

9. С какого времени в Красной Армии. с 1942..........

10. Каким РВК призван .Стерлибашевский РВК. Башасср..........

11. Чем ранее награжден медалью «За отвагу» пр. 73 гв. сд. № 24/н от 16.12.43............

12. Постоянный домашний адрес представляемого к награде и адрес его семьи.....

.......................

1. Краткое конкретное изложение личного боевого подвига или заслуг.

В боях за х. Лед 9.4.44 г. ведя умело стрельбу, уничтожил вражеский танк и метким огнем из своего орудия отразил контратаку противника. Когда кончились боеприпасы, он вместе с командиром орудия с пехотой пошел в атаку, уничтожая живую силу противника.

Представляется к Правительственной награде – ордену "КРАСНАЯ ЗВЕЗДА"

НАЧАЛЬНИК АРТИЛЛЕРИИ
гвардии ст. лейтенант
( МАЛЬЦЕВ ) Вмальцев

Ходатайствую о награждении орденом "КРАСНАЯ ЗВЕЗДА"

216 Гвардейский Стрелковый полк

КОМАНДИР 216 ГВ. СТР. ПОЛКА
гвардии подполковник
(В А Ж Е Н И Н) Важ

"..21.."..апреля.....1944 г.

Согласен с представлением к правительственной награде Ордену «Красная Звезда».
Командующий артиллерией 73 Гв. Краснознаменной Запорожской ордена Суворова Стрелковой Дивизии
Гв. майор Коротков /Коротков/.
„26" Апреля 1944 г.

Нури Минбаевны Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләү турында. 1944 ел.

авылыма җибәрделәр. Әти-әнием янында берәр ай яшәдем. 27 апрель көнне авыл советына чакырдылар һәм секретарь Исхак Мингалиев район хәрби комиссариатының чакыру кәгазен тапшырды. Май аенда мин яңадан Суслонгер лагеренда идем. Шуннан – кабат фронтка. Сугыш – сугыш инде, тагын яраландым һәм Балашово шәһәрендәге госпитальгә эләктем. Дәвалангач, 3 нче Украина фронтында сугыштым. Запорожьены, Одессаны азат итү сугышларында катнаштым. Висла елгасының аргы ярында плацдарм яулаганда кабат каты яраландым. Алты ай дәваландым. 1945 елның 24 февралендә туган авылыма кайтып кердем».

Нури Минбаев «Батырлык өчен» медале, өч Кызыл Йолдыз, I нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары белән бүләкләнә.

Сугыштан соң Нури Минбаев туган авылында авыл советы секретаре, аннан соң 30 ел буе, 1979 елга кадәр, авыл советы рәисе булып эшли. Колхозның партия оешмасы белән җитәкчелек итә. Сигезенче бишьеллыкта күрсәткән тырыш хезмәте өчен «Почёт билгесе» орденына лаек була. Хатыны Зәкия апа белән 7 бала тәрбияләп үстерәләр. Оныклары һәм онык балалары күп аларның.

Нури Минбаевның беренче Кызыл Йолдыз орденына тәкъдим ителү турындагы документында әтисенең исеме Төхвәтулла дип күрсәтелгән. Шулай ук туган елын күрсәтүдә дә ялгыш бар: 1924 ел диелә. «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнү документы белән чагыштыргач, икесендә дә бер кеше турында сүз баруы ачыклана. Кызыл Йолдыз орденына кагылышлы документының 11 нче пунктында аның 1943 елның 16 октябрендә «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнүе һәм 216 нчы гвардия укчы полкында хезмәт итүе раслана. Фронт шартларында сугышчының исем-фамилиясе, атасының исеме, туган елы ялгыш күрсәтелү очраклары еш була. Нишлисең, сугыш...

Фронтовик Нури Минбаев 2002 елның 20 августында вафат, Хәерби авылында җирләнгән.

**Абдуллин Габделхак Габдулла улы** 1924 елның 18 февралендә Хәербидә туган. 2005 елның 19 маенда вафат.

Бөек Ватан сугышы башланганда Габделхак Габдулла улына 17 яшь кенә була. Шулай булса да, ул фронтка китә. К.К.Рокоссовский[1] җитәкчелегендәге Белоруссия фронтында дошманга каршы сугышып, Берлинга кадәр барып җитә. Ул «Батырлык өчен» (1944), «Кенигсбергны алган өчен» медальләре, Кызыл Йолдыз, II дәрәҗә Ватан сугышы (1985) орденнары белән бүләкләнә. «Безнең әти өчен иң зур бәйрәм – 9 Май Җиңү көне иде. Әни иртүк мичкә

1 Күренекле Совет полководецларының берсе. Советлар Союзы маршалы, Польша маршалы, ике тапкыр Советлар Союзы Герое.


Приказ № 16/н
По 1003 Стрелковому полку 279 Стрелковой Лисичанской Краснознаменной дивизии.
От 26 мая 1944 года.
От имени Президиума Верховного Совета Союза ССР награждаю медалью „За Отвагу"
1. Автоматчика автоматной роты красноармейца Абдуллина Абдулхана Абдулловича за то, что он 8–9 мая 1944 года в боях в районе Северная бухта и в городе Севастополь проявил себя храбрецом. Он уничтожил из своего личного оружия 5 немецких солдат, мешавших продвижению нашей пехоты.
1927 года рождения, татарин, рабочий, член ВЛКСМ, образование 7 классов, призван в РККА 1942 года Стролбищенским РВК ТАССР.
Домашний адрес:

ягып, тәмле камыр ризыклары пешерә һәм без шатланып әтинең бәйрәмнән кайтканын көтә идек. Сугыш хатирәләрен ул шул көнне генә телгә ала иде», – дип искә ала балалары.

Габделхак Габдулла улы сугыш фаҗигасен, сугыш афәтләрен үз җилкәсендә тоеп кайтканнан соң, бар көчен җыеп, туган авылында эшли башлый. Казанда Югары авыл хуҗалыгы мәктәбен (1952–1955 еллар), Казан авыл хуҗалыгы институтының бухгалтер-икътисадчылар факультетын (1960–1965 еллар) тәмамлый. Хәербидә бригадир, агроном, авыл советы рәисе, колхозның баш бухгалтеры булып эшли. 65 яшендә лаеклы ялга чыга. Авылга практика узарга килгән студентларны да эшкә өйрәтә, үзе белән эшләгән хисапчы кызларга да һәрвакыт ярдәмгә килә. Туган авылын һәм кешеләрне бик ярата Габделхак Габдулла улы.

Габделхак Абдуллинның хатыны – Фоадия Билал кызы (1928–1989). «Сугыштан соңгы еллар, эшләргә дә, укырга да, балаларны үстерергә дә, тормышны алып барырга да кирәк. Әтинең ышанычы да, таянычы да, ярдәмчесе дә әни булган. Ул аңа укырга кушкан. Әтинең шундый укымышлы, дәрәҗәле



1



2



3



4

1. Фронттан кайткач. 2. Габделхак абый хатыны Фоадия апа белән.
3. Санаторийда ял иткәндә. 4. Ветераннар: Г.Абдуллин, К.Гарипов, Н.Минбаев.

кеше булуында әнинең өлеше, тырышлыгы бик күп», – ди кызлары Фәнүзә Габделхак кызы.

Абдуллиннар гаиләсендә 7 бала үсә: **Фоат** (1950), Казан дәүләт университетының юридик факультетын тәмамлый; **Габделәхәт** (1951), авыл хуҗалыгы техникумын тәмамлый, инженер-механик; **Фәнүзә** (1953), Мәскәү Совет сәүдәсе институтын тәмамлый; **Илгизәр** (1956), Казан механика һәм технология техникумын тәмамлый; **Искәндәр** (1958), Казан механика һәм технология техникумын тәмамлый; **Фирания** (1960), Казан кооперация техникумын тәмамлый, технолог; **Флёра** (1966), Казан дәүләт педагогия институтының табигыять-география, Казан дәүләт университетының юридик факультетларын тәмамлый.



Ветераннар советы рәисе Илсөя Ярмиева Бөек Ватан сугышы һәм тыл ветераннары белән: Габделхак Абдуллин, Мәгъсүм Ризванов, Кыям Гарипов, Габдрахман Галиев, Саимә Хисамова, Мөнирә Булатова.









9 Май — Бөек Җиңү бәйрәме көненнән күренешләр. 2018 ел.

## СУГЫШ ЧОРЫ БАЛАЛАРЫ

Сугыш... Син бит миллионнарча хатын-кызны ирсез, аналарны баласыз, балаларны әтисез иттең... Әтиләре сугышка киткәндә йорт тулы күпме бала калды. Кайберләре алар киткәннән соң дөньяга аваз салды. Әтиләре аларның барлыгын я хат аша гына белде, кайсылары белмичә дә һәлак булды. Әтиле балаларга кызыгып, үзләренең әтисез булуларына кимсенеп, әти кешене бер күрергә, аның көчле кулын тоярга хыялланып үткән балачак... Фронттан көттереп кенә килгән, дары исе сеңгән хатларны укып юанулар...

Әтиле балалар әтиләренә карап куанышсалар, ятим балаларга, «әти» сүзен гаилә бөтен чактагы истәлекләр өчен генә кулланып, сугыш китергән газап-михнәткә түзеп яшисе генә кала. Ә бер тапкыр әтисен күрмәгәннәр ул тәмле сүзне авызларыннан чыгарырга да кыймыйча гомер итәчәк. Язмышлар бер генә төрле булмый шул, ул чор балалары язмышы үзенә бер аерым, гыйбрәтле.

Сугыш чорында балалар ничек яшәгән? Алар аннарыниләр кичергән? Әлеге буын кешеләренең тормышы турында без бик аз беләбез. Ә бит алар, сугыш чоры балалары, төп югалтуларга дучар булучылар. Сугыш аларның бала чагын, бала чакка хас шатлык-куанычларын урлый, үзләрен вакытыннан алда олыгайта, иң якын кешеләрен тартып ала.

Әйе, тылда калганнарга җиңел булмый. Солдат әтиләрен, кардәш-туганнарын, бөтенләй дә таныш булмаган миллионлаган сугышчыны бөтен нәрсә белән тәэмин итеп тору өчен, станоклар артында, колхоз басуларында алныялны белми эшли тыл. Хатын-кыз, өлкәннәр, яшүсмерләр, балалар сыкранмый, сызланмый һәммәсен дә үз җилкәләрендә күтәрә.

Сугыш чоры балалары, бигрәк тә сугыш ятимнәре, сез бүген дә гаделсезлек кичерәсез. Әлегә кадәр сезнең фидакарь хезмәтегезнең, ил хакында күргән михнәтләрегезнең тиешлечә бәяләнгәне юк. Ватан сезнең алда бурычлы әле. Ә бездән, сезнең оныкларыгыздан, рәхмәтләр кабул итеп алыгыз. Рәхмәт сезгә! Әле озак еллар сәламәт булып, безгә олы терәк булып яшәгез! Бүгенге көндә күктә кояш балкый икән, авыл буйлап яшьләр яраткан хезмәтләренә ашыга, балалар чыр-чу килеп уйный икән, белегез: бу матур тыныч тормышта Сезнең өлешегез бик зур.

Хәерби авылында яшәүче сугыш чоры балалары турында да истәлекләр бар. Кызганыч, барысы турында да түгел. Бу бүлектәге материалларны туплауда укытучы Ләйлә Сафина да үзеннән зур өлеш кертте.

**Абдуллина Сәлимә Хәмидулла кызы** 1924 елның 7 февралендә Хәербидә туа. Кырчылыкта эшли. Гомеренең соңгы көннәренә кадәр авылда улы Фәрит, килене Гүзәлия тәрбиясендә яши.



С.Абдуллина оныгы белән.

Сәлимә апаның бертуганнары: Гайшә, Мөнирә, Насыйбулла, Хәбибулла, Габдулла. Сәлимә Абдуллинаның ире — Насыйбулла Габдулла улы, 1914 елның 1 гыйнварында Хәербидә туа. Бөек Ватан сугышы ветераны. 1988 елның 10 гыйнварында 74 яшендә вафат. Сәлимә һәм Насыйбулла Абдуллиннар сигез бала үстерәләр: Фоат, Сания, Фердинант, Саимә, Саҗидә, Фәридә, Фәрит, Фәния.

Сәлимә Хәмидулла кызы Абдуллина 2013 елның 8 мартында 89 яшендә вафат булды.

Түбәндә аның «Ватаным Татарстан» газетасында (2011 ел, 6 октябрь) басылган мәкаләсе тәкъдим ителә.

## Язмыш

«Миңа фатир бирделәр. Бер хөкүмәт бала чагымда өйдән куып чыгарып, бик нык кыерсыткан иде. Икенче хөкүмәт, 87 яшемдә, бөтен уңайлыклары булган бер бүлмәле фатир биреп, кадер-хөрмәт күрсәтте. Бөек Ватан сугышында катнашкан ирем, рәнҗетелгән әти-әни, абый-апалар күрә алмады бит шундый фатирны.

Безнең әти бик тырыш, булган кеше иде. Мул, иркен тормыш алып барды. 30 нчы елларда аңа «кулак» мөһере суктылар. Әти ике сыерыбызны, ике атыбызны, бик күп сарыкларыбызны колхозга илтте. Шуннан «авыл активы» – адәм актыгы (ул безгә бик күп газаплар күрсәтсә дә, исемен язмыйм, балалары-оныклары бардыр, алар аның өчен оялып тормасыннар) өйдән куып чыгарырга килде. Игеннәрне, бәрәңгеләрне капчык-капчык ташыдылар, өскә кия торган киемнәребезгә кадәр тартып алдылар. Без – әни, абый, апа, мин урам уртасында бер нәрсәсез басып калдык.

Әтине, Насыйбулла абый белән Хәбибулла абыйны төрмәгә алып киттеләр. Безне ялгыз яшәүче көтүче Галәү абый өенә керттеләр. Ул йорт абзар кебек иде: идәненә такта җәелмәгән, кап-кара җир. Галәү абый безне бик кыз-




ганды, үзенең иске тимер караватын бирде. Әни белән шунда йокларга ятабыз гына, баш очына күче белән бака җыела иде. Мин, шулардан куркып, төне буе йоклый алмый чыга идем. Озакламый безнең янда, шулай ук кулак итеп таланып урамга куып чыгарылган Җамалетдин абыйлар гаиләсе яши башлады. Алар бака оясында – җир идәндә ятты. Нишләсеннәр, кая барсыннар?

Безне куып чыгаргач, яңа, зур өебезгә башка авылдан килгән сигез балалы гаиләне керттеләр. Ул гаилә анда озак тормады. Шуннан соң безнең өйне, мунчаны сүтеп, бүрәнәләрен, такталарын фермага ташыдылар. Әни өзгәләнеп елады. Менә шулай, бөтен нәрсәбез Хәерби фермасын төзү өчен китте. Ул ферма өеннән үткәндә күңелдә кузгалган әрнүләремне белсәгез... Галәү абый өеннән бер ташландык җимерек өйгә чыктык. Әти, ачлыктанмы, кыйналуданмы, борчылуданмы, төрмәдән өйгә бик нык шешенеп кайтып егылды. Габдулла абый үпкә авырулыга әйләнде, озакламый ул да урын өстенә калды, йөткерә дә йөткерә... Безнең аны терелтерлек дару да юк, ашарга да тамчы ризык юк иде. Абый: «Әни, бәгърем, тилмертмә, кешедән бер телем ипи булса да алып чык инде!» – дип кычкырып ятканда, әнинең йөрәге ничек түзгәндер... Күз яшьләрен сөртә-сөртә өйдән чыгып китә иде. Әти төрмәдән кайткач мантый алмады, ачлыктан, интегеп, авырып үлде...

Әти үлде дә котылды. Бөтен авырлык әнигә калды. Ул көндез колхозга эшкә йөрде, кичләрен телемләп бәрәңге кыздыра иде. Аны төрмәгә абыйларга илтте. Аларны ничек тә исән калдырырга теләгәндер инде. Казанга җәяү барып кайтканчы чабатасы тишелеп бетә иде мескен-



Абдуллиннар гаиләсендә үскән биш кыз туган.



Сәлимә апаның кече улы – Фәрит Абдуллин.

нең. Абыйлар төрмәдән кайтты. Тик «кулак» дип мыскыл итүләр аның белән генә бетмәде. Берсендә клубта нindiдер кичә үткәрәләр, «авыл активы»: «Хәмидуллин, мен әле сәхнәгә!» – дип чакыра. Абый матур җырлый, бии иде, җырларга чакырадыр инде дип, ахырын уйлап бетермәстән, янына менә. Бераз салып алган теге бәндә, «кулак» калдыгы бит син, дип абыйның кулларын каерып бәйләп, бер сәбәпсез тагын төрмәгә озата. Ул куркыныч елларда кеше язмышы белән менә шулай уйныйлар иде.

Мәктәпкә юньләп йөри алмадым. Киеп барырга әйбер булмады. Сабантуйга халык безнең урамнан җыелышып төшеп китә иде. Берсендә дус кызларым мине алырга керде. Барысы да матур итеп киенгәннәр. Юк, чыкмыйм, авырып торам, дидем. Үзем кылка күлмәктән бәйрәмгә чыгарга оялдым. Әни, мине жәлләп, бер хәллерәк гаиләдән, берничә сәгатькә дип, буй-буй тукымадан тегелгән күлмәк, ялтыравыклы резин галош алып менгән. Шуның өчен ул кешеләргә дүрт көн буе чүп уаштым. Бер әйберебез дә булмады шул. Әнинең дә бары бер күлмәге бар иде, хәзер дә бар ул, аның төсе итеп тотам. Әй, ач-ялангач булып, нужаланып яшәдек тә инде.

16–17 яшьтән авыл ирләре белән окоп казырга, урман кисәргә җибәрделәр. Ул заманда өендә яклаучысы булганнарның берсе дә окоп казымады, төрле сәбәп табып калдылар. Мин дә идарәгә барып өс-башым юк, дигән идем, теләсә каян тап, качып калсаң, төрмәгә ябачакбыз, дип янадылар. Окоп казырга җизнинең иске бишмәтен киеп киттем. 40 градуслы салкыннарда чабата-оек белән ничек исән калганбыздыр?! Утын кискәндә ике табан астым да өшеде, окоп казыганда хәлсезләндем, авыз-борынымнан кан китә иде. Берничә хатын-кыз, каткан туфракны 9 атка төяп торабыз, ял күрмибез, ашарга юк, бетләп беттек. Ирләрне фронтка алдылар, безне авылга кайтарып җибәрделәр. Хәзер уйлап куям: бу урман кисүләрдән, окоп казулардан ничек исән-имин кайта алдык икән. Безнең елгыларның бик күбесе әллә кайчан, яшьли үлеп бетте. Без күргәннәрне кешегә түгел, эткә дә күрергә язмасын.

...Бүген менә үткәннәрне баштан кичереп җылы, якты фатирда утырам. Шулкадәр әйбәт итеп, күңел җылысы кушып төзегәннәр аны. Безне олылаганнары, кайгырткannары өчен илебез, районыбыз җитәкчеләренә зур рәхмәт әйтәсем килә. Ветераннарга картаеп беткәч нәрсәгә фатир бирәләр, дип яшьләр күпсенмәсен иде. Без дә күпне күрдек бит, балалар!!!».

**Абдуллина Фәүзия һәм Ибраһимов Шафик гаиләсе**[1]. «Бөек Ватан сугышы башланганда әтиебез Шафик Ибраһим улы Ибраһимовка 4 яшь (1937 елның 30 июнендә туган), ә әниебез Абдуллина Фәүзия Габдулла кызына (1939 елның 6 сентябрендә туган) бары 2 генә яшь була.

Бабабыз Ногманов Ибраһимны (1900 елгы) сугышка озаткан көнне әтиебез бик еш искә ала иде. «Балалык белән без сугышның ни икәнен башта аңламадык. Бүгенге кебек хәтеремдә. Әтине бөтен авыл белән озаттык. Өлкәннәр елаша. Ә без Нәҗип абый белән, ялан тәпиле ике малай, әтине басу капкасына кадәр озата бардык. Ул көнне без әтиебезне соңгы тапкыр күргәнбез икән. Сагынып карар өчен бабаегызның бер фотосы да юк. Ә сугыш үзенең ни икәнен бик тиз аңлатты. Әти булмагач, бар эш без бала-чага җилкәсенә төште. Ашау-эчү такы-токы. Миләүшә тавыннан кузгалак, акы, юа җыеп ашадык. Кычыткан ашы пешерү һәр гаиләдә дә гадәти хәл иде. Без Нәҗип абый белән урманнан чыбык-чабык утын ташыдык. Әзрәк үсә төшкәч, көтү көтә башладык. Әтинең хәбәрсез югалуы турында хәбәр килде. Без ятимнәрнең тормышы тагын да читенләште. Абый белән атлар карадык, көтү көттек. Апабыз Нәсимә торакторда эшләде. Соңрак шахтага китеп, шунда тормыш корып, ике бала үстерделәр. Икенче апам Саимә бозаулар карады, аннан кырчылыкта эшләп, яшелчәләр үстерде. Тормыш корды, бер улы бар. Без Нәҗип абыем белән мич чыгарырга өйрәндек. Авылдашларга мич чыгардык. Соңрак балта эшенә крештек, йортлар салып көн күрдек», — дип искә ала иде әти.



Шафик абый, Фәүзия апа.

Әниебез Фәүзия дә шул чор баласы. Сугыш афәте аларга да кагылмый узмаган. Шул ук авыр тормыш алар җилкәсенә дә төшә. Әнием Фәүзиянең бертуган абыйсы сугышка алына. Габделхак Габдулла улы Абдуллин сугыштан исән-сау әйләнеп кайтып, колхозыбызны күтәрүдә зур өлешен кертте.

Әти белән әни, бергә тормыш корып, сигез бала тәрбияләп үстерделәр. Аллага шөкер, барыбыз да эш сөючән. Әти 2000 елда, ә әни 2017 елда гүр

1 Мәкаләне кызлары Рәзинә Дәүләтова язып тапшырды; авторлар тарафыннан редакцияләнде.

иясе булдылар. Аларның уналты оныгы, унбер онык баласы бар. Барыбыз да аралашып яшибез. Әти-әни йортында гаиләсе белән энебез Сәгыйть яши. Бу йорт хәзер барыбызны да берләштереп тора. Туганлык арасы өзелмәсен!».

**Булатова Мөнирә Зариф кызы** 1929 елның 2 мартында Лаеш районы Хәерби авылында Зариф абый белән Җәмилә апа гаиләсендә дөньяга килә. Дәһшәтле сугыш башлануга йорт хуҗасы Зариф абый (алдарак Зариф Насыйбуллинның сугыштан язган хатлары китерелде) фронтка китә. Җәмилә апа ялгызы дүрт бала белән кала.



«Әтинең биш хаты килде. «Мөнирәгә тимәгез», – дип язган. Утын бетсә, сайгауларны сүтеп ягарга кушкан. Сугыштан соң исән кайтасына ышанган, бәгърем. Кайткач яңадан җәярмен, дигәндер. Әти сугыштан кире әйләнеп кайта алмады. Бер җирне дә сүтмәдек, каралты-курага тимәдек. Утынга «уфалла» арбасы белән Мишә буена бара идек. Шуннан ташып кистек утынны – чыбык-чабык иде инде ул. Госман энем белән печәнгә йөрдек», – дип сөйли Мөнирә апа.

Ул өч сыйныф белем белән кала. Сугыш башланганда аңа унике яшь була. Ач булмас өчен, кырдан коелган башак җыю дисеңме, язга чыккач, өшегән бәрәңге казумы – берсе дә калмый. Өшегән бәрәңгене әниләре елгада юа, киптерә, килегә салып төя, он ясый. Шул оннан ипи пешерә. «Туйганчы ипи ашау теләге белән яшәдек», – ди Мөнирә апа. Кырчылыкта эшли, 30 ел фермада сыер сава. Җәенә бишәр, алтышар гектар урак урып, көлтә бәйли. Мишә янындагы Кызыл ил авылы янындагы басуга җәяү барып, җәяү кайтып эшли. Мөнирә апа ике бала анасы. Ире Нариман абый белән 5 ай



Мөнирә Булатованың кызы – Асия, оныгы – Лилия, оныгының кызы – Алисә, оныгының оныгы – Дарина.

читтә торалар. Мөнирә апа туган ягын бик сагына һәм кайтып китәргә була. Ике баланы берьялгызы тәрбияләп үстерә. Улы Наил 21 яшендә бавыр авыруыннан вафат була. Бүгенге көндә биш оныгын, ун онықчыгын һәм оныгының оныгын сөйгән әби ул.

«Без күргән авырлыклар яшьләргә килмәсен. Дөньялар тыныч, имин булсын. Балалар ятимлек күрмәсен. Яшьләр матур яшәсеннәр», – дигән теләкләр белән яши Мөнирә апа.



**Вафина Нәкыя Закир кызы** 1943 елның 15 октябрендә Лаеш районы Хәерби авылында дөньяга килә. Сугыш елларының кышларын бик салкын дип искә ала шуны кичергәннәр. «Мин туган ел бик салкын булган», – ди Нәкыя апа да өлкәннәр сөйләвеннән. Әтисе – Кәримов Закир, әнисе – Кәримова Мәгъсүмә. Аларның дүрт балалары булган: Хәмәтгәрәй, Искәндәр, Нәкыя, Рәисә. Әтиләре Закир абыйны сугышка алганнар. Ул, яраланып госпитальдә яткач, 1943 елны туган якларына әйләнеп кайткан. Бик юаш кеше булган ул. Сугышка озатканда да аның артыннан «бу исән кайтмас» дип калганнар. Ә ул, бик күп яралар белән булса да, әйләнеп кайткан. Әтисенең Әмәт һәм Мингали абыйларын да хәтерли Нәкыя апа.

1956 елда мәктәпне тәмамлагач, Нәкыя апа фермага дуңгыз карарга билгеләнгән. Фермада ике ел эшләгән. «Ул вакытта миңа унөч кенә яшь иде. Дуңгызлардан курыкканым әле дә исемдә», – дип искә ала. Фермадан соң, колхозга төрле эшкә чыга. Колхозның «таякка» эшләткән көннәре аңа да эләгә әле.




Эш көннәренә акча бирелми, көн исәбен генә язып баралар. Фермада эшләп, 1998 елда пенсиягә чыга. Пенсиядән соң да эшлисе килгән аның, беркадәр эшләгән дә. «Беркөнне фермага совхоз җитәкчесе кергәч, күзләремә яшь тулды. Әллә җитәкчене күргәнгә күңелем йомшарды, әллә чынлап та арыган идем, белмим. Нигәдер елап җибәрдем», – дип искә ала Нәкыя апа.

Гаиләсен дә үз авылында кора, 1966 елда Габделхак абыйга кияүгә чыга. 1967 елда кызы Алсу, 1973 елда улы Альберт дөньяга килә. Ире Габделхак абый һәм кызы Алсу хәзерге вакытта вафат.



**Закиров Искәндәр Закир улы** 1939 елның 1 мартында Лаеш районы Хәерби авылында дөньяга килә. Кәримов Закир һәм Кәримова Мәгъсүмәләрнең икенче уллары. Ул 5 нче сыйныфтан соң фермада эшли башлый. Гомере буе ат җигеп, сарык, сыер фермасында төрле эшләр башкара. 1968 елны авылдашы Рәисә апага өйләнә. Алар дүрт бала тәрбияләп үстерәләр. Наил, Зөлфия, Камил, Шамилнең хәзер үз тормышлары. Искәндәр абыйның алты оныгы бар.



«Элек иске генә бер сәке бар иде. Әти сугышка киткәч, барыбыз да шул сәкегә җыелып утырып, әтиебезне сагынып елаганыбызны бик яхшы хәтерлим», – дип сөйли ул. Искәндәр абый 1999 елда 45 еллык хезмәт стажы белән пенсиягә чыга. 2014 елда вафат.

**Закирова Рәисә Солтанәхмәт кызы**, Искәндәр аганың хатыны, 1943 елның 4 апрелендә Лаеш районы Хәерби авылында дөньяга килә. Әнисе Җәмилә, әтисе Солтанәхмәт исемле була. Алар гаиләдә 9 бала үсә: Галимҗан, Кадыйр, Нурхәмәт, Гөлсем, Мәйсәрә, Мәгъсүм, Рәисә, Фатыйма, Разия. 7 сыйныфны тәмамлагач, урта белемне кичке мәктәптә укып ала. Хезмәт юлын фермада бозау, сарык караудан башлый. Соңыннан мәктәптә җыештыручы булып эшләп, 1998 елда 40 еллык стаж белән пенсиягә чыга. Сугыш чорын, кечкенә булса да, хәтерли ул. Әтиләре сугыштан исән кайта. Рәисә апаның 1926 елгы абыйсын да сугышка алганнар. Ул ике тапкыр яраланганнан соң, туган якларына әйләнеп кайткан. Әтисе сугыштан соң колхозда каравылчы була. «Черек бәрәңгеләрне чормага таратып киптереп, он итә идек. Ә олырак балалар урманнан кузгалак, кычыткан җыюда иделәр», – дип сөйли ул чорларны Рәисә апа.







Әминә һәм Мәсрүрә апалар.

**Зарипова Әминә Зариф кызы** 1925 елның 30 мартында Хәерби авылында туа. Гаиләдәге җиде бала арасында ул иң олысы. Үсмер һәм яшьлек еллары сугыш вакытына туры килгәнлектән, гаиләдә үзеннән кече туганнары өчен җаваплылык, төп авырлык аның җилкәсенә төшә. Колхоз эше, урманда утын кисүләр – ул чор яшьләре кичергәннәр аның да башыннан уза. Әминә апа Хәербидә яши, гомере буе намус белән тырышып эшли, шуңа күрә үзен дә хөрмәт итәләр, авыл һәм район советына депутат итеп сайлыйлар. Медальләре, Мактау грамоталары бик күп.



Әминә апаның әтисе – **Гыйләҗев Зариф**, 1900 елда Хәербидә туа. 1941 елда сугышка алына, авылга бары 1947 елда гына әйләнеп кайта. Зариф абыйның сәламәтлеге нык какшаган була, ул еш авырый, 1963 елда вафат була. Әнисе – **Гыйләҗева Мәсрүрә Вәлиулла кызы**, 1899 елда Хәербидә туа. Бик сабыр, киң күңелле хатын була. Озын гомер кичереп, 97 яшендә (1996 елда) дөньядан китә.

Әминә апа бердәнбер кызын – Гөлсемне тәрбияләп үстерә. Кызының игелеген күреп, кадер-хөрмәттә яшәп, 1998 елның 13 февралендә вафат була.

**Минбаева Бәдерниса Мингали кызы** 1929 елның 15 маенда Хәербидә гади крестьян гаиләсендә туа. 2 сыйныф башлангыч белем алып кала. Сугыш башланганда Бәдерниса апага 12 генә яшь була. Нәкъ менә шул елны ул үзенең хезмәт эшчәнлеген башлап җибәрә дә инде. Хезмәт кенәгәсен карасаң, анда бер генә язу – 37 ел Хәербидә яшелчәче булып эшләү генә теркәлгән.



90 яшь тулган көн.

Бәдерниса Мингали кызының ире – Минбаев Габдулла Минбай улы. Ул гомере буе фермада эшләгән. Бергә алар 52 ел яшәгәннәр, 6 бала: 3 кыз, 3 ул тәрбияләп үстергәннәр. Бүгенге көндә 8 оныклары, 5 оныкчыклары бар.

Габдулла абый 2005 елда вафат. Ә Бәдерниса апага 2019 елда 90 яшь тулды. Ул – Хезмәт ветераны, бик күп юбилей медальләре белән бүләкләнгән.

**Мингалиева Минбәян Сәхәбетдин кызы** 1929 елның 11 мартында гаиләдәге сигезенче бала булып дөньяга килә. Әтисе — Сәхәбетдин Сәлах улы, әнисе — Хәдичә Гыйззәт кызы. Аларның ун балалары була: Вәлиулла, Исхак, Әминә, Шиһап, Ибраһим, Хаҗәр, Мингаян, Минбәян, Гаҗилә, Мөхәммәт. Әниләре унынчы баласын тапканда, 38 яшендә үлә. Бу вакытта Минбәян апага дүрт кенә яшь була. Әтиләре Сәхәбетдин абзый, башка гаилә кормыйча, балаларны ялгызы тәрбияләп үстерә. Балалар үсә-үсә берсен-берсе караша, бер-берсенә ярдәм итешә.



Минбәян апа мәктәптә 5–6 ел укыганын хәтерли. Укыткан укытучыларын – Галия апа, Нәҗип абый, Мәймә апаларны тирән хөрмәт белән искә ала. Алар дусты Мөнирә Булатова белән бергә, бер партада утырып укыйлар. «Мин бик укырга ярата идем, тырышып укыдым», – ди Минбәян апа. Мәктәпне тәмамлагач, ул яшелчәчелеккә эшкә чыга. Алар кәбестә, кыяр, суган, помидор үстерәләр. Кул белән утыртып, чүбен утыйлар, көянтә-чиләк белән Камали күленнән, Кайнывактан ташып су сибәләр. Носилка белән фермадан тирес ташыйлар, парникларда эшлиләр.

Сугыш башлангач бертуган абыйлары сугышка китә. Шиһап абыйсы сугыш башлану хәбәрен балык тотып утырган вакытында ишетә. Кармакларын ярга ташлап, өйләренә ашыга. Өйдә инде аны повестка көтеп торган була. Шиһап, Ибраһим абыйлары шул сугышта үлеп кала. Ун бала атасы булган әтиләрен дә сугышка алалар. Тормыш авырлыгын алар бу елларда аеруча нык сизәләр. Сугыш тәмамлангач, әтиләре туган авылына исән-сау әйләнеп кайта.

Минбәян апа 1948 елда Исхак исемле егеткә кияүгә чыга. «Дустым Мөнирәнең хәлен белергә бара идем, Кашаф Габдулы белән урлап алып кайттылар мине», – дип елмаеп искә ала ул көннәрне Минбәян апа. Исхак абый шулай ук сугыш юлларын үтеп, минага эләгеп аяк бармакларын өздереп, яраланып кайткан була. Аны колхоз идарәсенә секретарь итеп эшкә алалар. Кияүгә чыкканда Минбәян апа яшь була әле. Ул елларда туйлап кияүгә чыгу-өйләнүләр онытылып тора. Иренең әнисе язылышыгыз инде дип әйтә торгач, Исхак абый язылышу кәгазе алып кайтып бирә. Исхак абый, инвалидлык буенча группада булса да, Минбәян апаның «Эшләмә, өйдә балалар белән генә бул», – дигәненә риза булмыйча, бөтен гомерен эшкә багышлый. Җиңү көнен якынайту өчен

авылның нинди тырышлык куюын бу чор кешеләре үзләре кичереп белә. Бертуктаусыз эшләү, салым түләүләр өстенә, хатын-кызлар, хәтта балалар да сугышка оек-бияләйләр бәйләп җибәреп торалар. «Авылга бервакыт солдатлар килгән иде. Аларны ашатып чыгардык, өйдә дә кундырдык»,– дип искә ала Минбәян апа. Ул 17 яшеннән Атабай урманнарында утын кисkәннәрен дә бүгенгедәй итеп сөйли. Бер ай кайтмыйча эшли алар. Мунчага дип кайткач, милиция белән кире куып җибәрәләр. Араларында өлкәнрәкләр дә була. Алар, бу яшьләр белән норма җыеп булмас дип, үзләреннән кечеләрне араларына кертмиләр. Ә яшьләр сынатмый, үзләре генә эшләп, утынны кубометрлап өеп куялар. Нормалары тулгач, аларны өйләренә кайтарып җибәрәләр. Хезмәт көнен анда да тамга белән генә билгеләп барганнар, акча булмаган. Эш өчен ашлык белән түләгәннәр. «Аякта чабата иде. Ә без чабаталарны бәйли дә белми идек. Кигезә белгәннәр безгә ярдәм итә иде», – дип искә ала Минбәян апа. Аулак өйләрне дә исендә тота ул. «Шәми Мәсерләренә гел аулак өйгә бара идек. Элеккеге дуслардан дүртәү генә калдык шул»,– дип моңая.



Тормыш иптәше Исхак абый белән алар дүрт бала тәрбияләп үстергәннәр. Суфия кызлары авырып үлгән. Зәлфирә апа, Фәридә апа, Илдар абыйларның хәзер үз гаиләләре. Минбәян апа улы Илдар, килене Гүзәл һәм оныклары белән яши. 1982 елда ире вафат булган. Минбәян апа хәзерге көннәргә тынычлык тели. «Без күргәннәрне башка беркайчан да күрергә язмасын»,– дип дога кыла. Ул «1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләнгән тыл ветераны.



**Насыйбуллина Дания Габдулла кызы** 1936 елның 16 августында Лаеш районы Хәерби авылында туа. Бүгенге көндә ул – балаларының яраткан әнисе дә, оныкларына иң ягымлы әби дә, оныкчыкларына дәү әби дә, авыл кешеләренә халык табибы да, күршеләренә киңәшче, ярдәмче дә. Дания апаның 6 баласы, 15 оныгы, 19 оныкчыгы бар. Ул улы Наил, килене Гөлүсә һәм оныклары белән яши. Балаларыннан бик уңды Дания апа. Алар һәрберсе тормышта үз юлларын, үз эшләрен таптылар. Бәйрәм көннәрендә төп йорт балалар, оныклар, балаларның оныклары белән

тула. Балалары, Дания апаның үзе кебек, эшчәннәр, кешеләргә карата ярдәмчелләр, ягымлылар.

Дания апаның хатирәләрен тәкъдим итәбез.

### Беренче хатирә

«Әтиебез 1942 елда сугышка китте, без әниебез белән ишле гаиләдә калдык: әтинең әбисе, әти-әнисе, әни белән без – 2 бала. Ашарга юк. Карт әни белән көн саен Бүре сазы дигән урынга кузгалакка барабыз. Карт әни зур капчык белән, ә миңа «мишавай мишук» («вещевой мешок»ны шулай дип йөрткәннәр) тоттыралар. Шуны тутырып күтәреп кайтам да, идәнгә авам. Бабаның ашказаны авырта, аңа гөмбә эзлибез. Бер баруымда гөмбә булмады. Таба алмагач, елап утырганым әле дә исемдә. Ул саз безнең авылга 5–6 чакрымнар ераклыкта иде. Кузгалактан соң ат колагы орлыгы өлгерә, аны сырып җыябыз. Авыл кырыендагы кычыткannар да калмый. Аларны җыярга карт әнием белән йөрдек. Үз әнием көне буе эштә. Кайткач, ул ай яктысы белән черек бәрәңге җыярга чыгып китә.



Уртада балалар: Дания һәм Нурания.

Бервакыт әтинең 3–4 ай хаты булмады, без хат көтеп почта буендагы чирәмлектән китә алмадык инде. Почтада Сталинградтан эвакуация белән килгән ике рус хатыны эшли иде. Аннары билгеле булды. Әтием Мурманскида хезмәт итә иде. Яраланып, аңсыз хәлдә аны кар күмгән булган, шинель итәге генә күренеп калган. Бер рус солдаты күреп алып, урман эченнән ике чакрым күтәреп барып, аны врачларга тапшырган. Госпитальдә әздән генә аякларын кисмәгәннәр, алар өшегән булган, итекләрен ярып алганнар. 1944 елда яраланып кайтты ул. Кайткач, колхоз счетоводы, аннары район әзерләүләр конторасы агенты булып эшләде. Авыл халкы ачлы-туклы яшәгән еллар. Ә ул алардан ит, сөт, йон һ.б.ны җыеп, хөкүмәткә тапшырырга тиеш. Бик катлаулы иде әтинең эше.

Үлеме үтә үкенечле, фаҗигале буды. Вәхшиләр кулыннан өзелде аның гомере. Сугыш кичкән әтиебез 1954 елның 1 апрелендә дөньядан китте.Үләренә берәр атна алда гына беләгеннән, шеш белән, бармак башы кадәр снаряд кыйпылчыгы тишеп килеп чыккан иде. Әтидән без биш бала калдык. Иң олысы мин идем.

Укулар беткәч, җәй көне, яшелчәдә эшләдек. Бездә җидееллык мәктәп, укулар башлангач, тагын укырга. Әти үлгәндә унҗиденче яшемә чыккан идем. Безне Карташ урманнарына урман кисәргә җибәрделәр. 38 градуслы салкында эшләдек. Өйдә ирләр булмагач, бөтен авырлык миңа килде. Мәктәптән соң сыер саварга кердем. Фермада иң яше мин идем. Казанга семинарларга барганнарым, грамоталар алганнарым булды. Ләкин бу эшләребезнең берсен дә хезмәт кенәгәсенә язмаганнар. 18 яшемдә «Хезмәт кенәгәсе» ачкач та, «разнорабочий» дип кенә язып куелган.

1958 елда тормышка чыктым. Алты бала үстердек: өч кыз, өч ул. Иптәшем Насыйбуллин Галимҗан өч ел армиядә хезмәт итеп кайткан иде. Улым Динар Төрекмәнстанда, Равил Әфганстанда, Наил Мәскәү янында хезмәт иттеләр. Үзем бер көн дә өйдә тормадым, без эш кешесе вакытта декрет яллары юк иде. Сыер савучылар ялга чыкса да, берәрсе авырып китсә дә гел мине килеп алып китәләр иде. Шулай эшләп, 1980 елда 50 яшемдә (35 ел да ничәдер ай стаж белән) пенсиягә чыктым. Алдан 18 яшькә кадәр эшләгәннәребез дә язылган булса, ничә ел булган булыр иде?! Рәхмәт, Мактау грамотасы бирделәр. «Хезмәт ветераны» билетым да бар.

Рәхмәт, безне искә алучыларга. Бездәй тилмереп үскән сугыш балаларын ник искә алмыйлар икән дип бик уңайсызлана идем. Күп язган дип ачуланмагыз, укый алсагыз, укыгыз. Безнең күргәннәрне дәфтәргә генә түгел, томнарга да язып бетереп булмый.

Күптән түгел оныгым «Алар илгә җиңү алып кайтты» дигән китап алып кайтты. Анда минем туганнарым бар: бабам – Ярмиев Гарифулла Гатаулла улы, 1890 елгы; әтием – Ярмиев Габдулла Гарифулла улы, 1916 елгы; әтиемнең энесе – Ярмиев Фарук Гарифулла улы, 1924 елгы.

Шушы китапны күргәч, кулыма алып еладым. Үлеп калганнарның якыннарына тагын да кыен, беләм. Әмма аларны барладылар, исемнәре ташка уелды. Исән кайтканнарны бер дә исемләп искә алучы юк дип борчыла идем. Ә алар бит илгә җиңү алып кайтканнар!».

### Икенче хатирә

Мин, Насыйбуллина Дания, үз әтием турында яздым. Кайнатам Насыйбуллин Габдулла турында кайнана әни сөйләгәннәрне дә язарга булдым. 1958 елда

шушы нигезгә килен булып төштем. Өйдә биш хатын кыз булдык: әни, аның сеңелесе Әминә апа, Галимҗанның ике сеңелесе. Узган гомерләрен сөйләгәндә әни гел елый иде. 1942 елда әтиләрен сугышка алганнар. Әни дүрт бала белән калган. Галимҗан 1935 елгы, Зифа апа 1930 елгы, Минниса апа 1938 елгы, Әлфия апа 1942 елгы. Әтине, авылда Насыйбуллиннар күп булгач, Наскин дип йөрткәннәр. Насыйбуллин Габдулла Насыйбулла улы ул, исеме билгеле булсын. Әтинең алмачуар аты булган, аны да сугышка алганнар. Аты кайткан, дип сөйлиләр иде. Үзе кайта алмаган. 1943 елның декабрендә хәбәрсез югалган дигән язуы килгән. Авылдан Солтанәхмәт исемле кеше күреп кайткан. «Пенза шәһәрендә машинага төяләә идек, аның кулы муенына асылган иде, минә алмый калды. Кайтып җитәр», – дигән. Әни: «Самоварга салырга шакмаклар ясап көттек», – дип сөйли иде. Иң җанына тигәне – ашарга булмау. Дүрт баланы көн дә туендырырга кирәк бит. «Иртән торырларына бер кабарлык ризык юк. Кыш көне яктыра башлагач, чыгып киттем. Безнең авыл аркылы атлар белән Каришәгә (Караишево) урыслар уза иде. Бераз баргач, юлда коелып калган клиндрикләр очрый башлады. Шулай бара-бара бер ал җыйдым, әллә урыстан коелган, әллә Аллаһы тәгалә биргән», – дип елап-елап сөйли иде әни.

**Нуриева Мәрьям Ибраһим кызы** 1940 елның 12 мартында колхозчы гаиләсендә икенче бала булып дөньяга килә. Әтисе – Сәлахетдинов Ибраһим, 1909 елда туган, Бөек Ватан сугышы ветераны. Сугыштан яраланып, бер аягын өздереп кайта. Әнисе – Насыйбуллина Маһиҗамал, 1910 елда туган. Ибраһим һәм Маһиҗамал алты кыз тәрбияләп үстерәләр: Сания, Мәрьям, Нурия, Наилә, Ләлә, Миңнегаян.

Мәрьям Ибраһим кызының ире – Нуриев Әхмәт Нурмөхәммәт улы, 1941 елның 3 мартында туган. Ул 11–12 яшьләреннән үк укуыннан туктап эшли башлый: яшелчәчелектә каравылчы, аннан янгын сүндерүче, механизатор (күбрәк тракторда эшли) була. Әхмәт бик матур җырлый һәм гармунда уйный. 19 яшендә Мәрьямгә өйләнә. Бер-бер артлы балалары туа: Мансур, игезәкләр Талия белән Тәлгать, Марат, Ринат. Бик матур гына яшәп ятканда зур фаҗига килеп чыга, 1972 елның 8 сентябрендә Әхмәт Нурмөхәммәт улы трактор астында калып вафат була. 32 яшьлек Мәрьям апа биш бала белән тол кала, олысы Мансурга – ун, ә кечесе Ринатка нибары дүрт яшь була. Кайнанасы Бибиһаҗәр һәм иренең апасы (ул да Мәрьям исемле) белән тәрбияләп үстерәләр алар балаларны. «Киленебез Мәрьямгә бик зур рәхмәт, әни белән бик тату, матур яшәделәр. Сабыр булды, тәүфикълы булды, балаларының битенә кызыллык китермәде. 32 яшендә тол калды, башка кияүгә чыкмады, ул зур ихтирамга лаек», – ди аның турында иренең апасы. Мәрьям Ибраһим кызының



Мәрьям Нуриева.



Әхмәт Нуриев.



Ибраһим Сәлахетдинов.

бүгенге көндә биш баласы, җиде оныгы, өч оныкчыгы бар. Ул улы Тәлгать белән яши.

Мәрьям апаның кайнанасы – Сафина Бибиһаҗәр (Һаҗәр) Сәхәбетдин кызы (1917 елгы), иренең апасы – Нуриева Мәрьям Нурмөхәммәт кызы (1938 елгы). Сугыш чоры балаларын язуыбызны белгәч, Мәрьям апа Нурмөхәммәт кызы үз гаиләсе язмышы турында түбәндәгеләрне сөйләде: «Без, сугыш чоры балалары, бик авыр тормышта үстек. Әти сугышка киткәндә миңа өч яшь, энем Әхмәткә өч ай иде. Без өйдә дүрт кеше – тәтә (әтинең әнисе) – Сафина Васфия (Васпи), әни Сафина Һаҗәр һәм без – ике бала калганбыз. Әти Сафин Нурмөхәммәт, Нури дип йөриләр иде аны, 1915 елгы, сугышка алынганнан соң озак та тормый хәбәрсез югала. Әти китүгә сыерыбыз үлә. Ашарга ризык та, ягарга утын да җитми. Әни чана тартып утын ташый, әмма ул алып кайткан тал чыбыгы, чикләвек куакларының җылысы юк диярлек. Сугыш беткәч тә җиңеллек килмәде, бик авыр еллар булды әле. Игенне җыеп алгач, коелган башакны җыя идек, аның өчен бик орышалар, куалар иде. Печән җирләрен таптыйлар дип, җиләккә дә йөрттермиләр иде.



Васфия Сафина оныклары Әхмәт һәм Мәрьям белән.





1. Нуриевлар гаиләсе. 2. Нуриевларның оныклары.

Миңа җиде, ә Әхмәткә дүрт яшьләр чагында, әнигә дә әйтмичә генә, чана тартып, фермага тирес белән чыккан салам җыярга йөрдек. Күпме җыйганбыздыр инде, бала бит. Ул саламның җылысы булгандырмы? Әхмәт 4 класста укыганда эт алып кайтты. Әни аның өчен бик орышты, ләкин энем бик ялынып сорагач, калдырырга ризалашты. Әхмәт этне утын ташырга өйрәтте. 5 нче классны тәмамлагач, энем эшли башлады. Помидор җирен саклаучы каравылчы булды, бер генә помидор да өзеп алып кайтмый иде. Аннары янгын сүндерүче булып эшләде, ат җикте, тракторчы булды. Авыл кешесенә дә бик ярдәмчел иде ул. Гомере генә кыска булды.

Бездә генә түгел, һәр йортта яши иде ул чакта кайгы һәм ачлык. Миңа быел 81 яшь. Картлыгыбызга Аллаһ тамагыбызны тук итте, акчаны өйгә китереп бирәләр, өстебез бөтен, Әлхәмдүлилләһ!»

**Садыйков Әнәс Миссәлим улы** 1935 елның 22 мартында Лаеш районы Хәерби авылында дөньяга килә.

Әтисе Садыйков Миссәлимне сугышка киткәндә озата барганын хәтерләрлек яшьтә була инде Әнәс абый. Бала чагына кире кайтып, шул мизгелләрне кат-кат күз алдыннан уздыргангамы, ул көн бөтен ваклыкларына кадәр исендә. «Стройга тезгәч, «Әти!» – дип кычкырдым. Ә аннары солдатлардан куркып кирегә йөгердем», – дип сөйли ул. Аның кебек «әти» дип өзелеп калган күпме баланы ятим итте шул сугыш. Садыйков Миссәлим дә сугышта үлеп кала.

Миссәлим абый белән Җәмилә апаның дүрт балалары була: Маһирә, Хабул, Әнәс, Сания.



Әнәс абый 7 сыйныфны укып чыккач, фермада эшли. Өч ел Совет Армиясе сафларында хезмәт итә. Армиядән кайткач та фермага килә. 1991 елда 41 еллык стаж белән лаеклы ялга чыга. «Әле тагын эшли ала идем, ләкин астма белән авырдым, группа бирделәр», – дип уфтана Әнәс абый.



1957 елда авылдашы Сабира апа белән өйләнешеп, үзләре дә дүрт бала тәрбияләп үстерәләр. «Ризәлә, Лилия кызларымның үз гаиләләре, эшләре бар. Рәмис һәм Рәфис улларым гына бу дөньяда юк», – дип сүзен дәвам итә ул әрнеп. Хәзерге көндә аның 5 оныгы бар. Әнәс абый Хәерби мәчетендә мулла да булып тора. «Хәзер бик нык картайдык. Яшьрәкләр көчлерәк», – ди ул.

**Садыйкова Сабира Зариф кызы** 1936 елның 14 июлендә Лаеш районы Хәерби авылында дөньяга килә.



Әтисе Зариф, әнисе Мәсрүрәнең җиде балалары булган: Әминә, Габдулла, Сәлимә, Гарифулла, Сабира, Сәйдә, Мәдинә. Унике яшендә Габдулла абыйсын эшкә алып китәләр һәм ул шул китүдән читтә төпләнеп кала. Сугыш башлангач, әтиләре Зарифны фронтка озаталар. Аңа кире әйләнеп кайту насыйп булмый.



Сабира апа мәктәптә яратып укый, 7 сыйныфны тәмамлагач, яшелчәчелеккә эшкә керә. Ул елларны алар кәбестә, кыяр, помидор, суган үстерәләр. Һәр эш кул көче белән башкарыла. Парник янына ат белән су китерә торган булалар, ә эшчеләр суны шуннан чиләкләп ташып сибәләр.

Җирне фермадан тирес ташып ашлыйлар. Биш ел Сокуры авылында, «Наука»да эшли ул. Шуннан соң лаеклы ялга чыга.

Кызлары Ризәлә һәм Лилия әти-әниләренә булышып яшиләр. Сабира апаның улларын искә алганда күзләренә яшь тула. Ата-ананың үзләре белән мәңгелеккә китәчәк йөрәк ярасы бу. Кичергәннәргә сабырлык бирсен.

**Солтанова Сания Гобәй кызы** 1936 елның 9 гыйнварында Лаеш районы Яушыйк авылында туа. Гаиләдә дүрт бала, дүрт кыз булалар алар: Минниса, Сания, Әминә, Халисә. Әминә апасы сөйләшә алмый.



Әтиләре Гобәй, 1908 елгы, сугышта үлеп кала. Әниләре Хәдичә, 1915 елгы. «Әнием бик матур иде минем», – дип искә ала торган була Сания апа. Ул Яушыйкта, аннары Саралан мәктәбендә укып сигезьеллык белем ала. Яушыйктагы «Яшәсен Ирек!» колхозында эшли.

Хәерби авылына Нурхәмәт абыйга кияүгә чыгып килә Сания апа. Хатыны бала тапканда үлеп, Нурхәмәт абый дүрт бала белән тол калган була. Сания апа Рәмис, Рәмзия, Фәрдия, Фираяга яңа әни була, аларны яратып карап үстерә, соңыннан уртак балалары Фәнис туа.



Хәерби авылында ул фермада эшли. «Утлык өстенә менеп егылып, башымны тиштем. Бик күп каным акты. Әле дә шул вакытларны искә төшереп торучы яраларым бар», – дип сөйли Сания апа.

Сугыш елларын яхшы хәтерли ул. «Ашарга черек бәрәңге, кычыткан иде. Шулар коткара иде безне. Авылда (Яушыйкта) төрмә бар иде. Шул төрмә начальнигының хатыны, бик яхшы күңелле апа, беркөнне безгә борчак бирде. Бу борчакны төйдек. Ул безгә шактыйга җитте», – дип искә ала торган була. Бүгенге көндә Сания апа исән түгел инде.

**Харисов Нури (Нурмөхәммәт) Харис улы** 1933 елда Хәерби авылында Галиев Харис Гали улы (1906 елгы) һәм Хөсниҗамал Сибгатулла кызы (1910 елгы) гаиләсендә туа. 1935 елны Галиевлар гаиләсе, кечкенә Нурины алып, Боровичи шәһәренә (Новгород өлкәсе) күчеп китә. Әти-әнисе заводка эшкә урнаша, торуын шәһәр читендәге посёлокта, фатирга кереп торалар. Нурины

хуҗа хатын карый. Күпмедер вакыт узгач, шәһәргә күченәләр. 1936 елда Харис белән Хөснижамал гаиләсендә тагын бер малай – Минзариф туа, ләкин ул яше дә тулмый үлә. Бераздан Мингариф (1938) һәм Маисә (1940) туып, гаилә ишәя. 1939 елда әтиләре совет-фин сугышында катнаша. Бөек Ватан сугышы башлангач та, икенче көнне үк фронтка китә. «Мемориал» сайты мәгълүматлары да шуны раслый: Харис Галиев 1941 елның 23 июнендә сугышка алынган, укчы булган. 12 августта аның соңгы хаты килә, шуннан соң элемтә өзелә, ягъни шул вакыттан ул хәбәрсез югала. Хөснижамал апа ирен 1948 елда да эзләтеп карый, аңа шундый ук җавап килә.

«Сугыш башланып бер ай да узмагандыр, Боровичи шәһәренең хәрби аэродромын немец бомбага тотты (1941 елның 30 июле булырга кирәк). Без малайлар белән Мста елгасында су коена идек, куркудан качып беттек. Төннәрен немец якты ракета атып десантлар төшерә иде. Корал заводы кешеләре аларны тотып алып кайталар. Бу вакытта тулай торакта кем бар, шуны уятып алып чыгалар. Июль айларында күпмедер балаларны һәм аналарны поездга утыртып, Урал ягына озаттылар. Юлда фашист аларны бомбага тотып, исән калганнары кире әйләнеп кайттылар. 1941 елның октябрь аенда башкалар белән бергә әни белән безне дә поездга утыртып Уралга җибәрделәр. Безне күпмедер вакыт самолёт озата барды», – дип искә ала Нури Харис улы. Поезд Горький шәһәренә җиткәч, Хөснижамал апа өч баласы белән төшеп кала һәм пароходка утырып Казанга, аннан Хәербигә кайта. Өйләрендә ул вакытта дүрт баласы белән Харис абыйның апасы Хәдичә яши. Өй бик зур, кышка әзерләнмәгән, почмагыннан урам күренеп торганга бик салкын, ягарга утын да, ашарга ризык та юк. Колхозның бәрәңгесе, октябрь ае булуга карамастан, әле алынып бетмәгән. Хөснижамал апа яңгыр астында бәрәңге ала. Кайтуларына 2 ай дигәндә эчләре бик каты авыртып, кече ике бала – Мингариф белән Маисә үлеп китә.

Әй, язмыш, язмыш! Бер анага күпме кайгы! Гомере буе ирен көтеп, балалары өчен сагышланып яши Хөснижамал апа. Ярый әле бер бөртек булса да баласы – улы Нурмөхәммәте исән кала. Пенсиягә чыкканчы колхозда эшли ул. Улы һәм аның гаиләсе белән яшәп, 1990 елда 88 яшендә вафат була.

Нури Харис улы 1949 елда җидееллык мәктәпне тәмамлый һәм колхозда эшли башлый. Уку чорында да колхоз эшләреннән калмый: печән әзерләүдә катнаша, атлар саклый һ.б. Караишево авылы янында электр станциясе төзүдә катнаша, носилка белән балчык ташый, үгез һәм ат җигә. «Электр станциясенең буасын ныгыту өчен 12 чакрымдагы Обухово авылы янында, Мишә елгасы буенда җәен таш чыгарабыз, кышын, боз каткач, үгезләр белән ташыйбыз. Беркөнне боз ватылып, үгез суга төште, кешеләр күп булу белән генә аны

99

# А Н К Е Т А

1. Фамилия Имя Отчество разыскиваемого — Голеев Харис

2. Год рождения — 1906

3. Место рождения: область, район, с/совет, деревня, город. — Татарская АССР, Стабишевского р-на, с. [illegible]

4. Каким военкоматом призван, когда в какую часть и когда направлен. — Боровичским РВК Новгородской обл. 23 июня 1941 года

5. Военное звание — солдат

6. Занимаемая должность в Красной Армии — стрелок

7. Когда прекратилась письменная связь — 12 августа 1941 г.

8. Воинский адрес по последнему письму. — Адреса нет

9. Где проживал до призыва область район, с/совет деревня город. — г. Боровичи Новгородской обл.

10. Дополнительные данные о разыскиваемом: письма товарищей, сообщения в/части, свидетельские показания и др. приложить к анкете. — Дополнительных данных не имеется

3.44

11. При наличии сведений о гибели указать: где и когда место, число, год /погиб: место похорон. — Сведений о гибели нет

---

12. Кто разыскивает: фамилия имя отчество заявителя- — Галеева Хусну

---

13. Родственное отношение заявителя к разыскиваемому: отец, мать и жена и др. — жена

---

14. Подробный адрес места жительства заявителя: область, район, с/совет, деревня город. — Татарская АССР Старошешминского района село Пирви

---

15. Личное заключение Военкома по маке для дам /военнослужащий: погиб, умер, пропал без вести. — Пропал без вести в августе 1941 г.

---

16: Об"яснение:

«17» мая 1[illegible] г.

Райвоенком
Майор а/сл:- /Гаврилов/

тартып чыгара алдык. Мин үгез өстенә толыбымны яптым. Иртәнгә үгез толыпны таптап, ертып бетергән», – дип сөйли Нури абый. 1953–1954 елларда тимерчелектә, 1954 елдан фермада учётчик, ферма мөдире, кырчылык бригадасы бригадиры булып эшли. 1978 елның ноябреннән 1984 елның февраленә кадәр авыл советы председателе, соңыннан, пенсиягә чыкканчы, Хәерби авыл советында Госстрахның штаттан тыш агенты була.

1958 елда Нури абый белән Рауза апа гаилә корып җибәрәләр. Өч балалары туа: Фирдәвес (1959 елда туган), Диләфрүз (1961), Марат (1964). Хатыны Рауза апа (1937 елгы) гомере буе башта колхозда, аннан соң совхозда бухгалтер булып эшли. Фирдәвес тә, әнисе юлы белән китеп, бухгалтер белгечлеге ала. Уртанчы бала Диләфрүз – укытучы, Марат – шофёр.

«Көздән калган бәрәңгене яз көне иртән, кояш чыкканчы, туң белән җыеп кайта идек. Аны киптереп, төеп он ясыйлар, күмәч пешерәләр. Юка итеп пешерелгәне бигрәк тә тәмле була иде, тәме әле дә авызда торган кук. Шулай да өшегән бәрәңге, алабута, терлек үләксәсен башка беркайчан да, берәүгә дә ашарга язмасын иде. Сугыш вакыты һәм аннан соңгы чорның авырлыгын сөйләп тә, язып та бетереп булмый. Авылда миннән күбрәк белә торган олырак кешеләр дә бар. Әле менә санадым, бүгенге көнгә Хәербидә миннән олырак, 1927–1930 елларда туган 5 ир кеше, 12 хатын-кыз бар», – дип тәгәлли Нури абый сүзен.

Әйе, өлкән буын әкренләп китә бара. Алар үзләре белән үткәннәрне, тарихны алып китә. Тормышның нинди авыр сынаулары алдында да тез чүкмәгән әби-бабайларыбыз, абый-апаларыбызны күбрәк сөйләтәсе, сөйләгәннәрен теркәп калдырасы иде!

**Хәлилова Камилә Хәбибулла кызы** 1926 елның 5 апрелендә Лаеш районы Хәерби авылында дөньяга килә. Әтиләре Хәбибулла абзый сугыш башланган көнне үк фронтка китә. Әниләре кулында алты бала кала. Камилә апа әтиләрен озаткан көнне бүгенгедәй хәтерли.

«Миңа 15 яшь вакытта сугыш башланды. Җәй көне, кызу эш вакыты иде. Әнинең йөзе кояш нуры капланган болытлы көндәй караңгыланган, күзләре тулы сагыш. Әтине озаттык. Бөтен тормыш мәшәкате безнең кечкенә иңнәребезгә өелеп калды. Иртә олыгайтты безне бу еллар. Әни белән көне-төне эштә. Иген өлгергәч, безгә ызанлап иген кырын бүлеп бирәләр. Аның очыкырые күренми, бик озын була иде. Без әни белән иртүк китәбез, кеше килгәнче урабыз. Урак белән урганга кулларыбыз кабарып чыга иде, төнлә генә кайтабыз. Ашлыкны учма-учма итеп урып, зур көлтәләргә бәйлибез, күтәреп илтеп тракторга төйибез. Күтәреп булмагач, елыйбыз да. Үзебез дә ябык кы-



на, ашарга-эчәргә юк. Черек бәрәңгедән күмәч пешереп ашыйбыз, шуның өстенә ураза да тотабыз. Аякларыбызда тишек чабаталар, өстебезгә кияргә юк», – дип искә ала ул елларны Камилә апа.

Әтиләр кайткач, барысы да җайланыр дип, үз-үзләрен юатып, тырышып-тырмашып эшли алар. Бер эштән дә куркып тормыйлар. Әтиләреннән, абыйларыннан хат яки берәр хәбәр килсә, куана-куана күршеләр белән укыйлар, шул шатлыктан дәртләнеп, сөенә-сөенә эшлиләр.

«Кыш көне безне, 18 яше тулган кызларны, урман кисәргә җибәрделәр. Без япь-яшь бит әле, бер ай буе кышкы салкында агач кистек, яктык, тунадык, билгеле бер озынлыкта турап, өйдек. Чабаталар тишелеп, аякларыбыз канап чыга иде. Учак ягып җылынырга өлгермибез, бригадир безне тагын эшкә куа. Ул безгә бик усал булып күренде инде. Аңа да җиңел түгел, план үтисе бар бит. Бик нужа күреп яшәдек», – дип күзләрен сөртеп ала Камилә апа. Сугышка җибәрәсе торбаларны чистарту эшендә катнашканын да яхшы хәтерли: «Буе белән сузылган торба эченә кереп китеп, эчләрен чистартабыз, тыннар бетә иде». Сугышның азагын җиткерү өчен җан-фәрман тырыша алар.



Камилә апаның уйлары-хыяллары тормышка аша, Җиңү көне килә. «Сугыш беткән көнне беркайчан онытасым юк. Берәү яулык болгап басуга таба чаба. «Сугыш бетте! Сугыш бетте!» – дип кычкыра. Без, җәй кереп килә бит, тагын кырда. Әлеге яңалыкны ишеткәч, эшләребезне ташлап авылга чаптык. Үзебез елыйбыз, үзебез сөенәбез», – дип сөйли ул.

Сугыш беткәч, иң элек абыйлары кайта. «Хәзер дә уйлап утырам әле. Без, җиткән кызлар бит инде үзебез, сабый балалар түгел, абыйдан: «Әтине күрдеңме, ул кайчан кайта?» – дип сорап аптыратабыз. Ул безне тынычландырыр өчендер инде: «Күрдем, күрдем, шушы көннәрдә кайтып җитә», – ди. Ышанабыз, сөенәбез», – дип шул мизгелләрне күз алдына китерерлек чынлык белән, нечкәләп сөйли Камилә апа.

Әтиләре Хәбибулла абзыйга да туган ягына әйләнеп кайтырга насыйп була. Тик ул ике айдан соң гына кайта. Тормыш әкрен генә җайга салына, түгәрәкләнә башлый.

Камилә апа сугыш беткәч, 1947 елда Бөек Ватан сугышы ветераны Хәлилов Сибгатулла Хәлил улына кияүгә чыга. Сибгатулла абый сугыштан яраланып, бер кулсыз кайта (2 нче группа инвалид). Аның ике абыйсы, Хабулла белән Миңнулла, сугышта үлеп кала. Көчле ихтыярлы кеше була Сибгатулла абый, авырлыклар алдында югалып калмый. Киресенчә, каяндыр көч алып яши. Ул каравылчы һәм кибетче хезмәтләрен башкара. Кечкенә генә йорт сатып алалар. Гаиләләрендә бер-бер артлы алты бала туа. Балалардан уңа алар, һәрберсе тормышта үз юлын таба. Һәрберсенең үз гаиләсе, яраткан эше бар. Күпсанлы оныклары, бик күп онықчыклары үсә. Камилә апа, өлкән яшьтә булуына карамастан, йорт эшләрендә дә, бакча эшләрендә дә әйдәп йөрүче. Аның уңганлыгына, олы йөрәкле, батыр әни булганына сокланмый мөмкин түгел. Бүгенге көндә Камилә апа кече кызы Нәҗия белән яши. Әмма бәйрәм көннәрендә төп йортка Камилә апа янына барлык балалары, оныклары җыела. Әни кеше өчен шуннан да зур бәхет бармы?!

**Хөсәенова Гадилә Зиннәтулла кызы** 1928 елның 20 гыйнварында Хәерби авылында Зиннәтулла Сибгатулла улы һәм Хәдичә Габдрахман кызы гаиләсендә икенче бала булып дөньяга килә. Шат күңелле, тырыш, шигъри җанлы кыз Хәерби мәктәбенең 7 нче сыйныфын яхшы билгеләренә генә тәмамлый. Кечкенәдән укытучы булу теләге белән яшәгән ундүрт яшьлек кызның хезмәт юлы яшелчә бригадасыннан башлана. Тырышлыгын күреп, аны звено җитәкчесе итеп куялар. Иртәнге сәгать өчтә торып яшелчәләргә су сибү, носилка белән тирес ташу, торфлы балчыкны иләп тирес өстенә түшәү, чүп утау, яшелчәләрне утырту, уңышны ярыша-ярыша җыеп алулары, иптәшләренең тырыш, дустанә мөнәсәбәттә булуы турында ул сагынып сөйли. Эшен шул кадәр яраткан Гадилә Зиннәтулла кызы аны алыштыру турында инде уйламый да, гомере буе кырчылык бригадасында эшли, 40 еллык гомуми эш стажы бар. Хезмәт ветераны.

**Хөсәенов Шафик Вафа улы** 1931 елның 10 гыйнварында Вафа Хөсәен улы һәм Миңнегарифә Мөхәммәтша кызы гаиләсендә дүртенче бала булып туа. Ул үзенең хезмәт юлын шулай ук яшелчәчелек бригадасында ат белән су ташучы булып башлый. Аннан шоферлыкка укый һәм колхоз председателе Гайнетдинов Салихҗанның шоферы булып эшли. Әтисе Вафа авырып киткәннән соң, 1959 елда әтисенең эшен дәвам итеп, Лаеш райпосында ти-



ре җыючы булып эшли. Хезмәт ветераны. Тырышлыгы өчен күпсанлы Мактау кәгазьләре, кыйммәтле бүләкләр белән бүләкләнә. Аны тирә-як авылларда да зур ихтирам белән искә алалар. 2000 елның 20 февралендә вафат. Гадилә һәм Шафик Хөсәеновлар бергә тормыш корып 55 ел яшиләр, өч ул, бер кыз үстерәләр: Ринат, Рөстәм, Роберт, Фирдәвес. Оныклары һәм оныкчыклары күп.

**Хөснетдинов Зәкәрия һәм Ибраһимова Минсәйдә гаиләсе[1].** «Әтием, Зәкәрия Низам улы Хөснетдинов, 1931 елның беренче гыйнварында туа. Әтисе — Хөснетдинов Низам Хөснетдин улы, 1905 елгы, әнисе — Хөснетдинова Мингаян, 1907 елгы. Икенче уллары — Хөснетдинов Габдулла Низам улы, 1934 елгы. Матур гына яшәп ятканда әниләре үлеп китә аларның. Әтигә 6 яшь, энесенә 3 яшь була. Ике ир баланы карарга авыр булгандыр, тормышны дәвам итәргә дә кирәк – Низам баба икенче хатын алып кайта. Үги әни малайларны яратып бетермәсә дә, бергә яши башлыйлар.

1941 елның җәендә сугыш башлангач, Низам баба фронтка китә. «Малайларымны ташламагыз инде», – дип борчылып, туганнарына фронттан хатлар яза. 1943 елның 2 июлендә Хөснетдинов Низамның һәлак булуы турында хат алалар. Ике малай инде әтисез дә кала. Әтигә – 12, Габдулла абыйга 9 яшь була.

Сугыш елларында нинди авырлыклар кичерсәләр дә, әти бервакытта да зарланмады, сорасак та сөйләмәде. Барыбер, ишеткәннәрдән, үзе әйтеп куйганнардан тулырак картина җыярга була. Ачтан үлмәс өчен, энесе белән землянкада торып, дуңгыз фермасында эшләгәннәр алар. Үсә төшкәч, әти ат абзарында каравылда торган. Гомере буе ат яратты, шуңа күбесенчә ат белән эшләде дә. Бик тырыш кеше иде ул. Яшь чагында җәйләрен комбайнда эшләсә, кышларын фермада терлек караучы иде. Олыгайгач, фермада гына эшләде. 1986 елда «II класслы терлекчелек остасы», 1998 елда «Хезмәт ветераны» исеменә лаек булды.

1 Мәкаләне кызлары Равия язып тапшырды; авторлар тарафыннан редакцияләнде.



Әти үзе гармунчы, сирәк булса да, җырлап җибәрергә дә мөмкин. Ашарга пешерергә маһирлыгы бар иде. Кәефе килгәндә, кичләрен мичтә бәрәңге тәгәрәтеп, ипи кыздырып, тозлы кәбестә белән ашаганнар әле дә истә. Бәрәңге боламыгын әти кебек пешерүче юк кебек тоела иде безгә. Үзе балта остасы да иде. Әнинең абыйсы Хәмәтхан белән шундый йомшак итекләр басалар иде тагын. Авылда беренчеләрдән булып радио, телевизор алып кайтты, ярты авыл жыелып карый идек. Кеше күңелен күрергә яратты. Сабан туенда атлар чабышы алдыннан җайдаклар безнең капка төбенә жыелалар иде. Әти бөтен атларны барлап, кайсысына тасма тагып, ялларын үреп, койрыкларын тасмалар белән бизәп җибәрә иде.

Әни белән танышу-өйләнешүләрен кызык итеп сөйли иде әти. «Әниегез бик усал иде ул, бөтен авыл егетләрен кыйнап җибәрә торган иде», – дип көлдерә иде. «Беренче тапкыр очрашырга барганда озын таяк, күсәк күтәреп бардым, әллә шуннан курыкты», – дип шаярта иде. «Әниегезне бик яратам», – дия иде. Гомер буе авыр эштә булган авыл агаенда менә шундый күңел. Нечкә җанлы кеше иде, мәрхүм. 2001 елның 16 гыйнварында 70 яшендә яман чирдән вафат булды. «Эх-х-х, кала атларым, җиләкле болыннарым, хуш исле мәтрүшкәләрем», – диде.



Зәкәрия Хөснетдинов, Минсәйдә Ибраһимова, Ибраһим Сафин, Маһиҗиһан апа, Минзәлия, Минниса.

Әнием, Минсәйдә Ибраһим кызы Ибраһимова, 1936 елның 13 маенда туа. Әтисе, Ибраһим Сафа улы Сафин, 1905 елгы. Әнисе, Маһиҗиһан Кәрим кызы Сафина, 1908 елгы. Ибраһим баба сугыш башлангач фронтка китә. Кечкенә генә дәү әни өч бала белән кала. «Ач чаклар күп булды, бәрәңге кабыгын пешереп ашый идек», – дип сөйли иде. Ибра-



Хөснетдиновлар Мишә буенда ялда.

һим бабаны сугышта авыр яраланып госпитальдә ятканнан соң, ярасы авыр булу сәбәпле, кайтарып җибәрәләр. Кайткач, шәһәрдә хәрби госпитальдә кочегар булып эшли, яралы солдатларга булыша. Сугыш беткәч, авылга кайтып колхозда эшли. Сугыштан соң тагын ике кызлары туа. Бабаны әле дә хәтерлим, безгә килгәндә кесәсендә күчтәнәче була иде. Сугыш ярасы үзенекен итә, Ибраһим бабай 1969 елның язында, сызлануларга түзә алмыйча үлеп китә.



Минсәйдә апа «Taste of Russia» («Россия тәме») программасына әзерләнгәндә.

Мәһиҗиһан дәү әни бик тырыш, житез иде. Урманнан чикләвек, балан, гөлҗимеш җыеп киптерә. Баланнан бик тәмле бәлеш, гөлҗимештән чәй ясый иде. 90 яшькә кадәр яшәде, апаларны: «Нинди авыру инде ул һаман», – дип әрли иде.

Әнием 7 нче классны тәмамлагач, өч ел юл төзүдә эшләп, үзенә



пальто, мамык шәл, озын балтырлы, үкчәле сапоги алып кия. Әти белән танышып, 1954 елда язылышалар, Низам бабаларның төп йортында яши башлыйлар. Олылар бу йортны авылдагы иң борынгы нигезләрнең берсе диләр. «Бер шакмак шикәребез булса, атагыз белән бер самовар чәй эчеп бетерә идек. Авыр чаклар күп булса да, бирешмәдек» – ди әни. Бер-бер артлы балалар туган. Барыбызга да исемнәребезне әти үзе кушкан. 1955 елны Мәгъсүм, 1957 елда Бибинур туган. Бибинур озын гомерле булмаган, яшь ярымлык вакытта үлгән. 1959 елгы Миңнеруй исемлесен, сигез яшендә муенына шеш чыгып, больницага салалар, ул операция өстәлендә үлә. Бу фаҗигаларны әни бик авыр кичерә, соңрак, безне шелтәләгәндә: «Апагызның тырнагына да тормыйсыз», – дия иде. 1961 елны Мәдинә, 1963 елны мин – Равия, 1969 елны Фәридә, 1974 елны Дәнис туа. Әлегә кадәр бишебез дә исән-саулар. Әти-әнигә мең рәхмәтлебез.

Әнием элек ипи пешерә иде, аңа яңа аерткан бал ягып, шунда, бал аерткан урында ук ашый идек. Артыбыздан бал кортлары оча иде. Әнинең камыр ризыклары бик уңа. Сиксәннән өстә булса да, хәзер дә пешеренергә иренми. Яшь чагында үзе белән пар итеп безгә күлмәкләр текте, чигәргә, бәйләргә өйрәтте. Җәй көннәрендә колхоз кырларында гектар-гектар чүп утады, кышын төнге каравылда фермада эшләде. Без үскәндә фермада сыер сауды. 1999 елда «Хезмәт ветераны» дигән исем алды. Аллага шөкер, ул әле һаман тәмле рызыклар пешерә, Казаннан килеп төшергән клипларда катнаша. Күптән түгел Россия актеры Оскар Кучера һәм Америка гурманы Глен Куцовский әни янында кунакта булып киттеләр. Әнием аларны милли рызыкларыбыз – бәрәңге пәрәмәче, кыстыбый, зур бәлеш белән сыйлады. Ничек пешергәннәрен төшереп «Russia today» телеканалының «Taste of Russia» («Россия тәме») программасында күрсәттеләр».

**Шакирова Җәмилә Шакир кызы** 1924 елның 12 маенда Хәербидә Мөхәммәтҗанов Шакир һәм Сибгатуллина Сара гаиләсендә дөньяга килә. Шакир абыйның беренче хатыны вафат була, ул 3 бала: Вафа, Зариф, Гайшә белән кала. Гайшә әнисеннән соң озак тормый. Шакир ике бала белән Сара исемле кызга өйләнә. Яңа әнидән туган беренче балага да Гайшә дип исем бирәләр. Аннары бер-бер артлы Фаизә, Мәдинә, Җәмилә, Закир, Кадыйр туа. Гайшә Хәербидә гомер итә. Фаизә Лаеш районы Петровский посёлогында, Мәдинә Казанда яшиләр. Закир сабый чагында үлә. Төп нигездә Кадыйр белән Җәмилә генә кала. Җәмилә иреннән яшьли аерылып, берләнбер баласын ялгыз гына үстерә.



Җәмиләнең апасы Мәдинә, Мәдинәнең ире – Нәбиулла, уртада – Җәмиләнең иренең сеңелесе, уңда – Җәмилә Шакирова һәм аның ире – Нәҗип. 1948 ел.

Сугышка кадәр Җәмиләне һәм авылдан Мәрьям исемле кызны ФЗУга укырга җибәрергә телиләр. Алар каршы килгәч, икесен дә 6 айга Казан төрмәсенә ябалар. Аннары авыр сугыш чоры... Җәмилә апа гаиләсе өчен дә җиңел булмый ул. Җәмилә апа 2005 елның октябрендә вафат.

**Шакиров Кадыйр (Габделкадыйр) Шакир улы**, Җәмилә Шакированың энесе, 1930 елда туа (документлары буенча 1931 елның апреле дип язылган). Сугыш башланганда аңа 10–11 яшь кенә була. Үсмер чагы бик авырга туры килә. Үгез җигеп, ул көнгә 8 әр мәртәбә Яңавыл кырына бара. Аннан иген көлтәләрен үзе арбага төйи, кайткач аны үзе бушата. Арбага утырып йөрми, үгез яныннан атлый, чөнки җитәкләп бармасаң, үгез атламый. Үсеп җитлеккәч, гомер буе



Кадыйр Шакиров авылдашы һәм хезмәттәше Шәйхулла Вәлиев белән. 1954 ел.




Шакировларның нәсел шәҗәрәсе.

хуҗалыкта балта остасы булып эшли. Өлкәнәйгән көннәрендә Кадыйр абыйның аяклары авырта башлап, ике аягы да тездән югары киселә. Шулай итеп, сугыш афәте, бала вакыттан күргән авырлыклар сугыш бетеп 50 ел үткәч тә үзләрен сиздерә. Җәмилә апасының бердәнбер кызы Гөлфирәне үз баласы кебек үстерешә Кадыйр абый. Әле Гөлфирәнең балаларын да, оныкларын да караша. Оныклар аны яратып «Дәү бабай» дип йөртәләр. Кадыйр абый 2008 елның мартында бу якты дөнья белән хушлаша.

Шакировларның иң олы апалары Гайшә исемле. Гайшә апаның балалары – Мәгъсүм, Галимҗан, Гайса, Ибраһим, Зәкия, Нәкыя, Шамил, Наил, Зәкирә. Бу тугыз баланың дүртесе шулай ук Хәербидә төпләнеп яши. Барысының да балалары, оныклары, инде онык балалары бар.

Шакирова Мәдинәнең ире Лаеш районы Пәрәү авылы кешесе, Нәбиулла исемле. Аларның балалары: Роза, Илдар, Ренат.

Шакирова Фаизәнең беренче ире – Хәерби авылы кешесе Кәримов Давыт. Давыт абзый Бөек Ватан сугышында хәбәрсез югала. Аннан өч бала – Дания, Фоат, Равил туып кала. Фаизә апаның икенче никахыннан туган балалары – Талия һәм Равия.

**Шәрәфиева Халидә Шәрәф кызы** 1935 елның 1 гыйнварында Лаеш районы Хәерби авылында туа. Әтисе Шәрәф, әнисе Фатиха исемле булган. Гаиләдә алар тугыз кыз, бер малай була. «Дүрт бала, шул исәптән берданбер малай да, авырып, кечкенә вакытта үк үлә. Исән калган Сәлимә, Әминә, Хәбирә, Сабира, Тәскирә исемле туганнарымны еш искә алам», – ди Халидә апа.



Мәктәптә 7 класс белем ала. «Хәтирә апа укытты безне, читтән дә килеп укыталар иде. Ләкин мин укуны бер дә яратмадым. Ә эш дигәндә атлыгып тордым», – ди Халидә апа. Мәктәпне тәмамлау белән, ул яшелчәчелеккә эшкә чыга. Гомере буе шунда, гел кул көченә корылган эштә эшләп пенсиягә китә. «12 шәр түтәл «чернушка»ны тезләнеп утаганныкыдыр, хәзер дә тезләр бик сызлый. Әле без аны Киндерлегә



үзебез алып барып тапшыра идек», – дип искә ала Халидә апа.

Әтиләре Шәрәф абый сугышка киткәч кичергән бик тә авыр елларны да яхшы хәтерли ул. Сугыш беткәч, әтиләре исән-сау туган якларга әйләнеп кайткан.

Халидә апа кияүгә чыга, ләкин уртак тормыш бәхет китерми. Хәзерге көндә ул ялгыз яши. Туган-тумачалары гел кайтып, хәлен белеп торалар. Олы булуына карамастан йорт эче, бакча эшләрен үзе башкара әле. Һәр көн күрше-тирә балаларын юлга чыгып матур сүзләр белән мәктәпкә озатып кала, илгә-көнгә изге теләкләр тели ул.

# XV БҮЛЕК

# СОЛДАТЛАР

Уллары җитлегеп килгән, ашкынып унсигезе тулганны көткән гаиләләрдә яз-көз күңелле дә, моңсу да мәшәкатьләр барлыкка килә: егетне армиягә озатасы бар. Солдат булу гомер-гомергә дәрәҗә саналган. Хәербидә солдатка озатканда егетнең туган йортында дус-ишләре белән озату мәҗлесе уздырыла, йорттан-йортка кереп саубуллашып китү дә, гармуннар уйнап авыл урамнарын әйләнеп чыгу да нәкъ элек-электән килгәнчә. Һәр кеше үзенең баласын исән-имин кайтсын дигән теләк белән озатып кала. «Илләр-көннәр тыныч була күрсен», «Сугыш кына булмасын» – бу сугыш хәсрәтләрен күргән халыкның иң ихлас теләкләре. Әмма ул куркыныч әллә каян гына чыгып, газизләребез гомеренә яный. Әйтерсең, һәр буынның үз сугышы булырга тиеш. Тыныч вакытта да солдат хезмәте – солдат хезмәте инде ул. Көтелмәгән бәла-каза анда ешрак сагалый. Үз аяклары белән чыгып китеп, табутка салып кайтарылган солдатлары да бар Хәербинең... Бу бүлек авылның каһарман солдатларына багышлана.

## ИЛДАР КАШАПОВ

Илдар Галләм улы 1959 елның 26 маенда Хәерби авылында туа. Мәктәпне тәмамлагач, Лаешта һөнәри-техник училищеда укып кайта. Армия хезмәтенә



алынганчы авылда тракторчы булып эшли. 1977 елның көзендә Совет Армиясе сафларына алына. Башта ул Хабаровск шәһәрендәге 35302 нче хәрби частьта диңгезче булып хезмәт итә башлый. Аннары аларны Сахалин өлкәсе Курил районының Буревестник бистәсендәге 34 нче һәм 24 нче отрядларга күчерәләр. Илдар Кашапов, демобилизация турында хәрби боерык чыкканнан соң, кайтыр вакыт җиткәч, Тын океанда 1979 елның 20 октябрендә булган көчле шторм вакытында, 20 яшендә һәлак була. Әниләренә кичтән: «Әни, кайтырга чыгам», – дигән хат, ә икенче көнне иртән «Сезнең улыгыз Кашапов Илдар хәрби бурычын үтәгән вакытта фаҗигале төстә һәлак булды» дигән телеграмма килә.





1. Илдар Кашапов. 2. Диңгезчеләр (сулдан уңга): Мәгъсүм, Иңгел, Илдар, Илшат, Мөнир, Кәлим.

Илдарның әтисе – Бөек Ватан сугышы ветераны, 41 ел мәктәптә укытучы булып эшләгән Кашапов Галләм абый. Әнисе – Мөнәвәрә апа. Илдар – аларның төпчек уллары.

«Исеме Тын океан булгач, тын дип белдем,
Котырына диеп белмәдем.
Бәхил бул, балам, тыныч йокла,
Син үскәндә, синнән кайгы-хәсрәт күрмәдем», – дип яза әнисе Мөнәвәрә бетмәс әрнүләрен шигъри тезмәләргә салып.

1990 елларга кадәр мәктәптә пионер отрядлары Илдар Кашапов исемен йөртә.

## ӘФГАНСТАНДАГЫ СУГЫШТА КАТНАШУЧЫЛАР

2019 елның 15 февралендә Әфганстаннан совет гаскәрләренең чикләнгән контингентын чыгаруга 30 ел тулу уңаеннан «Хәтер китабы» редакциясе» ике томлы «Книга Памяти ветеранов боевых действий в Афганистане (1979–1989)» («Әфганстандагы сугыш хәрәкәтләре ветераннарының Хәтер китабы (1979–1989)») бастырып чыгарды. Татарстаннан бу сугышта 11,5 меңнән артык кеше катнашкан, шуларның 296 сы сугышчан хәрәкәтләрдә һәлак булган яки яралардан үлгән. Хәерби авылының әфганчы солдатлары исемлеген шушы китаптан алып бирәбез:




**Билалов Илфар Низам улы**, 1962 елда туган, туган җире: Лаеш районы, Хәерби авылы. 1982 елда Лаеш районы хәрби комиссариаты тарафыннан чакыртылган. Әфганстан Демократик Республикасында 1982 елның июленнән 1983 елның 14 февраленә кадәр: рядовой, машина йөртүче; хәрби часть кыр почтасы 51087. Бүләкләре: Кызыл Йолдыз ордены (үлгәннән соң). 1983 елның 14 февралендә һәлак булган, Лаеш районы Хәерби авылында җирләнгән.

**Насыйбуллин Равил Галимҗан улы**, 1963 елда туган, туган җире: Лаеш районы, Хәерби авылы. 1981 елда Лаеш районы хәрби комиссариаты тарафыннан чакыртылган. Әфганстан Демократик Республикасында 1982 елның 31 декабреннән 1983 елның 15 июненә кадәр: ефрейтор, өлкән сапёр, хәрби часть 2066. Бүләкләре: «Сугышчы-интернационалистка рәхмәтле әфган халкыннан» медале. 2015 елның 26 июлендә вафат, Лаеш районы Хәерби авылында җирләнгән.

**Юнысов Әюп Гәрәй улы**, 1961 елда туган, туган җире: Лаеш районы, Хәерби авылы. 1980 елда Казан шәһәренең Мәскәү районы хәрби комиссариаты тарафыннан чакыртылган. Әфганстан Демократик Республикасында 1982 елның 1 гыйнварыннан 1982 елның 15 маена кадәр: моторист-механик, хәрби часть кыр почтасы 38021. Бүләкләре: «Сугышчы-интернационалистка рәхмәтле әфган халкыннан» медале.

## ИЛФАР БИЛАЛОВ

Илфар Низам улы Билалов 1962 елның 4 гыйнварында Хәерби авылында туа. 1969 елда беренче класска укырга керә. Авыл мәктәбендә дүрт ел укыгач, Казандагы 10 нчы интернат-мәктәпкә килә. 8 нче сыйныфны тәмамлагач, Әтнә авыл хуҗалыгы техникумында укып, инженер-механик белгечлеге ала. Ул татарча көрәш белән шөгыльләнә, шахмат уйнарга ярата, көрәшеп, яшьләр арасында батыр булып та кала.

1981 елның көзендә Совет Армиясе сафларына чакырыла, ләкин аны кире кайтарып торалар. 1982 елда аны яңадан хәрби хезмәткә чакырып алалар һәм Әфганстанга җибәрәләр.

1983 елның 14 февралендә сугышчан бурычын үтәгәндә Илфар Билалов каты яралана һәм Ташкенттагы госпитальгә җибәрелә, яралардан тернәкләнә алмыйча, шунда вафат була. Үлгәннән соң Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнә. Хәербидә җирләнә.



«Дәү әнием белән абыйсы Мансур аның янына госпитальгә баралар. Ләкин дәү әниемә улын соңгы тапкыр исән килеш күрергә насыйп булмый. Алар хушлашырга өлгерми калалар. Ана кеше өчен үзенең баласын югалтудан да зуррак хәсрәт юктыр дөньяда. Илфар абыйны югалту барысын да бик зур кайгыга сала. Аңа бит бары егерме бер яшь кенә була», – дип яза сочинениесендә Илфарның сеңелесе Рәмзиянең кызы. Йөрәк әрнеткеч сүзләр...

Хәерби урта мәктәбендә Илфар Билалов хөрмәтенә мемориаль такта ачылган, аның истәлегенә район күләмендә милли көрәш ярышлары үткәрелә. Элек пионер отряды аның исемен йөртә иде. Хәзерге вакытта Хәербидә Илфар Билалов исемендәге урам бар.

Илфар Билаловның үләренә ай ярым кала туганнарына язган хаты:

«Сәлам Әфганстаннан!

Исәнмесез, минем өчен якын булган туганнарым, әти, әни, Нияз абый, Рәмзия сеңелем! Сезгә бик күп сагынычлы солдат сәламнәре белән хат язучы улыгыз Илфар. Сәлам шулай ук абыйларның барысына, Әнисә апаларга, күрше тирәләргә һәм мине сораучыларга. Кыскача сәламем тәмам.

Минем хәлләргә килгәндә, әйбәт кенә хезмәт итеп ятам. Ашау әйбәт, юынырга мунчасы бар. Үзебезгә торырга казарма төзедек. Хәзер командировкаларга йөрибез. Монда бик тыныч, минем өчен борчылмагыз. Үзегезнең хәлләр ничек соң? Әти больницадан чыктымы әле? Әни авырмыйча гына йөреп торамы? Нияз абый эшләп йориме? Рәмзия, үзеңнең укуларың ничек бара? Тырышыбрак укы, укуның кирәге чыга аның. Абыйлар, Әнисә апалар кайталармы? Рәмзия, сиңа мин безгә бирелә торган акчаны җибәрәм, чек дип атала. 1, 2, 5, 10, 50 тиенлек һәм 1, 3 сумлык бирелә солдатларга. Бер айга 9 сум 20 тиен бирәләр. Афганистанның үз акчасын афгани дип йөртәләр. 100 афганиләре 1 сум 46 тиенгә генә тора. Сез анда XX (20) гасырда яшисез, ә мин монда 14 нче гасырда гына яшим. Монда 1361 нче ел. Бездәге 14 нче гасырга охшаган да, бик артта калган ил. Монда Яңа ел да март аенда гына. Мин Яңа елны яхшы гына каршы алдым. 4 солдат, 1 офицер идек. Елка итеп бер нарат ботагы бизәдек. Кибеттән мандарин, вафли, конфетлар сатып алдык. Кофе кайнаттык, пылау пешерттек. Сез ничек каршы алдыгыз Яңа елны, туганнар бергә җыелып


Награжден орденом — Красной Звезды
№ ордена — 3827864
Указом Президиума Верховного Совета СССР № 936-I от 25.12.1989 г.
от ... 19... г.
от ... 19... г.
от ... 19... г.
М. П.
Секретарь Президиума Верховного Совета СССР
... 19... г.
1





РЕСПУБЛИКА АФГАНИСТАН
В соответствии с Указом Президента Республики Афганистан от 15 мая 1988 г. награжден медалью „ВОИНУ-ИНТЕРНАЦИОНАЛИСТУ ОТ БЛАГОДАРНОГО АФГАНСКОГО НАРОДА“
Фамилия — Билалов
Имя — Ильфар
Отчество — Низамович
№
Дата
3


СОЮЗ СОВЕТСКИХ СОЦИАЛИСТИЧЕСКИХ РЕСПУБЛИК
ВОИНУ-ИНТЕРНАЦИОНАЛИСТУ
ПРЕЗИДИУМ ВЕРХОВНОГО СОВЕТА СССР ЗА МУЖЕСТВО И ВОИНСКУЮ ДОБЛЕСТЬ, ПРОЯВЛЕННЫЕ ПРИ ВЫПОЛНЕНИИ ИНТЕРНАЦИОНАЛЬНОГО ДОЛГА В РЕСПУБЛИКЕ АФГАНИСТАН, УКАЗОМ от 28 декабря 1988 г. НАГРАДИЛ
Билалова Ильфара Низамовича
ГРАМОТОЙ ПРЕЗИДИУМА ВЕРХОВНОГО СОВЕТА СССР ВОИНУ-ИНТЕРНАЦИОНАЛИСТУ.
Председатель Президиума Верховного Совета СССР
Секретарь Президиума Верховного Совета СССР
Москва, Кремль. 28 декабря 1988 г.
4







1. Илфар Билаловның Кызыл Йолдыз ордены таныклыгы. 2. Кызыл Йолдыз ордены. 3. «Сугышчы-интернационалистка рәхмәтле әфган халкыннан» медале таныклыгы. 4. СССР Югары Советы Президиумы грамотасы. 5–6. Илфар Билаловның сеңелесенә язган хатлары.

утырдыгызмы? Мине искә алдыгызмы соң? Мин сезне авызга пылау капкан саен искә төшердем. Мәскәү вакыты белән каршылаганда тын гына утырдык һәм бер-беребезне котлаштык. Әфган вакыты белән каршылаганда автоматтан

аттык. Шулай итеп бәйрәм узып та китте. Хәзер туган көнгә әзерләнәм. 4 январьда 21 яшь тула бит. Озакламый командировкага барам, икенче шәһәргә. Күпмегә икәне билгеле түгел. Сезне барыгызны да Яңа ел белән котлыйм. Яңа ел сезгә зурдан-зур уңышлар алып килсен. Яңа бәхетләр теләп, улыгыз Илфар. Хушыгыз. Хат көтәм. Язылды: 2.01.1983 Мәскәүчә. 2.11.1361 Әфганча».

Илфар Билалов истәлегенә Лаеш районы Ташкирмән авылы егете Анатолий Смирнов язган шигырь:

### Унөч меңнең берсе

Әфганстан, синдә булганым юк,
Язмыш мине сиңа илтмәде.
Тик уйларым гына,
Кошлар сыман,
Үтеп керде синең чикләрне.
Таулар арасында туплар шартлый,
Ишетелеп тора атышлар.
Мондагы җир безнең егетләрнең,
Йөрәк каны белән катышкан.
Ерак Татарстан җирләреннән
Теләпме соң алар килделәр?
Чит халыкның мәнфәгатен саклап,
Туры килде җанын бирергә.
Кеше җиргә тик бер тапкыр туа,
Тормыш тик бер тапкыр бирелә.
Торгынлыкның кырыс кануннары
Китерделәр сезне бирегә.
Була алмадым синдә, Әфганстан,
Сугыш мәхшәрләре күрмәдем.
Күрдем бары яп-яшь егетләрне
Туган җиребездә күмгәнне.
Цинк табутларда илгә кайтты
Туган җирнең сөйгән уллары.
Кисте сугыш сезнең мәхәббәтне,
Киләчәккә булган юлларны.
Таулар арасында күпме җаннар
Әрнеп елап йөри, моңланып.
Кошлар сыман очып кайтыр иде
Хәербигә Илфар Билалов.
Үлем эзләп килдемени соң ул,
Хезмәт дәрте белән янганда.
Сеңлесе һәм тәүге мәхәббәте
Гөлфиясе илдә калганда.
Батыр булган Илфар, җиңә белгән,
Авыр яраланган чакта да,
Туган җиргә, газиз әнисенә
Булган мәхәббәтен саклаган.
Аякларын тездән киссәләр дә,
Тишсәләр дә тәнен дошманнар,
Туган-үскән ягы Хәербигә
Исән кайтасына ышанган.
Ташкенттагы хәрби госпитальдә
Үткәргән ул соңгы көннәрен.
Көткән... үлем белән көрәшкәндә,
Әнисенең кабат кергәнен.
Бары ишек кенә бүлеп торган
Ана белән улның арасын.
Соңгы сулышында әйткән сүзен,
Тел белмәгәч, кем соң аңласын?
Бәлки әйткәндер ул, Гөлфиягә
Әйтегез, – дип соңгы сүземне, –
Ул көтмәсен мине, син дә, әнкәй,
Бик бетермә болай үзеңне!
Без бит сиңа җиде бөртек идек,

Абыйларым тапты юлларын.
Тик мин генә, таулар арасында,
Сезгә кайгы салып югалдым.
Сеңелемә сәлам җиткерегез,
Ул бит әле сабый, аңламас.
Циркларга бара алмадык шул,
Әйтер инде – абый алдаган.
Безнең үзебезне алдадылар –
Кем өчен соң түктек канны без.
Әни, Мансур абый, кайгыгызны
Минем белән бергә күмегез!
Сезгә әйталмаган сүзләремне
Кошлар булып кайтып сөйләрмен.
Вәгъдәм үтәлмичә калган өчен,
Кичерә күр мине, сөйгәнем!
Мин иң соңгы корбан булсам иде,
Тыныч тормыштагы сугышта...
Бәлки, шулай диеп әйткәндер ул,
Яткан чакта соңгы сулышта.
Соңгы сулышында туганнарын
Кертмәгәннәр Илфар янына.
Илфар җаны, ак күгәрчен булып,
Очкан туып-үскән ягына.
Егерме яшь бит ул, бу тормышның
Иң-иң гаҗәп, гүзәл мизгеле.
Аз яшәгән, ләкин гомерендә
Аз кылмаган Илфар изгелек.
Яшьтәшләре хөрмәт иткән аны,
Намуслы һәм тыйнак булганга.
Егермедә гүргә кергән Илфар,
Чордашлары тормыш корганда.
Әфган тауларыннан килгән хатлар
Изге ядкарь булып саклана.
Өзгәләнеп хатлар укый ана –
Күз яшьләре тама хатларга.
Уйлый ана, газиз баласының
Бишектәге чагын хәтерли.
Юа вакыт сагыш-кайгыларны,
Тик юылмый ана хәтере.
Рәмзиянең моңсу карашлары
Шул чаклардан калды сакланып.
Көтә ана, газиз улын көтә,
Белгән килеш аның кайтмасын.
Сезнең кайгы – бөтен ил кайгысы,
Зинһар, ана, тыныч булыгыз!
Риваятьләр булып яши алар,
Димәк, югалмаган улыгыз.
Исән булса, белер иде Илфар
Ул таңнарда туплар атмавын.
Безнең гаскәрләрнең бөтенләйгә
Туган илләренә кайтканын.
Туплар тынды Әфган тауларында,
Җиңел сулап куйды аналар.
Тик унөч мең солдат мәңгелекккә
Шушы җирне саклап калалар.
Исән калганнарның тәннәрендә
Мәңге төзәлмәслек яралар.
Җәрәхәтле йөрәкләре, әрнеп,
Кешелеккә оран салалар.
Синдә булалмадым, Әфганстан,
Ишетмәдем туплар тавышын.
Ләкин шунда һәлак булды минем
Күрше авылдагы танышым.
Шигыремне укып, туган ягым,
Илфар белән кабат танышсын!
Ишетсеннәр әйтә алмаган сүзен,
Ишетсеннәр аның тавышын!
Хәербинең курку белмәс улы,
Чит халыкны яклап баш салды.
Онытмаслар туган ягыбызда
Унөч меңнән берсе – Илфарны!

# РАВИЛ НАСЫЙБУЛЛИН



Равил Галимҗан улы Насыйбуллин 1963 елның 1 гыйнварында Хәербидә туа. 1978 елда Хәерби мәктәбен тәмамлап, совхозда эшли башлый. 1980 елда Лаеш авыл хуҗалыгы һөнәр училищесына укырга керә. Аннан тракторчы-машинист һөнәре алып чыга. Хәерби мәктәбенең кичке бүлегендә укып урта белем ала. 1981 елның маенда Совет Армиясенә чакырыла. Башта Ерак Көнчыгышта, Кытай чигендә шофер булып хезмәт итә. Яхшы хезмәт иткәне өчен «Чик буе гаскәрләре отличнигы» билгесе белән бүләкләнә. Ефрейтор дәрәҗәсе ала. 1982 елның декабрендә Равилне Әфганстанга җибәрәләр. Таулы-ташлы Әфган җире буйлап ул машинасы белән сугыш кирәк-яраклары ташый. Үлем белән күзгә-күз очрашырга да туры килә. Бер-



РЕСПУБЛИКА АФГАНИСТАН

В соответствии с Указом Президента Республики Афганистан от .......... 1988 г. награжден медалью „ВОИНУ-ИНТЕРНАЦИОНАЛИСТУ ОТ БЛАГОДАРНОГО АФГАНСКОГО НАРОДА"

Фамилия Насибуллин

Имя Равиль

Отчество Галимзянович

№

Дата 23 февр. 1989.



„70 лет ВООРУЖЕННЫХ СИЛ СССР"

УДОСТОВЕРЕНИЕ

Насыбуллин Равиль Галимзянович

в соответствии с Указом ПРЕЗИДИУМА ВЕРХОВНОГО СОВЕТА СССР от 28 января 1988 года награжден юбилейной медалью „70 ЛЕТ ВООРУЖЕННЫХ СИЛ СССР"

От имени ПРЕЗИДИУМА ВЕРХОВНОГО СОВЕТА СССР медаль вручена 19. 02 1988 года

М. П.



УДОСТОВЕРЕНИЕ

ЕФР. НАСИБУЛИН РАВИЛЬ ГАЛИМЗЯНОВИЧ

Приказом начальника войск Краснознаменного Дальневосточного пограничного округа КГБ СССР награжден нагрудным знаком «ОТЛИЧНИК ПОГРАНВОЙСК» II СТЕПЕНИ

Зам. Начальник войск Краснознаменного Дальневосточного пограничного округа КГБ СССР

М. П. генерал-майор В. СТУС



Насыбуллин Равиль Галимзянович

приказом Министра обороны Российской Федерации от «17» 12 2013 г. № 900 награжден (а) юбилейной медалью «В ПАМЯТЬ 25-ЛЕТИЯ ОКОНЧАНИЯ БОЕВЫХ ДЕЙСТВИЙ В АФГАНИСТАНЕ»

Р.Насыйбуллинның армия хезмәте бүләкләре.



Сәрия һәм Равил Насыйбуллиннар.

вакыт машинасына ут каба. Бите, тәннәре пешеп, Пяндж шәһәрендә ике ай госпитальдә ята. Сугыш хәрәкәтләрендә күп иптәшләрен югалтып, тетрәнүләр кичерергә дә туры килә аңа. 1983 елның 15 июнендә ул туган авылына әйләнеп кайта. Совхозда тракторчы булып эшли башлый. Өйләнә, хатыны Сәрия белән бер кыз, бер ул үстерәләр. 2015 елның 25 июлендә 52 яшендә вафат була.

## ӘЮП ЮНЫСОВ



Әюп Гәрәй улы Юнысов 1961 елның 12 июлендә Хәербидә туган. Мәктәптән соң Казан шәһәренең 10 нчы интернат-мәктәбенә китә, шунда урта белем ала. Казан шәһәренең Моторлар төзү берләшмәсендә эшли. 1980 елның 11 апрелендә Армиягә китә. Башта Германия Демократик Республикасында (ГДР), аннан соң Әфганстанда хезмәт итә. Ме-


РЕСПУБЛИКА АФГАНИСТАН

В соответствии с Указом Президента Республики Афганистан от 23 февраля 1988 г. награжден медалью „ВОИНУ-ИНТЕРНАЦИОНАЛИСТУ ОТ БЛАГОДАРНОГО АФГАНСКОГО НАРОДА“

Фамилия Юнусов
Имя Аюп
Отчество Гараевич
№
Дата 23 февр. 1989


„70 лет ВООРУЖЕННЫХ СИЛ СССР“

УДОСТОВЕРЕНИЕ

Юнусов
Аюп
Гараевич

в соответствии с Указом ПРЕЗИДИУМА ВЕРХОВНОГО СОВЕТА СССР от 28 января 1988 года награжден юбилейной медалью „70 ЛЕТ ВООРУЖЕННЫХ СИЛ СССР“

От имени ПРЕЗИДИУМА ВЕРХОВНОГО СОВЕТА СССР медаль вручена 22 февр. 1989 года

1. Әюп Юнысов туганнан туган сеңелесе Флёра белән. 2. «Сугышчы-интернационалистка рәхмәтле әфган халкыннан» медале таныклыгы. 3. СССР Югары Советы Президиумының «СССР Кораллы Көчләренә 70 ел» юбилей медале таныклыгы.

дальләре бар. Әфганстанда хезмәт иткәндә, СССРдан Әфганстанның Хайратон шәһәре Пули-Хумри пунктына авиация керосины, дизель ягулыгы кудыру объектында эшли. Бүгенге көндә Хәербидә яши.




Төрле елларда хәрби хезмәттә булган солдатлардан мәктәпкә килгән хатлар.

# XVI БҮЛЕК

## ЯШӘЕШ, КӨНКҮРЕШ, ҺӨНӘРЛӘР



Хәерби авылы мәчете макеты. Марат Әһлиуллин эше.

Авыл гомер-гомергә үз тырышлыгы белән, үз һөнәрче-кәсепчеләре осталыгына таянып көн итә. Нинди эш кузгатсалар да, үз араларыннан шуның осталары табыла. Һөнәр, гадәттә, нәсел эчендә буыннан-буынга тапшырыла. Инде борынгыдан килгән күп һөнәрләр юкка чыккан, яисә юкка чыгып бара. Хәзер инде ат дирбияләре ясаучылар, көянтә бөгүчеләр, мичкә тартучылар, тегермән калаклары һәм ташлары ясау осталары юк, тукучылар да сирәк авылларда гына. Ә менә балта осталары, итек басучылар, мич чыгаручы, чигүче, тегүче, шәлче, умартачы, тимерче, гармунчы һ.б. бар, чөнки аларның эшенә ихтыяҗ бар. Хәерби элек-электән һөнәрле авыл булып, аның осталары тирә-якта дан тоткан. Итекче, читекче, кәләпүшче кебек һөнәрләр сүрелгәндә, яңа тормыш рәвеше белән электр кертүче, көнкүреш техникасы төзәтүче кебек яңа һөнәр осталары барлыкка килгән. Элек Хәербидә хәтта суганны да яшелчә белән сату итүче руслардан алган булсалар, хәзер ул үзе яшелчә үстерү осталары белән атаклы. Бу сәхифәдә Хәербинең аерым һөнәр осталары санап үтелер.

**Киез итек басучылар** – Кашапов Вафа, Сафин Галимҗан, Сафин Хәмәтхан, Хөснетдинов Зәкәрия.

**Мамык шәл бәйләүче** – Сәхбиева Гаҗилә.

**Чигүче** – Кушмина Роза, Абдуллина Рәҗәп.

**Тегүчеләр** – Хәйруллина Мәрфуга, Хөснетдинова Хәбирә апа (Халидә Шәрәф кызының апасы), Хәбирә апа (фамилиясе билгесез), Сәмигуллина Саимә, Шәмсеруй апа (фамилиясе билгесез), Бәдри апа (фамилиясе билгесез), Насыйбуллина Нурия, Галәветдинова Зөлфия, Хәмидуллина Хәтирә.

**Мич чыгаручылар** – Хәмидуллин Минвәли, Ногманов Нәҗип, Ибраһимов Шафик.

**Балта осталары –** Гыймадиев Гариф, Насыйбуллин Габдулла, Гыймадиев Габидулла, Ситдыйков Әнвәр, Шакиров Кадыйр, Закиров Искәндәр, Садыйков Әнәс, Маннапов Әһлиулла, Ярмиев Гатаулла, Ярмиев Гарифулла (шулай ук тәрәзә рамнары, ярма яргыч машина ясый, комган, ләгәннәр, тишек казан, чиләкләрне төпли), Ногманов Ибраһим абый (Шафик абыйның әтисе), Ногманов Нәҗип, Әһлиуллин Марат (тәрәзә рамнары, агач эшләнмәләр остасы; Хәербинең иске мәчете макетын эшли, ул мәктәп музеенда саклана), Ярмиев Фарук, Мостафин Нургали.

**Ут кертүчеләр** – Нигъмәтов Булат, Ризванов Мәгъсүм, Низамов Мингазиз, Вафин Алмаз.

**Умартачылар** – Мингалиев Альтап, Гарипов Салидар, Гарипов Равил, Мифтахов Равил.

**Тимерче –** Галиев Минвәли (озак еллар тимерчелектә эшли, шуңа күрә Күзнич Вәли дип йөриләр).

**Тегермәнчеләр** – Насыйбуллин Габдулла, Сафа абый (фамилиясе билгесез).

**Гармунчылар** – Абдуллин Илсур, Булатов Илдус, Вафин Наил, Вафин Хафиз, Галиев Ринат, Гаязов Миңнулла, Гаязов Фәрит, Закиров Габделхак, Минбаев Нәҗип, Минбаев Фәрит, Минбаев Шамил, Мингалиев Рәшит, Насыйбуллин Мөнир, Насыйбуллин Наил, Насыйбуллин Шамил, Нигъмәтов Булат, Низамов Рафис, Сафин Мансур, Сафин Наил, Сафин Нәҗип, Хәбибуллин Шафик, Хөснетдинов Зәкәрия, Хәмидуллин Наил.





Роза Кушмина чиккән Кушминнар нәселе шәҗәрәсе һәм сөлгеләр.




Роза Кушмина чиккән әнисе Мәрзия Вафина ягыннан нәсел шәҗәрәсе.

# XVII БҮЛЕК
# ХӘЕРБИДӘ ГОМЕР ИТҮЧЕЛӘР

Һәр гаилә тормышы – үзе бер тарих, бер китапка гына сыйдырып бетерерлек түгел. Әлеге бүлек Хәербинең илгә-көнгә тырышып хезмәт иткән, нинди эштә эшләсәләр дә, мактауга һәм хөрмәткә лаек кайбер гаиләләре, аерым кешеләре белән таныштырыр.

**Әхмәтшина Гыйззелбәнат Мөхәммәтнури кызы**, Хәербинең йөзләгән уңган-булган хатын-кызларының берсе. 1927 елның 20 сентябрендә дөньяга килеп, 2005 елның 17 августына кадәр сузылган гомер юлын Хәербидә яшәп үткәрә. Бала вакыты, үсмер чагы Бөек Ватан сугышы елларына туры килгән Гыйззелбәнат үзенең башка яшьтәшләре белән бик иртә эшкә җигелә. Колхозда нинди авыр эш бар – барысын да эшли. Көнне төнгә ялгап, Бөек Җиңүне якынайту өчен бөтен көчләрен куя алар. Сугыш тәмамлангач та тормыш җиңеләйми. Бу чорның төп авырлыгы да шушы буын җилкәсенә төшә.

1948 елның 29 июлендә Гыйззелбәнат апа «1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында фидакарь хезмәт өчен» медале, озак еллар намуслы хезмәт иткәне өчен «Хезмәт ветераны» медале, 1995, 2000 елларда Бөек Җиңүнең 50 һәм 55 еллыклары уңаеннан юбилей медальләре белән бүләкләнә.

Гыйззелбәнат апа ачык йөзле, киң күңелле кеше була. Кайчан һәм кем килеп керсә дә, аның сые әзер. Күпсанлы туган-тумачаларының бала-чагасы да, ашыйсылары килсә, мәктәптән аңа йөгерә (ул чакта укучы балаларны туклandыру оештырылмаган була). Гыйззелбәнат апаның өе мәктәпкә якын. Бала-чага бу юмарт апаның кабартмалары, балан бәлешләре белән күп сыйланган.

**Билалов Низам Билал улы** 1926 елның 5 декабрендә Хәерби авылында туа. Колхозда бригадир була. 1944 елда фронтка алына. Сугыш тәмамлангач илдәге җимерекләкләрне бетерүдә катнаша, 1950 елның 28 гыйнварында гына туган авылына әйләнеп кайта. 5 нче аерым сапёрлар батальонында сапёр була. Медальләр белән бүләкләнә. 1990 елның 16 декабрендә вафат.

**Билалова Миңнебәдәр Хөсәен кызы**, Низам абыйның хатыны. 1929 елның 11 маенда Лаеш районы Яушыйк (Курманаково) авылында туа. Низам абый белән җиде бала тәрбияләп үстерәләр. Тыл ветераны. Медальләр белән бүләкләнә. Кече уллары Илфар Билалов Әфганстанда хәрби бурыч үтәгәндә һәлак була, батырлыгы өчен Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнә. Миңне-





бәдәр апа соңгы көннәренә кадәр кече кызы Рәмзия тәрбиясендә яши. 2012 елның 1 сентябрендә вафат. Оныгы Рәзиләнең дәү әнисе турында язган иншасыннан өзек китерәбез.

«Дәү әнием 1929 елда Лаеш районы Яушыйк авылында дөньяга килә. Алты яшь тулгач, әтисез кала. Әтиләре Беренче бөтендөнья сугышында алган яраларыннан бик яшьли үлеп китә. Әниләре ике бала белән тол кала. Сугыш башлангач, абыйсы сугышка китә. Авырлык унике яшьлек дәү әниемә дә төшә. Яшь кыз бала булуына карамастан, зурлар белән беррәттән эшли ул. Иген кырларында урак уру, утын кисү авырлыгын, ачлык, ялангачлык газапларын – барысын да күрә дәү әнием. Яз җиткәч кычыткан, кузгалак җыеп, ашлар пешергәннәр. Ашарга ипи булмаган. Шуңа күрә черек бәрәңге җыйганнар, аны киптереп, он ясаганнар. Шул оннан күмәч пешергәннәр. Ул күмәч, әлбәттә, бик яхшы булмый, ләкин кая барсыннар, шуны ашыйлар. Шулай ачлы-туклы үсәргә, эшләргә туры килгән дәү әниемә. 15 яше тулу белән аны урман кисәргә җибәрәләр. Киселгән агачларны кул пычкысы белән берәр метрлы итеп турап, көненә 9–10 кубометр утын әзерли торган булган алар. Җәен бар халык печән әзерләгән, урак урган. Бер дә ял итәргә вакыт булмаган, балалар да үз балачакларыннан мәхрүм калган. Бар кешенең күңелендә курку хисе булган. Менә шулай тырышып эшләп, көрәшеп, бар авырлыкларга түзеп, безнең халык бу сугышта җиңеп чыккан.



Низам һәм Миңнебәдәр балалары белән.

Ватан өчен барган зур сугыш бетеп күп кенә еллар узгач, дәү әниемә сугыш иң рәхимсез рәвештә китереп суга, ананың бәгырь җимешен – баласын тартып ала. Ул үзенең улы Илфарны Әфган сугышында югалта. Бу кайгы аның үзе күргән газапларыннан да көчлерәк булып чыга, җанына мәңге сызлаудан туктамас яра сала».

**Вафин Кадыйр һәм Миңсылу гаиләсе**[1]. 1951 елның кышкы салкын бер көнендә безнең әтиебез Кадыйр 17 яше дә тулмаган әниебез Миңсылуны урлап алып кайта. Баба – Әхмәтша улы Вафа, заманына күрә хәлле генә кеше булса да, әти белән әнине аерым йортка (йорт дисәң күп булыр, дүрт терәүле өйгә) чыгарып җибәрә. Баба бик тырыш кеше була, чисталыкны бик ярата. Үзенең умартасы бар, өстәленнән беркайчан да бал өзелмәс иде. Бакчасында тәмле алмалы агачлар үсә иде. Әби – Әсмабикә Җаббар кызы, бик уңган-булган кеше. Уңганлыгы өчен аны «түгәрәк» дип йөрткәннәр. Без аңа Түгәрәк тәтә дия торган идек. Урак өстендә ул, кеше кишәрлекне бер әйләнгәндә, ике-өч әйләнеп чыга торган булган. Шуңа кушаматы Түгәрәк булган да. Әни бик тырыш, әти бик үткен булулары белән, бик тиз үз йортларын булдыралар. Беренче бала – Әнвәр абыебыз туа, аннары мин, өченчебез – энем Радик. Без гаиләдә өч бала үстек.



Әтиебез — Вафин Кадыйр Вафа улы, 1927 елның 12 апрелендә туган. Сугыш елларында барлык балалар белән бергә колхоз кырында башак җыйганнар, көтү көткәннәр. Сугышның соңгы елларында, яше җитсә дә, буе кыска булу сәбәпле, әтине сугышка алмаганнар, ФЗӨ мәктәбенә трактористлыкка укырга җибәргәннәр. Буй белән алдырмаса да, тырышлыгы белән алдырган ул. Башта тракторчы, аннан озак еллар ферма мөдире булып эшләде. Белеме җиде генә класс булса да, олысы-кечесе аңа киңәшкә килде. Күрше рус авыллары кешеләре бурычка акча сорап торалар иде. Йортка килгән кешене ул бервакытта да кире борып чыгармады. Тормышны җигелеп тартты. Өч баласына да югары белем алуда булышты. Әйткән сүзен үти торган кеше иде ул безнең әти. Гомумән әйткәндә, әти – баскан җирдә ут чыгара торган кеше иде. Канга салынгандыр инде, без өчебез дә җитәкче булдык, эшләгән җиребездә намус белән эшләдек. Эшебезне яраттык, булсын дип тырыштык, чөнки әти кирегә барганны яратмый иде. «Башладыңмы, эшлә», – ди иде ул безгә.

Әниебез — Вафина Миңсылу Ибраһим кызы, 1933 елның 5 маенда Хәербидә туган. Әнинең бала чагы авыр булган дисәм, ялгыш булмас. Әтисе Ибрай бабай сугышка алынган. Әни 10–12 яшендә инде колхоз кырында башак җыеп, урманда утын кисеп, барлык авыр эшләрдә катнашкан. Әбиебез – Ма-

1 Кызлары Кадрия Хурамшина язып тапшырды, авторлар редакциясендә бирелә.



Әнвәр Вафин.

һиҗиһан Сафа кызы, өйдә 5 яшьлек Минсәйдә апага казан астына ут ягып ашарга пешерергә кушып, үзе хәлле кешеләрдә ялланып эшләгән. Соңрак аны колхозга хисапчы итеп чакырганнар. Баба 1943 елда сугыштан яраланып кайткач, Казанда госпитальдә эшләгән. Әни белән әби, Казанга кадәр чана тартып барып, атна саен бабага ризык илтеп торганнар.

Әни тыныч, акыллы, эшчән авыл хатыны иде. Олы бала булу сәбәпле, өч класс белем белән калып, гомере буе колхоз кырында, фермада эшләде, соңыннан фермада бозаулар карады. Безнең өчен әни аерым ихтирамга ия кеше. Әти табучы булса, әни тапканны тота белүче. Шуңа да, мөгаен, үз гомерләренә алар биш йорт җиткереп, балалар укытып, озын матур гомер кичерделәр. Бүген әтиебез мәрхүм. Әниебезнең 7 оныгы, 11 оныкчыгы бар. Әниебез, Акъәби булып, минем белән төп йортта яши.

Олы абый Әнвәр безнең өчен һәрвакыт үрнәк булды. Ул нәрсә эшләсә, без шуны кабатладык. Өчебез дә Казан шәһәренең 10 нчы интернат-мәктәбен тәмамладык, өчебез дә институтта укыдык, Радик белән абый икесе дә армия сафларында хезмәт итеп кайттылар. Әти без сайлаган һөнәрләрне хуплады, укыган вакытта акчалата зур ярдәм күрсәтте. Без әти белән әнигә гомеребез буе рәхмәтлебез.



Радик һәм Кадрия Вафиннар.

**Вафин Хәмәтхан һәм Асия гаиләсе**[1]. Әтиебез – Хәмәтхан Вафа улы 1915 елның 21 гыйнварында Хәербидә туган. Ул башта армия хезмәтенә алына, шуннан фин сугышына керә. Анда бик салкын булуын, кунар өчен карны 2 метр чамасы казып төшүләрен сөйли иде әти. Аннан соң алар Польшага күчерелә, кавалериядә була. Хәербигә кайтып 4 ай гына торып кала әти, Бөек Ватан сугышы башлана, ул беренче көннәрдә үк фронтка китә. Ленинград фронтында 45 нче гвардия укчы дивизиясендә сугыша. Ленинградны саклаганда алар блокадада калалар. Андагы авыр көннәр турында әти бик сызла-

1 Кызлары Илнура Маликова язып тапшырды, авторлар редакциясендә бирелә.

нып сөйли иде. «Урамнан баручы ике кешенең берсе егылса, икенчесе аны торгызмый, чөнки торгызалмый, ачлыктан хәл юк, аякта көчкә басып тора идек», – дип искә алып-алып куя иде. Әти маршал К.К.Рокоссовскийны күргән, аның белән кул биреп көрәшүен дә горурланып әйтә иде. Аңа сугыштан сән-сау әйләнеп кайту насыйп була.



Хәмәтхан Вафин балалары һәм оныклары белән. 1978 ел.

Әниебез – Асия Ситдыйк кызы 1915 елның 1 декабрендә Хәербидә туган. Ул Юнысов Ситдыйк белән Газизәләрнең җиденче, төпчек балалары була. Әни сабый елларда бабайның 3 аты, 5 сыеры, Мишә елгасы буенда умарта бакчалары була. Ул умарталык соңыннан колхозга алынып, әле хәзер дә шул ук урында тора. Кечкенә чагыбызда мин, энем Наил һәм әни бөрлегән җыйганда шунда кергәнебезне хәтерлим. Умарталыкта Һади абый, Зиннәтулла абый, Галәү абый эшлиләр иде. «Әйдә, Асия, бу сезнең йорт бит, керегез», – дип чакырып алып, бал белән чәй эчертеп чыгарганнар иде. Менә шуннан соң әни безгә, бик уңайсызланып, бабайны ничек кулак дип атаганнарын, йортларын сүтеп колхозга ферма өе салырга алып китүләрен, әйберләрен, киемнәрен талаганнарын, хәтта апаларының бирнәгә дип үзләре тукыган эскәтерләрен, сөлгеләрен дә алып чыгып китүләрен, соңыннан ул киемнәрне талаучылар башлыгы булган кешенең хатыны һәм балалары өстендә күрүләрен елый-елый сөйләгән иде. Шул елны бабабыз Ситдыйкны гаиләсе белән сөргенгә сөрергә булганнар. Ул вакытта аның Камилә исемле кызының ире (Нурмөхәммәт Исмәгыйлев, төрле мәгълүматлар буенча өлкә яки кантон дәрәҗәсендәге партия секретаре), бабайның эше (дело) теркәлгән папканы гел документлар арасыннан аскарак күчереп куя икән. Бу кияү кеше бабасының гаиләсен аклап калыр өчен җитди фактлар эзли һәм ул аны таба да. Ситдыйк бабайның олы улы Габделкадыйр башта атлы кавалериядә патша хезмәтендә була, соңыннан Кызыл Армиягә күчә. Аны һәм Хәербидән Гарифулла исемле кешене (клуб мөдире булып эшләгән Исмәгыйлева Наилә апаның этисе) армиядән сбруйлары белән ат биреп бүләкләп кайтаралар. Нурмөхәммәт җизни шушы фактларны табып, бабайны сөргеннән алып калырлык документ



Асия Вафина киленнәре һәм оныгы белән.

ясата. Камилә апа белән Нурмөхәммәт җизнинең балалары укымышлы, авылча әйтсәк, зур кешеләр булдылар. Уллары Ирек ветеринария институтында доцент, кызлары Рауза Республика хәрби комиссариатында врач, икенче кызлары Сания шулай ук врач, ә аның улы балет артисты булды.

Әниемнең әнисе – Газизә Шәриф кызы. Әнинең бабасы Шәриф авыл старостасы булып торган. Бу үзе үк аның абруйлы кеше булуын күрсәтә. Менә шушы бабай казыта да инде хәзерге вакытта да аның исемен йөртүче канауны. Шәрифнең бүгенге көндә дә Хәербидә яшәүче дәвамчылары бар. Болар – аның Сафа исемле улы һәм Газизә исемле кызының оныклары, онык балалары һәм башкалар. Без дә шулар арасында бит инде, әниебез Асия – Шәриф староста оныгы.

Әниемне, әти-әнисе өстендә сөргенгә сөрелү куркынычы торган дәһшәтле дәвердә, афәттән коткару өчен, 16 яшендә үк кияүгә биргәннәр. 1937 елда аның олы баласы Гөлсем туган. Гөлсем Хәмәтхан кызы Хәерби авылы егете Мөхәммәт Зариф улына кияүгә чыгып, кайнана-кайнатасы белән төп йортта яшәделәр, 2 ул, 1 кыз үстерделәр. Хәзерге көндә исән-сау. 1941 елның октябрендә игезәкләр – Зәкәрия абый белән Сания апа туган. Колхозда бәрәңге алганда әнинең тулгагы башлана. Малайны дөньяга китергәч, тагын икенче бала да барлыгы беленгәч, әни аңын югалта. Шул хәлендә кыз бала туа, тик тавышы-тыны чыкмый. Монысы үле туды дип, баланы мүккә төреп мич аралыгына куялар, ярар инде, заманалар авыр дип, берсе генә калганга артык көенмиләр. Әмма бераздан бала төчкереп җибәрә. Сания апа



Вафиннар.

шулай яшәргә дип туган җан булып чыга. Ул елны кыш бик салкын килгән, төнлә мичнең җылысы юк. Бала чүпрәкләрен әни биленә, корсагына куеп киптергән. Игезәкләр шулай итеп үсеп җитә. Зәкәрия абый 7 классны Хәербидә укый, аннан Чабакса авылында һөнәр училищесы тәмамлап, авылда эшли башлый. Мусин Исхак абый эшли торган С-4 комбайнында ярдәмче була ул, аннары үзенә дә комбайн бирәләр. 1962 елда Сибиев Хәмәт абый белән икесен чирәм җирләрне күтәрү эшенә җибәрәләр. Андагы эш нәтиҗәләре буенча 21 көнгә Сочига юллама белән бүләкләнә ул. Энем Наил белән әле дә искә алабыз: абый чемоданын күтәреп Сочидан кайтты, ә чемодан эчендә түгәрәк сары җимешләр. «Бу нәрсә бу?» – дибез аптырашып. Ул вакытта әле әфлисунның ни икәнен дә, ничек ашаганнарын да белгән кеше юк, беренче күрүебез. Абый соңрак авылда парторг, механик, шофёр булып эшләде. Вәлиуллин Җәүдәт белән авылга газ керттеләр. Дария исемле Хәерби авылы кызына өйләнеп, төп йортта әти-әниемнәр белән бергә яшәделәр, исән-саулар, өч бала үстерделәр, оныклары, онык балалары күп. Ә Сания апа мәктәпне тәмамлагач читтән торып Алабуга культура-агарту техникумында укыды. Авылның китапханәчесе, соңрак, лаеклы ялга чыкканчы, авыл советында бухгалтер булып эшләде. Ире Шамил җизни белән ике бала үстерделәр.



Мәхмүзә Ризванова, Хәмәтхан Вафин.

1946 елның 15 июлендә Айдар абыем туа. Ул да, 7 классны Хәербидә тәмамлагач, Казанга китеп һөнәр училищесында укый. Совет Армиясе сафларында хезмәт итеп кайта. «Теплоконтроль» оешмасына эшкә керә, бүгенге көндә дә, лаеклы ялда булуына карамастан, шунда эшли. Хезмәт ветераны, 50 еллык хезмәт стажы бар аның. Хатыны Хәлимә Кәрим кызы белән ике бала тәрбияләп үстерделәр.

Мин Вафиннар гаиләсендә бишенче бала. Мәктәпне тәмамлагач, туган авылымда калдым. Ирем Нил Ибраһим улы белән кызыбызны тәрбияләп үстердек.

Энем Наил Хәербидә 8 класс тәмамлагач, урта белемне Казан шәһәренең 10 нчы интернат-мәктәбендә алды. Авыл хуҗалыгы институтының инженерлык-механика факультетын тәмамлады. Совет Армиясе сафларында булды, Ерак Көнчыгышта – Кытай чигендә хезмәт итеп кайтты. Казан шәһәренең «Горзеленхоз» оешмасында баш инженер булып эшләп, лаеклы ялга чыкты. Хатыны Венера белән ике бала үстерделәр.

Әти-әнием сөйләгәннәрне искә төшерсәң, үзе бер китап итеп язарлык. Без заманаларны авыр дибез, менә кайчан авыр булган ул. Туганнарыбыз белән бер-беребезне яратып, ихтирам итеп, әти-әни рухына дога кылып исән-сау яшәргә язсын.

**Вафин Шәрәфетдин һәм Мөбарәкшина Миңнегайшә гаиләсе**. Шәрәфетдин Вафа улы 1903 елда Хәербидә туа. Аңа 6 яшь тирәсе булганда, әниләре үлеп, ике сеңелесе белән ятим калалар. Әтисе Вафа абый яңадан өйләнеп, Шәрәфетдиннең тагын бер энесе, бер сеңелесе туа. 25 яшендә үзе гаилә корып җибәрә. Сугышта була, контузия алып кайта. Аңа да әтисе язмышын кабатларга туры килә, алдагы ике хатыннан туган өч баланы һәм Миңнегайшә апа белән уртак гаиләдә туган өч баланы тәрбияләп үстерәләр алар. Шәрәфетдин абыйның балалары: Зәкия (1930 елда туган), Хәлим (1938), Фоат (1941), Әнәс (1948), Миңневәли (1951), Зәлфирә (1953). «Өч анадан туган балалар булсак та, әти белән әни безне дус-тату булып яшәргә өйрәттеләр», – ди Зәлфирә Шәрәфетдин кызы.

Миңнегайшә Мөбарәкша кызы 1915 елның 28 мартында туа. Колхозда төрле эшләрдә эшли. «Әти дә, әни дә Хәербидә туган. Икесе дә уразалар тоталар, ә әти намазга мәчеткә йөри иде», – дип искә ала кызлары Зәлфирә. Шәрәфетдин абый 1965 елның 17 гыйнварында, ә Миңнегайшә апа 1994 елның 28 гыйнварында вафат.

**Галәвов Җамалетдин Галәү улы** 1915 елның 5 апрелендә Хәербидә туа, 1980 елның 25 мартында вафат. Колхозда фермада эшли. Һәр елны ат чабышларында беренче булып килә. Үзеннән соң ат узыштыруда беренчелек аның улы – Габдуллага, аннары Габдулланың уллары Илдус һәм Илгизгә күчә.


1


2

1. Хөсникамал һәм Җамалетдин Галәвовлар; 2. Сабантуйда.

**Галиев Минзариф һәм Минзифа гаиләсе**[1]**.** «Мин дөньяга килүем өчен әти-әниемә рәхмәтле булсам, гамьсез балачагым өчен, әти һәм әни белән беррәттән, безне баккан, тәрбияләп үстерешкән Мәгъзүзә тәтәмә дә бик зур рәхмәтлемен. Ул минем әтиемнең әнисе. Кечкенә генә буйлы, чибәр булуы өстенә, бик пөхтә һәм бик уңган да хатын иде. Мәгъзүзә тәтәм 1897 елда дөньяга килеп, шушы Хәерби авылында үсеп, авылның иң чибәр Гали исемле егетенә кияүгә чыккан. Алар бабам белән биш бала: ике кыз һәм өч ул тәрбияләп үстергәннәр. Шул малайларның иң кечесе – минем әтием Галиев Минзариф була инде. Гали бабай сугышка кадәр үк армия хезмәтенә алынган була. Сугышлар белән бергә 12 ел хезмәт иткән булып чыга ул. Әтием армия сафларына хезмәт итәргә киткәч, бабам гүр иясе булган. Шулай итеп, әти аны җирләргә дә кайта алмаган.



Мәгъзүзә апа.



Гали абый.

Әтием Минзариф 1936 елның 21 гыйнварында дөньяга килгән. Балачагы сугыш еллары ачлыгына туры килеп, авырлык белән үскән. Ләкин ачлыктан исән-сау калып, егет булып җитешеп, өч елга армия хезмәтенә китәргә насыйп иткән Ходай. Армиядән кайткач, ул минем әнием Минзифа белән танышып, гаилә корып җибәргәннәр (ул әнине урлап алып кайткан, ул елларда йола шундый). Бу 1959 елның 2 октябре булган. Әти ат җигеп, фермада терлекләргә азык ташыган, аннары сөт ташу машинасында, йөк машиналарында эшләгән. Хезмәте өчен Мактау грамоталары, медальләр белән бүләкләнгән. Ул бик әйбәт кеше иде. Авыл халкы да, күрше-күләннәр дә хөрмәт итә, ярата иде аны. Ул үзе дә һәрчак кешеләргә ярдәм итәргә әзер иде.



Уңда – Минзариф Галиев.

1 Мәкаләне кызлары Гөлүсә язып тапшырды; авторлар тарафыннан редакцияләнде.



Минзифа һәм Минзариф Галиевлар.

Инде әниемә килгәндә, Минзифа исемле бик матур, уңган гади авыл кызы булган ул. Әти аны шуңа күрә дә яраткандыр, мөгаен. Әни 1942 елның 22 августында, сугыш вакытында дөньяга килгән. Аның әтисе, Вафа баба, аягы гарип булганга, сугышка яраклы булмаган. Шуңа күрә ул авылда калып, итек басу белән шөгыльләнгән. Барлык авыл халкы аннан итек бастырган, яматырга, олтан салдырырга китерә торган булган. Ул үз эшенең остасы булып, кешеләргә бик күп яхшылык эшләгән. Әнинең әнисе – Газзә тәтә – кыска гомерле булган. Ул каты авырып, әни кечкенә чакта ук дөнья куйган. Шуннан әни үги әнисе белән үскән. Әти әнине 17 яшендә кияүгә алып кайтып, алар биш бала – ике кыз, өч ул тәрбияләп үстергәннәр. Әнием гомере буе фермада сыер савып, алдынгылар рәтеннән төшмәгән. Әниемнең дистәләгән Мактау грамоталары, Рәхмәт хатлары истәлек булып саклана. Ул әле кайнанасы Мәгъзүзә тәтәм белән 28 ел тату яшәп, аны тәрбияләп соңгы юлга озатты. Вафаты алдыннан, тәтәнең тутырма ашыйсы килеп сорагач, җәйге чиллә дип тормыйча, алар әти белән сыер суеп, тутырма да ясап ашаттылар әле тәтәгә. Менә шундый акыллы, сабыр, уңган килен булып яшәве белән ул безгә дә зур үрнәк күрсәтте. Авыр туфраклары җиңел булсын, тыныч йокласыннар, алар инде гүр ияләре. Әти 2011 елда вафат, әни 2012 елда, әтидән соң 5 айдан дөнья куйды. Шунысы үкенечле булмады, алар 52 ел буе бергә, тату-матур гомер иттеләр. Без, аларның барлык балалары, оныклары, алтын туйларын зур итеп билгеләп үттек».



Гөлүсә һәм Наил Насыйбуллиннар.

Бүгенге көндә Минзариф абый һәм Минзифа апаның биш баласы, өч килене, ике кияве, унике оныгы, унҗиде оныкчыгы бар. Уллары Айрат һәм кызлары Гөлүсә Хәербидә яшиләр. Айратның ике баласы бар. Ә Гөлүсә тормыш





ДИПЛОМ
НАГРАЖДАЕТСЯ
семья Насыбуллиных
Кирбинского поселения
за участие в зональном туре
районного конкурса «Гордость Татарстана»
в номинации «Крепка семья – сильна держава»
среди творческих семей.

Начальник отдела культуры Л.Н. Макарова

1. Насыйбуллиннар район күләмендә оештырылган конкурста. 2008 ел.
2. «Татарстан горурлыгы» конкурсында бирелгән диплом.

иптәше Наил белән дүрт бала тәрбияләп үстерделәр: Раил, Фидаил, Гөлинә, Илүсә. Балалары барысы да тигез тормышлы, биш оныклары бар. Гөлүсә сигез ел сыер савучы булып эшләде. «Иң яхшы сыер савучы» дигән Мактау грамотасы белән бүләкләнде. Хәзер ресторанда повар булып эшли. Ире Наил Казан аэропорты хезмәткәре.

**Галиевлар – мал табиблары династиясе. Галиев Габдулла Мөхәммәтгали улы** 1905 елда дөньяга килә. 1936 елда ветеринарлар мәктәбен тәмамлап, «Алга» колхозында ветеринария фельдшеры булып эшли башлый. Иң беренче эше итеп ул авыл тирәсендәге үләт базларын, көтүлекләрне, болыннарны чистарттыра. Габдулла абый эшли башлагач, терлекләрнең үлү очраклары кими. Бу бер сыердан савып алынган сөтне чиләкләп санау вакытлары әле. 1936 елда һәр сыердан бер елга 40 чиләк сөт алынса, 1940 елда бу сан 60 ка җитә. Бөтен эш җайга салынды дигәндә, Бөек Ватан сугышы башлана. Габдулла абый сугышның беренче көннәрендә үк фронтка китә. Ул кавалериядә хезмәт итә. Полкның ветеринария хәрби лазаретында сугышта яраланган атларны дәвалый. Яшь ветеринарга күп сынаулар аша үтәргә туры килә. Чигенү ачысын да, җиңү шатлыгын да татый ул. 1944 ел җитә. Безнең гаскәрләр уңышлы рәвештә алга бара. Ә тылда хәлләр катлаулана. Төп тарту көче булган атлар тилчә, корчаңгы, менингит белән чирлиләр. Сау-сәламәт бер атның булуы да зур әһәмияткә ия була. Шул сәбәпле кайбер ветеринарларны армиядән чакыртып алалар. Алар арасында Габдулла абый да була. Кайтуының икенче көнендә иртүк эшкә чыга ул. Монда эшләр яхшыдан булмый: атлар гына түгел, башка



Габдулла Мөхәммәтгали улы Галиев.



Зәки Габдулла улы Галиев.



Айрат Зәки улы Галиев.

терлекләр дә бруцеллёз, туберкулёз, корчаңгыдан интегә. Тәҗрибәле белгеч бөтен тырышлыгын һәм осталыгын куеп эшкә җигелә. Тик гомере генә озын булмый, үзе турында яхшы истәлекләр калдырып, Габдулла абый 1958 елда, 53 яшендә үлеп китә.

Әтисенең иң беренче ярдәмчесе – өлкән улы Зәки була. **Галиев Зәки Габдулла улы** 1931 елның 5 августында туа. Ул 15 яшеннән башлап 30 ел авылда мал табибы булып эшли, зирәклеге, булдыклылыгы өстенә, җаваплылык, башлаган эшен ахырына кадәр җиткерә белү сыйфатларына ия була. Хәербидә төпләнеп кала, авылдашы Рауза Хәбибулла кызына (1931–2010) өйләнеп, 6 бала тәрбияләп үстерәләр. Балалары да үзләре кебек тырыш, хезмәт сөючән булып үсә. Зәки Габдулла улы 1975 елда 44 яшендә вафат була.

Зәки абыйның эшен улы Айрат дәвам итә. **Галиев Айрат Зәки улы** 1959 елның 19 мартында гаиләдә дүртенче бала булып дөньяга килә. Кечкенәдән авыл тормышын, терлек-туар тирәсен үз итә. Армия сафларында хезмәт итеп кайтканнан соң, Казан ветеринария институтына укырга керә. Институтны тәмамлап, яшь белгеч туган авылына кайта һәм бүгенге көнгә кадәр Галиевлар династиясенең эшен уңышлы дәвам итә. Хезмәтенең нәтиҗәләре дә көттерми: еллык савым арта, һәр сыердан елына 3500 кг сөт савып ала башлыйлар; яңа туган бозауларның 99 процентын саклап калуга ирешәләр. Айрат Зәки улы яратып эшләгән эше белән хөрмәт казана, күп мәртәбә «Районның иң яхшы ветеринария врачы» дипломы белән бүләкләнә. Ул яхшы белгеч кенә түгел, менә дигән гаилә башлыгы да. Тормыш иптәше Миләүшә белән алар бер кыз һәм бер ул тәрбияләп үстерәләр. Миләүшә Мансур кызы Хәерби урта мәктәбендә рус теле һәм әдәбияты укыта.

**Гарипов Госман Гариф улы** 1912 елда Хәербидә туа. «Алга» колхозының беренче тракторчысы. Октябрь Революциясе ордены кавалеры. I дәрәҗә Ватан сугышы ордены белән бүләкләнә. 1972 елда пенсиягә чыга. Госман абый Сәлимә апа белән унике бала тәрбияләп үстерәләр. Сәлимә апа Гарипова «Герой ана» исеменә лаек була һәм «Герой ана» ордены, СССР Югары Советының Мактау грамотасы белән бүләкләнә.

**Гарипова (Зиннәтуллина) Минҗиһан (Зөлхәбирә) Гариф кызы** 1935 елның мартында Хәербидә туа. 1950 елдан 1990 елга кадәр – дүрт дистә ел сыер савучы булып эшли. Үз эшен яратып һәм намус белән тырышып башкара, шул сәбәпле аның хезмәтен югары бәялиләр. 1969, 1970, 1971, 1972 елларда СССР халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсенең (ВДНХ) бронза медальләре иясе. «Социалистик ярыш җиңүчесе» (1974), «Тугызынчы бишьеллык ударнигы», «В.И.Ленинның 100 еллыгы», «Фидакарь хезмәт өчен» медальләре, 1973 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнә. Ун ел буе Лаеш рай-










Минҗиһан Гарипова хезмәтенең югары бәяләре.






1. Минҗиһан апа оныклары белән; 2. Эштән кайткан вакыт. Кызы Зәйтүнә белән; 3. Улы Камил үзенең гаиләсе белән; 4. Минвафа һәм Минҗиһан Гариповалар.

онының иң алдынгы сыер савучысы була. Ике баласын ялгызы гына тәрбияләп үстерергә туры килә аңа. Шулай булса да, ул аларга бик яхшы тәрбия бирә.

Улы Камил мәктәпне яхшы билгеләренә генә тәмамлый. Аннан армия сафларына барып кайта. Хәербидә механизатор булып, ә аның хатыны Нурхидә Якуп кызы сыер савучы булып эшли. Уллары Наил белән Рамил икесе дә Казан авыл хуҗалыгы институтын тәмамлыйлар. Хәзер үз гаиләләрен корып яшиләр. Рамил «Газпром»да инженер, үзенең ике баласы бар. Рамил авыл хуҗалыгы министрлыгында әйдәп баручы хезмәткәр, шулай ук ике бала үстерәләр.

Минҗиһан Гариф кызының кызы Зәйтүнә мәктәпне тәмамлаганнан соң Казан шәһәрендәге 7 нче заводта эшли. Аның ире Рөстәм Шафик улы да Хәерби авылы егете. Бу гаиләдә Илнур исемле егет үсеп җитә. Илнур Казан авыл хуҗалыгы институтын тәмамлый, Оргсинтез заводында эшли. Минҗиһан апаның онык балалары да күп.

Минҗиһан Гариф кызы 2007 елның 9 августында вафат.

**Гаяз бабай һәм аның нәселе**. Хәербидә Гаяз бабайның нәсел тармаклары бик ишле. Гаяз бабай үзе яшьтән дини кеше була. Беренче хатыны үлеп киткәч, ул бер оя бала белән тол кала. Икенче хатыныннан тагын алты бала туа: Бәдретдин, игезәкләр Мәүлия белән Гарифулла, Сәлимә, Миңнегали, Ибраһим. Игезәкләр 1921 елда дөньяга килә. Ашлык уңмау сәбәпле, хәтәр ачлык була бу елны. Йогышлы авырулар таралу, сугыш афәте хәлне тагын да авырайта. Балалар, хәлсезлектән, йөрергә өйрәнгәч тә атлый алмыйлар. Гаяз бабай читкә чыгып китә (Псковка булырга тиеш). Шуннан бераз акчалар эшләп кайткач, балаларга да хәл керә. Алтынчы бала булып Ибраһим абый туа. Аңа бер яшь вакытта, Гаяз абыйның икенче хатыны да үлеп китә. Бик күп авырлыклар күргән, дөньяның ачысын-төчесен татыган бу кеше өшкереп дәвалау ысулларын белә, дога көченә бик ышана торган була.



Гаяз бабай.

Игезәк сыңары Мәүлия апа узганнарны ачынып сөйли. Сугышка кадәр ут чыгып аларның өйләре янып бетү фаҗигасе бар тагын. Шушы хәлләрдән соң, Казанда яшәүче туганнары тиешле бер кеше, тамагың тук булыр дип, кызны макарон фабрикасына эшкә урнаштыра. Бертуган энеләрен дә карашасы бар бит. Сугыш башлангач, Мәүлия апа һәм тагын биш-алты кызны окоп казырга алып китәләр. Аларга көне буена бер телем генә ипи бирелә. Ачлыктан һәм салкыннан бер кыз шунда үлеп тә кала. Өч айдан Мәүлия апа да хастаханәгә эләгә, ул анда өч ай ята. Шуннан соң гомере буе Хәербидә яши ул. Фермада сыер сава. Ире – Гыймадиев Сафа абый, сугыш ветераны. Җиде балаларының икесе сабый чакларында үлгән. Мәүлия апа үзе 2017 елның башында 96 яшендә вафат.



Мәүлия Гыймадиева.



Ибраһим Гаязов.

Игезәк сыңары Гарифулла абый да Хәербидә яши. Аның да балалары, оныклары бик күп. Авылда төпләнеп яшәүче улы – Миңнулла Гаязов. Миңнулла абыйның да гаиләсе ишле.


Лаишевский отдел соц.защиты Республики Татарстан
(Наименование государственного органа, выдавшего удостоверение)
УДОСТОВЕРЕНИЕ
Серия ВВ № 4252985
Гимадеева
(фамилия)
Мавлия
(имя)
Гаязовна
(отчество)
(личная подпись)
М.П.
Предъявитель настоящего удостоверения ветеран Великой Отечественной войны имеет права и льготы, установленные статья 20 Федерального закона "О ветеранах"
УДОСТОВЕРЕНИЕ БЕССРОЧНОЕ ДЕЙСТВИТЕЛЬНО НА ВСЕЙ ТЕРРИТОРИИ РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ
Дата выдачи 28 сентября 2009 г.
Т.Я. Бурганова
(Подпись руководителя государственного органа, выдавшего удостоверение)
М.П.
Зак. № 50/00

Бөек Ватан сугышы елларында тылда эшләгәне өчен бирелгән таныклык.

Гаяз бабайның кече улы Ибраһим абый да туган авылында гомер итә. Ибраһим абый шулай ук бик дини була. Мәчеттә мулла булып торган вакытлары да була. Авылдашларының ихтирамын казанган кеше ул.

Гаяз бабаның балалары инде исән түгел. Әмма, әйткәнебезчә, токымы тармаклы, шул исәптән Хәербидә яшәүчеләре дә бик күп. Хәерби мәктәбендә бик күп еллар укытучы булып эшләүче Хәсәнов Рөстәм – аның оныгының улы, ә Гаязов Фәрит – оныгы. Тагын бер оныгы — Нурания Газизова, ире Р.Газизов белән бергә «Раннур» нәшриятын һәм «Юлдаш» газетасын оештыручы.

**Гыймадиева Раилә Сафа кызы**. 1950 елның 26 ноябрендә Хәербидә туа. 1967–2006 елларда сыер савучы булып эшли. 1974, 1976, 1980 елларда – «Социалистик ярыш җиңүчесе». 1973 елда СССР Югары Советы Президиумы




Награжден медалью
„За трудовую доблесть"
Указом Президиума Верховного Совета СССР
от „6" сентября 1973 г.
Секретарь Президиума Верховного Совета СССР М.Георгадзе
З № 283066
„24" сентября 73 г.
Гимадеева
(фамилия)
Раиля
(имя)
Сафовна
(отчество)

1. Раилә Гыймадиева. 2. «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләнү турында таныклык.

Указы белән «Фидакарь хезмәт өчен» медале; 1975 елда «Тугызынчы бишьеллык ударнигы» билгесе, бик күп Мактау грамоталары белән бүләкләнә. Хезмәт ветераны. Раилә Гыймадиева бүгенге көндә улы Таһир гаиләсе белән Хәербидә яши. Аның ике баласы, дүрт оныгы бар.

**Гыймадиевлар гаиләсе**. Гыймадиев Минвәли һәм Маһруйлар гаиләсендә 8 бала үсә: Афзал, Вилдан, Гариф, Сәгыйть, Фердинат, Ибраһим, Зариф, Мәрьям. Уллары Минзариф (Зариф) Минвәли улы 1948 елның 3 ноябрендә Хәерби авылында туа һәм гомере буе шунда яши. Ул 1956–1964 елларда Хәерби сигезьеллык мәктәбендә укый. Аннары укуын Лаеш авыл хуҗалыгы һөнәри-техник училищесында дәвам итә, аны тәмамлаганнан соң колхозда механизатор булып эшли. 1967–1969 елларда Кызыл Армия сафларында, Кытай чигендә хезмәт итә. Армиядән кайткач, «Алга» колхозында комбайнга утыра. Көйләүче оста (мастер-наладчик) булырга укып чыкканнан соң, 1977–1981 елларда «Центральный» (соңрак «Хәерби») совхозында баш инженер-механик, 1985 елдан химияләштерү буенча агроном, 1990 елдан яшелчәчелек цехы башлыгы. Ул елларда кырларда З.Гыймадиев җитәкчелегендә ташкабак, кыяр, суган, кәбестә, чөгендер, бәрәңге кебек күп төрле яшелчә үстереп, бик зур уңыш алалар. 1995 елда Зариф Минвәли улын Хәерби авылы җирле үзидарә рәисе итеп сайлап куялар. Ул анда 1999 елга кадәр эшли. 1999 елдан Хәерби



Минвәли Гыймадиев.





1. Асия һәм Минзариф Гыймадиевлар оныклары белән;
2. Ләйлә һәм Радик Сафиннар.





1. Гөлүсә һәм Илнур Миңнуллиннар гаиләсе; 2. Онык баласы – Дарина; 3. Лилия һәм Рәис Низамовлар.

урта мәктәбенә газ белән ягып җылыту эшенә урнаша. Ул анда 2008 елга кадәр – пенсиягә чыкканчы эшли. 2017 елда вафат.

Зариф Гыймадиевның хатыны – Асия Нариман кызы, 1952 елның 5 ноябрендә Хәерби авылында туа. Хәзерге көндә пенсиядә. Алар биш кыз тәрбияләп үстергәннәр. Олы кызлары Лилиянең ире – Хәерби егете Рәис Низамов. Икесе дә Казанда резина-техник эшләнмәләр заводында эшлиләр. Аларның ике кызлары бар, оныклары үсә. Икенче кызлары – Ләйсән, ул да Хәерби егете Суфьян Ибәтуллинда кияүдә, Хәербидә яшиләр. Ике кызлары, бер оныклары бар. Өченче кызлары – Ләйлә шулай ук гаиләсе белән туган авылында яши, Хәерби урта мәктәбендә башлангыч сыйныф укытучысы булып эшли. Ике балалары бар. Гыймадиевларның тагын ике кызлары – Энҗе белән Гөлүсә гаиләләре белән Казан шәһәрендә яшиләр. Энҗе ире Айрат белән ике ул, ә Гөлүсә ире Илнур белән өч кыз үстерәләр. Илнур Миңнуллин да Хәерби егете.



Энҗе һәм Айрат Шиһаповлар гаиләсе.

**Зиннәтова Хәлимә апа**. Хәлимә апаның әтисе үлеп, бер төркем бала ятим кала, тормышлары җиңелдән булмый. Ашар ризык, кияр киемсез тилмерәләр. Бервакыт кемдер Хәлимәгә улларыннан калган киемнәрен бирә. Бу киемнәр

кызга бик тә ошап китә, ул чәчен дә кистереп атып, малай булып йөри башлый. Хәлимә апа гомере буе авылның сарык көтүен көтә. Сарык көтүенә ул «хуҗа» чакта маллар тук-көр була. Миләүшәдә берәр сарык бәрәнләсә, яшь бәрәннәрне авылга кадәр күтәреп алып кайтып, ияләренә тапшыра ул. Шул кадәрле сарыкны каян, ничек танып бетергәндер – сарыкларга да хуҗаларының исеме белән кычкыра. Менә шушы Хәлимә апаны бөтен авыл халкы ярата. Кем өенә килеп керсә дә, аны табынга дәшәләр, дустанә мөнәсәбәт күрсәтәләр. Ул үзе дә авылдашларына Миләүшәдән көлтәсе белән мәтрүшкәләр җыеп алып кайтып бирә. Күчтәнәч итеп берәр әйбер бирсәләр, ул аның өенә кайтып җитми дә кала: кемгә кагылса, шул кешегә биреп калдыра. Шуны белгән хәлдә дә, авыл кешеләре аның күңелен күрергә тырыша. Хәлимә апа көн буе кырда, болында көтү көтсә дә, авылның бөтен хәбәрен белә. Кайсы хәбәрләргә «яңалык»ны үзе дә өстәп җибәрә. Авылдашлары аны тыңлыйлар, ышанмасалар да ышанган булалар, каршы төшеп, кәефен бозмыйлар.

Укый-яза белмәсә дә, Хәлимә апа «Азат хатын» журналын алдыра. Рәсемнәрен карагач, үз күңеленә ошаган берәр кешегә бу журналны бүләк итә. Хәербинең XX гасырдагы тормышын искә төшергәндә, бу апаны һич тә искә алмый калып булмый, чөнки ул авылның үзенеке, Хәербинеке генә.

**Ибәтуллин Суфьян Шафик улы** 1966 елның 12 мартында гаиләдә дүртенче бала булып туа. Хәерби сигезьеллык мәктәбен (1981), Лаеш авыл хуҗалыгы һөнәри-техник училищесын (1984) тәмамлый. Армия сафларында хезмәт итә (1984–1986). 1987 елдан бүгенге көнгә кадәр Хәербидә механизатор булып эшли. Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы механизаторы (2014). Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы министрлыгының,


ИБӘТУЛЛИН
(фамилиясе)
Суфьян
(исеме)
Шәфикъ улына
(атасының исеме)

«Татарстан Республикасының
Атказанган авыл хуҗалыгы
механизаторы»
дигән мактаулы исем бирелде

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов
Татарстан Республикасы
Президенты Указы
« 05 » июль 2014 ел

1


УКАЗ
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
УКАЗЫ

О присвоении почётного звания «Заслуженный механизатор сельского хозяйства Республики Татарстан»

За многолетний добросовестный труд в сельскохозяйственном производстве присвоить почётное звание «Заслуженный механизатор сельского хозяйства Республики Татарстан»

Ибатуллину Суфьяну Шафиковичу — механизатору общества с ограниченной ответственностью «Хаерби», Лаишевский район Республики Татарстан

Президент
Республики Татарстан Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
05 июля 2014 года
№ УП-643

2

1. «Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы механизаторы» таныклыгы; 2. «Атказанган авыл хуҗалыгы механизаторы» исеме бирелү турында ТР Президенты Указы күчермәсе.


1


2

1. Ләйсән һәм Суфьян Ибәтуллиннар; 4. Ибәтуллиннарның балалары.

Лаеш районы администрациясенең Мактау грамоталары, Рәхмәт хатлары белән бүләкләнгән.

Хатыны – Ләйсән Минзариф кызы, 1975 елда Хәербидә туган. Алар 1992 елда гаилә корып җибәрәләр, ике кыз үстерәләр. Бер оныклары бар. Ләйсән Казан май комбинатында эшли.

Суфьян Ибәтуллинның әтисе – Шафик Хәмәди улы, 1929 елның 16 июнендә Хәербидә туган. Зоотехник, ясалма орлыкландыручы булып эшләгән. Хезмәт ветераны. 2009 елның 4 октябрендә вафат. Әнисе – Миңнебәян Тимергали кызы, 1935 елның 15 июлендә Лаеш районы Пәрәү авылында туа. Хәербидә бозау караучы булып эшли. Татарстанның атказанган терлекчесе, хезмәт ветераны.

**Маликовлар гаиләсе**. Маликов Ибраһим Малик улы (1913–1974) Хәербидә туа. Әтисе – Малик Сабит улы, әнисе – Таифә Габдрахман кызы. Таифәләр гаиләдә 11 кыз үсә, уллары булмый. Аларны «Габдрахман кызлары» дип йөрткәннәр (Сибиева Гадилә һәм Хәтирә апаларның әниләре дә Таифә апа белән бертуган).

Ибраһим гаиләдә бердәнбер бала була. Ул кечкенә вакытта әтисе Малик Сабит улын патша хезмәтенә алалар. Ул шул китүдән кайтмый, революция вакыйгалары барышында, Кышкы сарайны штурмлаганда һәлак була. Әнисе Ибраһимны Казанда яшәүче сеңелесе Галимә янына җибәрә. Ибраһим Малик улы Казан төзелеш институтында укый. Инде имтиханнар тәмам, диплом яклаган дигәндә генә Бөек Ватан сугышы башлана, ул 1941 елда ук фронтка китә. 1945 (кайбер мәгълүматлар буенча 1947) елның 18 ноябрендә Хәербигә кайта. Колхозда баш бухгалтер булып эшли.

Бу урында Малик абзыйның бертуганы Фәйзрахман Сабит улының «Алга» колхозы рәисе булып эшләгән кеше булуын әйтеп үтү кирәктер.

Ибраһим Малик улының хатыны – укытучы Галия Гарифулла кызы. Аларның уллары – Нил Ибраһим улы (1952–2011), клубның киномеханигы булып эшли. Рәсем ясауга сәләте зур була. Хәербидә балалар бакчасы ачылганда ул анда хуҗалык эшләре мөдире вазифасын башкара, эшне оештырып җибәрүдә үзеннән бик зур тырышлык куя. Нил Ибраһим улының хатыны – Илнура Хәмәтхан кызы (1953 елгы). Бу гаиләдә үскән бердәнбер бала – Гөлназ Низамова, Татарстан Республикасы Милли китапханәсе хезмәткәре, ике балалары бар.



Ибраһим Маликов.

**Минбаев Нури һәм Зәкия гаиләсе[1].** «Безнең бала чаклар сугыштан соңгы авыр елларга туры килсә дә, бик күңелле булган икән. Безнең урамда барысы 12 йорт, һәрбер йортта 6–7 бала үсә иде. Әти-әниләргә булышырга да, урамда уйнарга да, яхшы укырга да өлгердек. Әти-әниләр безне ничек ашатып, киендереп, укытып бетергәннәрдер, шуңа гаҗәпләнәм.

Безнең әтине чын ир-егет дип әйтер идем мин, чөнки ул алдынгы карашлы, акыллы, гадел, батыр йөрәкле, артыгын сөйләшмәүче, әйтәсе сүзе уйланылган, төпле һәм дөрес кеше иде.

Әти озак еллар авыл советы председателе булып эшләде. Бер үк вакытта ул үзенең гаиләсенә дә (11 кеше идек — 7 бала, дәү әни, дәү әти, әти, әни), авылдагы гаиләләргә дә матур һәм дөрес итеп яшәү үрнәге күрсәтте. Гаиләдә без җиде бала үстек: Шамил (1947), Нәҗип (1949), Альмет (1951), Фирдәвес (1953), Флюра (1956), Фәрит (1960), Альберт (1965). Бишебез югары белемле. Нәҗип абый Казан дәүләт консерваториясен, Альмет абый белән Фәрит Казан авыл хуҗалыгы институтын, Фирдәвес апа Казан культура институтын, ә үзем – Флюра, Казан финанс-икътисад институтын тәмамладык. Нәҗип абый белән горурланабыз, ул Хәерби авылыннан чыккан бердәнбер музыкант-флейтачы, Татарстанның атказанган артисты, җырларга көйләр язучы. Әти белән әнинең 11 оныгы, 18 оныкчыгы бар. Әтинең әтисе – Миңнебай, әнисе – Галия, дәү әтисе – Төхвәтулла, ә Төхвәтулланың әтисе Галим исемле була. Әниебез Зәкия мәктәптә бик яхшы укыган, яттан сөйләргә биргән шигырьләрне шул ук көнне сөйләп кайтып китә идем дип әйтә иде. Ә әти: «Эш

1 Кызлары Флюра Исмәгыйлева язып тапшырды; авторлар редакциясендә бирелә.

буенча иң дөрес киңәшне әниегез бирә», – дип зурлады аны. Әни бик башлы, акыллы, сабыр булды.

Әтиләр алты бала үсә: Сәрвәр, Зөһрә, Гайсә, Нури, Гаян, Гайшә. Тормышлар авыр, ашау-эчү ягы ачлы-туклы була ул вакытларда. 18 яшендә әтине сугышка алалар. Батыр йөрәкле, куркусыз, үз-үзен аямыйча көрәшкәне өчен ул утлы сугыш кырында партиягә кабул ителә. Сугышчан бүләкләре – орден-медальләре дә бар аның. Әти сугыш барышында берничә тапкыр каты яралана. Ә аның бертуган абыйсы Гайсә мәңгелеккә ятып кала. 2013 елда гына аның кабере Польшада булуын белдек. Үзе сугыш кичкән кеше буларак, әтинең җанындагы аерым бер сызлау, яра булгандыр абыйсы. Кайда, ничек өзелде икән гомере, дөньядан җиңел кичтеме икән дип сызлангандыр, өзелгәндер ул абыйсын уйлап. Аз сүзле кеше булганга, бу турыдагы уйларны уртаклашмаган инде ул.

Әти-әни сөйләгәннәрдән истә калдырып, үзебезнең гаилә турында түбәндәгеләрне әйтә алам. Әти ягыннан да, әни ягыннан да әби-бабайлар урта хәлле крестьяннар булганнар. Хезмәт сөючән, тырыш, гадел кешеләр. Әти ягыннан дәү әтиләр мал-туар асраганнар, җир эше белән шөгыльләнгәннәр, умарта тотканнар. Дәү әтием биш вакыт намазын да калдырмаган, 94 яшендә вафат булган. Гомеренең соңгы көннәренә кадәр кулыннан сөлгесе, комганы төшмәде. Әни ягыннан дәү әти – Хисаметдин – сәүдә эше белән шөгыльләнгән.

Әтигә 6–7 яшьләр булганда, колхозлашу чорында, аларның өйләреннән булган бар әйберне (терлекләрне, умарталарны, гомумән, соңгы самоварга кадәр) алып чыгып китәләр. Моны да үзе кичергәннәр генә белә булыр. Тырышлык белән тапкан малларының көл булуын, анысыннан да бигрәк, бармакка-бармак сукмаганнар кулына керүен күргән кешеләр алар. Шул гаделсезлекләрне күргәннән соң да, Туган илгә тугры калган кешеләр.

1946 елда әти белән әни өйләнешеп, гаилә корып җибәрәләр. «Алар иң матур парлар иде», – дип сөйли иде әтинең сеңлесе Гайшә апа алар турында. 1971 елны, әле ике ел да тормаган яңа салган йортыбыз, газ шартлап, янып бетте. Ярый үзебез исән-сау калдык. Шул вакытта әтинең һуштан язып егылганын хәтерлим. Җиде бала белән йорт салуның ни икәнен ул үзе генә белгәндер. Район житкчеләре, шулай ук авыл кешеләре ярдәме белән бер ел эчендә яңа йорт салып чыктык».

**Мифтахова Шәмсия апа** белән Гайнетдинов Салих абый Мәскәүгә, ВДНХга – Бөтенсоюз Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсенә баралар. Анда Шәмсия апага патефон бүләк итәләр.

**Мөбарәкшин Әнәс Шәрәф улы** 1948 елның 3 октябрендә Хәербидә туа. 1964 елда мәктәпне, аннан соң урта һөнәри белем бирү училищесын тәмамлый. 1968–69 елларда армия сафларында хезмәт итә һәм туган авылына эшкә кайта. Башта тракторчы, ремонт мастерское мөдире, механик була. Аннары 22 ел буе хуҗалыкның өлкән инженеры вазифасын башкара. Гомуми хезмәт стажы – 42 ел. Әнәс Шәрәф улы 2019 елда вафат.



Әнәс Мөбарәкшин оныклары белән.

**Мөхәммәтҗанова Миңсылу Мөхәммәтгали кызы («Идрис тәтә»)**. Аны авылда барысы да «Идрис тәтә» дип йөргән. Олырак хатын-кызлар үзенә эндәшкәндә генә «Миңсылу абыстай» дигән. Сүз менә шул Миңсылу апа турында. Ул 1884 елда Сиңгел авылында туган. Әтисе Мөхәммәтгали, әнисе Фатиха исемле (фамилиясе Сәгыйтова) булган. Җиткән кыз булгач, ул Хәербинең Идрис исемле кешесенә кияүгә килә һәм гомеренең азагына кадәр шунда яши. Миңсылу апаның балалары яшьли үлеп бара. Нурмөхәммәт исемле улы һәм Әминә исемле кызы гына үсеп җитәләр. Гомеренең азагында Миңсылу апа якыннарының барысын да югалта. Улы шахтага эшкә җыенган авыл яшьләренә ияреп Донбасс якларына китә. Русча да белмәгән бу юаш авыл егете шуннан кайтмый. Язмышы билгесез. Соңгы өмете булган Әминәсе көннәр язга авышкан бер мәлдә, чана сөйрәп, урманга утынга китә. Көн бозылып, буран чыга. Өс-башы да юка, тамак ягы да чамалы. Кыз бик арый. Ял итәргә чанасына утыра һәм шунда туңып үлә. Бу вакытта Миңсылу апаның ире дә исән булмый инде.

Идрис тәтә авылның кендек әбисе дә була. Сугышка кадәр һәм аннан соң да авылда сабыйлар күп туа. Менә шуларның барысын да диярлек беренче булып кулына ул ала. Аналарга тиешле ярдәм күрсәтә: аларны бәби мунчасы кертә, «сылау» (массаж) да ясый, төрле үлән төнәтмәләре белән дәвалый да. Кыскасы, үз эшенең остасына әйләнә. Миңсылу апа дөньяга килергә ярдәм иткән балалар, үсеп җиткәч, аны туйларына чакыралар. Егетләр армиягә киткәндә: «Тәтә, безнең өчен догада тор, яме?!» – дип үтенәләр. Ә ул дога кыла, армиягә китүче егетләргә бер телем ипи алып килеп тешләтә. Ипинең калган өлешен, киптереп, җыеп куялар. Бу туган җирдә егетләрнең ризыгы бетмәсен өчен шулай эшләнә.

Олыгайгач, Миңсылу апаны Гайнетдинов Салихҗан абый белән Камилә апа үз гаиләләренә ала. Бу гаиләнең балалары аны бик яратып, үз әбиләре итеп йөри. Соңга юлга да әбине шушы гаилә кешеләре озата.

Авыл тарихында якты, җылы эз калдырган кеше ул Миңсылу абыстай. Коръән ашларында аның рухына багышлап бүгенге көндә дә дога кыла авыл халкы.

**Нигъмәтов Булат Хабул улы** 1948 елның 21 ноябрендә Хәерби авылында туа. Хәерби сигезьеллык һәм Саралан урта мәктәпләрен тәмамлый. Мәктәптән соң авылның киномеханигы вазифасын башкара, кыска гына вакыт Хәерби мәктәбендә физика фәнен укыта, соңыннан авылның электригы булып эшли. «Совхозның, мәктәпнең, авыл советының, медпунктның, клубның һәм Хәербидәге барлык йортларның электр приборлары безнең әти тарафыннан көйләнгән», – ди аның балалары. Хатыны – Гөлфирә Нәҗип кызы. Алар беренче сыйныфтан бергә укыйлар, гаилә корып, 44 ел бергә яшиләр. Ике кыз тәрбияләп үстерәләр, өч онык һәм бер оныкчыклары бар. 2014 елның 4 ноябрендә вафат.

Кызы Алсуның әтисе турындагы истәлекләре: «Минем әтием Булат белән әнием Гөлфирә классташлар, ә беренче укытучылары – минем әбием, әтиемнең әнисе. Әти совхозда электромонтёр булып эшләде. Совхозга электр белән эшләүче нинди генә җиһаз кайтмасын, барысын да иң элек әтигә күрсәтәләр иде. Хәербинең һәр йортына ут кертү, чыбыклар алыштыру, телевизор, суыткыч кебек әйберләрне төзәтү – боларның барысы да әтисез башкарылмый. Көндез генә түгел, төнлә дә килеп тәрәзә шакудан куркып та китә идек. Төнге шакулар еш кына янгын чыгу белән бәйле була. Андый куркыныч хәлләрдә әти белән бергә, электр төзәтү коралларын беренче эләктереп, әни дә йөгерә иде. Әгәр Хәербидә берәр кешедә туй, юбилей булса, аеруча кышның буранлы көннәрендә, әти алыштыргысыз кешегә әйләнә, утның сүнеп китүе бар бит. Ул үзе дә җаваплылык тоеп, андый көнне һәр очракка әзер тора.

Исемдә, бик яңгырлы көн, ярты авылда ут юк, күк йөзе ачылырга уйламый да. Әти трансформаторга утны төзәтергә бармакчы. Шунда ул сеңелем Фәридәгә әйтә: «Кызым, әйдә, әйбәтләп киен, утынлыкта сөялеп тора торган рәшәткә тактасын ал, мине ток сукса, шуның белән төртеп төшерерсең», – ди. Фәридә әле аны-моны аңламый: «И-и-и, әти, мин куркам, сине төртеп төшерергә дә кызганам, үзең генә егылып төшә алмыйсыңмы соң?» – ди. «Үзем егыла алсам, сине алып бармыйм да инде мин, әйдә-әйдә», – дип, әти аны алып чыгып китә. Әти сеңелемне мотоциклына утыртып гел үзе белән йөртә иде, я алар җәйге сыерлар лагерена, я печәнгә китәләр. Улы булмагач, әти Фәридәне малае урынына күргән, күрәсең.






1. Роза һәм Булат Нигъмәтовлар. 2. Роза, Булат, Гөлнара Хәерби кызы Миңниса белән. 3. Санаторийда. 4. Нигъмәтовлар оныклары Ильмира һәм Алмаз туенда. 2014 ел.

Әтинең эше авыр һәм җаваплы иде. Техника буенча бик күп китаплар укый, электрик буларак разрядын күтәрү өчен сынау бирә. Безгә физикадан дәресләр әзерләшә, аңламаган темаларны бик җайлы итеп өйрәтә иде. Ул яшь вакытында Хәерби мәктәбендә физика фәнен дә укыткан, шунлык белән аңа урамда кайбер кешеләр исеме белән түгел, ә мәктәптәгечә, «Абый!» дип эндәшә иде.

Яңа ел көннәре аеруча истә. Бу көннәрдә телевизорларын чанага салып тартып безгә килүчеләр күбәя, алар әтинең төзәтеп бетерүен түземсезлек белән көтеп утыралар иде. Башка вакытта да веранда идәне төзәтәсе магнитофоннар, телевизорлар белән тулган була, әни бик ачулангач кына, бераз бушап торгандай итә дә, тагын өелә. Менә шундый һәркемгә кирәк кеше иде әти:

совхоз сыерын да аннан башка сава алмыйлар, бәйрәм дә уздыра алмыйлар, хәттә дәү әни дә сепараторында сөт аерта алмыйча аны көтеп утыра иде.

Компьютерга да бик тиз өйрәнде ул. Баянда да бик матур итеп уйный иде. Динебезне дә бик хөрмәт итеп яшәде. Әнинең намазга өйрәнгәнен күреп бик сөенде, үзе дә еш кына тәсбихын кулына ала иде. Бик шаян сүзле, балалары, оныклары өчен җанын бирергә әзер, кешеләргә карата бик ярдәмчел иде әти. Туган авылы Хәербине, аның кешеләрен бик ярата иде. Кызганычка каршы, ул 2014 елның ноябрендә, 65 яшендә арабыздан китте».

**Нуруллина Җәмилә Гарифулла кызы** 1914 елның 5 маенда Агачбашы (Агайбаш, Державино) авылында Гарифулла Мөхәммәтзариф улы һәм Мәликә Хөсәен кызы гаиләсендә туа. 2–3 яшендә әти-әнисе үлә һәм аны Хәербидә яшәүче Латыйпов Сибгатулла һәм Маһиралар гаиләсе асрамага ала.

1935 елда 21 яшендә Җәмилә Гарифулла кызы Хәербинең Фатыйх исемле егетенә кияүгә чыга. Нуруллин Фатыйх Нурулла улы 1914 елда Хәерби авылында туган. Бөек Ватан сугышында катнаша. Нуруллиннарның өч уллары туа: Нәҗип (1936 елгы), Сәлим (1946), Наил (1948). Сугышта алган яралар үзенекен эшли, Фатыйх абый бик иртә, 1950 елда, үлеп китә. Җәмилә апа кечкенә балалар белән утырып кала, тормышны берүзенә генә тартырга туры килә. Ул догаларны бик яхшы белә, аның янына балаларны өшкертергә алып баралар. Олысы-кечесе, күрше-тирә бар да Җәмилә апаны бик ихтирам итә. Ул бар гомерен улы Наил һәм килене Зөлфирә гаиләсе белән яши. 2007 елның 20 маенда 93 яшендә вафат.


1


2

1. Җәмилә Нуруллина. 2. Наил Нуруллин гаиләсе, туганнары һәм авылдашлары арасында. Сабантуй, 1970 еллар башы.



**Сәхбиев Минвәли Зиннәт улы** 1950 елның 26 февралендә Хәербидә туа. Армия сафларына барып кайтканнан соң, гомере буе механизатор, комбайнчы булып эшли. Хәзер пенсиядә булуына карамастан, җәйләрен комбайнын ташламый, яшьләрне эшкә өйрәтә. Минвәли Сәхбиев Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең (2002 ел) атказанган авыл хуҗалыгы механизаторы. III дәрәҗә Хезмәт Даны ордены, «Казанның 1000 еллыгы» медале һәм күпләгән Рәхмәт хатлары, Мактау грамоталары, Дипломнар белән бүләкләнгән.

Минвәли Сәхбиевнең хатыны – Наилә Галимҗан кызы, 1951 елның 8 апрелендә Хәербидә туган. Алар өч бала тәрбияләп үстергәннәр: Наил (1974 елда туган), Нәҗия (1976), Миңнур (1980). Биш оныклары бар.



**Сибиев Мөхәммәт Зиннәтулла улы** 1931 елда Хәербидә туа. Мәктәптә 7 класс белем алгач, комбайнчы булырга укый. Гомере буе комбайнчы булып эшли. Ел саен беренчелекне алып килә, кыйммәтле бүләкләр, Мактау грамоталары белән бүләкләнә, медальләре бар. Казахстан һәм Оренбургка чирәм җирләр күтәрергә баручылар арасында да була ул. Мәскәүдә, ВДНХда – Бөтенсоюз Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсендә узган алдынгылар слетында катнаша.

Мөхәммәт абыйның әтисе – Сибиев Зиннәт Сибгатулла улы, 1941–1943 елларда авыл советы председателе булып эшләгән кеше, Бөек Ватан сугышы ветераны. Хатыны – Талия апа, Хәербидә кырчылыкта, яшелчәчелектә эшли. Мөхәммәт Зиннәтулла улы 1988 елның 20 октябрендә вафат.

**Хәлиуллина Саимә Гали кызы** 1929 елда туган. Әтисе Гали абзый башта Яушыйк авылы кызы Мәрфуга Шәмсетдин кызына өйләнә. Ике кызлары – Мәүлия белән Разия тугач, хатыны үлеп китә. Гали абзыйга Татар Сараланы авылыннан Мәрфуга Ярулла кызын димлиләр. Ике Мәрфуга бер-берсенә туган тиешле була, ятим калган балалар хакына дип тә шулай килешенә. Икенче хатыннан өч бала – Минвәли, Саимә, Миңнегаян туа.





1. Разия һәм Саимә апалар үз кызлары Әлфия һәм Нурхидә белән; 2. Саимә апаның оныклары – Рамил белән Наил.

Саимә апага дүрт яшь булганда – әтиләре, биш яшь булганда әниләре үлеп китә. Өйдә биш ятим утырып кала. Кечкенәләрен балалар йортына җибәрмәкче булалар, Әмма Разия апа, әле үзе дә үсмер кыз гына булуына карамастан, аларны үз җаваплылыгына ала.

Разия Гали кызы 1920 елда туган. 13–14 яшьләрендә үк колхозда эшли башлый. Кечкенә туганнарын карап үстерә. Тракторчы булып та эшли. Разия апаның биш баласы була. Улы Мәгъсүм гомере буе Хәербидә яши, совхозның автобусын йөртүче була. Разия Гали кызы 1980 елда вафат.

Саимә Гали кызы шулай ук бик иртә эшли башлый. Башта яшелчәчелектә, аннары бозаулар һәм бозауларга тиешле сыерларны карауда хезмәт куя. Аның ире – Хәлиуллин Якуп Ибраһим улы (1932–1975). Бу гаиләдә өч бала – Нурхидә, Альфред, Әнисә үсә. Саимә апа – хезмәт ветераны.

Саимә апаның абыйсы – Минвәли Гали улы, 1927 елда



Минвәли Галиев, Дания Юнысова, Сания Галиева, Саимә Хәлиуллина. Алда: Минвәли абыйның кияве Галимҗан, оныгы Гөлнара һәм оныгының кызы.

туган. Хатыны Сания апа белән биш бала тәрбияләп үстергәннәр. Гомере буе тимерчелектә эшләгәнгә, Минвәли абыйны авылдашлары яратып һәм андый исемле кешеләр авылда күп булу сәбәпле, «күзнич Вәли» дип йөртәләр. Минвәли Гали улы – хезмәт ветераны.



М.Хәмәтгалиев.



Рания Хәмәтгалиева.

**Хәмәтгалиев Миңнебай Хәмәтгали улы** 1935 елның 31 маенда Хәербидә туа. Авылда җидееллык мәктәпне тәмамлагач, 3 ел Казан шәһәрендә фабрика-завод өйрәнчекләре мәктәбендә (Школа фабрично-заводского обучения – ФЗО) укый. Аннары 40 нчы заводта слесарь-ремонтчы, фрезерчы булып эшли, корал ясый. Шуннан Совет Армиясе сафларына алына. Ул Германиядә хезмәт итә, корал төзәтүче була. Армиядән соң туган авылына кайта. Пенсиягә чыкканчы токарь-фрезерчы булып эшли. Миңнебай абыйның әтисе — Хәмәтгали (фамилиясе Гыйләҗев булырга тиеш); Бөек Ватан сугышында һәлак була. Хатыны – Рания апа, авылда сыер савучы һәм терлекче булып эшли, Саралан авылы кызы. Миңнебай абый белән алар дүрт ир-бала тәрбияләп үстерәләр.

Миңнебай абый 1973 елда бензин белән эшли торган, өсте ачык (кабинасыз) һәм арбалы, өч көпчәкле машина ясый. Аның руле урынында рычаг тора. Өч көпчәкле булганга, ул еш ава торган була. Берничә елдан оста аны дүрт көпчәкле итеп үзгәртә, руль куя. Бу машина белән печән дә ташыйлар, утын да алып кайталар. Сабан туе көнне күрше-тирәләрне җыеп Мишә буена ял итәргә баралар.



Миңнебай абыйның оныклары ул ясаган машинада.

Бервакыт, печәнгә барганда, Миңнебай абыйны ГАИ хезмәткәре туктата. «Я, абзый, күрсәт, моның тормозы кайда?» – дип

сорый. Миңнебай абый аптырап тормый, сикереп төшә дә, иңбашы белән тәрәп туктатып күрсәтә. Сак кына йөрергә кушып, көлеп китеп бара хезмәткәр.

Миңнебай абыйдан өйрәнеп, авылда Харис исемле кеше дә шуңа охшаш машина ясый. Аның арттагы бер көпчәге генә тарта торган була. Өсте ачык машинаны Шафик Мәннапов та ясый, аныкы күпкә көчлерәк һәм яхшырак була. Моннан тыш Шафик абый ябулы машиналар да ясый. Хәербидә шундый осталар яши!

**Хәмидуллин Минвәли Гарифулла улы** 1933 елның 20 гыйнварында Хәербидә туа. Күп еллар балта осталары бригадиры булып эшли. Авылдагы күп йортларны шушы бригада төзи. Хәерби халкы Минвәли аганы бигрәк тә мич чыгару остасы итеп белә. Ул чыгарган мичләр бик күп йортларда, мунчаларда хезмәт итә. 2016 елның декабрендә вафат.

**Хәмидуллин Минвәли Хәмидулла улы** 1939 елның 5 апрелендә дөньяга килә. Әтисеннән яшь ярымда кала. Инде шул вакыттан аңа тормышның ачысын да, төчесен дә тоярга туры килә. Ятимлек ачысы өстенә сугыш афәте дә өстәлә. Бу еллар турында менә ниләр сөйли торган була Минвәли абый: «Ул вакытта ачлык белән бергә кышкы суыклар үзәккә үтә иде. Өстә иске кием, аякта тишек киез итек. Су алып кайтканда аяк-куллар бозланып ката иде. Өйгә кайткач та җылынып булмый, утын-саламны саклап кына яга идек. Әни көне-төне эштә. Әле дә исемдә, алты яшьләр тирәсендә булганмындыр, чана шуып кайтып кердем. Чана табаны ялтырап тора. Ашыйсы килү шулкадәр көчле булганмы, белмим, шул чана табанын ялап алдым. Телем ябышып шактый кан акты. Бик озак әрнегәне истә калган».



М.Хәмидуллин хәрби хезмәттә.

Олы бала буларак, Минвәли әнисенең һәм үги әтисенең уң кулына әйләнә. Йорт-тирә көнкүреш эшләре дә, кечкенә эне-сеңелләрен карау да аның өстендә була. Җидееллык урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, шофёрлыкка укый. Өч ел Совет Армиясе сафларында хезмәт итә.



Хезмәт итү дәверендә почта ташучы булып эшли. 1962 елда туган ягына кайта. Шул ук елны Галиева Сания Хәсән кызы (1944 елның 25 июнендә туган) белән гаилә корып, тормыш итә башлыйлар. Бер-бер артлы 5 балалары: Раиф, Рузилә, Рәзинә, Айрат, Ильмира туа. Минвәли абый гаиләсе өчен бар көчен бирә, алны-ялны белми тырыша, бер-бер артлы яңа йортлар салып чыга. Җәен комбайнда, кышын дизель тракторында эшли. Салкын кыш айларында яланкул салкын тимер тотып эшләүләре эзсез узмаган, күрәсең. Пенсиягә чыгып бер ел үткәннән соң, 2000 елның 21 декабрендә вафат була.

Хәзерге көндә Минвәли абыйның бер улы, өч кызы үз гаиләләре белән тормыш кичерәләр. Аның ун оныгы, алты оныкчыгы бар. Тормыш иптәше Сания апа авылның атаклы абыстае. Барлык авыл халкы аны ярата, хөрмәт итә. Сания апа намаз саен мәрхүм тормыш иптәше рухына багышлап дога кыла. Балалары да, оныклары да бабайлары турында матур хәтирәләрне якты истәлекләр итеп саклыйлар.

**Ярмиевләр нәселе.** Ярмиевләр нәсел шәҗәрәсе Ярмөхәммәт исемле кешедән башлана. Мөгаен фамилиянең килеп чыгышы да шуннандыр. Ярмөхәммәт улы Бикмөхәммәт, Бикмөхәммәт улы Гатаулла. Гатаулланың улы Гарифулла баба турында бераз истәлекләр бар. Гарифулла баба 1890 елда туып, 1981 елның 10 июлендә 91 яшендә дөнья куя. Авылда аны Шәкерт баба дип йөртәләр. Ул, мәдрәсәдә белем алганлыктан, авылда мулла вазифасын да үти. Бик күп китаплары була, яшь вакытта «Нур»[1] газетасын алдыра. Газетаның бер санын алырга дип Казанга килгәч, Габдулла Тукай белән очрашып та-



Мөнирә һәм Габдулла Ярмиевләр.

1 «НУР», атналык иҗтимагый-сәяси, әдәби газета, татар телендә беренче вакытлы матбугат басмасы. 1905 елның 2 сентябреннән 1914 нең 22 июненә кадәр С.-Петербургта нәшер ителә, барысы 310 саны чыга. Оештыручы, нашир һәм мөхәррире — Г.Баязитов, аннан соң — М.Баязитов. К.Бәкер, Г.Еникеев, Г.Исхакый, Ш.Камал, Ф.Кәрими, С.Максуди, Һ.Максуди, К.Мотыйгый, С.Сүнчәләй, К.Тәфкилев һ.б. хезмәттәшлек итә.







Гарифулла Ярмиевнең Казан университеты Фәнни китапханәсенең «Кульязмалар һәм сирәк китаплар» бүлегендә сакланучы кульязма дәфтәре битләре.

нышып кайта. Бу Гарифулла баба хәтерендә гомерлек истәлек булып калган вакыйга, әлбәттә. Гарифулла Ярмиевнең 1949–1968 еллар арасында Хәерби авылындагы һава торышын, авыл хәлләрен (туу, үлү, никахлар) теркәп барган алты кульязма дәфтәре була. Бу искиткеч кызыклы һәм бай мәгълүмат Казан университеты Фәнни китапханәсенең «Кульязмалар һәм сирәк китаплар» бүлегендә 3560 т.–3565 т. шифрлары белән саклана.

Гарифулла бабаның бертуган апасы Нәгыймә Заһидулла Яруллинга кияүгә чыга һәм аларның Фәрит исемле уллары туа. «Композитор Фәрит Яруллинны бишектә тирбәтеп үстердем мин», – дип әйтә торган була Гарифулла бабай. «Заһидулла җизни скрипкада бик матур уйный иде, Мишә елгасы буйларында җырлашып утыра идек», – дип сөйли ул оныкларына. Совет власте урнашкан вакытларда аны мулла дип эзәрлекли башлыйлар. Олы улы Габдулла, шуны аңлап алып, 1930 елда беренчеләрдән булып колхозга керә. Кулы бик күп эш белгән Шәкерт баба мастерскойда (үзенең остаханәсе була), гади эшче булып, бар эшне эшли: хуҗалык кирәк-яраклары – ярма яргыч машина, тәрәзә рамнары, комган, ләгәннәр ясый; тишек казан, чиләкләрне төпли. Колхозлашу елларында хуҗалык эшләрендә катнаша. Шул ук вакытта кеше-


Пролетарии всех стран, соединяйтесь!
ВСЕСОЮЗНАЯ КОММУНИСТИЧЕСКАЯ ПАРТИЯ (большевиков).
МАНДАТ № 46
Предъявитель сего тов. Ермеев
является делегатом
...ой Столбищенской районной партийной конференции с правом решающего голоса от к-за Алга
первичной партийной организации.
Председатель Мандатной Комиссии


СССР
Министерство Заготовок
УПОЛНОМОЧЕННЫЙ по Татарской АССР
УДОСТОВЕРЕНИЕ
Предъявитель сего тов. Еремеев Абдулла Гарифуллович
действительно является агентом по поставкам сельскохозяйственных продуктов государству Уполномоченного Министерства Заготовок по Столбищенскому району ... СССР.
Срок ... 31 декабря 1949 года.
Уполномоченный Министерства ... СССР по ТАССР ... (...РТЕМЬЕВ).

Габдулла Ярмиевнең район партия конференциясе делегаты мандаты һәм СССР әзерләүләр министрлыгының ТАССРның Столбище районы буенча агенты таныклыгы.

гә күрсәтмичә генә намаз укый, никах, исем кушу йолаларын үти, мәет җирләү эшләрен башкара. «Бабаның бер сандык китаплары бар иде, 1969 елда Рәмзия исемле журналист килеп, ул китапларны алып китте», – дип сөйли оныгы Нурания апа. Шәкерт баба хатыны Камилә үлгәннән соң үзе генә яши. Дин тыелган вакытларда да авылның олылары, олырак ир-атлары җомга намазларын да, гает намазларын да укыйлар. Гадәттә җомга намазларына Әмин абыйларга (умартачы булган) җыела торган булалар. «Шәкерт баба кино карарга яраткан, клубта аның үз урындыгы булган һәм ул урынга аннан башка беркем дә утырырга кыймаган. Гарифулла бабаны барыбыз да хөрмәт иттек», – дип сөйли оныклары.

Олы улы Габдулла 1932 елда счетоводлар курсларында укып, 1942 елга кадәр колхозда счетовод булып эшли. 1935 елда Мөнирә исемле кызга өйләнеп, гаилә кора. Сугышка 1942 елда алына, Төньяк флотта диңгезче була. Сугышка киткәнче ике кызы: Дания (1936 елда) һәм Нурания (1942 елда) туып кала. «Унөч кеше тордык бер өйдә, ачлык вакыты, сугыш чоры булуга карамастан, бик тату яшәдек. Әти (Шәкерт баба) барыбызны да барлап, саклап торды», – дип сөйли торган була килене Мөнирә апа. Сугышта Габдулла абыйның уң кулы яралана, 1943 елда ул, хәрби хезмәткә яраксыз табылып, туган авылына кайта. 1943–1948 елларда колхоз счетоводы булып эшли. 1948 елда аны СССР әзерләүләр министрлыгының ТАССРның Столбище районы буенча агенты итеп алалар. Дошманнары да хезмәт вазифасына бәйле килеп чыккандыр – 1954 елда ул явызларча үтерелә. Мөнирә апа биш баласы белән тол кала. Ярмиевләр нәселен дәвам иттерергә тиешле ир балалары Динар




СССР әзерләүләр министрлыгының ТАССРның Столбище районы буенча агентлары. Арттагы рәттә уңнан икенче – Габдулла Ярмиев.

да (1953 елда туган) әтисеннән соң тугыз ай гына яши. Дүрт кызны аякка бастыру, ирсез тормыш итү бик авыр булса да, Мөнирә апа сыгылмый, бар тормышын аларны кеше итүгә багышлый. Дүртесен дә Хәерби егетләренә кияүгә бирә. Кызлар барысы да тормышлы, бүгенге көндә өчесе Хәербидә гомер кичерә.

Олы кызы Дания (1936 елда туган), алты бала үстереп, авылда иң ишле гаиләләрнең берсе булып, кече улы Наил (1969 елда туган) тәрбиясендә яши. Наил чын мәгънәсендә Шәкерт бабаның (Ярмиевләр) оныгы – үзенең мастерскоен булдырып, яшенә-картына төзелешләрдә киңәшләрен биреп, зур авыл тормышы белән яши.

Икенче кызы Нурания (1942 елда туган) Хәерби авыл советы председателе, соңрак озак еллар колхозда амбар мөдире булып эшли. Дүрт бала үстереп, бүгенге көндә авылда яши. Ике баласын бик яшьли югалтып, зур кайгылар күргән, сабырлык белән кичергән кеше.

Өченче кызлары Розалия (1947 елда туган) Казанда, ике кыз үстереп, алар тәрбиясендә үрнәк гаилә булып яши.

Дүртенче кызлары Илсөя (1949 елда туган) озак еллар авылда яшелчә үстерүчеләр бригадиры, соңрак, 1996–2006 елларда, авыл советы председателе булып эшләп, пенсиягә чыга. Лаеш районының мактаулы гражданы исеменә лаек була, яхшы җитәкче, авылның хөрмәтле кешесе булып, бүгенге көндә




оныклары тәрбиясендә яши. Авылда данлыклы Ярмиев фамилиясен йөртүче дә ул хәзер.

Гарифулла бабаның Габдулладан соң туган балалары Мөнәвәрә апа, Фарук абый, Сания апа хәзер исән түгелләр инде, ләкин аларның балалары Ярмиевләр нәселеннән икәнлекләрен белеп, туганннары белән аралашып яшиләр.






















**Хәербидә гомер итүчеләр.** 1. Миңнегайшә Кашапова (Сәхбиева) кызлары Мөршидә, Минҗиһан, Мөслимә һәм оныгы Рамил белән; 2. Ибраһим Сәхбиев, Минвәли Сафин, Гаҗилә Сәхбиева; 3. Гөлшат һәм Җәмилә апа Шакирова. 1971 ел; 4–5. Авыл апалары; 6. Фәрит Гәрәев, Сания Хәлилова сайлауда; 7. Хәтирә һәм Габдулла Хәмидуллиннар.


1


2


3


4


5


6

**Хәербидә гомер итүчеләр.** 1. Хатып Вафин, Кадыйр Шакиров; 2. Авыл сабан туенда. 1970 ел; 3. Казан Сабан туенда. 1971 ел; 4. Разия һәм Исмәгыйль Шәмиевләр; 5. Вафа абзый хатыны, балалары, кияүләре, киленнәре белән; 6. Җәмилә апа Нуруллина.



1



2



3



4



5



6

**Хәербидә гомер итүчеләр.** 1. Хәмәтгариф Сафинга 90 яшь; 2. Гөлсирә Абдуллина балалары белән; 3. Равия Закировага 80 яшь; 4. Шафик Вафинга 90 яшь; 5. Авыл мәдәният йортында; 6. Насыйбуллиннар оныклары белән.

## XVIII БҮЛЕК

## АВЫЛДАН ЧИТТӘ ЯШӘҮЧЕ КҮРЕНЕКЛЕ КЕШЕЛӘР



**Абдуллин Габделәхәт Габделхак улы**, 1951 елның 12 ноябрендә Хәерби авылында туа. Мәктәпне тәмамлаганнан соң, Хәрби-Диңгез Флотында хезмәт итә, хезмәт урыны Тын океанда, Советская Гавань шәһәрендә була. Авыл хуҗалыгы техникумының механика бүлеген тәмамлый. Тырышлыгы, булганлыгы, алдан күрүчәнлеге, эшне оештыра белүе белән ул җитәкчеләрнең дә, хезмәттәшләренең дә хөрмәтен казана. Г.Г.Абдуллин инде ике дистә елдан артык Казан шәһәрендәге җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять – «ХимАгроТранс» предприятиесе директоры. Хатыны Люция белән ике бала тәрбияләп үстерәләр, бер оныклары, ике оныкчалары бар. Габделәхәт Габделхак улы туган авылын яратып яши. Бәйрәмнәр уздырганда, башка күңелле мәшәкатьләр килеп чыкканда хәйрия ярдәме белән дә катнаша.





**Арсланова (Абдуллина) Фәния Насыйбулла кызы** 1969 елның 5 июнендә Лаеш районы Хәерби авылында туа. Урта мәктәпне тәмамлагач, Казан дәүләт университетының журналистика бүлегендә укый. 1992 елда «Ватаным Татарстан» газетасында корреспондент булып эшли башлый. Хәзерге вакытта газетаның хатлар һәм социаль мәсьәләләр бүлеге мөдире. «Казанның 1000 еллыгы» истәлек медале белән бүләкләнә, Татарстан Республикасының атказанган матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр хезмәткәре.

Фәния Арсланова туган авылын олы бер хис белән ярата, авыл халкы да аның белән горурлана.



Фәния Арсланова ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Әхмәтов белән. 2013 ел.

Фәниянең ире Илгиз Альберт улы Арсланов, Россия Фәннәр академиясе Казан гыйльми үзәгенең Физика-техника институтында әйдәп баручы инженер булып эшли. Кызлары – Гөлнара, Истамбулдагы (Төркия) Мәрмәрә университетын тәмамлый, тәрҗемәче вазифасын башкара, Алия Казандагы 2 нче татар гимназиясендә укый.



**Вафина Таһирә Әнвәр кызы** 1949 елның 3 мартында Лаеш районы Хәерби авылында туа. Хәерби сигезьеллык һәм Саралан урта мәктәпләрен, Совет сәүдәсе техникумын тәмамлый. Казан елга порты сәүдә системасында өлкән бухгалтер, ревизор, баш ревизор, «Грифон» ҖЧҖнең шәхси сак предприятиесендә баш бухгалтер булып эшли. Хәзерге вакытта лаеклы ялда.

Таһирә апаның әтисе – Бөек Ватан сугышы ветераны Закиров Әнвәр Закир улы (14.01.1926 – 20.10.1991), әнисе – Закирова Зөлфа Харис кызы (14.03.1927 – 20.04.2018). Таһирә Әнвәр кызы туган авылын, аның кешеләрен бик ярата. Хәербиләләр дә аны хөрмәт итәләр.

**Вафин Әнвәр Кадыйр улы** 1951 елның 9 ноябрендә Лаеш районы Хәерби авылында туа. Хәерби сигезьеллык мәктәбендә һәм Казанның 10 нчы интернат-мәктәбендә белем ала. Мәктәпне тәмамлагач, бер ел заводта эшли. 1969–1971 елларда армия сафларында хезмәт итә. Солдат хезмәтен август аенда Хабаровскида башлап, Грозный шәһәрендә тәмамлый. 1971–1975 елларда Казан авыл хуҗалыгы институтында укый. Үз теләге белән Кама Тамагы районына эшкә китә. Озак еллар Кама Тамагы районында агроном, парторг, колхоз җитәкчесе, райкомның икенче секретаре булып эшли. Хатыны Фәния Касыймҗан кызы белән институтта танышып тормыш корып җибәрәләр. Ике кыз үстерәләр. Фәния ханым хисапчы булып эшли, бүген ул лаеклы ялда. Алты оныклары бар. Әнвәр Кадыйр улы 1990 елда

үз якларына – Лаешка әйләнеп кайта һәм «Агрохимсервис» оешмасын җитәкли. Иген үстерү нияте белән, район җитәкчеләреннән җир сорый. Телә-генә ирешә. Җире дә була, иген дә үстерә. «Берёзовка» совхозын оештырып, анда мөгезле эре терлек алып җибәрә. Сөт заводын аякка бастыра. Районда беренчеләрдән булып сөт, каймак, эремчекне савытларга тутырып сатуга чыгара. Районны төрле ашламалар белән тәэмин итеп тора. Җитәкчене районда да, республикада да үрнәк итеп куялар. Аңа Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре исемнәре бирелә. Эшләр гөрләп барганда аяусыз чир Әнвәр Кадыйр улын аяктан ега. Ул 2013 елның 11 сентябрендә 62 яшендә якты дөньядан китеп бара. Авылның үз-үзен аямыйча эшләгән, күп игелекләр кылырга өлгергән затлы улын матур итеп искә алалар.



**Галәвов Әсфан Галләм улы** 1963 елның 25 ноябрендә Лаеш районы Хәерби авылында туа. 1990 елда Саратов политехник институтын тәмамлый, инженер-механик белгечлеге ала. «Хәерби» совхозында шофёр, слесарь, беренче категорияле техник, өлкән диспетчер булып эшли. 1989 елда «Казаньстройтранс» җитештерү берләшмәсендә мастер, 1990 да КПАТП-1 оешмасында өлкән инженер урынбасары, 1993 тән КПАТП-2 оешмасында өлкән инженер урынбасары, 1995 тән «КПАТП-2» оешмасы директоры, 2001 дән Казан «Казгорэлектротранс» коммуналь унитар предприятиесе директоры, 2002 дән «Казгорэлектротранс» муниципаль унитар предприятиесе генераль директоры, 2004 тән «Метроэлектротранс» муниципаль унитар предприятиесе генераль директоры. 2004–2009 елларда – ТРның өченче чакырылыш Дәүләт Советы, 2009–2014 елларда – дүртенче чакырылыш Дәүләт Советы, 2014–2019 елларда – бишенче чакырылыш Дәүләт Советы депутаты. «Бердәм Россия» партиясе әгъзасы. Шәһәр советының закон һәм хокук тәртибе комитеты әгъзасы. ТРның атказанган транспорт хезмәткәре. Икътисад фәннәре кандидаты (2008 ел). Мактау грамоталары, иң югары дәрәҗәдәге Рәхмәт хатлары, Почет ордены, медальләр һәм күкрәк билгеләре белән бүләкләнгән. Әсфан Галләм улының ике улы бар.





**Гарифуллина Фирдәүс Шафик кызы** Лаеш районы Хәерби авылында туа. Казан дәүләт педагогика институтын тәмамлагач, Хәерби мәктәбендә рус теле һәм әдәбияты фәнен укыта.1982 елдан Казан шәһәрендә, балалар бакчасында тәрбияче, татар теле укытучысы булып эшли. 1984 елдан Казан шәһәрендәге 2 нче педучилищеда татар теле һәм әдәбияты укыта. 1996–2006 елларда укытуын Татар дәүләт гуманитар институтында дәвам итә. 2004 елда югары уку йортлары укытучысы квалификациясен ала. ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы каршында оештырылган бәйсез экспертлар төркеме әгъзасы. ТР Фән һәм мәгариф министрлыгы каршында оештырылган Фәнни хезмәтләрне һәм методик әсбапларны рецензияләүче иҗади төркем эшендә актив катнаша. 2009 елда Казанның «Мәгариф» нәшриятында «Татар теленнән иҗади сочинениеләр һәм изложениеләр» хезмәте (автордаш) басылып чыга. 2011 елда татар мәктәпләре өчен «Әлифба» дәреслеге (автордаш) әзерләп бастыра. 2012 елда рус мәктәбендә укучы татар балалары өчен «Әлифба», методик ярдәмлекләр, үзлегеңнән эшләү өчен дәфтәр (автордаш) бастырып чыгара.

Бүләкләре: «Мәгариф өлкәсендәге казанышлары өчен» билгесе (2005), «Казанның 1000 еллыгы» медале (2007) белән бүләкләнә.

**Гыймадиева Рәйсә Сафа кызы** 1949 елның 2 гыйнварында Лаеш районы Хәерби авылында туа. 8 сыйныфны тәмамлагач, 1960 еллар уртасында, Казанга килә. Кичке мәктәптә укый, мех комбинатында эшли, җылы киемнәр тегә. 1967 елда бөек композиторыбыз Сара Садыйкова җитәкләгән хорга кабул ителеп, 20 ел үзешчән сәнгатьтә кайнап яши. Шул вакыт эчендә Рәйсә белән хор җитәкчесе арасында туганнарча дуслык урнаша. Ул Сара апада җиде ел фатирда тора. Сара апа язган җырларын иң элек Рәйсәгә җырлатып карый торган була. Р.Гыймадиева Татар агробизнес кадрларын яңадан әзерләү институтында хуҗалык мөдире булып эшли. Хәзерге вакытта лаеклы ялда. Рәйсәнең энесе — Хәйдәр Гыймадиев та Сара Садыйкова хорына йөри.

Түбәндә Рәйсә Гыймадиева турында «Социалистик Татарстан» газетасында басылган мәкалә тәкъдим ителә (Рафаэль Сальмушев, «Җырга гашыйк кыз». 1973 ел, 9 август).

«Концертны алып баручы: «Хәзер яраткан җырчыбыз Рәйсә Гыймадиева җырлый», – дип белдерде. Зал гөрләп кул чаба башлады. Янымда утыручыдан: «Кем соң ул?», – дип сорадым. «Икенче цехтан, тегүче», – диде күршем.



1



2




3

1. Сара Садыйкова һәм Рәйсә Гыймадиева; 2. Хәйдәр Гыймадиев (уңда);
3. Сара Садыйкова җитәкләгән хор. 1978 ел.

Аның белән беренче танышуым шулай булды. Күп тә узмагандыр, аның белән эш урынында очраштык. Шулай итеп, без бер цехта эшли башладык. Озак кына вакыт ул эшли торган машинага карап тордым: аның кулы кулга йокмый иде. Мондый осталыкка өйрәнүен тегү эшен яратуы белән аңлатты

Рәйсә. «Беренче еллар авыр булды, – дип сөйләп китте ул. – Училищены тәмамлагач, мехкомбинатның 7 нче фабрикасына җибәрделәр. Берничә елдан соң 8 нче фабриканың 2 нче цехына эшкә килдем. Яңа коллективка тиз күнектем. Ярдәм иттеләр».

Рәйсәнең җырчы булуына квартирада бергә торучы З.Корбангалиева да сәбәпче. Бервакыт, бүлмәдә үзе генә калгач, «Рәйхан»ны сузып җибәрә Рәйсә. Бу вакытта эштән кайткан З.Корбангалиева әкрен генә ишекне ачып керә дә Рәйсәнең җырын гаҗәпкә калып тыңлап тора. «Тавышың бигрәк матур, нигә үзешчән сәнгать түгәрәгенә йөрмисең? Бер квартирда торып, болай матур җырлаганыңны белми идем, – ди ул. – Иртәгә сине М.Горький исемендәге клубка алып барам».

Оялып кына алар Сара Садыйкова янына керәләр. «Рәйсә, без сезне хорга алырбыз», – ди Сара апа. Ул көннән соң биш елдан артык вакыт узып китте. 8 нче фабриканың үзенең җырчылары һәм биючеләре бар хәзер. Фабрика клубы каршында үзешчәннәр түгәрәге эшләп килә. Бәйрәм концертлары Рәйсә Гыймадиевадан башка узмый. Хәзер инде ул үзен сәхнәдә профессиональ җырчылар шикелле иркен тота. Ул М.Горький исемендәге клуб хорына йөрүен дәвам итә. 2 нче цех коллективы Рәйсәне ярата, ихтирам итә. Комсомолка кызны цех профсоюз комитетының культура-агарту секциясенә сайладылар».

**Җамалетдинова Зәлфирә Исхак кызы** Лаеш районы Хәерби авылында туа. 1981 елда Казан педагогика училищесын, ә 1986 елда Казан дәүләт педагогика институтын тәмамлый. 38 еллык педагоглык хезмәт стажы бар. Хезмәт юлын башлангыч мәктәп укытучысы булып башлаган кыз, Казан шәһәрендәге 20 нче гимназия директоры, Идел буе төбәкара мәгариф хезмәткәрләре белемен күтәрү һәм яңадан әзерләү үзәге өлкән укытучысы булып эшли. Бүгенге көндә Өстәмә һөнәри белем бирү дәүләт автоном мәгариф учреждениесе «Татарстан Республикасы мәгарифне үстерү институты» доценты.



2015 елда Россия мәгариф академиясенең «Һөнәри белем бирү педагогика һәм психология институты»нда педагогика буенча кандидатлык диссертациясе яклый, педагогика фәннәре кандидаты гыйльми дәрәҗәсенә ия була.

Зәлфирә Исхак кызы Җамалетдинова татар теленнән гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белем бирү программаларын тормышка ашыру өчен кулланышка тәкъдим ителгән, федераль

исемлеккә кергән укыту-методик комплектлар, 200 дән артык фәнни-методик мәкалә авторы.

2004 елда «Мәгариф өлкәсендәге казанышлары өчен» билгесе белән бүләкләнә, 2009 елда «Россия Федерациясенең Мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре» исеменә лаек була. 2007 елда Казан шәһәре күләмендә үткәрелгән «Ел укытучысы» бәйгесендә икенче урынны, ә республика күләмендә үткәрелгән шундый ук бәйгедә лауреат исемен яулый. Шул ук елны Россия Федерациясенең өстенлекле милли мәгариф проектында «Иң яхшы укытучы» номинациясендә грантка ия була. З.И.Җамалетдиновага, укыту-методик комплект авторы буларак, милли мәгарифне үстерүдәге казанышлары өчен 2010 елда Каюм Насыйри исемендәге премия бирелә.



**Зиннәтуллин Рамил Камил улы** 1984 елның 9 декабрендә Лаеш районы Хәерби авылында туа. 2002 елда Хәерби урта мәктәбен тәмамлап, Казан дәүләт аграр университетына укырга керә. Анда галим агроном-эколог белгечлеге алып чыга. Бер ел «Хәерби» хуҗалыгында агроном булып эшли, аннары хезмәт эшчәнлеген «ТР Фермерлар һәм крестьян хуҗалыклары ассоциациясе»ндә дәвам итә. 2009 елның апреленнән ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Орлыкчылык һәм химияләштерү секторында әйдәп баручы белгеч.

**Зиннәтуллина (Нигъмәтова) Гөлнара Хабул кызы** 1952 елның 7 апрелендә Лаеш районы Хәерби авылында туа. 5 нче сыйныфны авыл мәктәбендә укыганнан соң, белем алуны Казанның 10 нчы физика-математика интернат-мәктәбендә дәвам итә. 1960 елларда кечерәк шәһәрләр һәм авыл җирләрендәге сәләтле балаларны укыту өчен мондый уку йортлары бөтен ил буенча оештырыла. Мәктәп 6 нчы Союзлар урамында урнашкан була (хәзер Ш.Усманов урамы).

Бервакыт мәктәпкә күрше бинада гына урнашкан Казан телестудиясеннән өч хатын-кыз керә. Болар балалар тапшырулары режиссёры Гөлсем Билалова (Исхакова), телевидение режиссёры, ТРның халык артисты Флюра Бикмурзина, режиссёр ярдәмчесе Флора Орешина була. Алар тапшыруларда катнашу өчен талантлы балалар сайлыйлар, хәзергечә әйтсәк, кастинг уздыралар. Г.Билаловага Гөлнараның яхшы дикциясе һәм чиста тавышы ошый, һәм ул аны туры эфирда шигырь сөйләргә чакыра. Шуннан соң 12 яшьлек Гөлнара балалар өчен «Пионерстан» тапшыруын алып бара башлый. Бәлки нәкъ менә шул



вакытта ул микрофон һәм телекамералардан аерылмаска карар иткәндер. Гөлнара Хабул кызы 47 ел шунда эшли, аның хезмәт кенәгәсендә бары бер эш урыны күрсәтелгән – Татарстан Республикасы телевидениесе.

Гөлнара Зиннәтуллина Казан университетының тарих-филология факультетын тәмамлый. 1970 елдан алып балалар тапшырулары редакциясенең режиссёр ярдәмчесе, 1980 елдан балалар өчен «Пионерстан», «Без авылда яшибез», «Мәйданга чыгыгыз, батырлар!», «Күңелле уеннар», «Бергәләп өйрәник», «Әлли-бәлли-бәү», «Шигъри тәлгәшләр» тапшыруларының редакторы һәм алып баручысы була. Бу тапшырулар шул чордагы балаларны тәрбияләүдә, тулаем алганда, республика телевидениесеннән татар телендә трансляцияләнгән балалар тапшыруларының сыйфатын яхшыртуда бик мөһим роль уйный. Хәерби авылы балалары аның тапшыруларында бик еш катнашалар («Шигъри тәлгәшләр», Пионерстан», «Бергәләп өйрәник» һ.б.).

Балалар белән эшләгәндә Г.Зиннәтуллина үзен профессиональ алып баручы буларак кына түгел, талантлы журналист буларак та күрсәтә. Аның татар телендә «Бергәләп өйрәник», «Күңелле уеннар» авторлык программалары балаларның иң яраткан тапшыруына әйләнә. Яшь талантлар шулай ук Гөлнара Хабуловнаның югары рейтингка ия тапшыруында катнашырга омтылалар. Мәсәлән, «Бергәләп өйрәник» программасы чыгарылышларының берсендә һөнәрен күрсәткән биш яшьлек Муса Маликов турында бөтен республика белә. Хәзерге вакытта ул Европа күләмендә танылган уңышлы җырчы, музыкант, композитор.




Төрле вакытларда Г.Зиннәтуллина әзерләгән балалар тапшыруларында Чулпан Әхмәтҗанова (җырчы, Татарстан Республикасының атказанган артисты), Венера Шәмиева (җырчы, Казан дәүләт мәдәният институты доценты), Илшат Әминов («Татарстан – Яңа Гасыр» телекомпаниясе генераль директоры, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, 2019 елдан ТР Журналистлар берлеге рәисе) һәм башка балалар катнаша, талантлары ачыла, аларның казанышлары турында республикада гына түгел, бөтен Советлар Союзы киңлекләре дә белә. Г.Зиннәтуллинаның республика иҗади потенциалын популярлаштырудагы

нәтиҗәле эше сизелмичә калмый. Мәсәлән, Муса Маликов турындагы «Минем кечкенә дустым» сюжеты «Сахалин-92» халыкара телевизион программалар фестиваленең балалар һәм яшүсмерләр өчен тапшырулар номинациясендә, татар телевидениесе тарихында беренче тапкыр, II дәрәҗә Диплом белән бүләкләнә. Чаллы шәһәреннән «Айгөл» балалар вокаль ансамбле турындагы концерт-очерк исә Үзәк телевидение аша татар телендә күрсәтелгән беренче балалар тапшыруы булып тарихка кереп кала.



ТР радио һәм телевидениесенең өлкән режиссёры итеп Гали Хөсәенов билгеләнгәч, ул, әдәби-драматик тапшырулар редакциясенә тәҗрибәле режиссер ярдәмчесе кирәк булу сәбәпле, Гөлнара Зиннәтуллинаны шунда күчерә. Г.Хөсәенов белән хезмәттәшлек итү Гөлнара Хабуловнаның һөнәри үсеше юлында тагын бер баскычка әйләнә.

Соңрак аңа сценарист, телефильмнар һәм телеспектакльләр куючы режиссёр, әдәби очерклар авторы Әхтәм Зарипов белән эшләү бәхете елмая. Бу чор Гөлнара өчен режиссерлык практикасы алу, актерлык һәм сәхнә осталыгын камилләштерү мөмкинлеге бирелү белән кадерле. Мондый остазның ассистенты буларак, ул күп нәрсәгә өйрәнеп кенә калмыйча, әдәби-драматик тапшырулар редакциясенә әзерләнгән программаларның сыйфатын күтәрү өстендә дә актив эшли. Бәлки, нәкъ менә татар театр сәнгатенең атаклы кешеләре белән хезмәттәшлек итү алга таба «Яшәсен театр!» тапшырулар циклын булдыру турындагы уйга этәргәндер?!



Гөлнара Зиннәтуллина Татарстан Республикасы Дәүләт киңәшчесе ярдәмчесе Нурсөя Шәйдуллина белән.

1991–1994 елларда Гөлнара Зиннәтуллина журналист Владимир Булычев белән берлектә иртәнге «Чулпан» тапшыруын алып бара. «Чулпан»нан соң ул үзенең авторлык тапшыруларын әзерли башлый. Шуларның берсе – яшьләр тапшырулары редакциясендәге «Түрдән узыгыз» тапшыруы.

Аның алып баручылары ул үзе һәм ТРның халык артисты, җырчы Фердинанд Сәлахов була.

1998 елда ТРТ каналының яшьләр редакциясе базасында Илдар Кримчеев кул астында продюсерлык үзәге оештырыла, аның максаты – яңа проектлар чыгару, кинорепертуарны һәм музыка сәясәтен формалаштыру була. Продюсерлык үзәгенең баш режиссеры Илдус Кәримов (хәзер спорт тапшырулары баш режиссеры) эфирга егермедән артык яңа программа чыгара, алар арасында Гөлнара Зиннәтуллинаның «Иртә түгел, соң түгел» авторлык тапшыруы да була. Тапшыру туры эфирда бара, тамашачылар алып баручы яки чакырылган кунакка сораулар бирә ала. Мондый аралашу форматы тамашачы аудиториясендә кызыксыну уята. «Иртә түгел, соң түгел» тапшыруының берничә чыгарылышы ТАССР һәм РФнең атказанган мәдәният хезмәткәре Фирдания Исмәгыйль кызы Садриева белән берлектә әзерләнә. Тапшыру журналист эшләре конкурсына тәкъдим ителеп, Татарстан Республикасы Журналистлар берлегенең «Бәллүр каләм» («Хрустальное перо») лауреат дипломына лаек була.

2000 еллар башында Россия телевидениесендә күңел ачу тапшырулары популярлаша. Г.Зиннәтуллина республика телевидениесендә дә шундый проект булдырырга уйлый. Ул, шулай ук продюсерлык үзәге тарафыннан хуплanучы, «Шәрәфигә ияреп» тапшыруының авторлык циклын эшләүгә керешә. Тапшыру туристлык үзәкләре һәм истәлекле урыннар турында сөйли, ә аның төп герое – шаян Шәрәфи (Р.Ш.Шәрәфиев – драма актеры, ТАССРның һәм РСФСРның халык артисты) була. Алар Барселона (Испания), Прага, Пльзень, Карловы Вары (Чехия), Лимасол (Кипр), Афина, Рим (Италия), Ватикан, Кастория (Греция), Истанбул, Анталья, Аспендос, Бодрум, Авылдашук, Эфес, Белек (Төркия) һәм башка җирләрдә булалар.



Г.Зиннәтуллина «Бәллүр каләм» конкурсының чираттагы Лауреат дипломын («Журналистикада исем» номинациясендә) 2007 елда «Яшәү яме» тапшырулар циклы өчен ала. Аның белән берлектә циклны режиссерлар Заһирә Куртаева һәм Гөлсинә Әхмәдиева, операторлар Фәрдәт Мансуров, Рафаил Гәрәев һәм Илдар Шәмсетдинов, шулай ук студиянең телеоператорлары эшли. «Яшәү яме» тапшыруының геройлары язучылар, табиблар, укытучылар, хакимият эшлекләләре, җырчылар, композиторлар, артистлар, авыл хуҗалы-



гы предприятиеләре җитәкчеләре, югары уку йортлары укытучылары, нефть сәнәгате хезмәткәрләре һ.б. була. Гөлнара Хабуловна бу тапшыруны әзерләгәндә телевизор караучыларга кеше тормышының иң яхшы якларын күрсәтүне, кешеләрдә игелек кылу омтылышы тудыруны максат итә.

2006 елда Г.Х.Зиннәтуллина татар милли театрының йөз еллыгына багышланган «Яшәсен театр!» тапшырулары циклын эшли башлый (режиссеры – Заһирә Куртаева). Идмас Үтәгәнов тарафыннан 1976 елда әзерләп чыгарылган «Татар театры тарихы» фильмыннан соң, татар театрының тарихы һәм бүгенгесе турында экран аша дәвамлы, җитди тапшырулар күрсәтелгәне булмый. Ә Гөлнара Зиннәтуллинаның бу тапшырулары татар театры тарихының тулы бер видеоэнциклопедиясенә әйләнә. Аларда Россия буйлап таралган татар милли театрларының барлыкка килү тарихы һәм иҗади эшчәнлеге яктыртыла. Татарстан Республикасы, Уфа, Оренбург театрлары турында барлыгы 263 тапшыру әзерләнә һәм күрсәтелә. «Яшәсен театр!» тапшырулар циклы бүгенге көнгә кадәр актуаль, «ТНВ» каналы аны даими рәвештә трансляцияли.

Гөлнара Зиннәтуллина күп еллар дәвамында «Татарстан» ДТРК каналының, аннан соң «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясенең «йөзе»н тәшкил итә. Иртәнге мәгълүмати программаларны алып бару һәм төрле тапшырулар әзерләү белән беррәттән, ул Җиңү көне, Республика көне, Сабан туе, «Зәңгәр ут» кебек бәйрәмнәрнең алып баручысы, сәнгать циклларының авторы да була. Республика телевидениесен үстерүгә зур өлеш керткәне өчен 2000 елның маенда Татарстан Республикасы Президенты Указы белән аңа «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелә. Ире Ренат белән бер ул тәрбияләп үстерәләр, ике оныклары бар.





**Миңнебаев Нәҗиб Нури улы** 1949 елның 25 маенда Лаеш районы Хәерби авылында туа. 5 сыйныфтан соң ул Казан дәүләт консерваториясе каршында яңа оешкан махсус урта музыка мәктәбендә белем ала. Баян классы ачылмаган булу сәбәпле, Нәҗиб Миңнебаев Александр Геронтьев һәм Валерий Важоровларның флейта классында укый. Мәктәптән соң укуын Казан дәүләт консерваториясендә дәвам итеп, Александр Геронтьев классын тәмамлый. 1975–1976 елларда Хабаровск шәһәрендә армия сафларында хезмәт итә. Анда да Кораллы көчләр штабының тынлы оркестрында уйный. 1971 елдан алып Татарстан дәүләт симфоник оркестрының әйдәп баручы музыканты – флейтада уйнау остасы була. Ул, симфоник оркестрдан тыш, Татар дәүләт опера һәм балет академия театры оркестрында, Харис Нигъмәтҗанов җитәкчелегендәге Республика халык музыка уен кораллары ансамблендә дә уйный. Консерваториядә, үзе укыган махсус музыка мәктәбендә, музыка училищесында флейта классында белем бирә.


ГРАМОТА

УКАЗОМ ПРЕЗИДИУМА ВЕРХОВНОГО СОВЕТА ТАТАРСКОЙ ССР

ЗА ЗАСЛУГИ в ОБЛАСТИ ИСКУССТВА

МИННУБАЕВУ
Назибу Нуриевичу

*присвоено почетное звание*

„ЗАСЛУЖЕННЫЙ АРТИСТ
Татарской ССР"

Нәҗиб аганың хатыны Фирая ханым белән корган оясында кызлары Альбина үсә, ике оныклары бар. Нәҗиб Нури улы 2010 елның 11 ноябрендә вафат.

*Рөстәм Абязов, Татарстан дәүләт симфоник оркестры дирижеры, ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе:*

– Нәҗиб Миңнебаев — Татарстанның күренекле музыканты. Андыйлар йөз елга бер генә туадыр, мөгаен. Юкка гына күп еллар симфоник оркестрда беренче флейта партиясен уйнамагандыр ул. Оркестрда аның лаеклы үз урыны бар. Флейта партиясе ул кайберәүләр уйлаганнан күпкә виртуозрак, күпкә җаваплырак һәм флейта оркестрда җитди уен коралы булып санала. Оркестр өчен язылган әсәрдә иң матур көйләр флейтага бирелә. Казанда йөзләрчә флейтачы бар, ә Нәҗиб алар арасында бердәнбер иде. Татарстанның бөек музыкантына минем ихтирамым зур булды. ТРның атказанган артисты исеменә ул чыннан да лаек. Нәҗиб күптән инде халык артисты исеменә дә лаек иде, әмма барысы да бездән тормый бит. Нәҗиб Нури улы һәртөрле музыканы — халык музыкасын да, классиканы да, эстрада-

ны да уйнады. Бетховен, Брамс... төрле стиль, төрле жанр музыкасы аңа буйсына иде. Бароккоԋы, борынгы һәм хәзерге заман хәзинәләрен дә, Софья Гобәйдуллинаны да, татар музыкасын да... Башкару культурасы кабатланмас дәрәҗәдә иде.



Нәҗиб иң күренекле дирижерлар белән эшләде. Ул Натан Рахлинның яраткан флейтачысы булды. Дирижерлар концерт барганда еш кына осталыгы белән сокландырган, нәкъ менә бүген аеруча илһамланып уйнаган, яисә партиясе катлаулы, әйдәп баручы булган музыкантны тамашачыга аерым тәкъдим итә. Ә менә аны һәр чыгыштан соң, һәр дирижер диярлек шулай күтәрә иде. Ул шатланып торып баса, баш ия һәм публика аны сәламли. Музыкант өчен бу мизгел зур дәрәҗә һәм халык тарафыннан танылу билгесе. Иң югары исемнәр, халыкара премияләр, рәсми танылулардан кадерлерәк бу бүләк. Иҗат кешесе мизгел рәхәтлеге белән илһамлана, шуннан көч ала. Нәҗиб Миңнебаевны оркестр музыкантлары да хөрмәт итте. Интонация чисталыгы, стиль, ритм һ.б.га караган кимчелекләр аңа хас түгел иде. Һөнәри күзлектән музыкантлык осталыгы абсолют камил иде. Чит илләрдән һәм Россиядән килгән дирижерлар аңа игътибар итеп, үзен бөек музыкант буларак югары бәяләделәр. Миңа аның белән күп илләр (Франция, Германия, Испания, Италия, Бельгия, Көньяк Корея һ.б.) гизәргә, Европаның иң затлы залларында чыгыш ясарга насыйп булды. Көньяк Корея гастрольләрендә без Европа, татар һәм Корея музыкасын зур уңыш белән башкардык. Кореялеләр музыкасы татарныкына моңы, рухы, поэтикасы ягыннан охшашрак. Ул аларны искиткеч итеп яратып башкарды.

*Илсур Айнатулов, Дәүләт симфоник оркестрында фагот төркеме концертмейстеры, Казан дәүләт консерваториясенең тынлы уен кораллары кафедрасы мөдире, профессор, ТРның атказанган артисты:*

– Нәҗиб белән без махсус музыка мәктәбендә бер тирәдә укыдык. Алар мәктәпне алданрак тәмамладылар, консерватория елларында да очрашып, дус яшәдек. Ул консерваториядә һәм үзе укыган махсус музыка мәктәбендә флейта һәм тынлы уен кораллары ансамбле дәресләрен алып барды. Нәҗиб курайда бик оста уйный иде, музыка мәктәбендә балаларны курайда уйнарга өйрәтте. Шәкертләре арасында бик сәләтле, төрле дәрәҗәдәге конкурсларда лауреат исемнәренә

лаек булганнар да бар. Кайберләре оркестрларда эшли, күпләре музыка мәктәпләрендә укыталар. Флейтада виртоуз уйный торган укучылар тәрбияләде ул.

Нәҗиб яхшы дус, кызыклы әңгәмәдәш булды, ачык күңелле, нечкә хисле, позитив характерлы булып, хыянәтне, фальш, алдашуны яратмады. Көчле рухлы, гадел ир булуы белән дә хөрмәткә лаек иде, авырлык алдында бөгелеп төшмәде.

Нәҗиб зур шәхесләр белән иҗат итте – И.Шакиров, Х.Бигичев, З.Сәхәбиева, В.Ганиева, Р.Ибраһимов белән гастрольләрдә йөрде. Республикада флейтачылар күп булуга карамастан, танылган җырчылар флейтада уйнарга Нәҗибне чакыралар иде.

*Харис Нигъмәтҗанов — Республика халык музыкасы уен кораллары ансамбле җитәкчесе, ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе:*

– Мин аны һәвәскәр ансамбльләр оештырып йөргәндә, музыкантлар эзләгәндә «ачкан» идем. Халык көйләрен аннан да оста башкаручы юклыгына инандым. Нәҗиб, татар рухлы музыкант буларак, халык көйләрен, бигрәк тә озын көйләрне яратып, тетрәндерерлек итеп, җиренә җиткереп башкара иде. Киң колачлы музыкант — гармунда, баянда уйный, композиторлык сәләте дә бар иде. Аның җырларын Р.Закиров, Г.Фарукшин, З.Билалов һ.б. башкарды. Сабакташы Х.Бигичевка багышлап, «Дустыма» җырын иҗат итте. Безнең ансамбль дәүләт ансамбле статусын алгач, коллективка музыкант булып эшкә килде. Флейтада, язылып җитмәгән нюансларны кертеп, матур бизәкләр өсти, фантазиясе искиткеч бай иде аның. Безнең ансамбльдә бик күп яшь җырчылар эшләде. Алар өчен Нәҗиб үрнәк булды һәм яшьләр аның иҗатына якынлашырга тырыштылар.

*Илһам Шакиров, Татарстанның һәм Россиянең халык артисты, Н.Миңнебаев турында:*

– Флейтаны мин хәтта симфоник оркестр эченнән дә иң беренче булып эзләп табам, чөнки ул бигрәк тә үзебезчә — татарча яңгырый. Ә мин аның тавышына унбер яштән үк гашыйк. Флейта ул оркестрга да, ансамбльгә дә кушыла ала, әмма солоны сирәкләр генә уйный. Нәҗиб Миңнебаев уйный. Һәм ничек кенә әле!!! Үзе татар халкының чын улы буларак, халкыбызның борынгы көйләрен җиренә җиткереп, ялгызы гына да башкара. Ә Игорь Стравинскийны кем уйный ала? Әлбәттә, Нәҗиб! Аның уйнавын тыңлавы җанга рәхәт, йөрәккә ял бирә.

**Мөхәммәтҗанов Рәшит Мөхәммәт улы** 1961 елның 30 апрелендә Лаеш районы Хәерби авылында туа. Әтисе Мөхәммәт Мөхәммәтзариф улы – авыл хуҗалыгы эшчесе һәм сәүдә тармагы хезмәткәре, әнисе Гөлсем Хәмәтхан кызы шулай ук авыл хуҗалыгы өлкәсендә һәм фельдшерлык пунктында эшлә-

гән кешеләр. Гаиләдә алар өч бала үсә: 1959 елда туган абыйсы Рәфит һәм 1964 елда туган сеңелесе Нурия бар.

Рәшит Мөхәммәт улы Хәерби сигезьеллык мәктәбендә һәм Казан шәһәренең 10 нчы интернат мәктәбендә укый. 1983–1986 елларда Татарстанның Әтнә авыл хуҗалыгы техникумында техник-механик һөнәрен үзләштерә. 1996–2001 елларда Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан юридик институтында укып, юрист белгечлеге алып чыга. Болардан тыш, берничә төр квалификация күтәрү курсларында белем ала, соңрак үзе дә, яшь белгечләр өчен остаз буларак, белем һәм тәҗрибәсе белән уртаклаша. Гомер буе эшләп укый ул.



Рәшит Мөхәммәт улы 1978–1979 елларда Казан шәһәрендәге «Радиоприбор» заводында слесарь, 1979–1980 елларда Татарстанның Лаеш районы «Хәерби» совхозында машина йөртүче булып эшли. 1980–1982 елларда Совет Армиясе сафларында хезмәт итә, Мәскәү өлкәсендә хәрби частьларның берсендә машина йөртә, командирлары тарафыннан берничә тапкыр Рәхмәт хатына лаек була. Хәрби хезмәтен тәмамлап кайткач, 1982 елда Казандагы Татар дәүләт филармониясендә, 1982–1984 елларда Республика дәвалау-физкультура диспансерында, 1984–1987 елларда Казан шәһәре Дәүләт иминият идарәсендә, 1987–1988 елларда Дәүләт матди резервлар комитетының Казан территориаль идарәсендә, 1988–1990 елларда «Междуречье» комбинатында, 1990–1994 елларда Татарстанның «Татсахарагропром» җитештерү берләшмәсендә машина йөртүче булып эшли. 1994 елда һөнәри юнәлешен кискен үзгәртеп, Эчке эшләр органнарына күчә, хезмәтен кече лейтенант дәрәҗәсендә Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан юридик институты комендантлык бүлегендә милиционер булып башлап җибәрә. 1996 елда комендантлык бүлеге башлыгы итеп билгеләнә. 1997 елдан 2008 елга кадәр шушы ук институтның тәэминат бүлеге башлыгы вазифаларын уңышлы башкара. 2008 елдан бүгенгә кадәр Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының (2016 елдан – Россия Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләренең) махсус авиация отрядында отряд командиры урынбасары – тыл башлыгы булып хезмәт итә. Эчке эшләр органнарында 25 ел хезмәт итү дәверендә Рәшит Мөхәммәт улы кече лейтенант дәрәҗәсеннән полиция полковнигы дәрәҗәсенә кадәр күтәрелә. Шунысын да әйтергә кирәк: ул – Хәерби авылыннан чыккан хәрбиләр арасында тыныч шартларда беренче булып полковник дәрәҗәсенә ирешкән кеше. 2011 елда Төньяк Кавказ төбәгендә тынычлык урнаштыру буенча хәрби бурычын үтәп, Россия Эчке эшләр министрлыгының «Төньяк



Рәшит Мөхәммәтҗанов гаиләсе белән.

Кавказдагы хәрби хәрәкәтләрдә катнашучы», «Хәрби батырлык өчен» медальләре белән бүләкләнә һәм Хәрби хәрәкәтләр ветераны исеменә лаек була. 1998 елда «Эчке эшләр органнарында яхшы хезмәт өчен» билгесе, 2002 елда «Россия Эчке эшләр министрлыгына 200 ел» медале, 2003, 2007, 2012 елларда III, II һәм I дәрәҗә «Хезмәттәге казанышлары өчен» медальләре белән, 2012 елда «Хәрби бурычка тугрылык өчен» билгесе, «Үзәк казак гаскәрләре каршындагы хезмәтләре өчен» билгесе, Россия Эчке эшләр министрлыгының «Сугышчан хезмәттәшлек өчен» медале, 2016 елда «Махсус авиация отрядына 10 ел» юбилей медале, болардан тыш хезмәте дәвамында Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы һәм Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының күпсанлы Мактау грамоталары һәм Рәхмәт хатлары белән бүләкләнә. 2013 елда Татарстан Республикасы буенча мактаулы Эчке эшләр министрлыгы хезмәткәре исеменә лаек була.

Хатыны Венера Иңгел кызы белән ике ир бала тәрбияләп үстерәләр. Олы уллары Илназ, әтисе юлын дәвам итеп, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгында полиция майоры дәрәҗәсендә бүлек башлыгы булып хезмәт итә. Кече уллары Илдар – шулай ук һөнәре буенча хокук белгече, аспирантурада укый.



**Мутаева (Ибәтуллина) Илсөяр Шафик кызы** 1962 елның 4 июнендә Лаеш районы Хәерби авылында туа. Лаеш авыл хуҗалыгы техникумын (1980), Волгоград физкультура институтын тәмамлый (1984).

1984–86 елларда «КамАЗ» спорт-клубында тренер-укытучы. Чаллы кою заводы базасында беренчеләрдән булып терәк-хәрәкәт аппараты зәгыйфьлеге булган кешеләр һәм күрү-ишетү буенча инвалидлар өчен йөгереш клубы оештыра. Кою заводының җиңел атлетика җыелма командасы белән эшли. Чаллы шәһәрендә инвалидлар спортын үстерүдә актив катнаша. 2000 елда «10–12 яшьлек үсмерләрнең йөрәк эшчәнлегенә дзюдо көрәше

белән шөгыльләнүнең тәэсире» темасына кандидатлык диссертациясе яклый, биология фәннәре кандидаты, профессор (2011). Уку-укыту – методик кулланмалар, фәнни хезмәтләр, 4 монография авторы. Россия Федерациясенең физкультура һәм спорт отличнигы. Идел буе дәүләт физкультура, спорт һәм туризм академиясенең Чаллы шәһәре филиалында җиңел атлетика укытучысы, 2004–2006 елларда факультет деканы урынбасары, 2009 елдан факультет деканы, бер үк вакытта, 2010 елдан спортның циклик һәм ациклик төрләренең теориясе һәм методикасы кафедрасы мөдире.

**Насыйбуллин Илшат Әнвәр улы** 1960 елның 9 маенда Лаеш районы Хәерби авылында күп балалы гаиләдә туа. Хәрби дәрәҗәсе — майор. 1983 елда СССР Дәүләт куркынычсызлыгы комитетының (КГБ) Ф.Э.Дзержинский исемендәге Алма-Ата югары чик буе училищесын, 2006 елда Казан дәүләт университетының юридик факультетын тәмамлый.

1978 елның октябреннән 2005 елның 20 сентябренә кадәр чик буе гаскәрләрендә хезмәт итә. 1984 елның феврапеннән сентябренә кадәр Әфганстанда совет гаскәрләренең чикләнгән контингенты составында була, хәрби хәрәкәтләр ветераны.



1983–1988 елларда ВПБС (взвод повышенной боеспособности) командиры; 2086 нчы хәрби часть сәяси бүлеге өлкән инструкторы һәм комсомол эше буенча сәяси бүлек башлыгы ярдәмчесе, КГБның Көнчыгыш чик буе округы өлкән инструкторы. 1985 елда ВЛКСМ ҮК чакыруы белән Яшьләр һәм студентларның XII Бөтендөнья фестивален әзерләү һәм үткәрүне оештыруда катнаша (Мәскәү).

1988–1994 елларда Пржевальск чик буе отрядында сәяси бүлек өлкән инструкторы, уку-укыту үзәге җитәкчесе урынбасары, сәяси бүлек башлыгы урынбасары, чик буе отряды башлыгы урынбасары, тәрбия һәм кадрлар эше буенча бүлек башлыгы вазифаларында. 1994–2005 елларда «Казан-Аэропорт» чик буе контроле бүлегендә смена башлыгы, тәрбия эшләре һәм кадрлар бүлеге башлыгы урынбасары. Күп тапкыр илебезнең чиген бозучыларны тоткарлауда катнаша. Шул вакытта ике тапкыр яралана.

2005–2006 елларда федераль программалар буенча Россия Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча министр киңәшчесе. 2006–2011 елларда Казан дәүләт университетында икътисад мәсьәләләре буенча проректор урынбасары; халыкара элемтәләр идарәсе башлыгы урын-

басары; кадрлар идарәсе башлыгы. 2011–2012 дә ТР Мөселман Диния нәзарәтенең протокол бүлеге башлыгы. 2012 елдан Россия Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Саратов һәм Самара өлкәләре буенча чик буе идарәсенең кадрлар бүлеге өлкән инструкторы.

Илшат Әнвәр улының аналитик һәм системалы фикерләве, югары профессиональ сыйфатлары төрле тармакларда зур коллектив белән эшләргә ярдәм итә. Аның эшлекле сыйфатларыннан профессиональлек, җаваплылык, иҗади фикерләү сәләте һәм инициатива күрсәтүе, командада эшли белүе аерым бәяләнә.

«Суворов» медале (1997); «СССР дәүләт чикләрен саклауда батырлык күрсәткән өчен» медале (1980, 1991); «Чик буе хезмәтендәге казанышлары өчен» билгесе, шулай ук «Казанның 1000 еллыгы» медале; Россия Федераль куркынычсызлык хезмәте директорының, ТР Президентының, ТР Министрлар Кабинетының, ТР Дәүләт Советының, Казан шәһәре администрациясенең Мактау грамоталары, «Җәмәгатьчелек тарафыннан танылу» мактаулы гражданлык Көмеш йолдыз ордены белән бүләкләнә.

Илшат Насыйбуллин өйләнгән, ике кызы бар.

**Насыйбуллин Миңнегәрәй Закир улы** 1956 елның 16 августында Лаеш районы Хәерби авылында туа. 1963–1971 елларда Хәерби мәктәбендә укый.



Урта белемне 1971–1973 елларда Казан шәһәренең 10 нчы интернат мәктәбендә укып ала. 1978 елда Казан төзүче инженерлар институтын тәмамлый. Хезмәт юлын мастер булып башлый. Прораб, баш инженер, генераль директор дәрәҗәсенә ирешә. Ул төзелеш, реконструкция, капиталь ремонт эшләре белән шөгыльләнүче «Ремонтстройсервис» оешмасын җитәкли. Гәрәй Закир улы Насыйбуллин җитәкчелегендә ТР Икътисад министрлыгы, ТР Юстиция министрлыгы биналары, ТР Милли музее төзекләндерелә, Оргсинтез заводы, УНИКС комплексы, Универсиада объектлары, торак йортлар, мәктәпләр, балалар бакчалары, хастаханәләр төзелә. М.З.Насыйбуллин 2006 елда «Татарстан Республикасының атказанган төзүчесе» дигән мактаулы исемгә лаек була. Ул шулай ук «Төзелештәге казанышлары өчен» ордены, «Казанның 1000 еллыгы» медале белән бүләкләнә.



**Насыйбуллина Гөлназ Рөстәм кызы** 1988 елның 15 июнендә Лаеш районы Хәерби авылында туа. Спортчы (самбо, дзюдо). Дзюдо (2004 ел) һәм самбо (2006 ел) буенча Россиянең спорт мастеры. Әлмәт нефть институтын тәмамлый (2010 ел). Спорт белән 1999 елда шөгыльләнә башлый, тренеры — Р.Г.Насыйбуллин. ТР (2003–2006, 2009 — самбо, 2007–2008 — дзюдо, 2011 — самбо), РФ Мәгариф һәм фән министрлыгы (2004 — самбо), Идел буе федераль округы (2003 һәм 2007–2008 — дзюдо), ТР «Динамо» физкультура-спорт җәмгыяте (2009 — дзюдо), РФ (2004–2006 — самбо, 2007–2008 — дзюдо), чемпионатлары җиңүчесе. 2006 елда самбо буенча дөнья чемпионы. ТР (2007–2008 һәм 2010, көмеш — самбо), РФ Мәгариф һәм фән министрлыгы (2005, көмеш — самбо), Идел буе федераль округы (2004, бронза — самбо, 2004 һәм 2009 — дзюдо) чемпионатларында, Россия беренчелекләрендә (2007, көмеш; 2008, бронза — самбо), В.И.Карпычев истәлегенә дзюдо буенча турнирда (2004 — көмеш) медальләр яулый. 2005 тән Әлмәт шәһәрендә яши. 2009–2010 да «Юность» балалар-яшүсмерләр мәктәбендә тренер-укытучы. 2011 дән — Казанда, Татарстан нефть-газ эшкәртү идарәсендә инженер. Эшләгән урынында даими рәвештә җиңел атлетика, чаңгы, йөгерү ярышларында I урынны алып килә. ГТО алтын билгесе иясе. 2013 елда студентларның Казанда узган XXVII Бөтендөнья җәйге Универсиада Уты эстафетасында катнаша.



**Низамов Рөстәм Мингазиз улы** 1981 елның 17 апрелендә Лаеш районы Хәерби авылында, Сәлимә һәм Мингазиз Низамовлар гаиләсендә туа. 1998 елда Хәерби урта мәктәбен көмеш медальгә тәмамлагач, Казан дәүләт аграр университетында агроном белгечлеге ала һәм 2003 елда шул ук уку йортында аспирантурада калдырылып, укытучы булып эшли башлый. 2007 елда авыл хуҗалыгы фәннәре кандидаты, 2018 дә авыл хуҗалыгы фәннәре докторы дәрәҗәсенә диссертация яклый. Фәнни эшчәнлеге май культуралары үстерү технологияләрен Татарстан шартларына җайлаштыруга багышланган. Шул тема буенча аның җитәчелегендә ике фән кандидаты әзерләнгән, 6 аспирант диссертация язу өстендә эшли. 150 гә якын фәнни хезмәт, шул исәптән 6 китап авторы. Фән һәм укыту эшендә ирешкән уңышлары өчен

РФ Авыл хуҗалыгы министрлыгының Рәхмәт хаты, ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы, Казан мэриясе Мактау грамоталары белән бүләкләнә. «Татарстан Республикасы өчен иң яхшы 50 инновацион идея» конкурсында ике тапкыр җиңүче. РФнең мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең аккредитацияләнгән эксперты. Бүгенге көндә Казан дәүләт аграр университетының фәнни тикшеренүләр һәм инновацияләр бүлеген җитәкли. Җир төзелеше һәм кадастрлар кафедрасы доценты.



Гөлсем һәм Шәүкәт Сөнгатовлар.

**Сөнгатова (Зарипова) Гөлсем Хәбибулла кызы** 1952 елның сентябрендә Хәерби авылында туа. Мәктәпне тәмамлаганнан соң, 1968 елда Казанга китеп, 51 нче училищега укырга керә, урта һәм һөнәри белем ала. Озак еллар «Радиоприбор» заводында эшли.

«Әни, әби тәрбиясендә үсеп, рәхәтләнеп яшәп, Бай күлендә су коенып, урманыбызда җиләк-җимеш җыеп, бик күңелле бала чаклар узган. Урам тулы бала-чага, һәр өйдә алты-җиде бала, кайберләрендә күбрәк тә. Мин үзем Әнвәр абый белән Халисә апаларга керә идем. Аларда ун бала, менә кайда ул кызык, бәйрәм, шау-шулы уеннар! 1960 елда 1 класска укырга кердем. Беренче укытучым Мәрзия Вафина искиткеч көчле шәхес, ул дөньяны матур итеп күрергә, кешеләргә ышанырга, тормышта югалып калмаска өйрәтте», – дип искә ала Гөлсем Сөнгатова бала чаклары турында. Мәктәптә бик яхшы укый ул. Беренче укытучысы Мәрзия Вафинаның аны мактап әнисенә язган мактау хатлары әле дә саклана.


Хөрмәтле Әнисә!
Сезнең кызыгыз Гөлсем бүген
сораган дәресләрдән „5"кә генә
җавап бирде. Рус теленнән
яттан әйтүе соклангыч.
Гөлсем сезнең өчен дә, укытучы
өчен дә куаныч һәм шатлык.
Сез аңа дәресләрен хәзерләт-
кылуда зур булышлык күр-
сәтәсез. Моның өчен сезгә зур
рәхмәт.
Сезгә сәламәтлек һәм ты-
нычлык тели, кызыгызның ук-
тучысы Мәрзия Вафина.
25/IX-1963 ел.

Гөлсем Хәбибулла кызы Шәүкәт Хәнәфи улы белән ике ир бала тәрбияләп үстерәләр, дүрт оныклары бар.

**Хәмәтгалиев Камил Минбай улы** 1974 елның 16 июлендә Лаеш районы Хәерби авылында туа. Урта мәктәпне тәмамлагач, 1991–1996 елларда, Казан дәүләт педагогия университетының татар теле, әдәбияты һәм тарих факуль-


Казан шәһәр
мәгариф идарәсе

яшь буынны тәрбияләүгә һәм белем
бирүгә керткән зур өлеше өчен
Вахитов районының 39-нчы номерлы
инглиз телен тирәнтен өйрәнү мәктәбе
татар теле укытучысы
Хаматгалиев Камил Минбай улын

Мактау грамотасы

белән бүләкләнә.

Шәһәр мәгариф идарәсе
башлыгы

тетында укый. 1996 елдан Казан шәһәре Вахитов районының 39 нчы номерлы инглиз телен тирәнтен өйрәнү мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укыта. 2003 елда Вахитов районы буенча «Ел укытучысы» бәйгесе җиңүчесе. Казан шәһәре мәгариф идарәсенең, Вахитов районы мәгариф бүлегенең Мактау грамоталары, дипломнары белән бүләкләнә.



Камил Хәмәтгалиев – ике бала әтисе.

**Һадиева (Мөхәммәтҗанова) Нурия Мөхәммәт кызы** 1964 елның 11 маенда Лаеш районы Хәерби авылында туа. Әтисе Мөхәммәт Мөхәммәтзариф улы – авыл хуҗалыгы тармагы эшчесе һәм сәүдә тармагы хезмәткәре, әнисе Гөлсем Хәмәтхан кызы шулай ук авыл хуҗалыгы өлкәсендә һәм фельдшерлык пунктында эшли. 1959 һәм 1961 елларда туган Рәфит һәм Рәшит исемле абыйлары бар.

Нурия Мөхәммәт кызы 1979 елда Хәерби сигезьеллык мәктәбен тәмамлап, Казан шәһәрендәге Совет сәүдәсе техникумына укырга керә. Аны 1983 елда тәмамлап, җәмәгать туклануы техник-технологы булып чыга. 2001–2006 елларда Татарстан эшмәкәрлеккә булышлык итү институтында укып, бухгалтер-икътисадчы белгечлеге ала. 1983 елдан 1987 елга кадәр Казан шәһәре Идел буе районы җәмәгать туклануы оешмасында бухгалтер һәм бәяләр буенча икътисадчы, 1987–1989 елларда Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгында бухгалтер һәм хезмәт хакы исәпләү төркеме җитәкчесе булып эшли. 1990 елдан Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең исәп-хисап бүлегендә баш бухгалтер урынбасары, хәзерге көндә баш бухгалтер вазифасын башкара. 2005 елда «Казанның 1000 еллыгы» медале белән бүләкләнә. 2010 елда аңа Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының Мактау грамотасы бирелә.



Ире Һадиев Ирек Габделхәй улы – Татарстан Республикасы Милли китапханәсе директоры урынбасары, уллары Нияз – Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты студенты, Аяз – Россия дәүләт хокук университетының Казан филиалы студенты.

**Шаһитов Мәгъсүм Нәҗип улы** 1958 елның 20 гыйнварында Лаеш районы Хәерби авылында туа. 1972 елда сигезьеллык мәктәпне тәмамлаганнан



соң, шоферлыкка укый. Бораулаучы һәм шофер булып эшли. Чистай авыл хуҗалыгы техникумын тәмамлый, армиядә хезмәт итеп кайта. 1975 елдан Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының патруль-пост хезмәтендә. Бер үк вакытта СССР Эчке эшләр министрлыгы академиясенең Казан филиалында читтән торып укый. 1985 елдан патруль-пост хезмәте взводы командиры, аннары административ-хокук эшчәнлеге бүлеге өлкән инспекторы, ТР Эчке эшләр министрлыгының ЮХИДИ башлыгы урынбасары, ЮХИДИ районара теркәү-имтихан бүлеге идарәсе башлыгы булып эшли. Эчке эшләр министрылыгында 2004 елга кадәр, ягъни 28 ел хезмәт итә, полковник дәрәҗәсенә күтәрелә. 2004–2012 елларда «Спартак» аяк киемнәре фабрикасында транспорт бүлеге башлыгы. Хезмәт ветераны. Эчке эшләр министрлыгының III, II, I дәрәҗә «Хезмәттәге фидакарьлек өчен» медальләре; «Россия Эчке эшләр министрлыгына 200 ел» (2002), «ГИБДДга 75 ел» (2011), «ГИБДД (ГАИ)га 80 ел» юбилей медальләре белән бүләкләнә. Хатыны Гөлнара белән 3 ул тәрбияләп үстерәләр.



**Галиев Мингали Тимергали улы** 1953 елның 21 сентябрендә Лаеш районы Хәерби авылында туа. Хезмәт эшчәнлеген «Алга» колхозында механизатор булып башлап җибәрә. Совет армиясе сафларында хезмәт итеп кайтканнан соң, Чаллы шәһәренә «КАМАЗ» төзелешенә китә. Хезмәт сөючән, тырыш Мингали Галиев «Автоперегон Плюс» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры дәрәҗәсенә җитә. Бүгенге көндә гаиләсе белән Чаллы шәһәрендә яши, ике кыз – Ландыш белән Гөлназны тәрбияләп үстерәләр, дүрт оныклары бар.

# XIX БҮЛЕК

# ХӘЕРБИ ОНЫКЛАРЫ

Балдан татлы балам баласы, дип бик дөрес әйткәннәр. Оныклар бигрәк кадерле шул! Авылдагы әби-бабайда – туган нигез җылысы, нәсел җебенең башы шуңа барып тоташа. Оныклар, балалар җыелган, гөр килеп торган йортлар соклану тудыра. Хәерби авылына әби-бабайлары янына кайтып каникулларын уздырган, Миләүшә тауларында мәтрүшкә, җиләк җыйган, кышын чанада, чаңгыда шуган, Мишә буена барып су коенган балалар арасында хәзерге вакытта танылган кешеләр булып җитешкәннәре шактый күп.



**Алишев Булат Сәләм улы** 1954 елның 14 маенда Лаеш районы Татар Сараланы авылында туа. Әнисе – Хәерби авылында туган Даһия Гариф кызы Вафина (Алишева).

1976 елда Казан университетының тарих факультетын тәмамлый, психология фәннәре докторы (2002), профессор (2007). Казан авиация институтында, Профессиональ белем бирү педагогика фәнни тикшеренү институтында эшли. Хәзерге вакытта Казан (Идел буе) федераль университеты Психология һәм мәгариф институтының Гомуми психология кафедрасы профессоры.

«Вопросы психологии», «Психология», «Russian Education & Society», «Journal of Russian & East European Psychology» һәм башка журналларда басылган 200 дән артык фәнни мәкалә, 4 монография, 9 уку-укыту һәм фәнни-методик ярдәмлек, 7 фәнни хезмәтләр җыентыгы авторы. Аның җитәкчелегендә 11 кеше кандидатлык диссертациясе яклый.

Россия Федерациясенең Мактаулы һөнәри белем бирү хезмәткәре (2001). РФ Хөкүмәтенең Мәгариф өлкәсендәге премиясе лауреаты (2007).

**Вафин Илшат Риф улы** 1972 елның 26 июнендә Казан шәһәрендә туа. Әти-әнисе – Хәерби авылында туган Вафин Риф Гарифулла улы (11.06.1949) һәм Вафина Таһира Әнвәр кызы (03.03.1949). Дәү әти һәм дәү әниләренә – Закиров Әнвәр Закир улы (14.01.1926), Бөек Ватан сугышы ветераны һәм Закирова Зөлфа Харис кызы (14.03.1927) – кайтып, Хәербидә барлык каникулларын үткәргән. Хатыны да Хәерби авылы кызы – Вафина (кыз фамилиясе



Нигъмәтова) Фәридә Булат кызы (22.07.1974). Бер уллары бар.

Илшат 1989 елда Казанның 35 нче мәктәбен (хәзер 1 нче татар гимназиясе) тәмамлый. 1990–1992 елларда армия сафларында хезмәт итә. Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан юридик институтын тәмамлый (2001). 1992–2001 елларда – Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан буенча линия транспорты идарәсенең «Елга порты» бүлекчәсендә сугышчан хезмәт әзерлеге инспекторы, 2001–2016 елларда – Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Баш тикшерү идарәсендә – юстиция майоры, өлкән тикшерүче, кадрлар белән эшләү һәм тәрбия эше буенча бүлек башлыгы урынбасары. III, II, I дәрәҗә «Хезмәттәге фидакарьлек өчен» медальләре, «Милиция отличнигы», «Иң яхшы тикшерүче», «Эчке эшләр министрлыгында хезмәт казанышлары өчен», «Хезмәткә тугрылык өчен», «Эчке эшләр министрлыгының ТР буенча почётлы хезмәткәре» һ.б. билгеләре белән бүләкләнә. Хезмәт ветераны.



**Вәлиуллин Фидаил Фәрит улы** 1986 елның 14 маенда Казан шәһәрендә туа. Әти-әниләре Фәрит Якуп улы һәм Венера Зиннәт кызы Хәерби авылында туып үскән кешеләр. Фидаил Вәлиуллин Казан университетының юридик факультетын тәмамлый (2008). Шунда ук Конституцион һәм административ хокук кафедрасында укыта. Юридик фәннәр кандидаты. Фәнни хезмәтләре Конституцион суд процессы, хокук саклау темаларына карый. Укыта торган дисциплиналары: административ хокук, заманча шартларда паспорт-виза системасы, дәүләт идарәсе теориясе һәм практикасы. Хатыны София белән кызлары Ассельне тәрбияләп үстерәләр.

**Галәвов Адель Әсфан улы** 1987 елның 23 сентябрендә Казан шәһәрендә туа. Әтисе —Хәерби авылында туган Галәвов Әсфан Галләм улы. 2008 елда Казан дәүләт финанс-икътисад институтын тәмамлап икътисадчы белгечлеге ала. 2009 елда Бөекбритания Эксетер университетының (The University of Exeter) Халыкара менеджмент бүлеген тәмамлап, магистр дәрәҗәсе ала. Икътисад фәннәре кандидаты (2016 ел).



2009–2011 елларда «Ак Барс» банкының Казан филиалы аналитика бүлеге өлкән икътисадчысы.

2011 елда Татарстан Республикасы Президентының Эшләр идарәсендә: төрле чаралар оештыру һәм биналарны карап тоту бүлеге баш белгече, 2011–2014 елларда — Татарстан Президенты Эшләр идарәсе баш киңәшчесе, 2014 елда «Казметрострой» ААҖ генераль директоры урынбасары, 2015 елдан – Татарстан Республикасы Президентының Эшләр идарәсе башлыгы урынбасары.

Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хаты белән бүләкләнә (2013 ел).



**Галәвов Рөстәм Әсфан улы** 1984 елның 15 августында Казан шәһәрендә туа. Әтисе — Хәерби авылында туган Галәвов Әсфан Галләм улы.

2006 елда Казан дәүләт финанс-икътисад институтын тәмамлап, икътисадчы белгечлеге ала. 2004–2006 елларда «Эдванс» ҖЧҖ генераль директоры, 2006–2007 елларда Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының икътисад бүлегендә әйдәп баручы белгеч. 2007–2008 елларда Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының Эшләр башкару идарәсе башлыгы. 2008–2014 елларда Казан җир өсте һәм җир асты электр транспорты техникумы директоры. 2014–2018 елларда — А.П.Обыденнов исемендәге Казан автотранспорт техникумы директоры. 2018 елдан Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәт инспекциясе җитәкчесе.



**Гыймадиев Зөфәр Гариф улы**, Казан шәһәрендә туа. Әтисе — Хәерби авылында туган Гыймадиев Гариф Минвәли улы.

Казан медицина университетын тәмамлый (1998). Казан (Идел буе) федераль университеты клиникасы «Трансплантология һәм хирургия ысуллары» үзәгенең урология бүлеге мөдире, югары категорияле табиб, уролог. Татарстан Ресбуликасы һәм Россия урологлар җәмгыяте әгъзасы. Күпсанлы фәнни хезмәтләр авторы. Казан федераль университетының Фун-

даменталь медицина һәм биология институтында хирургия кафедрасы укытучысы. Үз эшенең остасы, кешеләргә карата игътибарлы, тирән белемле табиб.



**Нигъмәтов Ленар Ринат улы** 1978 елның 8 октябрендә Казан шәһәрендә туа. Әтисе – Хәерби авылында туган Нигъмәтов Ринат Хабул улы. Ленар Ринат улы Казан дәүләт университетының исәпләү техникасы һәм кибернетика факультетын тәмамлый (2000). ТР Министрлар Кабинеты каршындагы ТР Икътисади һәм социаль тикшеренүләр үзәгенең тарифлар сәясәте бүлеге әйдәп баручы белгече (2000–2006); ТРның Республика энергетика комиссиясе рәисенең беренче урынбасары (2006–2008), төзелеш һәм консалтинг бизнесы өлкәсендәге оешмаларда җитәкче (2008–2010). Бүгенге көндә медицина эшләнмәләре җитештерү оешмасы җитәкчесе. «Казанның 1000 еллыгы» медале, Мактау грамоталары белән бүләкләнә. Хатыны Регина Викторовна белән ике улларын – Тимур белән Русланны тәрбияләп үстерәләр.

**Нигъмәтҗанов Рамил Галимҗан улы** 1984 елның 11 ноябрендә Сургут шәһәрендә туа. Әнисе – Хәерби авылында туган Флёра Минвәли кызы Галәвова. Казанда «ТИСБИ» идарә университетын тәмамлый (2007). Федераль салым хезмәтенең төбәкара инспекциясендә өлкән дәүләт инспекторы (2007–2010), төп дәүләт инспекторы (2010–2011), инспекция башлыгы урынбасары (2011–2014) булып эшли. 2019 елдан эре салым түләүчеләр буенча Федераль салым хезмәтенең төбәкара инспекциясе башлыгы урынбасары. Мактау грамоталары, Рәхмәт хатлары белән бүләкләнә.



Рамил Нигъмәтҗановның хатыны – Лилия Равил кызы, Хәерби авылында туган. Алар ике ул һәм бер кыз тәрбияләп үстерәләр.

# XX БҮЛЕК

## ХӘЕРБИ КИЯҮЛӘРЕ

Гомер-гомергә халык телендә кияүләр турында мәкальләр, әйтемнәр, төртмәле яки шаян гыйбарәләр йөргән, җырлар җырланган. Менә аларның кайберләре:

«Тау буенда җиләк җыйдым,
Бөрлегәннәре белән.
Кода-кодача булыштык
Бер дигәннәре белән».

«Көзге катык, көмеш кашык киявем белән кызыма; язгы катык, ярык кашык киленем белән улыма».

«Юньсез кияү йорт тотмас».

«Кияү үзебезнеке, гаеп итмәс».

«Көйсез кияү булды бер».

«Утыр, кияү, урынча, эскәмия буенча».

Ә Хәербидә кияүләрнең урыны – түрдә, чөнки кияүләре тел-теш тидерерлек түгел. Алар арасында «Безнең авыл кияве ул!» дип горурланырлыклары бихисап! Кайберләре белән танышыйк.

**Алишев Сәләм Хатыйп улы** 1929 елда ТАССРның Чистай кантоны Шәрбән авылында туган, 2015 елның 23 июнендә вафат. Тарихчы, тарих фәннәре докторы, ТРның атказанган фән эшлеклесе. Казан педагогия институтын тәмамлаганнан соң, 1951–1960 елларда Лаеш районы Татар Сараланы авылы мәктәбендә укытучы, уку-укыту бүлеге мөдире, директор була. 1960–1962 елларда Югары Ослан районында мәгариф бүлеге мөдире. 1966 елдан, аспирантура тәмамлаганнан соң, СССР ФА КГҮнең Тел, әдәбият һәм тарих институтында: тарих бүлеге мөдире, әйдәп баручы фәнни хезмәткәр. Урта Идел буе, Казан ханлыгы һәм аның Рус дәүләте белән үзара мөнәсәбәтләре тарихы буенча белгеч.



Хәерби авылында туган Даһия Гариф кызына өйләнгән. Балалары: Булат (1954 елда туган), Айрат (1956 елда туган).

**Егоров Иван Михайлович** 1961 елның 21 гыйнварында Мамадыш районының Җөри авылында туа. 1979 елдан армиягә алына. 1980 елның июленнән 1981 елның октябренә кадәр Әфганстан Республикасындагы сугышчан хәрәкәтләрдә катнаша, взвод командиры урынбасары була. Сугышчан батырлыгы өчен 1981 елда Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнә. Казан дәүләт педагогика институтының физик тәрбия факультетын (1987), Мәскәү коммерция академиясен тәмамлый (1994). Магистр дәрәҗәсе ала.



1987–1996 елларда сәүдә һәм җәмәгать туклануы өлкәсендә җитәкче вазифаларда. Татарстан Республикасының атказанган азык-төлек сәнәгате хезмәткәре. 1996–2002 елларда «Татспиртпром» җитештерү берләшмәсе филиалы «Усад спирт заводы» дәүләт унитар предприятиесе директоры, 2002 елдан «Ак Барс» Холдинг компаниясе» ААҖ генераль директоры. 2009 елдан дүртенче, 2014 елдан бишенче, 2019 елдан алтынчы чакырылыш ТР Дәүләт Советы депутаты. «Бердәм Россия» партиясе һәм ТР Дәүләт Советында «Бердәм Россия» фракциясе әгъзасы. ТР Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты әгъзасы. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Әфганстан Республикасында сугышчан хәрәкәтләр һәм Төньяк Кавказ регионы территориясендә террорчылыкка каршы операцияләр ветераннары мәсьәләләре буенча Координацион совет рәисе. ТР автомотоспорт һәм ТР самбо федерацияләре президенты. ТР Дәүләт премиясе лауреаты (2013). Кызыл Йолдыз ордены (1981), «Казанышлар өчен» ордены (2006), «II дәрәҗә Ватан алдындагы казанышлары өчен» ордены медале, «Фидакарь хезмәт өчен» медале һәм башка медальләр белән бүләкләнә.

И.Егоровның тормыш иптәше — Хәерби кызы Флера Габделхак кызы. Алар ике ир һәм бер кыз бала тәрбияләп үстерәләр.

**Сөнгатов Шәүкәт Хәнәфи улы** 1952 елның 5 июнендә Казан шәһәрендә туа. 1969–1970 елларда «Радиоприбор» заводында беренче разрядлы электромонтёр булып эшли. 1970–1973 елларда Төньяк флотта, су асты көймәсендә хезмәт итә. Армия хезмәтеннән кайткач, «Радиоприбор»да һәм Росбанкның Татарстандагы бүлегендә электромонтёр-ремонтчы һәм аккумуляторчы булып эшли. 1979 елда Казан финанс-икътисад институтын тәмамлап, фи-



нанслар һәм кредит белгечлеге ала. 1979–1989 елларда ТАССР Финанс министрлыгының авыл хуҗалыгын финанслау бүлегендә ревизор-инспектор, өлкән икътисадчы, өлкән ревизор-инспектор була. 1989–1995 елларда ТАССР Финанс министрлыгының агросәнәгать комплексы бүлеге җитәкчесе, 1995–2004 елларда Татарстан Республикасы финанс министры урынбасары, 2004–2006 елларда Татарстан Республикасы Хисап палатасы рәисе урынбасары булып эшли. 2006–2010 елларда Шәүкәт Хәнәфи улы «Алтын башак» («Золотой колос») икмәк комбинатында: генераль директор урынбасары, генераль директор. 2010 елдан Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары. Россия Федерациясенең атказанган икътисадчысы (2008). «Россия Флотына 300 ел» (1996), «Сугышчан хезмәттәшлекне ныгыткан өчен» (2000), «РФ Финанс министрлыгына 200 ел» (2002), «Казанның 1000 еллыгы» (2005) һ.б. медальләр белән бүләкләнә.

2007 елдан Шәүкәт Сөнгатов — «ТР Диңгез җыены» иҗтимагый оешмасы рәисе. Шул ук вакытта ул Россия Диңгез җыеннары Ассоциациясе һәм Хәрби-Диңгез Флоты иҗтимагый оешмалары һәм ветераннарының Халыкара ассоциациясе әгъзасы. Шәүкәт Хәнәфи улы булышлыгы белән Хәерби авылы мәктәбендә, шулай ук Әгерҗе, Саба районнары урта мәктәпләрендә, Казанның 78 нче мәктәбендә Хәрби-Диңгез Флоты музейлары ачыла, Россиянең һәм Татарстанның данлыклы диңгезчеләренә мемориаль такталар һәм обелисклар куела. Казанның Җиңү паркындагы «Казан» атом су асты көймәсе рубкасы да аның ярдәме белән кайтарыла.



Хәербидә мәктәп, балалар бакчасы төзелешләрен планга кертү, алар өчен подрядчылар табу, матди ягын хәл итү, шулай ук урамнарга асфальт салдыру Ш.Х.Сөнгатовның турыдан-туры катнашы белән тормышка ашырыла. Шәүкәт Хәнәфи улы игелекле кияү генә түгел, ә авылның үз улы кебек!

Ш.Сөнгатовның хатыны — Хәербидә туган Гөлсем Хәбибулла кызы. Алар ике ир бала тәрбияләп үстерәләр.



**Тимербаев Айдар Рифкать улы** 1971 елның 22 октябрендә Саба районы Татар Икшермәсе авылында туа. Композитор, автор башкаручы һәм продюсер. Урта мәктәпне, 1994 елда Казан мәдәният һәм сәнгать институтын тәмамлый. Айдар Тимербаев җыр жанрында бик актив эшли. Аның көенә язылган җырларны Салават, Габделфәт Сафин, Резеда Шәрәфиева, Рифат Зарипов, Илдар Әхмәтов, Зөфәр Билалов, Ландыш Нигъмәтҗанова, Иркә, Раяз Фасыйхов, Вадим Захаров, Алсу һәм Азат Фазлыевлар, Алинә Сафиуллина һәм башка бик күпләр башкара. Ул Зинира һәм Ризат Рамазановларның продюсеры да. Күп кенә җырларын үзе дә башкара, кайбер җырларның сүзләрен дә үзе иҗат итә.

Айдар Тимербаев музыка язган җырларның кайберләре: «Туганымның хәлен белдем әле», «Матур итеп яшик», «Шәм яндыру кирәкме», «Кычыткан сабаклары», «Балачак», «Кышкы яңгыр», «Әти җитми бүген», «Уфалла арбасы», «Соңардым», «Кагылма кеше ярына», «Яратмый кавышмагыз», «Тапшырылмаган хат», «Кем син», «Тату яшик», «Калдыр мине», «Туган йорт», «Саба», «Син дә мине күрсәң иде», «Тозсыз аш», «Янымда булып кара», «Нигә белмәдем», «Туган нигез», «Вокзал», «Кайларда соң сез, дусларым» һ.б.

Айдар Тимербаев «Болгар радиосы» милли музыкаль премиясе лауреаты; Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең, Саба муниципаль районы башлыгының Рәхмәт хатлары белән бүләкләнә, дипломнар иясе. 2019 елда Татарстанның атказанган артисты исеме бирелә.

А.Тимербаевның хатыны — Хәерби авылында туган Гөлнара Габдулла кызы, Казан федераль университеты клиникасында эшли, медицина хезмәткәре. Алар ике ул: Азат һәм Булатны тәрбияләп үстерәләр.

**Һадиев Ирек Габделхәй улы** 1970 елда Татарстан АССРның Мамадыш районы Кече Кирмән авылында туа. 1985 елда Татарстанның Кукмара районы Мәмәшир сигезьеллык, 1987 елда Мәчкәрә урта мәктәпләрен тәмамлый. 1988–1989 елларда армия сафларында хезмәт итә. 1993 елда Казан дәүләт университетының татар филологиясе, тарих һәм көнчыгыш телләр факультетын тәмамлап, филолог, татар теле һәм әдәбияты, тарих укытучысы белгечлеге ала. Университетның соңгы курсында укыганда ук Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә эшли башлый. Гарәп язуын тиешле дәрәҗәдә өйрәнеп, иске басмалы татар һәм шә-



рекъ китапларын, әүвәлге татар вакытлы матбугаты басмаларын тасвирлау белән шөгыльләнә, китапханәнең Татарстан районнарында һәм Россия төбәкләрендә оештырган фәнни-археографик экспедицияләрендә катнаша. 1992–1997 елларда шушы бүлектә фәнни хезмәткәр, бүлек мөдире вазифаларын башкара. 1997 елда ТР Милли китапханәсе директорының фәнни эшләр буенча урынбасары. Китапханә белеме, библиография һәм китап белеме тармакларындагы фәнни-тикшеренү, милли библиография төзү, Татарстан Республикасындагы китапханәләргә фәнни-методик ярдәм күрсәтү, редакция һәм наширлек, татар милли мәдәнияте өлкәсендәге мәгърифәтчелек эшчәнлекләре, «Китапханә хәбәрләре» фәнни-гамәли журналын басмага әзерләү аның җитәкчелегендә яки турыдан-туры катнашында алып барыла.

Студент вакытыннан ук тарих фәненең күңеленә яткан аерым бер юнәлешен сайлап, инде өч дистә елга якын борынгы татар ташъязма истәлекләрен өйрәнә. Шушы теманы яктырткан биш китап авторы, милли тарихка һәм күренекле шәхесләргә багышланган дистәдән артык китапның төзүчесе, вакытлы матбугатта басылып чыккан фәнни мәкаләләре 50 дән артык. ТР Милли китапханәсенең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге хезмәткәре Раиф Мәрданов белән бергә язылган, татар китабының бай тарихына багышланган фәнни-популяр хезмәтләре Татарстан китап нәшриятында 2013 елда күләмле китап-альбом булып татар һәм рус телләрендә, ә 2019 елда нәшриятның 100 еллыгы уңаеннан рус телендә дөнья күрә.



2005 елда «Казанның 1000 еллыгы» медале белән бүләкләнә. 2010 елда аңа «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» исеме бирелә. 2015 елда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Рәхмәт хатына лаек була.

Хәерби авылында туган Нурия Мөхәммәт кызына өйләнгән, ике ир бала тәрбияләп үстерәләр.

# XXI БҮЛЕК

# ХӘЕРБИ АВЫЛЫ БЕЛӘН БӘЙЛЕ МӘШҺҮР ДИНАСТИЯЛӘР

## МАКСУДИЛАР

Максудилар – татар дөньясында тирән эз калдырган нәсел. Бертуган Әхмәтһади һәм Садри Максудиларның төрки-татар тарихында тоткан урыны, игелекле хезмәтләре турында түбәндәрәк төрле чыганакларга таянып тәфсилләбрәк язылыр. Бу нәселнең алдагы буыннары һәм аңа исем биргән Хәерби кешесе Максуд баба белән таныштыруны Габделхак Зәбировның «Максуд баба һәм Максудилар» китабыннан (Казан: Татар. кит. нәшр., 2000) алынган өзектән башларга булдык.

*«Максуд баба озын гомерле булып, 105 яшь яшәгән (1760–1865). Ул бервакыт улларына һәм оныкларына болай дип әйткән: «Бу дөньяда акылга зәгыйфь булмаган кешеләр ашап-эчеп, тыныч йоклап, хайван шикелле яшәргә тиеш түгел. Һәр кеше үзе исәнендә халык өчен файдалы эш эшләп, үлгәннән соң да аны мактап яд итәрлек (искә алырлык) югалмый торган эз калдырырга тиеш!»*

*Максуд бабабыз хәзерге Татарстанның Лаеш районындагы Хәерби исемле, Мишә елгасы янындагы бер авылда туган. Атасы шул авылда таза тормышлы Корбангали исемле кеше булган. Кайберәүләрнең сөйләвенчә, бу авылның исеме кайчандыр, әллә Болгар, әллә Казан ханлыгы заманында Хәер исемле бер би (князь) исеменә бәйле, имеш. Шуңа күрә Хәерби авылы булып киткән, имеш.*

*Корбангалинең әтисе Атнагул, аның әтисе Булат, ә аның әтисе Мәскәү исемле булган. Бу исем татарлар белән руслар арасында ниндидер бер вакыйгага бәйле рәвештә кушылган булса кирәк.*

*Корбангалинең Мансур, Мәхмүд, Максуд, Мәмдух һәм Мәхуб исемле биш улы булган.*

*Максуд шул биш угыл арасында үзенең зирәклеге, эш яратканлыгы һәм укырга ихласлыгы белән аерылып торган. Ул 12 яшьләрендә инде нинди китап очраса, шуны укый белгән, Һәфтияк белән Коръәнне дә тиз һәм дөрес итеп укыган. Язарга да өйрәнеп, нәшкый (матур) хат белән язарга да булдыра башлаган. Намазларны да иренмичә укый икән.*

*Корбангали агай бу улының сәләтлелеген һәм тырышлыгын күреп, эченнән берничә мәртәбә, бу малайны ничек тә булса укымышлы кеше итәргә кирәк, дип уйлап йөреп, көннәрдән бер көнне, җаен табып, Максудның үзеннән сораган: «Улым! Синең калада укып, гыйлемле кеше буласың киләме?». Малае бик тиз куанып китеп: «Бик килә, әти. Әнә Казанда мәдрәсәләр бар икән. Шунда авыллардан килгән малайлар укыйлар икән. Мин дә шулар белән укыр идем. Ул малайларга авылларыннан ипиләр һәм башка пешкән әйберләрне ашарга җибәреп торалар икән. Миңа да шулай җибәреп торсагыз, мин бик тырышып укыр идем, әти», – дигәч, әтисе сөенеп: «Алай булгач, бик яхшы, улым, калада укырсың. Хәзергә син бу хакта әниләреңә әйтми тор. Әниең, үз яныннан сине җибәрәсе килмичә, Казанга барып укудан күңелеңне сүрелдереп куймагае. Мин сиңа шуны да әйтим, улым. Син, гәүдәңә карганда, таза һәм көчле күренәсең. Ләкин анда баргач, яңа кеше дип, малайлар дөмбәсләп кыйнамаслар микән?» – дигән. Моңа каршы улы: «Юк, әти, миңа малайлар тимәс. Авылда да бер малай тигәне юк. Һәммәсе минем белән дуслар. Шәһәрдә дә мин аларга тидермәм», – дип җаваплаган.*




Г.Зәбировның «Максуд баба һәм Максудилар» китабы тышлыгы.

*Корбангали агай 1772 елда көз җитеп, кар төшкәч, чанага печән төяп, бастырыклап, ат җигеп куйгач, Максудка: «Әйдә, улым, минем белән калага барасыңмы? Укырга барасым килә дигән идең. Барып, бер бәхетне сынап карыйк. Белешеп кайтырбыз, бәлкем, сине мәдрәсәгә алырлар», – дигәч, Максуд шыпырт кына җыенып, киенеп, Һәфтияген куенына кыстырып, әниләрен дә уятып тормыйча, чанага төялгән печән өстенә менеп утыра. Шулай тәвәккәлләп аталы-уллы Казанга сәфәр чыгып китәләр.*

*Мин Максудның болай яшьтән үк зирәк булуын аның нәселеннән килгәндер дип уйлыйм. Чөнки Корбангалиев, Атнагулов, Булатов фамилияле прогрессив, зыялы кешеләр күп очрый. Алар да шул бер нәселдән таралган кешеләр түгел микән?*

*Юлчылар Казанга кояш чыкканда барып җитәләр.*

*Әтисе улына: «Син, улым, куеныңдагы Һәфтиякне югалтмыйча гына Күл буе мәдрәсәсенә барып кил», – дип, үзе печән сатарга кала. (Ул вакытта Пе-*




Габделхак Зәбиров төзегән шәҗәрә. 1994 ел.

*чән базары хәзерге Киров урамындагы (2004 елдан Мәскәү урамы. – Ред.) бензин колонкасы урынында булган.)*

*Максуд кешеләрдән сорашып, мәдрәсәне табып килеп керә дә, хәлфәләрне күреп, «Әссәламегаләйкем» дип сәлам бирә. Җавап алгач: «Мине мәдрәсәгә укырга алырсыз микән дип килгән идем», – ди.*

*Хәлфәләрең берсе: «Ярый, җегет, Һәфтиягеңне укып кара әле!» – ди. Максуд, бер дә каушамыйча һәм төртелмичә, бер сүрәне кычкырып укып бирә. Теге хәлфә: «Хуш, син яза да беләсеңме?» – дигәч, язып та күрсәтә. «Ярый, җегет, алабыз сине. Син инде мәдрәсәдә торып укырсың. Укулар яңа гына башланды әле, син тизрәк килергә тырышырсың. Үзең белән әтиең дә килсен. Килгәндә үзең белән бер мендәр, киез, юрган, ике җәймә, ике-өч пар күлмәкыштан, калай чәйнек, бер пар чынаяк, кашык, чүмеч, тоз һәм шикәр савыты, аш пешерергә чуен чүлмәк, аш тәлинкәсе яки җамаяк, сандык та алып килерсең. Сандыкның өсте тигез булсын. Ул сиңа язарга-укырга һәм ашарга өстәл дә булыр. Аны бикләргә бер кечкенә йозак та китер. Бер атнага җитәрлек ашау-эчү әйберләре. Аңладыңмы, энем?» – ди хәлфә абыйсы. «Аңладым, аңладым, хәлфә абзый, сез әйткәннәрне язып та куйдым», – ди Максуд. «Без сине ибтидаигә (башлангычка) куймыйча, рөшди (урта) сыйныфларның беренчесенә утыртырбыз. Анда дүрт ел укыгач, гали (югары) сыйныфларга күчеп, тагын дүрт ел тырышып укый алсаң, мулла булып чыгарсың», – диләр аңа.*

*Максуд кирәкле кешеләрне күреп, имтихан биреп һәм мәдрәсә тормышында кирәк булачак әйберләрне язып алып, әтисе янына – Печән базарына әйләнеп килгәнче, ике сәгать вакыт үткән. Максуд үзен мәдрәсәгә укырга алуларын әтисенә сөйләп биргәч, Корбангали агай бик канәгать кала...»*

Садри һәм Һади Максудиларның туганнан туган сеңелләренең кызы, филология фәннәре кандидаты, озак еллар Казан университетында журналистларга белем биргән мөгаллимә, доцент, ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре, «Бәллүр каләм» конкурсы лауреаты **Розалина Нуруллинаның** «Ватаным Татарстан» газетасында (1994 ел, 22 декабрь) басылган «Максудилар нәселе кайдан килә?» мәкаләсе: «Хәербидән, – ди торган иде әни», – дигән сүзләр белән башлана.

«Татар энциклопедиясе»нең (4 том, 24–25 битләр) Әхмәтһади һәм Садри Максудиларга багышланган мәкаләләрендә алар «Татар морзалары **Сөендековлар** нәселеннән. Мулла гаиләсеннән» дип тәкъдим ителә. Ә төп Максудилар нәселе башында **Мәскәү, Булат, Атнагол, Корбангали бабайлар** торганы билгеле. Димәк, болар барысы да Хәерби кешеләре. **Максуд** – Корбангалинең биш улыннан берсе. Ул бик зирәк, укуга, белемгә омтылучан, эш сөючән бала

булган. 12 яшендә инде «Һәфтияк»не (Коръәннең җидедән бер өлешен) үзләштергән. Сәләтле малайны Казанның Күл буе мәдрәсәсенә укырга бирәләр. Мәдрәсәне тәмамлагач, Максуд Мәмдәл волостеның Күлбаш авылы мәчетенә имам итеп куела. 105 яшенә кадәр яшәп, шунда вафат була.

Менә шушы озын гомерле, зирәк акыллы, эшчән Максуд бабайдан бөтен бер муллалык династиясе башлана. Максуд бабайның Биектау районы Ташсу авылында муллалык кылган улы **Гайнетдин**, аның улы **Низаметдин**, Низаметдинның уллары — **Садри һәм Әхмәтһади Максудилар**.

**Әхмәтһади Низаметдин улы Максуди** 1868 елның 28 сентябрендә Казан губернасы Ташсу авылында (хәзерге Биектау районына керә) туа. Җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе. 1892 елда татар әлифбасына 6 хәреф кертә һәм «Имляда ишетелгәнчә язу тиешле» дигән кагыйдәсеннән файдаланып, үзенең «Мөгаллим әүвәл» әлифбасын бастырып чыгара. Әлеге дәреслек 1918 елга кадәр барлыгы 32 басма кичерә, татар балалары өчен генә түгел, казакъ, башкорт, кыргыз, үзбәк балаларының да уку китабы булуы белән уникаль күренешкә әйләнә.



Әхмәтһади Максуди 1897 елда Казан сәүдәгәре Сөләйман Мишкинның 1881 елда туган **Зәйнәп** исемле кызына өйләнә. Аларның биш балалары була: **Фатыйма-Галия**, **Һарун**, **Шәфика**, **Һашим** һәм **Бәһрамия**.

1897–1904 елларда Әхмәтһади Максуди Печән базары мәчете каршындагы мәдрәсәдә мөдәррис булып тора. 1906 елның 15 гыйнварыннан Казанда «Йолдыз» газетасын чыгара башлый. Ул «Йолдыз» өчен әзерләнгән чәнечкеле, усалрак язмаларын «Хәерби» псевдонимы белән бастыра. Язучы һәм галим Мөхәммәт Мәһдиевнең «XX йөз башы татар әдәбиятында псевдонимнар» мәкаләсенә мөрәҗәгать итик («Казан утлары», 1973 ел, №12). «... «Йолдыз»да «Хәерби» псевдонимы белән басылган мәкаләләр, фельетоннар бик күп. «Йолдыз» моны үзе ачмый. Бәлки «Хәерби»не башка газеталар телгә аладыр? «Кояш»ны актарабыз. «Йолдыз» мөхәррире Хәерби әфәндене кем генә белми торгандыр инде», – дип яза Ф.Әмирхан үзенең бер фельетонында. «Йолдыз»ның мөхәррире – Һади Максуди икәнлеге ул чордагы газета укучыларга мәгълүм».

Әхмәтһади Максуди гомере буе китаплар язу белән дә шөгыльләнә. Күпчелек хезмәтләре тел белеменә карый. Аеруча озын гомерле китабы «Мөгаллим әүвәл» («Беренче дәреслек») әлифбасы. Гомерен татар халкына хезмәт итүгә, аның мәгарифе һәм мәдәниятен үстерүгә багышлаган, алты тел бел-

гән галим, педагог, журналист, 1906 елда Казанда беренче татар китапханәсен ачучы һәм һәм 1925 елга кадәр аның мөдире, элекке шәһәр думасы әгъзасы, «Иттифак әл-мөслимин» (Мөселманнар берлеге) партиясен төзүчеләрнең берсе һәм аның ике съезды – корылтае делегаты; 1917 елда игълан ителгән Эчке Россия һәм Себер төрки-татарларының Милли-мәдәни мохтарияте тарафдары, аның югары башкарма идарәсе – Милли Идарәдә халык мәгарифе комиссиясе составына кертелгән, Эчке Россия һәм Себер төрки-татарларының Милләт Мәҗлесенә – төрки-татарлар милли парламентына депутат итеп сайланган күпкырлы шәхес — татар милләтенең иң могътәбәр затларыннан булган Ә.Максуди 1932 елда, 64 яшендә кулга алына һәм 1933 елда «Бөтенсоюз социал-фашистлар партиясе» оештыруда ялган гаеп тагылып, Вятка (Киров) шәһәренә сөргенгә җибәрелә. Галим анда да фәнни эшчәнлеген дәвам итә. Сәламәтлеге какшау сәбәпле, Ә.Максудины 1939 елның башында төрмәдән чыгаралар, тик ул инде иректә озак яши алмый. Физик яктан ватылган, рухи яктан кимсетелгән 73 яшьлек Әхмәтһади Максуди 1941 елның 28 июнендә вафат була. Кабере – Казандагы Яңа татар бистәсе зиратында, Г.Тукай кабере белән янәшә.

**Садри (Садретдин) Низаметдин улы Максуди** (эмиграциядә Садри Максуди Арсал) 1878 елның 23 июлендә Казан губернасының Казан өязе Ташсу авылында туа. 1957 елның 20 февралендә вафат. Истанбул шәһәрендә җирләнгән. Садри Максуди татарларның милли азатлык хәрәкәте җитәкчеләреннән берсе, Төркиянең дәүләт эшлеклесе, тюрколог, хокук белгече. Әхмәтһади Максудиның энесе, Адилә (Гадилә) Айданың әтисе. 1888 елдан «Касыймия» (Казан) мәдрәсәсендә укый. Аны тәмамлаганнан соң (1894), абыйсы белән «Зынҗырлы» мәдрәсәсенә (Кырым, Бакчасарай ш.) китә, шунда Исмәгыйль Гаспринский белән таныша (соңрак аны үзенең рухи атасы дип атый). 1896–1901 дә Казан татар укытучылар мәктәбендә укый; уку чорында «Мәгыйшәт» (1898) романын яза. 1901 елның җәендә, киләчәк юлын билгеләү алдыннан, Ясная Полянада Л.Н.Толстой белән очрашып, озаклап әңгәмә кора, Кырымда И.Гаспринский, Истанбулда төрек язучысы Ә.Мидхәт янында булып, алар йогынтысы белән Парижга китәргә карар итә. 1902–1906 елларда Сорбонна университетының (Париж) юридик факультетында укый. 1906 да ватанга кайтып, Россиянең сәяси тормышына актив катнашып китә. Либераль-





Казанда Садри Максудига куелган һәйкәл.

демократик юнәлешле «Иттифак әл-мөслимин» партиясе җитәкчеләреннән берсе; «Иттифак әл-мөслимин» һәм Россия конституцион демократлар партияләре ҮКлары әгъзасы. Кадетлар партиясе исемлеге буенча Казан губернасыннан 2 нче Дәүләт думасы депутаты (1907); секретарь урынбасары һәм кадетлар фракциясе әгъзасы; 3 нче Дәүләт думасы депутаты, мөселманнар фракциясе җитәкчесе (1907–1912). С.Максуди Думаны мөселманнар, Россия халыклары, шул исәптән татарларның сәяси, мәдәни һәм дини хокукларын яклау трибунасы итеп файдалана. Парламентара берлекнең Берлин конференциясендә катнаша (1908), Дәүләт думасы делегациясе составында Англиядә булып, король Эдуард VII һәм премьер-министр Аксвит тарафыннан кабул ителә. Англиядә алган тәэсирләрен «Англиягә сәяхәт» (1914) китабында тасвирлый. Дәүләт думасы депутаты буларак, 1910 елның сентябрендә Төркестанга сәяхәт кыла: Ашхабад, Сәмәрканд, Бохара, Коканд, Ташкент шәһәрләрендә Россия мөселманнарын үз мәнфәгатьләрен яклау максатыннан берләштерү идеясен пропагандалый. 4 нче Дәүләт думасына сайлауларда үз кандидатурасын куя, ләкин үтми, Казанга кайта. 1913 елда Мәскәү университетында юридик дисциплиналар буенча экстерн тәртибендә имтиханнар тапшыра. 1913–1917 елларда Казан мәхкәмә палатасында антлы вәкил ярдәмчесе, адвокат, Казан шәһәр идарәсендә юридик комиссия әгъзасы.

1917 елгы Февраль революциясеннән соң кабат актив сәяси эшчәнлеккә кайта. Бөтенроссия мөселманнарының икенче корылтае өчен мөселманнарның Милли-мәдәни мохтарияте конституциясе текстын әзерли. Икенче корылтайда (1917, июль–август, Казан) доклад ясый, шуның нигезендә Эчке Россия һәм Себер мөселманнарының Милли-мәдәни мохтариятен (автономиясен) төзү турында С.Максуди эшләгән Декларация кабул ителә. Милли парламент (Милли Мәҗлес) ачылышында (1917 елның ноябре, Казан) Милләт Мәҗлесе рәисе һәм милли хөкүмәт — Милли Идарә рәисе итеп сайлана. С.Максудиның Россиядәге сәяси эшчәнлегендә бу иң югары нокта була. Садри Максуди Октябрь революциясен кабул итми, кулга алыну куркынычы тугач, 1918 дә Финляндия аша Франциягә китә. 1919 да, Милләт Мәҗлесе вәкиле буларак, Париж Халыкара солых конференциясендә Идел буе төркиләренең хокукла-

рын яклау мәсьәләсен күтәрә. 1921 елның гыйнварында Учредительләр җыены әгъзалары киңәшмәсендә (Париж) катнашып, татар вәкилләре Декларациясен игълан итә. 1922–1923 елларда Хельсинкида һәм Берлинда яши, төрки халыклар тарихы буенча материаллар туплый. 1923 елның августында Франциягә әйләнеп кайта; Париж университеты профессоры. 1919 дан Азия фәнни җәмгыяте әгъзасы, Парижда чыга торган «Le Temps» («Вакыт») газетасында һәм «Journal Asiatique» («Азия журналы») журналында язмалар бастыра.

Садри Максуди Төркиянең мәгариф министры Х.Сөбхи чакыруы буенча 1925 елда Төркиягә күчә; Юридик мәктәп һәм Әнкара университетының юридик факультеты профессоры. 1931–1938 елларда — Төркиянең Бөек Милләт Мәҗлесе депутаты. 1943 елдан Истанбул университетының юридик факультеты профессоры, хокук тарихы белгече. Төркия вәкиле буларак, 1936–1937 елларда Милләтләр лигасы конгресслары эшендә, Төркия парламенты делегациясе составында 1950 елда Европа Советы киңәшмәләрендә катнаша. «Төрек учагы» җәмгыятенең актив әгъзасы, Төркия тарих җәмгыятен оештыручыларның берсе. Төркия вакытлы матбугатында хезмәттәшлек итә. Төркия чоры С.Максудиның фәнни эшчәнлегендә иң уңышлысы. Аның төп фәнни эшчәнлеге хокук теориясе һәм тарихы өлкәсенә карый.

1955 елда С.Максуди сәясәттән китә; шул ук елда «Миллият тойгысының социологик әсаслары» (Истанбул, 1999) монографиясен бастырып чыгара. Әлеге хезмәтне аның татарлар һәм башка төрки-мөселман халыклары милли хәрәкәтенә идея һәм оештыру ягыннан зур йогынты ясаган эшчәнлегенә нәтиҗә дип карарга мөмкин. Тормышының кискен борылышларына карамастан, сәясәтче һәм галим буларак, С.Максуди үз инануларына тугры кала.

Садри Максуди 1910 елда алтын приисклары хуҗасы М.Рәмиев кызы **Камиләгә** өйләнә. С.Максудиның кызы — **Гадилә (Адилә) Айда** 1912 елда Санкт-Петербург шәһәрендә туа. 1992 елда Әнкара шәһәрендә вафат була һәм җирләнә. Төркия дипломаты, тарихчы. Гаагада һәм Белградта Төркия илчелегендә эшли. Италиядә илче вазифасын башкара. БМОда Төркиянең вәкаләтле илчесе. 1976–1978 елларда Төркиянең Бөек Милли Мәҗлес сенаторы. Хезмәтләре төрки халыклар тарихына, Садри Максудига багышлана.

Максуд баба нәселе данын лаеклы дәвам итүчеләрнең берсе – **Розалина Нуруллина** турында әйтеп уздык. Ул һәм аның бертуган абыйсы, озак еллар «Социалистик Татарстан» газетасын җитәкләгән танылган журналист **Рәис Мәрдан улы Сабиров** – Максуд бабаның дүртенче буындагы, Рәис Сабировның улы язучы **Рөстәм Сабиров** һәм Казан медицина институты доценты, Әхмәтһади Максуди оныгы **Диләрә Ходжаева** – бишенче буындагы оныклары.

# ГАБӘШИЛӘР

Хәерби авылы имам-хатибы Әбүбәкер Гомәровның (аның турында «Мәчет, имамнар» бүлегеннән укырга була) кызы **Шәмсеруй** Хәсәнгата исемле кешегә кияүгә чыга.

**Хәсәнгата Габәши**, 1863 елда Казан губернасының Казан өязе Кече Солабаш авылында туган, 1936 елда шунда ук вафат. Дин һәм җәмәгать эшлеклесе, тарихчы, педагог. Башлангыч белемне бабасыннан һәм атасыннан ала. 1874–1886 елларда Казандагы Әҗем мәчете каршындагы «Гаффария» мәдрәсәсендә укый һәм соңрак шунда мөгаллимлек итә. 1889 елда Казан эшмәкәрләре бертуган Юнысовларның мөселман балалары ятимханәсендә укыта һәм анда, шәһәрдә беренчеләрдән булып, җәдитчә укыту ысулларын кертә. 1890 елда Кече Солабаш авылы мәчете имам-хатибы. 1894 елдан – ахун. 1895–1899 елларда Оренбург Мөселманнар Диния нәзарәтендә казый, бер үк вакытта «Галия» һәм «Госмания» мәдрәсәләрендә укыта, төрле химаячелек җәмгыятьләренең әгъзасы булып тора. 1899 елда, сәламәтлеге какшау сәбәпле, Кече Солабашка кайта һәм сәүдәгәр Г.Хөсәеновның матди ярдәме белән җәдитчә белем бирә торган мәктәп ача, анда традицион дәресләр белән беррәттән тарих, география, Шәрекъ халыклары мәдәнияте укытыла. 1905–1915 елларда яңадан Оренбург Мөселманнар Диния нәзарәтендә казый. 1915 елда Кече Солабаш авылы мәдрәсәсенә кайта. 1 нче һәм 2 нче Бөтенроссия мөселманнары корылтайлары эшендә катнаша (президиумга сайлана). 1917 елдан Казан өязенең идарәсе Кече Солабаш авылында урнашкан 2 нче мөхтәсибәтендә мөхтәсиб вазифаларын башкара, бер үк вакытта фәнни һәм педагогик эшчәнлек белән шөгыльләнә. Октябрь революциясеннән соң, Арча кантоны педагогика курсларында укыта. ТАССР Үзәк музееның татар-мөселман коллекциясен туплауда зур роль уйный. Эчке Россия һәм Себер мөселманнарының Үзәк Диния нәзарәтендә Голәмалар шурасы әгъзасы (1923).



1932 елның гыйнварында кулга алына, хөкем ителеп, Архангельск өлкәсенә төзәтү эшләренә сөрелә. 1936 ел башында, сәламәтлеге какшау сәбәпле, иреккә чыгарыла. Фәлсәфә, педагогика, тарих мәсьәләләренә кагылышлы хезмәтләр авторы.

Шәмсеруй белән Хәсәнгата Габәши гаиләсендә Солтан исемле ир-бала туа.

**Солтан Габәши** – татар халкының беренче профессиональ композиторы. Тулы исеме – Габәши Солтанәхмәт Хәсәнгата улы, 1891 елның 1 маенда Казан губернасы, Казан өязе Кече Солабаш авылында туа – 1942 елның 8 гыйнварында Башкортстанның Борай районы Чалкак авылында вафат.

Композитор, музыка белгече, педагог, музыка-җәмәгать эшлеклесе Солтан Габәши Кече Солабаш мәдрәсәсендә, Уфада «Госмания» һәм «Галия», Казанда «Мөхәммәдия» мәдрәсәләрендә укый (1899–1911); 1911 елда Уфада Оренбург Диния нәзарәтендә имам-хатиб һәм мөдәррис булып эшләү өчен имтихан тапшыра. 1912–1915 елларда Уфа реаль училищесында, 1915–1917 елларда Казан университетының юридик факультетында укый. 1918–1922 елларда Казан уку йортларында, шул исәптән Шәрекъ консерваториясендә (1920–1922) эшли. 1922–1932 елларда Шәрекъ музыка техникумында музыка теориясе һәм хор фәннәрен укыта, мөдир урынбасары, бер үк вакытта Казан уку йортлары һәм мәдәни-агарту оешмалары каршында хорлар оештыра. 1932 елда Казаннан Уфага күчеп китә. 1932–1936 елларда Башкорт Милли мәдәният фәнни-тикшеренү институтында сәнгать белеме бүлеге фәнни хезмәткәре, бер үк вакытта Башкорт сәнгать техникумында музыка теориясен укыта һәм хор җитәкчесе булып эшли. 1936–1941 елларда БАССР халык комиссарлары советының Сәнгать эшләре идарәсе каршындагы музыкаль фольклор кабинеты фәнни хезмәткәре һәм мөдире. 1941–1942 елларда Чалкак урта мәктәбендә музыка укытучысы.



С.Габәши иҗат эшчәнлеген 1909 елдан пианист һәм аккомпаниатор буларак башлый. Аннан соң Уфада, Казанда әдәби-музыкаль кичәләр, лекция-концертлар, вокаль ансамбль һәм хорлар оештыру белән шөгыльләнә. Татар хор музыкасын үстерүгә мөһим өлеш кертә. С.Габәшинең композиторлык иҗатында милли сәхнә музыкасы әсәрләре зур урын алып тора. Ул 1917–1928 еллар эчендә милли театрның Г.Исхакый, Ф.Бурнаш, К.Рәхим һ.б. пьесалары буенча куелган уннан артык спектакленә музыка иҗат итә. Беренче татар опера коллективын оештыруда катнаша, беренче татар опералары «Сания» (1925) һәм «Эшче»не (1930, Г.Әлмөхәммәдов һәм В.Виноградов белән бергә) иҗат итүчеләрнең берсе була. Бу опералар Татарстанда композиторлык иҗаты һәм музыкаль башкару сәнгате үсешендә зур роль уйный. С.Габәши хор өчен, шулай ук вокаль һәм инструменталь әсәрләр иҗат итә, татар һәм башкорт җырларын эшкәртә. Иҗатында милли фольклор (бәетләр, озын көйләр) элемент-

ларын куллануга омтыла, Шәрекъ халыклары музыкасы белән кызыксына. Шул ук вакытта халык музыкасы традицияләрен Европа классик музыкасы тәҗрибәсе белән баету юлларын эзли.

Солтан Габәши, беренче татар музыкасы белгече һәм фольклорчы-этнограф буларак, фольклор экспедицияләре вакытында 200 дән артык татар, 100 ләп башкорт көйләрен җыя һәм туплый, музыкаль иҗат турында лекцияләр укый, татар һәм башкорт телләрендә музыка буенча әсбаплар, дәреслекләр төзи, татар һәм башкорт музыка мәдәниятенә кагылышлы актуаль проблемаларны яктырткан мәкаләләр яза. Аның иң мөһим язмаларының берсе – «Яңалиф» журналында татар музыкасы турында басылган (1931, № 3–6) анкета сорауларына җаваплары. Анда татар музыкасы үсешенең киләчәктәге тулаем фәнни-тарихи юлын анализлауга беренче омтылыш ясала. Солтан Габәшинең күпкырлы иҗат эшчәнлеге энциклопедик характерга ия булып тора, хәзерге татар һәм башкорт музыкасы мәдәниятенең төп юнәлешен билгеләүгә хезмәт итә.

Төп әсәрләре: «Сания» (1925), «Эшче» (1930) опералары (Г.Әлмөхәммәдов һәм В.Виноградов белән берлектә); «Зөләйха» (Г.Исхакый), «Таһир-Зөһрә» (Ф.Бурнаш), «Бүз егет» (К.Рәхим), «Фәтхулла хәзрәт» (Ф.Әмирхан), «Йосыф белән Зөләйха» (К.Әмири), «Җир уллары» (Һ.Такташ) һ.б. спектакльләргә музыка; «Кәккүк», «Оркыя», «Эшче кыз», «Ике заман», «Курай» җырлары; хор өчен татар һәм башкорт җырлары эшкәртмәләре; вокаль һәм



камера-инструменталь әсәрләр, шул исәптән фортепиано өчен «Пикник», «Кайгы», «Кайгыдан соң шатлык», «Яшьлек» пьесалары; симфоник оркестр өчен «Яңалиф маршы» (Г.Әлмөхәммәдов һәм В.Виноградов белән берлектә) һ.б.



Р.С.Габәшев.

Солтан Габәшинең улы — **Габәшев Рөстәм** 1941 елның 10 маенда Уфа шәһәрендә туа, 2010 елның 2 гыйнварында Казанда вафат. Рөстәм Габәшев – танылган археолог, тарих фәннәре кандидаты (1978), Татарстан Республикасы Дәүләт бүләге лауреаты (1994). Казан университетын тәмамлый (1968). 1974 елдан СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының, 1992 дән Россия Фәннәр академиясе Казан гыйльми үзәгенең Тел, әдәбият һәм тарих институтында, 1993 елдан ТР Фәннәр академиясенең Тарих институтында өлкән фәнни хезмәткәр. ТР Дәүләт бүләге Татарстан Республикасының археологик картасын төзүдә катнашканы өчен бирелә. Хезмәтләре Идел буе һәм Урал төбәкләренең таш һәм бакыр гасырлар археологиясе мәсьәләләренә карый.

Рөстәм Габәшевнең хатыны – **Дания Әхәт кызы Гыймранова** (23.10.1937, Казан – 29.10.2014, шунда ук), театр белгече, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе (1997), Язучылар берлеге һәм РФ театр әһелләре берлеге әгъзасы. Хезмәтләре татар театры тарихына, театр сәнгатенең күренекле эшлеклеләре иҗатын яктыртуга, Татар эшче театры, Татарстан республика күчмә театры, Минзәлә, Әлмәт татар драма театрлары тарихына карый.



Д.Ә.Гыймранова.

Рөстәм Габәшев һәм Дания Гыймрановаларның кызлары – **Айгөл Габәши**, сәнгать белгече, театр тәнкыйтьчесе, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Тел, әдәбият һәм сәнгать институты өлкән фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты. Татар театрының 110 еллыгына багышланган «Татар сәхнә сәнгатенең барлыкка килүе һәм үсеше» монографиясе авторы. «Тантана» театраль премиясе лауреаты.

## ЯРУЛЛИННАР

**Заһидулла Ярулла (Баязит) улы Яруллин** 1888 елның 12 октябрендә Мамадыш өязенең (хәзер Мамадыш районы) Кече Сон авылында туа. Хәерби авылында туган **Нәгыймә Гатаулла кызына** өйләнә, шуңа күрә Хәербидә еш була. Бу никахта бер ир бала, татар халкының атаклы композиторы Фәрит Яруллин туа.



Заһидулла Ярулла улы (кайбер мәгълүматлар буенча Баязит улы) Яруллин – пианист-ансамблист, музыкаль әсәрләр авторы. 19 йөз ахыры – 20 йөз башында Чистайда музыка уен коралларын төзәтү һәм көйләү остасының шәкерте, соңрак музыкант-башкаручы. 1912 елдан Казанда: кинематографларда, ресторапнарда, Шәрекъ клубында уйный; Түбән Новгород ярминкәләрендә, Уфа эстрада сәхнәсендә концертлар белән чыгыш ясый. «Сәйяр» труппасы спектакльләрендә катнаша. Заһидулла Яруллинның иҗаты Г.Кариев һәм Г.Тукай тарафыннан уңай бәяләнә, алар аның популяр булып китүенә булышлык итә. Ул «Тукай маршы», җырлар («Җәмилә» һ.б.) авторы. Үзе гармуннар ясый. 1923–30 елларда — Уфада, соңрак — Казанда, 1930 еллар ахырыннан Кече Сон авылында яши. 1964 елның 9 октябрендә вафат була һәм туган авылында җирләнә.

**Фәрит Заһидулла улы Яруллин** — мәшһүр татар композиторларының берсе, беренче татар балеты «Шүрәле» музыкасы авторы, ТАССРның Габдулла Тукай исемендәге дәүләт бүләге лауреаты (1958). Ул камера-инструменталь әсәрләр, романслар, җырлар иҗат итә, шулай ук халык җырларын да эшкәртә.

Фәрит Яруллинның туу вакыты һәм урынын рәсми рәвештә 1914 елның 1 гыйнварында Мамадыш өязе Кече Сон авылында дип күрсәтү кабул ителгән. Аның туган урыны Казан, шулай ук Лаеш өязе Хәерби авылы дип күрсәтелгән мәгълүматлар да очрый. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институтының Төбәкне өйрәнү үзәге мөдире Л.М.Айнетдинова тарафыннан 2013 елда ТР Милли архивыннан соратып алынган белешмәдә, 1913–1915 елларда бу урыннарның метрика кенәгәләрендә андый кешенең теркәлмәве турында әйтелә. Димәк, Фәрит Яруллинның туган урыны әлегәчә төгәл ачыкланмаган. Әмма, әти-әнисенең



ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
ТАТАР ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ ИНСТИТУТЫ
АКАДЕМИЯ НАУК РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ИНСТИТУТ ТАТАРСКОЙ ЭНЦИКЛОПЕДИИ

№ 102 н от « 29 » 03 2013 г.
на № ____ от « __ » ______ 2013 г.

420015 г.Казань, ул.Пушкина, 56
тел. (843) 238-35-82, 238-25-68
тел./факс (843) 238-25-58
E-mail: info-ite@mail.ru

Директору
Национального архива
Республики Татарстан
Л.В.Гороховой

**Уважаемая Людмила Васильевна!**

В шестом томе многотомной «Татарской энциклопедии» есть статья о татарском композиторе Фариде Загидулловиче Яруллине, который родился 1 января 1914 г. Просим Вас помочь нам определить точное место рождения. Среди мест его рождения указываются город Казань, д. Малая Сунь Мамадышского уезда, д. Кирби Лаишевского уезда.

Заведующая отделом
образования, науки и культуры Айнутдинова Л.М.



Вход. № 137 от 6.05.13

ГЛАВНОЕ АРХИВНОЕ УПРАВЛЕНИЕ
ПРИ КАБИНЕТЕ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
НАЦИОНАЛЬНЫЙ АРХИВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Кремлевская ул., 2/6, Казань, 420111
Тел (843) 279-41-18
Тел./факс (843) 292-42-88, 279-41-08
E-mail: nart@archive.gov.tatarstan.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ КАРШЫНДАГЫ
БАШ АРХИВ ИДАРӘСЕ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИЛЛИ АРХИВЫ
Кремль ур., 2/6, Казан, 420111
Тел (843) 279-41-18
Тел./факс (843) 292-42-88, 279-41-08
E-mail: nart@archive.gov.tatarstan.ru

17.04.2013 № Я-2636 н
На № 102 н от 29.03.2013 г.

Институт татарской энциклопедии
ул. Пушкина, 56
г. Казань, 420015

В метрических книгах родившихся в г. Казань за 1912-1915 гг., д. Малая Сунь Мамадышского уезда Казанской губернии за 1912-1915 гг., д. Кирби Лаишевского уезда Казанской губернии за 1912-1916 гг. сведений о рождении Фарида Загидулловича Яруллина не обнаружено. Метрические книги д. Малая Сунь Мамадышского уезда Казанской губернии за 1916 г. в архив на хранение не поступали.

Директор Л.В.Горохова
Начальник отдела Л.О.Кузнецова

бу вакытта Казан шәһәрендә яшәүләрен, Хәербигә еш кайтып йөрүләрен искә алсак, аның туган урыны шушы икенең берсендә булу дөреслеккә күбрәк туры килә. Документларда ул сугышка да Хәерби авылыннан алынган дип күрсәтелгән.

Фәрит Яруллинның әтисе — халык музыканты, үзе дә байтак кына җыр һәм инструменталь пьесалар авторы, мәшһүр «Тукай маршы»н иҗат иткән Заһидулла Яруллин, әнисе — **Нәгыймә апа** — Хәерби кызы («Ярми нәселе» шәҗәрәсен карарга була). Язучы Ришат Низамиевның композитор тормышына багышланган «Ут һәм җыр» роман-хроникасында бу турыда тәфсилләп язылган.

Сәнгать фәннәре кандидаты Аида Алмазова хезмәтләрендә Фәрит Яруллинның Заһидулла һәм Нәгыймәнең үз балалары булмавы турында әйтелә. Бу мәгълүматларны ул Нәгыймәнең бертуганы Ярмиев Гарифулла сүзләре буенча яза. Шулай булган очракта да (бу әле исбатланган факт түгел), Фәрит Яруллинның композитор булып җитешүендә әнисенең дә, әтисенең дә рольләре бик зур.

1923 елда гаилә Уфа шәһәренә күченә. Фәрит Яруллин беренче татар-башкорт мәктәбендә укый, ә башлангыч музыкаль белемне ул әтисеннән ала. 1930 елда ул Казан сәнгать техникумына укырга керә. Бу чорда Яруллиннар гаиләсе таркала. Заһидулла Яруллин Мамадыш районы Кече Сон авылына кайтып китә һәм анда яңа гаилә кора.



Ф.Яруллин башта виолончель буенча, тора-бара махсус фортепьяно сыйныфында белем ала башлый. Техникумда уку елларында ук ул Татарстанның музыкаль мәдәниятенә нигез салучыларның берсенә әверелә. Үзешчән сәнгать түгәрәкләре оештырып, аларга җитәкчелек итә, яңа ачылган яшьләр театрында, сүзсез кинофильмнарда музыка башкара. 1933 елда Фәрит Яруллин Мәскәү консерваториясенең татар опера студиясенә укырга керә. Биредә ул композиция буенча мәшһүр профессор Генрих Литинскийда белем ала. Мәскәүдә уку елларында (1934–1939) җырлар, романслар, инструменталь миниатюралар яза башлый. Зур күләмле әсәрләрдән виолончель һәм фортепьяно өчен соната, кыллы квартет һәм симфония иҗат итә. Әнә шулай яшь композитор үзен төрле жанрларда сынап карый. 1937–1938 елларда аның күңеленә Габдулла Тукайның «Шүрәле» әкият-поэмасын музыкага салу теләге туа. Ниһаять, 1941 елның җәендә автор «Шүрәле» балетының каралама нөсхәсен балетмейстр Л.В.Якобсонга тапшыра һәм балетны сәхнәләштерү эшләре башланып китә. Әмма балет сәхнәгә менә алмыйча кала – Бөек Ватан сугышы башлана.

Фәрит Яруллинны да, армиягә алып, фронтка җибәрәләр. 1941 елда ул Ульяновскидагы җәяүле гаскәриләр училищесын тәмамлый, лейтенант дәрәҗәсе ала. 1942 елда очраклы рәвештә дусты-остазы Генрих Литинский белән очраша. Танылган профессор Фәрит Яруллинны Мәскәү консерваториясенең хәрби дирижерлык факультетына күчерү хакында югары командованиегә үтенеч хаты яза. Әмма рөхсәт хаты килеп җиткәндә татар композиторын фронтка озаткан булалар. 1943 елның 17 октябрендә Белоруссиянең Витебск өлкәсе Дубровно районында барган бәрелешләрдә 19 нчы танк корпусының укчы взвод командиры лейтенант Фәрит Яруллин һәлак була, Новая Тухинь авылында җирләнә. Озак вакыт ул хәбәрсез югалганнар исемлегендә йөри, һәлак булган урыны 40 елдан соң гына ачыклана.

1996 елда Казан шәһәрендә басылган «Хәтер» китабының 15 том, 325 битендә: «Яруллин Фәрит Зәйдулла улы, Хәерби ав., Казан ш. Бауман РХК моб., кече лейтенант, 7.10.1943 һәлак булган, Витебск өлкәсе, Дубровно районы,

Новая Тухиня ав. җирләнгән» дип язылган. Ә русча текстта аның 82 нче укчы дивизиянең 250 нче укчы полкында хезмәт иткәнлеге турында да мәгълүмат бар. Бу мәгълүмат буенча ул Хәербидә туган булып чыга!



Фәрит Яруллин исеме мәңгеләштерелгән хәрби мемориал. Татарстан делегациясе составында: шагыйрь Ренат Харис, «Хәтер китабы» редакторы урынбасары Михаил Черепанов һ.б. 2006 ел.

1940 елның июнендә Фәрит Яруллин үзенең булачак хатыны – балет артисткасы, зур кара күзле, матур, зифа буйлы кыз **Галина Сачек** белән таныша. Алар танышканда, Галинага 25 яшь була. Берберсен бик яраталар. Композитор сөйгәнен «Гөлчәчәк» дип йөртә. Кызлары — **Наилә Яруллина** 1942 елда туа, хәзерге вакытта Киев шәһәрендә гомер итә.




1958 елда, вафатыннан соң, Фәрит Яруллинга «Шүрәле» балеты музыкасы авторы буларак, ТАССРның Габдулла Тукай исемендәге дәүләт премиясе бирү турында карар чыгарыла.

Казанның Киров районындагы бер урамы Фәрит Яруллин исемен йөртә. Кече Сон авылында Яруллиннар музее эшли. Әлмәт музыка көллиятенә Фәрит Яруллин исеме бирелгән. Язучы Рашат Низамиев Фәрит Яруллинга багышланган «Ут һәм җыр» роман-хроникасын иҗат итте (Казан, Татар. кит. нәшр., 2000).

2017 елның 3 июлендә Беларусь Республикасы Витебск өлкәсе Дубровно шәһәрендә татар композиторы Фәрит Яруллинга һәйкәл ачыла. Бюст Фәрит Яруллин исемен йөртүче Дубровно балалар сәнгать мәктәбе алдында куела.

Заһидулла Яруллинның икенче улы — композитор, педагог, ТАССРның, Каракалпак АССР һәм РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1970, 1980, 1985) **Мирсәет Яруллин**. Мирсәет – Заһидулланың икенче хатыныннан туган бала. Мирсәет Яруллин 1938 елның 12 июлендә Мамадыш районы Кече Сон авылында туа, 2009 елның 6 апрелендә вафат.

# XXII БҮЛЕК

# ХӘЕРБИГӘ КАЙТЫП ЙӨРГӘН ТАНЫЛГАН ШӘХЕСЛӘР

## САРА САДЫЙКОВА

Сара Садыйкованың кем икәнен бар татар дөньясы белә. Ул 1903–1986 елларда яшәгән милләттәшебез, җырчы (сопрано), актриса, композитор, ТАССРның халык артисты (1977), РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1984), ТАССРның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты (1990, вафатыннан соң).



Сара Гариф кызы Садыйкова иҗат юлын артист буларак башлап җибәрә. Мәскәүдә татар опера студиясен тәмамлаганнан соң, 1938–1948 елларда Татар опера һәм балет театрында эшли, солистка. «Сания», «Качкын», «Галиябану», «Башмагым» «Илдар» опера һәм музыкаль комедияләрендә, «Кандыр буе», «Наемщик» музыкаль драмаларында төп партияләрне башкара. Ә менә сугыштан соң дөньяга килгән буыннар аны композитор буларак хәтерли, җырларын яратып җырлый, үзен зыялы, затлы ханым буларак хөрмәтләп, истәлеген кадерләп саклый.

Сара Садыйкова җырларының тематикасы киң. Аеруча популяр җырлары – Ә.Ерикәй шигыренә «Көтәм сине», М.Ногман шигырьләренә «Онытa алмасам нишләрмен», «Балкый Шәйморза утлары», Г.Бәширов шигыренә «Җидегән чишмә», Х.Туфан шигыренә «Казан кичләре» һ.б.

Сара апа Садыйкова актив мәдәни һәм иҗтимагый эшчәнлек алып бара. Казанда М.Горький исемендәге клуб каршында халык хорын оештыра һәм күп еллар дәвамында аны җитәкли. Талантлы яшьләрне музыка сәнгатенә җәлеп итә. Күпләгән милли композиторлык һәм башкару сәнгате вәкилләренең иҗади үсешенә йогынты ясый. Татар халык җырларын җыя.

Сара Садыйкова истәлегенә һәм аның мирасын пропагандалауга балалар һәм яшьләр музыка конкурслары һәм фестивальләре, Казанда, Мәскәүдә, Санкт-Петербург һ.б. шәһәрләрдә концертлар, телевизион фильмнар багыш-

лана. Казанда ул яшәгән йортка мемориаль такта куела, Чаллыда концерт залына Сара Садыйкова исеме бирелә. 1992 дән Апас районының Тутай авылында Садыйкова Сара музее һәм 1996 дан Казанда Сара Садыйкова фонды эшли.

Р.Гобәйдуллин белән автордашлыкта «Мәхәббәт җыры» (1971) һәм «Кияүләр» (1972) музыкаль комедияләренә, 18 спектакльгә музыка яза; 400 дән артык җыр, инструменталь әсәрләр һ.б. иҗат итә.

Сара апа Садыйкова Хәербигә кунакка Гыймадиев Сафа абый һәм Мәүлия апа гаиләсенә кайтып йөри торган була, чөнки, аларның кызлары Рәисә һәм уллары Хәйдәр М.Горький исемендәге Мәдәният йортының ул җитәкләгән татар хорына йөриләр. Рәйсә Гыймадиевага әле бөек композиторның фатирында аның белән яшәү дә насыйп була.

«60 нчы еллар уртасында, 8 нче сыйныфны тәмамлагач, укуымны дәвам итәргә Казанга килдем, – дип сөйли Рәйсә ханым. – Кичке мәктәптә укыдым, мех комбинатында эшләдем, җылы киемнәр тектем. Җыр ярата торган гаиләдә үстек без. Беркөнне иптәш кызым мине М.Горький исемендәге Мәдәният йортындагы үзешчәннәр хорына алып барды. Хорның җитәкчесе Сара апа Садыйкова икән. Шулай итеп, мәшһүр композиторыбыз Сара апа җитәкли торган хорга йөри башладым. Бу 1967 ел иде.

Сара апа К.Тинчурин урамында яшәде. Ә мин – әнинең апасында фатирда торып эшлим. 1968 елда Сара апа мине үзенә торырга чакырды. Мин бик тартындым. Шундый олы шәхес белән бер фатирда яшәүне күз алдына китерсәң... Әмма Сара апа күндерде: мин аның фатирына күченеп килдем. Ләкин Сара апаның ни өчен мине сайлавын хәзергә кадәр аңлый алмыйм. Сара апа мине яратты, «икенче кызым» дип йөртә иде. Үзе исә минем «икенче әниемә» әверелде. Һәрвакыт «балакаем», «кызым» дип дәшә иде ул. Сара апа белән 7 ел бергә яшәдек без. Ул Татарстан урамында яңа фатир алгач, мине дә үзе белән чакырды, әмма мин бармадым, уңайсызландым.

Сара апа белән якыннан аралаша алуыма әйтеп бетергесез сөенәм. Әмма бер яктан үз-үземне гафу итә алмыйм – Сара апаны соңгы юлга озата алмадым. Ул вафат булганда, мин Сочида ял итә идем. Кайгылы хәбәрне ишеткәч, атналар буе еладым. Бу үкенеч йөрәктә калды инде...

Бергә яшәү дәверен бик еш искә алам. Язган җырларын башта миңа җырлатып карый иде ул. Бергәләп киңәшә, фикерләшә идек. Сара апа фатирыннан сәнгать әһелләре, шагыйрьләр, җырчылар өзелеп тормый. Аеруча Сибгат Хәким, Гөлшат Зәйнәшева, Мостафа Ногман, Илһам Шакиров, Әлфия Афзалова еш киләләр иде. Аның самоварының электрга тоташтырылмаган чагы сирәк булгандыр. Сара апа иртәнге якта эшләргә яратты. Кибеткә чыгып кергәч,

төштән соң да эшләп ала. Сара апа чәй янына коймак ярата иде. Фатирында артык-портык берни юк, җиһазлары гади генә. Ул өйдәге әйберләрнең урыннарын алыштыргалап тора. Мин эштән кайткач:

– Рәйсә, кара әле, яңалык күрәсеңме? – дип сорый да, соклануымны күргәч, балаларча шатланып куя.

Үзе җитәкләгән хорга бар йөрәген бирде Сара апа. Хорның горурлыгы булган Камил Денисов, Мәдинә Сафиуллина, Гөлфия Сабировалар сәхнә осталары булып үстеләр. Күренекле җырчыларыбыз Флёра Сөләйманова, Шамил Әхмәтҗанов, Рабига Сибгатуллина, Хәнәви Шәйдуллиннарга сәнгатькә, җырга, олы юлга чыгарга булышкан, юл күрсәткән кеше дә ул.

Сара апа Садыйкова татар зыялы ханымнары арасында чиккән калфак киеп йөрүче бердәнбер хатын-кыз иде. Бөек композиторыбызның кимсетелгән, кыерсытылган вакытлары да булды. Нишлисең, зур шәхесләрнең язмышы каршылыкларга бай була торгандыр. Бигрәк тә тоталитар режим вакытында андыйларны күп кактылар, туры сүзле, гадел, талантлы булганга кӱралмадылар. Озак вакыт Композиторлар берлегенә кабул итмәделәр. Сара апа аңа карап иҗат итүдән туктамады.



Ул К.Тинчурин урамындагы шаушулы, кысан бүлмәсеннән иркенрәк фатирга чыгарга омтылып яшәде. Дөрес, соңрак ул ике бүлмәле фатирны да, дәүләт бүләкләрен дә алды. Инде бу вакытта гаделлеккә өмет-ышанычы нык какшаган иде аның. Әмма аны халык яратты, таныды, үзенең мәшһүр кызы итеп кабул кылды».

Шулай бервакыт, Сара Садыйкова Рәйсә Гыймадиеваның әнисе Мәүлия апа янында Хәербидә калып тора. Шул ук көнне авылда печәнгә төшәләр. Мәүлия апа, чалгы кайраклары алып кайтырмын дип, тиз генә Столбищеның хуҗалык товарлары кибетенә барырга җыена. Сара апа үзе генә каласы килмәвен һәм аның да ияреп барырга теләге барлыгын әйтә. Столбищеда кайрак алгач та, тиз генә кайтып китәргә язмаган була аларга. Сара Садыйкованың башында көй туа! Хәзер инде ул үзе, Мәүлия апаны ияртеп, Казанга Кәрим Тинчурин урамындагы фатирына юл ала. Аңа бик тиз генә пианино артына утырып, көйне нотага төшерергә кирәк була. Печән кайгысымы?! Менә шулай итеп, кайракка барып көй язып кайттык, дип сөйли иде Мәүлия апа.

## ЭЛЬМИРА ШӘРИФУЛЛИНА

Язучы Эльмира Мөхәммәт кызы Шәрифуллина 1947 нең 4 июнендә, Мөслим районы Симәк авылында туган. Язучылар берлеге әгъзасы (1985), ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1993). 1973 елда Казан университетын тәмамлый. 1966 елдан Мамадыш шәһәрендә Пионерлар йорты директоры булып эшли. 1970 тән Казанда: ТАССР Министрлар Советының Телевидение һәм радиотапшырулар комитетында мөхәррир, 1974 тән «Ялкын» журналында бүлек мөдире, «Яшь ленинчы» газетасында (1983–1987) һәм «Мәгариф» (1993–1997) журналында әдәби хезмәткәр. 1997–2004 елларда Казан педагогия көллиятендә укытучы. Э.Шәрифуллина, шигърияттән прозага, прозадан – шигърияткә күчә-күчә, гомере буе әдәби иҗат белән шөгыльләнгән кеше. Ире – танылган язучы, шагыйрь, юмор остасы Фаил Шәфигуллин исән чакта, Эльмира апа, тыйнаклык күрсәтеп, үз иҗатын күрсәтми тота. Аннары иренең дуслары Зөлфәт, Мөдәрис Әгъләмовлар аны «дөньяга чыгарга» күндерәләр. Фаил абыйның фаҗигале үлеменнән соң, ул аңа багышланган повесть та язып бастыра. Эльмира Шәрифуллина – татар хатыннарының чибәрлеген, акылын, басынкылыгын, сабырлыгын, булдыклылыгын туплаган затлы ханым. Хәерби аны шундый итеп ярата. Әдибә иҗатының төп юнәлешләре — лирика һәм балалар







1. Фотограф Николай Седов, Эльмира Шәрифуллина һәм Роза Кушмина;
2. Укучылар белән очрашу.

өчен шигырьләр. Э.Шәрифуллина шигырьләренә композиторлар Ә.Бакиров, Р.Яхин, Н.Җиһанов, Р.Гатауллин, И.Закиров популяр җырлар иҗат итәләр.

Эльмира Шәрифуллина Хәербигә еш кайта, ул Роза һәм Шамил Кушминнарның гаилә дуслары. Аның катнашында авыл мәктәбендә балалар белән әдәби очрашулар, кичәләр уздырыла. Ул «Яшь ленинчы» газетасында эшләгәндә, Хәерби балаларын редакциягә экскурсияләргә еш алып баралар.

Эльмира Шәрифуллинаның дусты Роза Кушминага атап язган шигырьләре:

**Озак яшә!**

Туры сүзле, киң күңелле,
Олы җанлы Кеше син!
Тапкырлыгың, җорлыгыңа
Рәсәйдә дә юктыр тиң.
Ачык йөзле, тәмле телле,
Кунакчыл – кайчан килмә.
Үзең гадел, кешелекле,
Талантлы мөгаллимә.
Такташларны, Тукайларны
Яттан сөйләп бирәсең.

Чын шагыйрьнең йөрәгендә
Утлы кояш күрәсең.
«Мәктәбем!» диеп үткәрдең
Гомереңнең яртысын.
Елмаясың Хәербидә –
Казаннарда яктысы!
Синең ярдәм белән үрли
Мохтаҗларның да эше.
Озак яшә, кайгы күрмә,
Хөрмәткә лаек Кеше!

**Дустыма**

Киң күңелле дустым,
Мөгаллимә дустым,
Туганым күк дустым Роза,
Шигырь язмак булам,
Җырлар язмак,
Килеп чыга гади проза.
Мәрхәмәтле җаның,
Ипле, динле җаның
Синең байлык, синең биләмә.
Кем берәүдән шуның берсе төшми,
Күпме селке, күпме иләмә.
Сүзләреңдә хикмәт,
Шигъри аять
Телең оста сүзгә, сөйләмгә,

Минутың да әрәм итмәдең син,
Юк эшләргә, гайбәт, биләмгә.
Син тумыштан олы йөрәк белән,
Мәгърифәтле булып тугансың.
Туган җирең зурлап,
Авыл күңелендә
Иң югары баллны җыйгансың!
Киң күңелле дустым,
Мөгаллимә дустым,
Туганым күк дустым Роза,
Шигырь язмак булдым,
Җырлар язмак,
Килеп чыкты хисси проза!

## XXIII БҮЛЕК

## ГОРЕФ-ГАДӘТЛӘР, ЙОЛАЛАР, БӘЙРӘМНӘР

Авылның йөз еллар буе яшәп килгән гореф-гадәтләре, йолалары бар. Аларны берәү дә бозмый һәм һичсүзсез үти. Шуларның кайберләрен карап китик.

### Бәби туу белән бәйле йолалар

Бу бәйрәмгә мулла чакырыла. Мулла, тиешле догаларны укыганнан соң, баланың колагына баланың исемен әйтә. Элек бала авырса, яки миң чыкса, аның исемен алыштыра торган булганнар.

Бәби алып кайткан йортка туган-тумачалар, дуслар, күрше-тирәләр бәби ашы кертәләр. Бу, гадәттә, камыр ризыгы була. Шулай итеп, әле генә бәбидән котылган ана аш-су пешерү эшеннән бераз туктап тора, ял итә. Бәби мунчасы ягу өчен су ташу, мунча ягып өлгертү дә туганнар, дуслар тарафыннан эшләнә. Кешеләр бер-берсенә дус һәм ярдәмче булалар. Хәзер инде бәби ашлары китермиләр. Бәби котлап килүчеләргә ризыкларны хуҗалар әзерли. Вакыт үтү белән элеккеге матур гадәт югала бара.

### Чәч тарау йоласы

Чисталык-тәртипкә бәйле гадәтләрдән берсе – чәч тарау. Чәчне хәзерге кебек көзге каршына басып тарау гадәте бөтенләй булмый. Чәч тарарга җыенган хатын-кыз алдына яулыгын җәеп, аулаграк урында чәчен тарап үрә. Шуннан соң яулыкка коелган чәчләрен бөртеген дә төшермичә җыеп алып мичкә ыргыта, ә яулыкны тышка алып чыгып селки. Чәчен-башын җыеп йөрмәүче хатын-кызга караш тискәре була.

### Яңгыр теләү йоласы

Карга боткасы пешереп, су сибешеп, яңгыр теләү йоласын үтәүдә ирләр дә, хатыннар да, картлар һәм бала-чагалар да башлап йөрергә мөмкин. Авыл халкы төрле ярмалардан урманда, басуда яки су буенда ботка пешергән. Су сибешеп, яңгыр теләгәннәр. Ботка пешкәндә бу такмакны кабатлаганнар:

Яңгыр яу, яңгыр яу!
Без сорыйбыз Ходайдан,
Арыштан, бодайдан,
Пәрәмәчтән, күмәчтән.

Сыерларның сөтләре
Аз булмасын, күп булсын.
Игеннәрнең башлары
Ач булмасын, тук булсын.

### Ашау-эчүгә бәйле гадәтләр

Ашар алдыннан бөтен гаилә бергә җыела. Аерым-аерым утырып ашау гадәте булмый. Ризыкка бисмилласыз кагылмыйлар. Ата-ана беренче кашык ашны капканчы, балалар тик тора. Ата-анадан алда ашка үрелү зур әдәпсезлек санала. Ипине олылау гадәте дә борынгыдан килә. Аны кирәк кадәр генә кисәләр, сынык калдырмыйлар. Ашап-эчкәннән соң, ипине ашъяулыкка төреп шүрлеккә алып куялар.

### Гает бәйрәмнәре

Гает көне алдыннан өйләрне җыештыралар, бөтен кеше мунча керә. Гает көнне иртән мәчеттә намаз укыла. Мулла вәгазь сөйли. Кешеләр бер-берсен бәйрәм белән котлыйлар. Гает намазыннан кайтуга, һәркемне өйдә бәйрәм табыны көтә. Кешеләр бер-берсенә кунак мәҗлесенә йөриләр.

### Корбан чалу

Иминлек, мул уңыш теләп, күмәкләшеп корбан чалу, корбан итен бергәләп пешереп ашау йоласы аерым урын алып тора. Корбанны җир уңдырышлы булсынга, мал-туар ишәйсенгә, иминлек һәм муллык теләп чалганнар. Сарык, үгез, бозау, сыер корбан итеп чалына. Хайванның сөякләрен теләсә кайда ташламаганнар, аларны җыеп суга салганнар, я җиргә күмгәннәр.

### Өмә

Күп көч һәм вакыт сорый торган эшләрне өмә ясап, түләүсез, ирекле рәвештә җыелып, бергәләп, күмәкләп эшләү Хәерби авылы халкының борынгыдан килгән күркәм йолаларыннан берсе.

Өмәләр ашлык сугу, утын әзерләү, бура бурау, йорт күтәрү һ.б. кебек аеруча авыр һәм зур эшләрне кыска вакыт эчендә башкарып чыгу өчен үткәрелгән.

Каз өмәсен аеруча көтеп ала торган булганнар. Безнең борынгы әби-бабаларыбыз казны бик яратканнар. Беренчедән, аның мамыгыннан мендәр, түшәк, ястыклар ясаганнар. Икенчедән, каз итен аш-су өчен бик әйбәтләп файдалана белгәннәр, шулпасын яратып ашаганнар. Каклаган каз Сабан туе бәйрәменең иң тәмле сыйларыннан саналган һәм санала да. Беренче чиратта өмәгә туган-тумача, күрше кызларын дәшәләр.

### Сабан туе

XX гасыр башында сабан туйлары иртә язда ук үткәрелгән. Хәерби сабан туеның үзенчәлекле ягы булуын әйтеп китми булмый. Сабан туе элек өч өлештән торган: кыйбый, көрәш, Мишә буе.

Кыйбый иртәнге якта ат чабышы белән башлана. Гадәттә ул авылның Ачканбай болынында үткәрелә. Шунда ук җәяүлеләр йөгерә, капчык киеп һәм кашыкка йомырка салып узышу кебек ярышлар үтә. Халык төркем-төркем булып бии, җырлашалар. Төшке ашка өйләргә таралышалар. Ашап, бераз ял итеп алгач, халык Миләүшә тау итәгенә көрәш карарга җыела. Монда капчык белән бәрешү, әтәч яки итек алу өчен багана башына менү, катыктан акча эзләү кебек уеннар оештырыла.

Икенче көнне бәйрәм дәвам итә. Бу — Мишә буе көне. Кешеләр бу көнне Мишә елгасы янына баралар. Анда учаклар ягыла, казан асып, балык шулпасы пешерәләр, су коеналар. Бөтен җирдә җыр-музыка тавышлары яңгырый.

Элегрәк Мишә буена ат җигеп баралар. Ат матур бизәкле йөгәннәр белән җигелә. Дугага кызыл башлы – чигелгән сөлге урыйлар. Кызлар бу көн өчен махсус кулъяулыклар чигеп куялар. Үзләре кем атына утырып барсалар, шул атның ялларын кулъяулыклар белән бизиләр. Соңыннан бу кулъяулыклар ат хуҗасы егеткә бирелә. Мишә буена чыгып киткәнче, ат арбасына утырган яшьләр гармун уйнап, җырлап урам әйләнәләр. Авыл гөр килә. Өй сакларга калган әби-бабайлар капка төбендә яшьләрне тамаша кылып утыралар.

Хәзер инде сабантуйның беренче көнен «кыйбый», «көрәш» дип икегә бүлмиләр. Бөтен ярышлар Миләүшә тавында үтә. Мишә буена да машиналар белән генә җилдерәләр. Кыңгыраулы, бизәлгән дугалар белән җигелгән атларда урам әйләнүләр, кызыл башлы сөлгеләр, чигелгән кулъяулыклар якты бер моң булып өлкәннәрнең күңелендә генә яши.





1



2

1. Ат чабышын карарга «кыйбый»га җыйналган авыл халкы. 1960 еллар башы;
2. Сабан туен оештыручылар. 1966 ел.













Төрле еллардагы Сабан туе бәйрәмнәреннән күренешләр.














Төрле еллардагы Сабан туе бәйрәмнәреннән күренешләр.









Төрле еллардагы Сабан туе бәйрәмнәреннән күренешләр.















Төрле еллардагы Сабан туе бәйрәмнәреннән күренешләр.

















Төрле еллардагы Сабан туе бәйрәмнәреннән күренешләр.














Төрле еллардагы Сабан туе бәйрәмнәреннән күренешләр.










Төрле еллардагы Сабан туе бәйрәмнәреннән күренешләр.

# XXIV БҮЛЕК

## МЕДПУНКТ

Авылда беренче медпункт 1939 елда ачыла. Медпункт өчен аерым бина булмый, шуңа күрә ул Галиев Габдуллалар өендә урнаша. Фельдшер булып бер ир-егет эшли башлый. Соңыннан Хәйбуллин Насыйбулла, Гайнуллина Асылбикә, Җаббарова Гайшәләр йорты да медпункт итеп файдаланыла. Йорт хуҗалары авыл советы түләгән акча һәм кайтартылган утын хакына авыруларны үз өйләрендә кабул итәргә риза булалар.



1989 елда салынган медпункт бинасы.

1950 еллар азагында авыл советы 15 мең сумга Сафин Харисның иске өен сатып алып, аны медпункт итеп көйли. 1973 елда тагын бер агач йорт салына. 1989 елда таштан зур һәм уңайлы итеп махсус медпункт бинасы төзелә.

1950 елларда фельдшер булып Әхмәтшина Камилә, Минһаҗева Галина (эшләгән еллары билгесез), 1960 еллар уртасында – Фидания, 1966–1970 елларда Илсөяр, 1969–1972 елларда — Сания Кыяметдинова эшли. Илсө-





Гүзәл Юнысова һәм Алсинә Гаязова эш урыннарында.

яр апа эшләгән чорда Хәербидә кыска вакытта гына бала тудыру йорты да ачылып ала. 1971 елда Закирова Мәдинә һәм Хөсәенова Флюра Гомәр кызы эшли башлый. 1973 елны Фәттахова Диләфрүз килә һәм ул 1982 елга кадәр эшли. 1982–1985 елларда Зөлфия (хәзер Столбищеда яши) һәм Ираида исемле кызлар фельдшер булып тора. 1984–2005 елларда фельдшер Егорова Гөлзада Гариф кызы, 2005–2010 елларда Юнысова Зөлфия була. 2010 елдан медпунктта Юнысова Гүзәл һәм Гаязова Алсинә эшли.

Шәһәр җиреннән аермалы буларак, авылда фельдшер булып эшләү икеләтә зур җаваплылык сорый торган һөнәрләрнең берсе, чөнки, сер түгел, бер үк вакытта аларга педиатр да, күз табибы да, хирург та булырга туры килә. Тик, авылдашлары арасында абруй казаныр өчен, белемле булу өстенә, ачык йөзле, тәмле телле булу да бик мөһим. Гүзәлне дә, Алсинәне дә авыл халкы бик ярата.

2015 елның 10 маенда Хәерби авылында яңа фельдшер-акушерлык пункты (ФАП) ачыла. Яңа бина «2012–2016 елларга ТР халкына беренчел медицина ярдәме күрсәтүне камилләштерү» республика программасы буенча төзелә. Барлык кабинетлар да заманча җиһазландырылган, кешеләргә медицина ярдәме күрсәтү өчен барлык шартлар да тудырылган. Анда 200 дән артык кешегә хезмәт күрсәтелә.



1



2



3

1. 2015 елда ачылган медпункт бинасы; 2–3. Медпунктның эчке күренеше.

## XXV БҮЛЕК

## АВЫЛ КИБЕТЕ

Авыл җирендә кибет – кибет кенә түгел. Ул авыл кешеләренең күрешү, аралашу, бер-ике булса да сүз алышу, иң мөһиме – авыл яңалыклары белән танышу, ил, район яңалыкларын белешү урыны.

Хәерби авылында 1970–1990 елларда ике кибет эшли. Авыл халкы аның берсен — «яңа кибет», ә икенчесен «иске кибет» дип йөртә. Иске кибет Маликов Ибраһим абый һәм укытучы Галия апалар күршесендә була. Анда азык-төлек кенә сатыла. Яңа кибет Вафин Әхмәт абыйларга каршы якта, Вафин Шафик абыйлар күршесендә урнашкан була. Бу кибеттә сатучы булып Вәлиуллин Якуп абый һәм Вәлиуллина Нурхидә апалар эшли. Яңасында азык-төлек белән беррәттән көндәлек куллану, хуҗалык товарлары да сатыла.

Хәзерге көндә Хәербидә 4 азык-төлек кибете бар. «Алан» кибетендә 20 елдан артык Хәерби кызы Алсу Рәхмәтуллина эшли.

## ҮЗ ЭШЕНЕҢ ОСТАСЫ

*А.Насыйбуллина*

Кибетче, сатучы һөнәре бик борынгы һөнәр. Һәм ул бер генә заманда да җиңел эш саналмаган. Бигрәк тә үзең туып үскән һәм яшәгән авылда кибетче булып эшләү җиңелләрдән түгелдер. Тырышлык, җитезлек, белем һәм бик зур җаваплылык сорый торган эш бу. Хәербидә бик күп еллар авыл кибетендә эшләгән Якуп абый бар. Аның хезмәт стажы – 48 ел. Иртә таңнан кичкә кадәр көн саен эш урынында булган кеше ул. Кибете товарларга һәрвакыт бай була. Хәзерге кибетләрне түгел, ул эшли башлаган еллар кибетен күз алдына китерик. Авыр тартмаларны, капчыкларны күтәреп йөртергә кирәк, бар нәрсәне үзең үлчәп сатасы. Үлчәр өчен пакетлар юк диярлек, кәгазьдән төргәк ясыйсы. Ул арада чират җыела. Әле бит кешенең дә төрлесе бар. Сабырсызлары авыр сүзләр әйтеп чыгып китәргә дә күп сорап тормый. Ә кибетчегә көне буе кешеләр белән эшлисе. Бүген дә, иртәгә дә шулай. Барысын да җайлап, һәрберсенең соравына җавап биреп, олы кешеләрнең хәлләрен сорашып, матур итеп каршы ала һәм озатып кала Якуп абый!

Мин, аның кызы Фирдәвес белән бер класста укыганлыктан, Якуп абый һәм аның гаиләсе белән бик яхшы таныш. Кайчан керсәң дә, аны өйләрендә очратып булмый иде. Тормыш иптәше Нурхидә апа да аның белән бергә кибеттә эшли. Шул ук вакытта өйдәге эшләрнең дә күбесе Нурхидә апа өс-


КИБЕТ
АЙЛЕН
МАГАЗИН
ООО Айгуль






Ашамлыклар
АЛАН
Продукты


Продукты
МЫ ОТКРЫЛИСЬ!
РАЗЛИВНОЕ


КИРИЕШКИ

тендә. Балалар да бит дүртәү! Киендерергә, ашатырга, укытырга кирәк. Якуп абый үзенең кибеттәге эшенә бирелгән булуы белән аларның ничәнче класста укыганнарын да төгәл әйтә алмагандыр.

Бу өйдә кунакта булу бик рәхәт иде миңа. Без үскән вакытта кибетчеләрне бай, бик дәрәҗәле, үзләрен эрерәк тотучы кешеләргә саныйлар иде. Шулай булыр да: бу бит тоташ дефицит заманы. Ә бу гаиләдә гадилек, дуслык, татулык күренеп, сизелеп тора. Без, аларның балалары янына өйгә килгән дуслары, бу йортта үзебезне бик иркен тотабыз, кичке ашлар ашап, туйганчы уйнап кайтып китәбез. Бердәнбер усал зат – ул аларның этләре Шарик иде.

Бервакыт Якуп абыйга сельподан «Яшь гвардия» пионерлагерена путёвка тәкъдим иткәннәр, ул кызы Фирдәвес белән бергә миңа да алып кайткан. Путёвканы тутырганда фамилиямне онытып җибәргән. Аптырап тормаган Якуп абый, миңа да үз фамилиясен биреп, Вәлиуллина дип яздырган. Менә шулай ике Вәлиуллина булып «Яшь гвардия» лагеренда ял итәргә туры килгән иде безгә.

Якуп абый кибетче булып 30 ел, авыл советы рәисе булып 3 ел эшләде. Ул рәис булып эшләгәндә һәр хуҗалыкка 50 сутый бушлай җир бирелде. Якуп абый кешеләрне күпме өндәсә дә, күпләр ул вакытта җир алырга теләк белдерми, соңыннан үкенәләр. Ул шушы вазифасында вакытта авыл уртасындагы күлне казыттырып тирәнәйттерде, чистарттырды. Күл, суы чистарып, киңәеп, матураеп, зураеп киткән иде.

Нурхидә һәм Якуп Вәлиуллиннар дүрт бала тәрбияләп үстерделәр. Ике кызлары сәүдә техникумын һәм институтын тәмамлады. Ә минем классташым Фирдәвес башта елга техникумында, аннары педагогика институтында укыды. Олы абыйлары Фәрит Вәлиуллин җаваплы урыннарда зур җитәкче булып эшләгән кеше. Алар барысы да мәрхәмәтле, игелекле, авылның горурлыгы булырлык кешеләр.

Бу гаилә турында язганда киленнәре Венера апаны да әйтеп үтәсем килә. Ул да Хәерби кызы. Шул хәтле дә үзләренә охшап килгән, кешелекле кеше ул! Машина йөртү таныклыгы аның инде бик күп еллар бар. Казанга китәргә дип кузгалып китә икән дә, Травкинога барып җиткәч, авылга машина көтеп торучы яки җәяүләп атлаучы Хәерби кешесен күрсә, кайтарып куя икән! «Китә алмыйча икешәр тапкыр да борылып төшкәне бар әле аның», – дип яратып сөйләгән иде Фирдәвес. Бу мисал бит аның авылны, кешеләрне ятратканына төп дәлил.

Менә шундый Якуп абыйның гаиләсе. Бүгенге көндә ул үзе дә, хатыны Нурхидә апа да лаеклы ялда. Балалар, килен, кияүләр, алты оньк, оныкларның ике баласы янәшәсендәге бик лаеклы, бәхетле картлык бу.

# XXVI БҮЛЕК

# ПОЧТА, ЭЛЕМТӘ

Почта – ул бик борынгыдан килгән элемтә чарасы. Тарих битләренә күз салсак, элемтә хезмәте арадашчы ролендә Борынгы Римда барлыкка килә. Аңа нигез салучы дип фарсылар патшасы Дарийның кул астындагы башлык Кир исәпләнә. Кешеләрнең бер-берсеннән хәбәр алу яисә хәбәр ирештерү ихтыяҗы борынгы гасырларда ук булган. Моның өчен алар ни генә кулланмаганнар, учак төтене дисеңме, барабан кагумы. Тора-бара кабиләләр арасында махсус хәбәр йөртүчеләр барлыкка килгән. Соңыннан, язу барлыкка килгәч, кабиләләр төрле язулар аша аралашканнар. Кайларга гына, ниләр генә язмаган, нинди билгеләр генә уймаган алар?! Каен тузы, агач цилиндр, бамбук таякчыклары, папирус, пергамент – берсе дә калмаган. Кешелек дөньясы кәгазь уйлап тапкач кына, әкренләп элемтә бүлегенә дә нигез салына. Россиядә элемтә хезмәте үзгәрешсез диярлек Алтын Урдадан кабул ителгән һәм шул рәвештә яшәгән дә. Хәбәр йөртүчеләрнең туктап ат алыштыру урыннары «ям» дип, хәбәр йөртүче атлылар «ямчылар» дип аталган, шушы төрки сүз «ямчы» русчага «ямщик» булып кереп киткән. Хәзерге заманда да почта коммуникацияләрнең иң гади һәм популяр чарасы булып калып, үз вазифасын үтәп килә.




Тормышыбызга интернет нык үтеп кергән заманда элемтә бүлеге хезмәткәрләренең эше берникадәр дәрәҗәдә арткы плангарак күчте кебек. Виртуаль дөньяда аралашу, интернет киңлекләрендә электрон хезмәтләрдән файдалану элемтә бүлегенең эшчәнлегенә тәэсир итсә дә, авыл җирлеген элемтә бүлегеннән, тере, җанлы аралашулардан башка һич күз алдына китереп булмый. Сер түгел, интернет белән дус, компьютер белән яхшы идарә итә белүчеләрнең дә күпчелеге торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләргә, акча күчерү, газета-журналларга язылу өчен барыбер элемтә бүлегенә килә. Сирәк-мирәк булса да, конвертларга салып, хатлар яисә открытка юллаучылар да табылып тора әле. Арабызда посылкалар алучы яисә җибәрүчеләр дә юк түгел. Нәкъ




менә бу өлкәдә элемтә бүлеге үз дәрәҗәсен югалтмас, халыкка кирәк булып, шактый еллар яшәр кебек, чөнки интернет кибетләр челтәре тормышка киңрәк керә бара. Тормышның тагын нинди яңалыклар тәкъдим итәсен белмибез – тормыш үзгәрә тора, ә почтаның кирәге бетми. Бетмәс тә!

Элек почта хезмәткәрләре һәрбер йортта көтеп алынган кунакларның берсе иде. Кочак-кочак газета-журнал китереп, күптән көтелгән хат тапшырып, йортка шатлык, күңелгә рәхәтлек өстәп йөрүче изге бер зат кебек иде алар. Дәһшәтле сугыш елларында да һәрбер йортта, һәрбер окопта, землянкада хат ташучыны «дүрт күз» белән көтеп алганнар. Яңгыры-карына, көн кызуына, дошман ядрәләренең баш очыннан сызгырып очуына карамастан, хат ташучы өчпомаклы хатларны тиз арада ияләренә ирештерергә ашыккан.



Мәрзия апа Хәсәнова.

Бер карашка ансат кына тоелса да, тиешле нәрсәләрне тиешле вакытта тиешле җиргә җибәрү, матбугатка яздырып план үтәү, пенсия өләшү нәкъ тә менә элемтә хезмәткәрләре җилкәсендә. Ни генә булмасын, элемтә хезмәткәрләре белән беррәттән, хат ташучыларның да төп вазифасы – матбугат тарату, пенсия өләшү, хат китерү булсынмы ул – гади халыкка күтәренке кәеф, шатлык бүләк итүгә кайтып кала.

Хәербидә төрле елларда почта-элемтә начальниклары булып эшләгән кешеләрнең кайберләре: Әминә апа, Кашапова Кафия апа, Минвәлиев Нури, Мөхәмmәтҗанова Асия, Вафина Фаилә, Абдуллина Гөлсирә, Вәлиуллина Дамирә, Закирова Мәдинә, Насыйбуллина Сәрия, Маннапова Хәдичә, Садыйкова Гөлнара, Сәхбиева Ләйсән, Хәлиуллина Светлана. 1953–1970 елларда почта начальнигы булып Галәвов Галләм абый эшли.

**Галәвов Галләметдин Галәү улы** 1919 елның 16 августында Хәерби авылында туа. 1936 елда Татар Сараланы авылына барып трактористлыкка укый һәм туган авылына кайтып эшли башлый. 1939 елда армия сафларына алына. Армия хезмәте тулып җиткәндә Бөек Ватан сугышы башлана. Сугышның ахырына кадәр атлы артиллериядә хезмәт итә ул. Сугыш тәмамлануга ук кайтырга да насыйп булмый, армия хезмәтен дәвам итәргә кирәк була.



Сугышта хезмәтнең төрлесе була, аның үлеп калган солдат гәүдәләрен җыюда катнашуы турында билгеле. «Берсендә шулай үлгән солдат гәүдәләрен җыйганда, барабыз кыр буйлап, янымда барган кеше минага эләгеп шартлап күккә очты. Бернинди гәүдә калмады, ә мине алып бәрде, контузия алдым», – дип сөйли торган була Галләм абый. Польшадан Берлинга кадәр баруын сөйләгәнен дә хәтерли балалары. 1946 елның июнь аенда аңа туган авылына кайтырга насыйп була. Кайтуга, Хәербидә колхозда эшли башлый ул. 1953–1970 елларда авылда почта начальнигы була. Авыл халкы арасында аны «Почта Галләм» дип йөртү әнә шул вакыттан калган. Авылдашлары өчен хөрмәтле кеше булган ул. 1972–1984 елга кадәр Столбище урманчылыгында урман каравылчысы булып эшләгән. Почта эшендә дә, урманчылыкта да эшләп алган Мактау грамоталары бик күп Галләм Галәү улының.

1947 елда алар Миңнебай кызы Миңнегаян белән тормыш корып җибәрәләр, тугыз бала үстерәләр, шуларның җидесе бүгенге көндә исән-сау. Галәвов Галләм абый 1994 елның 7 июлендә вафат.



Миңнегаян һәм Галләм Галәвовлар.

Хатыны Миңнегаян апа да сугыш елларының авырлыгын, ашарга ризык юклыгын, кияргә кием, ягарга утын, эшләргә кеше булмавын ачынып сөйли. Төннәрен дә кырдан кайтмыйча, бригадир булып эшләгән ул. Бүгенге көндә, балаларын сөендереп, исән-сау, хәзерге рәхәтлекләргә куанып яши.

Хәерби халкы хат ташучы булып эшләгән Хәмидуллина Мәрьям, Вафина (Маликова) Илнура, Вафина Дария, Мөхәммәтҗанова Гөлсем, Галәвова Сөмбелә һәм Сибиева Лүзәләргә рәхмәтле.

**Галәвова Сөмбелә Шәһмәрдан кызы**. 1951 елның 15 гыйнварында Хәербидә туа. 1973 елның 1 октябреннән 2003 елның 6 октябренә кадәр почта хезмәткәре булып эшли.

**Сибиева Лүзә Әнвәр кызы**, 1951 елның 24 октябрендә Хәербидә туа. 1980 елның сентябреннән 2007 елга кадәр почта хезмәткәре булып булып эшли.

## XXVII БҮЛЕК

## ХӘЕРБИЛЕЛӘР СПОРТТА ДА КӨЧЛЕ

Авыл халкына, төп хезмәтеннән тыш, үз йорт-курасын, өлкән яшьтәге әти-әнисен, башка чыккан балаларын кайгыртырга, йорттагы мал-туарын карарга, туган-тумачага һәм дус-ишкә төрле эшләрдә булышырга кирәк. Барысын да санасаң, тавык чүпләп бетермәслек исемлек чыгар иде. Әмма гел хезмәткә генә чумып яшәми авыл. Концерт-спектаклен әзерләргә дә, район күләмендә оештырылучы үзешчән сәнгать фестивальләрендә, спорт ярышларында катнашырга да өлгерә.

Авыл яшьләрен, балаларны спортка тартучы, кызыксындыру уятучы, бу эш өчен үзенең вакытын кызганмаучы һәм нәтиҗәләреннән тәм табучы кешеләр бар Хәербидә. Барысы турында язып бетереп булмаса да, Хәерби халкын спорт сөяргә өйрәткән кайбер кешеләрне атап китми мөмкин түгел.

**Гатауллин Минвәли Гариф улы** 1947 елның 10 гыйнварында Хәерби авылында Хәмәтгариф Гатаулла улы һәм Камилә Сафа кызы гаиләсендә беренче бала булып туа. Тугыз бала була алар. 1966–1968 елларда армия сафларында хезмәт итеп кайта. 19 ел Хәерби мәктәбендә физик тәрбия дәресләре укыта. Ул вакытта балалар саны бик күп, шулай булса да, һәрберсендә физкультурага мәхәббәт тәрбияли белгән ул. Йөгерү, чаңгы ярышларында Лаеш районы буенча гел беренчелекне бирмәгән Хәерби мәктәбе. Шундый көчле укытучы барын башка авылларда да, мәктәпләрдә дә беләләр һәм андый көндәш булуын белү, ул әзерләгән укучыларның көченә тигезләнергә тырышу башкаларны да алга этәрә. Гадәттә ярышлар якшәмбе көненә туры килгәнгә, ял көннәрен дә балалар белән уздыра Вәли Гариф улы.



Мәктәптән соң, ул бик күп еллар «Хәерби» совхозы амбарында машинист булып эшли. Хәзер лаеклы ялда. Хатыны Диләрә Әнвәр кызы белән өч ул тәрбияләп үстерәләр, алты оныклары бар.

**Гаязов Фәрит Ибраһим улы** 1970 елның 14 маенда Лаеш районы Хәерби авылында туа. Әти-әнисе туган авылларында терлекчелектә эшлиләр. Гаиләдә ул бишенче бала. 1977 елда Хәерби сигезьеллык мәктәбенә укырга керә. 1987 елда урта мәктәпне тәмамлап, Хәерби урта мәктәбендә өлкән пионервожатый булып эшли башлый. 1988 елның декабрендә Совет Армиясе сафларына чакырыла. Тбилиси шәһәрендә һава десанты гаскәрләренең укыту үзәгендә хезмәт итә. Монда ул спорт белән җитди шөгыльләнә. Ел ярым эчендә ирекле көрәш һәм җиңел атлетика буенча спорт мастерлыгына кандидат нормасын үти, старшина дәрәҗәсен ала. 1991 елда армия сафларыннан кайтып, мәктәптә эшли башлый, читтән торып Казан педагогика институтының физик культура һәм тормыш иминлеге нигезләре факультетына укырга керә. 1996 елда бу уку йортын уңышлы тәмамлый. 1991 елда җиңел атлетика буенча Казанда узган Татарстан беренчелегендә беренче урын ала. Шул ук елны мәктәптә дзюдо һәм самбо түгәрәкләре ачып җибәрә. Параллель рәвештә укучыларны татарча көрәш түгәрәгенә дә тарта.



Дзюдо һәм самбо буенча иң яхшы күрсәткечкә беренче булып укучысы Насыйбуллина Гөлназ ирешә. 1999 елда Сергиев-Посад шәһәрендә узган Бөтенроссия турнирында ул беренче урынны ала. Аннан соң Тверь өлкәсенең Ржев шәһәрендә самбо буенча икенче урынны яулый. Татарстан буенча җиңү яулаучы укучылар исемлегенә бу елларда Хөсәенов Ришат, Шәйхиев Радик та өстәлә. 1999 елда дзюдо буенча Сергиев-Посад шәһәрендә узган Бөтенроссия турнирында җиңгән спортчыны әзерләгән өчен Ф.Гаязов медаль һәм диплом белән бүләкләнә.




Татарстан Республикасының физик культура һәм спорт отличнигы таныклыгы.

2013–14 елларда билбау көрәше буенча Шамил Садриев призына Түбән Камада узган ярышларда пьедесталга Харисова Илүзә күтәрелә. 2015 елда Россия беренчелегендә Ахунов Азат көмеш медаль ала һәм аңа еллык степендия дә билгеләнә. Бу укучылар Татарстан беренчелегендә бик күп тапкырлар чемпион булалар. Татарча көрәштә күтәрелеш чоры 2007 елга



1



2



3



4



5




6

1–4. Укытучы Фәрит Гаязов укучылары белән төрле ярышларда; 5. Сабан туе көрәшендә судья; 6. Лаеш районы хакимияте башлыгы М.П.Афанасьев белән.

туры килә. Татарстан беренчелегендә, төрле турнирларда күп җиңүләр яулана, кубок-медальләр алына. Ф.Гаязовның укчылары республиканың бөтен районнарында диярлек булып, пьедесталның югары баскычларына күтәреләләр.

Гаязов Фәрит Ибраһим улы 2011 елда Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгының Мактау грамотасы; 2010, 2012, 2014, 2015 елларда Лаеш районы хакимияте башлыгының Рәхмәт хатлары, 2014 елда республиканың Татарча көрәш федерациясе җитәкчесе Марат Әхмәтовның Рәхмәт хаты белән бүләкләнә.

Фәрит Гаязов 2015 елда республика категорияле хөкемдар таныклыгына ия була. Төрле республика ярышларында хөкемдарлык итә. Хәзерге вакытта югары категорияле физкультура укытучысы. 2017 елда «Татарстан Республикасының физик культура һәм спорт отличнигы» билгесе белән бүләкләнә.

Гаязов Фәрит Ибраһим улы оста гармунчы, җырчы да. Авылдагы, райондагы бер генә бәйрәм дә аның катнашыннан башка үтми. 2018 елның февралендә ул Теләче районында үткән гармунчылар арасындагы ярышта лауреат исеменә лаек була.



**Насыйбуллин Рөстәм Габдулла улы** 1963 елның 20 маенда Хәерби авылында туа. Хәерби сигезьеллык мәктәбен, Лаеш авыл хуҗалыгы техникумын (1986) тәмамлый. Агроном белгечлеге ала. Хәербидә агроном, Лаеш районы Татпотребсоюз әзерләүләр конторасында эшли. 2001 елдан Лаеш районы мәгариф бүлегенең мәктәптән тыш эшләр үзәгендә тренер-укытучы, шул ук вакытта (2006 елдан) Лаеш балалар йортында тренер. 2014 тән Лаеш районы спорт мәктәбендә тренер. 2010 елда «Балаларга өстәмә белем бирү педагогикасы һәм психологиясе» программасы буенча профессиональ әзерлек уза. Санкт-Петербург шәһәрендә П.Ф.Лесгафт исемендәге Милли университетта белемен күтәрә.

Рөстәм Насыйбуллин дзюдо һәм самбо буенча Татарстан, Идел буе федераль округы, бөтенроссия ярышларында, халыкара турнирларда, дөнья беренчелекләрендә күпсанлы җиңүчеләр һәм призлы урын алучылар тәрбияли. Аның кызы – Насыйбуллина Гөлназ – дөнья чемпионы, дзюдо һәм самбо буенча спорт мастеры.

Рөстәм Насыйбуллин кулы астында шөгыльләнеп, төрле дәрәҗәдәге җиңүләргә ирешкән Хәерби балаларын атап үтик: Вафин Азат, Вафин Руслан, Вафина Резеда, Гатауллина Алсу, Зиннәтуллин Рамил, Миңнуллин Айнур, Миңнуллин Илнур, Насыйбуллина Гөлназ, Насыйбуллина Айгөл, Насыйбуллин Фәнис, Насыйбуллина Лилия, Хөсәенов Ришат, Шәйхетдинова Гөлфия, Шәйхиев Радик.

Рөстәм Насыйбуллин «Татарстан Республикасының физик культура һәм спорт отличнигы», «Мәгариф өлкәсендәге казанышлары өчен» билгеләре, «Казанның 1000 еллыгы» медале, Мактау грамоталары, Рәхмәт хатлары белән бүләкләнә.


ДЕПУТАТ ГОСУДАРСТВЕННОЙ ДУМЫ
ФЕДЕРАЛЬНОГО СОБРАНИЯ РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ

БЛАГОДАРСТВЕННОЕ ПИСЬМО

Насыбуллину
Рустему Абдулловичу
Педагогу дополнительного образования
ГБУ для детей-сирот и детей,
оставшихся без попечения родителей «Лаишевский детский дом»

Выражаю Вам слова признательности за Ваш труд на благо детского спорта, личный вклад в развитие и популяризацию спортивного движения.

Уверена, что Ваш спортивный характер, целеустремленность, самоотдача и профессионализм помогут Вам и Вашим воспитанникам добиться самых высоких результатов!

Желаю Вам доброго здоровья, успехов и благополучия!

О.Н. Павлова

Москва, 2018

1


МИНИСТЕРСТВО СПОРТА РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ

ДИПЛОМ
I СТЕПЕНИ

НАГРАЖДАЕТСЯ
Насибуллин Р.А.
За подготовку чемпионки России
по самбо – спорт слепых
в весовой категории до 48 кг.

город Москва, Д\С МГСУ
19 – 22 мая 2017 года

МИНИСТР Колобков П.А.

2


МИНИСТЕРСТВО ПО ДЕЛАМ МОЛОДЕЖИ И СПОРТУ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Диплом
награждается

НАСИБУЛЛИН РУСТАМ
АБДУЛЛОВИЧ
тренер-преподаватель по дзюдо
ДЮСШ Лаишевского муниципального района

ЗА БОЛЬШОЙ ВКЛАД В РАЗВИТИЕ
ФИЗИЧЕСКОЙ КУЛЬТУРЫ И
ЮНОШЕСКОГО СПОРТА
В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН

Министр В.А.Леонов

3


МИНИСТЕРСТВО ПО ДЕЛАМ МОЛОДЕЖИ,
СПОРТУ И ТУРИЗМУ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ДИПЛОМ

НАГРАЖДАЕТСЯ

Насибуллин Рустем Абдуллович
за вклад в развитие борьбы самбо в Республике Татарстан
и подготовку Гульназ Насибуллиной -
победителя первенства мира по борьбе самбо
среди девушек в г.Москва 13-15 октября 2006 года

Министр М.М. Бариев

20.10.2006 г. г.Казань

4


5

1–4. Рөстәм Насыйбуллинның бүләкләре;
5. Хәерби мәктәбе балалары белән ярыштан соң.
















1. Рөстәм Насыйбуллин җитәкчелегендә спорт белән шөгыльләнүче Хәерби балалары; 2–3. Дзюдо һәм самбо ярышларында; 4–5. Р.Насыйбуллин Лаеш районы балалары белән Россия беренчелеге җыеннарында.

## Хәерби авылы балаларының спорт ярышларындагы уңышлары турында төрле елларда басылып чыккан мәкаләләр:

### Хәербинең хәер-фатихасы[1]

Габишево авылындагы өр-яңа мәктәп бинасында берсеннән-берсе мавыктыргыч спорт секцияләре эшләвен күреп, Фәрит хәйран кала. Андый мәктәп салу физик тәрбия укытучысының көченнән килми, билгеле. Ә менә кайбер нәрсәләрне күңеленә сеңдереп куя ул: нигә әле шул секцияләрнең берсен генә булса да үз укучылары өчен оештырмаска? Фәрит Гаязов бигрәк тә дзюдо көрәше белән ныклап кызыксына һәм байтак кына китаплар сатып ала.

1995 елда Хәерби урта мәктәбендә малайларга әлеге көрәш серләре өйрәтелә башлый. Бу минутларда кызлар күперчек ясый, йөгерә, сикерә һәм, әлбәттә, дзюдо алымнарын үзләштерүче малайларны күзәтә. Бигрәк тә Гөлназ мөкиббән китә. Фәрит абыйсының һәрбер хәрәкәтен ныклап өйрәнә ул. Өенә кайткач, күнегүләр дә ясап карый. Көннәрдән беркөнне кыз түзми, укытучысына дзюдо белән бик нык кызыксынуын әйтә һәм дәрестә малайлар белән бергә шөгыльләнергә рөхсәт ала. Тиздән кыз 25 малай арасында да үзенең сәләтле икәнен күрсәтә.

Шул ук елны бишенче класс укучысы Гөлназ Габишевода үткәрелгән ярышта көч сынашып карый. Монда кызлар – кызлар белән, малайлар – малайлар белән көрәшә. Кыз беренче чыныгуны менә шунда ала һәм әледән-әле дзюдо, самбо буенча үткәрелгән ярышларда катнаша. Гөлназ Насыйбуллина бүгенге көндә берничә диплом, Мактау кәгазе һәм истәлекле бүләкләргә ия инде.

1998 ел, декабрь. Гөлназ, Казанның «Батыр» физкультура йортында үткәрелгән дзюдо көрәшендә үз авырлыгындагы (27 килограмм) өч кызны җиңеп, диплом һәм кубок белән бүләкләнә. 1999 елның декабрь аенда Мәскәү өлкәсенең Сергиев-Посад шәһәрендә атаклы көрәшче В.Корпычев хөрмәтенә дзюдо буенча Бөтенроссия ярышлары үткәрелә. Анда 1984–1986 елларда туган яшүсмерләр – барлыгы 36 команда катнаша. Гөлназ шунда, көндәшләрен җиңеп, беренче урынны яулый.

Аннан соң Ржев шәһәрендә үткәрелгән самбо көрәшендә, бары бер кызга гына бирешеп, икенче урынны ала. Ә менә быел Казанның Совет районында Советлар Союзы Герое Н.Липатов призына үткәрелгән самбо бәйгесендә Гөлназ, үз авырлыгындагы (32 килограмм) кызларны җиңеп, кабат беренчелекне яулый. Бу юлы аны медаль, диплом, китап белән бүләклиләр. Ул ярыш 1 ап-

1 Арсланова Ф. Ватаным Татарстан. – 2000. – 1 сентябрь. – №174 (23731).













Хәерби урта мәктәбе укучылары төрле спорт ярышларында.



1



2



3


4



5


6

1–5. Хәерби урта мәктәбе укучылары төрле спорт ярышларында;
6. Чаңгы ярышын оештыручылар.

рельдә үткәрелә. Ә 14 апрельдә Лаеш районы хакимияте башлыгы Анатолий Демидов, Хәерби мәктәбенә килеп, кыю кызның кулын кыса, истәлекле бүләк һәм Мактау кәгазе биреп китә. Анда: «Гөлназ! Без синең белән горурланабыз, киләчәктә дә сынатма!» – дигән сүзләр бар.

Гөлназның кулы җиңел була. Бу көрәшкә аның дус кызлары Резеда, Алсу да тартыла. Быел 21 майда Казанда 1987–1989 елларда туган кызлар арасында үткәрелгән дзюдо көрәшенә хәербиләләр күмәкләшеп китә. Һәм юкка түгел: үз авырлыгындагы үлчәү буенча Гөлназ Насыйбуллина беренче, Алсу Гатауллина шулай ук беренче, Резеда Вафина һәм Радик Шәйхиев өченче урынга лаек була. Монысын Хәерби мәктәбендә зурлап билгеләп үтәләр, «Вафин һәм К°» ширкәте аларның һәркайсына акчалата бүләк тапшыра. Гомумән, әлеге ширкәт (җитәкчесе Радик Вафин) Гөлназга да ярышларда катнашу өчен һәрдаим иганәче ярдәме күрсәтеп килә. Үзләренә күрсәтелгән шундый игътибардан соң малайлар һәм кызларның ничек күңеле үсмәсен?! Алар шул ук составта июнь башында Анапада үткәрелгән ярышларда көч сынашырга чыгып китәләр. Әмма бу юлы берсе дә алдынгы урыннарны яулый алмый. Бу хәл аларның бераз кәефләрен төшерсә дә, берсе дә кул селтәргә ашыкмый. Тагын да тырышып көрәш алымнарын өйрәнә башлыйлар. Әлбәттә, бу җиңүләрдә аларга тренерлары – Фәрит Гаязов, Илнур Гарипов, Рөстәм Сөнгатуллиннар булышлык иткән. Яшүсмерләр бигрәк тә Ф.Гаязовка рәхмәтле. Дөрес, ул хәзер вакытлыча башка хезмәткә алынган. Балалар, ата-аналар, аны яраткан эшенә кире кайтыр, дигән теләктә калалар.

Спорт белән шөгыльләнү яки бу өлкәдә ниндидер җиңүләр яулау өчен махсус биналар булуы шарт, билгеле. Тик моның өчен, беренче нәүбәттә, үҗәтлек һәм оештырып йөрүче кирәк. Хәербидәге мисал шуны раслый.

### Яңа турнирлар һәм ярдәм көтеп[1]

Менә берничә ел инде Хәербидә спорт көрәше секциясе уңышлы эшләп килә. Соңгы ике елда аңа мәктәптән тыш эшләр үзәге тренеры Рөстәм Насыйбуллин җитәкчелек итә. Аның инициативасы буенча балалар өчен авыл янәшәсенә урнашкан элеккеге ял лагере базасында яхшы шартлар булдырылган. РКПЦ «Семруг» заводы директоры (лагерь аның карамагында) З.Сибгатуллин кыш көне балаларга шөгыльләнергә урын булмавын белгәч, бинаны спортзал итеп үзгәртергә рөхсәт бирә. Аның мәйданы милли көрәш һәм дзюдо яратучы яшь спортчыларга туры килә. Спонсор исәбенә җылытылган һәм яктыртылган мәйданы – 140 кв. метр.

1 Сибатов Р. Кама ягы. – 2002. – 5 гыйнвар.

Бүләккә бина алуга, Р.Насыйбуллин аны кирәкле җиһазлар белән баету эшенә керешә. Ул яхшы оештыручы булуы белән бергә, алтын куллы оста да булып чыга. Укучылар атнага дүрт тапкыр шөгыльләнгән тренажерларны Рөстәм Абдуллович үзе ясаган. Монда ял көннәрендә шөгыльләнү өчен Сокуры мәктәбе укучылары да килә.

Секциягә йөрүчеләр һәм ата-аналар маты алырга акча бүлеп бирелгәне өчен мәгариф бүлеге мөдире Н.Филипповка һәм дзюдочыларга 15 пар кимоно бүләк иткән яшьләр һәм спорт бүлегенә рәхмәт белдерәләр.

Хәзер секциядә кырыкка якын бала шөгыльләнә. Теләге булганнар монда килгәнче медкомиссия үтәләр. Көрәшкә беренче сыйныф укучылары да килә. Спорт белән шөгыльләнү балаларның сәламәтлеген ныгыта, аларны тәртипкә өйрәтә. Әйтергә кирәк, монда шөгыльләнгән өлкән сыйныф укучылары арасында тәмәке тартучылар юк.

Хәерби укучылары төрле ярышларда катнашалар. Мәсәлән, Р.Хөсәенов дзюдо буенча республика турнирында икенче урынны алды. Г.Насыйбуллина абруйлы ярышларда призлы урыннарны күп мәртәбәләр яулады. Р.Шәйхиев, И.Миңнуллин, А.Вафин һәм башка кызлар һәм яшүсмерләр Россия масштабындагы турнирларда көч сынашырга әзерләр.

Әлегә Хәерби көрәшчеләре спорт елын тәгәлләп, яңа турнирларга әзерләнәләр.

## Хәербиләләр тагын җиңүчеләр арасында[1]

Шушы көннәрдә Казанның «Тасма» спорт комплексында 1990 елда туган һәм яшьрәк яшүсмерләр арасында Мәскәү районының Кыш бабае призларына дзюдо буенча ярышлар булды. Ачык беренчелектә Хәерби урта мәктәбе командасы да катнашты. Руслан һәм Азат Вафиннар үз үлчәү категорияләрендә икенче урынны яуладылар. Аларга Мактау грамоталары һәм призлар тапшырылды.

## Келәмдә уңыш[2]

1–2 мартта Казанда «Динамо» спорт комплексының көрәш залында «Динамо» Бөтенроссия физкультура-спорт җәмгыяте оешуның 80 еллыгына багышланган республика ярышларында өлкәннәр, үсмерләр һәм кызлар арасында дзюдо буенча көч сынаштылар.

1 Кама ягы. – 2003. – 25 гыйнвар.

2 Насыйбуллин Р. Кама ягы. – 2003. – 5 март.

Ярышларда Хәерби һәм Нармонка урта мәктәпләренең яшь дзюдочылары катнашты.

44 килограммга кадәр авырлыкта Г.Насыйбуллина (Хәерби) беренче урынны алды. Р.Шәрәфиев (35 килограммга кадәр) икенче, И.Муллагалиев (81 килограммга кадәр) өченче урында (икесе дә Нармонкадан).

Ә бер атна элек Магнитогорск шәһәрендә 1987–89 елда тугын яшүсмерләр һәм кызлар арасында Бөтенроссия турниры булды. Татарстан данын Идел буе федераль округының 9 спортчысы яклады. Безнең районнан Г.Насыйбуллина да алар арасында иде. Россиянең көчле дзюдочылары белән кискен көрәшеп, ул тугызынчы урынга чыкты. Дзюдочылар 21–23 мартта үтәчәк ТР укучылары Спартакиадасы ярышларында катнашачаклар.

## Гөлназ тагын беренче[1]

ТР Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә үткәргән ТР укучыларының IV Республика спартакиадасының кызган чагы.

Казанның «Батыр» спорт комплексы базасында 11 апрельдән 13 енә кадәр 1987–88 елларда туган үсмерләр һәм кызлар арасында дзюдо буенча шәхси команда ярышлары булып үтте. Анда безнең районнан Нармонка һәм Хәерби урта мәктәпләренең яшь спортчылары катнашты. 44 килограммга кадәр авырлыкта Хәерби урта мәктәбе укучысы Гөлназ Насыйбуллина беренче урынны алды, ә Шуран мәктәбе укучысы Сергеева Марина II урында (32 килограммга кадәр авырлыктагы кызлар арасында).

## Беренче урын тагын бездә[2]

Сентябрь аенда Казанда ир-егетләр һәм хатын-кызлар арасында дзюдо буенча республика чемпионаты уздырылды. Анда спорт мастеры Гөлназ Насыйбуллина катнашты һәм 48 килограммга кадәр үлчәү категориясендә турнирның җиңүчесе булды.

Бу көннәрдә Гөлназ республика җыелма командасы составында 7 октябрьдә Пермь шәһәрендә узачак Бөтенроссия ярышларына әзерләнә.

1 Кама ягы. – 2003. – 19 апрель.
2 Кама ягы. – 2004. – 6 октябрь.

# XXVIII БҮЛЕК

# ХӘЕРБИ АВЫЛЫ XXI ГАСЫРДА

## 1. АВЫЛДАГЫ СӘНӘГАТЬ ОЕШМАЛАРЫ

### «Олероли»

«Олероли» компаниясе 2000 елда шешәле су җитештерү максатыннан оештырыла. Җитештерү 2001 елның августында UAT (Универсаль су технологияләре) Америка фирмасы җиһазларында башлап җибәрелә. «Олероли»ның товар билгесе РФ Дәүләт реестрының товар һәм хезмәт күрсәтү билгеләрендә теркәлгән. Саф-чиста су «Олероли» 84 м тирәнлектәге, агым һәм яңгыр суларыннан абсолют дәрәҗәдә сакланган, составы буенча тотрыклы артезиан коесыннан алына. Скважина Казан шәһәреннән 35 км ераклыкта – Татарстан Республикасы Лаеш районының Хәерби авылында – урнашкан. «2002 елда ТР табигать ресурслары торышы һәм әйләнә-тирәне саклау турында Дәүләт докладлары» буенча бу районда төче, ягъни эчәргә яраклы җир асты суларының торышы аеруча уңышлы санала. «Олероли» суын шешәләргә кеше катнашы беләннән түгел, ә Америкадан кайтарылган автоматлаштырылган Steelhead җиһазы белән тутыралар. Бу су сыйфатының иң зур дәрәҗәдә саклануын тәэмин итә. «Олероли» суының сыйфаты сертификатлар, дипломнар белән раслана. 2001 елдан алып ул «Россиянең иң яхшы суы» күргәзмәләрендә призлы урыннар ала. «Татарстанның 100 иң яхшы товары» конкурсы лауреаты (2004–2006).





«Олероли» суын җитештерү җайланмалары.

«Кулланучылар ышанычы» билгесе иясе (2006), «Милли казаныш» («Национальное достояние») медале белән бүләкләнә (2005, Мәскәү).

### Казан медицина инструментлары заводының стерильләштерү үзәге

Казан медицина инструментлары заводы 2018 елның февралендә Хәерби авылында стерилизация үзәге («КМИЗ Луч») ача. Завод ел саен 600 млн сумлык продукция чыгара, әмма стерильләштерү буенча үз куәтләре булмау сәбәпле, элек әзер продукцияне Мәскәү өлкәсенә алып барып стерильләштерергә туры килә. Бу, әлбәттә, товарның кулланучыга барып җитүендә тоткарлыклар тудыра. «КМИЗ Луч» шулай ук медицина максатларында кулланыла торган күпләп сату техникасы, җиһазлар һәм инструментлар белән сәүдә итә.




1. Заводның гомуми күренеше; 2. ТР Премьер-министры А.Песошин белән заводның җитештерү мәйданчыгында.

## 2. ВЕТЕРИНАРИЯ ПУНКТЫ

Хәербидә 2014 елның җәендә модульле ветеринария пункты ачыла. Ул республика программасы буенча төзелә. Әлеге вакыйга терлекләр сәламәтлеген кайгыртуда хезмәт куючы, куркыныч авыруларга юл куймас өчен профилактика эшләре алып баручы ветеринария хезмәткәрләре һәм халык өчен зур әһәмияткә ия.



Ветеринария пунктында квалификацияле ветеринария ярдәме күрсәтелә. Анда ветеринария табибы кабинеты, даруханә, ясалма орлыкландыру пункты, вак йорт хайваннарына медицина ярдәме күрсәтү клиникасы кабинетлары бар.

## 3. «АУЛАК ӨЙ» («АК КАЛФАК») ФОЛЬКЛОР АНСАМБЛЕ

«Аулак өй» фольклор ансамбле 2018 елның гыйнвар аенда Хәерби авылы мәдәният йортында оеша. Ансамбльне оештыручы һәм җитәкчесе – Роза Хабул кызы Кушмина.

Ансамбльнең эшчәнлегендә төрле яшьтәге 20 дән артык кеше катнаша. Күбесе пенсионерлар. Шулай ук яшьләр һәм балалар да яратып йөри. Ансамбльнең максаты: кешеләрне халык авыз иҗаты үрнәкләре, гореф-гадәтләр, йолалар белән таныштыру, аларны бүгенге көнгә яраклаштырып бирү, туган телебезнең матурлыгын, аһәңлелеген тоя белергә өйрәтү, милли үзенчәлекләрне саклап калырга омтылу, балаларга милли тәрбия бирү. Иң беренче чыгышлары 2018 елның 21 гыйнварында була, аулак өй күренеше күрсәтелә. Зал тулы халык җыела. Бәйрәм барысы бергә басып «Туган тел» җырын җырлау белән тәмамлана. Икенче программа 8 мартка багышлап әзерләнә. Яшьләрнең су буендагы уеннары, кыз яучылау, килен төшерү, кодаларның бер-берсен мактап кара-каршы җырлашулары, килен бирнәсе белән өй бизәү, бәби ашы, бишек җырлары җырлау – болар һәммәсе программаның төп өлешенә керә. Коллектив репертуарында татар халык җырлары: «Урманнарга керсәң», «Гөлмәрфуга», «Җизнәкәй», «Гөлҗамал», «Бас әле станокка», «Челтәр элдем читәнгә» һәм башкалар бар. Коллектив Сабан туе, Комсомолның 100 еллыгы, Әниләр көне, Мәүлид бәйрәме, Яңа ел кичәләрендә катнаша.

Хәзерге көндә ансамбль Бөтендөнья татар хатын-кызлары иҗтимагый оешмасы составына кергән «Ак калфак» фольклор ансамбле төркеме булып тора. Шул сәбәпле исеме дә «Ак калфак» дип үзгәртелә. «Җирле үзидарә советы башлыгы Минзәлия Дамир кызы Минбаеваның ярдәмен һәрвакыт тоеп торабыз. Шулай ук безнең эшебездә алыштыргысыз ярдәмчеләребез – мәктәп директоры Хәмәтгалиева Рузалия Зәки кызы, музыка укытучысы Гаязов Фәрит Ибраһим улы, мәктәпнең укытучылар коллективы һәм ата-аналар комитеты», – ди ансамбльнең җитәкчесе Роза Кушмина.













«Ак калфак» фольклор ансамбле чыгышларыннан күренешләр.












«Ак калфак» фольклор ансамбле чыгышларыннан күренешләр.

## Хәербидә – «Аулак өй»[1]

Бу атнада авылга «Аулак өй»гә кайтасым бар, дигәч, таныш-белеш: «Ник хәзер дә шулай җыелышалармы?» – дип гаҗәпсенеп, сорау арты сорау яудырды. Җыелышалар, әле ничек кенә, дип әйткәнемне сизми дә калдым.

Дөресен әйткәндә, үзем дә борынгыдан калган йоланың бүген ничек үтәсен күзаллап бетерә алмый идем. Җыелырга форсат бар, Хәерби авылының оешуына – 460 ел. Борынгы риваятьләргә караганда, авылның атамасы аңа беренче нигез салучы Хәйретдин би исеменнән калган. Хәерби халкы гомер-гомергә игенчелек, терлекчелек белән шөгыльләнгән. Ул гадәт хәзер дә сакланган. Хуҗалык белән инвестор да, килгән-киткән кеше дә түгел, шушы авылда туып үскән Радик Вафин җитәкчелек итә. Байтак авыллар кечерәеп, картаеп барганда, Хәербидә ел саен яңа йортлар төзелә, урта мәктәп, балалар бакчасы, китапханә, почта, берничә кибет эшләп тора, яңа мәчет салынды. Тик авыл урамнарына моңсулык өстәүче бушап калган йортлар да, саный китсәң, шактыйга җыела. Өлкәннәр – мәңгелек йортка, яшьләр шәһәргә күченгән.

«Аулак өй» карарга шәһәрдән кайтучылар да байтак иде. Клуб сәхнәсендә – яшьләр янәшәсендә биш, алты, җиде дистәне түгәрәкләгән хөрмәтле апалар, абыйлар. Аларның кайберсе әле беренче тапкыр сәхнәгә күтәрелгән. Клуб эче минут эчендә шыгрым тулды. Кайбер авылда яңа, иркен мәдәният йорты төзеп куйсалар да, йөрүче юк, дип уфтаналар. Ә Хәерби клубын саллы акчалар кертеп, яхшылап төзекләндерергә кирәк. Бу хакта район хакимияте дә хәбәрдар, ярдәм итәргә вәгъдә дә бирелгән. Ә артистларга мондый чатаклыклар гына комачау итә алмый.

«Аулак өй»не озак еллар авыл балаларына татар теле, әдәбияты фәне укыткан хөрмәтле остаз Роза апа Кушмина оештырды. Ул башта җирле үзидәрә җитәкчесе Минзәлия Минбаева белән киңәшә. Минзәлия ханым бик теләп ризалаша. Хатын-кызларга күлмәк, алъяпкыч тектерергә булышачагын әйтә. Чара узачак көнне билгелиләр. Роза апаның бер хәбәр салуы җитә: репетициягә ике дистәгә якын кеше килә. Хәер, әзерләнергә дә санаулы көннәр генә калган була. Тегүче Зөлфия Галәветдинова өчен дә йокысыз төннәр башлана: 13 бала итәкле күлмәк, алъяпкыч тегеп өлгертергә кирәк. Мондый чакта каушата да бит әле. Тырышлыгы бушка китмәгән: фирүзә төсендәге күлмәкләр бик килешле иде. «Дәү әниләрнең күлмәгенә, алъяпкычына охшатып, мул итеп тегәргә тырыштым», – ди Зөлфия. Сәхнә тотучылар ак яулыкны әбиләребез кебек язып бәйләп, баш артына төйнәп куйган. Ялтыравыклы галош-

1 Журналист, «Ватаным Татарстан» газетасының хатлар һәм социаль мәсьәләләр бүлеге мөдире Фәния Арсланова мәкаләсе.

ларны кибетче Илдус, ашыгыч кирәк дигәч, төрле авыллардан җыеп алып кайтып биргән. Кыскасы, авыл халкы ул көннәрдә «Аулак өй»гә әзерләнеп мәш килгән.

Менә тамаша башланды. Иң элек күзгә ташланганы – сәхнәне чигүле ашъяулыклар, тастымаллар белән бизәгәннәр. Алгы өлештә шәмнәр тезелгән. Аларның да соңрак кирәге чыкты. Бер ана кызын аулак өйгә барырга өнди. Кызның гына теләге юк, ялындыра. Әнисе: «Өйдә ятып кияүсез каласың», – дигәч кенә ризалаша. Икәүләшеп, аулак өйгә чыгып китәләр.

Кәрия-Зәкәрия уены вакытында аулак өйгә җыелганнарның бөтен осталыклары күренде: җырладылар, биеделәр, шигырь-нәфис сүз турында әйткән дә юк. Җитмешне узган Гөлсем апа Харисованы, гәүдәсен төз тотып, яшьләрчә хәрәкәт белән шулкадәр матур бии дип белми идем. Совхоз эшеннән дә кайтып кермәгән, биш бала табып үстергән ана да бит ул. Мәдинә апа Закирова лаеклы ялга чыкканчы балалар бакчасында эшләде. Сабыр, акыллы бу ханым – Яшел Үзән кызы, ләкин кырык ел яшәү дәверендә әллә кайчан Хәербинекенә әйләнеп беткән. Мәдинә апа җәзадан җиңел котылды: бәбиләр янында эшләгән кешегә ярый инде дип, Әминә Бикчәнтәеваның дүрт-биш юллык «Туп» шигырен сөйләде. Шафик абый Галиев аулак өйле, гармунлы яшьлеген сагынып җыр сузды, Каюм абый Насыйров шаян-шук шигырьләрне тиз ота икән. Алар икесе дә яшь чакларында авылдан читкә китү ягын караган. Берсе – Казанда, икенчесе Чаллыда яшәгән. Олыгайгач, авылга кайтып, матур йортлар салып, шунда төпләнгәннәр. Туган җир туфрагының үзенә тарту көче бар шул. Роза апага шигырь «җене» кагылган. Муса Җәлил, Һади Такташ шигырьләрен сәгатьләр буе сөйләп, үзе генә дә сәхнә тота алыр иде.

«Йөзек салыш» уены башланды. Лаеклы ялга чыкканчы төрле җаваплы урыннарда эшләгән, бала югалту ачылары күреп тә, үз эченә йомылмаган, сыгылса да, сынмаган Илсөя апа Ярмиева кичәдә җырлады, истәлекләр сөйләде, дога укыды. Халкыбызның «Җизнәкәй» җырын Илсур Абдуллин белән бергәләп башкардылар. Илсур гармун уйнауда, җырлауда чын сәнгатькәрләрдән бер дә калышмый. Тормыш арбасын ялгыз иңнәре белән җигелеп тарткан, уңган-булган Рәмзия апа Вафина, Нажия апа Маликоваларның да моңлы тавышлары үзәкләргә үтеп керде. Умартачы Альтап Миңневәлиевнең үзе язган шигыре хатын-кызларга мәдхия булып яңгырады.

Ул көнне Хәербидән Бөек Ватан сугышына киткән каһарманнарны да искә алдылар. 173 кеше яу кырында башын салган. Алар һәм авылыбыз сандугачы Мәхмүзә апа, клуб мөдире булып эшләгән Наилә апалар рухына дога кылынды. Венера Низамова шәм яктысында «Гөлҗамал» җырын башкарганда, сулыш алырга да кыймыйча утырдык. Япь-яшь кызга каян килгән шул-

кадәр моң? Роза апа Кушмина аңа чигүле тастымал бүләк итте. Венера Казан дәүләт авыл хуҗалыгы академиясендә һәм бер үк вакытта башкаладагы театр училищесында да укый. Киләчәктә «Гөлҗамал»ны аның башкаруында зур сәхнәләрдә тыңлап хозурлана алсак иде. Венераның әбисе Сәлимә апа да сынатмады: җырлады, биеде. Юкса, алдагы көнне генә якын туганын җирләгән. Сәлимә апа сәхнәдә чын артистларча сабыр итә белде, хис-кичерешләрен тышка чыгармады. Чибәр Нурхидә апа Зиннәтуллинаның һәр чыгышына авыл халкы гына түгел, ире дә сокланып утырган булса кирәк. Камил абый, сәхнәгә чыгып, кырык елга якын бергә гомер иткән, яраткан хатынына ал розалар бирде. Киленнәр – Резедә, Лилия, Эльвира, Ләйсән, кияү – Ирек тә авылдашлар янында үз кешегә әйләнеп беткән. Бар сәләтләрен күрсәттеләр. Укытучылар – Рузалия Хәмәтгалиева Хәербигә багышланган шигырьләр укыды, тарих битләре буйлап үткәннәргә алып кайтып килде, Фәрит Гаязов «Аулак өй»нең башыннан азагына кадәр гармунын кулдан төшермәде. Шул көннәрдә клуб мөдире вазыйфасына керешкән Илшат Абдуллин җырлап, өлкәннәрне биетте. Кичә Габдулла Тукайның «Туган тел» җырын аягүрә басып җырлау белән төгәлләнде.

Авыл сәхнәсендә өч сәгать дәвамында фольклор, җыр-моң, нәфис сүз тантана итте. Бүген авылда яшәүче өлкәннәр өйдә телевизор карап утырудан тәмам гаҗиз икән. Алар аралашуга сусаган, клубка тартылалар. Сәләтләрен ачардай, кузгатып җибәрердәй кеше генә кирәк. Әнә Роза апа кебек. «Аулак өй»дәгеләр, өйләренә таралып, тынычландылар дип уйламагыз, исәпләре – күрше авылларга барып концерт кую, аннары Казан сәхнәсен яулау. Залда утыручылар арасыннан, их, мин дә катнашыр идем, икенче юлы чакырырсыз әле, дигәннәрен дә ишеттем. «Аулак өй» башланып китте, дәвамлы булсын!




«Ак калфак» фольклор ансамбле чыгышларыннан күренешләр.

## 4. ХӘЕРБИНЕ АМЕРИКАДА ДА БЕЛӘЛӘР!

Россия актеры Оскар Кучера һәм Америка гурманы Глен Куцовский «Russia Today» телеканалының «Taste of Russia» («Россия тәме») программасы командасы белән Хәерби авылына килгәннәр.

### Хәербигә американнар килеп киткән[1]

Лаеш районы, Хәерби авылында актер Оскар Кучера һәм Америка гурманы Глен Куцовский булып киткән. Алар юлларны буран күмгән, карлы, салкын кышта Хөснетдиновлар йортына килеп кергән. Әлеге юлаучыларны – «Russia today» телеканалында «Taste of Russia» («Россия тәме») программасын алып баручыларны татарның яшәеше, ризыгы, гореф-гадәтләре кызыксындыра икән. Кунакчыл татар өенә килеп кергәч, аннан тиз генә чыгып китеп булмый бит инде. Бигрәк тә нарат бүрәнәле өй эченә бәрәңге катыш ит, суган исләре чыгарып, мичтә зур бәлеш пешкәндә. 82 яшьлек Минсәйдә апа Хөснетдиновaның әлеге йорты бик күпләрне үзенә тарта. Бер үк ишегалдында икенче өйдә улы яши. Минсәйдә апага Бөек Ватан сугышына кадәр салынган, әби-бабайдан калган бу йорт кадерлерәк. Хәзер бер-берсенә ике тамчы судай охшаш катлы-катлы коттеджлар белән беркемне дә шаккаттырып булмый, чөнки алар күп. Миче сакланган йортны эзләп табарга кирәк. Мичле йорт Хәербидә дә өчәү генә. Узган ел монда артистлар клип төшереп киткәннәр иде.

Минсәйдә апа беркемне кире бормый, мич алды коймагы белән сыйлый. Американ Гленның бәлешкә исе киткән. Баштарак, ялындырган кыяфәт чыгарса да, тәмен белеп алгач, «Ә тагын ярыймы?» – дип үзе тәлинкәсен суза башлаган. «Тәм-томнарыгызда – бәлештә, бәрәңге пәрәмәчендә, кыстыбыйда калорий күп, сез ничек шундый зифа соң?» – дип тә сораган ди. Татар хатын-кызларының матурлыгына сокланган ул. «Авыл халкы тәмле ашый да, җиң сызганып эшли дә», – дип җавап биргән аңа җирле үзидарә җитәкчесе Минзәлия Минбаева. Хөснетдиновлар ишегалдындагы абзар-кура тулы мал-туарны күрсәткәннәр. Анда – атлар, бозаулар, сарыклар, кош-кортлар... Бер хуҗалыкта гына әле бу. Чит ил кунагы моңа да гаҗәпсенгән. Аны күрше Травкино авылындагы дөяләр фермасына да алып барганнар. Кышкы авылны, аның якты йөзле халкын бик ошаткан Глен Куцовский. Ә хәербиләр Америка кешесенең татарча сөйләшергә тырышуына сокланган. Сүзләрне бик тиз отып ала ди. Киткәндә дә татарча рәхмәтләр әйтеп саубуллашкан. Җәй көне тагын киләм дигән, бу юлы инде берничә көнгә – кунача.

---

1 Журналист, «Ватаным Татарстан» газетасының хатлар һәм социаль мәсьәләләр бүлеге мөдире Фәния Арсланова мәкаләсе.













# XXIX БҮЛЕК

## 1. ШИГЫРЬЛӘР, ҖЫРЛАР (АВЫЛ ТАЛАНТЛАРЫ ИҖАТЫ)

### Мәрзия Вафина шигырьләре

#### Балалар киткәч

(*Оныгым Айдарга*)

Диванда уенчык аю
Йоклый күңелсез генә.
Айдар киткәнгә моңая –
Сез бит белмисез генә.
Мин дә сагынам, песикәем,
Мурзик, белдермим генә.
Бәлки, син дә уйлыйсыңдыр,
Миңа сиздерми генә.

Әйдә, ярар, тынычланыйк,
Тавык-сарыклар карыйк,
Ә кичен, йолдыз калыккач,
Роза апаңнарга барыйк.
Ә бәлки, алдагы ялга,
Тагын берәрсе кайтыр –
Өйнең эчен нурландырып,
Матур итеп таң атыр.

*1995 ел, 2 февраль*

* * *

Бик сагындым мин сезне,
Иртә торсам да көтәм,
Кичен ятсам да көтәм,
Сезнең өчен ут йотам.

* * *

Күптән инде Илдарны
Күргәнем юк – сагынам,
Фәритне, Илнур, Айдарны
Барысын да сагынам.

Ә Ленарны һәм Рамилне
Сагынмый дисезме әллә?
Аларның кайтып йөргәнен
Бер дә белмисезме әллә?

*1995 ел, 14 февраль*

#### Песи белән сөйләшү

Идән астында күселәр
Кыштыр-кыштыр йөриләр,
Кимерәләр, бозалар,
Зыян диеп белмиләр.
Ә мәчеләр йомшакта

Рәхәтләнеп яталар.
Йоклап туйгач, аяк язып,
Биләм итеп кайталар.
Ә минем ачуым килә:
«Күселәрне тотмыйсың!

Күкәй, ит, колбаса ашап,
Тагын менеп йоклыйсың.
Ашавын киметсәм, димен,
Күселәр тотар иде,
Идән астын ялт иттергәч,
Чоланга чыгар иде.
Бер көнне кызык булды,
Онга дип чыккан идем,
Тычкан малаен мин үзем
Мурзикка тотып бирдем.

* * *

Әгәр бер-берләре белән
Кара ягып әрләшсәләр,
Хурлашсалар –
Алар өчен мин дә
Янам, көям.
Ялганчыны һәм каракны
Ялагайны сөймим һаман,
Ә шулай да ялганчыга,
Алдакчыга, каракларга
Алгы урын бирә заман.

* * *

Кар бураннар, салкыннары белән
Жир өстенә матур кыш килә.
Бакчадагы miләш агачына
Төрле-төрле кошлар эленә.
Ниндие генә юк бу кошларның:
Озын койрык, кызыл түшлесе,
Ә кайсының
Баш өстендә бүреге бар,
Кикрик төслесе.
Чыпчыклар да куна яннарына,
Бастырыгын сөйрәп килә саескан,
Башка кошлар ала күрмәсен дип,
Песнәк өзеп үк капкан.
Ашагыз, матур кошкайлар,
Монда миләш җитәрлек.
Миләш быел мул булды бит,
Күрегез, исең китәрлек.

*1996 ел*

## Сөмбелә баланнары

Язын ап-ак чәчәк атты
Өй түрендә баланнар.
Кызыгып өзеп тә алды
Чәчәкләрне балалар.
Бар урамга хуш ис бөркеп
Ямьләттеләр урамны,
Балан турында җыр сузып,
Яшьләр узды урамнан.
Озакламый баланкайлар
Ак чәчәкләрен коеп,
Яшел җимешләр утырды,
Тәлгәш-тәлгәш оешып.
Көз килүгә бу җимешләр
Кызарышып пештеләр,
Балалар тагын кызыгып,
Җимешләрен өзделәр.
Баланын кабып карагач,
Ник капканга үкенеп,
Ачылыктан чырай сытып
Йөгерәләр төкереп.
Юк, балалар, ялгышасыз,
Төкермәгез сез аңа,
Бик күп авыру кешеләр
Алалар аннан дәва.

* * *

Авылыма кайтып барам әле
Машинага гына утырып.
Күренмәсме балачагым диеп,
Карыйм күзләремне тутырып.
Җәйрәп яткан басу-кырларыннан,
Урманыннан алмыйм күземне.
Урман юлларында бала-чага,
Ләкин күрмим анда үземне.
Нинди якын миңа бу урманнар,
Нинди матур күлләр, аланнар.
Сәламлиләр кебек якын итеп,
Гүя мине көтеп алганнар.
Күңелемә килә яшь вакытлар,
Урманында җиләк җыйганнар,
Урман-кырда, каланчага менеп,
Тирә-якка карап торганнар.
Шулай үсә кеше туган якта,
Тормыш дөнья буйлап тарата.
Мәхәббәтем һаман арта бара,
Туган якларыма карата.
Безнең эздән хәзер яшьләр йөри,
Йөрсен, эшләсен,
Уйнап көлсеннәр,
Яшьлек гомерен
Бушка уздырмыйча,
Файдалы эш эшли белсеннәр.

*1998 ел, январь*

* * *

Урманнар шаулавын,
Кошларның сайравын
Авылыма кайттым
Сагынып...
Мин кырларга гашыйк,
Авылым сөям шашып,
Туган җирсез яшәү юк сыман.

* * *

Хатларны көтмим инде,
Ни файда соң көткәннән.
Күпме генә көтсәң дә,
Килми инде күптәннән....

* * *

Йоклый алмый яткан төннәрдә мин
Тәрәзәдән күккә карыймын.
Каен ботаклары арасыннан
Янган йолдызларны саныймын.

Әнә, бик еракта, кояш баткан якта,
Балкып яна матур бер йолдыз.
Әллә минем күзгә генә шулай
Күренәме булып бер ялгыз.

Әллә ул да шулай, минем кебек,
Ялгыз гына пыскып ятамы?
Очып барып хәлен белер идем –
Үтеп булмый шул ул араны.

Бераз карап, уйлар уйлап торгач,
Барып ятам кире урынга.
Йолдызлар да миңа хәерле төн
Телиләрдер сыман тоела.

## Роза Кушмина шигырьләре

### Туган авылым

Без бит Хәербинең ул-кызлары.
Монда якын безгә һәрнәрсә –
Язлар житкәч, туган авылыбыз:
«Кайтыгыз сез!» – диеп эндәшә.
Ничә гасыр синдә сабан туйлар
Гөрләп уза, авылым Хәерби!
Якын миңа синең һәр урамың,
Таныш монда миңа һәрбер өй.
Кычытканлы аулак тыкрыкларың
Төшләремә керә кайвакыт.
Сабан туе житсә, туган авылым,
Торасың син үзеңә тартып.
Күпме гомер үткән:
Кар-яңгырлар яуган,
Күпме яфрак жиргә коелган.
Тагын язлар житкән,
Бер күрешү өчен
Балаларың монда жыелган.
Гомер үтәр-китәр, ә сабантуй?
Сабантуй һәм авыл калачак!
Алар безнең дәвам:
Уллар, кызлар белән
Киләчәк елларга барачак.
Сабан туе мәңге онытылмасын,
Шулай киләчәккә барсын ул!
Халкыбызның гореф-гадәтләре
Беркайчан да югалмасын ул!!
Татар онык әти һәм әнисен
«Папа», «мама» диеп йөрмәсен,
Өзелеп әйтсен бала
«Әнием!» – дип,
Туган телен ятка бирмәсен.

### Әнине юксынып…

Әнием, таякка таянып
Киләсеңдер кебек тоела.
Мәңгегә югалтуны тоеп,
Күземнән яшьләрем коела.
Әни, дип өзелә үзәгем,
Әни, дип сулкылдый йөрәгем,
Әнисез төн кебек көннәрем,
Әнине бер күрү теләгем.

Әнием, без алты балаңа
Үсәргә, яшәргә көч бирдең.
Ринатны югалту кайгысын
Күтәрә алмадың, бәгырем.

Әнием, кабереӊ өстендә
Утыра чәчәкләр тирбәлеп.
Ходаем, әнигә Җәннәт бир,
Сорыймын мин синнән инәлеп.

Әнием, рәнжеткән чакларым
Булмыйча калмаган, булгандыр.
Без сиңа күрсәткән хәсрәтләр
Күңеленә таш булып тулгандыр.
Гафу ит, бәхил бул, әнием,
Авырлык китергән булсак та.
Без артык кайнарлар, юләрләр,
Яшь идек бит әле ул чакта.

**Әни өендә…**

Чоланында кипкән мәтрүшкәләр,
Балан тәлгәшләре асылган
Мин шуларны сыйпап елыйм, әни,
Аларга бит кулың кагылган.
Балаларга суык тигән чакта
Эчертермен диеп җыйгансың,
Юкә чәчәкләрен дә киптереп
Хасиятләп төреп куйгансың.
«Туган якның әреме дә татлы,
Кычытканы чакса – файдалы.
Балаларым, авырсалар, эчәр,
Бөтнек җыеп куйыйм, каяле...» –
Дигәнсеңдер, әни, белгәнсеңдер
Бу үләннәр безгә кирәген.
Җиһаннарга сыймас яратуны
Сыйдыргандыр олы йөрәгең.
Якты бу дөньяны, табигатьне,
Тормышны син өзелеп яраттың.
Ак буранлы кыштан,
Ләйсәнле яңгырлардан
Яшәү өчен үзеңә көч таптың.
Салават күперле,
Җиләкле җәйләрдән
Илһам алып, әни, яшәдең.
Шыбыр-шыбыр
Яңгыр булып яудың,
Яшен булып та син яшьнәдең.
Алтын көзләр җитсә,
Дулкынланып,
Мәктәбеңә, әни, кузгалдың.
Синнән белем алган күпме бала
Зур тормышка таба юл алды.
«Лаеклы ял» диеп озаткач та,
Мәктәп диеп типте йөрәгең.
Балаларны аң-белемле итеп
Күрү иде бөтен теләгең.

* * *

Сиксән биш ел типкән йөрәге
Бер минут дигәндә тукталды.
Әнием җаннарын биргәндә
Чайкалып куйды күк җир шары.
Соң тапкыр күрик дип әнине,
Җыелып туганнар кайттылар.
Хәсрәтле чакларда
Бергәләп җыелгач,
Җиңелрәк үтәләр кайгылар.
Син киткәч, йөгереп кайттылар
Гөлназың, Фәридә һәм Алсу,
Елыйлар «әби» дип, өзелеп,
Аларга бик авыр һәм моңсу.
Алсу-ак яңаклар буенча
Энҗедәй яшьләре агалар.
Әйтерсең кебек син шулвакыт:
«Туктагыз, чү, сабыр, балалар!»
Булат та, Айрат та елыйлар,
Моңаеп сызлана Гөлфирә.
Кап-кара күзләрен
Яшь белән чылаткан
Кечкенә киленең Әлфия.
Малайлар, оныклар, кияүләр
Әнине күтәреп бардылар.
Авылның картлары, яшьләре
Елашып озатып калдылар.
Февральнең бер салкын көнендә
Әнине кабергә салдылар.
Уллары, кызлары, оныклар
Шул көндә кайгыга калдылар.
Өзелеп елама, Гөлнара,
Әнинең кабере өстендә.

Ходайдан вакытлар житкәндер.
Без соң ни? Без бит бик кечкенә.
Елама, сеңелем, елама,
Кабергә таммасын күз яшең,
Әҗәлдән берәү дә калмый бит,
Нишлисең? Түзәсең, түзәсең…
Сеңелем, Гөлшатым, һәрвакыт
Әнинең чәчләрен тарадың.
Урынга егылгач, иң әүвәл
Әнине алып син карадың.
Әнием, бу якты дөньяда
Без диеп кенә син яшәдең.
Шатлансаң, без диеп шатландың,
Без диеп тамдылар яшьләрең.
Бу озын гомереңнең юлында,
Калмагандыр синең күргәнең,
Гел шулай яшәрдәй тоелдың,
Искә дә килмәде үләрең.
Киттең дә бардың син беркөнне –
Эленеп калды тик күлмәгең…
Яшәргә тырышып борнаган
Тәрәзә төбендә гөлләрең.
Сине бик сагынып моңая
Өстәлең, китаплар һәм өең.
Сагына балалар, оныклар,
Сагынадыр ике песиең.
Өеңә кергәндә, әнием,
Чыгарсың шикелле каршыма.
Әйтерсең кебек син: «Балалар,
Мин риза, мин бәхил барсына».
Кияү дип, килен дип тормадың –
Барысын бертигез яраттың.
Тартылдык һәрвакыт без сиңа,
Син безгә җылылык тараттың.
Ринатың артыннан, әнием,
Җаныңда вулканнар кайнады.
Чын татарча сабыр кичердең,
Әни, син бу олы кайгыны.
Зәңгәр күзле киленем – Вәсиләм,
Василёгым – зәңгәр чәчәгем
Ялгызы калды дип өзелдең,
Гел аны уйлап син яшәдең.
Ходаем, бер Аллам, әнигә
Җәннәтнең түреннән урын бир,
Ә калган гомерне әнисез яшәргә
Безгә дә түзем бир, түзем бир.

*2006 ел.*

* * *

**Галимҗан Гайнетдинов шигырьләре**

Лаеш ягы – туган ягым,
Сиңа бәйле язмышым.
Минем өчен син – серле күл
Ә мин синең камышың.
Шул күлеңнең, мин, ярында –
Янган учак ялкыны.
Җәйге эссе көннәрендә
Саф суының салкыны.
Ак каеннар чайкалалар
Лаеш күл ярларында.
Томан булып болыт төшкән –
Йөзә Кама суында.
Туган ягым, синнән башка
Берни юк кебек миңа.
Шуңа күрә теләп яшим
Муллык, иминлек сиңа.
Кыр казлары кычкыралар
Лаеш күл камышында
Туган ягым, мин бер казың,
Ә син – күл, язмышымда.

* * *

Лаеш ягы – икмәк ягы,
Сөт елгалары ягы.
Якташларым, сез үстергән
Бакчалар, гөлләр ягы.

Лаеш ягы – Кама ягы,
Балык ягы, ит ягы.
Якташларым, сез яулаган
Даннар, уңышлар ягы.

Лаеш ягы – эшлеклеләр,
Зур төзелешләр ягы.
Яңалыкларга таянган
Заманча эшләр ягы.

Лаеш ягы – кунакчыл як,
Ачык йөзлеләр ягы.
Чын дуслыкның кадерен белгән
Безнең якташлар ягы.

Лаеш ягы – зәңгәр күлләр,
Яшел урманнар ягы.
Киң болыннар һәм аланнар
Елга-көймәләр ягы.

Лаеш ягы – чибәр кызлар,
Уңган егетләр ягы.
Үзгәрешләр, яшәрешләр,
Чын яңарышлар ягы.

Лаеш ягы – чал тарихлы,
Ата-бабалар ягы.
Бабайлардан мирас булган
Җиргә мәхәббәт ягы.

Лаеш ягы – телгә кергән
Ачы шулпалар ягы.
Шул шулпаны эчкәннәрнең
Моң-зарын саклар ягы.

Лаеш ягы – заманында
Богаулы юллар ягы.
Шул юллардан Себер киткән
Бик күп язмышлар ягы.

Лаеш ягы – моңлы яклар,
Батыр солдатлар ягы.
Илне саклап һәлак булган
Бик күп якташлар ягы.

Лаеш – сәясәтче шагыйрь
Державин туган як ул.
Рәсәйгә олы шәхесне
Үстереп биргән як ул.

Килегез Лаеш ягына
Безнең якта яшәргә.
Безнең белән бергәләшеп
Яшен кебек яшьнәргә!

## Гөлүсә Насыйбуллина шигырьләре

### Хәербием

Кыйгак-кыйгак
Казлар каңгылдаша,
Тау астының зәңгәр күлендә.
Тормышымның кадерле бизәге
Син, авылым, күңел түремдә.
Хәербием минем, туган оям,
Тирбәләм синең кочагында.
Сагынып кайтам еракләрдан
Җылынырга дип учагында.
Язлар җитсә, алма бакчаларың
Әкият иленә әйләнә.
Ташып ага Мишә елгаларың,
Гөлләр белән йөзең ямьләнә.

Кояш нурларына үрмәлидер
Җиләкле Миләүшә тауларың.
Шат күңелле синең балаларың,
Саф күңелле сөйгән ярларың.
Якын миңа синең урамнарың,
Урманнарың, болын-кырларың.
Бүләк итәм сиңа, Хәербием,
Күңелемнең барлык моңнарын.
Чит җирләргә ташласа да язмыш,
Яшимен мин сиңа табынып.
Кайтып киләм кабат урамыңнан,
Яшьлек эзләремне сагынып.

### Гаилә

Гаилә!
Ходай аны безгә
Изге оя итеп яраткан.
Адәм белән Һава мәхәббәтен
Җаннарыбыз аша тараткан.

Пар канатлар куйган иңебезгә –
Тормыш күкләрендә очарга.
Сөю чишмәсеннән суын биргән
Эчкән саен һаман сусарга.

Ерак буыннардан киләчәккә
Сузар өчен нәсел җепләрен,
Язмышларга язып бүләк иткән
Мәхәббәтебез җимешләрен.

Янәшәмдә бүген газиз ярым,
Бердәнберем, тормыш иптәшем.
Ике улым, ике кызым үсә –
Тормышымда иң зур терәгем.

Башларына ак яулыгын бәйләп,
Киеп балаитәкле күлмәген,
Өй түрендә әнкәй дога укый,
Теләп безгә изге теләген.

Әнә шулай гаилә учагында
Тәм табабыз бергә янудан.
Саклый күр, син,
Ходам, газизләрне
Ялгызлыктан, ятим калудан.

## 2. ГЫЙБРӘТЛЕ ҺӘМ КЫЗЫКЛЫ ХӘЛЛӘР

* * *

Миңнебаева Бәдерниса апаны Хәербидә барысы да белә. Бер күч бала үстереп, колхоз эшен дә җимертеп эшләгән апаларыбыздан берсе ул. Колхозда эшләгән акча гына ул балаларны тукландырып торырга җитми. Казан шәһәренең якынлыгы ярап куя. Хәерби апалары Казанга сөт-катык, күкәй, бәрәңге сатарга йөриләр.

Бервакыт, сөт сатылып беткәч, хатын-кызлар авылга кайтырга бер-бер машина килеп чыкмасмы дип көтеп утыралар. Шактый вакыт үтә – ә машина юк. Шунда берсе якындагы кибеткә барып кекс алып килә. Бик тәмләп кенә ашый башлый. Бәдерниса апа да кызыга моңа. «Бу әйбернең исеме ничек?» – дип сорый да кибеткә китә. Юл буе: «Кекс, кекс», – дип кабатлап барса да, кибеткә кергәч, бу сүзне оныта. Шуннан соң ул витринада яткан кекска төртеп күрсәтә дә: «Дайте мне шиштирна», – дип сорый. Кибетче рус хатыны моны аңлап ала һәм көлә-көлә, кексны аңа сатып җибәрә. «Кекс бит чыннан да шиштирнага – шестерня диюе инде – охшаган», – ди Бәдерниса апа. Ул бүген дә исән-сау, оныкларының балаларын тәрбияләүгә үз өлешен кертә.

* * *

Ярмиева Мөнирә апаның ирен 1954 елда явызларча үтерәләр. Берүзе дүрт бала тәрбияләп үстерергә, авыр елларда шул балаларны аякка бастырырга туры килә аңа.

Бервакыт Мөнирә апа сыерын суйдыра да, итен Казанга илтеп сатарга уйлый. Сыерның башы да бар бит әле, ул аны да шәһәр базарына алып китә. Сыерның колакларын да өтеп капчыгына сала. Ит тә, баш та уңышлы гына сатыла, эш беткәч, ул бер танышына чәй эчәргә керә. «Колакларын гына алучы булмады», – дип кайгыра Мөнирә апа. Дус хатыны югары этажда тора икән. Ул мондый киңәш бирә: «Син, Мөнирә, подъездга чыккач, баскычтан төшкәндә кычкырып төш. Бездән астагы катта бер яһүд кешесе тора. Аның эте бар. Бәлки колакларны шул кеше алыр», – ди. Мөнирә апа саубуллашып чыгып китә. Тик ишектән чыгуга колак сүзенең русча ничек икәнен оныта. Аптырап тормый тагын үзе. Кино караганда телефоннан сөйләшкән кешенең «слушаю» дигәнен ишеткәне бар икән моның. «Слушаю продаю!» – дип кычкыра бу. Теге яһүднең өйдә чагы була. Чыгып, сатып ала сыер колакларын. «Балаларга ипи алырлык акча бит ул», – дип сөенеп кайтып китә Мөнирә апабыз.

* * *

Галимә тәтә белән Миңнебикә апа – килен белән кайнана – сүзгә киләләр. Хәмәтхан абый кайтып кергәч, икесе дә бер-берсеннән зарлана башлыйлар. Тегеләй дә көйләп карый Хәмәтхан абый, болай да итә. Юк кына бит!

Берсе: «Син хатыныңны гына яратасың», – дип бәйләнсә, икенчесе: «Әниеңне генә яратасың», – дип аптырата. «Икегезне дә яратам», – ди Хәмәтхан абый. «Әни, сине балны яраткан кебек яратам, ә Бикәне — тозны яраткандай», – дип тә өстәргә онытмый зирәк ир.

Галимә тәтә сөенеп чыгып киткәч, хатынына әйтә: «Миңнебикә, мин бал ашамыйча ел буе да тора алам, ә тозсыз бер көн дә яши алмыйм», – ди. Өчесе дә мәрхүмнәр инде. Искә алуыбыз дога булып барсын!

## Изгелек җирдә ятмас[1]

Әтием белән әниемнең якты истәлегенә багышлыйм.

Кыскача гына үзем белгән ике очрак турында сөйләп китәсем килә. Ник дисәгез, бу хәлләр, бер яктан караганда, көн дә очрап тормаса да, гади тормыш күренешләре. Икенче яктан, ул Хәерби халкының холкы, тәрбиясе, күрше руслар белән мөнәсәбәтләре турында уйландырырлык, бүгенгебез белән чагыштырып, гыйбрәтләндерерлек тарихи вакыйга да. Ә иң мөһиме – сезнең болардан үз нәтиҗәгезне ясавыгыз.

Беренче хәлне мина әнием Камилә Гайнетдинова сөйләде.

Әниемнең кечкенә чагы, ничә яшь булганын төгәл генә әйтә алмыйм, бер 5–6 яшь тирәсе булдымы икән. Авылда бик көчле янгын чыга. Бу эссе җәй көне. Нәни кыз бик каты курка, ул үзенең кая чапканын да белештермичә, чаба да чаба. Артына борылып карый, ә ут аның артыннан чапкан сыман күренә. Шуңа күрә ул туктамыйча йөгерә һәм Караишево (Каришә) авылы кырыена килеп чыкканын сизми дә кала. Авыл кырыенда балта осталары бура бурыйлар. Болар рус кешеләре. Елап йөгергән, хәлдән тайган баланы күреп: «Син кем кызы?» – дип сорыйлар. Ә әни русча аңламый, шуңа күрә җавап бирә алмый. Бу абзыйлар русча аңламаган бала Кирби авылыныкы булырга тиеш диеп нәтиҗә ясыйлар. Берсе әнине кулына күтәреп авылга китерә. Кем баласы икәнен кешеләрдән сорый-сорый, ул абзый әнине өенә кертеп, әтисе Вафа баба кулына тапшыра.

Иң изге эшләрнең берсе шушыдыр диеп уйлыйм. Бу хәл шулай ук рус халкы белән татар халкының мөнәсәбәтләре яхшы булуын да раслый.

---

1 Сафина (Гайнетдинова) Минниса Салих кызы сөйләгәннәрдән.

Икенче хәл минем кечкенә чагымда булды, ул хәлгә мин үзем дә шаһит.

Бик каты буранлы көндә әти (Салихҗан Гайнетдинов) белән әни ат чанасына утырып Столбищедан авылга юл тоталар. Ул вакытта Саламыково авылы аркылы йөриләр иде. Ат авырлык белән генә атлый, чөнки юл юк, кар күмгән, кул сузымында берни күрерлек түгел, буран көчле. Әти белән әни алай да юлда бер кара күч сыман нәрсә шәйләп алалар. Әти инде безнең сугышның кайнаган урыннарында йөреп кайткан кеше, табигате буенча да батыр, шуңа күрә ул куркып тормый, ат чанасыннан сикереп төшә дә, карга бата-бата шул кара күч янына йөгерә. Караса – кар астында кеше ята, аңсыз, аның иңбашы гына карга күмелеп бетмәгән була. Әти юлаучыны җилкәсеннән тота, әни аяк ягыннан, һәм алар бу кешене, кем икәнлеген дә белмичә, ат чанасына салып өйгә алып кайталар. Мин әни белән әтинең ул кешене төреп җылытканнарын, аяк кулларын аракы белән уганнарын хәтерлим. Бу инде кич иде, йоклый торган вакыт, йоклап киткәнмен, ә иртә белән мин уянганда әти һәм бу абзый русча сөйләшеп өстәл янында утыралар иде. Әни сый тезеп йөри. Бу кеше Караишево кешесе булып чыккан. Әлбәттә, ул зур рәхмәтләр укып китте, әти белән әни очрамаса, аның исән калуы икеле булган бит инде. Әти ат җигеп, ул кешене авылына илтеп куйды.

Нәрсә әйтәсем килә: Әти белән Әни безнең өчен һәрвакыт һәм һәрьяктан үрнәк булдылар. Алар изгелек кылып яшәделәр. Аларның әйткән сүзләре дә, кылган эшләре дә бик зур ихтирамга лаек.

## ЙОМГАК

